# ГАРӘПЧӘ-ТАТАРЧА-РУСЧА

# алынмалар СҮЗЛЕГЕ

М. И. Махмутов, К. З. Хамзин, Г. Ш. Сайфуллин

# АРАБСКО-ТАТАРСКО-РУССКИЙ СЛОВАРЬ
## ЗАИМСТВОВАНИЙ

(АРАБИЗМЫ И ФАРСИЗМЫ
В ЯЗЫКЕ ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЫ)

С приложением
справочника по арабской грамматике,
составленного М. И. Махмутовым

I том

Издательство «Иман»
Казань 1993

М. И. Мәхмутов, К. З. Хәмзин, Г. Ш. Сәйфуллин

# ГАРӘПЧӘ-ТАТАРЧА-РУСЧА АЛЫНМАЛАР СҮЗЛЕГЕ

(ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА КУЛЛАНЫЛГАН ГАРӘП ҺӘМ ФАРСЫ СҮЗЛӘРЕ)

М. И. Мәхмүтов төзегән гарәп теле грамматикасы белешмәсе кушымта итеп бирелде

I том

«Иман» нәшрияты
Казан 1993

Редакторлары:

*Р. С. Газизов,*
*М. Г. Гыймадиев, И. Г. Гыйльфанов*

Сдано в производство 7.09.93 г. Подписано в печать 14.10.93 г. Объем 15 п. л. Тир. 10000. Зак. Я-564. Отпечатано в типографии Татарского газетно-журнального издательства. 420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.

# ТӨЗҮЧЕДӘН

80 нче елларның уртасында җәмгыятьтә башланып киткән демократизация процессы Россиядәге рус булмаган халыкларның милли хәрәкәтенә киң юл ачты. 1991 нче елны Татарстан суверенитеты турында Декларация кабул итү милли мәдәниятне торгызу эшендә яңа этап булды; тел, әдәбият тарихы һәм татар халкының үзенең чын тарихы тирәнтен өйрәнелә башлады.

Татар галимнәре үз язмышлары һәм басма хезмәтләре өчен борчылмыйча гына эшли башладылар; алар татар һәм гарәп мәдәнияте мөнәсәбәтләре тарихы, Ислам дине мәсьәләләре буенча китап-мәкаләләрен ачыктан-ачык мәйданга чыгара башладылар. Татар мәктәбен торгызу, яңарту һәм ана телендә укыту өчен кызу эш башланды.

...Мең елга якын татарлар гарәп язуыннан файдаланалар, милли мәктәпләре житәрлек күп була, XX йөз башында, башка халыклар белән чагыштырганда, Россиядә иң укымышлы халыкларның берсе була. Ләкин 20—30 нчы елларда милли мәдәният зур зыян күрә: халыкның теләге белән исәпләшмичә, ике мәртәбә алфавит алмаштырыла, өлкән буынны ана телендә надан калдыралар, яшь буынны элекке бай әдәби мирастан аералар, мәхрүм итәләр. Гасырга якын коммунистлар партиясе тарафыннан Ислам мәдәниятен эзәрлекләү нәтиҗәсендә милли традицияләргә сусаган халык, рухи таланганлыгын сизеп, озак еллар тыелып торган дини китапларга сузыла.

Лексикасыннан меңләгән гарәп сүзе һәм гыйбарәләре алып ташланган татар теленә бүген игътибар артты. Элекке вакытта «гарәп» дигәнне надан чиновниклар күрә алмаганнар: алар аны бай Ислам мәдәнияте татар теленә, халыкның культурасы үсешенә, китап, язу таралуына гаять көчле (һәм заманасына күрә прогрессив) йогынты ясаган, мәгърифәт китергән Ислам культурасы белән түгел, фәкать дини йолалар белән генә бәйләп аңлаганнар. Хәтта гарәп хәрефләрен мыскыл итеп «комган хәрефләре» дип йөрткәннәр.

Мәгълүм ки, барлык телләрнең дә үсеш тарихы башка телләрдән сүзләр алу шикелле объектив күренеш белән нык бәйләнгән. Бу күренеш татар әдәби теле тарихына да карый. Башка телләрдән кергән күпсанлы алынмалар катламында гарәп һәм фарсы телләреннән алынганнары да шактый урын алып тора. Бу алынмаларның күп гасырларга сузылган тарихы бар. Аларның күбесе әдәби телдә генә түгел, бәлки халыкның гарәп-фарсыны үз сүзе итеп аңлаган (кабул иткән) сөйләм телендә дә киң кулланыла. Мисал өчен, китап, дәфтәр, хат, мәктәп, иман, сабый, сабыр, вөждан, намус, каләм, сандык һәм меңләгән шуңа охшашлы көн дә кулланыла торган сүзләр татар сүзләре түгел дип, кем генә әйтә алыр икән?

XX йөзнең башына чаклы булган әдәби әсәрләр телендә (китап телендә) гарәп-фарсы сүзләре татар телендә житешмәгән сүзләр өчен

генә түгел, хәтта татар телен чүпли торган һәм аны аңларга кыенлаштырган, төп үз сүзләре урынына да кулланылган. Ләкин XX йөз башында алынмаларның артыграк өлеше саф татар сүзләре белән алмаштырылган. Калган алынмалар фән һәм әдәби телебезнең совет чоры үсеше башланганчы киң кулланышта булалар.

Соңгы ярты гасыр эчендә элек киң күләмдә кулланылган бу гарәп-фарсы сүзләренең күпчелеге татар теленең үз сүзләре, рус һәм интернациональ сүзләр белән алыштырылдылар. Татар теленә бик кирәкле булган меңләгән сүз һәм сүз тезмәләре алып ташланды. Әдәби телебезнең үсешендә мондый үзгәреш эзлеклелек принцибын җимерде, телне ярлыландырды, ул чор әдәбиятын укуда зур гына читенлек тудыру гына түгел, кешенең хәтта фикерләү сәләтенә дә тискәре йогынтысы булды шикелле.

Татар теленең югалткан сүз байлыгын, теле һәм әдәбиятының милли колориты белән бәйле аның синонимикасын, идиоматик тәгъбирләрен кире кайтару һәм торгызу өчен күп еллар тырышлык күрсәтергә кирәк булыр. Моның өчен халыкны фәнни һәм методик әдәбият белән, мәктәп дәреслекләре, сүзлекләр һәм белешмәләр белән тәэмин итәргә зарурдыр.

1965 нче елны бик зур кыенлыклар белән бастырылган «Гарәп-фарсы алынмалар сүзлеге» милли мәдәниятне советлаштыру процессында бай лексикасы таланган татар теле өчен сүз байлыгы хәзинәсе булды. Ул киң катлау укучылар, укытучылар, студентлар, тәрҗемәчеләргә, әдәбият һәм матбугат өлкәсендә эшләүчеләргә, фән әһелләренә югарыда әйтелгән читенлектән чыгуга ярдәм итүче белешмә-сүзлек итеп төзелде. Аннан файдаланучылар арасында рус телен татар теленә караганда яхшырак белүчеләр булуны искә алып, һәм иске әдәбиятны русчага тәрҗемә итүчеләрнең хезмәтен җиңеләйтү нияте белән, сүзләрнең тәрҗемәсе татар һәм рус телләрендә бирелде.

Сүзләр XIII йөз шагыйре Кол Галидән башлап хәзерге чор шагыйрь әдипләренең әсәрләреннән, шулай ук төрле фәнгә караган дәреслекләрдән, элекке чор вакытлы матбугатыннан чүпләп тупланды.

Сүзлеккә, белешмә сүзлек булганга, сүз берәмлеге булган сүзләр генә түгел, әдәбиятыбызда очраган сүз тезмәләре, әйтем һәм мәкаль төсендәге катып калган гыйбарәләр дә кертелде. Сүзләр сүз берәмлеге булган төп формаларында гына алынмады, бәлки әдәбиятта очраган грамматик формаларында да, артикль, бәйлек, зат кушымчалары һ. б. белән бергә килгән хәлендә дә алынды. Мондый сүзләр, татарлар тарафыннан бер сүз итеп үзләштерелгәнлектән, күп очракта кушылып язылалар. Мәсәлән, би-эл-илтифат = билилтифат. Сүзлеккә сүзләр һәм сүз тезмәләре хәзерге татар алфавиты тәртибендә урнаштырылды. Ләкин шуның янында ук шул сүзнең гарәп хәрефләре белән дә (гарәп орфографиясе нигезендә) язылышы күрсәтелде.

Алынмаларга сүзгә-сүз мәгънә бирү белән беррәттән, аңлатмалы сүзлекләрдәгечә, аңлатулар һәм, кирәк тапканда, әдәбияттан алынган мисаллар да бирелде. Мисаллар сүзнең мәгънәсен ачыклау өчен китерү белән бергә, әдәбиятта куллану барлыгын, сүзне бозып яки ясап куллану барлыгын, бик борыннан кулланылуын, яки хәзерге чорда да кулланылуын һ. б. күрсәтү өчен дә китерелделәр; файдаланучыларның

эшен жиңеләйтү өчен мисалларның күпчелеге соңгырак чор, XIX йөз азагы һәм XX йөз башы әдәбиятыннан алындылар.

Сүзлеккә кергән күплек санындагы сүзләр, сүзлектә берлек саны булса, тәржемә ителмәде, берлегенә юнәлтелде, берлеге сүзлектә булмаса, яки берлегендә булмаган өстәмә мәгънәсе булса, аларга тәржемә бирелде. Мәсәлән, мотәгалликат-ис.— 1) Мотәгалликъның күплеге. 2) Якыннар, кардәшләр. 3) грам. Җөмләнең иярчен кисәкләре; Лосус-ис. к. Караклар (берлеге сүзлектә юк).

Бер үк сүз мөзәккәр (м. р.), мөәннәс (ж. р.) формасында килгәндә, мәгънәләрендә аерма булмаса, мөәннәсе тәржемә ителми, мөзәккәренә юнәлтелә, мәсәлән, балига-кара: балигъ. Сүзләрнең русча мәгънәләре дә татарча мәгънәләреннән чыгып бирелде.

Мисаллар, татарча мәгънәгә иллюстрация булганлыктан, русчага тәржемә ителмәделәр. Төп сүзне иллюстрацияләүче сүз тезмәләре, идиомалар, лексик берәмлек булганлыктан, русчага тәржемә ителделәр. Мәсәлән, Кәбаир мн. от Кәбир. Гонахе кәбаир—«грехи великие» дип тәржемә ителде.

Татар теленә кергән гарәп һәм өлешчә фарсы алынмаларының грамматик үзенчәлекләре турында сүзлеккә өстәмә итеп «Гарәп теле грамматикасы белешмәсе» бирелде.

Сүзлеккә материал җыю 1940 нчы елларда башланып, таррак күләмдә 1946 елда ук тәмам була язса да, төрле сәбәпләр аркасында (төзүчеләрнең берсе шул вакытларда ук мәрхүм булды, икенчесе милләтчелектә гаепләнеп кулга алынды) сүзлекне матбугатка чыгару мөмкин булмады. Эш тик 1956 нчы елда гына башланды, һәм СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалының тел, әдәбият һәм тарих институтының Гыйльми советы ярдәмендә дәвам иттерелде. Ләкин аны тәмамлауга һәм рәсми шәхесләрнең шундый сүзлекне чыгару идеясенә каршылыгын җиңеп, гарәп хәрефләрен эзләп табуга (Мәскәүдә генә табылдылар), сүзлекне бастырып чыгаруга күп вакыт сарыф ителде. 30 елга якын элек чыккан сүзлек хәзер сирәк табыла торган китапка әверелде.

Сүзлекне төзегәндә фәнни һәм әдәби әсәрләрдән тыш, төзүчеләр беренче басмада исемләп күрсәтелгән элек төзелгән башка сүзлекләрдән дә файдаландылар. Автор Сүзлекнең икенче басмасын хәзерләргә ярдәм иткән өчен Дилара Шакировага һәм китапны мәйданга чыгарышучы Винерулла Якуповка үзенең рәхмәтен белдерә.

Сүзлекнең яңа басмасы галимнәргә халыкның бай тарихын һәм мәдәни мирасын иске чыганаклардан өйрәнергә, борынгы татар һәм гарәп телләре белән кызыксынучыларга ярдәмлек булыр дип ышанасы килә.

Мирза МӘХМҮТОВ

# ОТ СОСТАВИТЕЛЯ

Начавшаяся в середине 80-х годов демократизация общества открыла возможности для активизации национального движения нерусских народов России. Принятие в августе 1991 года Декларации о суверенитете Татарстана стала новым этапом возрождения национальной культуры, началась активная работа по более глубокому изучению истории развития языка, литературы и подлинной истории самого татарского народа.

Ученые без опасения за свою научную деятельность начали публиковать материалы по истории взаимоотношений татарской и арабской культур, по вопросам мусульманской религии. Началось движение за возрождение татарской школы и обучения на родном языке.

Татары почти тысячу лет пользовались арабской письменностью, имели широкую сеть национальных школ, грамотность населения в начале XX века была одной из самых высоких в России. Но в 20—30-е годы национальная культура понесла большой урон: дважды без согласия народа поменяли алфавит, оставив старшее поколение неграмотным на родном языке, а молодое отрезав от богатой литературы прошлого. Долгие годы под запретом находилась религиозная литература, к которой жадно потянулось население, чувствующее духовное опустошение после почти векового гонения на мусульманскую культуру.

Большое внимание ныне уделяется татарскому языку, из лексики которого были выброшены тысячи слов и выражений арабского происхождения. Невежественные чиновники все арабское связывали с исламом, а не с богатейшей мусульманской культурой, оказавшей в древнее время колоссальное (и прогрессивное по тому времени) воздействие на язык татарского народа, развитие его культуры, письменности, книжного дела, образования.

Как известно, история развития всех языков связана с такими объективными явлениями как заимствование иноязычной лексики. Это относится и к развитию татарского литературного языка. В большом пласте иноязычных заимствований определенное место занимают слова и словосочетания, вошедшие из арабского и персидского языков. Этот слой заимствований имеет многовековую историю, он встречается не только в литературном, но и в разговорном языке татарского населения, воспринимающего эту лексику как свою, татарскую. Кто скажет, что слова китап, дэфтэр, мэктэп, иман, сабый, сабыр, вождан, намус, калэм, сандык и тысячи подобных слов нетатарские?

Вплоть до начала XX века арабские и персидские заимствования употреблялись не только из-за недостатка собственно татарских слов, но многие и вместо них, засоряя тем самым язык и затрудняя его понимание. Однако в начале XX века часть излишних заимствований была заменена собственно татарскими. Они продолжают жить в языке художественной и научной литературы вплоть до начала советского периода развития татарского языка

Большие изменения произошли в лексике литературного языка за последние полвека. Огромное количество ранее употреблявшихся арабо-персидских заимствований вытеснены собственно татарскими, русскими и иностранными заимствованиями. Изгнанию подверглись тысячи слов и выражений, крайне необходимые татарскому языку. Такое быстрое изменение, точнее обеднение, лексики литературного языка нарушило принцип преемственности в его развитии и вызывало значительные трудности не только при чтении литературы прошлого времени, но и оказало отрицательное воздействие на развитие мышления.

Потребуется немало времени для возрождения утерянного лексического богатства татарского языка, его синонимики, идиоматических выражений, связанных с национальным колоритом языка и литературы. Однако все это необходимо обеспечить научной и методической литературой, учебниками для школ, словарями и справочниками.

Настоящий словарь арабских и персидских заимствований, с очень большими трудностями изданный в 1965 году, явился хранилищем той богатой лексики, которой татарский язык, по существу, лишился в процессе советизации национальной культуры. Он представляет собой словарь-справочник для широкого круга читателей татарской литературы, для учителей школ и студентов, переводчиков и научных работников. Для облегчения понимания обрусевшими татарами смысла старотатарских слов, а также перевода дореволюционной литературы на русский язык, значения арабских и персидских слов поясняются на татарском и русском языках.

Словарь составлен на основе лексики произведений татарских писателей и поэтов (с XIII века по настоящее время), на материале периодической печати и татарских учебников по различным отраслям знаний. Он включает как активно употребляющиеся в современном татарском языке арабские и персидские слова и выражения, так и те, которые сохранились лишь в старой письменной литературе.

Слова и словосочетания в Словаре даны в порядке букв ныне действующего татарского алфавита; рядом дается написание слова на основе арабской графики.

Словарь включает в себя как отдельные арабские и персидские слова, так и целые словосочетания в том виде, в каком они встречаются в литературе: с предлогами, определенным артиклем, местоименными аффиксами, падежными окончаниями и т. п. Ввиду того, что они воспринимаются татарами как одно слово, в Словаре дано слитное написание словосочетаний. Например, Би-эл-илтифат = билилтифат.

Наряду с обычным переводом значений многие арабские и персидские слова и выражения имеют более широкое пояснение смысла по принципу толковых словарей. В некоторых случаях приведены примеры из литературы для того, чтобы подтвердить, что: 1) слово заимствовано не в основной своей форме, а в сочетании с различными морфологическими категориями; 2) слово употреблено в ином смысле, чем в арабском (персидском) языке; 3) слово заимствовано очень давно и т. д. Иллюстрации взяты в основном из литературных произведений конца XIX начала XX веков.

Если множественное число арабских слов, встречающихся в Словаре, имеет то же значение, что и единственное, то делается ссылка на его единственное число. Если же единственное число арабского слова в Словаре отсутствует или множественное число имеет дополнительное значение, то в этих случаях дается перевод их значений. Например, **мутагалликат** сущ. 1) мн. от мутагалликъ. 2) Близкие, родственники. 3) грам. Второстепенные члены предложения. **Лосус** — сущ. мн. Воры (единственного числа в Словаре нет).

Арабское слово женского рода отсылается к тому же слову мужского рода, если оно не имеет отдельного значения, например, **балига** — см. балигъ.

Примеры из литературы, иллюстрирующие татарское значение слова, на русский язык не переводятся. Словосочетания и идиомы, иллюстрирующие основное слово словарной статьи, переводятся на русский язык. Например, **кэбаир** мн. от кебир. Гонаһе кэбаир — грехи великие.

Приложением к Словарю дан «Справочник по арабской грамматике», в котором имеются сведения об особенностях арабских (и отчасти персидских) заимствований в татарском языке. Справочник может быть использован и как пособие для ознакомления с элементами арабской грамматики.

Подготовка материала для составления настоящего Словаря началась еще в 1940 году и в меньшем объеме была завершена в 1946 году. Однако из-за некоторых обстоятельств издание Словаря задерживалось (один из составителей умер, другой был репрессирован). Работа была возобновлена в 1956 году при поддержке Ученого Совета Института языка, истории и литературы Казанского филиала АН СССР. На преодоление отрицательного отношения официальных лиц к самой идее такого словаря, поиск арабских шрифтов (составитель нашел их только в Москве) и издание ушло еще несколько лет. Опубликованный почти 30 лет назад словарь стал библиографической редкостью.

При работе над Арабско-татарско-русским словарем заимствований, кроме научной и художественной литературы, были использованы ранее изданные арабоязычные словари, названия которых указаны в первом издании. Выражаю благодарность Диляре М. Шакировой за помощь в подготовке второго издания словаря, Винерулле Якупову — за организацию его издания. Автор надеется, что новое издание Словаря окажется полезным для ученых, изучающих историю народа и его культуру по богатым старым источникам, он может служить учебным пособием для всех, кто интересуется и татарским, и арабским языками.

Казань,
август 1993

## ФАМИЛИЯЛӘРНЕҢ ШАРТЛЫ КЫСКАРТМАЛАРЫ

*Ак.* — Акменла
*В. Җәләл* — Вәкыйфь Җәләл
*Г. Аф.*— Гамил Афзал
*Г. Габ.*— Гафил бине Габдулла
*Г. Газиз* — Газиз Гобәйдуллин
*Г. Ибр.*— Галимҗан Ибраһимов
*Г. Кам.*— Галиәсгар Камал
*Г. Кан.*— Габделҗаббар Кандалый
*Г. Ил.*— Габдерахман Ильяси
*Г. Кут.*— Гадел Кутуй
*Г. Мин.*— Габдерахман Минский
*Г. Рәф.*— Гали Рәфикый
*Г. Сон.*— Габдерахман Сонгати
*Г. Тук.*— Габдулла Тукай
*Г. Хар.*— Габдулла Харисов
*Г. Фәез.*— Габделгалләм Фәезханов
*Г. Чок.*— Гали Чокрый
*Дәрд.*— Дәрдмәнд
*З. Ер.*— Зыя Ермәки
*З. Биг.*— Заһир Бигиев
*З. Гыйф.*— Заһидә Гыйффәт
*З. Һад.*— Закир Һади
*И. Баш.*— Ибраһим Башмаков
*К. Гал.*— Кол-Гали
*К. Нас.*— Каюм Насыйри
*К. Әм.*— Кәрим Әмири
*К. Юлдаш* — Кыям Юлдашев
*М. Сәфилә* дигән шигырьнең авторы (Альманах, 1914 ел)
*М. Ак.*— Муса Акъегетзадә
*М. Бөд.*— Мәхмүт Бөдәйли
*М. Гаф.*— Мәҗит Гафури
*М. Кол.*— Мәүла-Колый
*М. Моз.*— Маһруй Мозаффария
*М. Фәйз.*— Мирхәйдәр Фәйзи
*Мөхм.*— Мөхәммәтъяр
*М. Җәл.*— Муса Җәлил
*М. бәй.* — Мәкәрҗә бәете
*М. Гал.*— Мөхәммәт Галиев
*М. Ук.*— Миргазиз Укмасый
*М. Ур.*— Мәхмүдә Урманчиева (Мозаффария)
*Н. Дум.*— Нәҗиб Думави
*Н. Над.*— Нургали Надиев
*Р. Фәх.*— Ризаэтдин Фәхретдинов
*Сәгъ.*— Габдерахман Сәгъди
*С. Рәм.*— Сәгыйть Рәмиев
*Ут.-Им.*— Утыз-Имәни
*Ф. Хөсни* — Фатих Хөсни
*Ф. Әмир* — Фатих Әмирхан
*Х. Ис.*— Хәбиб Исхакый
*Х. Мөсл.*— Хисаметдин Мөслими
*Хорәз.*— Хорәзми
*Х. Туф.*— Хәсән Туфан
*Х. Чис.*— Харис Чистапули
*Ш. ж.*— Шура журналы
*Ш. Кам.*— Шәриф Камал
*Ш. Баб.*— Шәехзадә Бабич
*Ш. Мәр.*— Ш. Мәрҗани
*Ш. Суф.*— Шәмсетдин Суфи
*Ш. Фид.*— Шамун Фидаи
*Чәй. бәй.*— Чәй бәете
*Ә. У. К.*— Әхмәт Уразаев Курмаши
*Ә. Мос.*— Әхмәтҗан Мостафа
*Ә. Сәгъ.*— Әбрар Сәгыйди
*Җ. Вәл.*— Җамал Вәлиди
*Җ. Юм.*— Җамалетдин Юмаев
*Һ. Сал.*— Һибатулла Салихов
*Һ. Так.*— Һади Такташ

## ШАРТЛЫ КЫСКАРТМАЛАР

*ā* — озын сузык билгесе
*ал.*— алкушымча
*алм.*— алмашлык
*анат.*— анатомия
*астр.*— астрономия
*б.*— берлек
*биол.*— биология
*бот.*— ботаника
*бәйл.*— бәйлек
*геогр.*— география
*грам.*— грамматика
*гф.*— гарәп-фарсы
*гыйб.*— гыйбарә
*дини* — дингә караган
*из.*— изафәт
*ис. с.*— исем сыйфат
*ис.*— исем
*и. сан.* икелек сан
*к.* — күплек, күплеге
*кара:*— кара
*кис.*— кисәкчә
*куш.*— кушымча
*күч.*— күчмә мәгънәдә
*линг.*— лингвистика
*м.*— масдар (исем фигыль)
*м. I.* — беренче бап масдары
*м. II.*— икенче бап масдары
*м. III.*— өченче бап масдары
*м. IV.*— дүртенче бап масдары
*м. V.*— бишенче бап масдары
*м. VI.*— алтынчы бап масдары
*м. VII.*— җиденче бап масдары
*м. VIII.*— сигезенче бап масдары
*м. IX.*— тугызынчы бап масдары
*м. X.*— унынчы бап масдары
*мат.*— математика
*мед.*— медицина
*мин.*— минерал
*миф.*— мифология

## УСЛОВНЫЕ СОКРАЩЕНИЯ

*ā* — обозначение долготы гласного
*анат.*— анатомия
*ар.-п.*— арабско-персидское слово
*астр.*— астрономия
*биол.*— биология
*бот.*— ботаника
*букв.*— буквально
*геогр.*— география
*гл.*— глагол
*грам.*— грамматика
*дв. ч.*— двойственное число
*ед. ч.*— единственное число
*жен.*— женский род
*из.*— изафет
*и. с.*— имя собственное
*ист.*— история
*к.-л.*— какой-либо
*линг.*— лингвистика
*м.*— масдар (отглагольное имя).
*м. I.*— масдар первой породы
*м. II.*— масдар второй породы
*м. III.*— масдар третьей породы
*м. IV.*— масдар четвертой породы
*м. V.*— масдар пятой породы
*м. VI.* масдар шестой породы
*м. VII.*— масдар седьмой породы
*м. VIII.*— масдар восьмой породы
*м. IX.*— масдар девятой породы
*м. X.*— масдар десятой породы
*мат.*— математика
*мед.*— медицина
*межд.*— междометие
*мест.*— местоимение
*метр.*— метрика

*мнс.*— мөәннәс (хатын җенесе)
*м. м.*— мимлы масдар
*мәс.* — мәсәлән
*полит.*– политика
*р.*— рәвеш
*с.*— сыйфат
*сан* — сан
*ст.*— сүз тезмәсе
*сф.*— сыйфат фигыль
*тар.*— тарих
*тер.*— теркәгеч
*ф.*— фарсы сүзе
*фиг.*— фигыль
*ф. из.*— фарсы изафәсе
*фәл.*— фәлсәфә
*хим.*— химия
*шигъ.*— шигырь
*ым.*— ымлык
*ял. ис.*— ялгызлык исем
* — хәзер дә киң кулланыла

*мин.*— минерал
*миф.*— мифология
*м. м.*— масдар мимий
*мн.*— множественное число
*н.*— наречие
*напр.*— например
*осн. зн.* — основное значение
*п.* — персидское слово
*перен.* - переносное значение
*п. из.*— персидский изафет
*полит.*— политика
*поэт.*— поэтический термин
*пр.*— префикс
*пред.*— предлог
*прил.*— имя прилагательное
*пр. д.*— причастие действительного залога
*пр. с.*— причастие страдательного залога
*рел.*— религия
*с.*— союз
*см.*— смотри
*соб.*— собирательное
*ср. пр.*— (сравнительная) превосходная степень арабского прилагательного
*сс.*— словосочетание
*сущ.*— существительное
*фил.*— философия
*фр.*— фразеология
*ч.*— числительное
*част.*— частица
* — употребляется в современном татарском языке.

**Гарәп хәрефләре татар әлифбасында нинди хәреф белән бирелә**

| Гарәп хәрефләре | Татар хәрефләре |
|---|---|
| Мәдле әлиф (آ) | а |
| Фәтхәле „ (اَ) | ә |
| Кәсрәле „ (اِ | и |
| Заммәле „ (اُ) | о (калын)<br>ө (нечкә) |
| ب | б |
| ت، ط | т |
| ج | җ |
| ح، خ | х |
| د | д |
| ظ، ض، ز، ذ | з |
| ر | р |
| س، ص، ث | с |
| ش | ш |
| گ، غ، ع | г |
| ف | ф |
| ك، ق | к |
| ل | л |
| م | м |
| ن | н |
| ۋ، و | в |
| ه | һ |
| Фәтхәле يَ | я |
| Заммәле يُ | йо, йө |
| پ | п |
| ژ | ж |
| چ | ч |

**Какой букве татарского алфавита соответствует начертание арабо-персидской буквы**

| Татарские буквы | Арабские буквы |
|---|---|
| а | آ алиф с маддой |
| б | ب |
| в | ۋ، و |
| г | گ، غ، ع |
| д | د |
| е | — |
| ж | ژ |
| з | ظ، ض، ز، ذ |
| и | اِ алиф с кясрой |
| й | ي (и) |
| к | ك، ق |
| л | ل |
| м | م |
| н | ن |
| о | اُ алиф с даммой |
| п | پ |
| р | ر |
| с | ص، س، ث |
| т | ط، ت |
| у | — |
| ф | ف |
| х | خ، ح |
| ч | چ |
| ш | ش |
| я | يَ и с фатхой |
| ә | اَ алиф с фатхой |
| ө | اُ алиф с даммой |
| ү | — |
| җ | ج |
| ц | — |
| һ | ه |

# А

**А** — ا (Татар һәм гарәп әлифбасында беренче хәреф булып, гарәпчәсе „әлиф“ дип атала. Әлифнең төп язылышы ا формасында булып, сүз башында ул дүрт төрле укыла:

„آ“ формасында язылса — „а“ укыла,

„اَ“ формасында — „ә“, „اُ“ формасында — „ө — о“ һәм „اِ“ формасында язылса — „и“ укыла. Мәсәлән: آن — ан (бик кыска вакыт); آب — әб (ата); اُم — өм (ана); اِبن — ибен (ул, угыл); Әлиф әбҗәд хисабында бер (1) санын белдерә).

Алиф (ا — первая буква арабского алфавита, имеет четыре варианта чтения в начале слова:

آ — а,

اَ — э,

اُ — ө — о,

اِ — и; например:

آن — ан (момент); آب — эб (отец); اُم — өм (мать); اِبن — ибен (сын). Цифровое значение 1).

**Аб** آب *ф. ис.* Су (әдәбиятыбызда күбрәк башка сүзләр белән бәйләнгән хәлдә очрый: *абруй* (йөз суы, авторитет); *абхәят, абелхәят* (тереклек суы); *абераван* (агым су). *Хак ризасы өчен миңа бир аб вә нан.* (Мөхм.)

*п. сущ.* Вода (в татарской литературе часто встречается в фразеологических сочетаниях типа *абруй* — авторитет; *абхәят, абелхәят* — живая вода; *абераван* — проточная вода).

**Абад I** آباد *ис.* Әбәд-нең *к.*

*сущ. мн.* от әбәд.

**Абад II, Абадан** آباد، آبادان *ф. с.* **1.** 1) Һәрнәрсәсе житеш, мәдәниләшкән, төзек (урын). 2) Утрак (җир), халык яши торган урын. **2.** *грам.* Гыйбарәләрдә үзе кушылган исем аңлаткан предметның урынын һәм күплеген белдерә.

*п. прил.* **1.** 1) Обработанный, цветущий, благоустроенный. 2) Населённый (пункт). **2.** *грам.* В словосочетаниях придаёт значению основного слова оттенок изобилия и указывает на его местонахождение.

**Абаэ** آبآ *ис.* әб-нең *к.* *Аh, кем! Абаэмез һәп лихьялы сыйбъян имеш.* (Г. Тук.)

*сущ. мн.* от әб.

**Абдәст** آبدست *ф. ис.* **1.** Төп мәгънәсе: кул юар өчен су. **2.** Юыну, тәһарәт алу. — *п. сущ.* **1.** Осн. зн. вода для мытья рук. **2.** Омовение.

**Абдәстханә** آبدستخانه *ф. ис.* 1) Юыну бүлмәсе, тәһарәт ала торган урын. 2) Бәдрәф. — *п. сущ.* 1) Помещение, место для омовения. 2) Уборная, отхожее место.

**Абелхәят** آب‌الحيات *гф. из. ис.* Мәңгелек суы, тереклек суы. *Ник ләгыйн абелхәятны урлаган?* (Ш. Баб.) — *ар.-п. из. сущ.* Живая вода.

**Абруй*** آبروى *ф. ис.* Абруй, йөз суы, йөз аклыгы, авторитет. *Абруй өчен хәзрәт кызы мәслихәт.* (З. Биг.) — *п. сущ.* Честь, достоинство; авторитет.

**Абүнә** آبونه *ф. ис.* Абүнә, акча түләп язылу (мәс., газетага). — *п. сущ.* Абонирование; подписка.

**Аваз*** آواز *ф. ис.* Тавыш. — *п. сущ.* Звук.

**Авазә** آوازه *ф. ис.* 1) Колак хәбәре, имеш-мимеш хәбәр. 2) Жыр, көй. 3) Тон. — *п. сущ.* 1) Слух, молва. 2) Песня, мотив. 3) Тон.

**Аварә** آواره *ф. ис.* 1) Әвәрә, эшсез, урынсыз йөрүче, бушка йөрүче. 2) Мәш килүче, мавыгучы. — *п. сущ.* 1) Скиталец, бродяга. 2) Увлекающийся.

**Агаз** آغاز *ф. ис.* Баш, башланыш. *Агаз кылу* — башлау, башлап жибәрү. — *п. сущ.* Начало.

**Агуш** آغوش *ф.:* درآغوش قيلماق (дәр агуш кыйлмак) — кочаклау, кочаклап алу. *Бу җария һибә хәбәрен сөйләмәстән, Ибраһимны дәр агуш кыйлмак теләгән.* (К. Нас.) — *п.* Обнять, обнимать.

**Агяһ** آگاه *ф. с.* Белеп торучы; хәбәрдар булучы. *Әгәр хезмәт идәрсәң гайреләргә, үзең хезмәт күрерсең, улгыл агяһ.* (Ут. Им.) — *п. прил.* Сведущий, знающий; осведомлённый.

**Агяһландыру** — искәртү, белдереп, сиздереп кую. — Напоминать, осведомлять, сообщать.

**Адаб** آداب *ис.* 1) Әдәб-нең *к.* 2) Кагыйдәләр. — *сущ.* 1) *мн.* от әдәб. 2) Правила.

**Адабе тәгълим** آداب تعليم *из.* Укыту кагыйдәләре. — *из.* Правила обучения.

**Азад** آزاد *ф. с.* Азат, ирекле, хөр. — *п. прил.* Свободный, вольный.

**Азадә** آزاده *ф. с.* Юмарт, игелекле. *Газәл кычкыручы азадәләнә* (Сайяди). — *п. прил* Щедрый, благородный.

**Азар** آزار *ф. ис.* 1) Әр, шелтә, ачулану, орыш. 2) Азарлау, әрләү, орышу, шелтәләү. *Җан яктан азарыңа һич кинәсез мәфтүнеңем.* (Г. Тук.) — *п. сущ.* 1) Выговор, наказание. 2) Обида, нарекание; порицание, отчитывание.

**Айнә** آينه *ф. ис.* Көзге. — *п. сущ.* Зеркало.

**Акшам** آقشام *ф. ис.* **1.** Эңгер-меңгер вакыт. **2.** Кич белән. *Бүген акшам сәкез сәгатьтә.* (М. Ак.) — *п. сущ.* **1.** Сумерки; вечерняя заря. **2.** Вечером.

**Алиһә** آلهه *ис.* 1) Илаһ-ның *к.* 2) Хатын алла. 3) Гыйшык, мәхәббәт алласы. *Алиһәмне нур томалый дулкыныңда йөздереп.* (Ш. Баб.) — *сущ.* 1) *мн.* от илаһ. 2) Богиня. 3) Богиня любви.

**Алман** آلمان *ис.* **1.** Германияле, немец. **2.** Германиягә, немецка караган. *Борыгыз муеныи комсыз карчыганың, кояш чыксын Алман җиренә.* (М. Җәл.) — *сущ.* **1.** Немец. **2.** Немецкий, германский.

**Аль** آل *ис.* 1) Гаилә, өй җәмәгате. 2) Династия; нәсел. — *сущ.* 1) Семья. 2) Династия; потомство.

**Алям** آلام *ис.* Әләм I-нең *к.* — *сущ. мн.* от әләм I.

**Алят** آلات *ис.* Аләт-нең *к.* — *сущ. мн.* от аләт.

**Аляте җәррахия** — хирургия кораллары. — Хирургические инструменты.

**Аляф** آلاف *сан. к.* Меңнәр. — *ч. мн.* Тысячи.

**Аләт** آلت *ис.* 1) Корал, эш коралы, инструмент, прибор. *Сугышканда хәзер ике төрле аләт белән сугышалар.* (Г. Газиз). 2) Чара, әмәл (хәрәкәттә). — *сущ.* 1) Орудие, инструмент; прибор. 2) Средство (передвижения).

**Аләте нәкълия** آلت نقليه *ст.* Күчерү коралы, транспорт. *Батсачы шунда үзе һәм аләте нәкълиясе.* (Г. Тук.) — *сс.* Средство передвижения, транспорт.

**Алү** آلو *ф. ис.* 1) Алча, әлү (кара җимешнең бер төре). 2) Әлү кагы. — *п. сущ.* 1) Слива, алыча, 2) Алычевая пастила.

**Амаль** آمال *ис.* Әмәл-нең *к.* — *сущ. мн.* от әмәл.

**Аман** آمان *ис. кара:* әман. *Күренмәсен күзгә, аман, раббем, аман.* (Ш. Баб.) — *сущ. см.* Әман.

**Амиз** آميز *ф. с.* Аралаш, катнаш. *Бу мәлгунә карчык ничә сихыр амиз эшләр кыйлмыш иде.* (К. Нас.) — *п. прил.* Смешанный, перемешанный.

**Амин** آمين Шулай булсын! Амин! — Да будет так! Аминь!

**Амир** آمر *сф.* 1) Боеручы, кушучы, боерык бирүче, әмер бирүче. 2) Түрә, — *пр. д.* 1) Повелевающий, приказывающий.

начальник. *Китте Иблис бәй булып, амир булып, остаз булып.* (Ш. Баб.)

**Амиранә** آمرانه *гф. р.* Түрәләрчә боергансыман, боерык бирүчедәй. *Күзең ач! — ди миңа амиранә.* (Һ. Так.)

**Ан** آن *ис.* 1) Бик кыска вакыт. 2) Вакыт, заман. *Бакып туймас идем һәр ан.* (Г. Кан.)

**Араеш** آرايش *ф. ис.* Бизәк, зиннәт.

**Арам** آرام *ф. ис.* 1) Рәхәтлек, тынычлык. 2) Йорт; бүлмә.

**Араэ** آراء *ис. к.* 1) Фикерләр, карашлар. 2) Уйлар, исәпләр.

**Арзу** آرزو *ф. ис.* Теләк, омтылыш. *Сезнең белән юлыкмакны күптән арзу кыладыр идем.* (М. Ак.)

**Ари** آرى *ф. ис. кара:* арам 1.

**Асаеш** آسايش *ф. ис.* 1) Гомуми тынычлык; тәртип; куркынычсызлык, иминлек. 2) Рәхәт.

**Асар** آثار *ис.* Әсәр-нең *к.* *Кыйраәт әйләдем, әзбәрләдем бән җөмлә асарең.* (Г. Тук.)

**Асаре гатика, асаре кадимә** آثار عتيقه، آثار قديمه *ст.* 1) Борынгы (иске заманга караган) әйберләр. 2) Археологик истәлекләр.

**Асим** آثم *сф.* 1) Бозыклык эшләүче; гөнаһ кылучы. 2) Җинаятьче.

**Асия I** آسيا *ис.* Азия.

**Асия II** آسيا *ф. ис.* Тегермән.

**Асияб** آسياب *ф. ис.* Су тегермәне.

**Асла, аслан** آصلا، آصلاً *р.* Һич, һичбер (вакытта), бер дә, беркайчан да. *Дәресләренә асла күңел куймас.* (З. Һад.) *Аның тавышы колагыма аслан керми.* (Г. Кам.)

**Асли** آصلى *с.* Асыл 1- (гә караган).

**Аслия** آصليه *с.* Асли-нең *мнс.*

**Асман** آسمان *ф. ис.* Күк. *Көндә кич*

2) Повелитель; начальник, командир.

*ар.-п.* н. Властно, повелительно, начальнически, в тоне приказа.

*сущ.* 1) Очень короткое время, миг. 2) Время.

*п. сущ.* Украшение.

*п. сущ.* 1) Покой, спокойствие. 2) Здание; комната.

*сущ. мн.* 1) Взгляды, мнения. 2) Мысли, раздумья.

*п. сущ.* Желание, стремление; грёза.

*п. сущ. см.* Арам 1.

*п. сущ.* 1) Спокойствие; порядок; безопасность. 2) Удовольствие.

*сущ. мн.* от әсәр.

*сс.* 1) Древности. 2) Археологические памятники.

*пр. д.* 1) Грешащий; греховный. 2) Преступник.

*сущ.* Азия.

*п. сущ.* Мельница.

*п. сущ.* Водяная мельница.

*н.* Отнюдь не, совсем не, вообще не, никогда.

*прил.* Основной, коренной, главный.

*прил. жен.* от асли.

*п. сущ.* Небо.

*асманга җен, шайтан менә; менгәне берсе бетә, корбан булa.* (Ш. Баб.)

**Астанә** آستانه *ф. ис.* 1) Бусага. 2) Сарай ишеге төбе. *Вәйси бер кабердә бик олуг теш табып астанәгә китерде.* (К. Нас.)

*п. сущ.* 1) Порог двери. 2) Вход во дворец.

**Асыл*** آصل *ис.* **1.** 1) Төп; тамыр; нигез. *Мин бу эшнең аслына дөшәрмен.* (З. Биг.) 2) Башлангыч, чыгыш. **2.** Матур, шәп.

*сущ.* **1.** 1) Корень; основа; суть. 2) Начало, происхождение. **2.** Красивый, прекрасный.

**Ати** آتى *с.* Киләчәк.

*прил.* Следующий, будущий.

**Атиян** آتيا *р.* Киләчәктә.

*н.* В следующем, в будущем, далее.

**Атәш** آتش *ф. ис.* Ут, ялкын. *Бәхак бән нар сачар әтрафә бер атәшле вулканым* (хокук өчен тирә-якка ут чәчә торган ялкынлы вулкан мин). (Г. Тук.)

*п. сущ.* Огонь, пламя.

**Атәшпәрәст** آتشپرست *ф. ис.* Утка табынучы.

*п. сущ.* Огнепоклонник.

**Афат** آفات *ис.* Афәт-нең *к.*

*сущ. мн.* от афәт.

**Афтаб** آفتاب *ф. ис.* 1) Кояш. 2) Кояш яктысы.

*п. сущ.* 1) Солнце. 2) Солнечный свет.

**Афәрин*** آفرين *ф.* Шәп! Яшә! (дигән кебек берәр кешенең сүзен яки эшен яратып, үзен мактап әйтелә торган сүз). *Мең вә миллион афәрин бу сурәтең нәкъкашына.* (Г. Тук.)

*п.* Браво! Прекрасно! (возглас одобрения).

**Афәт*** آفت *ис.* Бәла-каза, зыян, бәхетсезлек.

*сущ.* Беда, несчастье, стихийное бедствие.

**Ахад** آحاد *сан.* Әхәд-нең *к.*

*ч. мн.* от әхәд.

**Ахир** آخر *с.* **1.** Сон, ахыр. **2.** Ахыргы, соңгы.

*прил.* **1.** Конец. **2.** Последний, конечный.

**Ахирел әмер** آخر الامر *из.* Иң ахырда, иң актыкта, иң соңында, соңгы чиктә.

*из.* В конце концов, наконец.

**Ахирәт*** آخرت *ис.* 1. Теге дөнья. 2) Мәңгелек дус. *Әсмабикә җаным, ахирәт.* (Г. Аф.)

*сущ.* 1) Загробная жизнь. 2) Верный, закадычный друг.

**Ахмак*** آحمق *с. кара:* әхмак:

*прил.* см. Әхмак.

**Ахшам** آحشام *ф. кара:* акшам.

*п. см.* Акшам.

**Ахәр** آخر *с.* Башка, бүтән, үзгә, икенче бер. — *прил.* Другой, иной.

**Ашкярә** آشكاره *ф. р.* Ачык, ачыктан-ачык. — *п. н.* Явно, открыто.

**Ашкярә итү** — фаш итү, ачып салу. — Разоблачать.

**Ашна** آشنا *ф. ис.* **1.** Таныш, әшнә, дус, белеш. *Кярханәләрдә күрешеп даныш вә ашна улмышлар иде.* (З. Биг.) **2.** Мәгълүматлы, хәбәрдар. — *п. сущ.* **1.** Знакомый, друг. **2.** Знающий, сведущий.

**Ашпәз** آشپز *ф. ис.* Аш пешерүче. — *п. сущ.* Повар.

**Ашпәзханә** آشپزخانه *ф. ис.* Кухня, аш пешерү бүлмәсе. — *п. сущ.* Кухня.

**Ашъян, әшьян** آشيان *ф. ис.* Оя, кош оясы. *Арамың тупрагы бәхет ашъяни.* (Хорәз.) — *п. сущ.* Гнездо.

**Ашөфтә** آشفته *ф. с.* Борчылган, борчулы. *Бәс ашөфтә хәйран булып мән.* (Мөхм.) — *п. прил.* Взволнованный.

**Аять*** آية، آيت *ис.* 1) Билге; галәмәт, әсәр. 2) Коръән сүрәләрендә аерым җөмләләр, аерым бәетләр. — *сущ.* 1) Знак; метка. 2) Стих Корана.

**Аһу** آهو *ф. ис.* 1) Газәл (матур күзле кыр кәҗәсе). 2) *күч.* Матур, сөекле. *Аһу нәргис күзеңне* (Ә. У. К.) — *п. сущ.* 1) Газель. 2) *перен.* Красивая, любимая.

**Аһәстә** آهسته *ф. с.* 1) Акрын. 2) Йомшак, йомшак кына. — *п. прил.* **1.** 1) Медленно. 2) Мягко. **2.** Тихий, медленный.

**Аһәстә-аһәстә** — әкрен-әкрен, йомшак-йомшак. *Саллаер аһәстә-аһәстә бәни бу мәһде дәрт.* (Г. Тук.) — Тихонечко, потихоньку.

**Аһәң** آهنك *ф. ис.* 1) Тон. 2) Гармония. 3) Мелодия. *Моңсу бер аһәң белән очсыз-кырыйсыз дәрт вә хыяллар көйли.* (Ш. Кам.) 4) Тизлек. 5) Нијат. — *п. сущ.* 1) Звук, тон. 2) Гармония, созвучие. 3) Мелодия. 4) Темп. 5) Цель, намерение.

# Б

**Б** — ب Татар һәм гарәп әлифбасында икенче хәреф булып, гарәпчәсе „ба“ (بَا) исеме белән йөртелә. Әбҗәд хисабында 2 санында йөри. — Вторая буква татарского и арабского алфавита. Цифровое значение 2.

**Ба** بَا *ф. бәйл.* 1) Белән: *батәртиб* — тәртип белән. 2) Чы-че, лы-ле кушымчалары яки *бар* сүзе белән бирелә: *бахәбәр* — белеп торучы, хәбәре бар (кеше); *бафәһем* — аңлы, зирәк, фәһеме бар.

*п. пред.* 1) Обозначает орудийность (если стоит при имени, выражающем предмет неодушевленный): *бакаләм* — пером. 2) Передает значение русского предлога с. *Бафәһем* — с понятием, т. е. понятливый.

**Баб** باب *ис.* 1) Ишек, капка. 2) Бүлек, бүлекчә, параграф; төр. 3) *грам.* Фигыль юнәлеше: үтем бабы, калым бабы. 4) Тема. *Ачылды язар өчен безләрә баблар.* (М. Гаф.) 5) Мәсьәлә. *Мин булам шул вакыт бу бабта мәҗнуннән тиле.* (М. Гаф.)

*сущ.* 1) Дверь, вход. 2) Глава, раздел, отдел, параграф; разновидность, род, вид. 3) *грам.* Глагольная форма, порода (в татарском — залог). 4) Тема. 5) Вопрос; смысл.

**Бабелмәмат** باب الممات *из.* Үлем ишеге. *Капаттык* (бикләдек) *шимди без бабелмәмати.* (Г. Тук.)

*из.* Врата смерти.

**Бабелмәндәб** باب المندب *из.* Кызыл диңгезнең көньяк бугазы („Елау капкасы" дигән сүз).

*из.* Пролив Баб-эль-Мандеб в Красном море, *букв.* „Ворота слёз".

**Бабунәҗ** بابونج *ис.* Ак чәчәк, пәйгамбәр чәчәге.

*сущ.* Ромашка.

**Бавәр** باور *ф. ис.* Ышану, ышаныч. *Сәңа булдым ушал бәхер эчрә бавәр* (Сайяди).

*п. сущ.* Вера, доверие.

**Баг** باغ *ф. ис.* Бакча.

*п. сущ.* Сад.

**Багбан** باغبان *ф. ис.* Бакчачы.

*п.* Садовник.

**Багбостан** باغبستان *ф. ис.* 1) Җимеш бакчасы. 2) Яшелчә бакчасы.

*п. сущ.* 1) Фруктовый сад. 2) Огород.

**Багстан** باغستان *ф. ис.* Бакча урыны, бакчалык җир.

*п. сущ.* Место, изобилующее садами, сады.

**Багчәван** باغچوان *ф. ис. кара:* багбан.

*п. сущ. см.* Багбан.

**Багый** باغى *сф.* 1) Җәберләүче, хаксызлык итүче, изүче. *Кем ул Аксак-Тимер багый.* (Г. Чок). 2) Чиктән чыгучы.

*пр. д.* 1) Притесняющий, совершающий несправедливость. 2) Притеснитель, тиран. 3) Превышающий (власть).

**Багыйс** باغث *сф.* 1) Сәбәп, сылтау. 2) Сәбәпче, кузгатучы. *Хатын-кызларның болай качмый йөрүләре менә ничек багыйсе фетнә була.* (Ф. Әмир.)

*пр. д.* Причина, мотив, побуждение.

**Бад** باد *ф. ис.* 1) Җил. *Сулыйсы килә иде бади сәмум.* (К. Нас.). 2) Булсын! *Нәүруз мөбарәк бад!* (Нәүруз бәете.) — *п. сущ.* 1) Ветер, дуновение. 2) Пусть будет.

**Бадам** بادام *ф. ис.* Бадам, миндаль. — *п. сущ.* Миндаль.

**Баде саба** باد صبا *ст. шигъ.* Төньяк-көнчыгыштан искән йомшак җил. *Мөҗәссәм бер сафа (рәхәт), баде саба сез.* (Г. Тук.) — *сс. поэт.* Мягкий, нежный ветерок с северо-востока.

**Бади I** بادى *сф.* 1) Башлап җибәрүче; баш, әүвәл. 2) Сәбәп, сәбәп булучы. 3) Тышкы як. — *пр. д.* 1) Начинающий; зачинщик, начало. 2) Повод, причина. 3) Внешняя сторона.

**Бади II** بادى *ф. с.* Җилле, җилгә карашлы. — *п. прил.* Ветряный.

**Бадинҗан** بادنجان *ф. ис.* Баклажан. — *п. сущ.* Баклажан.

**Бадирә** بادره *сф.* 1) Билге, булу билгесе. 2) Уйламаганда, кинәт булган вакыйга. 3) Уйламастан әйтелгән сүз. 4) Беренче адым, башлау. — *пр. д.* 1) Признак, предтеча, предвестник. 2) Внезапность, неожиданный случай. 3) Невзначай сказанное слово. 4) Первый шаг.

**Бадия** باديه *ис.* 1) Кыр, дала, япан. *Дөньяны куып, залаләт бадиясендә йөгерәсең.* (Г. Фәез.) 2) Күчмә халык. — *сущ.* 1) Пустыня, степь. 2) Кочевники.

**Бадә** باده *ф. ис.* Шәрап, хәмер, эчемлек. — *п. сущ.* Вино, напиток.

**Бадәи наб** — саф шәрап. *Кил, әй сакый, китергел бадәи наб.* (Хорәз.) — Чистое вино.

**Баз** باز *ф. с.* 1) Ачык, ялан. **Сәрбаз** — ялан баш. 2) Уйнаучы. **Комарбаз** — отыш уены уйнаучы. 3) Янә, тагы. 4) Карчыга, лачын. — *п. прил.* 1) Открытый, голый. **Сәрбаз** — с непокрытой головой. 2) Игрок. **Комарбаз** — играющий в азартные игры. 3) Опять, еще. 4) Сокол, ястреб.

**Базаркян** بازارکان *ф. ис.* Алыш-биреш итүче, сатучы, сәүдәгәр. — *п. сущ.* Купец, торговец.

**Баигъ** بايع *сф.* Сатучы. — *пр. д.* Продавец.

**Баин** باين *сф.* 1) Ачык, күренеп тора торган. 2) Бөтенләй (хатын аеру турында). **Талакы баин** — янадан кушылмаслык итеп хатын аеру. — *пр. д.* 1) Ясный, очевидный. 2) Окончательный (о разводе).

**Байтар** بيطر، بيطار *ис.* Хайваннар врачы, ветеринар. — *сущ.* Ветеринар.

**Бакирә** باکره *сф.* Гыйффәтле кыз, кыз кеше. — *пр. д.* Девушка, девственница.

**Бакый** باقی *сф.* 1) Калучы, калдык. 2) Мәңге яшәүче, мәңгелек. *Намнары бакый улды та кыямәт тидия.* (Г. Тук.) — *пр. д.* 1) Оставшийся. 2) Вечный.

**Балига** بالغه *сф.* Балигъ-нең *мнс.* *Балига булганнан соң теләгән адәменә бара белер.* (З. Һад.) — *жен.* От балигъ.

**Балигъ*** بالغ *сф.* 1) Үсеп җиткән. *Балигъ булган балаларны булмас алдап* (М. Гаф.). 2) Ирешүче, җитешүче, ирешкән, җитешкән. 3) Кимчелексез, тулы. — *пр. д.* 1) Взрослый, достигший совершеннолетия, совершеннолетний. 2) Достигающий, достигший. 3) Совершенный, полноценный.

**Балин** بالين *ф. ис.* Мендәр, күпчек. — *п. сущ.* Подушка; изголовье.

**Баль** بال *ис.* 1) Уй. 2) Күңел, хәтер. 3) Йөрәк. — *сущ.* 1) Ум. 2) Память. 3) Сердце.

**Бани** بانى *сф.* Бина итүче, нигез салучы, төзүче. — *пр. д.* Строитель, конструктор.

**Бану** بانو *ф. ис.* Бикә, ханым; кәләш. — *п. сущ.* Госпожа, дама; невеста.

**Бари** بارى *сф.* Юктан бар итүче, яратучы, алла. — *пр. д.* Творец, создатель, бог.

**Барид** بارد *сф.* Суык, салкын. *Мулла Галимҗан барид шул, җанга бик салкын бата.* (Ш. Баб.) — *пр. д.* Прохладный, холодный.

**Барика** بارقه *ис.* 1) Елдырым; яшен ялтыравы. 2) Яшен. — *сущ.* 1) Отблеск молнии; проблеск. 2) Молния.

**Барикъ** بارق *сф.* Ялтыраучы, җемелдәүче, яктылык бирүче. — *пр. д.* Блестящий, сверкающий, сияющий.

**Баруд** بارود *ис.* Дары. — *сущ.* Порох.

**Баруди** بارودى *с.* Дары -(га караган). — *прил.* Пороховой.

**Барәкәаллаһ** بارك الله *гыйб.* 1) *дини* Алла мөбарәк кылсын. 2) Бик шәп, яхшы, егет! *Һай, барәкәаллаһ, бик яхшы булган.* (К. Нас.) — *фр.* 1) *рел.* Да благословит Аллах! 2) Здорово, хорошо, молодец!

**Батыйль** باطل *сф.* 1) Бозык; дөрес түгел, чын түгел; яраксызга, ялганга чыгарылган. *Надан сиңа зарарга вә батыйльлеккә киңәш бирер.* (К. Нас.) 2) Буш, файдасыз. — *пр. д.* 1) Ложный, неверный, несостоятельный, недействительный. 2) Тщетный, напрасный; ничего не стоящий, бесполезный.

**Батыйн** باطن *сф.* **1.** 1) Эчке. 2) Яшерен. **2.** Эч, эчке як. *Җәмигъ дусларымның заһиры хуш, вәләкин, мәгълүмдер, батыйны буш.* (Ут. Им.)
*пр. д.* **1.** 1) Внутренний. 2) Скрытный, тайный. **2.** Внутренность.

**Батыйни** باطنى *с.* 1) Эчке, эчтәге. 2) Күңелдәге. 3) Серле, яшерен.
*прил.* 1) Внутренний. 2) Сокровенный. 3) Скрытый, тайный.

**Батыйнән** باطنًا *р.* 1) Эчтән. 2) Яшертен.
*н.* 1) Внутренне. 2) Скрытно, тайно.

**Батыйнән вә заһирән** باطنًا و ظاهرًا *гыйб.* Эчтән дә тыштан да. *Заһирән дус булса да, батыйнән дошман иде.* (З. Биг.)
*фр.* Тайно и явно.

**Батәртиб** باترتيب *гф. р.* Тәртип белән, тәртибе буенча, тәртипле.
*ар.-п. н.* По порядку, в полном порядке.

**Бахис** باحث *сф.* Бәхәс иткән, берәр нәрсә турындагы мәгълүматны эченә алган.
*пр. д.* Содержащий сведения, повествующий о чём-либо.

**Бахосус** باخصوص *гф. р.* 1) Бигрәк тә. 2) Атап, махсус, төбәп.
*ар.-п. н.* 1) Особенно, в особенности. 2) Нарочно, специально.

**Бахур** باخور *ис.* Җәйге чиллә.
*сущ.* Самые жаркие дни лета.

**Бахәбәр** با خبر *гф. с.* Белеп торучы, хәбәрдар, белеме бар. *Хикмәте хөкме кадәрдән бахәбәр булсаң әгәр.* (Дәрд.)
*ар.-п. прил.* Осведомленный, сведущий.

**Баж** باج *ф. ис.* 1) Пошлина. 2) Налог, ясак.
*п. сущ.* 1) Пошлина. 2) Дань, налог.

**Баһадир*** بهادر *ф. ис.* Батыр, көчле кеше.
*п. сущ.* Богатырь, герой.

**Баһадиранә** بهادرانه *ф. р.* Батырларча, батырлардай, каһарманнарча, егетләрчә.
*п. н.* Смело, по-богатырски; геройски.

**Баһир** باهر *сф.* 1) Ачык, анык. 2) Матур, гүзәл. *Гаһедкә вафадар — бер нуры баһирдыр диде.* (К. Нас.)
*пр. д.* 1) Ясный, очевидный. 2) Прекрасный, превосходный.

**Би I** ب *бәйл.* Кайбер гарәп сүзләренә алдан кушылып „га-гә", „ча-чә", „белән", „өчен" функцияләрендә кулланыла.
Предлог „с".

**Би II** بى *ф. бәйл.* Юклыкны белдерә торган бәйлек. Исемнәр алдында кул-
*п. пред.* В персидском языке предлог, обозна-

ланыла; бездәге „сыз-сез“ кушымчалары мәгънәсен белдерә. *Бихәбәр* — хәбәрсез. *Битараф* — нейтраль, бер якка да кушылмаган. *Бихисап* — хисапсыз. чающий отсутствие какого-либо предмета или качества и соответствующий русским *не, без (бес).*

**Биби** بیبی ، بی بی ، بی *ф. ис.* Бикә, ханым; хуҗа хатын. *п. сущ.* Госпожа, дама; хозяйка.

**Бибәһа** بی بها *ф. с.* Бәясез, бәя куя алмаслык дәрәҗәдә кадерле, кыйммәт. *п. прил.* Бесценный, очень дорогой.

**Бибәһрә** بی بهره *ф. с.* 1) Өлешсез, бәхетсез. 2) Белемсез. *п. прил.* 1) Бедный, обездоленный, лишённый (чего-либо). 2) Несведущий.

**Бивакыт** بی وقت *гф. р.* Вакытсыз. *ар.-п. н.* Несвоевременно, безвременно, не вовремя.

**Бивафа** بی وفا *ф. с.* Ышанычсыз, сүзендә тормаучы, ялганчы, алдакчы, хыянәтле. *п. прил.* Неверный; ненадёжный; вероломный.

**Бивая** بی وایه *ф. с.* Өлешсез, мәхрүм, өлешсез калдырылган. *Ифтиракыңнан бирү бән бикәсем, биваяем.* (Г. Тук.) *п. прил.* Обездоленный.

**Бивә зән** بیوه زن *ф. ис.* Тол хатын. *Мәни бичарадырмын, бивә зәнмен* (Сайяди). *п. сущ.* Вдова.

**Бигайбә*** بیعیبه *гф. ст.* Гаепләмә, гафу ит. *ар.-п. сс.* Извини, прости, простите.

**Бигайниһи** بیعینه *ст.* 1) Нәкъ үзе. 2) Коеп куйган, үзе шикелле үк, нәкъ. *Бигайниһи гөл утыртырга хәзерләнгән туфрак шикелле.* (К. Нас.) *сс.* 1) Он сам. 2) В точности, точно, точь-в-точь.

**Бигайри** بیغیر *гф. ст.* Гарәп сүзләре алдында килеп бездәге „сыз-сез“ һәм „башка“ ярдәмлеге мәгънәләрен белдерә. *Бигайри риза* — ризалыктан башка, ризалыксыз. *ар.-п. сс.* Без (ставится перед именами).

**Бигайри хак** بیغیر حق *гф. ст.* 1) Хаклыктан башка, хаксызлык белән. 2) Урынсыз, тиешсез. *Берәү бигайри хак берәүгә дошманлык кылычын чыгарса, ул кылычның кыны үзенең башы булыр.* (К. Нас.) *ар.-п. сс.* 1) Без права (на что-либо). 2) Неуместно.

**Бигакыйланә** بی عاقلانه *гф. ст.* Акылсыз рәвештә, уйламыйча. *ар.-п. сс.* Безрассудно, неумно, неразумно, необдуманно.

**Бигамь** بى غم *гф. с.* 1) Кайгысыз, хәсрәтсез. 2) Гамьсез. — *ар.-п. прил.* 1) Без печали, без скорби. 2) Беспечный.

**Бигараз** بيغرض *гф. ст.* **1.** Гаделлек белән, турылык белән. **2.** Гадел; турылыклы. — *ар.-п. сс.* **1.** Беспристрастно. **2.** Беспристрастный, незаинтересованный.

**Бигать** بيعت *ис. кара:* бәйгать. — *сущ. см.* Бәйгать.

**Бигаун** بعون *р.* Ярдәме белән. — *н.* С помощью, при помощи.

**Бигаять** بيغايت *гф. р.* Чиксез, чиктән тыш, бик. *Кылычны төргән бигаять озын киндерне чишә-чишә...* (Г. Газиз). — *ар.-п. н.* Весьма, очень.

**Бигиран** بى گران *ф. с.* Бәясез, бәя куя алмаслык кыйммәт. *Аның өчен симзәрдән* (алтын-көмештән) *вирде аңа бигиран.* (Рәхим кол Әбубәкер улы). — *п. прил.* Очень дорогой, бесценный.

**Бигъсәт** بعثت *ис.* 1) Җибәрү, юллау, вәкил итеп җибәрү. 2) Делегация, миссия. — *сущ.* 1) Отправка, посылка, командировка. 2) Миссия, делегация.

**Бигыйбарәтиһа, бигыйбарәтиһи** بعبارته، بعبارتها *гыйб.* Үзе сөйләгәнчә, үзе әйткәнчә, үз сүзе белән, үзенең гыйбарәләрен үзгәртмичә. — *фр.* Его же выражением, его же словами.

**Бигянә** بيگانه *ф. с.* Ят, чит, таныш булмаган. *Якты көндә шәм яндырганны гакылдан бигянә диерләр.* (К. Нас.) — *п. прил.* Чужой, посторонний, незнакомый.

**Бигяһ** بيگاه *ф. р.* Вакытсыз, тиешсез чакта. — *п. н.* Не вовремя, не ко времени.

**Бигөман** بيگمان *ф. р.* 1) Шиксез, шөбһәсез. 2) Уйламыйча, уйламастан. *Хөббе дөнья илә калбем мәел итмеш бигөман.* (Һ. Сал.) — *п. н.* 1) Без сомнения. 2) Не думая, необдуманно.

**Бигөнаһ** بى گناه *ф. с.* 1) Гөнаһсыз. 2) Гаепсез. — *п. прил.* 1) Безгрешный. 2) Неповинный, невиноватый.

**Бидар** بيدار *ф. с.* Уяу, сак, йокысыз. *Күңел биргем сәнең гыйшкыңда бидар* (Сайяди). — *п. прил.* Бодрствующий; бдительный.

**Бидаять** بدايت *ис.* 1) Башлау, керешү (сүзгә, эшкә). 2) Башлангыч. — *сущ.* 1) Начинание, инициатива. 2) Начало.

**Бидгать** بدعت *ис.* 1) Элеккесенә каршы килә торган яңа бер эш. 2) Яңа — *сущ.* 1) Нововведение. 2) Ересь.

гадәт. *Бакчада явыз бидгать уен кургән.* (Ш. Баб.)

**Биддәфгат** بالدفعات *ст.* Күп тапкыр, кабат-кабат. — *сс.* Несколько раз; в несколько приемов; повторно.

**Би дил** بی دل *ф. с.* 1) Күңелсез; кәефсезләнгән. 2) Рәхимсез, шәфкатьсез, җансыз. 3) Мәхәббәт утына дучар булган, мәхәббәт белән йончылган. *Мәни би дил гариплектә йөрермен* (Сайяди). — *п. прил.* 1) Унылый. огорчённый. 2) Бессердечный; бездушный. 3) Снедаемый любовью.

**Бидиянәт** بی دیانت *гф. ст.* Диндарсызлык; шәригать буенча эш итмәүчелек. — *ар-п. сс.* Отсутствие набожности; несоблюдение законов шариата.

**Бизар** بیزار *ф. с.* 1) Аптыраучы, йөдәүче, интегүче. *Булмыш ирде балыкыннан ул бизар.* (Мөхм.) 2) Күңеле кайтучы, хәтере калучы. — *п. прил.* 1) Усталый, измученный. 2) Питающий отвращение; избегающий.

**Бизарур** بی ضرور *гф. ст.* **1.** Юкка, кирәксезгә. **2.** Кирәксез. — *ар-п. сс.* **1.** Бесполезно; без необходимости, понапрасну. **2.** Бесполезный, напрасный.

**Биззарур** بالضرور *ст.* Чарасыз, чарасызлык белән, теләр-теләмәс, ирексездән, ирексезлек белән. *Биззарур шул сәбәптән хуп аламын.* (Ак.) — *сс.* По необходимости, поневоле.

**Биззат** بالذات *ст.* Турыдан-туры үзе (үзем, үзең), башкаларга тапшырып (йөкләтеп) түгел. — *сс.* Лично, собственной персоной; сам.

**Биигътибар** بی‌اعتبار *гф. ст.* Игътибарсыз, игътибар итмичә. — *ар.-п. сс.* Без внимания.

**Биирадә** بی‌اراده *гф. ст.* Теләмичә, көчләнеп, ирексездән. — *ар.-п. сс.* Безвольно.

**Биихтияр** بی‌اختیار *гф. ст.* 1) Үзе теләмичә, көчләнеп, ирексездән. 2) Ихтыярсыз. — *ар.-п. сс.* 1) Вынужденно, невольно. 2) Невольный.

**Биништибаһ** بی‌اشتباه *гф. ст.* Шиксез, шөбһәсез. — *ар.-п. сс.* Без сомнения; без колебания.

**Бикадәри халь** بقدر حال *ст.* Көч җиткәнчә, көч җитәрлек кадәр. — *сс.* По мере возможности, по возможности.

**Бикарар** بى قرار *гф. ст.* Карарсыз; гынычсыз, тынгысыз, башны кая куярга белмәүче. *Бәс ул хальдә бикарар, бихуд булды.* (К. Гал.) — *ар.-п. сс.* Беспокойный, непостоянный; неустойчивый.

**Бикер** بكر *ис.* **1.** Кызлык, кул тимәгәнлек. **2.** Гыйффәтле кыз. — *сущ.* **1.** Девственный, целомудренный. **2.** Девственница.

**Бикяр** بيكار *ф. с.* 1) Эшсез, шөгыльсез. 2) Файдасыз, бушка вакыт үткәрүче. — *п. прил.* 1) Безработный. 2) Праздный.

**Бикәс** بيكس *ф. с.* Ташланган, ыргытылган, ярдәмсез, ялгыз калган. *Ифтиракыңнан биру бән бикәсем, биваяем.* (Г. Тук.) — *п. прил.* Одинокий, оставленный, покинутый, заброшенный.

**Билахир, билахирә** بالاخر، بالاخره *ст.* Ахырда, азакта, иң ахырда, иң азакта. — *сс.* Наконец, в конце концов.

**Билбәдаһәт** بالبداهه *ст.* 1) Кинәт, көтмәгәндә. 2) Хәзерлексез. *Кятиб бәетне билбәдаһәт назым итте.* (К. Нас.) — *сс.* 1) Экспромтом, сразу, вдруг, неожиданно. 2) Без подготовки.

**Билвасыйт** بالواسط *ст.* Кеше аркылы, арадаш ярдәме белән, арадашлык белән; берәр нәрсә ярдәмендә. — *сс.* При помощи, при посредстве (чего, кого-либо); посредством.

**Билгаен** بالعين *ст.* Күз белән. — *сс.* Глазом.

**Билгаен вәррәэс** بالعين والرأس *гыйб.* Күзем, башым белән (дигән мәгънәдә булып, бездәге „баш өсте“, „теләп“, „бик риза булып“ дигән сүзләргә туры килә). *Жәмилә боларга өйдәш булып керүне бик яратканга күрә, билгаен вәррәэс кабул иттеләр.* (М. Гаф.) — *фр.* Охотно, с удовольствием, с большим желанием.

**Билгакес** بالعكس *ст.* Киресенчә, уйлаганның киресенчә. *Без көнне кояшлы булыр дип уйлаган идек, ул, билгакес, яңгырлы булды.* (Ф. Әмир.) — *сс.* Наоборот, напротив.

| **Викая** وقايه *ис.* 1) Саклау, яклау. 2) Булдырмау чараларын күрү. | *сущ.* 1) Охрана, защита. 2) Предупреждение, предохранение. |
| **Вилдан** ولدان *ис. к.* 1) Тудырылганнар, балалар, угыллар. 2) *дини* Җәннәт хезмәтчеләре. *Хур янына илтәбез: без вилданбыз, гыйльманбыз.* (Г. Тук.) | *сущ. мн.* 1) Дети; сыны. 2) *рел.* Слуги в раю. |
| **Виляд** ولاد *ис.* Бала тудыру. | *сущ.* 1) Рождение. 2) Роды. |
| **Вилядәт** ولادت *ис.* Туу, дөньяга килү. | *сущ.* Рождение, появление на свет. |
| **Вилядәтханә** ولادتخانه *ис.* Бала тудыру йорты. | *сущ.* Родильный дом. |
| **Виляят** ولايات *ис.* Виляять-нең *к.* | *сущ. мн.* от виляять. |
| **Виляять** ولايت *ис.* Өлкә, губерна. *Гали бай бу виляятьтә бөек төҗҗар иде.* (М. Ак.) | *сущ.* Область, провинция, губерния, штат, вилайет. |
| **Вирасәт** وراثت *ис.* 1) Үлгән кешенең малына ия булу хокукы. 2) Нәселдәнлек. | *сущ.* 1) Право наследования. 2) Наследственность. |
| **Вирд** ورد *ис.* 1) *дини* Билгеле вакытларда укыла торган догалар, аятьләр. *Бу бер догалык һәм вирд иде.* (Г. Ибр.) 2) Чишмә. | *сущ.* 1) *рел.* Моление, молитва. 2) Часть Корана, читаемая молящимися ночью, краткая молитва. 3) Источник (воды). |
| **Висак** وثاق *м. III.* Договор, килешү, вәгъдәләшү. | *м. III.* Договор, союз; соглашение. |
| **Висаль** وصال *м. III.* Кавышу, очрашу, кушылу, сөйгәне белән кавышу. *Хакыйкать висаль көне тугды имде.* (К. Гал.) | *м. III.* Любовная связь; свидание (с любимым.) |
| **Витер** وتر *ис.* 1) Ялгыз, парсыз. 2) Такъ. | *сущ.* 1) Одинокий, отдельный. 2) Нечётный. |
| **Вифак** وفاق *м. III.* 1) Бер фикер, бер карашка килү; татулык. 2) Ярашу. | *м. III.* 1) Согласие. 2) Соответствие. |
| **Вижаһ** وجاه *м. III.* Йөзгә йөз килү, очрашу, кара-каршы килешү. | *м. III.* Встреча лицом к лицу; стояние лицом к лицу. |
| **Вижаһән** وجاهاً *р.* Йөзгә йөз очрашып, кара-каршы килеп. | *н.* Лицом к лицу. |
| **Виждан** وجدان *ис.* 1) Вөждан. *Изге виждан рәнҗемиме, анда ерткычлар ничек?* (Ш. Баб.) 2) Вөжданнан чыгып | *сущ.* 1) Совесть. 2) Сознательность; чувство ответственности. |

үзеңнең эш итүеңә бәя бирү, җаваплылыкны тою.

**Виждани** وجدانى *с.* Вөждан(га бәйләнешле). *прил.* 1) Относящийся к чувству, сознанию. 2) Интуитивный.

**Вижданән** وجداناً *р.* Вөждан белән, вөждан буенча. *н.* По совести, сознательно.

**Восул** وصول *ис.* 1) Ирешү, тапшырылу. 2) Килеп җитү. *сущ.* 1) Достижение; получение (чего-нибудь). 2) Прибытие, приезд.

**Вә*** و *тер.* Һәм, да. *Анда бик салкын вә бик эссе түгел, урта һава.* (Г. Тук.) *с.* И.

**Вәбал** وبال *ис.* 1) Берәр эш аркасында булган авыр нәтиҗә, гөнаһ, язык. 2) Авырлык. *Ашамый, эчми җый да дошманыңа калсын, һаман вәбалы сиңадыр.* (К. Нас.) *сущ.* 1) Тяжёлое последствие чего-либо; вина, грех, проступок. 2) Тягость.

**Вә бәгыйдә** وبعد *ст.* Шуннан соң, моннан соң. *сс.* После того, после этого, затем.

**Вәгаз** وعظ *ис.* Вәгазь, үгетләп, димләп, өндәп сөйләнгән сүз. *сущ.* Увещевание, проповедь; проповедование.

**Вә гайре залик** وغيرذلك *ст.* Моннан башкалар. *сс.* И так далее, и прочее, и тому подобное.

**Вә гайреһи** وغيره *ст.* Һәм башкалар. *сс.* И другие, и прочее, и тому подобное.

**Вәгъдә*** وعده *ис.* Вәгъдә, сүз бирү. *сущ.* Обещание.

**Вәгыд** وغد *ис.* 1) Кол, хезмәтче. 2) Түбәнлек, хурлык. *сущ.* 1) Раб, слуга. 2) Низость, позор.

**Вәгыддар** وغددار *гф. с.* Түбән, хурлыклы. *Наданлык вә һөнәрсезлек кеби ике олуг вәгыддар дошманның әленә төшеп.* (М. Ак.) *ар.-п. прил.* Низкий, подлый, позорный.

**Вәгыйд** وعيد *ис.* 1) Янау. 2) Начарлыктан тыю өчен куркыту, кисәтү. *Әмер вә вәгыйд адәм өстенә йөкләтелмештер.* (К. Нас.) *сущ.* 1) Угроза. 2) Предупреждение, предостережение.

**Вәдад** وداد *ис.* Ярату, дуслык, яхшылык. *сущ.* Любовь, дружба, симпатия.

**Вәдаигъ** ودايع *ис.* Вәдига-ның *к.* *сущ. мн.* от вәдига.

**Вәдига** وديعه *ис.* Саклау өчен бирелгән әйбер, әманәт. *сущ.* Вещь, отдаваемая на хранение; вклад, депозит.

**Вәзарәт** وزارت *ис.* 1) Вәзирлек, министрлык. 2) Вәзирлек, министрлык дәрәҗәсе. *сущ.* 1) Министерство. 2) Должность, функция министра, везира.

**Вэзен** وزن *ис.* 1) Үлчәү. 2) Шигырьдә ритм, такт, иҗек саны. 3) *грам.* Гарәб теле морфологиясендә сүз калыплары—формалары.
*сущ.* 1) Взвешивание. 2) *поэт.* Размер, количество слогов; ритм. 3) *грам.* В арабской морфологии форма слова.

**Вэзир** وزير *ис.* Вәзир, министр.
*сущ.* Везир, министр.

**Вэ илля** والا *ст.* Югыйсә, башкача булса; алай булмаса. *Күңелдә тотмагыл зурлык, вә илля күрерсең хурлык.* (Г. Кан.)
*сс.* А не то, в противном случае, иначе.

**Вэйл** ويل *ис.* Үкенеч, кайгы.
*сущ.* Беда, горе.

**Вэйля** ويلا *ым.* Ни үкенеч! Ни кайгы! *Вәйля!.. Дәригъ! Бер күреп каналмадым.* (Дәрд.)
*межд.* О горе! Как жаль!

**Вэйран** ويران *ф. с.* Ватык, җимерек, бозык; хәрабә хәленә килгән. *Бу үсемлек вәйран гыймарәтләр тикрәсендә үсәр.* (К. Нас.)
*п. прил.* Опустошённый, разорённый; разрушенный.

**Вэйранэ** ويرانه *ф. ис.* Җимерелергә йөз тоткан бина; җимерелгән, ишелгәннән калган бина калдыклары, җимереклек. *Ташландык вәйранәләр шикелле буш урынга килеп чыктык.* (Ш. Кам.)
*сущ.* Развалины, руины; опустошённое место.

**Вэкаигъ** وقايع *ис.* Вакыйга-ның. *к.*
*сущ. мн.* от вакыйга.

**Вэкар** وقار *ис.* Олысымаклык, үзен олы тота белү; горурлык. *Әй, Маһирә, ходай биргән вәкарың бар, вәкар белән матур итеп бакарың бар.* (Ш. Баб.)
*сущ.* Солидность, важность, величавость, достоинство.

**Вэкахэт** وقاحت *ис.* Оятсызлык, әдәпсезлек.
*сущ.* Наглость, нахальство, бесстыдство.

**Вэкил*** وكيل *ис.* Ышанып эш тапшырылган кеше; сайлап җибәрелгән кеше, агент.
*сущ.* Представитель; уполномоченный, агент.

**Вэкыф** وقف *ис.* 1) Туктау, туктап тору. 2) Укыганда тын алу өчен туктау. 3) Берәр кеше тарафыннан килерен җәмәгать файдасына тоту өчен бирелгән мал, милек. *Вәкыфләр тәгаен кылдырып калдырырга кулыннан килмәде.* (З. Һад.)
*сущ.* 1) Стояние; остановка. 2) Пауза. 3) Имущество, завещанное на благотворительные цели, вакуфное имущество.

**Вэкыфнамэ** وقفنامه *гф. ис.* Берәүнең вәкыф итеп биргән әйберләре язылган рәсми язуы.
*ар.-п. сущ.* Акт пожертвования (завещания) на богоугодное дело.

**Вэкялэт** وكالت *ис.* 1) Вәкәләт. 2) Вәкиллек. 3) Берәүнең урынында эшләп тору.
*сущ.* 1) Полномочие. 2) Представительство. 3) Исполнение чьих-либо обязанностей.

**Вәкяләтнамә** وكالتنامه *гф. ис.* 1) Берәүнең вәкил итеп җибәрелгәнен күрсәтә торган таныклык, шәһадәтнамә. 2) Ышаныч кәгазе. — *ар.-п. сущ.* 1) Акт уполномочия, верительная грамота. 2) Доверенность.

**Вәкяләтән** وكالةً *р.* Вәкил буларак, вәкил булып. — *н.* По поручению, по доверенности.

**Вәли I** ولى *тер.* Ләкин (вәләкин сүзләреннән кыскартылган). *Вәли җиңсәң, ганимәт маллары бар.* (Г. Тук.) — *союз.* Но, однако (сокращение от слова вәләкин).

**Вәли II** ولى *ис.* 1) Ия, хуҗа. 2) Яклаучы; опекун. 3) *дини* Изге. *Бу адәм вәлиләрдән дия иде.* (З. Һад). — *сущ.* 1) Обладатель, хозяин. 2) Покровитель, опекун. 3) *рел.* Святой, угодник.

**Вәли гаһед** ولىعهد *из.* Патшаның үзе урынына тәхеткә утырачак варисы. — *из.* Наследник престола.

**Вәлид** وليد *ис.* 1) Тудырылган, бала. 2) Ир бала. *Мин өмид иткән вәлидләр „Җим Валид“ тән ләм ялид.* (Мин тудырылыр дип өмет иткәннәр Җ. Вәлидидән тумады). (Ш. Баб.) — *сущ.* 1) Ребёнок, дитя. 2) Мальчик.

**Вәлимә** وليمه *ис.* Туй, туй мәҗлесе. — *сущ.* Пир, угощение, банкет.

**Вәли нигъмәт** ولى نعمت *из.* Нигъмәт иясе; ашарга, эчәргә бирүче. — *из.* Хлебосол, угощающий.

**Вәлхасыйл** والحاصل *р.* Кыскасы, бер сүз белән әйткәндә, җыеп әйткәндә. *Вәлхасыйл Хәнифә туташның гаиб улмасы чук сүзләрә сәбәп улды.* (М. Ак.) — *н.* Одним словом, в итоге.

**Вәләд** ولد *ис.* 1) Бала. 2) Ул (угыл.) 3) Токым, нәсел. — *сущ.* 1) Дитя. 2) Сын; мальчик. 3) Дети, потомки.

**Вәләделгак** ولدالعاق *из.* Ата-анасын рәнҗетүче бала. — *из.* Неповинующийся родителям, непокорный ребёнок.

**Вәләкин** ولكن *тер.* Ләкин, тик, бары. — *союз.* Но, однако.

**Вәләү** ولو *кис.* Ичмасам, һич булмаса, гәрчә. — *част.* Хотя бы, и хотя.

**Вә ма әшбәһе залик** وما اشبه ذلك *гыйб.* Һәм моңа охшаган, моның кебек, мондый, моңа охшашлы. *Җәмәгать арасында вә ма әшбәһе залик сүзләр сөйләнәдер.* (З. Биг.) — *фр.* И тому подобное.

**Вә мәга залик** ومع ذلك *ст.* Һәм шуның белән бергә, шулай булган хәлдә, шулай була торып. *Наданлыкны һич-* — *сс.* Вместе с тем; в таком случае.

*кемнең күрәсе килми, вә мәга залик надан күп.* (К. Нас.)

**Вәрасәт** وراثت *ис. кара:* вирасәт. — *сущ. см.* Вирасәт.

**Вәраэ** وراء *бәйл.* Арка, арт, арт як. — *пред.* 1) Задняя часть, тыл. 2) За, позади.

**Вәраэ җәбәл** — тау арты.

**Вәрем** ورم *ис.* Шеш, шешү. — *сущ.* Вздутие, опухоль.

**Вәрзиш** ورزش *ф. ис.* 1) Гимнастика, физик күнегү. 2) Эш, тырышлык. *Дусты дустының шунда улыр вәрзише.* (Ут. Им.) — *п. сущ.* 1) Физическое упражнение, гимнастика, спорт. 2) Работа, старание.

**Вәригъ** وريع *с.* Начарлыктан сакланучы, куркып сакланучы. — *прил.* 1) Богобоязненный. 2) Боязливый, осторожный.

**Вәрид** وريد *ис.* Вена, кара кан тамыры. — *сущ.* Вена.

**Вәрсә** ورثه *ис.* Варис-нең *к.* — *сущ. мн.* от варис.

**Вәрта** ورطه *ис.* 1) Бәла, зыян. 2) Куркунычлык. *Бу вәртадан хәлас булгач.* (К. Нас.) — *сущ.* 1) Беда, неприятность. 2) Опасность.

**Вәрәгъ** ورع *ис.* Тыелу, харамнан саклану, диндарлык. — *сущ.* Набожность, богобоязненность, благочестие.

**Вәрәка** ورقه *ис.* 1) *бот.* Бер яфрак. 2) Бер бит кәгазь, хат; записка. 3) Документ. — *сущ.* 1) *бот.* Лист. 2) Лист бумаги; письмо, записка. 3) Документ.

**Вәрәкъ** ورق *ис.* 1) *бот.* Яфраклар. 2) Китап, газета бите. 3) Язылган кәгазь. — *сущ.* 1) *бот.* Листья. 2) Страница книги, газетный лист. 3) записка, бумага.

**Вәсаил** وسائل *ис.* Вәсилә-нең *к.* — *сущ. мн.* от вәсилә.

**Вәсаитъ** وسائط *ис.* Васита-ның *к.* — *сущ. мн.* от васита.

**Вәсамәт** وسامت *ис.* Йөзнең матурлыгы, матурлык, чибәрлек. — *сущ.* Красота лица, миловидность.

**Вәсат** وسط *ис.* Урта, урталык. — *сущ.* Середина, центр.

**Вәсатать** وساطت *ис.* Арадашлык, васитачылык. — *сущ.* Посредничество, ходатайство.

**Вәсатый** وسطى *с.* 1) Уртадагы. 2) Урта. — *прил.* Средний, срединный.

**Вәсвәсә*** وسوسه *ис.* 1) Котырык; эчтән, астыртын бирелгән котырык; саташтыру; күңел аздыру. *Кичә вә көндезләрдә вәсвәсә бирүче шайтаннар.* (З. Һад.) 2) Шик, хәвеф. — *сущ.* 1) Искушение, соблазн; развращение. 2) Опасение, тревога.

**Вәсеб** وثب *ис.* Сикерү, сикереп алу. *сущ.* Прыгание, подпрыгивание.

**Вәсем** وسم *ис.* 1) Билге, тамга. 2) Тамга, келәймә. *сущ.* 1) Знак, метка, 2) Клеймо, тавро.

**Вәсигъ** وسیع *с.* Киң, иркен. *прил.* Пространный; широкий; вместительный.

**Вәсика** وثیقه *ис.* 1) Ышанырлык, таянырлык нәрсә (документ). 2) Нигезле дәлил. *сущ.* 1) Документ, акт. 2) Обоснованное доказательство.

**Вәсилә** وسیله *ис.* 1) Чара, юл, әмәл. 2) Берәр сылтау белән якын булырга тырышу. *Безнең белән вәсилә кылган кешегә мәрхәба, — дип хезмәтен әдә кылды.* (К. Нас.) *сущ.* 1) Средство; способ. 2) Стремление сблизиться под каким-либо предлогом.

**Вәсим** وسیم *с.* Гүзәл, матур йөзле, матур. *прил.* Красивый, миловидный.

**Вәссәлям*** والسلام *гыйб.* Бетте, тәмам булды, башка юк, бар кадәрлесе шул. *Шаять аңларсыздыр инде бетте тәмсил, вәссәлям.* (М. Гаф.) *фр.* И всё! И дело с концом! И до свидания!

**Вәсән I** وثن *ис.* 1) Тәре. 2) Пот; табыну сурәте. *сущ.* 1) Крест. 2) Идол, истукан; предмет поклонения; икона.

**Вәсән II** وسن *ис.* Йокыга талу, йокымсырау, черем итү, оюю. *сущ.* Дремота, лёгкий сон.

**Вәсәни** وثنی *с.* 1) Мәҗүси; потка табынучы. 2) Мәҗүсилек(кә бәйләнешле). *прил.* 1) Язычник, идолопоклонник. 2) Языческий.

**Вәсәх** وسخ *ис.* Кер, пычрак. *сущ.* Грязь, нечистота.

**Вәтәд** وتد *ис.* 1) Казык. 2) Инсә сөяге. 3) Шигырь үлчәве гыйльмендә ике иҗектән торган өч хәреф. *Вәтәд мәҗмуг* — тулы вәтәд (алдагы икесе хәрәкәле, өченчесе сәкенле). *Вәтәд мәфрук* — аерылган вәтәд (беренче һәм өченчесе хәрәкәле, икенчесе сәкенле). *сущ.* 1) Кол, колышек. 2) Ключица. 3) *метр.* Часть стопы, состоящая из трех букв.

**Вәфрәт** وفرت *ис.* Күплек, муллык. *сущ.* Обилие, множество, масса, изобилие.

**Вәфык** وفق *м. I.* Ярашканлык, лаеклык, муафыйклык; уңай килүчәнлек. *м. I.* Соответствие, согласие.

**Вәхалән*** وحالاً *р.* Хәзердә дә; хәзер, шушы вакытта. *н.* Ныне, теперь, сейчас, в данное время.

**Вәхаләнки*** وحالاًکی *гф.* Чынлыкта. *ар.-п.* В действительности, тогда как.

**Вәхдани** وحداني *с.* 1) Берდәнбер, уникаль. 2) Ялгыз. — *прил.* 1) Единственный, уникальный. 2) Одинокий.

**Вәхданиять** وحدانيت *ис.* 1) Бердәмлек. 2) Бердәнберлек, уникальлек. 3) *дини* Бер аллалылык, алланы бер дип тану. — *сущ.* 1) Единство. 2) Единичность, уникальность. 3) *рел.* Единобожие.

**Вәхдәт** وحدت *ис.* 1) Берлек, ялгызлык, ялгыз гына булу. 2) Үлчәү берәмлеге. 3) *кара*: вәхданиять 3. — *сущ.* 1) Единство. 2) Единица измерения. 3) *см.* Вәхданиять 3.

**Вәхеш** وحش *ис.* 1) Кыргыйлык, кешедән качучылык. 2) Ерткыч, куркыныч вәхши хайван. — *сущ.* 1) Дикость, одичалость. 2) Зверь, дикое животное, чудовище.

**Вәхи** وحى *ис. дини* Берәр фикерне алла тарафыннан пәйгамбәрнең күңеленә салу. *... фәрештәсен вәкил итеп вәхи җибәрә.* (М. Гаф.) — *рел.* Откровение.

**Вәхид** وحيد *с.* 1) Берүзе, тиңдәше юк, тиңдәшсез. 2) Ялгыз. — *прил.* 1) Единственный; несравненный. 2) Одинокий.

**Вәхим** وخيم *с.* 1) Авыр сеңешле (аш), саулык өчен зарарлы. 2) Соңы начар, соңы куркыныч. — *прил.* 1) Нездоровый, тяжёлый (о пище). 2) Чреватый (опасностями), опасный.

**Вәхши*** وحشى *с.* 1) Кыргый, кулга ияләшмәгән, ияләшми торган; кеше белән аралашудан качучы. 2) Явыз, канечкеч, кансыз. *Дөнья, сине Ләйля төсле күреп, Мәҗнүн гыйшкы белән яраттым, ә син минем керсез йөрәгемне вәхши этләреңнән талаттың.* (М. Җәл.) 3) Ерткыч хайван. *Болай булгач, кешенең вәхшидән аермасы нәрсә?* (М. Гаф.) — *прил.* 1) Дикий, неприрученный, избегающий встречи с человеком. 2) Зверский, свирепый, варварский; жестокий, кровожадный. 3) Дикое животное, зверь.

**Вәхшиянә** وحشيانه *гф. р.* 1) Ерткычларча, вәхшиләрчә. 2) Иялəнмичә. — *ар.-п. н.* 1) Зверски, свирепо, дико, варварски. 2) Не приручаясь.

**Вәхшият, вәхшәт*** وحشت، وحشيت *ис.* 1) Кыргыйлык. 2) Ерткычлык, кансызлык, кан эчүчәнлек. *Байларның ярлыларга күрсәткән золымнары, вәхшәтләре турында язылды.* (М. Җәл.) — *сущ.* 1) Дикость. 2) Зверство, свирепость.

**Вә әтүни би әһликөм әҗмәгыйн** واتونى باهلكم اجمعين *гыйб.* Гаиләләрегез белән барыгыз да мина килегез. *„Вә әтүни би әһликөм әҗмәгыйн“ диер имди.* (К. Гал.) — *фр.* Приходите ко мне со всей семьей.

**Вәҗазәт** وجازت *м. I.* Күп мәгънәне аз сүз белән аңлатып сөйләү, аз сөйләп, күп аңлату.
*м. I.* от *гл.* وجز (вәҗәзә) — говорить кратко, лаконично.

**Вәҗаһәт** وجاهت *ис.* 1) Йөз матурлыгы, гүзәллек. 2) Дәрәҗә, игътибар, дан, кадер. *Игътизал иттеки соң Мәгаррнең кадере, вәҗаһәте дәхи бер кат артмыштыр.* (Р. Фәх.)
*сущ.* 1) Красота лица. 2) Знатность, достоинство, сановитость.

**Вәҗед** وجد *ис.* 1) Һәртөрле эчке тойгы: сөю, шатлык, кайгы, ачыну, дулкынлану һ. б. 2) Байлык.
*сущ.* 1) Волнение; страсть; любовь; гнев, радость, веселие. 2) Богатство.

**Вәҗига** وجيعه *ис.* Сызлану, авырту. *Дәхи һәм зарбе вәҗига.* (Г. Кан.)
*сущ.* Боль.

**Вәҗиз** وجيز *с.* Кыска, кыскартылган.
*прил.* Краткий, укороченный.

**Вәҗиһ** وجيه *с.* 1) Матур, гүзәл. 2) Хөрмәт ителерлек (кеше).
*прил.* 1) Красивый. 2) Уважаемый, почтенный (человек).

**Вәҗнә** وجنه *ис.* Яңак, бит алмасы.
*сущ.* Щека.

**Вәҗәгъ** وجع *ис.* 1) Чир, авыру. *Куеп киттем аның вәҗәгына тирьяк.* (Г. Тук.) 2) Азап чигү.
*сущ.* 1) Боль, болезнь. 2) Страдание.

**Вәҗһе** وجه *ис.* 1) Бит. 2) Төс, йөз. 3) Бер әйбернең өске ягы, өслеге, йөзе. 4) Стиль, юл, ысул. 5) Сәбәп. *Һичбер вәҗһесез көлмәк ахмаклыкдыр.* (К. Нас.) 6) Як, мөнәсәбәт. *Вәҗһе карабәте ничек?* (кардәшлеге кай яктан?) 7) Алгы як. 8) Як, юнәлеш.
*сущ.* 1) Лицо. 2) Лик, образ, внешность. 3) Поверхность, лицевая сторона. 4) Стиль, способ, манера. 5) Причина, основание. 6) Отношение. 7) Перед, передняя сторона. 8) Сторона, направление.

**Вәҗһи** وجهى *с.* Йөз (гә), бит (кә бәйләнешле).
*прил.* Лицевой.

**Вәҗһән** وجهاً *р.* Бер яктан, бер яктан караганда.
*н.* С одной стороны, односторонне.

**Вәҗһән минәл вәҗеһ** — һичбер юл белән дә, ничек кенә итсәң дә.
Никоим образом.

**Вәһеб** وهب *ис.* Бүләк итеп бирү, багышлау.
*сущ.* Дарение; приподношение.

**Вәһем** وهم *ис.* 1) Хыялдагы уй, күз алдына китерелгән уй. *Гакылы сәлим бар, вәһем белән катнаш була торган гакылы гайре сәлим бар.* (Ф. Әмир.) 2) Шикле уй. 3) Ялгыш, бозык уй, буш уй.
*сущ.* 1) Воображение; иллюзия; фикция. 2) Подозрение, догадка. 3) Пустая мысль, ошибочное мнение.

**Вәһемнакь** وهمناك *ф. с.* Юктан шикләнүчән, шомланучан, шикләнеп куркучан. *Күргәне юк гомре дә вәһемнакь.* (Мөхм.) — *п. прил.* Подозрительный, мнительный.

**Вәһлә** وهله *ис.* 1) Күз ачып йомганчы уза торган вакыт, бик кыска вакыт. 2) Беренче танышу (берәр нәрсә белән). — *сущ.* 1) Мгновение. 2) Первое знакомство (с чем-либо).

**Вәһми** وهمى *с.* Хыялга, төпсез уйга бәйләнешле, хыялый. — *прил.* Воображаемый, вымышленный, иллюзорный.

**Вәһмият** وهميات *ис.* Вәһем-нең *к.* — *сущ. мн.* от вәһем.

**Вәһһаб** وهاب *ис.* 1) Бик юмарт, бик ярдәм итүче. 2) *дини* Бүләкне бик күп бирүче (алланың исеме). — *сущ.* 1) Щедрый. 2) *рел.* Вседарящий (эпитет аллаха).

**Вөзуэ** وضوء *м. I.* Таһарәт алу, билгеле йола буенча юыну. *Ике төрле тәһарәт булуы голяма каршында мөмкин: вөзуэ һәм тәяммем* (Г. Газиз). — *м. I.* Омовение, ритуал омовения.

**Вөзух** وضوح *ис.* 1) Ачыклык, билгеле булу, ачык булу. 2) Күзгә күренеп тора торган булучылык. — *сущ.* 1) Ясность, очевидность. 2) Отчётливость.

**Вөзәраэ** وزراء *ис.* Вәзир-нең *к.* — *сущ. мн.* от везир.

**Вөкуг** وقوع *м. I.* 1) Төшү. 2) Төгәлләү. 3) Вакыйга. 4) Булган эш, очрак. — *м. I.* 1) Падение. 2) Совершение, завершение. 3) Событие. 4) Случай.

**Вөкугат** وقوعات *ис.* Вөкуг-ның *к.* — *мн.* от вөкуг.

**Вөкуд** وقود *м. I.* 1) Яну, ялкынлану. 2) Ягулык (күмер, агач һ. б.) — *м. I.* 1) Горение. 2) Топливо (дрова, уголь и т. п.)

**Вөкуф** وقوف *м. I.* 1) Тору, урыннан тору. 2) Туктау. 3) Тукталыш; тик тору. 4) Басып тору. — *м. I.* 1) Вставание. 2) Остановка. 3) Стоянка. 4) Стояние.

**Вөкәля** وكلا *ис.* Вәкил-нең *к.* — *сущ. мн.* от вәкил.

**Вөруд** ورود *м. I.* 1) Килү, ирешү, килеп җитү. 2) Терлекләргә су эчерә торган урын. — *м. I.* 1) Прибытие, приход. 2) Водопой.

**Вөсгать** وسعت *ис.* 1) Киңлек, җәенкелек. 2) Байлык, иркенлек, муллык, җитешлек. — *сущ.* 1) Обширность, простор; широта, объём. 2) Обилие, достаток.

**Вөсгы** وسع *ис.* Куәт, сәләтлелек, көч җитү. *Такатем вөсгынча коллык итмәдем көсла булып.* (И. Сал.) — *сущ.* Сила, способность.

**Вөсук** وثوق *м. I.* Бик нык ышану. — *м. I.* Доверие, уверенность.

**Вөсул** وصول *м. I. кара:* восул. *Хакыйкатькә вөсул өчен, үзенә яхшы юл ача.* (М. Гаф.) — *м. I. см.* Восул.

**Вөхуш** وحوش *ис.* Вәхеш-нең *к.* *Вөхуштан ул тимсах, ерткыч, ифрат хәтәр* (Г. Газиз). — *сущ. мн.* от вәхеш

**Вөждан*** وجدان *ис. кара:* виждан. — *сущ. см.* Виждан.

**Вөждани** وجدانى *с. кара:* виждани. — *прил. см.* Виждани.

**Вөжданән** وجدانًا *р. кара:* вижданән. — *н. см.* Вижданән.

**Вөҗүб** وجوب *м. I.* Зарурлык (эшләргә тиешле булучылык, ансыз котылу мөмкин булмаган эш, эшләми калу ярамый торган эш). — *м. I.* Необходимость; обязательность (в выполнении чего-либо).

**Вөҗүд** وجود *м. I.* 1) Барлык, бар булу, бар булып тору. 2) Хәзер булу. 3) Гәүдә. *Ул каты йоклый, вөҗүден кара туфрак каплаган.* (Г. Тук.) — *м. I.* 1) Бытие, существование. 2) Наличие, присутствие. 3) Человеческое тело.

**Вөҗүһ** وجوه *ис.* Вәҗһе-нең *к.* — *сущ. мн.* от вәҗһе.

**Вөһүм** وهوم *ис.* Вәһем-нен *к.* — *сущ. мн.* от вәһем

# Г

**Г** — گ ، غ ، ع татар әлифбасында дүртенче хәреф булып, гарәп әлифбасындагы унсигезенче хәреф булган ع (йомшак гайн) һәм унтугызынчы хәреф булган غ (каты гайн), шулай ук фарсы әлифбасындагы егерме алтынчы хәреф булган گ хәрефен белдерә. Әбҗәд хисабында ع 70 кә, غ 1 000 гә йөртелә, گ хәрефе гарәптә юк, алар аны „кяф фарсый“ дип йөртәләр. Мисыр гарәпләрендә „г“ авазы булса да, алар аны „җ“ белән күрсәтәләр. — Четвертая буква татарского алфавита. Обозначает 18-ю букву арабского алфавита „айн“ и 19-ю букву „гайн“, а также 26-ю букву персидского алфавита „ге“, цифровое значение „айн“ 70, цифровое значение „гайн“ — 1 000.

**Габа** عبا *ис.* Өске йон кием (плащ кебек). *Габа киер, үз-үзен суфи белер.* (М. Кол.) — *сущ.* Аба (название шерстяной одежды в виде плаща).

**Габавәт** غباوت *ис.* Ангыралык, зиһенсезлек, аңсызлык, габилек. — *сущ.* Слабоумие, глупость, тупость.

**Габи** غبى *с.* 1) Аңгыра, зиһенсез, аңсыз. *Гаҗәп түгел сабый итә сабыйлык, гаҗәптер әмма галәмдә габилек.* (Дәрд.) 2) Надан. — *прил.* 1) Глупый, неразумный, тупой. 2) Невежда.

**Габид** عابد *сф.* Гыйбадәт итүче; коллык итүче, табынучы. — *пр. д.* Поклоняющийся; раболепствующий.

**Габиданә** عابدانه *гф. р.* Гыйбадәт кылучыларча, габидләрчә. — *ар.-п. н.* Благочестиво, набожно.

**Габгаб** غبغب *ис.* Ияк асты, тамак асты (хайванда); ике ияк, куш ияк. — *сущ.* Подгрудок (у животных); второй подбородок.

**Габде милләт** عبد ملت *ст.* „Милләт колы"; патриот. — *сс. букв.* „Раб нации"; патриот.

**Габдиять** عبديت *ис.* 1) Коллык. 2) Бәндәлек, табынучылык. *Монда габдиять, гыйбадәтнең илаһи серләре.* (Г. Тук.) — *сущ.* 1) Рабство. 2) Поклонение, служение.

**Габед** عبد *ис.* 1) Кол. 2) *дини* Бәндә. *Хәтта тәкълид без габедләргә гыйбадәттер дидем.* (Ш. Баб.) — *сущ.* 1) Раб, невольник, слуга. 2) *рел.* Раб божий.

**Габәс** عبث *ис.* 1) Уен. 2) Файдасыз эш, буш нәрсә, яраксыз, юк нәрсә. *Габәс уткәрмәгәйлем маһ вә сали.* (Г. Тук.) — *сущ.* 1) Игра, забава. 2) Напрасный, тщетный, бесполезный, ненужный, никчемный.

**Гаваид I** عوائد *ис.* Гаидә-нең *к.* — *сущ. мн.* от гаидә.

**Гаваид II** عوائد *ис.* Керемнәр, килерләр. *Төшәрде бер-беремезгә гаваид.* (Ут. Им.) 2) Салым, налог. — *сущ. мн.* 1) Прибыли, доходы. 2) Налог, подать.

**Гаваил** غوائل *ис.* Гаилә II-нең *к.* — *сущ. мн.* от гаилә II.

**Гавакыйб** عواقب *ис.* Гакыйбәт-нең *к.* **Гавакыйбе өмүр** — эшнең ахырлары, нәтиҗәләре. — *сущ. мн.* от гакыйбәт.

**Гавам** عوام *ис.* Масса, халык; кара халык. *Гавам бичараларны теләгәнчә алдады.* (З. Һад.) — *сущ.* Толпа, масса; чернь.

**Гавамил** عوامل *ис.* Гамил-нең *к.* — *сущ. мн.* от гамил.

**Гавамиз** عوامض *ис.* Гамиз-нең *к.* — *сущ. мн.* от гамиз.

**Гаваять** عوايه *ис.* 1) Адашу, турылыктан читкә чыгу. 2) Күңел азуы, коткы. — *сущ.* 1) Заблуждение. 2) Соблазн.

**Гад I** غد *ис.* Иртәгәге көн. — *сущ.* Завтрашний день.

**Гад II** عد *ис.* Сан, исәп. ... *гад улынан* — ... дип саналган, ... дип уйланган. *Укымышлы гад улынан шәкердләр.* (М. Ак.) — *сущ.* Счёт.

**Гадавәт** عداوت *ис.* 1) Дошманлык, ачу саклау, ачу итү. *Җәһаләт сәбәпле гадәвәтдер.* (З. Һад.) 2) Нәфрәт, күрәлмау, дошман күрү. — *сущ.* 1) Вражда, враждебность. 2) Ненависть.

**Гадаләт** عدالت *ис.* Турылык, гаделлек. *Тип-тигез салган була, гүя гадаләт курсәтә.* (Г. Тук.) — *сущ.* Справедливость; правосудие.

**Гадат** عادات *ис.* Гадәт-нең *к.* — *сущ. мн.* от гадәт.

**Гадаэ** غدا *ис.* Иртәнге аш. — *сущ.* Завтрак.

**Гаддар** غدار *ис.* 1) Хыянәтче, хаин, сатлык җан. *Гаддар дошманның эленә* (кулына) *тотып вирде.* (М. Ак.) 2) Җәберләүче, золым итүче, залим. — *сущ.* 1) Изменник, предатель. 2) Насильник, мучитель, тиран.

**Гаддаранә** غدارانه *гф. р.* Хыянәтчел рәвештә, хаиннарча. — *ар.-п. н.* Предательски, вероломно.

**Гадел*** عدل *м. I.* **1.** 1) Турылыклылык, гаделлек. 2) Турылык, дөреслек. **2.** Туры, гадел, турылыклы. — *м.I.* **1,** 1) Справедливость, правосудие. 2) Прямота, честность, правота. **2.** Справедливый, правосудный.

**Гаден** عدن *ис.* 1) Җәннәт исеме. 2) Гаден шәһәре (Гарәбстанда). 3) Даими тору урыны. — *сущ.* 1) Эдем (рай). 2) Аден (город на Аравийском полуострове). 3) Постоянное место жительства.

**Гади*** عادى *с.* Катлаусыз, гадәттәге, гади. — *прил.* Простой, обычный.

**Гадид** عديد *с.* 1) Күп санлы, берничә. 2) Сан, микъдар. — *прил.* 1) Многочисленный. 2) Численность, количество.

**Гадил I** عادل *сф.* Турылыклы; туры, дөрес хөкем итүче; турылык (дөреслек) белән эш итүче, гадел. — *пр. д.* Справедливый; правосудный; честный, правдивый.

**Гадил II** عديل *с.* Тигез, тин, охшаш. — *прил.* Равный, подобный; схожий, похожий.

**Гадиляпә** عادلانه *гф. р.* Гаделлек белән, яклашусыз, турылык белән. — *ар.-п. н.* Справедливо, честно.

**Гадим** عديم *с.* (Берәр нәрсәсе) булмаган. *Гадимел хәя* — оятлы булмаган, оятсыз. — *прил.* Не имеющий, лишённый (чего-либо).

**Гадир** غادر *сф.* Хыянәтче, алдакчы. — *пр. д.* Вероломный, предательский, неверный.

**Гадли** عدلى *с.* 1) Гадел, турылыклы. 2) Хөкем-суд эшләренә бәйләнешле. — *прил.* 1) Справедливый. 2) Связанный с юстицией, судебный.

**Гадлия** عدليه *ис.* Юстиция. — *сущ.* Юстиция.

**Гадр** غدر *ис.* 1) Хыянәт; алдау, сүздә тормау. 2) Мәкерлелек. 3) Золым; мәрхәмәтсезлек. *Ит надانлыкларны тәгъриф, зәһрене яз, гадрене.* (Г. Тук.) — *сущ.* 1) Вероломство, измена, предательство. 2) Коварство. 3) Гнёт, насилие; несправедливость.

**Гадәд** عدد *ис.* 1) Сан. *Миллион ярым гадәдле бәни адәм урынына 7—8 җанлы курчаклар һәм „ата" булыр.* (Ф. Әмир.) 2) Данә, нөсхә, номер. — *сущ.* 1) Число; цифра. 2) Экземпляр; штука, номер.

**Гадәде кәсри** عدد كسرى *ст.* Вакланмалы сан, вакланма сан. — *сс.* Дробное числительное.

**Гадәде мотлак** عددمطلق *ст.* Саналмышсыз килгән сан. — *сс.* Числительное без исчисляемого.

**Гадәде мөгайян** عددمعين *ст.* Исемле сан, саналмышын күрсәтеп килгән сан (1 китап, 5 ат). — *сс.* Числительное со своим исчисляемым (одна книга, пять коней и т. п.).

**Гадәде мөрәккәб** عدد مركب *ст.* Кушма сан. — *сс.* Сложное числительное.

**Гадәде там** عددتام *ст.* Бөтен сан. — *сс.* Целое число.

**Гадәде әгъшари** عدداعشارى *ст.* Унарлы вакланма. — *сс.* Десятичная дробь.

**Гадәди** عددى *с.* 1) Сан(га), цифр(га бәйләнешле). 2) Унарлап (дистәләп) санала торган. — *прил.* 1) Числовой, цифровой. 2) Считаемый десятками.

**Гадәм** عدم *ис.* Юк булу, юклык, булмау. *Вөҗүденә караганда гадәме яхшы* — булуына караганда булмавы яхшы. — *сущ.* 1) Отсутствие, небытие. 2) Без-, бес-, не.

**Гадәм икътидар** عدماقتدار *из.* Көч җитмәү, булдыра алмау, кулдан килмәү. — *из.* Неспособность; немощь, бессилие.

**Гадәт*** عادت *ис.* Өйрәнелгән, һәрвакыт эшләнә торган эш, күнегелгән эш; йола, гадәт. — *сущ.* Обычай, обыкновение, привычка, привычное дело.

**Гадәтән** عادتاً *р.* Гадәт буенча. — *н.* Обычно, по привычке.

**Гадү** عدو *ис.* 1) Дошман. *Гадүләр һәр тарафдин күп.* (Г. Чок.) 2) Яу. — 1) Враг. 2) Полчище, рать.

**Газа** غزا *ис.* Сугыш (изге сугыш). — *сущ.* Война (священная).

**Газаб*** عذاب *ис.* Азап, җәфа, җәза. — *сущ.* Мука, страдание.

**Газазил** عزازيل *ис.* 1) Иблис, шайтан. 2) *миф.* Җәннәттән куылган бер фәрештә исеме. *Инде аны мәңгегә иблис диләр, газазил дип эндәшергә кушмыйлар.* (Ш. Баб.) — *сущ.* 1) Дьявол, чёрт. 2) *миф.* Имя ангела, изгнанного из рая.

**Газаим** عظائم *ис.* Газыймә-нең *к.*

*сущ. мн.* от газыймә.

**Газаль** غزال *ис.* 1) Кыр кәҗәсе. 2) *Куч.* Матур, сөекле.

*сущ.* 1) Газель, антилопа. 2) *перен.* Красивая, любимая.

**Газамәт** عظمت *ис.* 1) Олылык, бөеклек. *Газамәтле диңгез ай яктысында ялтырый.* (Ш. Кам.) 2) Тантана, мәһабәтлек. 3) Горурлык.

*сущ.* 1) Величие, достоинство. 2) Великолепие. 3) Гордость.

**Газаә** عزا *ис.* Сабырлык күрсәтү; борчылмау.

*сущ.* 1) Терпение. 2) Безмятежность.

**Газбан** غضبان *с.* Ачулы, ачуланган.

*прил.* Гневный, сердитый.

**Газбнакь** غضبناك *гф.* *ис.* Ачулы кеше.

*ар.-п.* *сущ.* Сердитый, гневливый человек.

**Газвә** غزوه *ис.* Сугыш; һөҗүм итү.

*сущ.* Поход, набег, нашествие; война.

**Газд** عضد *ис.* Кул, беләк; беләк сөяге.

*сущ.* Рука, предплечье; плечевая кость.

**Газеб** عذب *с.* 1) Татлы, тәмле, ләззәтле. *Лисане газеб* — татлы тел. 2) Төче. *Маә газеб* — төче (тозсыз) су.

*прил.* 1) Сладкий; приятный, нежный; сладкоязычный. 2) Пресный.

**Газел** عزل *ис.* 1) Урыннан төшерү, хезмәттән чыгару. *Патшалыктан карганы газел дә кылмак булдылар.* (М. Гаф.) 2) Читләтү.

*сущ.* 1) Смещение, отстранение, увольнение (со службы); отставка. 2) Удаление; отделение, изоляция.

**Газем** عزم *ис.* 1) Тәвәккәллек, кискен ният. 2) Бер ният белән юлга чыгу.

*сущ.* 1) Решимость; твёрдое решение. 2) Отправление куда-нибудь с какой-либо целью.

**Газзә вә җәлл (ә)** عزوجل *ст.* *дини* Югары кадер һәм бөеклек иясе (алла дигән урында кулланыла).

*сс.* *рел.* Величие и великолепие (эпитет аллаха).

**Гази** عازى *сф.* 1) Сугышта җиңеп чыгучы; яулап алучы. 2) Дошман белән сугышучы.

*пр. д.* 1) Победитель; завоеватель, захватчик. 2) Воин.

**Газиз*** عزيز *с.* 1) Кадерле, хөрмәтле, газиз. 2) Кыйммәтле. *Бу игенне газиз белеп һәркем игәр.* (М. Кол.) 3) *дини* Изге. 4) Патша, хаким.

*прил.* 1) Милый, дорогой. 2) Редкий, ценный. 3) *рел.* Святой. 4) Правитель, властелин.

**Газим** عازم *сф.* 1) Алдан уйлап куючы, исәпләүче, ниятләүче. 2) Батырчылык итүче, кыюлык итүче. 3) Баручы, юл тотучы. *Уалым җөмләмез бер юла газим.* (Г. Тук.)

*пр. д.* 1) Намеревающийся, решившийся (на что-либо). 2) Смелый, решительный; твёрдый. 3) Следующий по определённому пути.

**Газимәт** عزيمت *ис.* 1) Күңелдән уйлап кую, ниятләнү. *Ризык хасиль итмәк өчен Бәгъдадтан күчмәгә газимәт кыйлдылар.* (К. Нас.) 2) Юлга чыгу, сәфәр кылу.

*сущ.* 1) Намерение; заветное желание. 2) Отправление в путь; поездка.

**Газлә** عضله *ис.* Сум ит, мускул.

*сущ.* Мускул, мышца.

**Газм** عظم *ис. к.* Сөякләр.

*сущ. мн.* Кости.

**Газраил** عزرائل *ис.* 1) *дини* Газраил (җан алучы фәрештә). 2) Каты күңелле, шәфкатьсез.

1) *рел. и. с.* Азраил (ангел смерти). 2) Жестокосердный, жестокий.

**Газраэ** عذراء *ис.* Кыз, гыйффәтле кыз.

*сущ.* Девственница, девушка.

**Газыб** غضب *м. I.* Ачу; ачулану; кызулану. *Газыбилә агзыннан утлар чәчәр.* (Г. Тук.)

*м. I.* Гнев, недовольство; злоба.

**Газыйм** عظيم *с.* 1) Бөек. 2) Чиксез зур. 3) Югары дәрәҗәле; бик өлкән. 4) Әһәмиятле, җитди.

*прил.* 1) Великий. 2) Огромный. 3) Знатный. 4) Важный; серьёзный.

**Газыймә** عظيمه *ис.* Гадәттән тыш зур эш, әһәмиятле мәсьәлә.

*сущ.* Важное (великое) событие (дело).

**Газәват** غزوات *ис.* Газвә-нең *к.*

*сущ. мн.* от газвә.

**Газәл** غزل *ис.* 1) Гыйшык-мәхәббәт шигырьләре, бәетләре. 2) Сөйгән кызга карата язылган мәдхия.

*сущ.* 1) Газель, лирическое стихотворение. 2) Ода, хвалебный стих.

**Газәлият** غزليات *ис. к.* Гыйшык-мәхәббәткә бәйләнешле шигырьләр (җыентыгы).

*сущ. мн.* Сборник любовных стихотворений.

**Газү** عزو *ис.* Йөкләү, аудару, бер эш яки сүзне берәр кешегә аудару, аның эше (сүзе) дер дип күрсәтү, ябсару.

*сущ.* Отнесение (к чему-либо); приписывание (кому-либо) чего-либо.

**Гаиб** غائب *сф.* 1) Күз алдыннан югалучы; күз алдында булмаучы, күз арты. 2) Юкка чыккан, күздән югалган. *Кичә чыгып киткән Шәех шул көе гаиб булды.* (М. Гаф.)

*пр. д.* 1) Отсутствующий. 2) Скрытый, невидимый; исчезнувший, скрывшийся.

**Гаибанә** غائبانه *гф. р.* Күрмичә, күз артында торып, читтән торып, үзе юкта.

*ар.-п. н.* Заглазно, заочно, в отсутствие.

**Гаид** عائد *сф.* 1) Берәр нәрсәгә кайтучы, кайткан. *Сөйләячәгем — унҗиде яшь тулып яңа унсигезгә чыккан заманыма гаид.* (Г. Ибр.) 2) ...-га караучы, ...-га караган, ...-га бәйләнешле, ...-га бәйләнеше булган.

*пр. д.* 1) Восходящий (к чему-либо). 2) Имеющий отношение к чему-либо.

**Гаидә** عائده *ис.* 1) Берәр нәрсәгә бәйле керем; хезмәт куймыйча килә торган доход. 2) Файда. — *сущ.* 1) Поступление (извне), прибыль, доход, рента. 2) Польза, выгода.

**Гаикъ** عائق *сф.* 1) Кичектерүче, тоткарлык ясаучы. 2) Киртә, тоткарлык. — *пр. д.* 1) Препятствующий. 2) Преграда, помеха, загруднение.

**Гаика** عائقه *ис.* Берәр эшнең кичегүенә сәбәп булган нәрсә. — *сущ.* Преграда, помеха; задержка, замедление.

**Гаилә* I** عائله *ис.* Өй җәмәгате, семья. — *сущ.* Семья, семейство; фамилия.

**Гаилә II** غائله *ис.* 1) Бәла, борчу. 2) Авыр эш, читен мәсьәлә. — *сущ.* 1) Зло, несчастье; бедствие, беда, загруднение. 2) Трудный, сложный вопрос.

**Гайб I** غيب *м. I.* 1) Күз алдында булмау, гаип булу; 2) Билгесез әйбер, көтмәгән нәрсә, уйламаган әйбер; сер. — *м. I.* 1) Отсутствие. 2) Всё невидимое, сокровенное; неожиданное; тайна.

**Гайб II** عيب *м. I.* 1) Кимчелек, җитешсезлек, гаеп. 2) Яманлау. — *м. I.* 1) Недостаток, порок. 2) Порицание.

**Гайбәт*** غيبت *ис.* Берәүнең артында гаепләрен сөйләү, яманлау; гайбәт. — *сущ.* Сплетня, хула; дурная молва, худая слава.

**Гайбүбәт** غيبوبت *ис.* Күз алдында булмау, югалу, юкка чыгу. *Кальбемә гайбүбәтең таглар кадәр вирде кәдер.* (Г. Тук.) — *сущ.* Отсутствие, исчезновение.

**Гайд** عيد *ис.* 1) Бәйрәм. 2) *дини* Гает. — *сущ.* 1) Праздник. 2) *рел.* Праздник гает (в конце месяца Рамазана).

**Гайде фитыр** — عيدفطر ураза гаете. — Праздник разговения.

**Гайд әзхия** — عيداضحيه корбан гаете. — Праздник жертвоприношения.

**Гайз** غيظ *м. I.* Ачу, орышу, ачулану. — *м. I.* Гнев, раздражение, ярость.

**Гайн I** غين *ис.* غ хәрефенең исеме. — *сущ.* Название буквы « غ ».

**Гайн II** عين *ис.* **1.** 1) Күз. 2) Чишмә, болак. 3) Дәүләтнең күренекле кешесе. 4) ع хәрефенең исеме. **2.** 1) Үзе; нәкъ үзе, чат үзе, бөтенләй үзе кебек. 2) Бөтенләй, тулысынча. *Сыйххәткә гайне зарардыр.* (К. Нас.) — *сущ.* **1.** 1) Глаз. 2) Источник (воды). 3) Видный деятель государства. 4) Название буквы « ع ». **2.** 1) Тот же самый, он сам. 2) Совсем, полностью.

**Гайнелякыйн** عين اليقين *из.* Ачыктан-ачык, бөтенләй ачык. *Арысланның ниятен гайнелякыйн белде.* (Г. Фәез.) — *из.* Ясно, со всей очевидностью, точно.

**Гайни** عينى *с.* 1) Күз(гә), күрү(гә бәйләнешле). 2) Әһәмиятле. — *прил.* 1) Глазной. 2) Существенный.

**Гайнән** عيناً *р.* Үзгәртмичә; ничек булса, шул көенчә; үзенчә. — *н.* В точности, точь-в-точь; подлинно; в подлиннике.

**Гайре** غير *с.* 1) Бүтән, башка, үзгә. *Фәриднең боннан гайре хезмәте юк иде.* (З. Биг.) 2) Гарәпчә сыйфат яки сыйфат фигыльләр белән килгәндә татарчада „сыз-сез“ кушымчасы яки „түгел“ мәгънәсен аңлата. *Кочакларга аны шул гайре мөмкин.* (Г. Тук.) — *прил.* 1) Иное, другое. 2) Не, без, бес. (Перед прилагательными и причастиями выполняет роль отрицательных частиц.)

**Гайре гамил** غيرعامل *ст.* Эшләмәүче. — *сс.* Не работающий.

**Гайре ихтыяри** غيراختيارى *ст.* 1) Ихтыярсыз. 2) Көчләнеп, мәҗбүри рәвештә. — *сс.* 1) Невольно, вынужденно. 2) Насильно, силой, принудительно.

**Гайре могайян** غيرمعين *ст.* Билгесез. *Мәгъюбләрнең һәр икесен халык алдында гайре могайян рәвештә тәүбә иттерделәр.* (Г. Ибр.) — *сс.* Неопределенный, неясный.

**Гайре мә ъкуль** غير معقول *ст.* Акылга муафыйк түгел, акылга сыймый торган. *Җуләрлек ул өйләнмәк — гайре мәгъкуль.* (Г. Тук.) — *сс.* Неразумный, нелогичный; непонятный; абсурдный.

**Гайре мәгъруф** غير معروف *ст.* Гадәт-горефтә булмаган, халык каршында танылмаган. — *сс.* 1) Неизвестный; не существующий в обычаях. 2) Непризнанный.

**Гайре мәхдүд** غيرمحدود *ст.* Чикләнмәгән. — *сс.* Неограниченный.

**Гайре мөмкин** غيرممكين *ст.* Мөмкин түгел, булдырып булмый, мөмкин булмаган. — *сс.* Невозможный; невыполнимый.

**Гайре мөнтазам** غيرمنتظم *ст.* Тәртипсез, рәтсез. — *сс.* Неорганизованный; беспорядочный.

**Гайре мөнтәһа** غيرمنتهى *ст.* Иксез-чиксез. — *сс.* Бесконечный, беспредельный, нескончаемый.

**Гайре мөтәнаһи** غيرمتناهى *ст.* Чиксез; исәпсез-хисапсыз. — *сс.* Бесконечный, беспредельный.

**Гайре нәтыйк** غيرناطق *ст.* 1) Сөйләшми торган. 2) Хайван. — *сс.* 1) Бессловесный. 2) Животное.

**Гайре рәсми** غيررسمى *ст.* Рәсми булмаган. — *сс.* Неофициальный.

**Гайре табигый** غيرطبيعى *ст.* Табигый булмаган. *Шулай итеп, бөтен хәрәкәтендә гайре табигыйлек күрсәтә иде.* (М. Гаф.) — *сс.* Неестественный.

**Гайре жаиз** غيرجائز *ст.* Тыелган, ярамый торган. — *сс.* Недозволенный, запрещённый.

**Гайрәт*** غيرت *ис.* **1.** 1) Батырлык, кыюлык. 2) Тырышлык. *Яхшы тәрбия кылмага гайрәт идәм.* (З. Биг.) 3) Көч, энергия. 4) Чыдамлык, үз-үзен тота алу сәләте. **2.** 1) Үз фикеренә бик нык ябышып яту. 2) Ашкынып-ашкынып эшләү. 3) Җикеренү. — *сущ.* **1.** 1) Смелость, мужество. 2) Усердие, рвение, пыл. 3) Энергия. 4) Самообладание, терпение. **2.** 1) Самоуверенность. 2) Возбуждённость. 3) Покрикивание (на кого-либо), грубость.

**Гайш** عيش *ис.* 1) Тормыш, тереклек, яшәеш. 2) Икмәк, ашау-эчү. — *сущ.* 1) Жизнь, существование. 2) Хлеб, пища, пропитание.

**Гайяр I** غيار *ис.* Гайрәт нясе, дәртле кеше, гайрәтле. — *сущ.* Усердный, ревностный, энергичный.

**Гайяр II** عيار *с.* 1) Ялганчы, алдакчы. 2) Хәйләкәр. — *прил.* 1) Обманщик, плут. 2) Хитрый.

**Гайяш** عياش *ис.* 1) Кәеф-сафа коруны бик яратучы. 2) Икмәк сатучы. — *сущ.* 1) Гуляка. 2) Торговец хлебом.

**Гак** عاق *с.* 1) Буйсынмаучы, буйсынмас, баш имәс, бунт күтәрүче, фетнәче. 2) Каргалган, ләгънәтләнгән. *Җәһәләтдин улыр остазига гак.* (Ут. Им.) — *прил.* Непокорный, бунтующий. 2) Проклятый, подвергшийся проклятию.

**Гаканд** عقائد *ис.* Гакыйдә-нын *к.* — *сущ. мн.* от гакыйдә.

**Гакакыйр** عقاقير *ис. к.* Дару үләннәре, үлән тамырлары, дару-дәрман; имчеләр даруы. *Сырхауга үз җиренең гакакыйре килешәрәк бирәдер.* (К. Нас.) — *сущ. мн.* Зелья, снадобья, лекарства, лекарственные травы.

**Гакар** عقار *ис.* Билгеле бер килере булган күчми торган милек (өй, җир, бакча һ. б.). — *сущ.* 1) Недвижимость. 2) Имение, поместье.

**Гакариб** عقارب *ис.* Гакрәб-нең *к.* — *сущ. мн.* от гакрәб.

**Гак-госый** عاق‌عصى *ст.* Ата-анасын рәнжеткән гөнаһлы кеше. *Атамыза гак-госый улдыгымыз.* (К. Гал.) — *сс.* Обижающий родителей; грешный в оскорблении родителей.

**Гакде мөгаһәдә** عقد معاهده *из.* Договор төзү. — *из.* Заключение договора.

**Гакде никях** عقدنكاح *из.* Никях уку (шаһитлар каршында егет белән кызның өйләнешүләренә ризалыкларын язу эше). *Иске заман гадәтенчә Фәхрелбәнатның сигез яшендә гакде никяхы булды.* (З. Һад.) — *из.* Заключение брачного соглашения.

**Гакес** عكس *ис.* **1.** 1) Капма-каршылык, киресе. 2) Кире як, тискәре як. **2.** Яктылык нурының кире кайтуы. *Ко-* — *сущ.* **1.** 1) Противоположность. 2) Оборотная

*яшьнең нурын гакес итеп күзне камаштырып тора иде.* (М. Гаф.) — сторона. **2.** Отражение (лучей, света).

**Гаккылвалидәйн** عاق الوالدين *гыйб.* Ата-анасына хөрмәт күрсәтмәүче, ата-ана сүзен тотмаучы, ата-ананы санга санамаучы. — *фр.* Непослушный, непокорный, непочтительный (о сыне).

**Гаклы кәсби** عقل كسبى *ст.* Укү, өйрәнү эше, тәҗрибә юлы белән алынган акыл. — *сс.* Ум, приобретённый в процессе труда (в ученье, на практике).

**Гаклы сәлим** عقل سليم *ст.* Сәламәт акыл, тулы акыл. — *сс.* Здравый смысл.

**Гаклы табигый** عقل طبيعى *ст.* Тумыштан булган акыл. — *сс.* Природный ум.

**Гаклый** عقلى *с.* Акыл(га бәйләнешле). — *прил.* 1) Умственный, интеллектуальный. 2) Умозрительный.

**Гаклыят** عقليات *ис. к.* Уйлап беленгән, табылган фикерләр, төшенчәләр; философик төшенчәләр. — *сущ. мн.* Всё, постигаемое умозрительным путём; философские понятия.

**Гаклән** عقلاً *р.* Акыл буенча, акылга салып карап. — *н.* Умно, по-умному, разумно.

**Гакрәб** عقرب *ис.* 1) Чаян. 2) Зодиак тамгасы буенча 22 октябрьдан 22 ноябрьгача була торган вакыт (октябрь ае). — *сущ.* 1) Скорпион. 2) По знаку Зодиака время между 22/X—22/XI (октябрь).

**Гакселхәрәкәт** عكس الحركت *из.* 1) Каршы юл тоту, каршы хәрәкәт итү, каршы йөреш. 2) Революциягә каршы хәрәкәт. — *из.* 1) Контрдвижение. 2) Контрреволюционное движение.

**Гакур** عقور *с.* 1) Зәһәр, явыз. 2) Чага (тешли) торган. — *прил.* 1) Злобный, злой. 2) Кусающийся, жалящий.

**Гакыб** عقب *ис.* 1) Үкчә. 2) Сон, нәтиҗә. — *сущ.* 1) Пятка. 2) Исход, результат, конец.

**Гакыд** عقد *м. I.* 1) Бәйләү, төенләү. 2) Сүз бирешү, сүз бәйләшү, сөйләшеп килешү төзү. *Ялганчылык белән мәшһүр кеше гакыд кылса, гакыдендә ышаныч булмас.* (К. Нас.) 3) Төен. — *м. I.* 1) Связывание. 2) Заключение (договора); соглашение. 3) Узел.

**Гакыйб** عقيب *с.* Бер нәрсәнең артыннан килгән, соңында булган. — *прил.* Следующий (за кем-либо, чем-либо).

**Гакыйбәт** عاقبت *ис.* Соң, ахыр, азак; эшнең соңы, нәтиҗәсе. *Һәр катылыкның гакыйбәте шатлыктыр.* (К. Нас.) — *сущ.* Последствие, исход, результат.

**Гакыйд** عاقد *сф.* Договор төзүче ике якның берсе, берәр эш турында сүз беркетеп язышучы якларның берсе, договор төзүче. — *пр. д.* Договаривающийся, одна из договаривающихся сторон.

**Гакыйдә** عقيده *ис. дини* Ышану, иман. — *сущ. рел.* Вера, убеждение.

**Гакыйк** عقيق *ис.* 1) *мин.* Ахак ташы. 2) Агым су юлы. — *сущ.* 1) *мин.* Сердолик. 2) Водный путь; русло.

**Гакыйланә** عاقلانه *р.* Акыллы кешечә, акыллы кешеләр кебек, акыллылардай, акыл белән. — *н.* По-умному, разумно, с умом.

**Гакыйль** عاقل *сф.* Акыллы, акыл иясе; акылга утырган кеше. — *пр. д.* Умный, разумный; находящийся в здравом уме.

**Гакыйлә** عاقله *сф.* Акыллы (хатын-кыз). — *пр. д.* Умная, разумная.

**Гакыйм** عقيم *с.* 1) Баласы булмый торган ир кеше. 2) Җитештерми торган. — *прил.* 1) Бесплодный, бездетный. 2) Непроизводительный.

**Гакыймә** عقيمه *с.* Баласы булмый торган хатын. — *прил.* Бесплодная (женщина).

**Гакыйр** عاقر *сф.* 1) Кысыр. 2) Уңыш бирми торган. 3) *кара:* гакыймә. — *пр. д.* 1) Бесплодная (о женщине). 2) Бесплодный.

**Гакыл** عقل *ис.* Акыл, аң, аңлый белүелек, дөрес фикер йөртүчелек. — *сущ.* Ум, разум, интеллект; понимание, здравый смысл.

**Гали I** عالى *сф.* 1) Бөек, өстен, олы. *Күңел югарылана әллә нинди гали хис белән.* (М. Гаф.) 2) Биек, югары, күтәренке. *Ничек гали минем урным, түбәннәр күрәмсез ди.* (Г. Тук.) 3) Югары дәрәҗәле. *Телим булырга мин инсане гали* ... (Г. Тук.) — *пр. д.* 1) Выдающийся; великий. 2) Высокий, возвышенный. 3) Знатный.

**Гали II** غالى *сф.* Кыйбат, бәһалы, югары бәяле. — *пр. д.* Дорогой, высокий (по цене).

**Галиб** غالب *сф.* Җиңүче, өстен чыгучы, өстенлекле, (көрәштә җиңеп) өстенлек алучы. *Бәнем мәхәббәтемә һичкем галиб булмаз.* (М. Ак.) — *пр. д.* 1) Побеждающий, превосходящий. 2) Преобладающий. 3) Победитель.

**Галибанә** غالبانه *гф. р.* Җиңгәнсыман булып, батырларча, җиңүчеләрчә, каһарманнарча. *Галибанә яктырып әкрен генә ал таң ата.* (Г. Тук.) — *ар.-п. н.* Победоносно; геройски.

**Галибиять** غالبيت *ис.* Җиңү, җиңеп өстен чыгу. — *сущ.* Преобладание, превосходство; победа.

**Галибән** غالبًا *р.* Күбрәк вакытта, күп чакта, күбесенчә. — *н.* По большей части, чаще всего, по преимуществу.

**Гализ** غليظ *с.* 1) Тупас; әдәпсез. 2) Юан. — *прил.* 1) Грубый, жёсткий; невоспитанный. 2) Толстый.

**Галил** عليل *с.* 1) Авыру, зәгыйфь. 2) Көчсез, хәлсез. — *прил.* 1) Больной, хворый. 2) Хилый, бессильный.

**Галим* I** عالم *сф.* Белүче, укымышлы, белекле, белемле. — *пр. д.* Знающий, сведущий; учёный.

**Галим II** عليم *с.* Бик белүче, һәрнәрсәне белүче, барын да белүче. — *прил.* Знающий, сведущий; эрудированный; всеведущий.

**Галим гайре гамил** عالم غیرعامل *гыйб.* Белгәне белән эш итмәүче белгеч, белгәнен тотмаучы. *Галим гайре гамилгә бирәү әйтте:* ... (К. Нас.) — *фр.* Учёный без дела (в смысле без пользы).

**Галиманә** عالمانه *р.* Укымышлыларча, белемле кешеләр кебек. — *н.* По-учёному.

**Гали мәкам** عالی مقام *ст.* 1. Бөек урынлы, зур дәрәҗәле. 2. Зур урын. — *сс.* 1. Имеющий высокое положение. 2. Высокое положение, большая должность.

**Гали шән** عالی شان *гф. ст.* Бөек (зур, югары) дәрәҗәле; кадерле, мәртәбәле. — *ар.-п. сс.* Высокопоставленный, сановитый, именитый.

**Галия** عاليه *сф.* Гали I-нең *мнс.* — *пр. д. жен.* от гали I.

**Гали җәнаб** عالی جناب *ст.* 1) Бөек, мөхтәрәм. 2) Зур дәрәҗәгә ия булучы. — *сс.* 1) Высокий, почтенный, уважаемый. 2) (Его) превосходительство.

**Гали һиммәт** عالی همت *ст.* 1. Югары ният, уй; яхшы уй. 2. 1) Бик юмарт. 2) Бик тырыш, гайрәтле. — *сс.* 1. Благонамеренность. 2. 1) Щедрый. 2) Деятельный, энергичный.

**Галлям** علام *ис.* Бик күп белүче. — *сущ.* Весьма знающий, всесведущий.

**Галлямелгоюб** علام الغیوب *из. дини* Кешеләрнең житешсезлекләрен белүче (алла турында). — *из. рел.* Знающий о недостатках людей (эпитет аллаха).

**Галлямә** علامه *ис.* Күп фәннән белеме булган кеше, бик галим, бик белгеч, зур укымышлы. — *сущ.* Выдающийся учёный, высокообразованный, эрудит.

**Галлә** غله *ис.* 1) Ашлык, бөртекле ашлык, иген уңышы. 2) Керем. 3) Урыпҗыю. — *сущ.* 1) Продукция, урожай, зерно, зерновой хлеб. 2) Сбор, доход. 3) Жатва.

**Галтан** غلتان (غلطان) *ф. с.* 1) Йомры, йомарлак, түгәрәк. *Бар иде хәзинәдә һәм дөрре галтан* (Сайяди). 2) Әйләнүче. — *п. прил.* 1) Круглый. 2) Вращающийся, катящийся.

**Галь** عال *с.* 1) Югары, биек. 2) Иң яхшы, менә дигән. — *прил.* 1) Высокий, великий. 2) Превосходный; первоклассный.

**Галяикъ** علائق *ис.* Галяка-ның *к.* — *сущ. мн.* от галяка.

**Галяим** علائم *ис.* Галямәт-нең *к.* — *сущ. мн.* от галямәт.

**Галяка** علاقه *ис.* Бәйләнеш, үзара якынлык, аралашу, элемтә, мөнәсәбәт. — *сущ.* Связь, отношение, близость.

**Галякадар** علاقه‌دار *гф. ис.* Бәйләнеш тотучы, бәйләнештә булучы. — *ар.-п. сущ.* Имеющий отношение (к чему-либо).

**Галямәт*** علامت *ис.* 1) Галәмәт, билге, тамга; значок. 2) Хәзерге татар телендә *бик, үтә* сүзләре мәгънәсендә дә кулланыла. *Бер дә галямәт тырышкан: хәрефләре берсеннән-берсе матур...* (Ф. Хөсни.) — *сущ.* 1) Знак, метка; значок; признак. 2) В современном татарском языке употребляется в значении слов *очень, слишком.*

**Галяниять** علانيت *ис.* Бер эшнең ачыктан-ачык эшләнүе, ачык һәм билгеле булу, ачыклык. — *сущ.* 1) Явность. 2) Публичность.

**Галяниятән** علانيةً *р.* Ачык итеп, ачыктан-ачык, бөтен халык алдында. — *н.* Публично, открыто, явно.

**Галяэ I** علاء *ис.* 1) Биеклек, югарылык. 2) Югары сыйфатлылык, бик шәп булу. — *сущ.* 1) Высота, высь, высокое положение. 2) Высокое качество.

**Галяэ II** غلاء *ис.* Кыйммәтчелек, бәяләр күтәренкелеге. — *сущ.* Дороговизна, высокая стоимость.

**Галә** على *грам. бәйл.* Рәвеш ясау өчен кулланыла торган бәйлек. — *пред. грам.* Предлог, служащий для образования наречий.

**Галәбә** غلبه *ис.* 1) Җиңү, өстен булу, өстенлек. *Галәбә иткәнсыман көлеп куйды.* (Ф. Әмир.) 2) Шау-шу. — *сущ.* 1) Победа, превосходство. 2) Шум, суматоха.

**Галә вәфкыйлматлуб** على وفق المطلوب *гыйб.* Ничек теләсә шулай, теләгән рәвештә, теләгәнчә. — *фр.* Согласно с требованием, соответственно с...; как хотел так и,..

**Галәддәвам** على الدوام *ст.* Бертуктамыйча, һаман, һичтуктаусыз, тоташтан. — *сс.* Постоянно, беспрестанно, безостановочно.

**Галәйкем** عليكم *алм.* Сезгә, сезгә булсын. — *мест.* На вас, вам, над вами.

**Галәйкә** عليك *алм.* Сиңа, сиңа булсын. — *мест.* На тебя, тебе, над тобой.

**Галәйһа** عليها *алм.* Аңа (хатын-кызга), аңа булсын. — *мест.* На нее, ей, над ней.

**Галәйһеллэгънәти** عليه اللعنه *гыйб.* Аңа ләгънәт булсын. *Мулла „газазил“ иде абзаң аты, ә хәзер „Иблис галәйһеллэгънәти“.* (Ш. Баб.) — *фр.* Да будет на нём проклятие, будь он проклят.

**Галәйһи** عليه *алм.* Аңа, аңа булсын. *Галәйһенә* — аның зарарына, аңа каршы. — *мест.* На него, ему, на нём.

**Галәйһим** عليهم *алм.* Аларга, аларга булсын. — *мест.* На них, им, над ними.

**Галәйһима** عليهما *алм.* Аларның икесенә, икесенә булсын. — *мест.* На них (двоих), им (двоим), над ними (двоими).

**Галә кадәриттакать** على قدر الطاقة *гыйб.* Көче җиткән кадәр, хәл кадәренчә. — *фр.* По мере сил, по возможности.

**Галә көллеттәкъдир** على كل التقدير *гыйб.* Һәр очракта, һәрхәлдә. — *фр.* Во всяком случае.

**Галә көлле халь** على كل حال *гыйб.* Һәрхәлдә, ничек кенә булса да. — *фр.* Во всяком случае; как бы то ни было.

**Галәлгадәт** على العادة *ст.* Гадәттәгечә; гадәт буенча, гореф (йола) буенча. — *сс.* Как обычно, согласно обычаю.

**Галәлгафлә** على الغفله *ст.* Гафиллек белән, белмичә, сизмичә, хәбәрсез калып, искәрмәстән. — *сс.* Неожиданно, врасплох; по глупости, по незнанию, не разобравшись.

**Галәлгаҗлә** على العجله *ст.* Ашыгычлык белән, бик ашыгып, ашык-пошык. — *сс.* Скоро, быстро; поспешно, наспех.

**Галәлгомум** على العموم *ст.* 1) Бөтенесе берлектә, тулаем. 2) Гомумән. — *сс.* 1) Сообща, совокупно. 2) Вообще.

**Галәлгомъя** على العميا *ст.* Сукырлык белән, сукыр килеш, күз йомып, сукырларча; аны-моны карап тормыйча. *Галәлгомъя фикер йөртми бераз да.* (Г. Тук.) — *сс.* Вслепую; ни на что не обращая внимания; закрыв глаза.

**Галәликраһ** على الاكراه *ст.* Көчләп, ирексезләп, җәберләп. — *сс.* Принудительно, насильно.

**Галәлитлак** على الاطلاق *ст.* Киң мәгънәдә, гомумән, тулаем (берәүгә генә каратып түгел). — *сс.* Абсолютно; в широком смысле, вообще.

**Галәлкавел** على القول *ст.* 1) Бер сүз белән әйткәндә, кыскасы. 2) Әйткән сүзләргә караганда. — *сс.* 1) Одним словом. 2) Согласно сказанному, по словам...

**Галәлкыяс** على القياس *ст.* Ошатып нәтиҗә чыгару юлы белән, тиңдәштереп карау юлы белән, аналогия буенча. — *сс.* По сравнению; по аналогии; сравнительно с...

**Галәлкәсрәт** على الكثرت *ст.* Күбесенчә, күп очракта, күпләп. *Бу китаплар бу мәмләкәтләрдә галәлкәсрәт табыладыр.* (Ш. Мәр.) — *сс.* В большинстве случаев; в большом количестве.

**Галәлхосус** على الخصوص *ст.* Бигрәк тә, аеруча, башлыча. — *сс.* Особенно, в особенности, главным образом, преимущественно.

**Галәм* I** عالم *ис.* 1) Галәм, бөтен дөнья. *Ах, галәм көннән-көн үзгәрәдер.* (Г. Ил.) 2) Халык. *Моны бөтен галәм белә.* 3) Аерым бер төркем. *Бу ике галәмнең берсе шагыйрьнең рухында хаким була.* (Г. Ибр.) — *сущ.* 1) Свет, вселенная; мир. 2) Народ, публика. 3) Отдельная группа, общество.

**Галәм II** علم *ис.* 1) Әләм, байрак. 2) Билге, галәмәт. — *сущ.* 1) Знамя, флаг. 2) Знак, метка.

**Гыйрфан** عرفان *ис.* 1) Ан, белем. *Татарда да гыйрфан уты кабынганны күрсәтергә китәрелгән бөтен кеше.* (Г. Тук.) 2) Тәрбия. *Шулар кебек әйтер идем мин гыйрфансыз.* (Г. Тук.) 3) Белем һәм тәрбия аркасында барлыкка килгән булдыклылык. 4) Чын дөресен аңлаучы. — *сущ.* 1) Знание, познание. 2) Воспитание. 3) Знания и способности, полученные через образование. 4) Правильно понимающий.

**Гыйсави** عيسوى *с.* Гайса дине(нә бәйләнешле), христиан дине(нә бәйләнешле). — *прил.* Христианский.

**Гыйсавиять** عيسويت *ис.* Христианлык. — *сущ.* Христианство.

**Гыйсмәт** عصمت *ис.* 1) Начар эшләрдән тыелу. 2) Намус, йөз суы, пакьлек. *Күзләрең ялтырый, уйный шаян нур балкытып гыйсмәт, савап.* (Ш. Баб.) — *сущ.* 1) Непогрешимость; непорочность, чистота. добродетель. 2) Честь; стыдливость; репутация.

**Гыйсъян** عصيان *ис.* 1) Баш күтәрү, баш тарту, каршылык күрсәтү. 2) Закон бозу, җинаять. — *сущ.* 1) Бунт; неповиновение. 2) Нарушение закона, преступление.

**Гыйтаб** عتاب *ис.* Шелтә, орышу, әр, азарлау, биткә бәрү. *Шөбһәле маллар өчен гыйтаб.* (М. Гаф.) — *сущ.* Порицание; упрекание; упрёк.

**Гыйтрәт** عترت *ис.* 1) Гаилә, семья. 2) Кардәш-кабилә. — *сущ.* 1) Семья. 2) Родственники, родичи.

**Гыйфрит*** عفريت *ис.* **1.** 1) Каты күңелле, рәхимсез кеше. 2) Мәкерле. **2.** *миф.* Дию пәрие. *Иләмсез „җен" кебек, гыйфрит кебек.* (М. Гаф.) — *сущ.* **1.** 1) Жестокий, немилосердный. 2) Хитрый, подлый. **2.** *миф.* (Злой) дух, демон.

**Гыйффәт*** عفت *ис.* 1) Кызлык, сафлык, бөтенлек. 2) Намус, йөз суы, абруй. *Егеткә кызның гыйффәтенә кагылырлык һичбер нәрсә эшләмәүне шарт итеп куйды.* (К. Нас.) — *сущ.* 1) Целомудрие, девственность. 2) Честь, совесть; авторитет.

**Гыйш** عيش *ис. кара:* гайш. — *сущ. см.* Гайш.

**Гыйшаэ** عشاء *ис.* Кояш баю кызыллыгы беткәннән соңгы вакыт. — *сущ.* Сумерки.

**Гыйшвә** عشوه Чытлык, наз, көязлек. *Әйт: әй миһерең аз, гыйшвәң фәрван.* (Хорәз.) — Кокетство, любовный жест, любовная игривость.

**Гыйш-гыйшрәт** عيش عشرت *ст.* Вакытны ашап-эчеп, типтереп уздыру, типтерү. *Гыйш-гыйшрәт сөр җиһанда.* (М. Гаф.) — *сс.* Распутная жизнь; разврат, дебош.

**Гыйшнуш** عيش نوش *гф. ис.* Ашапэчеп типтерү. *Шу дикле гыйшнуш итдем, сафа вә зәүкы җуш итдем.* (Шул кадәр типтердем, рәхәтлек һәм тәм табуны шаулатып кайнаттым.) (Г. Кан.) — *ар.-п. сущ.* Распутная жизнь; разврат.

**Гыйшнуша-нуш** عيش نوشانوش *ф. ст.* Типтерү, кәеф-сафа, азган-тузганлык. *Нәшат вә гыйшнуша-нуш кылгыл.* (Хорәз.) — *п. сс.* Распутная жизнь, разврат, дебош.

**Гыйшык*** عشق *ис.* Сөю, өзелеп ярату. — *сущ.* Любовь, влюблённость.

**Гыйшыкбаз** عشقباز *гф. ис.* Гыйшык белән уйнаучы, алдакчы гашыйк. — *ар.-п. сущ.* Ухажёр, повеса, соблазнитель.

**Гыйшрин** عشرين *сан.* **1.** Егерме. **2.** Егерменче. — *ч.* **1.** Двадцать. **2.** Двадцатый.

**Гыйшрәт** عشرت *ис.* 1) Ашау-эчү мәҗлесе. 2) Кәефләнү, эчү, исерү. — *сущ.* 1) Пиршество, пир. 2) Веселье; опьянение.

**Гыяд** عياد *ис.* Кире кайту. — *сущ.* Возвращение.

**Гыядәт** عيادت *ис.* Хәл белә бару, авыруның хәлен белү. ... *кардәшләре гыядәткә килмәгәнлекләреннән сөаль кыйлды.* (К. Нас.) — *сущ.* Посещение больного.

**Гыял** عيال *ис.* Өй җәмәгате, бала-чага, гаилә. ...*малларым вә гыялем вә әүладем һәлак булды.* (К. Нас.) — *сущ.* Семейство, семья; жена, дети (находящиеся на содержании главы семьи).

**Гыяр** عيار *ис.* Проба, алтын-көмеш әйберләрдә кушымта күпме булуын күрсәтү. — *сущ.* Проба (с целью определения количества примеси в золотых или серебряных изделиях).

**Гыйһен** عهن *ис.* Йон. — *сущ.* Шерсть.

**Гыйһне мәнфуш** عهن منفوش *из.* Тузгылган йон. *Туза уйлар мисале гыйһне мәнфуш.* (Г. Тук.) — *из.* Растрепанная шерсть.

**Гяһ** گاه *ф. ис.* 1) Әле, кайчак, кайчакта. *Гяһ алай, гяһ болай сөйли, бер дә төшенеп булмый.* 2) Урыны, вакыты. *Сәхәргяһ* — таң вакыты. — *п. сущ.* 1) Иногда. 2) Указатель времени или места действия.

**Гяһ вә нагяһ** گاه و ناگاه *ф. ст.* Вакытлы-вакытсыз. — *п. сс.* Не во-время.

**Гяһ-гяһ** گاه گاه *ф. р.* Вакыт-вакыт, кайбер вакыт. *Чыкарлар ирде анда гяһ-гяһ* (Сайяди). — *п. н.* Иногда, время от времени.

**Гяһан** گاها *ф. р.* Кайчакта, кайвакытта. — *п. н.* Временами, иногда.

**Гәб*** گب *ф. ис.* Гәп, сүз, сөйләшү, әңгәмә. *Белдем эшнең асылын, инде бетте гәб.* (М. Гаф.) — *п. сущ.* Разговор, беседа.

**Гәдай** گداى *ф. ис. кара:* гидай. — *см.* Гидай.

**Гәзаф** گزاف *ф. с.* 1) Күп санлы, гадәттән тыш мул. 2) Нигезсез, мәгънәсез. *Падиша назар кылмыш гәзаф ирмәс, әлбәттә.* (Мәхмуд бине Гали.) — *п. прил.* 1) Многочисленный; чрезмерно обильный. 2) Неосновательный, бессмысленный.

**Гәнеж** گنج *ф. ис.* 1. Хәзинә; кыйммәтле нәрсә. 2. 1) Яшь, егет (кеше). 2) Яңа гына өлгергән. — *п. сущ.* 1. Клад. 2. 1) Молодой, юный. 2) Новый, свежий.

**Гәр** گر *ф.* Әгәр („әгәр“дән кыскартылган). *Иртәгә килгәнче дуслар, тәндә җаным торса гәр.* (Г. Тук.) — *п.* Если (сокращенное от „әгәр“).

**Гәрд** گرد *ф. ис.* Тузан; порошок. — *п. сущ.* Пыль, прах; порошок.

**Гәрдаб** گرداب *ф. ис.* Упкын, чоңгыл. *Олуг гәрдаб иде тәңре яраткан* (Сайяди). — *п. сущ.* Водоворот, омут, пучина.

**Гәшт (кәшт)** گشت *ф. ис.* Гизү, сәяхәт. *Гәшт итеп гәздем бу татар иленең яхшылыгын* (Сайяди). — *п. сущ.* Странствование, путешествие.

**Гәүһәр*** گوهر *ф. ис.* 1) Җәүһәр, алмаз. 2) Асылташ. *Авызың зәмзәм, ирнең кәүсәр, тешең гәүһәр.* (Ш. Баб.) — *п. сущ.* 1) Жемчуг, алмаз. 2) Драгоценный камень.

**Гөзар** گذار، گزار *ф. ис.* 1) Үтәчәк юл. 2) *күч.* Кабер. *Бу Зөһрә алдига төзде гөзарын* (Сайяди). — *п. сущ.* 1) Проход; проезд. 2) *перен.* Могила.

**Гөзарнамә** گزارنامه *ф. ис.* Юл өчен бирелгән таныклык. — *п. сущ.* Дорожное свидетельство.

**Гөлгончә** گلغنچه *ф. ис.* Гөл бөресе. — *п. сущ.* Бутон.

**Гөлгыйзар** گلعذار *гф. с.* Гөл яңаклы, гөл шикелле матур яңаклы. — *ар.-п. прил.* С красивыми, как роза, щеками.

**Гөлзар** گلزار *ф. ис.* Чәчәклек, чәчәкләр үскән җир. *Нә әшгар гөлзары күрдек.* (Дәрд.) — *п. сущ.* Цветник; луг, покрытый цветами.

**Гөлрох** گلرخ *ф. с.* Гөл яңаклы, матур йөзле. — *п. прил.* Красивый, красиволикий.

**Гөлстан** گلستان *ф. ис.* Гөл бакчасы. — *п. сущ.* Цветник; насаждения роз; цветочный сад.

**Гөлчиһрә, гөлчәһрә** گلچهره *ф. ис.* Гөл йөзле, матур йөзле. — *п. сущ.* С лицом, красивым как цветок.

**Гөләб*** **(гөлаб)** گلاب *ф. ис.* 1) Гөл суы, хуш исле су. 2) Гөлҗимеш. — *п. сущ.* 1) Цветочная вода; душистая вода. 2) Шиповник; дикая роза.

**Гөм** گم *ф. с.* Югалган. — *п. прил.* Пропавший, потерянный.

**Гөман** گمان *ф. ис.* 1) Уй, фикер. *Ул эшне күркәм эш дип гөман ителде.* (З. Һад.) 2) Шик, шөбһә. — *сущ.* 1) Мысль, мнение. 2) Предположение, подозрение, воображение.

**Гөмраһ** گمراه *ф. с.* 1) Юлдан язган. 2) *күч.* Әдәпсез, бозык, әхлаксыз. *Ки шәйтан ул бәсарны кылды гөмраһ* (Сайяди). — *п. прил.* 1) Сбившийся с пути. 2) *перен.* Развращённый, испорченный, порочный.

**Гөнаһ*** گناه *ф. ис. дини.* Гөнаһ, язык. — *п. сущ. рел.* Вина, проступок; грех.

**Гөнаһкяр** گناهكار *ф. ис.* 1) Гөнаһ эшләр эшләүче. 2) Ярамый торган эшләр артыннан йөрүче. — *п. сущ.* 1) Грешник, преступник. 2) Преследующий преступные цели.

**Гөраз** گراز *ф. с.* Батыр, кыю; ярсу; үз ирекле, башбаштак. *Газимәт әйләде сүз гөразлә.* (Дәрд.) — *п. прил.* Храбрый, отважный; буйный; непокорный, озорной.

**Гөрк** گرك *ф. ис.* Бүре. *Ерак китсә улыр гөрк дәрәндә.* (Ут. Им.) — *п. сущ.* Волк.

**Гөруһ*** گروه *ф. ис.* Төркем. — *п. сущ.* Группа, отряд, толпа.

**Гөстах, көстах** گستاخ *ф. с.* Әдәпсез, тупас, дорфа, оятсыз, әрсез. *Мәңа тикмәс кем гөстахлык кылмага.* (Мөхм.) — *п. прил.* Дерзкий, наглый, нахальный.

**Гөфтегү** گفتگو *ф. ис.* Сөйләшүләр, кара-каршы сөйләүләр; әңгәмә. *Анда уеннар, көлүләр, гөфтегүләр бар иде.* (Дәрд.) — *п. сущ.* Разговор, беседа, диалог.

**Гөфтар** گفتار *ф. ис.* 1) Статья. 2) Әңгәмә. *Мәгърифәт базарыйда торган шәкәр гөфтар өчен* (Сайяди). — *п. сущ.* 1) Статья. 2) Беседа, речь.

**Гүаһ*** گواه *ф. ис.* Танык, таныклык бирүче, шаһит. *Мин гомеремдә миравайга гүаһ булып та барганым юк* (Г. Газиз). — *п. сущ.* Свидетель.

**Гүр*** گور *ф. ис.* Кабер. — *п. сущ.* Могила.

**Гүрстан** گورستان *ф. ис.* Каберлек, зират. — *п. сущ.* Кладбище.

**Гүя*** گويه *ф. р.* Һәкъ, әйтерсең. — *п. н.* Будто бы, якобы, как будто; словно.

**Гүяндә** گوينده *ф. ис.* Әйтеп, сөйләп торучы, сөйләүче. *Мөганниләр нәгъмәләрен чалып* (көйләрен уйнап), *гүяндәләр шигырьләрен әйтеп, шаһ бигамь тамаша вә тәфәррежддәдер.* (К. Нас.) — *п. сущ.* Говорящий; рассказывающий.

# Д

Д — د татар әлифбасында бишенче, гарәп әлифбасында сигезенче хәреф; гарәпчә дал дип атала, әбҗәд тәртибендә 4 санын белдерә.

Пятая буква татарского, 8-ая буква арабского алфавита; цифровое значение 4.

**Даббә** دابه *ис.* 1) Атланып йөри торган һәм йөк ташый торган хайван. 2) Дүрт аяклы хайван.

*сущ.* 1) Верховое или вьючное животное. 2) Четвероногое животное.

**Даг** داغ *ф. ис.* 1) Кызган тимер басып салынган тамга, билге, keләймә. 2) *куч.* Кайгы, көенеч. *Күңелдә калды бу даг кыямәт* (Сайяди).

*п. сущ.* 1) Клеймо, тавро, знак (наносимый раскалённым железом). 2) *перен.* Печаль, скорбь.

**Дагдар** داغدار *ф. ис.* Тамгалы, тамгаланган, keләймә сугылган.

*п. сущ.* Заклеймённый, с клеймом.

**Дагый** داعی *сф.* 1) Чакыручы, өндәүче. 2) Дога кылучы.

*пр. д.* 1) Зовущий, призывающий. 2) Молящийся.

**Дад** داد *ф. ис.* 1) Турылык, гаделлек һәм аны үтәү. *Тик кыямәт көнгә калды хаклар эстәр дад көне.* (Г. Тук.) 2) Ярдәм сорап чакыру. *Дад, дад! Саламторхан суга акты, ярдәмгә килегез.* (К. Нас.) 3) Зар, шикаять.

*п. сущ.* 1) Правосудие, справедливость, возмездие. 2) Крик о помощи, о защите против несправедливости. 3) Жалоба

**Дад бидад** دادبی داد *ф. ым.* Ни кайгы! Ни кызганыч! *Аларны тотты солтан дад бидад* (Сайяди).

*п. межд.* Увы! Как жаль! О горе.

**Дадхаһ** دادخواه *ф. ис.* Турылык эстәүче, дөреслек таләп итүче.

*п. сущ.* Истец; требующий правосудия.

**Даим*** دائم *сф.* Һәрвакыт булып тора торган, дәвам итүче, өзлексез, үзгәрешсез, мәңге. *Даим, даим сәгать саен син төшәсең исемә* (Халык җыры).

*пр. д.* Длящийся, беспрерывный, длительный, постоянный, вечный.

**Даими*** دائمی *с.* Мәңгелек, дәвамлы, һәрвакыт була торган.

*прил.* Длительный, постоянный, всегдашний, вечный.

**Даимият** دائمیت *ис.* Һәрвакыт булып торучылык, даимилек.

*сущ.* Постоянство, длительность, вечность.

**Даимән** دائماً *р.* Өзлексез, һәркайчан, һәрвакытта, тоташтан. *Даимән инсанга инсан, җенгә җен тәкълит итә.* (Ш. Баб.)

*н.* Всегда, постоянно, беспрестанно.

**Даин** دائن *сф.* Бурычка биреп торучы.

*пр. д.* Заимодавец, кредитор.

**Даир** دائر *сф.* 1) Тирәли әйләнеп йөри торган. 2) Бәйләнешле, караган. карата, турысында. *Сезгә даир бертә язым кәләнчә икътидарымнан.* (Г. Тук.) — *пр. д.* 1) Вращающийся, на ходу, пущенный в ход. 2) Относящийся (к чему-либо).

**Даирә*** دائره *ис.* 1) Түгәрәк сызык, түгәрәк әйләнәсе. 2) Түгәрәк әйбер, бөҗра, алка. — *сущ.* 1) Круг, окружность. 2) Кольцо.

**Даирәләр** — берәр эшкә, профессиягә караган кешеләр группасы, мәс.: әдәби даирәләр (ягъни, әдәбият өлкәсендә эшләүчеләр, язучылар һ. б.). — Круги.

**Даирәи котбия** دائرهٔقطبیه *ф. из. геогр.* Поляр түгәрәк, котып түгәрәге. — *п. из. геогр.* Полярный круг.

**Дал** دال *сф.* Күрсәтеп (белдереп, дәлилләп) торучы, дәлаләт итүче. *Зөләйханың мәкътул булган көнендә язылганына мәктүбтәге числосы далдыр.* (З. Биг.) — *пр. д.* Указывающий, доказывающий; показывающий.

**Дам** دام *ф. ис.* Тозак, ау. *Һөҗүм иткән фәләк җир-җир* (һәр җирдә) *корып дам.* (Дәрд.) — *п. сущ.* Сеть, тенёта.

**Дамад** داماد *ф. ис.* Кияү. — *п. сущ.* 1) Зять. 2) Жених.

**Даман** دامان *ф. ис.* 1) Итәк. 2) Кайма. *Пакь-даман* — намуслы, гыйффәтле. *Ирләр пакь-даман хатын-кызларның чәчы аклыгын кәриһ күрәләр.* (К. Нас.) — *п. сущ.* 1) Пола, подол. 2) Кайма, обшивка. *Пакь-даман* — Честная, девственная.

**Дамелля** داملا *ф. ис.* 1) Югары мәктәп укучысы. 2) Зур укымышлы, дәрес бирүче. — *п. сущ.* 1) Учащийся высшей школы. 2) Образованный, дающий уроки.

**Дамән** دامن *ф. ис. кара:* даман. — *п. сущ. см.* Даман.

**Дана** دانا *ф. с.* **1.** Белүче, укымышлы, аңлы. **2.** Галим. *Әһле инсаф вә дана кемсәнәләр чыкалар.* (М. Гаф.) — *п. прил.* **1.** Знающий, образованный, сведущий, мудрый. **2.** Ученый.

**Даниш** دانش *ф. ис.* Белем, фән. — *п. сущ.* Знание, наука.

**Данишмәнд** دانشمند *ф. ис.* Белгеч, галим, гыйлем иясе. — *п. сущ.* 1) Учёный, деятель науки. 2) Мудрец.

**Данпәрәст** دانپرست *ф. с.* Дан сөюче, шөһрәт (дан) яратучы. *Гыйсмәтуллин шалтыравык, ялтыравык данпәрәст...* (Ш. Баб.) — *п. прил.* Любитель славы, гоняющийся за славой.

**Данә*** دانه *ф. ис.* 1) Бөртек, орлык. 2) Экземпляр. — *п. сущ.* 1) Зерно, семя. 2) Штука, экземпляр.

**Данәнд** داننْد *ф. с.* Белүче, төшенүче, белемле. *Аз-аз өйрәнеп данәнд булырлар.* (К. Нас.) — *п. прил.* Знающий, понимающий.

**Дар I** دار *ис.* 1) Зур йорт, зур торак. 2) Урын, җир, ил. — *сущ.* 1) Жилище, дом, здание. 2) Земля, местность, страна.

**Дар II** دار *ф. ис.* Кушма сүз составында „иясе“, „хуҗасы“, „биләүче“ мәгънәләрендә килә. *Хәзинәдар* — казначы, *малдар* – бай, мал иясе. — *п.* Служебное слово со значением „обладающий“, „владеющий“. *Малдар* — владеющий богатством.

**Дар III*** دار *ф. ис.* Асып үтерү өчен утыртылган баганалар. — *п. сущ.* Виселица.

**Дарелбәка** دارالبقا *из. дини* „Мәңгелек йорт“, ахирәт, теге дөнья. — *из. рел.* Загробный мир.

**Дарелвилядәт** دارالولادت *из.* Бала тудыру йорты. — *из.* Родильный дом.

**Дарелгаҗизин** دارالعاجزين *из.* Картлар йорты, инвалидлар йорты. — *из.* Дом старости, дом инвалидов.

**Дарелголум** دارالعلوم *из.* Гыйлем йорты, югары уку йорты. — *из.* Высшее учебное заведение.

**Дарелмөгаллимат** دارالمعلمات *из.* Хатын-кызлардан укытучылар хәзерли торган уку йорты. — *из.* Женская школа для подготовки учителей.

**Дарелмөгаллимин** دارالمعلمين *из.* Ирләрдән укытучылар хәзерли торган уку йорты. — *из.* Мужская школа для подготовки учителей.

**Дарелфәна** دارالفنا *из. дини* „Бетә торган йорт“, дөнья. *Дарелфәнадән дарелбәкага рихләт итте.* (Кабер ташыннан.) — *из. рел.* Земля, этот мир.

**Дарелфөнүн** دارالفنون *из.* Фәннәр йорты, югары уку йорты, университет. *Һинди Минһаҗ шул җирләрдә дарелфөнүн саласы.* (Г. Тук.) — *из.* Университет, высшее учебное заведение.

**Дарелхәреб** دارالحرب *из.* Сугыш мәйданы, фронт. — *из.* Фронт, театр военных действий.

**Дарелгаман** دارالامان *из.* Иминлек, тынычлык йорты (урыны). — *из.* Место спасения; безопасное место.

**Дару*** دارو *ф. ис.* Дару, им. — *п. сущ.* Лекарство, медикаменты.

**Дарчин*** دارچين *ф. ис.* Дарчин (агач исеме). — *п. сущ.* Корица.

**Дарәйн** دارين *ис. дини* „Ике йорт“, дөнья-ахирәт. — *сущ. рел.* Два мира (этот и загробный).

**Дастан*** داستان *ф. ис.* Поэма; эпос. — *п. сущ.* Дастан, поэма; эпос.

**Дафигъ** دافع *сф.* Кире кайтаручы, читләштерүче, этәрүче. — *пр. д.* Отражающий, отбирающий, отталкивающий, толкающий.

**Дахил** داخل *сф.* **1.** Эчкә керүче, катнашучы. **2.** Әйбернең эчке ягы, эче. — *пр. д.* **1.** 1) Входящий. 2) Внутренний. **2.** Внутренность.

**Дахили** داخلی *с.* Эчке, эчке як(ка бәйләнешле). *Дахили хәбәрләр*—дәүләт эчендәге хәбәрләр. — *прил.* Внутренний.

**Дахилия назараты** داخلیه‌نظرتی *ст.* Эчке эшләр министрлыгы. — *сс.* Министерство внутренних дел.

**Дахилән** داخلاً *р.* Эчтән, эчке яктан. — *н.* Внутренне, с внутренней стороны.

**Даэ** داء *ис.* Авыру, чир, хәстәлек. — *сущ.* Болезнь, хворь.

**Даэлфил** — аяклар шешү авыруы. — Опухание ног, слоновая болезнь.

**Даэссәгъләб** — чәч, сакал коелу авыруы. — Выпадение волос.

**Даэннәмел** — корчангы авыруы. — Чесотка.

**Дая** دایه *ф. ис.* Бала караучы хатын, бала багучы. — *п. сущ.* Няня, кормилица.

**Даһи*** داهی *сф.* 1) Чиктән тыш зирәк (кеше). 2) Иң югары иҗат сәләтенә ия (кеше). *Чыкты каршы бу даһига сәфил дошман.* (Г. Тук.) — *пр. д.* 1) Талантливый, способный. 2) Гений, гениальный.

**Даһианә** داهیانه *гф. р.* Даһиларча. — *ар.-п. н.* Гениально.

**Даһия** داهیه *ис.* Чиктән тыш үткен зиһен һәм зирәклек иясе. *Әбү Гали ибне Сина ошашсыз бер даһия иде.* (Р. Фәх.) — *сущ.* Умный человек, большая умница, выдающийся ум.

**Дибаҗ** دیباج *ис.* 1) Чәчәкле ботак бизәкләре. 2) Шундый бизәк төшерелгән ефәк тукыма. *Яшел дибаҗдан түшәк вә юрган үзрә утырыр.* (К. Нас.) — *сущ.* **1.** Цветущая ветвь дерева. **2.** Шёлк, парча.

**Дибаҗә** دیباجه *ис.* 1) Кереш сүз. 2) Китапның төрле бизәкләр белән бизәлгән беренче бите. — *сущ.* 1) Введение. 2) Разукрашенная первая страница книги.

**Диван** دیوان *ф. ис.* 1) Бер шагыйрьнең шигырьләр җыентыгы. 2) Дәүләтнең югары советы. *Падишаһ ачуланып диваннан чыгып китте.* (К. Нас.) 3) Диван. — *п. сущ.* 1) Диван (сборник стихотворений). 2) Высший совет государства. 3) Диван, софа.

**Дивана*** دیوانه *ф. ис.* Тиле, юләр, тинтәк. — *п. сущ.* Безумный, сумасшедший, юродивый, помешанный.

**Дивар** دیوار *ф. ис.* Стена. *Дин хәзер иске, аварга торучы черегән дивар.* (Г. Тук.) — *п. сущ.* Стена.

**Дигәр** دیگر *ф. ис.* Башка, бүтән. — *п. сущ.* Другой, иной.

**Дидар** دیدار *ф. ис.* 1) Очрашу, юлыгу, табышу, кавышу. 2) Йөз, бит, чырай. *Хөррият шунда ук бөтен дөньяга күрсәтте дидар.* (М. Гаф.) — *п. сущ.* 1) Визит, свидание, встреча. 2) Лицо, облик, вид.

**Дидә** دیده *ф. ис.* 1) Күз. *Нур дидә* — күз нуры. 2) Күргән. *Җиһан дидә* — дөнья күргән, күп йөргән, күп яшәгән. — *п. сущ.* 1) Глаз, око. 2) Много повидавший, опытный, бывалый.

**Дикъкать*** دقت *ис.* 1) Нечкәләп тирәнтен уйлаучылык, караучылык, тикшерүчелек. 2) Күңел бирү, игътибар. *Дикъкатә лаек... татарның яшьләре.* (Г. Тук.) — *сущ.* 1) Аккуратность, точность, тщательность. 2) Внимательность; внимание.

**Дил** دل *ф. ис.* Күңел; йөрәк; акыл. *Оча дилдән бөтен шик-шөбһәләр һәм мин җылый башлыйм.* (Г. Тук.) — *п. сущ.* Сердце; душа; мысль, разум.

**Дилавәр** دلاور *ф. с.* Йөрәкле, батыр, курыкмый торган. — *п. прил.* Мужественный, храбрый, отважный.

**Дилазар** دل‌آزار *ф. с.* 1) Күңел калдыручы, хәтер калдыручы. 2) Рәхимсез. — *п. прил.* 1) Огорчающий; обижающий. 2) Жестокий, немилосердный.

**Дилара, диларам** دلارا، دلارام *ф. с.* Күңелне бизәүче, күңелне рәхәтләндерүче, хушландыручы, тынычландыручы. *Йөзе анының маһру дилараи дик.* (Мөхм.) — *п. прил.* Возлюбленная, *букв.* „услаждающая душу“; успокаивающая.

**Дилбәр** دلبر *ф. с.* Сөекле, сөйдерүче, күңелне үзенә тартучы, күңелне биләүче. *Миһербаным, әлфирак, дилбәр җаным әлфирак.* (Ә. У. К.) — *п. прил.* Возлюбленная, привлекательная.

**Дилбәстә** دلبسته *ф. с.* Күңеле бәйле; гашыйк, сөюче. — *п. прил.* Привязанный (душой), влюблённый, любящий.

**Дилгир** دلگیر *ф. с.* Рәнҗетелгән, хәтере калган, үпкәләгән, кайгылы, хәсрәтле. — *п. прил.* Оскорблённый, обиженный, печальный.

**Дилдадә** دلداده *ф. с.* Башы-күзе әйләнгән, сокланган, гашыйк булган. *Ки Зөһрә дилбәр ул, дилдадәсе мән* (Сайяди). — *п. прил.* Увлечённый любовью, влюблённый, очарованный.

**Дилдар** دلدار *ф. с.* 1) Күңелне тоткын итүче, күңел аулаучы; кыю. 2) Сөекле, сөелгән. *Зөләйха әйдәр: „Аңлагыл сән ая дилдар“.* (К. Гал.) — *п. прил.* 1) Пленяющий, очаровывающий; отважный. 2) Возлюбленный, возлюбленная.

**Дилкәш** دلكش *ф. с.* Күңелне үзенә тартучы. — *п. прил.* Привлекательный; заманчивый.

**Дилкәшад** دلكشاد *ф. с.* Күңел ачучы, шатландыручы. ... *бер җан дилкәшад иде.* (К. Нас.) — *п. прил.* Веселящий, увеселяющий; радующий.

**Дилмөрдә** دلمرده *ф. с.* Күңеле үлгән, үле йөрәкле; күңелсез. — *п. прил.* Вялый, не жизнерадостный; скучающий.

**Дилнәваз** دلنواز *ф. с.* Күңелгә ошаган, күңелне хушландырган, күңелгә хуш күренгән. *Сәлам и миһрбан дилнәвазым.* (К. Нас.) — *п. прил.* Ласкающий сердце, понравившийся, приглянувшийся.

**Дилпәзир** دلپزير *ф. с.* Күңел теләгән, сөекле. — *п. прил.* Желанный, любимый.

**Дилпәсәнд** دلپسند *ф. ис.* Күңелгә ягымлы. — *п. прил.* Приятный, милый.

**Дилроба** دلربا *ф. ис.* Күңелне буйсындыручы, күңелне басып алучы; гүзәл, матур. *Шикәрдин татлы сүзле дилроба син.* (Хорәз.) — *п. сущ.* Восхитительный, обаятельный; красавица; возлюбленная.

**Дилситан** دلستان *ф. ис.* Йөрәк талаучы, йөрәккә баскынлык итүче; матур, гүзәл. *Сәламемне тикер* (җиткер) *ул дилситанга.* (Хорәз.) — *п. сущ.* Возлюбленная; красавица.

**Дилсухтә** دلسوخته *ф. с.* Йөрәге янган, күңеле азап чиккән, бәхетсез. — *п. прил.* Горестный, печальный, страдающий, несчастный.

**Дилсәрд** دلسرد *ф. с.* Күңеле суынган, күңеле кайткан. — *п. прил.* Охладевший, разочаровавшийся.

**Дилсүз** دلسوز *ф. с.* Йөрәге янган, тойгыланган, ачынган. *Бу сүзи ишетеп Таһир дилсүз* (Сайяди). — *п. прил.* Подверженный влиянию, огорчённый; расстроенный.

**Дилтәнг** دلتنك *ф. с.* Күңеле төшкән, гамьле, күңелсез. — *п. прил.* Грустный, тоскующий, скучающий; невесёлый; неприятный.

**Дилфикяр** دلفكار *ф. с.* Күңеле яраланган, йөрәге җәрәхәтләнгән. *Кайчан кем Мәҗнүн дилфикяр ителде фәүте Ләйләдән хәбәрдар.* (Дәрд.) — *п. прил.* Опечаленный, огорчённый; разочарованный; убитый горем.

**Дилфруз** دلفروز *ф. с.* Күңелне сөендерүче, шатландыручы. — *п. прил.* Услаждающий, приятный, веселящий, радующий.

**Дилхуш** دلخوش *ф. с.* Күңеле булган, шат, канәгатьләнгән. — *п. прил.* Довольный, радостный, удовлетворённый.

**Дилхәраш** دلخراش *ф. с.* Үзәкне өзүче, коточкыч; үкенечле. — *п. прил.* Душераздирающий, потрясающий; прискорбный.

**Дилшад** دلشاد *ф. с.* Шат күңелле, күңеле шат, сөенечле. — *п. прил.* Довольный, осчастливленный, в приподнятом настроении.

**Дилшикяр** دلشکار *ф. с.* Күңел аулаучы, күңелне үзенә тартучы (әсир итүче). — *п. прил.* Привлекательный, чарующий.

**Дилшикәстә** دلشکسته *ф. с.* Күңеле сынган, сынык күңелле, күңеле китек. — *п. прил.* Огорчённый, обиженный, оскорблённый.

**Диләфкяр** دلافکار *ф. с.* *кара*: дилфикяр. — *п. прил. см.* Дилфикяр.

**Дилҗу** دلجو *ф. с.* Сөекле, сөелгән, күңелгә якын булган, күңел теләгән. — *п. прил.* 1) Участливый, ласковый. 2) Пленительный, привлекательный; желанный.

**Димаг** دماغ *ис.* Ми. — *сущ.* Мозг.

**Динар*** دينار *ис.* 1) Борынгы алтын акча. 2) Гыйрак акчасы. — *сущ.* 1) Динар (древняя золотая монета). 2) Основная денежная единица в Ираке.

**Диндар*** ديندار *гф. с.* Дин тотучы, динле. — *ар.-п. прил.* Религиозный, благочестивый, набожный.

**Дини*** دينى Дин(гә), дин эшләре(нә караган). — *прил.* Относящийся к вере; религиозный.

**Дираз** دراز *ф. с.* Озын, озак, дәвамлы. *Аның дуслыгы дираз улмас.* (К. Нас.) — *п. прил.* Длинный, долгий, длительный, продолжительный.

**Дираять** درايت *ис.* Зирәклек, акыллылык; тирән аңлау, төшенү, белү, ерактан күрү. *Бәян идәм ишет сән, кыйл дираять.* (Һ. Сал.) — *сущ.* Знание, осведомлённость, разумение, понятливость, проницательность.

**Дирга** درعه *ис.* Өс киеме, җөббә. *Күлмәк өстеннән йоннан бер дирга кимешдер.* (К. Нас.) — *сущ.* Одежда, одеяние, вид рубахи.

**Диргы** درع *ис.* 1) Өс киеме. 2) Вак тимер боҗралардан эшләнгән һәм сугышта киелә торган кием, борынгы телебездә күбә дип аталган кием-калкан. — *сущ.* 1) Рубаха. 2) Кольчуга (защитная одежда из металлических колец или в виде сетки), панцирь.

**Дирәфшан** درفشان *ф. с.* Ялтырап, җемелдәп торган, күз камаштыргыч, яктыручы. — *п. прил.* Сверкающий, яркий, ослепительный.

**Дирһәм** درهم *ис.* 1) Борынгы көмеш тәнкә. 2) Үлчәү берәмлеге драхма = = 3,12 гр. — *сущ.* 1) Дирхем, серебряная монета. 2) Драхма.

**Диянәт** ديانت *ис.* Динлелек, дин тотучылык. *Килеп җитте кыямәт, сизелде һәр хыянәт, инде ялган диянәт файда бирми тидия.* (Г. Кам.) — *сущ.* Благочестие, набожность, религиозность.

**Диянәткяр** ديانتكار *гф. с.* Динле, дин тотучы. — *ар.-п. прил.* Набожный, верующий, религиозный.

**Дияр** ديار *ис.* Дар I-нең *к.* *Кырым дияры илә Казахстанда тереклек әйләгән.* (К. Нас.) — *сущ. мн.* от дар I.

**Диять** ديت *ис.* Берәүне үтергән, зәгыйфьләгән өчен түләнгән мал. *Диятьләрне түләтеп мәнкульләрне разый кылдык.* (К. Нас.) — *сущ.* Плата за (пролитую) кровь (замена кровной мести), вира.

**Диһкан** دهقان *ф. ис.* Игенче, крестьян. *Диһкан иген игәр.* (К. Нас.) — *п. сущ.* Дихкан, крестьянин, селянин, земледелец, пахарь.

**Дога*** دعا *ис. дини* 1) Теләк, теләү, ялынып сорау, үтенү. 2) Кләү итү, дога кылу. — *сущ. рел.* 1) Мольба, просьба, зов. 2) Молитва.

**Дузәх** دوزخ *ф. ис.* Җәһәннәм, тәмуг. *Мин сизәм дөнья йөзе дузәх җәһәннәмдер миңа.* (Г. Тук.) — *п. сущ.* Ад, преисподняя.

**Дурбин** دوربين *ф. ис.* 1) Бинокль, ерактан күрсәтә торган корал. 2) Ерактан күрүче, тирән мәгънәләргә төшенүче. — *п. сущ.* 1) Бинокль, зрительная труба. 2) Дальнозоркий, дальновидный.

**Дуст*** دوست *ф. ис.* Дус, дуст. — *п. сущ.* Друг, приятель.

**Дустанә** دوستانه *ф. р.* Дусларча. — *п. н.* По-дружески.

**Дучар*** دوچار *ф. с.* Эләккән, төшкән (бәлагә), дучар. — *п. прил.* Подвергшийся, попавший (в беду).

**Дәббаг** دباغ *ис.* Тире иләүче. — *сущ.* Дубильщик.

**Дәва*** دوا *ис.* Дару, им. — *сущ.* Лекарство, снадобье.

**Дәвавин** دواوين *ис. к.* Диваннар, шигырь китаплары, шигырь җыентыклары. — *сущ. мн.* Сборники (стихов).

**Дәвагый** دواعى *ис.* Дагый-ның *к.* — *сущ. мн.* от дагый.

**Дәвам*** دوام *ис.* Өзлексез булып тору, туктамау. — *сущ.* Длительность, продолжительность, постоянство.

**Дәват** دوات *ис.* Кара савыты. — *сущ.* Чернильница.

**Дәвер** دور *м. I.* 1) Әйләнү, тирәли әйләнеп йөрү. 2) Чор, заман, эпоха, дәвер. — *м. I.* 1) Вращение, круговорот. 2) Эпоха, период, эра, время.

**Дәверан** دوران *ис.* 1) Тирәли әйләнеп йөрү, гизеп йөрү, йөреп чыгу. 2) Авыздан-авызга, колактан-колакка йөрү. 3) Дәвер, чор, вакыт, заман, гомер. *Нәбиләр, падишаһлар сөрде дәверан.* (Дәрд.) — *сущ.* 1) Вращение; оборот, обращение. 2) Хождение; переход (слова, молвы) из уст в уста. 3) Время, эпоха, период, жизнь (время от рождения до смерти).

**Дәверания** دورانيه *ис.* Әйләнүдә булган. **Хәрәкәт дәверания** — әйләнү хәрәкәте. — *сущ.* 1) Круговое движение, вращательное движение. 2) Относящийся к вращению.

**Дәгави** دعاوى *ис.* Дәгъва-ның *к.* — *сущ. мн.* от дәгъва.

**Дәгъва*** دعوا، دعوى *ис.* 1) Низаг, дау. 2) Бер эштә үз хакын даулау, суд аркылы хакын таләп итә. **Дәгъва вәкиле** — адвокат, яклаучы, защитник. — *сущ.* 1) Притязание. 2) Иск, тяжба, судебное дело.

**Дәгъвалы** دعوالى *с.* Үзе турында югары уйлы. *Дәгъвалысың: сүзгә шәп тә телгә шәп, эш гакылга килсә, син нәкъ бер ишәк.* (Г. Тук.) — *прил.* Высокомерный, спесивый.

**Дәгъвәт** دعوت *ис.* 1) Чакыру, өндәү. 2) Кунакка чакыру. — *сущ.* 1) Приглашение, призыв. 2) Приглашение в гости.

**Дәгъвәтнамә** دعوتنامه *гф. ис.* Чакыру язылган кәгазь, чакыру кәгазе (билеты). — *ар.-п. сущ.* Пригласительный билет.

**Дәйн** دين *ис.* Бурыч, әҗәт. — *сущ.* Долг, заём.

**Дәйюс** ديوث *ис.* 1) Намуссыз, түбән. 2) Хатынының башка ирләр белән очрашуына арадашлык итүче. *Үз хатынының матур вә купшы йөзен намәхрәмнәргә күрсәтергә һичбер гакыл сәлим сахибе риза булмас, фәкать дәйюсләр бу эшкә ризалык күрсәтерләр.* (Ф. Әмир.) — *сущ.* 1) Низкий, подлый; бесчестный. 2) Сводник; торгующий своей женой.

**Дәкаикъ** دقائق *ис.* Дәкыйка-ның *к.* *Хәкаикъ ы фәһемдән вә дәкаикына вөсулдан гаҗизләр.* (К. Нас.) — *сущ. мн.* от дәкыйка.

**Дэкыйк** دقيق *с.* 1) Нечкә, нәзек. 2) Төгәл. 3) Вак. 4) Анык. *Назар дәкыйккә вә тәдбире гамикъка иҗтиһадларын сарыф итмешләр.* (К. Нас.) — *прил.* 1) Тонкий. 2) Точный, верный. 3) Мелкий. 4) Подробный, внимательный.

**Дәкыйка** دقيقه *ис.* 1) Нечкә фикер, уй. 2) Минут. *Башка ихтыярлы кеше бер дәкыйка тора алмаслыктыр.* (Ш. Кам.) 3) Градус. 4) Берәр нәрсәнең аерым өлеше, кисәк. — *сущ.* 1) Тонкая мысль. 2) Минута. 3) Градус. 4) Тонкость, подробность.

**Дәкыйка шинас** دقيقه‌شناس *гф. ст.* Бик нечкә мәгънәләрне, фикерләрне тиз аңлаучы, тиз төшенүче. — *ар.-п. сс.* Проницательный, сметливый, догадливый.

**Дәкән** د كن *ис.* Бәке. *Кабан күлендә әүвәл туры килгән дәкәнгә атты.* (З. Биг.) — *сущ.* Прорубь.

**Дәлил*** دليل *ис.* 1) Бер фикер яки эшнең дөреслеген күрсәтү өчен китерелгән таньк, факт, нигез, дәлил. *Кешенең сафлыгына дәлил булыр һәрвакыт хаклык белән кылган эше.* (М. Гаф.) 2) Юл күрсәтүче, юлбашчы, җитәкче. 3) Билге. — *сущ.* 1) Довод, доказательство. 2) Признак, показатель. 3) Проводник, гид, путеводитель. 4) Знак.

**Дәллял** دلال *ис.* Арадашлык итүче, маклер. — *сущ.* Маклер, посредник.

**Дәллялә** دلاله *ис.* Уйнашка арадашлык итүче хатын. — *сущ.* Сводня, сводница.

**Дәляил** دلائل *ис.* Дәлил-нең *к.* — *сущ. мн.* от дәлил.

**Дәлял** دلال *ис.* 1) Иркәләнү, назлану. 2) Көязләнү, купшылану. 3) Кыбырсыклык, тынгысызлык. — *сущ.* 1) Кокетство, жеманство, щегольство. 2) Избалованность. 3) Непоседливость.

**Дәляләт** دلالت *ис.* 1) Юл күрсәтү, димләү, өйрәтеп күрсәтү. 2) Берәр хәл булганлык билгесе; дәлиллек. *Бу мәктүб сезнең Зөләйха илә белеш улдыгыгызга дәляләт кыладыр.* (З. Биг.) — *сущ.* 1) Указание. 2) Доказательство; признак, знак.

**Дәлү** دلو *ис.* 1) Су чиләге. 2) Зодиак елының бер ае исеме булып 22 нче январьдан 22 нче февральгә кадәр булган вакыт, январь ае. — *сущ.* 1) Ведро, бадья 2) Созвездие Водолея, название времени года от 22 января до 22 февраля.

**Дәм I** دم *ис.* Кан. — *сущ.* Кровь.

**Дәм II** دم *ф. ис.* 1) Сулыш. 2) Бик аз, бик кыска вакыт, сулыш алырлык кына вакыт. *Һәр минут, һәр дәм хәзердер юлдашы.* (Г. Тук.) — *п. сущ.* 1) Дыхание вздох. 2) Мгновение миг.

**Дәмздәм** دمادم *ф. кара:* дәмбәдәм. — *п. см.* Дәмбәдәм.

**Дәмбәдәм** دمبدم *ф. р.* Һәрвакыт, бертуктаусыз, өзлексез. — *п. н.* Каждое мгновение, в любую минуту, постоянно.

**Дәмгъ** دمع *ис.* Күз яше. — *сущ.* Слеза.

**Дәмгый** دمعی *с.* Күз яше(нә бәйләнешле). — *прил.* Слёзный, относящийся к слезам.

**Дәмсаз** دمساز *ф. ис.* 1) Җайлашучы, яраклашучы, ипләшүче. 2) Иптәш, аркадаш. *Мәхәббәт берлә ул дәмсаз булды* (Сайяди). — *п. сущ.* 1) Приспосабливающий(ся); приспособленец. 2) Товарищ.

**Дәмәви** دموی *с.* Кан (га бәйләнешле). — *прил.* Кровавый.

**Дәнанир** دنانیر *ис.* Динар-ның *к.* — *сущ. мн.* от динар.

**Дәнаәт** دنائت ис. Түбәнлек, кешелексезлек, әшәкелек. — *сущ.* Низость, подлость, бесчеловечность.

**Дәни** دنی *с.* 1) Дәрәҗәсез, түбән, хур. *Ни сәбәп соң җөмлә әдна бәндәләрдән бән дәни.* (Г. Тук.) 2, Пычрак, әшәке, кешелексез, начар, бозык. *Шул дәни адәм белән сөйләшеп авызымны былчыраттым.* (К. Нас.) — *прил.* 1) Низкий, подлый, низменный, презренный. 2) Плохой, бесчеловечный; развращённый.

**Дәнкяр** دنكار *гф. ис.* Вак-төяк сатучы, кырык тартмачы. *Дәнкяр Хәнифә туташа инә, төймә алмага тәкъдим итте.* (М. Ак.) — *ар.-п. сущ.* Коробейник, занимающийся мелочной торговлей.

**Дәр I** در *ф. ис.* Капка, ишек. — *п. сущ.* Дверь, ворота.

**Дәр сәгадәт** — 1) Бәхет ишеге. 2) Борынгы әдәбиятта Истамбул шәһәре. — 1) Ворота счастья. 2) Эпитет Стамбула.

**Дәр II** در *ф. бәйл.* Дә, да, эчендә (мәгънәләрен бирә торган ярдәмлек сүз). *Дәрагуш* — кочакта, кочак эчендә. — В, на, при, под (предлог, обозначает местонахождение в пространстве, отвечает на вопрос „где?“).

**Дәраһим** دراهم *ис.* Дирһәм-нең *к.* — *сущ. мн.* от дирһәм.

**Дәрбан** دربان *ф. ис.* Ишек ачып торучы. — *п. сущ.* Швейцар, привратник.

**Дәр-бәдәр** دربدر *ф. ис.* 1) Зимагур; хәерче; дәрвиш. 2) Йортсыз-җирсез. *Эзләп висалең, и кәһер (гәүһәр), булдым гәдай дәр-бәдәр.* — *п. сущ.* 1) Скиталец; нищий; дервиш. 2) Бездомный, бесприютный.

**Дәрбәнд** دربند *ф. ис.* Тарлавык, таулар арасындагы тар юл, кичү, тау капкасы. — *п. сущ.* Горный проход; перевал.

**Дәрвазә** دروازه *ф. ис.* Капка, шәһәр (крепость) капкасы. — *п. сущ.* Ворота города, крепости.

**Дәрвакыйг** درواقع *гф. р.* Чынлап та, дөрестән дә, чыннан да. — *ар.-п. н.* В самом деле, в действительности.

**Дәрвиш** درويش *ф. ис.* 1) Дәрвиш. 2) Фәкыйрь, ярлы кеше. 3) Бернәрсәгә дә исе китми йөрүче, дөньядан кул селтәгән кеше. — *п. сущ.* 1) Дервиш. 2) Нищий, бедняк. 3) Ничему не удивляющийся; отрёкшийся от мира.

**Дәрвишанә** درويشانه *ф. р.* Дәрвишләрчә, дәрвишләр кебек, ярлы гына. — *п. н.* По-дервишески, бедно.

**Дәргаһед** درعهد *ф. ис.* Өстенә алу, өстенә йөкләү, йөкләмә алу. — *п. сущ.* Взятие на себя определённых обязательств.

**Дәргяһ** درگاه *ф. ис.* 1) Капка төбе, ишек төбе, бусага. **Дәргяһдан сөрү** — ишегеннән куу, мәрхәмәтеннән мәхрүм итү. 2) Зур дәрәҗәле кешеләрнең өйалды. *Язиднең дәргяһына килмешләр.* (К. Нас.) 3) Дәрвишләр торагы. — *п. сущ.* 1) Порог (дверей). 2) Сени, прихожая знатных людей. 3) Общежитие дервишей.

**Дәрд** درد *ф. ис.* Төп мәгънәсе — авыру, газаплану; бездә: теләк, омтылыш, кызыгу, дәрт. *Бәнем дәрдем вә шәвкым да сәнең дәрдеңлә яксандыр.* (Г. Тук.) — *п. сущ.* Желание, стремление, намерение.

**Дәрдмәнд** دردمند *ф. с.* 1) Кайгысы булган (кеше). 2) Бичара, гаҗиз. *Сөйлә, күрдеңме бәнем шәклемдә һичбер дәрдмәнд.* (Г. Тук.) — *п. прил.* 1) Страдающий, печальный. 2) Несчастный.

**Дәрдәст** دردست *ф. ис.* Кулга алу, тоткын итү. — *п. сущ.* Захват, арест, взятие (в плен).

**Дәрес*** درس *ис.* Сабак. — *сущ.* Урок.

**Дәресханә** درسخانه *ф. ис.* Уку бүлмәсе, класс, аудитория. — *ар.-п. сущ.* Класс, аудитория.

**Дәрига** دريغا *ф. ым.* Ни аяныч! Ни кызганыч! Ни үкенеч! — *п. межд.* О, горе! О, жалость!

**Дәригъ** دريغ *ф. ис.* Аяу, аяучылык, үкенеч, үкенүчелек, кызганыч. *Дәригъ, махзун күңел, без дә бетәбез.* (Дәрд.) — *п. сущ.* Жалость, сожаление, раскаяние.

**Дәричә** دريچه *ф. ис.* 1) Кечкенә ишек. 2) Тәрәзә, кечкенә тәрәзә. — *п. сущ.* 1) Дверца. 2) Окошко, оконце, форточка.

**Дәрхаст** درخواست *ф. ис.* Сорау, үтенү, таләп итү. *Бер пәрә үтмәк (икмәк) бирсәңез! - тип дәрхаст кылды* (Мәхмүд бине Гали). — *п. сущ.* Просьба, требование, прошение.

**Дәркяр** درکار *ф. с.* 1) Эштә булучы. 2) Билгеле, ачык. 3) Кирәк, котылгысыз. *Синең чыгып китмәгең дәркярдыр.* (К. Нас.) — *п. прил.* 1) Находящийся в работе. 2) Ясный, очевидный. 3) Необходимый, нужный.

**Дәркәнәр** درکنار *ф. ис.* 1) Кырыйда, кырында булган. 2) Китап бите кырыена язылган аңлатма, искәрмәләр. 3) Гариза (үтенеч) өстенә язылган резолюция. — *п. сущ.* 1) Находящийся в стороне, с боку. 2) Комментарий, заметки на полях книги. 3) Резолюция на заявлении, прошении.

**Дәрман*** درمان *ф. ис.* 1) Әмәл, чара. 2) Дару. 3) Көч, куәт, хәл. — *п. сущ.* 1) Средство, способ. 2) Лекарство, снадобье. 3) Сила, мощь.

**Дәрун** درون *ф. ис.* 1) Эч, эчке як. 2) Йөрәк, күңел. — *п. сущ.* 1) Внутренняя часть, внутренность. 2) Душа, сердце.

**Дәрунихәнә** درونخانه *ф. ис.* Өй эче. — *п. сущ.* Внутренняя часть дома.

**Дәрхаль** درحال *ф. р.* Шул ук вакытта, шул хәлдә, шунда ук. *Бер яңа хәбәр улса, дәрхаль сачыләдер.* (М. Ак.) — *п. н.* Тотчас, тут же; в ту же минуту, немедленно.

**Дәрхәкыйкать** درحقیقت *гф. р.* Дөресен әйткәндә, чынлыкта. *Дәрхәкыйкать, Габденнасыйр гомерендә Кышкарга барган кеше түгел иде.* (М. Ак.) — *ар.-п. н.* На самом деле, в действительности.

**Дәрчәшем бәр хун** درچشم برخون *ф. гыйб.* Күземне кан алган, күземне кан баскан. *Булыпмын Мәҗнүн, дәрчәшем бәр хун* (Сайяди). — *п. фр.* Глаза мои облиты кровью.

**Дәрья*** دریا *ф. ис.* 1) Диңгез. 2) Зур елга, зур су. — *п. сущ.* 1) Море. 2) Большая река.

**Дәрәндә** درنده *ф. с.* Вәхши, ерткыч, ботарлаучы, ерткалаучы. *Хозурда, сөфрәдә куйдыр чәрадә: ерак китсә улыр гөрк дәрәндә.* (Ут. Им.) — *п. прил.* Хищный, растерзывающий, разрывающий.

**Дәрәхт** درخت *ф. ис.* Агач. — *п. сущ.* Дерево.

**Дәрәхтзар** درختزار *ф. ис.* Агачлык. — *п. сущ.* Роща.

**Дәрәҗат** درجات *ис.* Дәрәҗә-нең *к.* — *сущ. мн. от* дәрәҗә.

**Дәрәҗә*** درجه *ис.* 1) Мәртәбә, тоткан урын. 2) Градус. 3) Кадәр, микъдар. — *сущ.* 1) Степень; сан, чин, занимаемая должность. 2) Градус. 3) Количество.

**Дәрәҗә бәдәрәҗә** درجه بدرجه *гф. р.* Тезелмәле рәвештә, бер-бер артлы, системалы рәвештә. — *ар.-п. н.* Постепенно, мало-помалу, понемногу.

**Дәрж** درج *ис.* Теркәү, эченә салу, арага кертү. — *сущ.* Занесение, включение.

**Дәсисә** دسيسه *ис.* Хәйлә, алдау, алдауга корылган эш. — *сущ.* Интрига, каверза, подвох, коварство.

**Дәссас** دساس *ис.* Хәйләкәр, мәкерле кеше, алдау белән эш итүче. — *сущ.* Интриган; хитрый, коварный человек.

**Дәст** دست *ф. ис.* Кул. — *п. сущ.* Рука.

**Дәстан** دستان *ф. ис. кара:* дастан. — *сущ. см.* Дастан.

**Дәстгир** دستگير *ф. ис.* Кулдан тотучы, җитәкләүче, булышучы. — *п. сущ.* Берущий за руку, ведущий, помогающий.

**Дәстемал** دستمال *ф. ис.* 1) Тастымал, кул сөрткеч, салфетка. 2) Кулъяулык. — *п. сущ.* 1) Носовой платок. 2) салфетка; полотенце (для рук).

**Дәстә** دسته *ф. ис.* 1) Сап, тоткыч. 2) Тотым, бәйләм. *Гөлдәстә* — букет. — *п. сущ.* 1) Ручка, рукоятка. 2) Пучок, связка.

**Дәстәрхан** دسترخان *ф. ис.* Ашъяулык, эскәтер. — *сущ.* Обеденная скатерть.

**Дәстүр** دستور *ф. ис.* 1) Төп законнар җыентыгы. 2) Кагыйдә. 3) Кулланма, инструкция. *Хәлифәнең дәстүре буенча кара кием кидердек.* (К. Нас.) 4) Баш вәзир. 5) Рәхсәт, рөхсәт бирү. — *п. сущ.* 1) Свод законов. 2) Правило. 3) Инструкция, предписание. 4) Первый везир. 5) Разрешение, позволение.

**Дәф** دف *ис.* Кипкән тирене иләксыман кысага тартып, аңа төрле шөлдерләр т..ккан уен коралы.[ — *сущ.* Тамбурин, бубен.

**Дәфаин** دفائن *ис. к.* Җиргә күмелгән маллар, акчалар, хәзинәләр. — *сущ. мн.* Клады, сокровища.

**Дәфга** دفعه *ис.* Берьюлы, тапкыр, кат, кабат. *Кипте исә, бер дәфга кузгалып бары кул буеның мәдрәсә талибләре.* (Г. Тук.) — *сущ.* Раз.

**Дәфгатән** دفعةً *р.* Кинәт, көтмәгәндә, искәрмәстән. *Ямьле тылсым чаткысы, могҗиз төсе дәфгатән яктыртты һәм балкытты нур.* (Ш. Баб.) — *н.* Внезапно, сразу.

**Дәфгы** دفع *ис.* 1) Кире кайтару. 2) Бетерү, китәрү. *Тилбәрән яфрагын авырткан җиргә япсаң, шул сәгать авыруны дәфгы кыйладыр.* (К. Нас.) 3) Читләтү. — *сущ.* 1) Толкание, отражение, отталкивание. 2) Удаление. 3) Отвергание, отстранение.

**Дәфгы зарар** دفع ضرر *ст.* Зарарны булдырмау, зарарны китәрү. — *сс.* Предотвращение вреда, бедствия.

**Дәфен** دفن *ис.* 1) Җирләү, җиргә күмү. *Ничек булса да дәфен итәргә кирәк.* (З. Биг.) 2) Мәет күмү. 3) Яшерү. — *сущ.* 1) Зарывание, закапывание. 2) Погребение. 3) Сокрытие.

**Дәфинә** دفینه *ис.* Җиргә күмелгән байлык, хәзинә. — *сущ.* Клад, сокровище.

**Дәфтәр*** دفتر *ис.* 1) Дәфтәр. 2) Хисап дәфтәре. — *сущ.* 1) Тетрадь. 2) Книга для записей.

**Дәхел** دخل *ис.* 1) Эчкә керү. 2) Катнашу, керешү. *Аның бу эштә дәхеле һич юк.* 3) Йогынты, тәэсир. — *сущ.* 1) Вход. 2) Отношение, вмешательство, касательство. 3) Влияние.

**Дәшт** دشت *ф. ис.* Дала, сахра, япан җир, кыр, чүл. **Дәшт кыпчак** — кыпчак даласы. — *п. сущ.* Степь, равнина, поле, пустыня.

**Дәүләт*** دولت *ис.* 1) Мал, байлык; материаль тәэмин ителгәнлек. *Җир йөзе җәннәт иде, дәүләт вә нигъмәт бар иде.* (Г. Тук.) 2) Ил, мәмләкәт, дәүләт. — *сущ.* 1) Богатство, могущество; благо. 2) Государство, держава, империя.

**Дәүләтмәнд** دولتمند *гф. с.* Бай, дәүләтле. — *ар.-п. прил.* Состоятельный, богатый.

**Дәүри** دوری *с.* Әйләнү(гә бәйләнешле). — *прил.* 1) Периодический. 2) Циркулярный.

**Дәүрә** دوره *ис.* Әйләнеш, бер әйләнеш, бер әйләнеп чыгу. — *сущ.* Оборот, обращение.

**Дәҗҗал** دجال *ис.* 1) Дәҗҗал (дини экият буенча: кыямәт булыр алдыннан чыгачак бер алдакчы). 2) Алдакчы, ялганчы. — *и. с.* 1) Антимухаммед (который, по религиозному поверью, появится перед кончиной мира). 2) Шарлатан, обманщик, лжец, самозванец, антихрист.

**Дәһер** دهر *ис.* 1) Заман, чор. *Санняры тик аллага мәгълүм дәһерләр үтеп, җитте хәзер ошбу гасыр.* (Ш. Баб.) 2) Матди дөнья, табигать, тереклек. — *сущ.* 1) Эпоха, век. 2) Материальный мир, природа.

**Дәһри*** دهری *с.* **1.** 1) Бер заман(га), чор(га бәйләнешле). 2) Табигать(кә), материаль дөнья (га бәйләнешле). 3) Ахирәткә ышанмаучы, алласыз, динсез. **2.** Материалист, атеист. — *прил.* **1.** 1) Вековой; эпохальный. 2) Природный. 3) Безбожный, атеистический, вольнодумный. **2.** Материалист, атеист.

**Дәһшәт*** دهشت *ис.* 1) Зур куркынычлык алдында куркып, югалып калу. 2) Курку, өркү, куркуга төшү. 3) Куркынычлы күренеш. *Эчтә дулкыннар куба, дәһшәт бирмә өреләә.* (Ш. Баб.) — *сущ.* 1) Паника, смятение. 2) Ужас, страх, испуг.

**Дәһшәт амиз** دهشت‌آمیز *ф. ст.* 1) Куркынычны эченә алган нәрсә. *Балалар арасында минем өчен иң дәһшәт амиз... яз көнендә була торган иде.* (Ф. Әмир.) 2) Куркыныч. — *ар.-п. сс.* **1.** Ужасающий, ужасный. **2.** Ужас.

**Дөбб** دب *ис.* Аю. — *сущ.* Медведь.

**Дөббеләкбәр** دب‌الاکبر *из. астр.* Зур жидегән йолдыз. — *из. астр.* Большая медведица.

**Дөббеләсгар** دب‌الاصغر *из. астр.* Кечкенә жидегән йолдыз. — *из. астр.* Малая медведица.

**Дөвәл** دول *ис.* Дәүләт-нең *к.* — *сущ. мн.* от дәүләт.

**Дөвәл могаззама** دول‌معظمه *ст.* Зур дәүләтләр. — *сс.* Великие державы.

**Дөкян** دکان *ис.* Кибет, магазин. — *сущ.* Лавка, магазин.

**Дөлдөл** دلدل *ис.* Гали хәлифә атланып йөргән качыр исеме. — *и. с.* Кличка мула халифа Алия.

**Дөмугъ** دموع *ис.* Дәмгъ-нын *к.* — *сущ. мн.* от дәмгъ.

**Дөнья*** دنیا *ис.* 1) Дөнья, галәм. 2) Татар телендә бик күп мәгънәсендә кулланыла. *Дөнья балык тоттым* (Г. Минский). — *сущ.* 1) Мир, свет, вселенная. 2) В татарском языке употребляется в значении очень много.

**Дөньяви** دنیاوی *с.* Дөньяга караган, дөньяныкы. *Сызлану белән кулымдан дөньяви шөгълем оча.* (Ш. Баб.) — *прил.* 1) Мировой. 2) Светский. 3) Мирской.

**Дөньядар** دنیادار *гф. с.* Дәүләт иясе, зур байлык иясе. — *ар.-п. прил.* **1.** Богатый. **2.** Богач.

**Дөньяпәрәст** دنیاپرست *гф. с.* Дөнья яратучы, дөнья сөюче. — *ар.-п прил.* 1) Преданный мирским удовольствиям. 2) Жизнелюбивый.

**Дөрешт** درشت *ф. с.* 1) Салмак, эре. 2) Каты. 3) Тупас. *Дөрешт җамә киеп арпа өярдем.* (Ут. Им.) — *п. прил.* 1) Массивный, крупный. 2) Жесткий, твердый. 3) Грубый, дерзкий.

**Дөррә** دره *ис.* **1.** Энже, энже бөртеге. *Чыкты балык карнындин дөррәи халь.* (Мөхм.) **2.** 1) Зур, тирән мәгънәле. 2) Кыйммәтле, кадерле. — *сущ.* **1.** Жемчужина, перл. **2.** 1) Имеющий глубокий смысл. 2) Драгоценный.

**Дөррәнисар** درەنثار *гф. ис.* Энже чәчүче; тирән мәгънәле сүз чәчүче. *Равиян асар вә накыйлан дөррәнисар шундак риваять вә мондак хикаят кылырлар.* (Ә. У. К.) — *ар.-п. сущ.* Сеятель жемчужин; сеятель слов глубокой мысли.

**Дөруг** دروغ *ис.* Ялган, яла, алдау; алдавычлы. — *сущ.* **1.** Ложь, неправда, обман. **2.** Ложный, обманчивый.

**Дөрудгәр** درودگر *ф. ис.* Балта остасы, столяр. *Дөрудгәр тактадан бер сандык ясады.* (Көлке намә.) — *п. сущ.* Плотник, столяр.

**Дөрус** دروس *ис.* Дәрес-нең *к.* — *сущ. мн.* от дәрес.

**Дөф** دف *ис. кара:* дәф. — *см.* Дәф.

**Дөхан** دخان *ис.* 1) Төтен. 2) Тәмәке. — *сущ.* 1) Дым. 2) Табак.

**Дөханкәш** دخانكش *гф. ис.* Тәмәке тартучы. — *ар.-п. сущ.* Курильщик, трубакур.

**Дөхтәр** دختر *ф. ис.* Кыз. *Аның берәр як читендә матур бер дөхтәрнең нурлы күзләләре...* (М. Гаф.) — *п. сущ.* Девушка.

**Дөхтәран** دختران *ф. ис.* Дөхтәрнең *к.* — *п. сущ. мн.* от дөхтәр.

**Дөхулия** دخوليه *ис.* Берәр җиргә керү өчен алына торган хак, пошлина. — *сущ.* Входная плата, пошлина.

**Дөхуль** دخول *ис.* 1) Эчкә керү, керү. 2) Керем, табыш, килер. — *сущ.* 1) Вход, вхождение. 2) Доход, прибыль.

**Дөшвәр** دشوار *ф. с.* 1) Кыен, авыр, куркынычлы. *Хәлем дөшвар, тәнем мәҗрух, күңлем мәгъмум.* (К. Гал.) 2) Кырыс, нык, җитди. 3) Күңелсез. — *п. прил.* 1) Трудный, тяжёлый, опасный. 2) Строгий, серьёзный.

**Дөшнам** دشنام *ф. ис.* Сүгү, ачулану, орышу. *Тәвәне күзе күргәч дөшнам урынына, алла сине ярлыкасын диде.* (К. Нас.) — *п. сущ.* Брань, ругань, ругательство.

**Дөҗа** دجا *ис.* Караңгылык. — *сущ.* Темнота, тьма, мрак.

**Дөҗаҗ** دجاج *ис.* Тавык. — *сущ.* Курица.

**Дөһен** دهن *ис.* Май, туң май. — *прил.* Масло, сало, жир.

**Дөһни** دهنى *с.* Майлы, туң май(га бәйләнешле.) — *прил.* Масляный, жировой, сальный.

**Дөһниять** دهنيت *ис.* Майлылык, майга бәйлелек. *Алтынның сарылыгы нарияттән* (утка бәйлелектән), *йомшаклыгы дөһнияттән вә ялтыравыгы суның сафүвәсеннәндер* (сафлыгыннандыр). (К. Нас.) — *сущ.* Масляность, жирность.

**Дүзәх** دوزخ *ф. ис.* Тәмуг, җәһәннәм. *Мәхәббәтең көйдерәдер, дүзәхме әллә.* (Ш. Баб.) — *п. сущ.* Ад, преисподняя.

**Дүн** دون *ф. с.* 1) Түбән, пәс. 2) Әһәмиятсез. 3) Арзан. 4) Аскы (кат). *п. прил.* 1) Низкий, мерзкий. 2) Незначительный. 3) Хуже, дешевле. 4) Нижний.

**Дүру** دورو *ф. ис.* 1) Икейөзлелек, монафыйклык. 2) Монафыйк. *п. сущ.* 1) Двуличность. 2) Двурушник.

**Дүсал** دوسال *ф. ис.* Ике ел. *п.* Два года.

**Дүшизә** دوشيزه *ф. ис.* Кыз бала; гыйффәтле кыз; туташ. *п. сущ.* Девушка, девица; девственница; барышня.

**Дүшәмбе*** دوشمبه *ф. ис.* Атнаның 2 нче көне. *п. сущ.* Понедельник.

# З

**З** — ذ، ز، ض، ظ татар әлифбасында сигезенче хәреф, гарәп әлифбасындагы тугызынчы хәреф „ذ“, унберенче хәреф „ز“, унбишенче хәреф „ض“ һәм унҗиденче хәреф булган „ظ“ хәрефләрен белдерә. Болардан фәкать „ز“ генә бездәге „з“ авазына туры килә, ә „ذ“ Минзәлә, башкорт әйтелешендәге сакау „з“ гә туры килә, „ض“ һәм „ظ“ исә „з“ гә тартымлы „д“ авазын белдерәләр. Сан урынында кулланганда „ذ“ —700 не, „ز“ — 7 не, „ض“ —800 не, „ظ“ — 900 не белдерә. Восьмая буква татарского алфавита, обозначающая девятую букву арабского алфавита „ذ“ (цифровое значение 700), одиннадцатую букву „ز“ (цифровое значение 7), пятнадцатую букву „ض“ (цифровое значение 800) и семнадцатую букву „ظ“ (цифровое значение 900).

**За** ذا *кис.* Ия, хуҗа, биләүче (һәрвакыт берәр сүзгә бәйләнеп килә). *част.* Обладающий, владеющий, имеющий (ставится обычно перед именем существительным).

**Забит** ضابط *сф.* **1.** 1) Буйсындыручы, биләүче, кулга кертүче. 2) Басып алучы, сугышып алып буйсындыручы. 3) Үзләштерүче (дәресне). **2.** Офицер. *пр. д.* **1.** 1) Подчиняющий. 2) Управляющий. 3) Захватывающий. 4) Усваивающий (урок). **2.** Офицер.

**Забита** ضابطه *ис.* 1) Канун—закон нар исемлеге, кагыйдә. 2) Шәһәрдәге тәртипне карый торган идарә. *сущ.* 1) Закон, порядок, правило. 2) Полиция, полицейское управление.

**Забих** ذابح *сф.* Суючы, хайван суючы, сугымчы. *пр. д.* Убивающий, закалывающий (животных), работающий на бойне, мясник.

**Забыт** ضبط *м. I.* 1) Биләү. 2) Үзләштерү, кулга төшерү. 3) Кулга алу. 4) Басып алу, сугышып алу. 5) Буйсындыру. *Каләмне забыт итеп вирдем ниһаять.* (Г. Тук.) 6) Беркетмәгә теркәү, язып кую. — *м. I.* 1) Держание, владение, удерживание. 2) Захват, ловля, схватывание, арест. 3) Усвоение, присвоение. 4) Занесение в книгу. 5) Подчинение.

**Забытнамә** ضبطنامه *гф. ис.* Беркетмә, протокол. — *ар.-п. н.* Протокол, акт.

**Зәваһир** ظواهر *ис.* Заһир-ның *к.* — *сущ. мн.* от заһир.

**Завия** زاويه *ис.* 1) Почмак. 2) Өй почмагы, бүлмә. — *сущ.* 1) Угол. 2) Угол, комната.

**Загыф** ضعف *ис.* Зәгыйфьлек, көчсезлек, хәлсезлек, дәрмансызлык. — *сущ.* Слабость, немощь, бессилие, тщедушие.

**Зад*** زاد *ис.* Азык, ашамлык, ризык. — *сущ.* Пища, продукт, съестное.

**Задә** زاده *ф. ис.* Ир бала (берәүнең улы); патша улы. — *п. сущ.* Сын, дитя; царевич, принц.

**Зәдәкян** زادكان *ф. ис.* Аксөяк, дворянин. — *п. сущ.* Дворянского происхождения, „белая кость“, „Голубая кровь“.

**Заегат** ضايعات *ис.* Заегъ-нең *к.* — *сущ. мн.* от заегъ.

**Заегъ*** ضايع *сф.* 1) Әрәм, файдасыз. 2) Югалган, әрәм булган, юкка чыккан, һәлак булган. — *пр. д.* 1. Потерянный, пропавший. 2. Потеря, утрата, гибель.

**Заид** زائد *сф.* 1) Артык, арттырылган; артып калган. 2) Өстәлгән. — *пр. д.* 1) Лишний, излишний. 2) Добавочный.

**Заика** ذائقه *ис.* 1) Тәм тату тойгысы. 2) Татып караучы. — *сущ.* 1) Чувство вкуса. 2) Вкушающий, снимающий пробу.

**Заикъ I** ذائق *сф.* Тәм тоючы, тәм тою сәләтенә ия булган кеше. — *пр. д.* Со вкусом, обладающий хорошим вкусом.

**Заикъ II** ضيق *с.* Тар, тыгыз. — *прил.* Тесный, узкий.

**Заил** زائل *сф.* 1) Бетә (юкка чыга) торган, югала торган. 2) Үтә (уза) торган. *Яшьлек тиз заил була.* 3) Үткән, булып узган. *Мөхарәбәи заилдә батырлык күрсәткәннәр.* (К. Нас.) 4) Язу. *Акылдан заил булу* — акылдан язу. — *пр. д.* 1) Заходящий, исчезающий, перестающий, прекращающийся. 2) Преходящий, кратковременный. 3) Прошедший, исчезнувший. 4) Потерять рассудок.

**Заир** زائر *сф.* Хәл белә килүче, күрергә килүче, күрешергә килүче. *Өемә* — *пр. д.* 1. Посетитель. 2. Навещающий, наведывающий.

*кайттым, үзем заирләр көтә башладым.* (Ф. Әмир.)

**Зайг*** ضيع *ис.* Югалту, әрәм итү, бушка уздыру. — *сущ.* Потеря, утрата; напрасная трата.

**Зайчә** زايچه *ф. ис.* 1) Астрономик җәдвәлләр. *Гыйльме нөҗүм үзрә зайчә тәхрир кылды.* (К. Нас.) 2) Метрика таныклыгы. — *п. сущ.* 1) Астрономические таблицы. 2) Метрическое свидетельство.

**Зайк** ضيق *м. I.* 1) Тарлык, тыгызлык, кысылу. 2) Шик, шикләнү. *Бу ни дигән сүз? — дип зайк күрсәтте.* (М. Гаф.) — *м.I.* 1) Узость, теснота; стеснение. 2) Сомнение.

**Зайкыннәфес** ضيق النفس *из.* Сулыш тарлыгы, сулыш кысылу. — *из.* Стеснение дыхания.

**Зайкылкальб** ضيق القلب *из.* Йөрәк кысылу. — *из.* Боль сердца.

**Закир** ذاكر *сф.* 1) Телгә алучы, телгә алып сөйләүче, искә алучы. 2) *дини* Догалар укучы; алланы мактап зикер әйтүче. — *пр. д.* 1) Упоминающий, называющий, вспоминающий. 2) *рел.* Восхваляющий, славословящий (аллаха в своих молитвах).

**Залик** ذلك،ذالك *алм.* Шул, теге. — *мест.* Тот.

**Залил** ظليل *с.* Күләгәле, ышык, күләгәләнгән. — *прил.* Тенистый; затенённый.

**Залим*** ظالم *сф.* 1) Җәберләүче. 2) Мәрхәмәтсез, каты күңелле кеше. *Бүген булды залимнәрнең йөзе кара.* (М. Гаф.) — *пр. д.* 1) Несправедливый, жестокий. 2) Притеснитель, тиран.

**Залима** ظالما *ис.* Залим-нын *к.* *Сез рәисе залимани „Йолдыз"ә хибес иттеңез* (Сез җәберләүчеләр башлыгын (төрек солтанын) „Йолдыз"га — сарай төрмәсенә ябып куйдыгыз.) (Г. Тук.) — *сущ. мн.* от залим.

**Залиманә** ظالمانه *гф. р.* Залимнәрчә, хаксызлык белән. — *ар.-п. н.* Жестоко, тиранически, несправедливо.

**Залл** ضال *сф.* Бозык юлга керүче, азгын, бозык, начар. — *пр. д.* 1) Заблуждающийся, заблудившийся, сбившийся, сошедший с пути истинного. 2) Развращённый.

**Заляль, заляләт** ضلال،ضلالت *м. I.* Туры юлдан язу, начар юлга керү, ялгыш юлга керү; азгынлык. *Һава* (теләк) *вә һәвәскә ияргән кеше залялəттәдер.* (К. Нас.) — *м. I.* Заблуждение, ошибка, отклонение от истинного пути.

**Зам** ضم *м.I.* 1) Тоташтыру, берләштерү, кушу, өстәү, арттыру. *Җөзэ әүвәлләрени тәгъйин өчен зам кылыныр.* (К. Нас.) 2) *грам.* Хәрефнең өтер белән укылуы. — *м.I.* 1) Прибавление, сложение, присоединение. 2) *грам.* Дамма (диакритический знак для звука о — ө).

**Заман* I** زمان *ис.* 1) Вакыт, чор, эпоха. 2) *грам.* Заман. — *сущ.* 1) Время, пора, эпоха. 2) *грам* Время.

**Заман II** ضمان *ис.* 1) Җаваплылык. 2) Тәэмин итү; гарантия, ышаныч. 3) Йолып алу, салым түләү, бер нәрсәнең бәясен түләү. *Өйемездә өзелгән бауның заманы безнең өстемездәдер.* (К. Нас.) — *сущ.* 1) Ответственность. 2) Обеспечение, гарантия, ручательство. 3) Уплата выкупа.

**Замане мазый** زمان‌ماضی *ст. грам.* Үткән заман. — *сс. грам.* Прошедшее время.

**Замане мөзаригъ** زمان‌مضارع *ст. грам.* Хәзерге-киләчәк заман. — *сс. грам.* Настояще-будущее время.

**Замане мөстәкъбәл** زمان‌مستقبل *ст. грам.* Киләчәк заман. — *сс. грам.* Будущее время.

**Замане халь** زمان‌حال *ст. грам.* Хәзерге заман. — *сс. грам.* Настоящее время.

**Замани** زمانی *с.* 1) Вакытлы. 2) Вакытлыча. — *прил.* 1) Временный. 2) Временно.

**Заманә** زمانه *ис. кара:* заман. — *сущ. см.* Заман.

**Заманән** زماناً *р.* 1) Вакыт-вакыт. 2) Хронологик рәвештә. — *н.* 1) По временам. 2) Хронологически.

**Замимә** ضمیمه *ис.* 1) Өстәмә, кушымта. 2) Китапның азагына өстәлгән өстәмә. — *сущ.* 1) Добавление, прибавка. 2) Дополнение (в конце книги).

**Замин** ضامن *сф.* Бер кешенең бурычын түләүне үз өстенә алучы, түләүче. — *пр. д.* **1.** Ручающийся. **2.** Поручитель.

**Замир** ضمیر *ис.* 1) Эч, һәр әйбернең эчке ягы. 2) Йөрәк, вөждан. 3) *грам.* Алмашлык сүзләр; тартым һәм зат кушымчалары. — *сущ.* 1) Содержание. 2) Совесть. 3) Помыслы. 4) Смысл. 5) *грам.* Местоимение; притяжательный и личный местоименный аффикс.

**Замиры изафи** ضمیراضافی *ст.* Исемнәрдә тартым кушымчасы. — *сс.* Притяжательный аффикс имён.

**Замиры фигъли** ضمیر فعلی *ст.* Фигыльдә зат кушымчасы. — *сс.* Личный аффикс глагола.

**Заммә** ضمه *ис. грам.* Өтер (тартык авазның „о“ яки „ө“ сузыгы белән укылырга тиешлеген күрсәтә торган диакритик билге). — *сущ. грам.* Дамма (диакритический знак, обозначающий звуки ө — о).

**Зан** ظن *ис.* 1) Анык (ачык) булмаган, якынча гына булган уй. *Гайбем җиңел улыр зан кылмыш исә дә...* (З. Биг.) 2) Берәр нәрсә турында шикләнеп карау. **Хөсне зан** — яхшы уйда булу, яхшы уй тоту. — *сущ.* 1) Предположение, мнение, мысль. 2) Сомнительное отношение к чему-либо.

**Зани** زانی *сф.* Уйнашчы ир. — *пр. д.* Развратник.

**Зания** زانیه *сф.* Уйнашчы хатын. *Зани белән заниянең эшләрен дүрт кеше бердән күргән булырга тиеш.* (М. Гаф.) — *пр. д.* Развратница.

**Занун** ظنون *ис.* Зан-ның *к.* — *сущ. мн.* от зан.

**Зар I** زار *ф. с. ис.* **1.** Тавыш белән елаучы, иңелдәп, үкереп елаучы. **2.** Тавыш белән елау, иңелдәп, үкереп елау. **3.** Дәрмансыз, көчсез, зәгыйфь. — *п. сущ. прил.* **1.** 1) Плачущий, рыдающий, вздыхающий. 2) Тощий, бессильный, слабый. 3) Ничтожный. **2.** Плач, рыдание.

**Зар II** زار *ф. кис. грам.* Үзе кушылган исем белдергән әйбернең күп була торган урынын белдерүче кушымча („лык, сар“ мәгънәсендә), мәс., *гөлзар* — чәчәклек. — *п. част. грам.* Суффикс, обозначающий место изобилия, напр., *гөлзар* — место, где много роз; цветник.

**Зарар*** ضرر *ис.* Зарар, зыян. — *сущ.* Повреждение, вред, потеря, убыток.

**Зарафәт** ظرافت *ис.* 1) Үзен тотуда, кеше белән мөгамәләдә нәзакәтлек, тәрбиялелек, ягымлылык. 2) Сүздә, сөйләшүдә ягымлылык. — *сущ.* 1) Элегантность, изящество, грация, хорошие манеры. 2) Нежность, утончённость. 3) Остроумие, юмор.

**Зарб** ضرب *м. I.* 1) Сугу, кыйнау, ору. 2) Акча сугу. 3) *мат.* Тапкырлау. — *м. I.* 1) Удар, избиение. 2) Чеканка. 3) *мат.* Умножение.

**Зарбе мәсәл** ضرب مثل *из.* Күп очракта мисал итеп китерергә яраган сүз әйтү, гыйбрәтле кыска хикәя әйтү, мәкаль әйтү. *„Йөргән таш шомарыр, яткан таш тутыгыр“ гавам арасында зарбе мәсәлдер.* (К. Нас.) — *из.* Употребление пословицы, поговорки, нравоучительной басни.

**Зарбә** ضربه *ис.* 1) Бәрү, бер сугу, кыйнау. *Залим фәләкнең һәрбер зарбәсенә каршы мин үз тарафымнан берәр химая итенү коралы уйлап чыгара торган идем.* (Ф. Әмир.) 2) Бәхетсезлек, зыян. — *сущ.* 1) Удар. 2) Бедствие, несчастье.

**Заргирьян** زارگریان *ф. с.* Акырып елаучы. — *п. прил.* Рыдающий, вопящий, плачущий навзрыд.

**Зар-зар** زار - زار *ф. р.* Акырып, кычкырып-кычкырып (елау). — *п. н.* Навзрыд.

**Зариб** ضارب *сф.* 1) Сугучы, кыйнаучы, оручы. 2) *мат.* Тапкырлаучы. — *пр. д.* 1) Наносящий удар, бьющий. 2) *мат.* Множитель.

**Заригъ** زارع *сф.* Игенче. — *пр. д.* Земледелец, пахарь.

**Зари-зари** زاری - زاری *ф. р. кара:* зар-зар. *Зари-зари еглады шәмче Гали.* (Г. Тук.) — *п. н. см.* Зар-зар.

**Зар-интизар** زارانتظار *гф. ст.* Елап көтеп тору. — *сс.* Рыдающий, вздыхающий в ожидании.

**Зариф** ظریف *с.* 1) Ягымлы, нәзакәтле, чибәр. 2) Күнелне табарлык итеп ягымлы сөйләүче кеше, оста сүзле кеше. — *прил.* 1) Красивый, элегантный. 2) Остроумный, красноречивый.

**Зарифанә** ظریفانه *гф. р.* Ягымлы итеп, ягымлылык белән; юаш (ягымлы) табигать белән; нәзакәт белән. — *ар. -п. н.* 1) Элегантно, красиво, изящно. 2) Остроумно, красноречиво.

**Зарсәргәрдан** زارسرگردان *ф. ст.* Елый-елый баш әйләнү. — *п. сс.* Головная боль от того, что человек плакал.

**Зарур*** ضرور *с.* Тиеш, кирәк, тиешле, кирәкле, чарасыз, котылгысыз. — *прил.* **1.** Необходимый, нужный, обязательный. **2.** Необходимо, нужно, обязательно.

**Зарури** ضروری *с.* 1) *кара:* зарур. 2) Булмый калуы мөмкин булмаган, бик кирәкле, котылгысыз. — *прил.* 1) *см.* Зарур. 2) Самый (крайне) необходимый.

**Зарурият, зарурәт** ضرورت،ضروریت *ис.* Чарасызлык, котылгысызлык, ирексезлек, үтә кирәклек, мохтаҗлык. *Менә зарурәт буенча алган кисәкләрне ашаттым.* (М. Гаф.) — *сущ.* Необходимость, крайность; неизбежность, нужда.

**Зарф** ظرف *ис.* 1) Савыт. 2) Футляр. 3) Конверт. 4) Дәвам, эч. *Ике атна зарфында.* 5) Шарг. 6) *грам.* Рәвеш. **Зарфе заман** — вакыт рәвеше. **Зарфе мәкян** — урын рәвеше. — *сущ.* 1) Сосуд. 2) Футляр. 3) Конверт. 4) Продолжение. 5) Обстоятельство, условие. 6) *грам.* Наречие.

**Зарәбә** ضربه *ис. кара:* зарбә. — *сущ. см.* Зарбә.

**Зат** ذات *алм.* 1) За-ның *мнс.* 2) Әйбер, нәрсә. 3) Шәхес, аерым кеше. *Мә-* — *мест.* 1) *жен.* от За. 2) Вещь, предмет. 3) Лич-

*хәббәт орлыгын чүпли әтәч кебек усал затлар.* (М. Гаф.) 4) Яратылыш, нигез, үзлек. — ность, особа, субъект. 4) Сущность, суть, существо.

**Зате гали** ذاتعالی *ф. из.* Югары дәрәҗәле, яратылышы югары булган, аксөяк. — *п. из.* Знатный, знатного происхождения.

**Зате пакь** ذاتپاك *гф. ис.* Алла. *Һәм тәбәррекләп боларны* (шайтан сакалын) *зате пакь алды бер кодрәт кулы берлән сыйпап.* (Ш. Баб.) — *ар.-п. сущ.* Аллах.

**Зати** ذاتی *с.* 1) Зат(ка бәйләнешле). 2) Яратылышына бәйләнешле, табигый. *Яз башында агачларның яфрак яруы зати бер халәттер.* — *прил.* 1) Личный, персональный. 2) Естественный, обусловленный самой природой.

**Затән** ذاتاً *р.* 1) Нигездә, төптә, яратылышта. *Затән моның Зыяга кирәге дә юк.* (Г. Ибр.) 2) Үзе. — *н.* 1) По природе, в сущности. 2) Лично, сам (сама).

**Зәфәр** ظفر *ис.* Өстен булу, өстенлек табу, җиңеп чыгу, теләккә ирешү. *Җөрьәт дигән нәрсә әсбабы зафәрдәндер.* (К. Нас.) — *сущ.* Победа, успех, достижение цели.

**Зафәрияте** ظفریت *ис.* Өстен чыгучылык, җиңеп чыгучылык, теләккә ирешүчелек. — *сущ.* Победоностность, успешность.

**Зафәрьяб** ظفریاب *ф. с. кара:* зофырьяб. — *п. прил. см.* Зофырьяб.

**Захик** ضاحك *сф.* Көлүче. — *пр. д.* Смеющийся.

**Захикән** ضاحكاً *р.* Көлеп, көлгән хәлдә. — *н.* Смехом, в шутку, смеясь.

**Заһиб** ذاهب *сф.* Йөрүче, баручы, китүче. — *пр. д.* Идущий, уходящий, исчезающий.

**Заһид** زاهد *ис. дини* Дөнья эшләреннән ваз кичеп, гыйбадәт белән генә шөгыльләнүче ир кеше, монах. *Таза бер мужик чаклы эш эшли..., чын бер заһид кадәрле динен, гыйбадәтен үти иде.* (Г. Ибр.) — *сущ. рел.* 1. Монах, отшельник. 2. Набожный; отрекшийся от „мира сего“.

**Заһидә** زاهده *ис.* Дөнья эшләреннән ваз кичеп, гыйбадәт белән шөгыльләнүче хатын кеше, монах хатын. — *сущ. жен.* 1. Монахиня. 2. Набожная.

**Заһир I** ظاهر *сф.* 1. 1) Ачык булучы, күренеп торучы. 2) Ачык, билгеле, күренеп торган. *Гайбенә күз салма дустым гыйсмәте мәнзур имәс, гайбе* — *пр. д.* 1. 1) Ясный, явный, очевидный, видимый. 2) Наружный, внешний. 2. Внешность, внешняя сторона.

*заһир улса — улсын, гайбе мәзъһәр улмасын.* (Ак.) 2. Тыш, тышкы күренеш.

**Заһир II** ظهير *с.* 1) Ярдәмче, булышчы. 2) Берәүне үз карамагына алучы. — *прил.* 1) Помощник, пособник. 2) Покровитель.

**Заһир III** زاهر *сф.* 1) Якты нур чәчүче, ялтырап тора торган. 2) Бик матур. — *пр. д.* 1) Блестящий, яркий. 2) Цветущий, прекрасный.

**Заһири** ظاهرى *с.* Тышкы, тыштагы, күренеп торган, тышкы якка караган, тышкы күренеш(кә бәйләнешле). *Бу, икенчедән, мәйданга заһири шатлык бирә.* (Г. Ибр.) — *прил.* Внешний; видимый; очевидный.

**Заһирән** ظاهراً *р.* 1) Тыштан, тыштан караганда. *Инсан улан өстенә таш төшсә дә хәуф итмәсен, батыйнән хәуф итсә итсен, заһирән белгертмәсен.* (М. Гаф.) 2) Ачыктан-ачык. — *н.* 1) Внешне, снаружи. 2) Явно, очевидно.

**Заһыр** ظهر *ис.* 1) Арка. 2) Әйбернең өске ягы. — *сущ.* 1) Спина. 2) Поверхность.

**Заһыри** ظهرى *с.* 1) Аркадагы. 2) Өстәге, өске як(ка бәйләнешле). 3) Арт яктагы. — *прил.* 1) Относящийся к спине. 2) Поверхностный. 3) Тыльный, задний.

**Зи** ذى *кис. кара:* за. — *част. см.* За.

**Зиб** زيب *ф. ис.* 1) Бизәк, зиннәт. 2) Матурлык. — *п. сущ.* 1) Украшение. 2) Красота.

**Зиба** زيبا *ф. с.* 1) Бизәкле, зиннәтле. 2) Матур, гүзәл, зифа. *Дөшем эчрә бер зиба сурәт күрдем.* (К. Гал.) — *п. прил.* 1) Украшенный, нарядный. 2) Красивый, стройный.

**Зи гыял** ذى‌عيال *ст.* Бала-чага иясе. — *сс.* Многодетный; имеющий много детей.

**Зи зәкявәт** ذى‌ذكاوت *ст.* Үткен (зирәк) кеше. — *сс.* Сообразительный, сметливый.

**Зий** زى *ис.* Тышкы кыяфәт, профессиягә карата форма (кием). — *сущ.* Внешний вид, профессиональная форма (одежды).

**Зикер** ذكر *ис.* 1) Искә алу, искә төшерү. 2) Телгә алу, әйтеп узу, телгә алып узу. *Югарыда зикер кылган ярлылар тора торган урынга барып торды.* (Ш. Кам.) 3) *дини* Зикер әйтү. — *сущ.* 1) Упоминание. 2) Воспоминание. 3) Зикр (моленье, заключающееся, главным образом, в беспрестанном произнесении хором имени аллаха).

**Зикер билхәер** ذكربالخير *гыйб.* Яхшылыгы белән искә алу, мактау. — *фр.* Поминание добром.

**Зикре җәмил** ذكر جميل *ст.* Яхшылык белән искә алу. *Зикре җәмил бер ягмурдыр ки, аның лотфы тауларны вә болыннарны ихья кылыр, диде.* (К. Нас.) — *сс.* Добрая память (о ком-либо).

**Зи кыйммәт** ذى قيمت *ст.* Кыйммәт иясе, кыйммәтле, бәяле. — *сс.* Драгоценный, дорогой.

**Зилзилә** زلزله *ис. кара:* зәлзәлә. — *сущ. см.* Зәлзәлә.

**Зилкагдә** ذى القعده *ст.* Ай елының унберенче ае исеме. — *сс.* Зулькагда (одиннадцатый месяц лунного календаря).

**Зилләт** ذلت *ис.* Түбәнлек, хурлык, гарьлек. *Безгә зилләт вә хурлык кына булачак.* (М. Гаф.) — *сущ.* Унижение, позор.

**Зилхиҗҗә** ذى الحجه *ст.* Ай елының уникенче ае исеме. — *сс.* Зульхиджа (двенадцатый месяц лунного календаря).

**Зимам** زمام *ис.* 1) Тезген, нукта бавы. *Мәхбубнең зимам ихтыярын мәхбубә кулына тәслим итәр.* (К. Нас.) 2) Җитәкләү, идарә итү. — *сущ.* 1) Повод, ремень. 2) Управление, руководство.

**Зимми** ذمى *с. тар.* Ислам дәүләте кул астында булган мөселман булмаган кеше, халык. *Бер зимми үзенең дуңгызын симертү өчен алдына печән салып куймыш иде.* (К. Нас.) — *прил. ист.* Наименование немусульман, живущих в мусульманских странах.

**Зиммә** ذمه *ис.* 1) Бер эшне үз өстенә йөкләү, җаваплылыкны алу. 2) Йөкләмә. *Зиммәңә лязим булган нәрсәне әдә кыл* (үтә). (К. Нас.) — *сущ.* 1) Ответственность. 2) Обязательство.

**Зиммәт** ذمت *ис. кара:* зиммә. — *сущ. см.* Зиммә.

**Зина*** زنا *ис.* 1) Уйнаш. 2) Фахишәлек. — *сущ.* 1) Прелюбодеяние, распутство. 2) Проституция.

**Зинакяр** زناكار *гф. ис.* Уйнашчы, зиначы. — *ар.-п. сущ.* 1) Прелюбодей, распутник. 2) Проститутка.

**Зиндан** زندان *ф. ис.* Төрмә. — *п. сущ.* Тюрьма, темница.

**Зиндикъ** زنديق *ис.* Динсез. *Юк исә мөнкир вә зиндикъ дәһриләр аллагыз гафләттә калган бит, дияр.* (Ш. Баб.) — *сущ.* Еретик, безбожник.

**Зиндәгяни, зиндәги** زندگانى، زندگى *ф. ис.* Терелек, җанлылык; тормыш, тереклек. *Мән куркамын, сән аның гадәт* — *п. сущ.* Жизнь.

*вә хоенча зиндәгянлык кыла алмассың* (Мәҗмәгыл хикәят).

**Зиннәт*** زينت *ис.* Бизәк, бизәү әйбере, матурлау, гүзәлләү әйбере. — *сущ.* 1) Украшение. 2) Предмет украшения; декорация.

**Зи нөфүз** ذى‌نفوز *ст.* Йогынтылы, сүзе үтемле. — *сс.* Влиятельный.

**Зинҗир** زنجير *ф. ис.* Чылбыр, богау. — *п. сущ.* Цепь, оковы.

**Зир** زير *ф. ис.* Аст, аскы як. *Мөхатыз һәр җәһәттән саг* (уң) *вә сулдан, зир вә бәладән* (өстән). (Г. Тук.) — *п. сущ.* Низ, нижняя часть.

**Зираг** زراع *ис.* Кул; терсәк; терсәк буе озынлык улчәве (58 *см*). — *сущ.* Рука; локоть (орган тела и как мера длины, равная 58 *см*).

**Зирагать** زراعت *ис.* 1) Игенчелек. 2) Авыл хуҗалыгы. — *сущ.* 1) Земледелие. 2) Возделывание, сеяние, разведение, культивирование. 3) Сельское хозяйство.

**Зирагый** زراعى *с.* Авыл хуҗалыгы(на), игенчелек(кә караган). — *прил.* 1) Земледельческий. 2) Сельскохозяйственный; аграрный.

**Зир-зөбәр*** زيرزوبر *ф. ис.* Асты өскә (килү). *Бар залимнәр зир-зөбәр килгән имеш.* (М. Гаф.) — *п. сущ.* Перевернутое вверх дном; хаос.

**Зи рух** ذى‌روح *ст.* Җан иясе, җанлы. — *сс.* Имеющий душу, одушевлённый.

**Зирә** زيرا *ф. тер.* Чөнки, аның өчен, нигә дисәң. *Зирә ул башкалар кебек Гали байны озгламас иде.* (М. Ак.) — *п. союз* Потому что, так как, ибо.

**Зирәки** زيرا كه *ф. ис. кара:* зирә. — *п. сущ. см.* Зирә.

**Зирәһ** زره *ф. ис.* 1) Сугышта уктан, кылычтан саклану өчен киелә торган кием, күбә. 2) Броня. — *п. сущ.* 1) Кольчуга. 2) Броня.

**Зифаф** زفاف *ис.* 1) Кыз янына кияү булып керү. 2) Никахланышу. — *сущ.* 1) Прибытие жениха к невесте. 2) Бракосочетание.

**Зиэб** ذئب *ис.* Бүре. — *сущ.* Волк.

**Зиядә** زياده *ис.* 1) Арту, күбәю. 2) Артып калганы. 3) Күп, артык, артыграк, арттырып, артыграк итеп. *Ул егерме яшьтән зиядә үлмас.* (З. Биг.) 4) *грам.* Кушымча. — *сущ.* 1) Увеличение, прибавление. 2) Излишек. 3) Более, больше. 4) *грам.* Аффикс.

**Зи хәят** ذی‌حیات *ст.* Тереклек иясе. *Ул, һәрбер зи хәят шикелле, бу җәберләргә үз көче белән каршы торырга тели.* (Ф. Әмир.) — *сс.* Живой, одушевлённый.

**Зи шан** ذی‌شان *ст.* Дан иясе, данлы, даны бар. *Анлары инкяр идән зи шан икәндер белмәдем.* (Г. Тук.) — *сс.* Прославленный, славный.

**Зишт** زشت *ф. с.* Ямьсез, кыяфәтсез, чиркәнеч, начар; тупас. *Энҗе, алмаслар да бирмәс зишт руга зиба ру.* (Дәрд.) — *п. прил.* Некрасивый, гадкий, безобразный; плохой, дурной; гнусный; грубый.

**Зиян*** زیان *ф. ис.* Кимчелек, зарар, зыян. — *сущ.* Вред, убыток, ущерб, потеря, изьян.

**Зиярәт** زیارت *ис.* 1) Зират. 2) Күрергә, күрешергә бару, хәл белә бару. *Бер генә сәгатькә зиярәткә кергән иптәшем хәтеремә төште...* (Ф. Әмир.) — *сущ.* 1) Кладбище. 2) Посещение, визит.

**Зиярәтгяһ** زیارتگاه *гф. ис.* Зиярәт кыла торган урын, алдан билгеләнгән күрешү урыны. — *ар.-п. сущ.* Место посещения, место встречи, свидания.

**Зиярәтән** زیارتاً *р.* Хәл белеп, хәл беләрәк, күрешү (хәл белү) өчен. — *н.* Навещая, посещая.

**Зи җәмал** ذی‌جمال *ст.* Матурлык иясе; матур, күркәм. — *сс.* 1) Красивый. 2) Красавец.

**Зиһен*** ذهن *ис.* 1) Күңелдә, истә тота алу. 2) Хәтер, аң. — *сущ.* 1) Ум, разум. 2) Память, сознание.

**Зиһни** ذهنی *с.* Акыл(га), зиһен(гә бәйләнешле), хәтердә тоту(га бәйләнешле). — *прил.* Умственный, интеллектуальный.

**Зиһнән** ذهناً *р.* Күңелдән, яттан, хәтердән. — *н.* На память, наизусть.

**Зобани** زبانی *ис. дини* 1) Тәмугта яндырып торучы, газап фәрештәсе. 2) Бөҗәк чәнечкесе. 3) Сатлык җаннар. *Кояш шаһит, илем ирке өчен сугышып йөрдем, ул күү де, зобанилар, явыз зобанилар, алар... алар мине үтерде.* (Һ. Так.) — *сущ.* 1) *рел.* Адское воинство, черти. 2) Жало (насекомого). 3) Предатели, наймиты.

**Зогафа** ضعفا *ис.* Зәгыйфь-нең *к.* — *сущ. мн.* от зәгыйфь.

**Зогыф** ضعف *ис.* Физик зәгыйфьлек, көчсезлек, хәлсезлек. *Зогфе хактан хәүф итеп, сез иттеңезме иртидад.* (Г. Тук.) — *сущ.* Физическая слабость, немощь, тщедушие.

**Зонун** ظنون *ис.* Занун-ның *к.* — *сущ. мн.* от занун.

**Золым** ظلم *ис.* 1) Хаксызлык, гаделсезлек, турылыксызлык. 2) Кысу, җәбер, урынсыз рәнҗетү, изү. *Заманның безгә кылган золымын күр.* (М. Гаф.) — *сущ.* 1) Несправедливость. 2) Гнёт, притеснение, тирания.

**Золмән** ظلما *р.* Җәберләп, хаксызлык белән. — *н.* Насильственно, несправедливо.

**Золмәт** ظلمت *ис.* Караңгылык. *Золмәт китеп, урынына тулды нурлар.* (М. Гаф.) — *сущ.* Темнота, мрак.

**Зорубе әмсал** ضروب امثال *из.* Зарбе мәсәл-нең *к.* — *из. мн.* от зарбе мәсәл.

**Зофыр** ظفر *ис. кара:* зафәр. — *сущ. см.* Зафәр.

**Зофырьяб** ظفرياب *гф. с.* Өстен чыгучы, теләгенә ирешүче, җиңүче. *Әлхәнәфи әй Мозаффар, зофырьяб бул, нык тырыш, борчагың сип, муллаларны аска ташлап өскә оч!* (Ш. Баб.) — *ар.-п. прил.* Победоносный.

**Зоха** ضحا،ضحى *ис.* Иртәнең соңы, төш алды вакыты. — *сущ.* Позднее утро, время до полудня.

**Зоюф** ضيوف *ис. к.* Кунаклар. — *сущ. мн.* Гости.

**Зоһер** ظهر *ис.* Төш вакыты, көн уртасы. — *сущ.* Полдень.

**Зоһрия** ظهريه *ис.* Көндезге аш. — *сущ.* Обед.

**Зоһур** ظهور *м. I.* Килеп чыгу, беленү, күренү, мәйданга чыгу, барлыкка килү. *Һәр көндә нинди эшләр зоһур итә.* (М. Гаф.) — *м. I.* Появление, выход.

**Зоһурат** ظهورات *ис.* Зоһур-нын *к.* — *сущ. мн. от* зоһур.

**Зу** ذو *кара:* за. — *см.* За.

**Зу фөнүн** ذوفنون *ст.* Белем иясе, төрле фәннәрдән белеме булган кеше. — *сс.* Учёный, человек науки, эрудит.

**Зуэ** ضوء *ис. кара:* зыя. — *сущ. см.* Зыя.

**Зыйдд** ضد *ис.* 1) Кире, киресе, каршы, тискәре. 2) Дошман. *Һәрнәрсә үзенең зыйддын ан качар.* (К. Нас.) — *сущ.* 1) Противоположность, контраст. 2) Противник, враг.

**Зыйддиять** ضديت *ис.* 1) Каршылык, капма-каршылык, кирелек, тискәрелек. 2) Дошманлык. — *сущ.* 1) Противоположность, контраст. 2) Антагонизм; вражда.

**Зыйлгы** ضلع *ис.* 1) Кабырга. 2) *мат.* Геометрик фигураның ягы. — *сущ.* 1) Ребро. 2) *мат.* Сторона (треугольника).

**Зыйлл** ظل *ис.* Күләгә. *Зыйлле иблиси дә милләт зыйлле мәгъбүд әйләмәс.* (Г. Тук.) — *сущ.* Тень.

**Зыймни** ضمنی *с.* 1) Киная белән (читләтеп) аңлатылган. 2) Сүз сөрешенә карап аңлашыла торган. — *прил.* 1) Скрытый, не выраженный словами. 2) Косвенный, подразумеваемый.

**Зыймнән** ضمناً *р.* Ачыктан-ачык түгел, читләтеп, сүз сөреше буенча. — *н.* 1) Косвенно, не явно 2) По ходу разговора

**Зыймын** ضمن *ис.* 1) Бер әйбернең эчке ягы, эче. *Бәрәкәт хәрәкәт зыймынында хасил булыр.* (К. Нас.) 2) Бер әйбернең эченә салынган, эчендә булган әйбер, мәгънә. 3) Сөйләмдә читләтеп аңлатылган мәгънә. 4) Максат, теләк. — *сущ.* 1) Внутренняя часть чего-либо. 2) Содержимое, внутренность. 3) Косвенное объяснение. 4) Цель, намерение.

**Зыйхек** ضحك *ис.* Көлү. — *сущ.* Смех.

**Зыя** ضیا *ис.* Яктылык, нур. *Нигә булды зыя сөйгән азат баш, монафыйклар караңгысында хоффаш* (ярканат). (Г. Тук.) — *сущ.* Свет, сияние

**Зыяг** ضیاع *ис.* Югалу, әрәм булу, юкка чыгу. — *сущ.* Потеря, утрата, гибель.

**Зыядар** ضیادار *гф. с.* Яктыртылган, нурланган, яктыланган. — *ар.-п. прил.* Освещённый, озарённый.

**Зыяпаш** ضیاپاش *гф. с.* Нур чәчеп тора торган, нурлы. — *ар.-п. прил.* Лучезарный, лучистый.

**Зыяфәт** ضیافت *ис.* 1) Кунак итү, сыйлау, хөрмәтләү. 2) Кунакчыллык. — 1) Угощение; почтение 2) Гостеприимство, радушие.

**Зәбан** زبان *ф. ис.* 1) Тел. 2) Сүз, яхшы сөйләү сәләте. *Рузи кылса мән колына хак зәбан.* (Мин колына алла тел бирсә.) (Мөхм.) — *п. сущ.* 1) Язык. 2) Слово, красноречие.

**Зәбандан** زباندان *ф. ис.* 1) Сүз остасы. *Ходаның хөкме илә бер зәбандан.* (Ут. Им.) 2) Лингвист. — *п. сущ.* 1) Красноречивый (человек). 2) Лингвист.

**Зәбани гавам** زبان‌عوام *гф. из.* Халык теле. — *ар.-п. из.* Просторечие

**Зәбани мадәри** زبان مادری *ф. из.* Ана теле. — *п. из.* Родной язык.

**Зәбех** ذبح *м. I.* Хайван бугазлау, сую, чалу. — *м. I.* Закалывание (скота).

**Зәбихә** ذبحه *ис.* Бугазланган, корбанлык хайван, суелган корбан. *сущ.* Жертвенное животное, приносимое в жертву животное.

**Зәбун** زبون *ф. с.* 1) Куәтсез, зәгыйфь, начар. 2) Бик вак, әһәмиятсез. 3) Хурлыклы, чиркәнеч. *прил.* 1) Слабый, бессильный, плохой. 2) Мелочный, неважный. 3) Постыдный, отвратительный.

**Зәбур** زبور *ис.* Безнең тарих башланудан 1086 ел элек борынгы гыйбрани (еврей) телендә язылган дини, тезмә китап исеме. Псалмы Давида (написанные в 1086 г. до н. э. на древнееврейском языке).

**Зәваид** زوائد *ис.* Заид-нең *к.* *сущ. мн.* от заид.

**Зәвал** زوال *ис.* 1) Китү, бетү, юкка чыгу, югалу. 2) Кояшның төшлектән баюга таба авышуы. 3) Түбәнгә китү. *Һәр шәйнең кәмале соңында зәвале кагыйдәсенчә...* (З. Һад.) 4) Үлем. *Илчегә зәвал юк.* (К. Нас.) *сущ.* 1) Исчезновение, прекращение. 2) Склонение солнца к закату. 3) Гибель, смерть.

**Зәват** ذوات *ис.* Зат-ның *к.* *сущ. мн.* от зат.

**Зәваты кирам** ذوات كرام *ст.* Хөрмәтле затлар. *сс.* Почтенные особы.

**Зәвая** زوايا *ис.* Завия-нең *к.* *сущ. мн.* от завия.

**Зәгъфран*** زعفران *ис. бот.* Загфыран (үсемлек). *Мисале зәгъфран саргайды урман.* (Г. Тук.) *сущ. бот.* Шафран.

**Зәгыйфь*** ضعيف *с.* 1) Гарип, физик яктан житешсез (сукыр, аксак кебек). 2) Көчсез, хәлсез, дәрмансыз. *Гыйшкыма бирәр шаһит сорасагыз —вөҗүдем зәгыйфь, йөзем сарыланды.* (М. Гаф.) *прил.* 1) Имеющий физический недостаток, калека. 2) Слабый, бессильный, больной.

**Зәгыйфә** ضعيفه *ис.* 1) Хатын-кыз. 2) *кара:* зәгыйфь. *сущ.* 1) Женщина. 2) *жен.* от слова зәгыйфь.

**Зәгым** زعم *ис.* Гөман, фараз, уй. *сущ.* Предположение, мнение, допущение.

**Зәдә** زده *ф.* Башка бер сүзнең ахырына кушылып, „аңа дучар булган, очраган, туры килгән“ мәгънәләрне бирә; мәс.: *гамьзәдә* — кайгыга дучар, кайгылы. *Зәхемзәдә* — яраланган, яра алган. *п.* Суффикс, придающий слову значение „подверженный, подвергшийся“.

**Зәйгъ** زيغ *ис.* 1) Авышу, адашу, читкә тайпылу. 2) Югалу, бетү. *сущ.* 1) Отклонение; заблуждение. 2) Уход, исчезновение.

**Зәйл** زيل *ис.* 1) Өстәмә; кушымта, берәр әсәргә автор тарафыннан яки башка бер кеше тарафыннан өстәмә рәвешендә язылган кушымта. 2) Язуларда читенә яки астына язылган өстәмә аңлатма. 3) Итәк. 4) Постскриптум (P. S.) — *сущ.* 1) Дополнение, приложение. 2) Комментарий (к тексту). 3) Пола, подол. 4) Постскриптум (P. S.), приписка.

**Зәйит** زيت *ис.* Зәйтүн мае. — *сущ.* Оливковое масло.

**Зәйтүн*** زيتون *ис.* Зәйтүн мае чыгарыла торган җимеш, зәйтүн агачы. — *сущ. соб.* Масличные деревья, оливы.

**Зәйтүнә** زيتونه *ис.* 1) Зәйтүн агачы. 2) Куе яшел төс. 3) Исем — Зәйтүнә. — 1) Оливковое дерево. 2) Темнозеленый цвет 3) *и. с.* Зайтунә.

**Зәки I** زكى *с.* Саф, таза, ару, пакь. — *прил.* Чистый, невинный

**Зәки II** ذكى *с.* Үткен, зирәк, сизгер; зиһенле, тиз аңлаучы. — *прил.* Проницательный, умный, способный; смышлёный.

**Зәкъкум** زقوم *ис.* 1) *дини* Агулы җәһәннәм агачы. 2) Үтерә торган дәрәҗәдәге ачылык, ачы, зәһәр. *Эчтегезме сез зәкъкум?... нигә сез эндәшмисез?!.* (Һ. Так.) — *сущ.* 1) *рел.* Адское дерево (плодами которого якобы будут питаться грешники). 2) Горечь, ядовитость, яд.

**Зәкявәт** ذكاوت *ис.* Зирәклек, үткенлек, акыл үткенлеге, аңлау, төшенүдә тизлек. *Гакылының зәкявәте хәйран кылды.* (К. Нас.) — *сущ.* Смышлёность, проницательность.

**Зәкят** زكات *ис.* 1) Чисталык, сафлык, пакьлек, тазалык. 2) *дини* Зәкят (ислам дине буенча сәүдәгәрләргә еллык кеременең 40 тан бере күләмендә салынган еллык налог). — *сущ.* 1) Чистота. 2) *рел* Подоходный налог на торговцев в размере 1/40 дохода.

**Зәкяә I** ذكاء *ис. кара:* зәкявәт. — *сущ. см.* Зәкявәт.

**Зәкяә II** زكاء *ис.* Сафлык, чисталык, пакьлек. — *сущ.* Чистота, непорочность.

**Зәкәр** ذكر *ис.* 1) Ир, ир кеше. 2) Ата хайван. — *сущ.* 1) Мужчина. 2) Самец.

**Зәлзәлә** زلزله *м I.* 1) Тетрәү. 2) Җир тетрәү, җир селкенү. — *м. I.* 1) Трясение, дрожь. 2) Землетрясение.

**Зәлил** ذليل *с.*. Хурлыклы, түбән, кадерсез. *Наданлыкның зәлил нәрсә икәненә дәлил шул.* (К. Нас.) — *прил.* Низкий, презренный.

**Зәллә, зәлләт** زلت،زله *ис.* 1) Ялгышлык, хаталык, дөрес булмаучылык. *Галимнең зәлләсе тиз фаш булыр,* — *сущ.* 1) Ошибка, промах. 2) Спотыкание.

*наданның зәлләсен наданлыгы каплар.* (К. Нас.) 2) Таю, тайпылу, аяк таю.

**Зәлялэт** ذلالت ис. Түбәнлек, хурлык. — *сущ.* 1) Унижение. 2) Низость.

**Зәм** ذم *ис.* Әр, шелтә, үткәндәге кимчелекләрне әйтеп орышу, „битенә бәрү", гаепләп сөйләү. *Фәкыйрь бәһадир икән, аны җөбен вә йөрәксез дип зәм кылырлар.* (К. Нас.) — *сущ.* Порицание, упрёк; ругань, поношение; обвинение.

**Зәмаим** ذمائم *ис.* Зәмимә-нең *к.* — *сущ. мн.* от зәмимә.

**Зәмзәм** زمزم *ис.* 1) Мәккә шәһәрендә „изге" коеның исеме. *Биәре милләт, маи зәмзәм күзләдем еллар буе.* (Дәрд.) 2) *күч.* Хәмер, аракы. *Зәмзәм суын ялаштыра, шешә төбен караштыра.* (Г. Аф.) — *и. с.* 1) Земзем (колодец при храме Каа а в г. Мекке), 2) *перен.* Вино, водка.

**Зәмим** ذميم *с.* Начар, алама, ярамый торган, хурлыклы, әшәке. *Ахмак вә надан бозыклыкта булып, сүзе кибри вә фигыле зәмим булган кешеләр...* (К. Нас.) — *прил.* Позорный, достойный порицания, неприятный.

**Зәмимә** ذميمه *ис.* Начар, алама, әшәке эш, хурлыклы эш. *Саранлык әхлакы зәмимәдәндер, нәфсенең хыйрыслыгы сәбәпле гайре кешегә изгүлек ирешмәкен эстәмәмәктер* (теләмәү). (К. Нас.) — *сущ.* Позор, дурной поступок, неприятность.

**Зәмин** زمين *ф. ис.* 1) Җир, туфрак. *Бетте, мәху улды зәмин, һәм дә замана калмады.* (Г. Тук.) 2) Төп, җирлек, нигез. — *п. сущ.* 1) Земля, почва. 2) Основа, основание; фундамент.

**Зәмистан** زمستان *ф. ис.* Кыш, кыш көне. — *п. сущ.* Зима, зимний период.

**Зәммам** ذمام *ис.* Бик хурлаучы, мыскыл итүче. — *сущ.* Позорящий, оскорбляющий, издевающийся.

**Зәмһәрир** ذمهرير *ис.* Көчле суык, әче суык, каты салкын. *Яратырга ярый кышны, вәләкин зәмһәрире бар.* (Г. Тук.) — *сущ.* Сильный холод, леденящая стужа.

**Зән** زن *ф. ис.* Хатын, хатын-кыз. — *п. сущ.* Жена, женщина.

**Зәнадика** زنادقه *ис. к. дини* Аллага инанмаучылар, динсезләр. — *сущ. мн. рел.* Безбожники.

**Зәнан** زنان *ф. ис.* Зән-нең *к.* — *п. сущ. мн.* от зән.

**Зәнб** ذنب *ис.* 1) Гөнаһ, язык. 2) Гаеп. 3) Җинаять. — *сущ.* 1) Грех. 2) Вина. 3) Проступок, преступление.

**Зәнбил** زنبيل *ф. ис.* Камыштан үреп ясалган кәрзин. *Исхак сучи зәнбиленә азык куйды.* (К. Гал.) — *сущ.* Большая камышовая корзина.

**Зәнбур** زنبور *ф. ис.* Тешли (чага) торган чебен, бөҗәк; төклетура, шөпшә һ. б. — *п. сущ.* Оса, шершень, шмель и др. насекомые

**Зәнбәрәк** زنبرك *ф. ис.* 1) Пружина. 2) Рессора, сиртмә. 3) Туп. — *п. сущ.* 1) Пружина. 2) Рессора. 3) Пушка; самострел.

**Зәнгин** زنگين *ф. ис.* Бай, дәүләт иясе. — *п. сущ.* Богач, богатей.

**Зәнек** زنك *ф. ис.* Тутык. — *п. сущ.* Ржавчина.

**Зәнки** زنگى *ф. ис.* 1) Негр, кара тәнле. 2) Тупас, усал кеше. *Һи зәнки, бәдбәхет, кит!* (Г. Ил.) — *п. сущ.* 1) Негр, чернокожий, эфиоп. 2) Грубый, злой человек.

**Зәнҗи** زنجى *ис. кара:* зәнки. — *сущ. см.* Зәнки.

**Зәнҗир** زنجير *ф. ис. кара:* зинҗир. — *п. сущ. см.* Зинҗир.

**Зәнҗәбил** زنجبيل *ф. ис.* Имбир (Һиндстаннан килә торган үсемлек тамыры). — *п. сущ.* Имбирь.

**Зәр** زر *ф. ис.* Алтын. — *п. сущ.* Золото.

**Зәргъ** زرع *ис.* Ашлык чәчү, игү. — *сущ.* Возделывание, обработка, сеяние.

**Зәргәр** زرگر *ф. ис.* Алтынчы, алтынкөмештән әйберләр эшләүче. — *п. сущ.* Золотых дел мастер, ювелир.

**Зәрдә** زرده *ф. ис. бот.* Зәрдә. — *п. сущ. бот.* Пастернак (огородное растение, пряность).

**Зәрдәлү** زردالو *ф. ис.* Өрек. — *п. сущ.* Абрикос, урюк

**Зәрига I** زريعه *ис.* Үренте, шытым. — *сущ.* Росток, саженец.

**Зәрига II** ذريعه *ис.* 1) Сылтау, сәбәп. 2) Арадаш. *Мал дөньяда бәхетле булуга вәсилә, ахирәттә газаптан котылуга зәригадер.* (Г. Фәез.) — *сущ.* 1) Предлог, оправдание, средство. 2) Посредник.

**Зәркъ** زرق *ис.* 1) Хәйлә, рия, икейөзлелек. 2) Суфилар кия торган кием. — *сущ.* 1) Хитрость, мошенничество, двуличие. 2) Одежда суфиев.

**Зәркяр** زركار *ф. ис.* 1) Алтын яки көмеш җеп белән тукып эшләнгән тукыма. 2) Алтын эше. — *п. сущ.* 1) Расписанный, разукрашенный золотом; шитый золотом. 2) Работа по золоту.

**Зәррә** ذره *ис.* 1) Бөртек, материянең иң кечкенә, иң вак бөртеге. 2) Атом. — *сущ.* 1) Частичка. 2) Пылинка. 3) Атом.

*Әгәрчә зәррә микъдар һиммәте бар; аның артыннан тау-тау миннәте бар.* (Г. Тук.)

**Зәрхуш** زرخوش *ф. ис.* Күңелле карт. *Шатлык булсын сәңа, и зәрхуш.* (Мөхм.) — *п. сущ.* Веселый старик.

**Зәрәһ** زره *ф. ис. кара:* зирәһ. — *п. сущ. см.* Зирәһ.

**Зәхаир** ذخائر *ис.* Зәхирә-нең *к.* — *сущ. мн.* от зәхирә.

**Зәхем** زخم *ф. ис.* 1) Ору, сугу. 2) Ору, сугудан булган яра. *Синең зәхмеңә кемнәр сызлана соң.* (Г. Тук.) 3) Өзәңге каешы. — *п. сущ.* 1) Удар, битьё. 2) Рана (от удара). 3) Ремень, на котором подвешивается стремя.

**Зәхемдар, зәхемзәдә, зәхемнак** زخمدار، زخمزده، زخمناك *ф. с.* Яралы, яраланган. — *п. прил.* Раненый, имеющий рану.

**Зәхирә** ذخيره *ис.* Азык, ашлык, орлык запасы. *Кыйхытлык вакыйг улып, малымны җыеп, Мисырга зәхирә алмага җибәрдем, ул кешем кайтмады.* (К. Нас.) — *сущ.* Запас, припасы, провиант.

**Зәхмәт** زحمت *ис.* 1) Эш, хезмәт. *Йөкләдем мин бик авыр зәхмәт сиңа.* (Г. Тук.) 2) Азап, борчу, мәшәкать. *Зәхмәт чикмәгез, минем бауларым, тәртәләрем озындыр, җитешермен, — диде.* (К. Нас.) 3) Кысынкылык, тыгызлык. *Хөрриятсез яшәмәк зәхмәт идекен белермен.* (М. Ак.) 4) Сырхау, чир. — *сущ.* 1) Труд, работа. 2) Тягость, беспокойство, гнёт. 3) Зависимое положение. 4) Болезнь, недомогание.

**Зәхмәткәш** زحمتکش *гф. ис.* Хезмәт иясе. — *ар.-п. сущ.* Трудящийся.

**Зәүкъ** ذوق *ис.* 1) Зәвык, тәм, татым. 2) Тәм тату тойгысы. 3) Ләззәтләнү, берәр нәрсәдән, яки эштән ямь табу, күңел табу, тәм табу. *Күзләре аңсыздан бу җәмиләя бакып зәүкъландылар.* (М. Ак.) 4) Яхшыны начардан аеру көче, аеру үзлеге. *Ни кәбаирдер мисакта рухым иткән иртикяб, кем гадәм зәүкыннан әүвәл хөкем ителгән янасы.* (Нинди зур гөнаһ, яратылу вакытында ук рухым әшәкелек иткән, һәм яхшыны начардан аеру көчем югында ук утка янасым белән хөкем ителгән.) (Дәрд.) — *сущ.* 1) Вкус. 2) Склонность. 3) Вкушение, наслаждение, удовольствие. 4) Способность отличить хорошее от плохого.

**Зәүкат** ذوقات *ис.* Зәүкъ-ның *к.* — *сущ. мн.* от зәүкъ.

**Зәүкый** ذوقى *с.* Эстетик (матурлык, гүзәллеккә бәйле). — *прил.* Эстетический.

**Зәүкы сәлим** ذوقسليم *из.* Дөрес тойгы ләззәте. — *из.* Удовольствие от полноты ощущения (чего-либо).

**Зәүкы хәят** ذوقحيات *из.* Тормыш ләззәте, яшәү тәме, тормыштан, яшәүдән ләззәтләнү. — *из.* Вкус жизни; наслаждение жизнью.

**Зәүкы ٶлхан** ذوق الحان *из.* Көйләр ләззәте, моңнар ләззәте. *Җил-җиләслӛрнең моңыннан зәүкы әлхан алмадым.* (Дәрд.) — *из.* Сладость музыки.

**Зәүкыяб** ذوقياب *гф. с.* Тәм табучы, ләззәт ала белүче. — *ар.-п. прил.* Имеющий хороший вкус, умеющий наслаждаться (чем-либо).

**Зәүкыят** ذوقيات *ис.* Зәүкъ-ның *к.* — *сущ. мн.* от зәүкъ.

**Зәүрак** زوراق *ис.* Каек, көймә. — *сущ.* Лодка, баркас.

**Зәүҗ** زوج *ис.* 1) (Хатынның) ире. *Хакыйкать сәнең зәүҗең кыйтмыйр дорыр.* (К. Гал.) 2) Җөп, пар (такның киресе), парлы, пары булган ир. — *сущ.* 1) Муж, супруг 2) Пара, чета.

**Зәүҗиять** زوجيت *ис.* Ирле-хатынлылык. — *сущ.* Супружество.

**Зәүҗә** زوجه *ис.* Кәләш (ирнең хатыны). — *сущ.* Жена, супруга.

**Зәүҗәен** زوجين *ис.* Ир белән хатын, ирле-хатынлы. — *сущ.* Супруги, муж и жена.

**Зәҗр** زجر *м.I.* 1) Тыю, юл куймау. 2) Көчләү, мәҗбүр итү. 3) Азаплау, җәбер-җәфа. 4) Хәзергедән чыгып киләчәктән хәбәр бирү. — *м. I.* 1) Запрещение, запрет. 2) Принуждение. 3) Угнетение, притеснение; мучение, беспокойство. 4) Предвидение.

**Зәҗрән** زجراً *р.* Тыеп, комачаулап, ирексезләп, тоткарлык ясап, юл куймыйча, көчләп. — *н.* 1) Запрещая; мешая 2) Насильно.

**Зәһаб** زهاب *ис.* Китү, бару. — *сущ.* Уход, отправление.

**Зәһадәт** زهادت *ис.* Тәкъвалык, дөньядан бизеп гыйбадәт белән генә шөгыльләнүчелек. — *сущ.* Умеренность, воздержание, монашество.

**Зәһи** زهى *с.* Бик шәп, яхшы. *Варислар өчен мал сакламак зәһи хыял батыйльдер.* (К. Нас.) — *прил.* Прекрасный, хороший.

**Зәһр** زهر *ф. ис. кара:* зәһәр. *Ит наданлыкларны тәгъриф, зәһрене яз, гадрене.* (Г. Тук.) — *п. сущ. см.* Зәһәр.

**Зәһраэ** زهرا *с.* Ачык йөзле, якты йөзле (хатын). — *прил.* Приветливая, весёлая.

**Зәһрә** زهره *ф. ис.* 1) Үт, үт капчыгы. 2) *күч.* Батырлык, егетлек, гайрәтлелек. — *п. сущ.* 1) Желчь, желчный пузырь. 2) *перен.* Храбрость, отвага, мужество.

**Зәһәб** ذهب *ис.* Алтын. *Бу мәзһәб бер зәһәб мәзһәб ...* (Г. Тук.) — *сущ.* Золото.

**Зәһәби** ذهبی *с.* Алтыннан ясалган, алтын төсле. — *прил.* Золотой, золотистый.

**Зәһәр*** زهر *ф. ис.* 1) Агу, әче. *Сәүмәдекем адәмә яр улмак бәңа зәһәрдер.* (М. Ак.) 2) Үткен, булдыклы. — *п. сущ.* 1) Яд, отрава. 2) Прыткий, проворный.

**Зөбаб** زباب *ис.* Зөбабә-нең *к.* — *сущ. мн.* от зөбабә.

**Зөбабә** زبابه *ис.* Чебен. — *сущ.* Муха.

**Зөбан** زبان *ф. ис. кара*: зәбан. — *п. сущ. см.* Зәбан.

**Зөбдә** زبده *ис.* 1) Бер нәрсәнең сайланган иң яхшы өлеше, сыгып алынганы, каймагы. 2) Нәтиҗә. — *сущ.* 1) Суть, сущность, квинтэссенция. 2) Результат, итог.

**Зәбәрҗәд*** زبرجد *ис.* Зөбәрҗәт (яшел төстә кыйммәтле таш исеме). *Яратам тәмле, татлы сүзеңезне, зөбәрҗәд төсле якты күзегезне.* (Г. Тук.) — *сущ. мин.* Оливин; хризолит; изумруд.

**Зәкак** زقاق *ис.* Урам. — *сущ.* Улица, улочка.

**Зәкям** ذکام *ис.* Томау, борынга томау төшеп авыру. — *сущ.* Простуда, насморк.

**Зөкүр** ذکور *ис. к.* Ирләр. — *сущ. мн.* Мужчины.

**Зөлеф** زلف *ф. ис.* 1) Сөйгәннең чәче, толымы. 2) Йөзнең ике ягына аерылып төшкән чәч. *Гаҗәб торфә кара рәңле зөлефләрең вар.* (К. Гал.) — *п. сущ.* 1) Локоны любимой. 2) Кудри, завитки волос.

**Зөлкагдә** ذوالقعده *ст. кара*: зилкагдә. — *сс. см.* Зилкагдә.

**Зөлкарнәен** ذوالقرنين *ст.* 1) Ике мөгез иясе, ике мөгезле. 2) Александр Македонскийның кушаматы. *Дәҗҗал музыкасын тыңлаган кешенең маңгаена Зөлкәрнәеннең мөгезе шикелле мөгез чыгар, диган...* (Г. Газиз). — *сс.* 1) Двурогий. 2) Прозвище Александра Македонского.

**Зөлмәгашәйн** ذوالمعاشين *ст.* Җирдә дә, суда да яши торган (хайван). — *сс. букв.* Земноводное (животное).

**Зөлфөкар** ذوالفقار *ст.* „Арка умырткасын кисүче" мәгънәсендә булып, хәлифә Галинең легендар кылычына би- — *сс. букв.* „Рассекающий позвонки"; название легендарного меча халифа

релгән исем. *Чыгар кыннан каләм тел зөлфөкарын.* (Дәрд.) (Али.)

**Зөлхиҗҗә** ذوالحجه *ст. кара:* зилхиҗҗә. (*сс. см.* Зилхиҗҗә.)

**Зөлял** زلال *ф. ис.* Салкын һәм тонык су. *Һәм эчәр ул чишмәдән абе зөлял.* (Ут. Им.) (*п. сущ.* Холодная, прозрачная вода.)

**Зөлҗәлал** ذوالجلال *ст.* 1) Олылык иясе, бөек. 2) *дини* Алланың исеме. *Зөлҗәлалыңнан сора төнлә торып тәкъва кияү.* (Ш. Баб.) (*сс.* 1) Важный, сановитый. 2) *рел.* Обладатель величия (эпитет аллаха).)

**Зөлҗәнах** ذوالجناح *ст.* Канат иясе, оча ала торган, канатлы. (*сс.* Крылатый, имеющий крылья.)

**Зөлҗәнахәен** ذوالجناحين *ст.* Ике канат иясе; ике канатлы. *Ул шәкерт вакытында русча да укыган, үзен зөлҗәнахәен итеп фараз кыла* (Г. Газиз). (*сс.* Обладатель двух крыльев, двукрылый.)

**Зөмред** زمرد *ф. ис. кара:* зөбәрҗәд. (*п. сущ. см.* Зөбәрҗәд.)

**Зөмрә** زمره *ис.* 1) Җәмәгать, төркем, группа. *Имде ушбу халык зөмрәсеннән ишеткән сән бер хәбәр.* (К. Нас.) 2) *полит.* Класс, бүлек. *Шәриф шул көннән башлап хәерчеләр зөмрәсенә керде.* (М. Гаф.) 3) *биол.* Семьялык, җенес. (*сущ.* 1) Компания, группа; клика. 2) *полит.* Класс. 3) *биол.* Семейство, род.)

**Зөннар** زنار *ис.* Билбау, күлмәк өстеннән бәйли торган чуклы билбау. (*сущ.* Пояс; кушак.)

**Зөнуб** ذنوب *ис.* Зәнб-нең *к.* (*сущ. мн.* от зәнб.)

**Зөннәвал** ذوالنوال *ис.* 1) Бүләк иясе, бүләк итеп бирүче. 2) Бик рәхимле, кеше хәленә керүче. (*сущ.* 1) Дарящий, преподносящий дары. 2) Добросердечный; милосердный; сочувствующий.)

**Зөррият** ذريت *ис.* Буын, ыру, нәсел, нәсел-нәсәп, бер буыннан килгәннәр. (*сущ.* Дети, потомство, династия.)

**Зөхәл** زحل *ис. астр.* Сатурн (планета). *Тиңсез улды йөзләрендә хәтта Зөхәл.* (Мөхм.) (*сущ. астр.* Сатурн.)

**Зөюф** زيوف *ис.* 1) Ялган акча. 2) Алдалау. (*сущ.* 1) Фальшивые деньги. 2) Обман.)

**Зөҗаҗ** زجاج *ис.* Пыяла. (*сущ.* Стекло.)

**Зөҗаҗә** زجاجه *ис.* 1) Пыяла савыт. 2) Шешә. (*сущ.* 1) Стеклянная посуда. 2) Бутылка.)

**Зөһад** زهاد *ис.* Заһид-нең *к.* (*сущ. мн.* от заһид.)

**Зөһд** زهد *ис.* Тәкъвалык, суфилык. *Бу халыкча: зөһд, тәкъва, тугрылык та, дин дә шул.* (Г. Тук.) — *сущ.* 1) Воздержанность 2) Благочестие, набожность.

**Зөһрә** زهره *ис.* 1) *астр.* Зөһрә йолдызы, чулпан. 2) Чәчәк. 3) Кеше исеме. *Ләйләсеме әллә бу Мәҗнүннең, Зөһрәсеме әллә Таһирның.* (М. Җәл.) — *сущ.* 1) *астр.* Венера 2) Цветок. 3) Имя собственное.

**Зөһул** ذهول *м. I.* 1) Оныту. 2) Юри оныкканга салышу. 3) Уйга бату, фикергә чуму аркасында онытылу. *Дөньядан зөһул иткәнсыманрак фикергә талган кешеләр.* (Ф. Әмир.) — *м. I.* 1) Забытье. 2) Притворство в забывчивости. 3) Растерянность, рассеянность.

**Зүд** زود *ф. с.* Йөгерек, чапкын, тиз йөрешле, елдам. — *п. прил.* Быстрый, скорый.

# И

**И** — татар әлифбасында тугызынчы, гарәп әлифбасында беренче хәреф булган „ا“ не (сүз башында) һәм егерме сигезенче хәреф булган „ی“ не (сүз уртасында һәм сүз азагында) белдерә; әбҗәд тәртибендә унга йөри. — 9-я буква татарского алфавита. Обозначает первую букву арабского алфавита алиф (ا) (в начале слова) и 28-ю букву йа (ی) в середине и в конце слова; цифровое значение 10.

**Иба** ابا *ис.* 1) Риза булмау, кабул итмәү, баш тарту. 2) Каршылык күрсәтү, буйсынмау. 3) Җирәнү, җирәнеп саклану. — *сущ.* 1) Несогласие, непринятие; отказ. 2) Сопротивление; неподчинение. 3) Отвращение.

**Ибахә** اباحه *м. IV. дини* Рөхсәт итү; ирегенә тапшыру, ирегенә кую. — *м. IV. рел.* Разрешение, позволение; полная свобода (действий).

**Ибгад** ابعاد *м. IV.* 1) Ераклаштыру. 2) Озакка сузу, соңлаштыру. — *м. IV.* 1) Удаление, устранение. 2) Задержка, продление.

**Ибдаг** ابداع *м. IV.* 1) Уйлап чыгару, барлыкка китерү, иҗат итү. 2) Иҗат. 3) Кинәттән, язылмаган шигырь сөйләү. — *м. IV.* 1) Создание, изобретение, творение 2) Творчество. 3) Прочтение стихотворения экспромтом.

**Ибдал** ابدال *м. IV.* Алмаштыру, алмашу; башкарту, үзгәртү. — *м. IV.* 1) Замена, перемена. 2) Обмен.

**Ибдаэ** ابداء *м. IV.* Юктан бар итү, иҗат итү. — *м. IV.* Создание, сотворение.

**Ибка** ابقا *м. IV.* 1) Калдыру, искечә (элеккечә) калдыру, саклау. 2) Исемен (данын) калдыру, мәңгеләштерү. — *м. IV.* 1) Оставление, сохранение. 2) Сохранение имени, увековечение.

**Иблис*** ابليس *ис. дини* 1) Шәйтан. 2) Начар кеше. — *сущ. рел.* 1) Дьявол, чёрт. 2) Дурной человек.

**Ибляг** ابلاغ *м. IV.* Җиткезү, хәбәр итү, ирештерү. — *м. IV.* Доведение до сведения, уведомление.

**Ибн** ابن *ис.* Ул, ир бала. — *сущ.* Сын.

**Ибне ави** ابن آوی *ст.* Шакал, чүл бүресе. *Арслан янында ибне ави хезмәтендә йөреп, калган ашларын ашый иде.* (Г. Фәез.) — *сс.* Шакал.

**Ибнелвакыт** ابن الوقت *ст.* Замана баласы, үзе яшәгән заманга гына буйсынып эш итүче. *Галиҗәнаб вә философ адәмнең ибнелвакыт булуы һич монасиб эш түгел иде.* (Р. Фәх.) — *сс.* Раб своей эпохи, человек, взгляды которого ограничены временем, в котором он живёт.

**Ибне сәбил** ابن سبيل *ст.* Юлчы, мөсафир. — *сс. букв.* „Сын пути", путник.

**Ибнә** ابنه *ис.* Берәүнең кызы. — *сущ.* 1) Дочь. 2) Девушка.

**Ибраз** ابراز *м. IV.* Күрсәтү, мәйданга кую, тышка чыгару. *Бонлара мәхәббәтен ибраз әйләде.* (М. Ак.) — *м. IV.* Показывание; выставление, выявление.

**Ибрам** ابرام *м. IV.* Үз дигәнендә нык торып йөдәтеп сорау, сорап интектерү, йөдәтү. *Адәм хаҗәт вә ярдәм эстәгәндә, ибрам кылмаенча, хәле үзрә куелмак кирәк.* (К. Нас.) — *м. IV.* Настояние, упорствование, надоедливость, настойчивость.

**Ибраэ** ابراء *м. IV.* Бурычтан котылдыру, бурычны кичерү, йөкләмәдән котлару. — *м. IV.* Освобождение от уплаты долга, от обязательств.

**Ибриз** ابريز *ис.* Саф алтын. — *сущ.* Чистое золото.

**Ибрикъ** ابريق *ис.* Комган, чәйнек, борынлы савыт. — *сущ.* Чайник; кувшин с носиком.

**Ибрә** ابره *ис.* Инә. — *сущ.* Иголка.

**Ибталь** ابطال *м. IV.* Юк итү, юкка чыгару; бозыклыгын күрсәтү. *Әфьюнның агуын ибталь кылырга кирәк.* (К. Нас.) — *м. IV.* Отмена, уничтожение, аннулирование.

**Ибтида** ابتداء *м. VIII.* 1) Башлау, башлап җибәрү. 2) Баш, әүвәл, элек. — *м. VIII.* 1) Начинание. 2) Вступление, начало.

**Ибтидаи** ابتدائی *с.* Башлангыч, башлап җибәрү (гә бәйле). *Әмма һичберсе* — *прил.* 1) Начальный. 2) Вступительный, пред-

*укуны ибтидаи мәктәптән уткәреп югарырак китүне уйламый иде.* (Г. Ибр.) — варительный. 3) Элементарный.

**Ибтидар** ابتدار *м. VIII.* 1) Ашыгу; ашыкгыру. 2) Омтылу, эшкә омтылып керешү. — *м. VIII.* 1) Спешка; поспешность. 2) Стремление.

**Ибтидаән** ابتداً *р.* Башлап, башлап җибәрү өчен. — *н.* Сначала, для начала.

**Ибтизал** ابتذال *м. VIII.* 1) Искергәнлек. 2) Күп чәйнәлгәнлек, вульгарлык. 3) Түбәнсетү, кимсетү. — *м. VIII.* 1) Заношенность. 2) Избитость, банальность; вульгарность. 3) Унижение.

**Ибтиля** ابتلاء *м. VIII.* 1) Бәлагә очрау, бәлагә дучар булу. *Икъбале вакытында дус вә карендәш итеп, идбар вә ибтиля вакытында хәкарәт кыйлган.* (К. Нас.) 2) Авыру, авырып китү. 3) Газап чигү. — *м. VIII.* 1) Бедствие, бедственное положение. 2) Заболевание. 3) Страдание.

**Ибтина** ابتناء *м. VIII.* 1) Бер нәрсәнең өстенә кору, нигезләү. *Ниләем* (нишлим) *аслым, әсасем дәртә* (дәрткә) *итмеш ибтина.* (Г. Тук.) 2) Берәр нәрсәгә таянып эш итү. 3) Дәгъваны нигезләү. — *м. VIII.* 1) Надстройка; построение. 2) Основа, опора. 3) Обоснование заявления, претензии.

**Ибтинаән** ابتناً *р.* Таянып, нигезләп. — *н.* Основываясь, опираясь на что-либо.

**Ибтисам** ابتسام *м. VIII.* Елмаю, көлемсерәү, ачык йөз күрсәтү. — *м. VIII.* Улыбка, приветливость.

**Ибтисар** ابتصار *м. VIII.* Күңел күзе белән күрү, эшнең төбен ерактан күрү. — *м. VIII.* Внутреннее чувство, видение.

**Ибтихас** ابتحاث *м. VIII.* Берәр нәрсәдән бәхәс итү, эзләнү, тикшерү. — *м. VIII.* Обсуждение; исследование, изучение.

**Ибтиһал** ابتهال *м. VIII.* Ялвару, ялыну, сорау. — *м. VIII.* Ходатайство, просьба, мольба.

**Ибтиһаҗ** ابتهاج *м. VIII.* Шатлану, сөенү, куану. — *м. VIII.* Радость, ликование, восторг.

**Ибшар** ابشار *м. IV.* 1) Сөенеч, куаныч. 2) Шатландыру, сөендерү. — *м. IV.* 1) Радость. 2) Радостная весть.

**Ибыт** ابط *ис.* Култык асты. — *сущ.* Подмышка.

**Ибһам I** ابهام *ис.* Баш бармак. — *сущ.* Большой палец.

**Ибһам II** ابهام *м. IV.* 1) Билгесезлек, ачык түгеллек, буталчыклык. 2) Сүздә яшерен мәгънә. — *м. IV.* 1) Неопределённость, неясность, запутанность. 2) Двусмысленность (в значении слов).

**Ибһаж** ابهاج *м. IV.* 1) Шатландыру, куандыру. 2) Шатлыклы хәбәр, сөенеч. — *м. IV.* 1) Приведение в восторг. 2) Радостная весть.

**Игадә** اعاده *м. IV.* 1) Кире кайтару, кире бирү, кайтару. 2) Кабатлау, кабат эшләү. 3) Элекке хәленә китерү. — *м. IV.* 1) Возвращение. 2) Повторение. 3) Пере- (перевыборы, пересмотр и т. д.).

**Иганат** اعانات *ис.* Иганә-нең *к.* — *сущ. мн.* от иганә.

**Иганә*, иганәт** اعانه،اعانت *м. IV.* 1) Ярдәм, булышлык. 2) Берәр яхшы эш өчен халыктан җыелган акча, иганә акчасы. *Иганәт эстәдек без чөн буңа дик гайре мәуладан.* (Г. Тук.) — *м. IV.* 1) Помощь, поддержка, содействие. 2) Пожертвование.

**Иганәтән** اعانةً *р.* Булышлык итеп, ярдәм йөзеннән. — *н.* В виде помощи, в качестве поддержки.

**Игашә** اعاشه *м. IV.* Кичендерү, яшәтү, ашату. — *м. IV.* Пропитание, поддержание жизни.

**Игъбирар** اغبرار *м. IX.* 1) Тузанлану, өстенә тузан куну. 2) Хәтер калу, үпкәләү. — *м. IX.* 1) Запыление, покрытие пылью. 2) Огорчение, обида.

**Игъва** اغواْ *м. IV.* Аздыру, юлдан яздыру, начарлыкка өндәү; котырту. *Бәлки бакмаслар иде шайтаннары игъвасына.* (Г. Тук.) — *м. IV.* 1) Обольщение, искушение. 2) Наущение; подстрекательство

**Игъван** اعوان *ис. кара:* әгъван. *Анлары мөршид санан игъваннары ахмак имеш.* (Г. Тук.) — *сущ. см.* Әгъван.

**Игъдад** اعداد *м. IV.* 1) Хәзерләү. 2) Берәүне укытып өйрәтеп бер эшкә хәзерләү. — *м. IV.* 1) Подготовка. 2) Обучение какому-нибудь делу.

**Игъдади** اعدادى *с.* Хәзерләү(гә караган). — *прил.* Подготовительный.

**Игъдадия** اعداديه *ис.* Мәдрәсәдә югары белем алуга хәзерләү класслары. — *сущ.* Подготовительные классы в медресе (для поступления в высшую школу).

**Игъдам** اعدام *м. IV.* 1) Юк итү, юкка чыгару. *Милләти иһдам идән, игъдам идән шунлар имеш.* (Г. Тук.) 2) Закон нигезендә үтерү. — *м. IV.* 1) Уничтожение. 2) Казнь.

**Игъзаз** اعزاز *м. IV.* Хөрмәтләү, кадерләү, олылау. — *м. IV.* 1) Оказание внимания, почтения. 2) Почтительность.

**Игъзазе гыйззәт** اعزازعزت *ст.* Кадер, хөрмәт, олылау. *Татый бер-берени игъзазе гыйззәт* (Сайяди).

*сс.* Почесть, уважение, почтение.

**Игъзазән** اعزازاً *р.* Хөрмәтләп, олылап, кадерләп.

*н.* Почтительно, с почтением.

**Игъзам** اعظام *м. IV.* 1) Зурайту, кирәгеннән артык әһәмият биреп күтәрү. 2) Кечкенә әйбер яки эшне зурайтып, күпертеп карау.

*м. IV.* 1) Почитание; возвеличивание. 2) Преувеличение.

**Игъля I** اغلاء *м. IV.* 1) Күтәрү, югары итү. 2) Шөһрәтле итү, атказандыру.

*м. IV.* 1) Подъём, возвышение. 2) Прославление.

**Игъля II** اغلاء *м. IV.* 1) Әйбернең бәясен күтәрү. 2) Бәя кую.

*м. IV.* 1) Повышение, поднятие цен. 2) Оценка.

**Игълякъ** اغلاق *м. IV.* 1) Бикләү, йозаклау; киртәләү. 2) Сүзне аңлаешсыз итеп, бутап сөйләү.

*м. IV.* 1) Закрытие, запирание на замок. 2) Путанное объяснение.

**Игълям** اعلام *м. IV.* 1) Белдерү, аңлату. *Килсә кайгы гәр аңар, игълям кыладыр күз, йөзе.* (Г. Хар.) 2) Аңлатма; белдермә, хәбәр.

*м. IV.* 1) Уведомление, извещение. 2) Объяснение; сообщение; 3) Известие.

**Игълян*** اعلان *м. IV.* 1) Белдерү. 2) Мәйданга чыгару, ачык итү, халыкка белдерү.

*м. IV.* 1) Объявление, извещение. 2) Обнародование, публикация.

**Игъляне ифляс** اعلانافلاس *из.* Бөлгенлеккә төшүне фаш итү, банкрот булганлыгын белдерү. *Байларның игъляне ифляс итуләренә сәбәп булдың.* (М. Гаф.)

*из.* Объявление банкротства, разорения.

**Игъма** اغماء *м. IV.* Һушсыз булу, хәлдән таю.

*м. IV.* Обморок, обморочное состояние.

**Игъмаз** اغماض *м. IV.* 1) Күз йому, күрми китү, карамый узу. 2) Күрмәмешкә салышу.

*м. IV.* 1) Попустительство, поблажка, потворство. 2) Притворство.

**Игъмаль** اعمال *м. IV.* 1) Эшләү, ясау. 2) Барлыкка китерү.

*м. IV.* 1) Применение, делание. 2) Создание.

**Игъмар** اعمار *м. IV.* 1) Эшкәртү, төзек итү. 2) Утраклау, мәдәниләштерү.

*м. IV.* 1) Возделывание. 2) Заселение.

**Игъра** اغراء *м. IV.* 1) Берәүне берәр кешенең зарарына эш итәргә кызыктыру, котырту. 2) Комсызландыру, хирысландыру.

*м. IV.* 1) Побуждение, подстрекательство, соблазн. 2) Побуждение к жадности, скаредности.

**Игъраб** اعراب *м. IV. грам.* 1) Сүзләрнең төрләнүе. 2) Сүзләрне тәнвиннәре белән язу, уку.

*м. IV. грам.* 1) Изменение по флексиям (имени) или изменение по окончаниям (глагола); флексия. 2) Чтение, написание с полными окончаниями.

**Игърак** اغراق *м. IV.* 1) Суга батыру; су басу. 2) Акылга сыю ягыннан мөмкин булып та, гадәттә булуы мөмкин булмаганча арттырып мактау яки яманлау. *Г. Ибраһимовның: „Ул өшәнчеге, бирнәсе дисәң, адәм әйтеп, адәм бетермәс, әйтәм бит, өеңә сыймас... авылыңа сыймас...“, дигән җөмләсендә игърак бар.*

*м. IV.* 1) Затопление, наводнение. 2) Преувеличение, превышение меры (в хвале или хуле).

**Игъта** اعطا *м. IV.* Бирү, өләшү, алга китереп бирү. *Зыя бине Җәләлетдин Сабитовка имам хатыйб вә мөдәррислек рөтбәсе игъта кылынды.* (Г. Ибр.)

*м. IV.* Предоставление, отдача, раздача.

**Игътибар** * اعتبار *м. VIII.* 1) Әһәмият бирү, күңел бирү. 2) Хөрмәтләү, санга санау. 3) Сүзе үтемлелек, танылганлык, авторитет. 4) Илтифат.

*м. VIII.* 1) Принятие во внимание. 2) Уважение, авторитет, почёт. 3) Значение, престиж. 4) Внимание.

**Игътибарән** اعتباراً *р.* 1) Әһәмият биреп, санга санап, илтифат итеп, истә тотып, игътибарга алып, искә алып. *Минем ятим калган мулла баласы икәнемә игътибарән...* (Г. Тук.) 2) Башлап. *Бу көннән игътибарән* — бу көннән башлап.

*н.* 1) Принимая во внимание. 2) Начиная с...

**Игътидад** اعتداد *м. VIII.* Исәпкә алу.

*м. VIII.* Принятие в расчёт.

**Игътидал** اعتدال *м. VIII.* 1) Ике хәлнең, ике якның уртасында булу. 2) Урта сызыкта булу, уртача фикердә булу. *Мин үзем игътидал тарафында.* (Ф. Әмир.)

*м. VIII.* 1) Умеренность; равновесие. 2) Соразмерность, симметрия.

**Игътидаэ** اعتدا *м. VIII.* 1) Дошманлык күрсәтү. 2) Рәнҗетү, золым итү. 3) Көчләү.

*м. VIII.* 1) Враждебность, враждебное действие. 2) Обида, притеснение, гнёт. 3) Насилие.

**Игътиза** اغتذا *м. VIII.* Туену, ризыклану.

*м. VIII.* Насыщение.

**Игътизал** اعتزال *м. VIII.* 1) Аерылу, читкә китү, халык арасыннан читкә ка-

*м. VIII.* 1) Отшельничество, жизнь в уедине-

гылу. 2) Хезмәт урыныннан чыгу. *Игътизал иттеки соң Мәгарринең кадере артмыштыр.* (Р. Фәх.) — нии. 2) Уход с работы, оставление должности.

**Игътизар** اعتذار *м. VIII.* 1) Бер эшне эшләү яки эшләмәвенең сәбәбен күрсәтеп үзен аклау. 2) Гозерне кабул итүен үтенү. 3) Гафу үтенү. *Имде бу вакыйгане кешегә сөйләмә, ... дип игътизар кылды.* (К. Нас.) — *м. VIII.* 1) Объяснение причин невыполнения обязательств. 2) Мольба о прощении. 3) Извинение.

**Игътикад** اعتقاد *м. VIII.* Ышану, чын күңелдән ышану, инану; күңел беркетү, күңел бәйләү. *Шул юлны туры юл дип игътикад итәр.* (З. Һад.) — *м. VIII.* Верование, вера, убеждение, доверие.

**Игътикяф** اعتكاف *м. VIII. дини* 1) Берәр изге саналган урыннан (мәчеттән) чыкмый берникадәр вакыт гыйбадәт кылып яту. *Булчы син миңа мөрит, мине аркаңда йөрет, ачыйк гамәл кибетен, игътикяфларга керик.* (Г. Тук.) 2) Бер урында ябылып яки тукталып тору. — *м. VIII. рел.* 1) Продолжительное моление не выходя из храма. 2) Упорное занятие (чем-либо).

**Игътиля** اعتلاء *м. VIII.* 1) Югары ашу, күтәрелү, биекләнү, югары менү. *Игътиля итсәң, канатың ач, вакыт җитте бугай.* (Г. Тук.) 2) Дәрәҗәсе күтәрелү. — *м. VIII.* 1) Восхождение, подъём, возвышение. 2) Возвеличение.

**Игътимад** اعتماد *м. VIII.* 1) Таяну, аркалану, ышану. *Нык үзенә игътимады һәм сүзенә игътикад.* (Г. Тук.) 2) Ышаныч, таяныч. — *м. VIII.* 1) Вера, доверие. 2) Опора.

**Игътимадән** اعتماداً *р.* 1) Ышанып. 2) Таянып, аркаланып. — *н.* 1) Доверяя. 2) Опираясь (на что-либо).

**Игътинаэ** اعتناء *м. VIII.* 1) Әһәмият бирү, булдырырга тырышу, бик нык дикъкать итү, игътибар итү. 2) Игътибар. — *м. VIII.* Внимание, забота.

**Игътинам** اغتنام *м. VIII.* 1) Сугышып трофей алу. 2) Кан, җан биреп алган мал кебек кадерле күрү. — *м. VIII.* 1) Захват трофеев. 2) Считать (считание) драгоценным, дорогостоящим (добытым ценою крови).

**Игътинам форсат** اغتنام فرصت *ст.* Вакытның кадерен белү. — *сс.* Знать цену времени.

**Игътираб** اغتراب *м. VIII.* 1) Чит җиргә китү, туган-үскән иленнән аерылу. 2) Башка милләттән хатын алу. — *м. VIII.* 1) Отъезд на чужбину, удаление от родины. 2) Бракосочетание с женщиной другой нации.

**Игътираз** اعتراض *м. VIII.* 1) Бер фикер яки карарга каршы төшү, каршы сөйләү, кире кагу. 2) Фикернең дөреслегенә сәбәпләр, дәлилләр сорау, каршы дәлил, сәбәп кую; аркылы төшү. *Әхмәт кызык өчен атасына игътираз итте.* (Ф. Әмир.) 3) Хур итү, намуска тукыну. — *м. VIII.* 1) Противодействие, возражение, протест. 2) Требование веских доказательств. 3) Посрамление, скомпрометирование.

**Игътирар** اغترار *м. VIII.* 1) Алдану, зыянсыз дип уйлап зыянга төшү. 2) Масаю, горурлану. 3) Сизмичә, белмичә калу. — *м. VIII.* 1) Обман, заблуждение. 2) Самодовольство, зазнайство. 3) Неведение, неосведомлённость.

**Игътираф** اعتراف *м. VIII.* Үзенең гаебен тану, әйтү, кимчелекләрен тану, өстенә алу. *Үзегезнең мәсъүл икәнлегегезне игътираф итеп, адәм балаларына башка юллар эзләргә...* *чакырмыйсызмы?* (Г. Ибр.) — *м. VIII.* Признание (своих ошибок, недостатков и. т. д.).

**Игътисаб** اغتصاب *м. VIII.* Тартып алу, җәберләп, талап алу, көчләп алу, үзенеке итү. — *м. VIII.* Похищение, узурпация, грабёж; присвоение.

**Игътисал** اغتسال *м. VIII.* Юыну, коену. — *м. VIII.* Обмывание, купание, умывание.

**Игътисам** اعتصام *м. VIII.* 1) Тотыну, кулы белән ябышу. 2) Бер-бер нәрсәдән һич аерылмау. 3) Гаепле булудан үзен саклау. — *м. VIII.* 1) От гл. عصم (гасамә) — крепко держаться за что-либо. 2) Нежелание расстаться с чем-либо. 3) Избежание обвинения.

**Игътисаф** اعتساف *м. VIII.* 1) Туры юлдан язу, юлдан сабу. 2) Хаксызлык. — *м. VIII.* 1) Уклонение от прямого пути. 2) Притеснение, несправедливость, жестокость.

**Игътишаш** اغتشاش *м. VIII.* 1) Хәйлә, яман ният белән яхшы сүз әйтү. 2) Бозык уй белән эшләнгән яки сөйләнгән дип уйлау. — *м. VIII.* 1) Плутовство, хитрость, двуличие. 2) Выражение недоверия к сказанному или сделанному.

**Игътияд** اعتياد *м. VIII.* 1) Гадәтләнү, гадәткә кертү, гадәт итү. 2) Гадәт, гадәткә кергән нәрсә. — *м. VIII.* 1) Привыкание, приучение. 2) Обыкновение, привычка.

**Игъфал** اغفال *м. IV.* Белемсезлеккә төшерү, йомыклыкка төшерү, алдау, сизмсез итү. *Сез, әй, чалмалылар, безне моңа дик* (чаклы) *иттегез игъфал.* (Г. Тук.) — *м. IV.* Введение в заблуждение, обман.

**Игъҗаб** اعجاب *м. IV.* Гаҗәпләнүгә төшерү, гаҗәпләнүгә сәбәп булу. — *м. IV.* Вызвать удивление, привести в восторг.

**Игъҗаз** اعجاز *м. IV.* 1) Гаҗизлеккә төшерү, аптырауда калдыру. 2) Һәркемне гаҗәпләндерә һәм беркем дә эшли алмый торган гадәттән тыш нәрсә. *Ушбу мәзкүрләр аның ләфзында булгач игъҗаздыр.* (К. Нас.) — *м. IV.* 1) Ослабление, обессиливание, делание неспособным (к чему-либо). 2) Удивительное явление, чудо.

**Игъҗал** اعجال *м. IV.* Ашыктыру, тизләтү. — *м. IV.* Потарапливание, ускорение.

**Идаг** ایداع *м. IV.* Малын сакларга бирү. — *м. IV.* Вкладывание, вложение, вручение, отдача на сохранение.

**Идамә** ادامه *м. IV.* Дәвам иттерү, туктатмый алып бару. — *м. IV.* Продолжение, продление.

**Иданә** ادانه *м. IV.* Бурыч бирү, ссуда бирү, заём. — *м. IV.* Предоставление займа, отдача в долг; ссуда.

**Иданәтән** ادانةً *р.* Бурычка бирү юлы белән. — *н.* Путём одолжения, при помощи займа.

**Идарә*** اداره *м. IV.* 1) Эш йөртү, эшкә җитәкчелек итү. 2) Эш башкару урыны. — *м. IV.* 1) Управление; руководство. 2) Учреждение, контора, правление.

**Идбар** ادبار *м. IV.* 1) Бәхетнең артка (кирегә) китүе; бәхетсезлек. 2) Эшнең артка китүе, эш чуалу; уңышсызлык. *Икъбале бар вакытта дус, карендәш итеп, идбары вактында хәкарәт кылган.* (К. Нас.) — *м. IV.* 1) Несчастье, напасть. 2) Неудача в делах; безуспешность.

**Идгам** ادغام *м. IV. грам.* Авазларның йотылышы, охшашлану. — *м. IV. грам.* Ассимиляция.

**Иддигаэ** ادعا *м. VIII.* 1) Дәгъва итү, даулау. 2) Нигезсез (хаксыз) дәгъва. 3) Үз-үзен әллә кемгә кую. — *м. VIII.* 1) Претензия, притязание, требование, иск. 2) Необоснованная претензия. 3) Самомнение.

**Идман** ادمان *м. IV.* 1) Күнегүләр ясау; күнегү. 2) Үзләштерү өчен бер эшне кабатлау. — *м. IV.* 1) Работа над упражнениями; упражнение. 2) Повторение (материала).

**Идман бәдән** ادمان‌بدن *ст.* Гимнастика ясау. — *сс.* Гимнастическое упражнение.

**Идракь** ادراك *м. IV.* Төшенү, уйлап белү, аңлап җитү, зиһенгә алу. *Гакыл* — *м. IV.* Понимание, постижение, догадка.

*белән хөсең, кабих вә гакыйбәте мәстүр булган нәрсәләрне идракь кыйлыныр.* (К. Нас.)

**Идхал** ادخال *м. IV.* Кертү. — *м. IV.* Введение, внесение, включение.

**Изага** اضاعه *м. IV.* 1) Бетерү, югалту, юкка чыгару. 2) Бушка җибәрү, әрәм итү. — *м. IV.* 1) Потеря; уничтожение. 2) Напрасная трата.

**Изака** اذاقه *м. IV.* 1) Татыту, тәмен татыту. 3) Зәвыкландыру. — *м. IV.* 1) Давать пробовать. 2) Удовлетворение (вкуса).

**Изалә** ازاله *м. IV.* Китәрү, җибәрү; бетерү, юк итү. — *м. IV.* Устранение, уничтожение.

**Изар** ازار *ис.* 1) Киң юбкасыман эчке кием. 2) Гәүдәне билдән түбән каплау өчен билгә бәйли торган җаймә — өреткеч. — *сущ.* 1) Широкое нижнее платье. 2) Покрывало для прикрытия нижних частей тела.

**Изафә** اضافه *ис.* 1) Кушу, тоташтыру. 2) *грам.* Изафә (иялек килешендәге исем белән бирелгән аергычның аерылмышка мөнәсәбәте). — *сущ.* 1) Присоединение, добавление, дополнение. 2) *грам.* Изафет (определение в род. падеже.)

**Изах** ایضاح *м. IV.* Аңлату, ачыклау, ачык итеп аңлату. *Бер җөзаф сүз булса да гә*, (гәрчә) *бер изахсыз үтмәек.* (Ш. Баб.) — *м. IV.* Разъяснение, объяснение.

**Изахат** ایضاحات *ис.* Изах-ның *к.* — *сущ мн.* от изах.

**Изахән** ایضاحاً *р.* Ачыклап, ачык итеп сөйләп. — *н.* Ясно, чётко (объяснять что-либо).

**Изгаф** اضعاف *м. IV.* Зәгыйфьләү, көчсезләндерү. — *м. IV.* Ослабление.

**Издиваж** ازدواج *м. VIII.* Өйләнешү, парлашу. — *м. VIII.* Брак, бракосочетание, женитьба.

**Изен** اذن *ис.* Рөхсәт, эшләргә ирек бирү юл кую. — *сущ.* Разрешение, позволение.

**Изкяр** اذکار *м. IV.* Искәртү, исенә төшерү, хәтерләтү. — *м. IV.* Напоминание.

**Излял I** اضلال *м. IV.* Юлдан яздыру, адаштыру, саташтыру, аздыру. — *м. IV.* Сбивание с пути, введение в заблуждение; совращение.

**Излял II** اذلال *ис.* Кимсетү, түбәнәйтү, санга санамау. *Мәгариф әһлидән чук күрдем иҗлял, җәһаләт каумидин төхкыйр вә излял.* (Ут. Им.) — *сущ.* Унижение, пренебрежение.

**Измар** اضمار *м. IV*. 1) Яшерү, сер итеп тоту. 2) Яшерелгән уй. — *м. IV*. 1) Сокрытие, умалчивание. 2) Тайный замысел.

**Израр** اضرار *м. IV*. Зарар иттерү, зыянга кертү. — *м. IV*. Нанесение вреда, причинение ущерба.

**Изтыйраб** اضطراب *м. VIII*. 1) Дулкынлану. *Ул миңа моңарчы таныш булмаган изтый*,*аблы бер тавыш белән „эткәй вафат" диде*. (Г. Ибр.) 2) Икеләнү. 3) Көенү. 4) Йөдәү; аптырау; интегү; мәшәкатькә тару, азаплану, борчылу. *Мин алдан ук икенче класста бер урын яздырып куйганлыгымнан, бик изтыйрабка төшми утыруымда дәвам иттем*. (Ф. Әмир.) — *м. VIII*. 1) Волнение. 2) Колебание. 3) Возбуждение, смута, замешательство. 4) Путаница, неясность. 5) Затруднение, беспокойство.

**Изтыйрар** اضطرار *м. VIII*. Көчләнү, чарасыз булу, мәҗбүр булу. — *м. VIII*. Вынужденность, необходимость.

**Изтыйрари** اضطرارى *с*. Чарасыз; мәҗбүри. *Күбрәк ашаганнары арпа иде, бу хәлне ихтыяр кылмакы, әлбәттә, изтыйрари иде*. (К. Нас.) — *прил*. Вынужденный.

**Изһар** اظهار *м. IV*. Күрсәтү, ачып салу, мәйданга чыгару. *Телләре белән изһар кыла шатлыкларын*. (М. Гаф.) — *м. IV*. 1) Обнаружение, выявление. 2) Показ.

**Икад** ايقاد *м. IV*. Кабызу, яндырып җибәрү, яндыру. — *м. IV*. Зажигание, разведение огня.

**Иказ** ايقاظ *м. IV*. 1) Уяту, йокыдан торгызу. 2) Кисәтү, сизми, белми калудан коткару. — *м. IV*. 1) От гл. يقظ — (яказа) будить, пробуждать. 2) Предупреждение, предостережение.

**Икамә** اقامه *м. IV*. 1) Торгызу, аякка бастыру. 2) Бер урында яшәү. — *м. IV*. 1) Поднятие, постановка, воздвижение. 2) Пребывание, проживание на одном месте.

**Икамәт** اقامت *м. IV*. 1) Бер урында тору; яшәү, тереклек итү. 2) *дини* Намазга керешүдән элек (аягүрә торып) кыла торган дога. — *м. IV*. 1) Жительство, поселение. 2) *рел*. Слова, произносимые перед чтением молитвы (намаза).

**Икамәтгаһ** اقامتگاه *гф. ис*. Тора торган урын. — *ар.-п. сущ*. Местожительство, резиденция.

**Икан** ايقان *м. IV*. 1) Анык белү, ачык белү, дөрестән белү. 2) Ышану. — *м. IV*. 1) Знание истины. 2) Убеждённость, убеждение.

**Икмаль** اكمال *м. IV*. Тулысынча житлекле итү, камилләштерү, төзеп — *м. IV*. Завершение, совершенствование.

бетерү. *Хатип хәзрәт тарафыннан кат-кат икмаль ителгән иде.* (Г. Ибр.)

**Икрам** اكرام *м. IV.* 1) Хөрмәт. 2) Олылау, хөрмәт күрсәтү, санга санау. *Ут кабызмый үл төтен эчкәндә дә синнән элек, әүвәле сиңа суза: икрам вә хөрмәт күрсәтә.* (Г. Тук.)

*м. IV.* 1) Почёт. 2) Почтение, уважение.

**Икрамән** اكراماً *р.* Хөрмәтләп, олылап.

*н.* С уважением; почтительно.

**Икраһ** اكراه *м. IV.* Бер эшне эшләргә көчләү, ирексезләү.

*м. IV.* Принуждение, применение силы.

**Икраһән** اكراهاً *р.* Көчләп, ирексезләп; җәберләп.

*н.* Насильно, принудительно.

**Иктиса** اكتساء *м. VIII.* Кию, кием кию.

*м. VIII.* Одевание.

**Иктисаб** اكتساب *м. VIII.* 1) Казану, булдыру. 2) Эшләп табу.

*м. VIII.* 1) Добывание, приобретение. 2) Зарабатывание.

**Иктифа** اكتفاء *м. VIII.* Канәгатьләнү. *Бу юлга вәгазьләп кенә төзәтү белән иктифа итүегезне үтенәм.* (Ф. Әмир.)

*м. VIII.* Удовлетворённость, довольство; удовлетворение.

**Икъбал** اقبال *м. IV.* 1) Эшнең алга баруы. 2) Бәхет алга китү, бәхетле булу, уңышлы булу. 3) Бәхет, уңыш. *„Аның мәчесе дә куян тота“ — икъбале алга барган кеше хакында ирад кылыныр* (сөйләнер). (К. Нас.) 4) Каршы алу.

*м. IV.* 1) Движение вперёд. 2) Становиться счастливым. 3) Успех, счастье. 4) Приём, встреча.

**Икъдам** اقدام *м. IV.* 1) Алга китү, тырышлык белән алга адым атлау. 2) Көч кую, тырышу, үз дигәнен итү. *Фөнүннең тәрәккыйсенә әрбабе гакыл икъдам итсә гаҗәп түгел.* (К. Нас.)

*м. IV.* 1) Движение вперёд. 2) Старание, усердие; приложение усилий.

**Икъдар** اقدار *м. IV.* Көч җитә торган итү, көч казандыру, кулыннан килә торган итү.

*м. IV.* Развитие (чьихлибо) способностей (к чему-либо).

**Икълим** اقليم *ис.* 1) Климат. 2) Борынгы бүленештә җирнең экватордан төньяк котыпка кадәр булган җиде бүленешенең һәрберсе. *Җиде икълим аның кул астында иде.* (К. Нас.)

*сущ.* 1) Климат. 2) Поясное деление земного шара к северу от экватора (по делению древних географов).

**Икънаг** اقناع *м. IV.* Канәгатьләндерү, ризаландыру, ышандыру. *Әхмәт, атасын икънаг өчен, икенче дәлил тапты.* (Ф. Әмир.)

*м. IV.* Удовлетворение; убеждение; уверение.

**Икъраз** اقراض *м. IV.* Бурычка биру, көтәчәккә биреп тору. — *м. IV.* Ссуда, кредитование.

**Икърар** اقرار *м. IV.* 1) Урнаштыру. 2) Тынычландыру. 3) Танмый сөйләп биру, икърар иту, тану. *Советларга булган гөнаһларын берәм-берәм икърар иттеләр.* (М. Гаф.) — *м. IV.* 1) Установление. 2) Успокоение. 3) Признание, сознание.

**Икътибас** اقتباس *м. VIII.* 1) Алынма, алып файдалану, ияреп файдалану. *Хәзрәти Пушкин вә Лермонтов әгәр булса кояш, ай кеби нурны алардан икътибас иткән бу баш.* (Г. Тук.) 2) Үрнәк алу. 3) Цитата китеру, цитата биру. — *м. VIII.* 1) Заимствование; подражание. 2) Следование чьему-либо примеру. 3) Цитирование.

**Икътибасән** اقتباساً *р.* Алып, үрнәк итеп алып, файдаланып. — *н.* Путем заимствования, подражая; используя.

**Икътидар** اقتدار *м. VIII.* 1) Кулдан килү, булдыра алу, көч житү. 2) Көч, куәт. *Бәнем икътидарым улса, ярдәм кылыр идем.* (З. Биг.) — *м. VIII.* 1) Способность, умение. 2) Сила, могущество.

**Икътидаэ** اقتداء *м. VIII.* Ияру, берәүгә ияреп шуның кебек эшләү. — *м. VIII.* Подражание, следование (примеру).

**Икътидаэн** اقتداً *р.* Берәүгә ияреп. — *н.* Подражая, следуя примеру (чьему-либо).

**Икътиза** اقتضاء *м. VIII.* 1) Кирәклек, мохтажлык. 2) Теләү, таләп иту, кушу. *Кагыйдә икътизасынча, дәхи мөтәгайир була.* (К. Нас.) — *м. VIII.* 1) Потребность, необходимость, нужда. 2) Требование; желание, веление.

**Икътизаи заман** اقتضاءِ زمان *ф. из.* Заман теләве, заман кушуы, заман таләп итүе. — *п. из.* Требование времени (эпохи).

**Икътиран** اقتران *м. VIII.* 1) Якынлашу, якын килү, бер юлда булу. 2) *астр.* Жиргә карата айның кояш белән бер сызыкта булуы яки ике йолдызның бер сызыкта булуы. 3) Өйләнешү. — *м. VIII.* 1) Сближение, союз, соединение. 2) *астр.* Противостояние. 3) Бракосочетание, женитьба.

**Икътисад** اقتصاد *м. VIII.* 1) Экономика, берәр эшнең хужалык ягы. 2) Әйберне, малны сак тотучылык, экономия. 3) Жәмгыятьнең хужалыгын идарә иту. 4) Жәмгыятьнең килерен бүлү юлы. — *м. VIII.* 1) Экономика, хозяйство. 2) Умеренность, бережливость, экономия. 3) Руководство экономикой общества. 4) Распределение доходов общества.

**Икътисади** اقتصادی *с.* Экономик, экономика(га бәйләнешле). *Шул тор-* — *прил.* Экономический, хозяйственный.

*мыш биргән материаллар аның фикерен икътисади калыпка салды.* (Г. Ибр.)

**Икътисам** اقتسام *м. VIII.* Бүлешү. — *м. VIII.* Деление, раздел.

**Икътисар** اقتصار *м. VIII.* 1) Кыскарту, кыска итү. 2) Кыскалык. — *м. VIII.* 1) Сокращение; укорачивание. 2) Краткость.

**Икътифа** اقتفاء *м. VIII.* Берәүнең артыннан китү, берәүгә иярү. — *м. VIII.* Следование (за кем-либо).

**Ила** الى *бәйл.* Чаклы, кадәр, хәтле, ...-ка ча, ...-ка чаклы. — *пред.* В, к, до, для, за.

**Ила ахириһи** الى آخره *ст.* Ахырына чаклы, ахырына кадәр. — *сс.* До конца, и так далее.

**Ила гайренниһая** الى غيرالنهايه *гыйб.* Чиксезлеккә кадәр. — *фр.* До бесконечности.

**Иләһ** اله *ис. дини* 1) Алла, тәңре. 2) Табынылa торган пот. 3) Сугыш алласы. 4) Гыйшык (мәхәббәт) алласы һ. б. — *сущ. рел.* 1) Бог, божество. 2) Идол. 3) Бог любви. 4) Бог войны и т. п.

**Иләһи*** الهى *с.* 1) *дини* Алла(га бәйләнешле). *Ахырына куйган ходай үз имзасын, ягъни илаһи тамгасын.* (Ш. Баб.) 2) И аллам. *Илаһи ярдәм ит.* 3) Искиткеч шәп, бик яхшы, тиңләштермәслек. — *прил.* 1) *рел.* Божий. 2) Господи, бог мой. 3) Божественный. 4) Прекрасный, несравненный.

**Иләһиун** الهيون *ис. к.* 1) Алланың барлыгына ышанучы философлар. 2) Фәлсәфәнең илаһият бүлеге белән шөгыльләнүчеләре. — *сущ. мн.* 1) Верующие философы. 2) Философы, занимающиеся вопросами теологии.

**Илаһият** الهيات *ис.* Теология (аллалыкка бәйләнешле мәсьәләләр турында дини фәлсәфә гыйлеме). — *сущ.* Богословие, теология.

**Илаһә*** الهه *ис. кара:* Алиһә. *Без мәхәббәт илаһәсенә самими гыйбадәтебезне вакытында самимият белән үтәдек.* (Г. Ибр.) — *сущ. см.* Алиһә.

**Илзам** الزام *м. IV.* Бәхәстә җиңеп өстен чыгып, каршы якны бер сүз дәшмәслек итеп җавапсыз калдыру. *Мине илзам итмәк булып: „Пар йөрткәч, нигә йөрми соң самовар", — дип җавап бирде.* (М. Гаф.) — *м. IV.* Безусловная победа в споре (заставить противника замолчать).

**Илка** القاء *м. IV.* 1) Ташлау, ыргыту. 2) Фикерне икенче якка бору өчен сөйләү. — *м. IV.* 1) Бросание. 2) Перевод разговора на другую тему.

**Илля*** الا *тер.* Әмма, тик, ә инде. *Бу Гыйлаҗи дигәнең эт нәрсә, бер ук балта тотып сәнәк очларга кулыннан килми, илля мәгәр тел дигәндә авызына иблис төкергән инде.* (Г. Ибр.) *с.* Но, однако.

**Илтизам** التزام *м. VIII.* 1) Үз өстенә йөкләү, үзенә тиешле дип табу, өстенә алу. 2) Йөкләү, мәҗбүр итү. *м. VIII.* 1) Принятие на себя обязательства. 2) Вменение в обязанность, принуждение.

**Илтика** التقا *м. VIII.* Юлыгу, очрашу, бергә кушылу, кавышу. *м. VIII.* Встреча, свидание.

**Илтикат** التقاط *м. VIII.* 1) Чүпләп җыю. 2) (Төрле китаплардан) мәгълүмат җыю, туплау. *м. VIII.* 1) Подбирание, собирание. 2) Подбор материала (из книг).

**Илтимас** التماس *м. VIII.* 1) Үтенү, сорау, инәлү. *Илтимас илә булган сөальләр тук авызлы, шат кешеләргә артык тәэсир итми иде.* (М. Гаф.) 2) Таләп итү. *м. VIII.* 1) Прошение, просьба. 2) Требование.

**Илтисак** التصاق *м. VIII.* 1) Тоташу, ябышу. 2) Аралашу. *м. VIII.* 1) Соединение. 2) Общение.

**Илтифәт*** التفات *м. VIII.* 1) Борылып карау. 2) Ягымлылык күрсәтү, ярату, ошату. 3) Олылау, хөрмәт күрсәтү, яхшы кабул итү. *Илтифат белән кабул итте.* 4) Дикъкать, игътибар. *Кызның миңа кылган илтифатына көнлиләр...* (М. Гаф.) 5) Әһәмият бирү, күңел биреп карау, абайлау. *м. VIII.* 1) Обращение внимания. 2) Внимание, интерес, благосклонность. 3) Возвышение, возвеличивание; уважение. 4) Хороший приём. 5) Внимание. 6) Придание значения.

**Илтихак** التحاق *м. VIII.* Тоташу, бергә кушылу, үзеннән алдагыларга җитеп шулар белән бергә булу, соңыннан килеп кушылу. *м. VIII.* Присоединение, примыкание (к чему-либо).

**Илтихам** التحام *м. VIII.* 1) Тоташу. 2) Ярага ит үсеп каплану. 3) (Сөяк) тоташу. *м. VIII.* 1) Связь, соединение. 2) Заживание (раны). 3) Срастание (кости).

**Илтиям** التيام *м. VIII.* (Яра капланып) төзәлү. *Мәҗрух адәмнәр дәва кылынып илтиям тапмышлардыр.* (К. Нас.) *м. VIII.* Рубцевание, затягивание (ран).

**Илтиҗа** التجاء *м. VIII.* Ышыклану, берәүнең кул астына барып сыену, берәүдән үзен яклауны үтенү, сыену урыны сорау. *м. VIII.* Укрытие, поиск убежища; просьба о предоставлении убежища, покровительства.

**Илтиһаб** التهاب *м. VIII.* 1) Шешү; җилсенү, пешегү. 2) Ялкынлану, кабыну. 3) Бик каты ачулану, ачудан кызу. — *м. VIII.* 1) Опухание, вздутие. 2) Покраснение (опухоли). 3) Воспламенение, загорание. 4) Озлобление.

**Илх** الخ „һәм башкалар“, „ахырына чаклы“ (ила ахириһи дигән сүздән кыскартылган). — *част.* И так далее (сокращение от слов „ила ахириһи — и так до конца“).

**Илхак** الحاق *м. IV.* Кушу, тоташтыру. — *м. IV.* Присоединение, добавление.

**Илхах** الحاح *м. IV.* 1) Йөдәтеп сорау, „сагыз булу“. *Илхах вә ибрам итеп, хатын алды.* (К. Нас.) 2) Үзсүзлелек. — *м. IV.* 1) Убедительная просьба; надоедание 2) Настойчивость, упорство.

**Илһам*** الهام *м. IV.* 1) Күңелгә салынган нәрсә. *Шул вакытта уйла, шагыйрь, килде илһам уйласаң.* (Г. Тук.) 2) Күңелгә салыну, күңелгә салу. — *м. IV.* 1) Вдохновение. 2) Внушение.

**Илһами** الهامى *с.* 1) Илһам(га бәйләнешле). 2) Алдан уйланмыйча, тик үтәү вакытында гына иҗат ителгән яхшы шигырь, речь. — *прил.* 1) Вдохновляющий. 3) Экспромт.

**Имам*** امام *ис. дини* 1) Кешеләрне үзенә ияртеп намаз укытучы, мәхәллә мулласы. 2) Кайбер мөселман илләрендә дин һәм дәүләт башында торучы. 3) Мәзһәп (секта) тудыручы кеше. 4) Бер гыйлем-фәндә сүзе нигез, дәлил итеп алынырлык дәрәҗәдә булган галим. *Фәхрелислам ярты назим, ярты хазин, ярты имам, ярты нашир, ярты насир—бәхте киткән ярты дан.* (Ш. Баб.) 5) Җитәкче кулланма. *Бу нәсыйхәтләр дәүләт юлының җитәкчеләре; падиша аларны үзенә имам итсә, дәүләте төкәнмәс.* (Г. Фәез.) — *сущ. рел.* 1) Имам, духовное лицо. 2) Мусульманский деятель, располагающий духовной и светской властью; вождь 3) Основатель религиозной секты. 4) Авторитет в науке.

**Имамәт** امامت *ис.* 1) Имамлык, дини җитәкчелек. 2) Башында имам торган дәүләт. — *сущ.* 1) Имамат, духовное руководство. 2) Звание, должность имама 3) Государство, во главе которого стоит имам (духовное лицо).

**Иман*** ايمان *м. IV.* 1) Ышану, инану. 2) Аллага инануны белдерә торган дога сүзләре. — *м. IV.* 1) Вера, убеждение. 2) Иман (слова, произносимые для заверения в верности богу).

**Имаэ** ایما *м. IV*. Ым беләп, ишарә белән аңлату, сөйләү. — *м. IV*. Намёк, знак, жест.

**Имдад** امداد *м. IV*. Ярдәм; ярдәм итү, булышлык күрсәтү. *Гакыйль шулдыр, үзенең гакылыннан нашц халыкка имдадта булып, сүзе тугры, фигыле күркәм булган кешедер*. (К. Нас.) — *м. IV*. Помощь, содействие, подмога.

**Имза*** امضا *м. IV*. Кул кую, тамга салу. — *м. IV*. Подпись.

**Имин*** امین *с*. Куркынычсыз, ышанычлы, тыныч. — *прил*. 1) Безопасный, безбоязненный, надёжный. 2) Спокойный, благополучный.

**Имкян*** امکان *м. IV*. Мөмкин булу, мөмкинлек, булырлык хәлдә булу. — *м. IV*. Возможность.

**Имля*** املا *м. IV*. 1) Әйтеп яздыру, имла. 2) Орфография; дөрес язу кагыйдәсе. — *м. IV*. 1) Диктовка, диктант. 2) Орфография; правописание.

**Имрар*** امرار *м. IV*. Уздыру, үткәрү, кичерү. — *м. IV*. 1) Пропуск. 2) Проведение.

**Имраре** *хәят امرارحیات *из*. Гомер кичерү, гомер үткәрү, гомер уздыру. — *из*. Проведение жизни

**Имрәәт** امرأة *ис*. 1) Хатын. 2) Хатын-кыз. — *сущ*. 1) Жена. 2) Женщина.

**Имсакь** امساك *м. IV*. 1) Үз-үзеңне тыю. *Гайбәттән имсакь итте*. 2) Саранлык, үз-үзеннән кысу. — *м. IV*. 1) Отказ, воздержание. 2) Скупость, жадность.

**Имтидад** امتداد *м. VIII*. Озаю, озакка сузылу, тартылу, дәвамы сузылу, озак булу. — *м. VIII*. Протяжение; продление.

**Имтизаҗ** امتزاج *м. VIII*. 1) Кушылу, катнашу. 2) Ярашу, килешү, оешу. — *м. VIII*. 1) Смещение, соединение. 2) Согласование.

**Имтинаг** امتناع *м. VIII*. 1) Баш тарту. 2) Тыелу, тыйнаклану, үзеңне тыю. — *м. VIII*. 1) Отказ; воспрещение. 2) Воздержание.

**Имтинан** امتنان *м. VIII*. 1) Бирәүнең яхшылыгына рәхмәт әйтү. 2) Миннәт итү, үзенең бирәүгә эшләгән яхшылыкларын телгә алып табалау. *Миңа һәркөн бирә ул аш вә нани* (икмәк), *вә миннәт итми һич юк имтинани* Г. Тук.) — *м. VIII*. 1) Признательность, благодарность. 2) Укор, упрёк благодеянием.

(

**Имтисал** امتثال *м. VIII.* 1) Охшатып эшләү, ияреп үрнәк алу. 2) Алынган боерыкка, әмергә карышмый буйсынып тулысынча үтәү. — *м. VIII.* 1) Подражание. 2) Послушание, повиновение.

**Имтисаләи** امتثالاً *р.* Буйсынып, яраклашып. *Аларның илтимасларына имтисаләи бу нөсхәнең тәсвиденә шруг иттем* (Хисаметдин Мөслими). — *н.* Подчиняясь, повинуясь, следуя примеру.

**Имтихан*** امتحان *м. VIII.* Сынау, сынап белү. — *м. VIII.* Испытание, экзамен.

**Имтияз** امتياز *м. VIII.* 1) Башкалардан аерылып тору, өстен булу. 2) Укучыга бирелгән мактау кәгазе. *Ни кушсаң да укый алды, ни әйтсәң дә яза алды, балаларның арасында үзенә имтияз алды.* (Г. Тук.) 3) Берәр хуҗалык эшен кору өчен аерым капиталистка берәр дәүләт тарафыннан бирелгән хокук-рөхсәт. — *м. VIII.* 1) Различие, отличие. 2) Привилегия, преимущество. 3) Похвальная грамота (в школе). 4) Концессия (разрешение на предпринимательство).

**Имһал** امهال *м. IV.* Кичектерү, вакытны озайту. — *м. IV.* 1) Предоставление отсрочки. 2) Промедление.

**Инәбәт** انابت *м. IV.* Ышану; ышаныч, таяныч. *Галиевнең сүзенә инабәт кылмаенча.* (З. Биг.) — *м. IV.* Доверие.

**Инас** اناث *ис.* Хатын-кызлар. — *сущ. соб.* Женщины.

**Инба** انباء *м. IV.* Хәбәр бирү, хәбәр китерү, белдерү. — *м. IV.* Сообщение, извещение.

**Инбат** انبات *м. IV.* Үстерү. — *м. IV.* Выращивание (растений).

**Инбисат** انبساط *м. VII.* 1) Җәелү, киңәю, ачылу. *Ачык йөзлелек инбисате мунислекне муҗибдер.* (К. Нас.) 2) Түшәлү. 3) Күңел ачылу. — *м. VII.* 1) Расширение. 2) Растилание. 3) Радость, довольство, хорошее настроение.

**Инбисәте кальб** انبساطقلب *из.* Йөрәк киңәю (авыру). — *из.* Расширение сердца.

**Ингам** انعام *м. IV.* 1) Нигъмәт бирү, аш бирү, сыйлау. 2) Яхшылык итү. *Асрады шаһ үз ингамы белән.* (Мөхм.) — *м. IV.* 1) Питание; угощение. 2) Милость, благодеяние.

**Ингыйкад** انعقاد *м. VII.* 1) Бәйләнү, төенләнү. 2) Договор төзү. 3) (Мәҗлес) кору, оештыру. — *м. VII.* 1) Связь, соединение. 2) Заключение договора. 3) Организация обеда или ужина для гостей.

**Ингыйкяс** انعكاس *м. VII.* 1) Чагылу, кире шәүләләнү, нурларның кире кай- — *м. VII.* 1) Рефлексия. 2) Преломление (света). 3) Отзвук, эхо.

туы. *Буш вәһемнәр берлә ысланган хыялым ләүхәсе, бәс ничек күңлемдә илһам анда итсен ингыйкяс.* (Ш. Баб.) 2) Нур сыну (яктылык нурларының кайбер әйбер аркылы узганда үзенең юнәлешен үзгәртеп сынган кебек булуы). 3) Янғырау, яңгырык, кайтаваз (авазның урман, тау кебекләргә бәрелеп кире кайтуы, яңгыравы).

эхо.

**Ингыйтаф** انعطاف *м. VII.* Бер якка юнәлү, борылу; мәел итү, күңел авышу.

*м. VII.* 1) Отклонение, наклон. 2) Склонность.

**Индифаг** اندفاع *м. VII.* 1) Омтылу, омтылыш. 2) Дәртләнү, дәрт.

*м. VII.* 1) Стремительность, порыв. 2) Страстность.

**Инес** انس *ис.* Кешеләр, адәм женесе. *Сәгадәт бәхтемезгә калсын инес, җинниләр хәйран.* (Г. Тук.)

*сущ.* Люди, род человеческий.

**Инзал** انزال *м. IV. дини* Индерү, югарыдан түбән төшерү. *Хәкимнәр „инзал" кылынмыш дүрт китаптан дүрт сүз сайладылар.* (К. Нас.)

*м. IV. рел.* Ниспослание.

**Инзар** انذار *м. IV.* Алдан куркытып тыю, алдан ук кисәтеп кую; киләчәге бик начар булу белән янау, котны алу.

*м. IV.* Предупреждение, предостережение; увещевание; запугивание.

**Инзыймам** انضمام *м. VII.* 1) Кушылу, аннексияләнү. 2) Өстәлү.

*м. VII.* 1) Присоединение, аннексирование. 2) Добавление.

**Инкал** انقال *м. IV.* Күчерү, күчереп урнаштыру. *Полициядән төрмә хәбесханәсенә инкал кылып.* (З. Биг.)

*м. IV.* Перемещение, передвижение.

**Инкисар** انکسار *м. VII.* 1) Сыну, сындырылу. 2) Дошман гаскәренең каршылыгы сыну. 3) Каты нәрсәнең йомшавы. 4) (Күңел) кайту, сыну. *Инкисар ит гадәтеңчә, ян күңел, сызлан күңел.* (Г. Тук.)

*м. VII.* 1) Поломка, надлом. 2) Конец сопротивления войск противника. 3) Смягчение твёрдого предмета. 4) Обида.

**Инкисаф** انکساف *м. VII. астр.* Кояш тотылу.

*м. VII. астр.* Солнечное затмение.

**Инкишаф** انکشاف *м. VII.* 1) Ачылу, күренә торган хәлгә килү, мәйданга чыгу. 2) Фәндә яңа нәрсә ачылу.

*м. VII.* 1) Открытие, обнаружение. 2) Научное открытие.

**Инкишаф әзһар** انکشاف ازهار *ст.* Чәчәкләр ачылу, чәчәк ату.

*сс.* Раскрытие бутонов, цветение.

**Инкыйбаз** انقباض *м. VII.* 1) Җыерылу, бөрешү. 2) Кысылу, кыскару. 3) Эч кату.

*м. VII.* 1) Сморщивание, 2) Сокращение, сжатие. 3) Запор, засорение желудка.

**Инкыйза** انقضا *м. VII.* 1) Срогы бетү, срогы чыгу. 2) Бетү, тәмам булу, бер кисәге дә калмау, төкәнү. — *м. VII.* 1) Окончание, истечение (срока). 2) Конец.

**Инкыйляб** انقلاب *м. VII.* 1) Әйләнү, асты өскә килү. 2) Алмашыну, үзгәрү, революция, переворот. 3) *грам.* Чиратлашу (бер авазның икенче авазга әйләнүе, күчүе). *„Л" нең „н" гә инкыйлабы.* (К. Нас.) — *м. VII.* 1) Переворачивание, опрокидывание. 2) Переворот, революция. 3) *грам.* Чередование звуков.

**Инкыйлябат** انقلابات *ис.* Инкыйлябның *к. Заманның инкыйлябатына бән һәр дәмдә калканым.* (Г. Тук.) — *сущ. мн.* от инкыйляб.

**Инкыйляби** انقلابی *с.* Революцион. *Гомере вафа иткән булса, Бабич әллә ничаклы яңа инкыйляби җәүһәрләр бирәчәк иде.* (Г. Ибр.) — *прил.* Революционный.

**Инкыйраз** انقراض *м. VII.* 1) Бетү, юкка чыгу, сүнү, үлеп бетү, нәсел калмау, нәселе киселү. *Бара торгач сандугачлар калды азга, йөз тотты бичаралар инкыйразга.* (М. Гаф.) 2) Регресс, түбән китү. — *м. VII.* 1) Вымирание, угасание, исчезновение, прекращение. 2) Регресс.

**Инкыйсам** انقسام *м. VII.* Бүленү, өлешләргә аерылу. — *м. VII.* 1) Разобщённость. 2) Разделение, раскол.

**Инкыйтаг** انقطاع *м. VII.* 1) Киселү, ара киселү, ара өзелү. 2) Туктау (яңгыр һ. б.). 3) Кору, (чишмәнең) суы кору, кибү. 4) (Сүз) бетү, киселү. 5) Юл киселү. — *м. VII.* 1) Перерыв. 2) Прекращение (дождя и т. п.). 3) Высыхание русла (реки). 4) Прекращение речи. 5) Пресечение (пути).

**Инкыйтагы иштиһа** انقطاع اشتها *гыйб.* Ашыйсы килмәү, аппетит бетү. — *фр.* Исчезновение аппетита.

**Инкыйяд** انقیاد *м. VII.* Буйсыну, сүз тыңлау, кушканны төгәлләү, баш ию. — *м. VII.* Покорность, повиновение, подчинение.

**Инкяр*** انکار *м. IV.* Юк дип әйтү, юкка чыгару, кире кагу, танымау, инкарь итү. — *м. IV.* Отрицание, непризнание.

**Инсан** انسان *ис.* Кеше, адәм. *Телим булырга мин инсаны гали.* (Г. Тук.) — *сущ.* Человек.

**Инсани** انسانی *с.* Кеше (гә), адәм (гә бәйләнешле). — *прил.* Человеческий.

**Инсаният** انسانیت *ис.* 1) Кешелек дөньясы. 2) Кешелек, кеше сөючәнлек, адәмдә генә була торган бөек, яхшы сыйфатлар. — *сущ.* 1) Человечество. 2) Гуманность; человечность.

**Инсаф*** انصاف *м. IV.* 1) Гаделлек. 2) Дөреслек, турылык белән эш күрү. — *м. IV.* 1) Справедливость, правосудие. 2) Беспристрастное ведение дела.

**Инсиять** انسيت *ис.* Кешелек. *Җиһанда хиссе инсиять озак көррәтлә ганкадан.* (Г. Тук.) — *сущ.* Человечность.

**Инсыйраф** انصراف *м. VII.* 1) Йөз чөерү. 2) Артка китү, кире кайтып китү. — *м. VII.* 1) Отказ. 2) Уход, отход.

**Интак** انطاق *м. IV.* 1) Сөйләтү. 2) Телле итү. — *м. IV.* 1) От глаг. نطق (нәтака) — заставлять говорить. 2) Наделение даром слова.

**Интаҗ** انتاج *м. IV.* 1) Нәтиҗә бирү, нәтиҗәле булу. *Мәгарифнең таралуы сәнагатнең тәрәккыйсенә интаҗ итәр.* (К. Нас.) 2) Җитештерү. — *м. IV.* 1) Результативность. 2) Производство, выработка.

**Интибаһ** انتباه *м. VII.* (Томаналыктан) уяну, күз ачу. *Интибаһ дәвере* — уяну чоры. — *м. VII.* Пробуждение.

**Интизам** انتظام *м. VIII.* Тәртиплелек, тәртипле булу, рәтле булу, кагыйдә буенча эш итү. — *м. VIII.* 1) Порядок. 2) Правильность, регулярность.

**Интизар** انتظار *м. VIII.* Зарыгу, зарыгып көтү, күз текәп көтеп тору. *Минем өчен синнән шәфкать булырмы дип бөтен гаскәр тын да алмый интизарда.* (Г. Тук.) — *м. VIII.* Ожидание, поджидание, томительное ожидание.

**Интикад** انتقاد *м. VIII.* 1) Әдәби, фәнни әсәрләрне битараф рәвештә җентекләп тикшерү нәтиҗәсендә җитешсезлекләрне күрсәтү. 2) Тәнкыйть. *Яки уйга калдырадыр интикад, итмәсәм дә мин аңа күп илтифат.* (Г. Тук.) — *м. VIII.* 1) Указание на недостатки литературных и научных трудов. 2) Критика.

**Интикал** انتقال *м. VIII.* 1) Күчү, күченү, (урын) алмаштыру. *Интикал мәкян идеп* — урын алмаштырып. 2) Үлү, дөньядан күчеп китү. — *м. VIII.* 1) Переезд, переход. 2) Кончина, смерть.

**Интикам** انتقام *м. VIII.* Үч алу, ачу кайтару. *Аның күңелендә Закирга карата һичничек интикам итеп булмый торган икътидарсыз ачу хисе кузгалды.* (Ф. Әмир.) — *м. VIII.* Месть, отмщение; реванш.

**Интисаб** انتساب *м. VIII.* Мөнәсәбәтле булу, бәйләнешле булу. 2) Бер нәселнәсәптән булу, кардәш булу. — *м. VIII.* 1) Нахождение в связи, в отношении кому-нибудь. 2) Родственность.

**Интисар** انتشار *м. VIII.* Чәчелү, сибелү. — *м. VIII.* Рассыпание, рассеивание.

**Интисаф** انتصاف *м. VIII.* Яртысына җитү, яртылык. — *м. VIII.* Достижение половины, половинчатость.

**Интифаг** انتفاع *м. VIII.* Файдалану, файда алу, файда күрү. — *м. VIII.* Пользование, использование.

**Интифах** انتفاخ *м. VIII.* Шешү, кабарып, күбеп чыгу, өрелү. — *м. VIII.* Вздутие, опухание; наполнение воздухом.

**Интихаб** انتخاب *м. VIII.* Сайлау, аралап алу, сайлап алу. — *м. VIII.* Выбор, избрание; отбор.

**Интихаби** انتخابی *с.* Сайлау (га бәйле), сайланмалы, сайланып алына торган. — *прил.* Выборный, связанный с выборами.

**Интихал** انتحال *м. VIII.* 1) Әдәби караклык, плагиат. 2) Нигезсез дәлил. — *м. VIII.* 1) Плагиат. 2) Неосновательное утверждение.

**Интихар** انتحار *м. VIII.* Үз-үзен үтерү, үз-үзенә кул салу. — *м. VIII.* Самоубийство.

**Интишар** انتشار *м. VIII.* Таралу, чәчелү; җәелү. *Бу вакыйга бөтен шәһәргә интишар итте.* — *м. VIII.* Распространение.

**Интиһа** انتهاء *м. VIII.* Соң, ахыр, чик, ахырга барып җитү, бетү, тәрәлү. *Гыйлемнең интиһасы юктыр.* (К. Нас.) — *м. VIII.* Конец, окончание, истечение (срока).

**Интиһаз** انتهاز *м. VIII.* Моменттан файдалану, форсатны качырмау. — *м. VIII.* Использование удобного случая, момента.

**Интыйбаг** انطباع *м. VII.* Басылу (типографиядә). — *м. VII.* Отпечаток, оттиск, печатание (в типографии).

**Интыйбак** انطباق *м. VII.* Яраклы булу, килешеп тору, туры килеп тору. — *м. VII.* Соответствие, согласованность, совпадение.

**Инфаз** انفاذ *м. IV.* Үтәү, җиренә җиткерү, эшкә ашыру. — *м. IV.* Исполнение, приведение в исполнение.

**Инфак** انفاق *м. IV.* Тереклек өчен кирәк булганнарны биреп тору; туйдырып тору чыгымнары. — *м. IV.* Расходование, трата, обеспечение.

**Инфигал** انفعال *м. VII.* 1) Әсәрләнү, бер эшкә пошыну; борчылу. 2) Хурлану, гарьләнү. 3) Гомумән һәртөрле тойгы белән тойгылану. *Гаять шиддәтле бер инфигал вә тәэссер эчендә калыр.* (Г. Сәгъ.) 4) *грам.* Фигыль бабларыннан *VII* форма масдар (исем фигыль) үлчәве.

*м. VII.* 1) Огорчение, неудовольствие, досада. 2) Стыд. 3) Выражение различных чувств. 4) *грам.* Форма масдара *VII* породы арабского глагола.

**Инфикяк** انفكاك *м. VII.* 1) Аерылу, кубып төшү. 2) Торган җиреннән аерылу.

*м. VII.* 1) Разъединение отставание. 2) Покидание местожительства.

**Инфирад** انفراد *м. VII.* 1) Ялгызлану, аерым яшәү; аерымлашу, ялгыз калу. 2) Ялгызлык.

*м. VII.* 1) Обособленность. 2) Уединение. 3) Одиночество.

**Инфисад** انفساد *м. VII.* Бозыклык; әшәкелек.

*м. VII.* Испорченность; негодность.

**Инфисал** انفصال *м. VII.* 1) Аерылу. 2) Хезмәт урыныннан китү. 3) Берәүне яки бер урынны ташлап китү.

*м. VII.* 1) Отделение. 2) Удаление, уход (со службы, из партии). 3) Уход (от кого-либо, откуда-либо).

**Инфиҗар** انفجار *м. VII.* 1) Таң ату, таң беленү. 2) (Су) ташу. 3) Шартлау.

*м. VII.* От глагола انفجر (инфәҗәрә) — 1) Заниматься (о заре). 2) Бить, „вытекать" (о ключе). 3) Взрыв, разрыв (снаряда).

**Инфиһам** انفهام *м. VII.* Аңлашылу, аңлану, беленү.

*м. VII.* Быть понятым.

**Инхилал** انحلال *м. VII.* 1) Таркалу. 2) Чишелү, (берәр мәсьәләнең) хәл ителүе.

*м. VII.* 1) Распад, развал, разложение. 2) Разрешение (вопроса).

**Инхина** انحناء *м. VII.* Бөгелү, иелү, бөкрәю, кәкрәю.

*м. VII.* 1) Искривление, изгибание. 2) Кривизна, выгнутость.

**Инхинак** انحناق *м. VII.* 1) Буылу, тончыгу, тын бетү; күкрәк кысу. 2) *мед.* Бума авыруы (астма).

*м. VII.* Удушье. 2) *мед.* Астма.

**Инхираф** انحراف *м. VII.* Тайпылу, авышу, туры юлдан таю; читләшү, читкә китү, дүнү.

*м. VII.* Уклонение, отклонение в сторону.

**Инхисаф** انحساف *м. VII.* Ай тотылу.

*м. VII.* Затмение луны.

**Инхитат** انحطاط *м. VII.* 1) Түбән төшү, түбәнәю. 2) Кимү. 3) Кирегә таба китү.

*м. VII.* 1) Спуск. 2) Убыль. 3) Падение, упадок.

**Инша** انشاء *м. IV.* 1) Барлыкка китерү, кору, салу, төзү. 2) Уйлап табу, уйлап чыгару. *Күперләр вә тимер юллар инша вә тәгъмир кылынды.* (К. Нас.) 3) Үзлегеннән иҗат итеп язу; укылган әсәрнең эчтәлеген күңелдән язу, инша, сочинение. — *м. IV.* 1) Создание, постройка, строительство. 2) Изобретение. 3) Составление, сочинение, изложение.

**Инша алла** انشاءالله *гыйб. дини* Алла теләсә, алла кушса. — *фр. рел.* Если аллаху будет угодно.

**Иншад** انشاد *м. IV.* Шигырь уку, шигырь сөйләү. *Иншад итүче мөләкъкаб дәрдемәнд Акменлаңыз.* (Ак.) — *м. IV.* Декламирование, чтение (стихов).

**Ин шаэ** ان شا *фиг.* Теләсә, әгәр теләсә. *Батыйли ибтальидәр ин шаэ мәмдүд әйләмәз.* (Г. Тук.) — *гл.* Если захочет, если ему будет угодно.

**Иншикак** انشقاق *м. VII.* 1) Ярылу, икегә аерылу. *Камәрләр иншикак итте* (айлар ярылды), *гакыллар шашты гаугадан.* (Г. Тук.) 2) Чатнау. — *м. VII.* 1) Расщепление. 2) Раздвоение. 3) Раскол, трещина.

**Инширах** انشراح *м. VII.* 1) Ачылу, күңел ачылу. 2) Шатлык, сөенеч. *Тәсныйг вә тәзйин белән инша кылынмыш кәлям зиядә иншираx бирер.* (К. Нас.) — *м. VII.* Радость, веселье, довольство.

**Инҗиля** انجلاء *м. VII.* 1) Ачылу, якты булу, яктыру, нур чәчү. 2) Ачыклык. — *м. VII.* 1) Выяснение; прояснение. 2) Ясность.

**Инҗимад** انجماد *м. VII.* Туңу, бозлану, кату, бозга әйләнү. — *м. VII.* Затвердевание, оледенение, замерзание.

**Инһидам** انهدام *м. VII.* Җимерелү, бозылу, ватылу. — *м. VII.* Разрушение; порча.

**Инһизам** انهزام *м. VII.* Җиңелү, җиңелеп чигенү, качу, сафлары бозылып тәртипсез рәвештә качу. — *м. VII.* Поражение; отступление; отход, бегство.

**Ирад** ايراد *м. IV.* 1) Китерү, мисал итеп, дәлил итеп китерү, нәрсәгә булса да таянып яки нәрсәне дә булса күздә тотып сөйләү. *„Аның ишегеннән дә керә, тишегеннән дә керә“, — дәүләте алга барган кемсәнә турында ирад кылыныр.* (К. Нас.) 2) Күчми торган милектән алынган керем, килер. 3) Килер бирә торган мал-мөлкәт. — *м. IV.* 1) Приведение доводов, доказательств, ссылка (на что-либо). 2) Доход, поступление. 3) Имущество, достояние, дающее прибыль, доход.

**Ирадн** ارادى *с.* 1) Теләк(кә), омтылыш (ка бәйләнешле). 2) Ихтыяри. — *прил.* 1) Добровольный. 2) Вольный.

**Ирадә** اراده *м. IV.* 1) Теләү, эстәү, омтылу. 2) Кешедә булган теләү һәм — *м. IV.* 1) Намерение, желание, охота, добрая

ирек-ихтыяр үзлеге. *Тимер кулы, куәтле ирадәсе белән әхвәлне үзе теләгән якка бора.* (Г. Ибр.) — воля. 2) Добровольность.

**Ирадән ля язаль** ارادۀلايزال *гыйб. дини* Алла теләве, алла кушуы. *Бәс моның сәбәбе ... вә багыйсы ирадәи ля язальдер.* (Г. Фәез.) — *фр. рел.* Воля, веление бога.

**Ирәкаә** اراقه *м. IV.* Агызу, түгү. — *м. IV.* Литьё, пролитие.

**Ирәкаэддәм** اراقهالدم *из.* Кан агылу. — *из.* Пролитие крови.

**Ирас** ايراث *м. IV.* 1) Мирас калдыру. 2) Китерү, бирү. 3) Бер нәрсә икенче бер нәрсәнең булуына сәбәп булу. *Якут ташын янда йөртмәк вәкарь вә мәһабәтне ирас кылыр.* (К. Нас.) 4) Берәүне үзенең варисы итеп билгеләү. — *м. IV.* 1) Оставление в наследство. 2) Принос; отдача. 3) Причина порождения. 4) Определение (кого-либо) наследником.

**Ирахә** اراحه *м. IV.* Тындыру, тынычландыру; рәхәтләндерү, ял иттерү, сулу алдыру. — *м. IV.* Отдых, покой; успокоение, облегчение (кому-либо).

**Ираэә** ارائه *м. IV.* Күрсәтү, күрсәтеп өйрәтү, белдерү. — *м. IV.* Показ, показывание, обучение.

**Ирваэ** ارواء *м. IV.* 1) Сугару. 2) Су бирү. *Агыз яшьләрне, кыл төшләрне ирваэ.* (Дәрд.) — *м. IV.* 1) Орошение. 2) Выдача воды.

**Иргаб** ارغاب *м. IV.* Кызыксындыру, кызыктыру. — *м. IV.* Возбуждение желания, интереса.

**Ирза** ارضاء *м. IV.* Ризаландыру, күңелен табу. — *м. IV.* Удовлетворение, ублаготворение, угождение.

**Ирзаг** ارضاع *м. IV.* Сөт имезү, бала имезү, имдерү. — *м. IV.* Кормление грудью

**Ирс** ارث *ис.* 1) Ата-анадан яки башка туганнарыннан калган малга ия булу, мирас ашау. 2) Мирас. 3) *биол.* Ата-анада булган сыйфатның балага күчүе, нәселдән нәселгә күчү. — *сущ.* 1) Наследование. 2) Наследство. 3) *биол.* Наследственность.

**Ирсал** ارسال *м. IV.* Җибәрү. *Китаплар ирсал хакында мәктүб яз.* (М. Ак.) — *м. IV.* Отправка, посылка.

**Ирси** ارثى *с.* 1) Мирас(ка бәйләнешле), мирас рәвешендә күчә торган. 2) Нәселдән нәселгә күчә торган. — *прил.* 1) Унаследованный. 2) Наследственный.

**Ирсән** ارثاً *р.* Мирас рәвешендә, мирас буларак. — *н.* По наследству.

**Иртибат** ارتباط *м. VIII.* 1) Бәйләнеш, бәйләнү, ябышу. 2) Арадагы мөнәсәбәт, — *м. VIII.* 1) Связанность, связь. 2) Взаимосвязь.

элемтә. *Тәм белән зәукъ арасында иртибат бардыр.* (К. Нас.) — взаимоотношение.

**Иртигаб** ارتعاب *м. VIII.* Курку, өркү. — *м. VIII.* Чувство страха, испуг.

**Иртигаш** ارتعاش *м. VIII.* 1) Калтырау, дерелдәү. 2) Көзән җыеру. — *м. VIII.* 1) Дрожь, содрогание. 2) Судорога, конвульсия.

**Иртидад** ارتداد *м. VIII.* 1) Кайту. 2) Кайтару. 3) Диннән чыгу, мөртәд булу. 4) Тоткан юлын, идеясен үзгәртү. *Зогфе хактан хәуф итеп, сез иттеңезме иртидад.* (Г. Тук.) — *м. VIII.* 1) Отход, отступление. 2) Возвращение. 3) Отступничество. 4) Перемена идеи, изменение своих взглядов.

**Иртиза** ارتضا *м. VIII.* Риза булу, ризалык, яхшы дип тану; канәгатьләнү. — *м. VIII.* Признание удовлетворительным, удовлетворение.

**Иртизаг** ارتضاع *м. VIII.* Сөт имү. — *м. VIII.* Сосание груди.

**Иртизак** ارتزاق *м. VIII.* Туклану өчен эшләп ризык табу. — *м. VIII.* Зарабатывание на жизнь; пропитание.

**Иртикаэ** ارتقا *м. VIII.* Ашу, югары күтәрелү, культурада күтәрелү, алга киү, тәрәккъый итү. — *м. VIII.* 1) Постепенное развитие, рост, эволюция. 2) Возвышение; прогресс.

**Иртикяб** ارتكاب *м. VIII.* 1) Гаеп; начар һәм тыелган эшне эшләү, гөнаһка төшү. *Ни кәбаирдер, мисакта рухым иткән иртикяб.* (Дәрд.) 2) Ришвәт алу. — *м. VIII.* 1) Совершение преступления, впадение в грех. 2) Получение взятки.

**Иртифаг** ارتفاع *м. VIII.* 1) Югары күтәрелү, менү. 2) Дәрәҗәгә менү, югары урынга күтәрелү. 3) Югарылык, биеклек, калкулык. — *м. VIII.* 1) Повышение, подъём. 2) Повышение (в должности). 3) Высота; возвышенность.

**Иртифаган** ارتفاعاً *р.* Югарылык ягыннан; күтәрелү ягыннан. — *н.* 1) Высотой, по высоте. 2) По степени (подъёма).

**Иртихал** ارتحال *м. VIII.* 1) Күчү, күчеп китү. 2) *күч.* Үлү, вафат булу, дөньядан күчү. — *м. VIII.* 1) Отправление, отъезд, эмиграция. 2) *перен.* Смерть (переход в другой мир).

**Иртиша** ارتشا *м. VIII.* Ришвәт (взятка) алу. — *м. VIII.* Взяточничество.

**Иртияб** ارتیاب *м. VIII.* 1) Шикләнү, шөбһәләнү, икеләнү. 2) Оялып калу. — *м. VIII.* 1) Сомнение, недоверие, подозрение. 2) Смущение.

**Иртиҗал** ارتجال *м. VIII.* 1) Кинәт илһамлану (алдан хәзерләнмичә, тик үтәү вакытында гына тиз уйлап шигырь — *м. VIII.* 1) Внезапное вдохновение; импровизация. 2) Экспромт.

уку, көй чыгару яки речь сөйләү). 2) Кинәт илһам белән сөйләнгән сүз, шигырь.

**Иртиҗалән** ارتجالاً *р.* Кинәт илһам белән. — *н.* Экспромтом.

**Иртиһан** ارتهان *м. VIII.* Әҗәткә биргәндә берәр әйберен алып калу. — *м. VIII.* Получение залога, заклад.

**Ирфәгъ** ارفع *фиг.* 1) Күтәр. 2) Алып кит. *Ирфәгъ ... ганна бу карангу хаили.* (Күтәр ... бездән бу караңгы пәрдәне.) (Г. Тук.) — *гл.* 1) Подними, возвысь. 2) Сними, удали, убери.

**Ирхас** ارخاص *м. IV.* (Әйбернең) бәясен төшерү, арзанайту, очсызлату. — *м. IV.* Удешевление, снижение (цен).

**Иршад** ارشاد *м. IV.* Юлга салу, туры юлга кертү, юл күрсәтеп җибәрү. — *м. IV.* 1) Наставление на путь истины. 2) Указание, инструкция.

**Иршаднамә** ارشادنامه *гф. ис. дини* Ишанлык документы. *Иршаднамә алыр бу; зәңгәр йортлар салыр бу ...* (Г. Тук.) — *ар.-п. сущ. рел.* Религиозный документ на право быть ишаном.

**Иржагъ** ارجاع *м. IV.* Кире кайтару; аслына кайтару. — *м. IV.* Возврат, возвращение.

**Ирһаб** ارهاب *м. IV.* Куркыту, өркетү. — *м. IV.* 1) Спугнуть. 2) Запугивание, устрашение.

**Исабәт** اصابت *м. IV.* 1) Төз бәрү, төзәгән урынга тию, тидерү. *Галәлгомья фикер йөртми бераз да; исабәтләп бер ук аттым Хиҗазга.* (Г. Тук.) 2) Эштә, сүздә турылыкка, дөреслеккә ирешү. — *м. IV.* 1) Меткость, попадание, поражение. 2) Достижение правдивости в (каком-либо) деле.

**Исагуҗи хан** ایساغوجی‌خوان *гф. ис.* Иске мәдрәсәнең II баскычында укучы. *Бу хәл аның „исагуҗи хан“ заманында „тәүзыйх“ мәсьәләләренә катнашып көлкегә калуларына да сәбәп була иде.* (Г. Ибр.) — *ар.-п. сущ.* Учащийся средней ступени медресе.

**Исаль** ایصال *м. IV.* Тапшыру, илтеп бирү, китереп бирү, ирештерү. — *м IV.* Доставление, доставка.

**Исалә** ایساله *м. IV.* Агызу, кою. *Күз яшьләрен исалә итте.* — *м. IV.* Проливание, излияние.

**Исар** ایثار *м. IV.* 1) Хөрмәтләү, олылау. 2) Юмартлану, үз интересын корбан итеп кешегә ярдәм итү, малны бик юмарт тарату. *Нигъмәтне исар кылмак кирәк.* (К. Нас.) — *м. IV.* 1) Оказывание предпочтения, уважения. 2) Пожертвование, щедрая раздача.

**Исаэ** ایصاء *м. IV.* Васыять әйтү, васыять итеп әйтеп калдыру. — *м. IV.* Оставление завещания, распоряжение.

**Исаэт** اسائت *м. IV*. Начар эш эшләү, усаллык (явызлык, әшәкелек, начарлык) итү. — *м. IV*. Причинение зла.

**Исбат*** اثبات *м. IV*. 1) Фактлар, дәлилләр белән тулысынча ышандырырлык итеп күрсәтү. *Изге, пакь эш белән ант иттеләр, вәгъдәләрен исбат итәргә.* (М. Гаф.) 2) Беркетү. — *м. IV*. 1) Подтверждение, удостоверение, доказывание. 2) Доказательство. 3) Фиксирование.

**Исгад I** اسعاد *м. IV*. 1) Бәхетле итү, бәхетлеләндерү. 2) Бәхет һәм тынычлык тудыру. — *м. IV*. 1) Осчастливить. 2) Создание счастья и мира.

**Исгад II** اصعاد *м. IV*. Югары менү, югары күтәрелү; югары күтәрү. — *м. IV*. Поднятие вверх, подъём.

**Исгаф** اسعاف *м. IV*. Берәүнең үтенүен, сорауларын кабул итеп, аны канәгатьләндерү; уңышлы чыгуына булышлык күрсәтү. — *м. IV*. Оказание помощи, содействие, удовлетворение просьбы.

**Исгаэ** اصغاء *м. IV*. 1) Тыңлау, колак салу. 2) Берәүнең йомышын тыңлау (үтәү), теләгәнен эшләү, кабул итү. — *м. IV*. 1) Слушание, выслушивание. 2) Внимание; исполнение чьей-либо просьбы.

**Исем* I** اسم *ис*. Исем, ат. — *сущ*. Имя; название.

**Исем II** اثم *ис*. Гөнаһ, язык. — *сущ*. Грех, вина, проступок.

**Искаэ** اسقاء *м. IV*. Сугару; эчертү, су бирү, сусавын басу. — *м. IV*. Орошение; утоление чьей-либо жажды.

**Искат** اسقاط *м. IV*. 1) Төшерү, ташлау. 2) Өстеннән алып ташлау (йөкләнгәнне). — *м. IV*. 1) Сбрасывание, свержение. 2) Снятие с себя обязательства.

**Искян** اسكان *м. IV*. Җирләштерү, утраклаштыру, бер буш җирне тора торган җир итү. — *м. IV*. Поселение; расселение, колонизация новых земель.

**Искят** اسكات *м. IV*. 1) Тындыру; сөйләүдән, елаудан туктату. 2) Авызын ябу, каршы сөйләмәслек итү. *Дәлилләр күрсәтеп, бу кяинати идәлем искят.* (Г. Тук.) — *м. IV*. 1) Успокаивание (плачущего, говорящего.) 2) Принуждение к молчанию.

**Ислямиять** اسلاميت *ис*. Мөселманлык. — *сущ*. Исламизм, мусульманство.

**Ислях*** اصلاح *м. IV*. 1) Килештерү, дуслаштыру, яраштыру, араны төзәтү. 2) Үзгәртү, яхшыландыру, реформа ясау. 3) Реформа. *Мәгълүмедер, күптән бирле исляхчы сез, ислях өчен чын күңелдән ихласлы сез.* (Г. Тук.) — *м. IV*. 1) Улучшение отношений, налаживание дружбы. 2) Изменение, улучшение, реформирование. 3) Реформа.

**Исляхат** اصلاحات *ис.* Ислях-ның *к.* *Шәкертләр әллә нинди исляхат өметләре белән дулый башлаган заманда Сабир да тик ятмады.* (Г. Ибр.) — *сущ. мн.* от ислях.

**Исмаг** اسماع *м. IV.* Ишеттерү. — *м. IV.* Доведение до слуха, внушение.

**Исме аләт, исмелаләт** اسم آلت ‖ اسم الآلت *из. грам.* Корал исеме. — *из. грам.* Имя орудия.

**Исме гадәд, исмелгадәд** اسم عدد ‖ اسم العدد *из. грам.* Сан исеме. — *из. грам.* Имя числительное.

**Исме гадәд аслый** اسم عدد اصلى *гыйб. грам.* Микъдар саны. — *фр. грам.* Числительное количественное.

**Исме гадәд тәртиби** اسم عدد ترتيبى *гыйб. грам.* Тәртип саны. — *фр. грам.* Порядковые числительные.

**Исме гайре мөнсариф** اسم غير منصرف *гыйб. грам.* Ике килешле сүз. — *фр. грам.* Двухпадежное имя.

**Исме гам** اسم عام *из. грам.* Күмәклек исеме. — *из. грам.* Имя нарицательное.

**Исме заман (исмелзаман)** اسم زمان *из. грам.* Вакыт исеме. — *из. грам.* Имя времени.

**Исме зат** اسم ذات (اسم الذات) *из. грам.* Әйбер исеме, исем. — *из. грам.* Название предмета; имя существительное.

**Исме истифһам, исмелистифһам** اسم الاستفهام ‖ اسم استفهام *из. грам.* Сорау алмашлыгы. — *из. грам.* Вопросительное местоимение.

**Исме ишарә** اسم الاشاره ‖ اسم اشاره *из. грам.* Күрсәтү алмашлыгы. — *из. грам.* Указательное местоимение.

**Исме кәйфия** اسم الكيفيه ‖ اسم كيفيه *из. грам.* Сыйфат исеме. — *из. грам.* Имя качества.

**Исме ләүн (исмелләүн)** اسم اللون *из. грам.* Төс исеме. — *из. грам.* Имя цвета.

**Исме мәкян** اسم المكان ‖ اسم مكان *из. грам.* Урын исеме. — *из. грам.* Имя места.

**Исме мәфгуль** اسم المفعول ‖ اسم مفعول *из. грам.* Төшем юнәлешендәге сыйфат фигыль. — *из. грам.* Причастие страд. залога.

**Исме мәүсуль** اسم موصول *из. грам.* Мөнәсәбәтлек алмашлыгы. — *из. грам.* Относительное местоимение.

**Исме мөбаләга** اسم مبالغه *из. грам.* Көчәйттерү сыйфаты. — *из. грам.* Усилительные прилагательные

**Исме мөнсариф** اسم منصرف *ст. грам.* Өч килешле сүз. — *сс. грам.* Трехпадежное имя.

**Исме мөштак** اسم مشتق *ст. грам.* Ясалма исем. — *сс. грам.* Производное имя.

**Исме нисбә (исменнисбәти)** اسم النسبه *из. грам.* Нисби сыйфат. — *из. грам.* Относительное, отымённое прилагательное.

**Исме нәуг, исменнәуг** اسم النوع، اسم نوع *из. грам.* Хәрәкәт ысулы исеме. — *из. грам.* Имя образа действия.

**Исме тәсгыйрь** اسم التصغير *из. грам.* Кечерәйтү һәм иркәләү исеме. — *из. грам.* Уменьшительное, ласкательное имя.

**Исме тәфзыйль** اسم التفضيل *из. грам.* Артыклык сыйфаты. — *из. грам.* Прилагательные превосходной степени.

**Исме фагыйль** اسم الفاعل‖اسم فاعل *из. грам.* Хәзерге заман сыйфат фигыль. — *из. грам.* Имя действующего, причастие действительного залога.

**Исме хас** اسم خاص *из.* Ялгызлык исеме. — *из.* Имя собственное.

**Исме җинс (исмелҗинс)** اسم الجنس *из. грам.* Күмәклек исем. — *из. грам.* Нарицательное имя.

**Исмән** اسماً *р.* Исем ягыннан, исеме белән. *Исмән мөдәррис булса да, дәрес биргән юктыр.* (З. Биг.) — *н.* По имени; именем.

**Иснад** اسناد *м. IV.* 1) Берәр эшне яки хәлне бер кешегә кайтарып калдыру. 2) Үз эшен берәүгә сылтау, япсару, башка берәүгә аудару. *Үзенең гаебен икенче кешегә иснад итте.* (К. Нас.) 3) Терәк. — *м. IV.* 1) Приписывание (каких-либо) действий (кому-либо). 2) От гл. سند (сәнәдә)—свалить на кого-либо сделанное самим. 3) Опора.

**Иснагашер** اثناعشر *сан.* Унике. — *ч.* Двенадцать.

**Иснан, иснәтәен** اثنين، اثنان *сан.* Ике. — *ч.* Два.

**Исраг** اسراع *м. IV.* Ашыктыру, җәһәтләтү; чаптыру, юырту, йөгертү. — *м. IV.* Ускорение, убыстрение; потараппливание.

**Исраил** اسرائيل *ис.* Израил (еврейләрнең төп бабаларының исеме). — *и. с.* Израиль.

**Исрар I** اصرار *м. IV.* Үз сүзендә нык тору, үз дигәнен, үзенекен эшләү. *Хәзрәт исрар итте, әйт, оялма диде* (Г. Газиз). — *м. IV.* 1) Настойчивость, упорство. 2) Упрямство.

**Исрар II** اسرار *м. IV.* Яшерү, сер итү. — *м. IV.* Прятание, засекречивание, сообщение по секрету.

**Исраф*** اسراف *м. IV.* Малны урынсыз һәм кирәгеннән артык тоту, әрәм итү. *„Болар исраф итә нишләп“, кала бер көн ирен тешләп.* (Г. Тук.) — *м. IV.* Расточительность; расточительство.

**Исрафил** اسرافیل *ис. дини* Мөселманнар ышануынча, кыямәт көнендә сур (быргы) өрү өчен билгеләнгән фәрештә исеме. — *сущ. рел.* Исрафил (архангел, который, по поверью мусульман, будет трубить о наступлении страшного суда).

**Истибгад** استبعاد *м. X.* Ерак дип белү, ерак санау, ерак күрү; чит күрү; ераксыну. — *м. X.* 1) Признание маловероятным, далёким (от истины). 2) От гл. استبعد (истәбгадә)—считать чужим, далёким.

**Истибдад** استبداد *м. X.* Һичбер законга буйсынмый үзенчә хөкем итү, чикләнмәгән власть, деспотизм, абсолютизм. *Китте җаннар азыгы, һәм кайтты истибдад кире.* (Г. Тук.) — *м. X.* Самовластие, деспотизм, абсолютизм.

**Истибдади** استبدادی *с.* Деспотик, тираник. — *прил.* Самодержавный, самовластный, деспотический.

**Истибдадкяр** استبدادکار *гф. ис.* Һәр эшне үзе теләгәнчә генә йөртүче, деспот, тиран. — *ар.-п. сущ.* 1. Самодержавный, самовластный. 2. Деспот, тиран.

**Истибдадкяранә** استبدادکارانه *гф. ст.* Деспотларча, деспотлар кебек. — *ар.-п. сс.* Деспотически, по-деспотски.

**Истибдал** استبدال *м. X.* 1) Алыштыру, алышу. 2) Үзгәреш. — *м. X.* 1) Мена, размен. 2) Перемена.

**Истибка** استبقاٴ *м. X.* Бер нәрсәнең калуын (саклануын), булып торуын, дәвамын теләү. — *м. X.* Сохранение про запас, хранение (у себя); стремление сохранить.

**Истибра** استبرا *м. X.* Бәвел итү, бәвелдән соң юыну. — *м. X.* Очищение, омовение, приведение себя в порядок.

**Истибрак** استبراق *ис.* Зиннәтле калын ефәк тукыма. *Сөндес* (алтынлы ефәк) *истибрактан ирде хөлләсе.* (Ш. Баб.) — *сущ.* Узорчатая шёлковая ткань; золотая парча.

**Истива** استوا *м. VIII.* 1) Тигезлек. 2) Төзлек. — *м. VIII.* 1) Равенство. 2) Ровность.

**Истигаб** استيعاب *м. Х.* 1) Эченә алу, сыйдыру. 2) Каплап, томалап алу, каплап тору. — *м. Х.* 1) Ёмкость. 2) Охватывание; окутывание.

**Истигазә** استعاذه *м. Х.* 1) Сыену, ялыну, ялвару. 2) *дини* „Әгузе“ дип әйтү. — *м. Х.* 1) Просьба о помощи; мольба. 2) Произнесение слов „боже, упаси“.

**Истиганә** استعانه *м. Х.* Ярдәм итүне үтенү; ярдәм, булышлык сорау. — *м. Х.* Обращение за помощью, просьба о помощи.

**Истигарә** استعاره *м. Х.* 1) Көтәчәккә, бурычка алып тору. 2) Читтән алып куллану. 3) Метафора. *Гарәп сүзләрен куллану Бабич өчен бер истигарә генә икәнен һәркем аңлый.* (Г. Ибр.) — *м. Х.* 1) Взятие взаймы, заём. 2) Использование взятого взаймы. 3) Метафора.

**Истигъдад** استعداد *м. Х.* 1) Сәләтлелек, булдыклылык. *Бер дә тумаслык булып ят, син дә истигъдад кире.* (Г. Тук.) 2) Зирәклек, үткенлек. — *м. Х.* 1) Природная склонность, способность. 2) Проницательность, сметливость.

**Истигъзам** استعظام *м. Х.* Кечкенә бер эш яки хәлне зурайтып, әһәмиятле итеп күрсәтү, зурайту. *Ул авыруын һәрвакыт истигъзам итә.* — *м. Х.* Преувеличение.

**Истигъля** استعلاء *м. Х.* Югарылану, югары ашу, күтәрелү, югары дәрәҗәгә менү, ирешү. *Зиһенне, фикерне истигъля кылыр.* (К. Нас.) — *м. Х.* Возвышение, повышение.

**Истигълям** استعلام *м. Х.* Берәр оешмага берәр нәрсә турында мәгълүмат сорап җибәрелгән язу. — *м. Х.* Запрос, осведомление; требование объяснения.

**Истигъмаль** استعمال *м. Х.* Куллану, тоту, файдалану. *Уру, чабу, сугу вә җилгәрү эшләрендә машина истигъмаль кылынмый иде.* (Г. Ибр.) — *м. Х.* Употребление, использование; применение.

**Истигъна** استغناء *м. Х.* 1) Мохтаҗ булмау, барына канәгатьләнү. 2) Исе китмәү, югарыдан карау. *Хатын истигъна кылып „теләсәм кайда китәрмен“,— диде.* (К. Нас.) — *м. Х.* 1) Материальная обеспеченность, отсутствие нужды. 2) Пренебрежение, равнодушие.

**Истигърәб** استغراب *м. Х.* Гаҗәпләнү, таңга калу, хәйран булу. — *м. Х.* Удивление, изумление.

**Истигърак** استغراق *м. Х.* 1) Чуму (мәс., суга). 2) Төрену. 3) Эш белән күмелү. — *м. Х.* 1) Погружение (напр., в воду). 2) Окутывание. 3) Чрезмерное занятие делами.

**Истигъфа** استعفا *м. Х.* 1) Гафу итүне сорау, гафу эстәү, гафу үтенү. 2) Хезмәттән азат ителү, эштән чыгу. — *м. Х.* 1) Просьба о прощении. 2) Отставка, уход (со службы); выход (из состава).

**Истигъфар** استغفار *м. Х. дини* Гафу итүне, ярлыкауны сорау, „әстәгъфирулла" дию. — *м. Х. рел.* Просьба о прощении, об отпущении грехов.

**Истигъфаф** استعفاف *м. Х.* Начар эшләрдән тыелу, тыелганнарны эшләүдән саклану. — *м. Х.* Воздержание (от всего плохого, запрещённого).

**Истигъҗаб** استعجاب *м. Х.* Гаҗәпләнү; сокланып гаҗәпләнү. — *м. Х.* Удивление; изумление.

**Истигъҗал** استعجال *м. Х.* 1) Ашыктыру, тизләтү, тиз бетүне теләү. 2) Ашыгычлык. — *м. Х.* 1) Ускорение. 2) Поспешность, торопливость.

**Истидамә** استدامه *м. Х.* Бер эш яки хәлнең дәвамы, һаман булып торуы; дәвамлылык, озакка сузылганлык. — *м. Х.* Длительность, продолжительность.

**Истидга** استدعا *м. Х.* 1) Ялынып, ялварып сорау. 2) (Хөкүмәттән) берәр эшнең үтәлүен яки берәр эшкә рөхсәт бирүен үтенү. 3) Таләп итү. — *м. Х.* 1) Просьба, мольба. 2) Прошение; просьба о разрешении. 3) Требование.

**Истидганамә** استدعانامه *гф. ис.* Хөкүмәт органнарына берәр эшнең үтәлүен яки берәр эшкә рөхсәт бирүне сорап биргән язу. — *ар.-п. сущ.* Петиция, прошение, письменный запрос.

**Истидлял** استدلال *м. Х.* 1) (Берәр фактка, дәлилгә таянып) нәтиҗә чыгару. *Берәр адәмдә гакыл булганлыгын аның фигыльләреннән вә холыкларыннан гына истидлял кылып буладыр.* (К. Нас.) 2) Билгеле нәтиҗәгә килү өчен фактлар, дәлилләр китерү. — *м. Х.* 1) Вывод, заключение. 2) Доказывание, приведение доказательств, аргументов.

**Истидлялән** استدلالاً *р.* 1) Берәр фактка, дәлилгә таянып. 2) Нәтиҗә чыгарып. — *н.* 1) Аргументируя. 2) Делая выводы, подводя результаты.

**Истидракь** استدراك *м. Х.* 1) Аңлау, мәгънәсенә төшенү. 2) *фәлс.* Аң. 3) Аңлатма; өстәмә. — *м. Х.* 1) Понимание, установление смысла. 2) *фил.* Сознание. 3) Дополнение, поправка.

**Истизан** استيذان *м. Х.* Рөхсәт сорау. — *м. Х.* Просьба о разрешении, испрошение разрешения.

**Истизах** استيضاح *м. Х.* Ачык итеп аңлатуны таләп итү. — *м. Х.* Просьба о разъяснении, выяснение, запрос.

**Истизахән** استيضاحاً *р.* Ачык итеп аңлатуны таләп итү йөзеннән. — *н.* Добиваясь ясности, изучая (что-либо).

**Истизлял** استظلال *м. Х.* Күләгә астында булу, күләгә астында тору. — *м. Х.* Пребывание в тени.

**Истикамәт** استقامت *м. Х.* Турылык, намуслылык, дөрес юнәлеш, туры юл. *Тик ходай хәзер урынны сайлый ул азмак өчен, әһле дөньяга тышыннан истикамәт күрсәтә.* (Г. Тук.) — *м. Х.* Прямолинейность, прямота, честность, правдивость, правильность.

**Истикбар** استكبار *м. Х.* Үз-үзен олы санау, үзе турында югары фикердә булу, тәкәббер булу. — *м. Х.* Высокомерие, надменность.

**Истикмаль** استكمال *м. Х.* 1) Төгәлләү, эшләп бетерү, тәмам итү. 2) Кимчелекне бетерү, берәр эшнең кимчелексез төгәлләнүе. — *м. Х.* 1) Завершение, заканчивание, доведение до конца. 2) Ликвидация недостатков в чём-либо.

**Истикраһ** استكراه *м. Х.* Җирәнү, чиркану, күңел йөкләмәү. — *м. Х.* Отвращение, брезгливость.

**Истикъбаль** استقبال *м. Х.* 1) Киләчәк, булачак. *Истикъбальләреннән өмет өзгән ник тудым дип елый анадан.* (М. Укм.) 2) Каршы алу, хөрмәтләп каршылау. — *м. Х.* 1) Будущее. 2) Встреча, приём.

**Истикъбали** استقبالی *с.* Киләчәк(кә бәйләнешле.) — *прил.* Будущий, грядущий.

**Истикъбалән** استقبالاً *р.* Киләчәктә, киләчәк заманда. — *н.* В будущем.

**Истикъляли** استقلالی *с.* Бәйсез, иреклe, берәүгә дә буйсынмый торган. — *прил.* Независимый, самостоятельный.

**Истикъляль** استقلال *м. Х.* 1) Бәйсезлек, ирекле лек, берәүгә дә буйсынмаганлык. *Кемнән алдык дин фикрендә истикъляльне, кем ташытты ушбу бәхет, бу икъбальне.* (Г. Тук.) 2) Хөкемдарның үз ихтыяры белән генә эш йөртүе. — *м. Х.* 1) Независимость, самостоятельность. 2) Самовластие (правителя).

**Истикъраз** استقراض *м. Х.* Бурычка акча биреп торуны сорау, процент белән акча алып тору. — *м. Х.* Просьба о займе, заём.

**Истикърар** استقرار *м. Х.* 1) Җирләшү, бер урында утырып калу, урынлашу. 2) Күңел утырту. — *м. Х.* 1) Устройство, поселение. 2) Принятие намерения.

**Истикъраэ** استقراء *м. Х.* 1) Аерым фактларга нигезләп, гомуми нәтиҗә чыгару. 2) Өйрәнү. *Истикъраэ вә тәтәб-* — *м. Х.* 1) Индукция. 2) Исследование, изучение.

*бог кыйлып карасак, телемездә ун төрле тавыш хәрефләре бардыр.* (К. Нас.)

**Истилзам** استلزام *м. Х.* Бер эшнең табигый нәтиҗәсе буларак котылгысыз кирәк булу, лязим булу. *Кичен соңга калып яту соң торуны истилзам итә.*
*м. Х.* Вызывание необходимости (чего-либо), признание необходимым.

**Истиля** استیلا *м. Х.* 1) Басып алу (берәр җирне), сугышып алу. 2) Җәелү, каплап алу. *Елганың суы, ярыннан чыгып, әтрафны истиля итте.* (Х. Чис.)
*м. Х.* 1) Завоевание, овладение, захват. 2) Затопление (берегов реки).

**Истиляи** استیلائی *с.* Истиля(га бәйләнешле).
*прил.* Захватнический.

**Истимаг** استماع *м. VIII.* 1) Тыңлау, колак салу; тыңлап тору. 2) Сүз тыңлау, кушканны эшләү.
*м. VIII.* 1) Слушание; подслушивание. 2) Послушность.

**Истималәт** استمالت *м. Х.* Мәел иттерү, тарту, үзенә карату.
*м. Х.* Привлечение, заманивание; склонение (на свою сторону).

**Истимдад** استمداد *м. Х.* Булышлык итүне үтенү, ярдәм сорау, дошманга каршы тору өчен читтән ярдәм сорау. *Сыйдкы ният белән үкенеп истимдад кылсалар, аларның киткән нигъмәтләрен кайтарыр.* (К. Нас.)
*м. Х.* Просьба о содействии, помощи; просьба о подкреплении.

**Истимляк** استملاک *м. Х.* 1) Кулга кертү, үз милеге итү. 2) Национализация, дәүләт файдасына алу.
*м. Х.* 1) Овладение; захват. 2) Национализация (с выплатой стоимости).

**Истимрар** استمرار *м. Х.* Өзлексезлек, дәвамлылык, озакка сузылу.
*м. Х.* Длительность, непрерывность; продолжительность.

**Истимрари** استمراری *с.* Озакка сузыла торган, дәвамлы.
*прил.* Длительный, продолжительный, беспрерывный.

**Истимтар** استمطار *м. Х.* Яңгыр теләп чыгу.
*м. Х.* Вымаливание дождя.

**Истинад** استناد *м. VIII.* 1) Таяну. 2) Терәк. 3) Берәр нәрсәгә сылтау итеп күрсәтү.
*м. VIII.* 1) Опора (на что-либо). 2) Ссылка на что-либо; указание причины.

**Истинадән** استناداً *р.* Таянып, берәр фактка таянып.
*н.* Опираясь, полагаясь.

**Истинаф** استيناف *м. Х.* 1) Яңадан башлау. 2) Яңа баштан тикшерергә бирү; апелляция. — *м. Х.* 1) Начинание. 2) Апелляция (к вышестоящим судебным органам), обжалование.

**Истинбат** استنباط *м. Х.* (Берәр хәл яки эшне өйрәнеп) хөкем (нәтиҗә) чыгару. *Адәм фикер иясе булып, теләгән нәрсәне ихтираг кыйлыр вә гыйлемне истинбат кыйлыр.* (К. Нас.) — *м. Х.* Вывод, заключение.

**Истинкяф** استنكاف *м. Х.* 1) Кабул итмәү, кире кагу. *Бу хотбәне һәмширәләргә һәм гарыз кылган идем, истинкяф иттеләр* (К. Нас.) 2) Муафыйк күрмәү. 3) Баш тарту, кире чигенү; элек сөйләгәнгә каршы эшләү. — *м. Х.* 1) Отказ, отклонение. 2) Указание на несоответствие. 3) Непокорность, неповиновение; отход.

**Истинсар** استنصار *м. Х.* Ярдәм таләп итү, ярдәм сорау. — *м. Х.* Просьба о помощи.

**Истинсах** استنساخ *м. Х.* Копия алу, икенче нөсхәсен язу. — *м. Х.* Снятие копии; переписка, копирование.

**Истинтаҗ** استنتاج *м. Х.* Нәтиҗә чыгару, йомгак ясау. — *м. Х.* Подведение итогов; резюмирование.

**Истинҗа** استنجا *м. Х.* Тәрәттән соң пакьләнү. *„Мохтасар“да хаез, истинҗа, тәһарәт бар иде.* (Г. Тук.) — *м. Х.* Обмывание после естественных надобностей, подмывание.

**Истирахәт** استراحت *м. Х.* Ял итү, эштән бушап тору; рәхәтләнү. *Яхшы йокладыгызмы, истирахәт кылдыгызмы?* (К. Нас.) — *м. Х.* Отдых; покой.

**Истирдад** استرداد *м. Х.* Үзенә кире кайтаруны сорау, кайтарып бирүне таләп итү. — *м. Х.* Требование возвращения, востребование.

**Истирзак** استرزاق *м. Х.* Ризык табу белән шөгыльләнү. — *м. Х.* Поиски пропитания, средств к существованию.

**Истирхам** استرحام *м. Х.* Ялыну, ялвару; рәхимле булуны, шәфкать итүне сорау. — *м. Х.* Просьба о пощаде, о милосердии.

**Истирҗа** استرجا *м. Х.* Үтенү. — *м. Х.* Просьба, прошение.

**Истирҗаг** استرجاع *м. Х.* Кире кайтаруны сорау. — *м. Х.* Просьба о возвращении.

**Истисгар** استصغار *м. Х.* Кечкенә итеп карау; әһәмият бирмәү. — *м. Х.* Пренебрежение (чем-либо), умаление.

**Истиска** استسقا *м. Х.* Корылыктан яңгыр теләү. — *м. Х.* Мольба о ниспослании дождя.

**Истискал** استثقال *м. Х.* Салкын кабул итү, салкын мөгамәлә итү. — *м. Х.* Холодность, тягость в отношении, обращении.

**Истисна** استثنا *м. Х.* Чыгарма, чыгарып алу, аерып алу. *Хәйләкәр карт мулла тирә-яктагы муллаларны берәм-берәм сугеп чыкты да ахырдан китереп Җәләшне истисна кылды.* (Г. Ибр.) — *м. Х.* Исключение.

**Истисхаб** استصحاب *м. Х.* Үзенә юлдаш итеп алу, чакыру. — *м. Х.* Приглашение в спутники.

**Иститагать** استطاعت *м. Х.* Көч җитү; булдырырга көч җиту, кулдан килү. — *м. Х.* Возможность сделать (что-либо); сила, способность.

**Истифадә** استفاده *м. Х.* Файдалану, куллану, тоту. *Мәхдүмнең яшьлегеннән истифадә итмәкче булды.* (З. Һад.) — *м. Х.* Использование.

**Истифсар** استفسار *м. Х.* Сорап белү, тулы аңлатуны сорау. *Хаҗәтең юкмы дип, истифсар кыйлмадым дип егылаймын, диде.* (К. Нас.) — *м. Х.* Запрос, запрашивание.

**Истифтах** استفتاح *м. Х.* 1) Керешү, башлау. 2) Ачу. 3) Алу, буйсындыру (шәһәрне һ. б.). — *м. Х.* 1) Начинание. 2) Открытие. 3) Покорение (страны), взятие (города, крепости).

**Истифһам** استفهام *м. Х.* 1) Сорап белү, белер өчен сорау. 2) Сорауны белдерә торган сүз. 3) Аңлатуны үтенү. — *м. Х.* 1) Запрос, справка. 2) Вопрос. 3) Просьба об истолковании.

**Истихалә** استحاله *м. Х.* 1) Бер хәлдән икенче хәлгә күчү. 2) Мөмкин булмау, мөмкин булмаучылык. — *м. Х.* 1) Метаморфоза, изменение состояния, превращение, переход в другое состояние. 2) Невозможность.

**Истихарә** استخاره *м. Х.* *дини* Төшлек салу, төшлек салдыру, төш кую (берәр эшнең яхшы яки начар булачагын алдан төштә күреп белү өчен кичтән догалар укып, шуңа ниятләп йокыга яту). *Без... истихарә дә кылып карадык.* (Г. Ибр.) — *м. Х. рел.* Загадывание на сон.

**Истихбар** استخبار *м. Х.* Сорашып хәбәр алу; сорап, тикшереп мәгълүмат алу; информация алу. — *м. Х.* Разузнавание, осведомление, разведывание; сбор сведений, информаций.

**Истихдам** استخدام *м. Х.* 1) Хезмәт иттерү. 2) Хезмәт өчен куллану.

*м. Х.* 1) Привлечение на службу. 2) Использование.

**Истихзар** استحضار *м. Х.* 1) Алга китерү; хәтергә төшерү, искә китерү. 2) Чакырып алу, килүне таләп итү.

*м. Х.* 1) Мысленное представление, воспроизведение (чего-либо) в уме. 2) Вызов; приглашение.

**Истихкак** استحقاق *м. Х.* 1) Лаек булу, лаеклы булу, хаклы булу. 2) Яраклы булу; яраклылык.

*м. Х.* 1) Заслуженность, право (на что-либо). 2) Пригодность, достоинство.

**Истихкар** استحقار *м. Х.* Хур күрү, түбән дәрәҗәле итеп санау, түбән күрү, кимсетү, хурлау.

*м. Х.* Пренебрежение, унижение, презрение.

**Истихкям** استحکام *м. Х.* 1) Ныгайту, таза (чыдамлы) итү. 2) Хәрби ныгытма. *Диләр: госманлы, өч истихкямны кулда тотканда, туктатмас канны.* (Г. Тук.)

*м. Х.* 1) Укрепление, упрочение; прочность; крепость. 2) Крепость, форт.

**Истихкямат** استحکامات *ис.* 1) Истихкям-ның *к.* 2) Фортификация корылмалары.

*сущ.* 1) *мн. от* истихкям. 2) Фортификационные сооружения.

**Истихляс** استخلاص *м. Х.* Котылдыру, коткару, иреккә чыгару.

*м. Х.* 1) Спасание. 2) Освобождение, предоставление воли.

**Истихляф** استخلاف *м. Х.* Берәүне үз урынына билгеләү, үз урынына кую.

*м. Х.* Оставление после себя, оставление (кого-либо) своим заместителем.

**Истихмам** استحمام *м. Х.* Мунча керү, ваннада юыну.

*м. Х.* Купание, принятие ванны, мытьё в бане.

**Истихраҗ** استخراج *м. Х.* 1) Чыгару. *Юлда сызык сызып, киләчәк вакыйгаларны истихраҗ кыла белүче бер хатынга очрадык.* (К. Нас.) 2) Сыгып чыгару. 3) Нәтиҗә чыгару. 4) Чит телдә язылганны укып мәгънәсен чыгару.

*м. Х.* 1) Извлечение, добывание. 2) Выжимание. 3) Резюмирование. 4) Реферирование текста на иностранном языке.

**Истихсаль** استحصال *м. Х.* 1) Тырышып булдыру, хасил итү. 2) Кулга кертү, булдыру.

*м. Х.* Получение (чего-либо), добывание.

**Истихсан** استحسان *м. Х.* Яхшы дип табу, ярату, яхшыга санау.

*м. Х.* Одобрение.

**Истихфаф** استخفاف *м. Х.* 1) Җиңелгә санау. 2) Көлеп карау, кимсетеп карау,

*м. Х.* 1) Считать лёгким. 2) Унижение, насмешка,

әһәмият бирмәү, кимсетү, мыскыллау. *Моның белән син истихфаф голама кыласың.* (Ф. Әмир.) — издевательство; пренебрежение, неуважение.

**Истишарә** استشاره *м. X.* Киңәш, киңәш сорау, киңәш итү. — *м. X.* Консультация, совет.

**Истишмам** استشمام *м. X.* 1) Тою, сизү. 2) Иснәү, иснәп белү. 3) Ис чыгару. — *м. X.* 1) Чувство, ощущение. 2) Вдыхание запахов, обоняние. 3) Выделение запаха.

**Истишһад** استشهاد *м. X.* 1) Шаһит булуны таләп итү, шаһит итеп китерү, шаһит ясау. 2) Исбат өчен дәлилләр, цитаталар китерү. — *м. X.* 1) Приглашение в свидетели, требование свидетельского показания. 2) Цитирование, ссылка.

**Истиэзан** استئذان *м. X.* Рөхсәт сорау. — *м. X.* Просьба о разрешении, позволении.

**Истиҗабә** استجابه *м. X.* Үтенечне кабул итү; уңай җавап бирү. — *м. X.* Исполнение, удовлетворение (просьбы).

**Истиҗазә** استجازه *м. X.* Рөхсәт алу. — *м. X.* Получение разрешения, позволения.

**Истиһда** استهدا *м. X.* Турылыкны (туры юлга төшүне) теләү. — *м. X.* Поиски верного пути, руководство (чем-либо).

**Истиһза** استهزاء *м. X.* Көлү, мыскыл итү, хурлау. *Гадәте я истиһза яки тәхкыйрь; сүз сөйләмәс бирәүне җәрых кылмый.* (Ак.) — *м. X.* Глумление, насмешка, издевательство.

**Истиһляк** استهلاك *м. X.* Әрәм-шәрәм итү, юкка тотып бетерү. — *м. X.* Потребление, расточение, растрачивание.

**Истиһлял** استهلال *м. X.* 1) Башлану. 2) Яңа туган айны күзәтү, күрү. — *м. X.* 1) Начало, вступление. 2) Наблюдение за молодым месяцем.

**Истыйлях** اصطلاح *м. VIII.* Атама, термин. *Алты елда үзгәреп китте лөгать һәм истыйлях.* (Г. Тук.) — *м. VIII.* Специальное выражение, термин.

**Истыйляхат** *ис. к.* — атамалар, терминнар. — *сущ. мн.* Термины.

**Истыйляхи** اصطلاحی *с.* Атама(га бәйләнешле). — *прил.* 1) Идиоматический. 2) Терминологический.

**Итагать*** اطاعت *м. IV.* Буйсыну, карышмау, кушканны эшләү, күндәм булу, сүз тыңлау. *„Һәрвакыт шушы әмерләргә итагатьле бул“... диделәр.* (М. Гаф.) — *м. IV.* Послушание, повиновение; исполнительность.

**Италә** اطاله *м. IV.* Озайту, озынайту, сузу. — *м. IV.* Удлинение; растяжение.

**Итгам** اطعام *м. IV.* Ашату, туйдыру, ризыкландыру. — *м. IV.* Кормление, питание.

**Итлак** اطلاق *м. IV.* 1) Коткару, азат итү. 2) Аеру (хатынны). 3) Исем бирү, атап йөртү. 4) Гафу итү; җәзадан коткару. — *м. IV.* 1) Освобождение. 2) Развод (с женой). 3) Наименование (дать имя кому-либо). 4) Прощение, помилование.

**Итляф** اتلاف *м. IV.* 1) Үтерү, һәлак итү, юк итү. 2) Вату, җимерү, бозу, харап итү. 3) Бушка тотып бетерү, әрәм-шәрәм итү. — *м. IV.* 1) Умертвление, уничтожение. 2) Повреждение, порча, приведение в негодность. 3) Расточение, растрата.

**Итмам** اتمام *м. IV.* Тәмамлау, тәмам итү, эшләп бетерү. *Чөн ул шәйтан эшен итмам идеп кыйлган сөрүрен там* (Г. Чок.) — *м. IV.* Окончание, довершение.

**Итмиэнан** اطمئنان *м. IX.* Имин булу, тынычлану; күңел утырту. — *м. IX.* Спокойствие, уверенность, чувство безопасности, успокоение.

**Итнаб** اطناب *м. IV.* Сүзне озайту, сузу; кирәксез аңлатмалар белән төп фикерне томалап, озын итеп сөйләү. — *м. IV.* Преувеличение, проявление чрезмерности (напр., в речах); многословность.

**Иттибаг** اتباع *м. VIII.* Буйсыну, иярү (берәр фикергә). — *м. VIII.* Повиновение; следование (за кем-либо).

**Иттибаган** اتباعاً *р.* Ияреп, иярү белән. *Иттибаган куп намәшруг нәрсәләр пәйда булмыштыр.* (К. Нас.) — *н.* Следуя (за кем-либо или чему-либо).

**Иттигаз** اتعاظ *м. VIII.* Үгетне (вәгазьне) кабул итү. — *м. VIII.* Выслушивание нравоучения, увещевания, наставления.

**Иттика** اتقاء *м. VIII.* 1) Саклык күрсәтү. 2) Тыелганнардан саклану, тәкъвалык. *Хәмер миңа харам булсын, дип иттика кылды.* (К. Нас.) — *м. VIII.* 1) Принятие мер предосторожности. 2) Избегание (чего-либо недозволенного).

**Иттикан** اتقان *м. VIII.* Ачык белү, анык белү. — *м. VIII.* Достоверное знание (чего-либо).

**Иттилягъ** اطلاع *м. VIII.* 1) Төшенү, белү, аңлау. 2) Югарыдан түбәнгә карау, күзәтү. 3) Туу (кояш). — *м. VIII.* 1) Понимание, знание. 2) Наблюдение. 3) Восход (солнца).

**Иттисал** اتصال *м. VIII.* 1) Тоташу, ялгану. 2) Якын булу, кушылу. — *м. VIII.* 1) Соединение, контакт. 2) Общение, связь, отношение.

**Иттисалән** اتصالاً *р.* Тоташып, ялганып, кушылып. *Музыка авазына иттисалән тәганни кылды.* (К. Нас.) — *н.* Общаясь, связываясь; в такт.

**Иттисам** اتسام *м. VIII.* Тамга салу, тамгалау, keләймә сугу. — *м. VIII.* Клеймение (скота).

**Иттисаф** اتصاف *м. VIII.* Сыйфатлану, берәр сыйфатка ия булу. — *м. VIII.* Отличие; обладание (какими-либо) качествами, свойствами.

**Иттифак** اتفاق *м. VIII.* Бер сүздә (бер киңәштә) булу, союз. *Кояш, яңгыр әле бу көнгә чаклы бозып эш кыйлмыйлар бу иттифакны.* (Г. Тук.) — *м. VIII.* Союз, единодушие, согласие.

**Иттифакан** اتفاقاً *р.* 1) Бердәм, бер авыздан, бергәләшеп. 2) Очраклы рәвештә. *Бу мәсәл өмид итмәгән кешедән касдан яки иттифакан бер яхшы тәдбир яки бер яхшы эш садир булганда әйтелер.* (К. Нас.) — *н.* 1) Единодушно. 2) Случайно.

**Иттифакый** اتفاقی *с.* Очраклы, очраклы рәвештә. *Кисмәк өстенә кара кош иттифакый кунган ул.* (Г. Тук.) — *прил.* Случайный.

**Иттихад** اتحاد *м. VIII.* 1) Фикер бердәмлеге. 2) Берләшү, бер фикердә булып эш итү. — *м. VIII.* 1) Единство взглядов. 2) Объединение, союз.

**Иттихади** اتحادی *с.* 1) Берләшү(гә бәйләнешле). 2) Федератив. — *прил.* 1) Союзный, входящий в состав союза. 2) Федеративный.

**Иттихаз** اتخاذ *м. VIII.* Алу, кабул итү; кулга алу. — *м. VIII.* Принятие; взятие.

**Иттиһам** اتهام *м. VIII.* Ялган бәла тагу; гаепле итеп күрсәтү; гаепле итү. — *м. VIII.* Обвинение, подозрение.

**Итфаэ** اطفا *м. IV.* Утны сүндерү, янгынны бастыру. — *м. IV.* Тушение (огня).

**Итхаф** اتحاف *м. IV.* Бүләк итеп бирү, багышлау. — *м. IV.* Дарение, одаривание.

**Ифа** ایفا *м. IV.* Эшне, бурычны үтәү, башкару, җиренә җиткерү, башкарып чыгу, җитештереп төгәлләү. *Мин өстемдә булган икмәк-тозыңның хакын ифа кылмак өчен касдән җөрьәт иттем, диде...* (К. Нас.) — *м. IV.* Исполнение, выполнение; претворение в жизнь; полное завершение (какого-либо дела).

**Ифадә** افاده *м. IV.* 1) Аңлату, аңлатып бирү. *Сүз һәрникадәр күңелдә булган мәксудны ифадә кылмакта васый-* — *м. IV.* 1) Разъяснение, объяснение, изложение. 2) Способ изложения, объяснения.

*та булса да, күзнең ифадәсе кадәр юктыр.* (К. Нас.) 2) Аңлату юлы, әйтелеш, сүз сөреше.

**Ифадәи мәрам** افادۀمرام *ф. из.* Теләкне (максатны) аңлату. — *п. из.* Изложение цели, желания.

**Ифадәи тәхририя** افادۀتحريريه *ф. из.* Язып аңлату. — *п. из.* Письменное объяснение.

**Ифакать** افاقت *м. IV.* 1) Авырудан терелү. 2) Авырудан терелә башлаудан тулысынча терелеп бетүгә кадәр булган вакыт. 3) Һуш китүдән, исереклектән айну. *Һушы китте, ифакать кылганнан соң әйтде...* (К. Нас.) — *м. IV.* 1) Улучшение здоровья, выздоровление. 2) Период выздоровления. 3) Вытрезвление.

**Ифатә** افاته *м. IV.* Качыру, ычкындыру, югалту. — *м. IV.* Упущение, потеря.

**Ифляс** افلاس *м. IV.* Бөлү, бурычын түли алмау. — *м. IV.* Банкротство, крах, разорение; несостоятельность.

**Ифлях** افلاح *м. IV.* 1) Хәвеф-хәтәрдән котылу. 2) Теләгән уңышка ирешү, рәхәтлеккә ирешү. — *м. IV.* 1) Избежание бедствия. 2) Успех, преуспевание; достижение благоденствия.

**Ифна** افنا *м. IV.* Юк итү, юкка чыгару, әрәм итү. — *м. IV.* Уничтожение, истребление.

**Ифнаи гомер** افناٴعمر *ф. из.* Бушка уздырган гомер. — *п. из.* Напрасно проведённая жизнь.

**Ифрад** افراد *м. IV.* Ялгызлык, ялгыз яшәүчелек. — *м. IV.* 1) Обособление, уединение. 2) Одиночество.

**Ифраз** افراز *м. IV.* Бүлеп алу, аерып алу. — *м. IV.* Выделение, отделение.

**Ифрат*** افراط *м. IV.* Чамадан тыш, чиктән тыш, үлчәүсез, чамасыз, үтә, бик. — *м. IV.* 1) Чрезмерность, излишество, неумеренность. 2) Чрезмерно.

**Ифсад** افساد *м. IV.* 1) Җимерү, вату, эштән чыгару. 2) Бозу, аздыру. — *м. IV.* 1) Порча; разрушение; вывод из строя. 2) Разложение, развращение.

**Ифта** افتا *м. IV. дини* Фәтва бирү (бер эшнең дини караштан дөрес яки дөрес булмавын күрсәтү). — *м. IV. рел.* Издание фетвы, функция муфтия.

**Ифтар** افطار *м. IV. дини* Уразада авыз ачу. 2) Авыз ачу мәҗлесе. — *м. IV. рел.* 1) Прекращение поста, разговение. 2) Угощение при разговении.

**Ифтикар** افتقار *м. VIII.* 1) Үзенең фәкыйрьлеген, мохтаҗлыгын, ярлылыгын тоеп тору. 2) Фәкыйрьлек, ярлылык.

*м. VIII.* 1) Ощущение своей бедности, нужды. 2) Бедность, нужда.

**Ифтира** افترا *м. VIII.* Яла ягу, берәү өстенә ялган гаеп ташлау. *Чыкмый мәйданга хакыйкать ифтира, бөһтан белән...* (З. Ер.)

*м. VIII.* Клевета, измышление, инсинуация.

**Ифтирак** افتراق *м. VIII.* Аерылу, аерылышу. *Чөнки иттем ифтирак җанымлә, җананемлә бән...* (Г. Тук.)

*м. VIII.* 1) Расставание. 2) Раскол.

**Ифтирас** افتراص *м. VIII.* Уңайлы момент күзәтү, нәүбәт көтү.

*м. VIII.* Ожидание удобного случая, момента.

**Ифтитах** افتتاح *м. VIII.* Ачу, башлап керешү, башлап җибәрү.

*м. VIII.* Открытие, начало (чего-нибудь).

**Ифтихар** افتخار *м. VIII.* 1) Мактану. 2) Горурлану. **Багыйс ифтихар** — мактануга сәбәп. *Җаһилең дошманлыгыйлә ифтихар итмәк кәрәк.* (Г. Тук.)

*м. VIII.* 1) Хвастовство, похвальба. 2) Горделивость; кичливость.

**Ифша** افشا *м. IV.* 1) Фаш итү, мәйданга чыгару, халык арасына чыгару. 2) Яшерен серне ачу.

*м. IV.* 1) Разоблачение; обнародование. 2) Разглашение (тайны).

**Ифһам** افهام *м. IV.* Аңлату, белдерү.

*м. IV.* Объяснение, разъяснение.

**Ихалә** احاله *м. IV.* Бер эшне икенче берәүгә авыштыру, тапшыру, йөкләтү.

*м. IV.* Передача, перепоручение; вручение; обязательство.

**Ихата*** احاطه *м. IV.* 1) Койма, киртә. 2) Тирәли корып алу. 3) Тирәли күз күреме җирләр.

*м. IV.* 1) Ограда, ограждение. 2) Охват. 3) Простор, пространство.

**Ихафә** اخافه *м. IV.* Куркыту, өркетү, шүрләтү, куркуга төшерү.

*м. IV.* Устрашение, запугивание.

**Ихбар** اخبار *м. IV.* 1) Хәбәр бирү, хәбәр итү, белдерү. 2) Аңлату.

*м. IV.* 1) Сообщение, извещение, уведомление. 2) Объяснение.

**Ихван** اخوان *ис.* 1) Туганлык, карендәшлек. 2) Туганнар, кардәшләр. 3) Дуслар, иптәшләр, фикердәшләр.

*сущ.* 1) Братство. 2) Братья. 3) Друзья, единомышленники.

**Ихвәт** اخوت *кара:* ихван.

*см.* Ихван.

**Ихда** احدى *сан* 1) Бер. 2) Ялгыз, бер.

*ч.* 1) Одна. 2) Одинокая.

**Ихдас** احداث *м. IV.* 1) Яңа бер нәрсә чыгару. 2) Иҗат итү.

*м. IV.* 1) Нововведение. 2) Создание; изобретение.

| | |
|---|---|
| **Ихзар** احضار *м. IV*. Хәзерләү, әзерләү, бар итү, хәзерләп кую. | *м. IV*. Приготовление, изготовление. |
| **Ихлял** اخلال *м. IV*. Бозу, кимчелек китерү, зарар китерү. | *м. IV*. Нарушение; порча, повреждение. |
| **Ихляс*** اخلاص *м. IV*. 1) Керсез күңел, турылык, риясызлык, ихлас. *Янган йөрәк белән чын ихлястан тәбрик итәм изге юлыңны.* (М. Гаф.) 2) Күңел кую. | *м. IV*. 1) Искренность, чистосердечие, откровенность, преданность. 2) Привязанность к чему-либо. |
| **Ихлясан** اخلاصا *р*. Керсез күңелдән, чын күңелдән. | *н*. Чистосердечно, откровенно. |
| **Ихляте әрбәга** اخلاطاربعه *ст*. (Борынгы медицина карашы буенча) җанлы организмны төзүче дүрт элемент: кан, үт, кара үт һәм селәгәй-яшь. | *сс*. (По представлению древней медицины) четыре составных элемента живого организма (кровь, жёлчь, чёрная жёлчь и слизь). |
| **Ихмирар** احمرار *м. IV*. Кызыл төскә керү, кызару, кызылаю. | *м. IV*. Покраснение. |
| **Ихнак** احناق *м. IV*. Буып үтерү. | *м. IV*. Удушение. |
| **Ихраз** احراز *м. IV*. Казану, ирешү. | *м. IV*. Достижение, приобретение, получение, овладевание. |
| **Ихрак** احراق *м. IV*. Яндыру, утка ату; ут төртеп яндыру. | *м. IV*. Сожжение, уничтожение, поджог. |
| **Ихрам** احرام *ис*. 1) *дини* Хаҗилар өсләренә кия торган япма, өреткеч, кием. 2) Җәймә, чаршау, япкыч. | *сущ*. 1) *рел*. Ихрам (одежда, одеваемая при вступлении паломниками на священную землю). 2) Покрывало, занавес. |
| **Ихраҗ** اخراج *м. IV*. Чыгару (казып чыгару, сыгып чыгару, тышка чыгару, читкә, чит илгә чыгару). | *м. IV*. Выведение, вытаскивание (выкапывание, выжимание, вывод и т. д.). |
| **Ихса** احصا *м. IV*. 1) Исәпләү, хисаплау, санау. 2) Сан алу. | *м. IV*. 1) Исчисление, счёт; вычисление. 2) Статистика. |
| **Ихсан** احسان *м. IV*. Ярдәм, булышлык, изгелек итү. *Әйтсәң әйт Габделлатиф хаҗины бер ихсанчы дип! Тик тәэссеф, бу хаҗи да „Ишми куштаннарча" бит.* (Ш. Баб.) | *м. IV*. Совершение добрых дел; благодеяние. |

**Ихсас I** احساس *м. IV.* 1) Тою, хис итү, сизү. 2) Хис, тойгы; кичереш. *м. IV.* 1) Чувствование, ощущение, восприятие. 2) Чувство; переживание.

**Ихсас II** احصاص *м. IV.* Өлеш чыгару, өлеш бирү. *м. IV.* Деление на части, выделение доли.

**Ихтар** اخطار *м. IV.* 1) Берәүнең хәтеренә китерү, исенә төшерү. 2) Алдан белдереп кую, искәртү; кисәтү, дикъкатен тарту. 3) Искәртмә. *м. IV.* 1) Напоминание. 2) Извещение, уведомление, предупреждение. 3) Осведомление.

**Ихтибас** احتباس *м. VIII.* 1) Тотылу, тоткарлану. 2) Әгъзаларның нормаль эшләмәве. *Ихтибасе нәфәс* — сулыш ала алмау, буылу. *м. VIII.* 1) Задержка. 2) Ненормальное функционирование членов.

**Ихтива** احتوا *м. VIII.* Эченә алу, үз эченә җыю. *м. VIII.* Охват; содержание, заключение в себе.

**Ихтидад** احتداد *м. VIII.* 1) Тиз ачулану, тиз кабынып китү. 2) Кабынып китүчәнлек, ачуланучанлык. *м. VIII.* 1) Раздражение. 2) Раздражительность, вспыльчивость.

**Ихтизар** احتضار *м. VIII.* Үлү дәрәҗәсендә авыру булу; үлем алды, гаргарә хәле, соңгы сулыш хәле. *м. VIII.* Агония, последние минуты жизни, умирание, угасание.

**Ихтикар** احتقار *м. VIII.* Хурлау, мыскыл итү, кимсетү. *м. VIII.* Презрение, пренебрежение; унижение.

**Ихтикяр** احتكار *м. VIII.* 1) Спекуляция максаты белән җыю. 2) Спекуляция белән шөгыльләнү. *м. VIII.* 1) Скупка. 2) Занятие спекуляцией.

**Ихтиляль** اختلال *м. VIII.* 1) Баш күтәрү, фетнә, бунт ясау. *Син, түрә Габделгазиз, бар, ихтиляльләрне бетерт, торма һич вөҗдан, иман дип, бар мөселманны үтерт.* (Ш. Баб.). 2) Чуалыш ясау, башбаштаклык ясау. *м. VIII.* 1) Бунт, восстание. 2) Смута, расстройство, дезорганизация.

**Ихтилят** اختلاط *м. VIII.* 1) Аралашу, катнашу, якыннан танышу. 2) Дуслык. *м. VIII.* 1) Общение, сношение; смешивание. 2) Дружба.

**Ихтиляф** اختلاف *м. VIII.* 1) Каршылыклы булу, берлек булмау; оешмау, фикер башкалыгы; үзара килешмәүчелек. 2) Дау, ызгыш. *Минә бөтен ихтиляф бетте дә: „ышандыралар икән, мин аларча булам“.* (Ф. Әмир.) *м. VIII.* 1) Разногласие, противоречие, несогласие. 2) Скандал; ссора.

**Ихтиляҗ** اختلاج *м. VIII.* 1) Калтырау, дулкынлану; дерелдәү. 2) Күзән җыеру. *м. VIII.* 1) Содрогание, волнение, дрожь. 2) Судорога, конвульсия.

**Ихтимал*** احتمال *м. VIII.* Мөмкин булу, булуы мөмкин.

*м. VIII.* Вероятность, возможность, предположение.

**Ихтималят** احتمالات *ис.* Ихтимал-ның *к.*

*сущ. мн.* от ихтимал.

**Ихтимар** احتمار *м. VIII.* Әчетеп кабарту, әчеп кабару.

*м. VIII.* Брожение (теста).

**Ихтинак** اختناق *м. VIII.* Буылу, тын бетү, тончыгу.

*м. VIII.* Удушение; асфиксация, удушье.

**Ихтираг** اختراع *м. VIII.* Уйлап чыгару, яңа нәрсә уйлап табу. *Әхмәт электрик фаслында берничә кәшфият вә ихтирагысы белән мәшһүр...* (Ф. Әмир.)

*м. VIII.* Изобретение, открытие.

**Ихтирагат** اختراعات *ис. к.* Уйлап табып чыгарылган әйберләр.

*сущ. мн.* Открытия, изобретения.

**Ихтирагый** اختراعى *с.* Уйлап табыла торган әйбер(ләргә бәйләнешле); уйлап табыла торган.

*прил.* Относящийся к изобретению, открытию.

**Ихтираз** احتراز *м. VIII.* 1) Саклану, саклык белән эш итү, сак булу. 2) Саклык. *Бу дөньяда өч кешедән ихтираз: бере аксак, бере сукыр, бере таз* (борынгы мәкаль).

*м. VIII.* Осторожность.

**Ихтиразән** احترازاً *р.* Сакланып, саклык йөзеннән.

*н.* Осторожно, с опаской.

**Ихтирак** احتراق *м. VIII.* Яну, янып китү, янып көл булу.

*м. VIII.* Горение, сгорание; превращение в пепел.

**Ихтирам*** احترام *м. VIII.* 1) Хөрмәтләү, олылау, санга санау. 2) Хөрмәт.

*м. VIII.* 1) Уважение, почёт. 2) Почести.

**Ихтирамән** احتراماً *р.* Хөрмәт йөзеннән, хөрмәтләп, олылап, кадерләп.

*н.* Почтенно, с почестями.

**Ихтирас** احتراص *м. VIII.* Бик комсыз булу, комсызлык.

*м. VIII.* Жадность, алчность.

**Ихтираф** احتراف *м. VIII.* 1) Эштә зур тәҗрибәле булу. 2) Һөнәр сайлап алу.

*м. VIII.* 1) Профессиональная практика. 2) Выбор ремесла, профессии.

**Ихтисаб** احتساب *м. VIII.* 1) Хисап бирү, отчёт бирү. 2) Соңыннан исәпләшергә тиешле булу.

*м. VIII.* 1) Отчётность; исчисление. 2) Подотчётность.

**Ихтисам** احتصام *м. VIII.* Дошманлык итешү, ачуланышу.

*м. VIII.* Ссора, пререкание, вражда, препирательство.

**Ихтисар** اختصار *м. VIII.* 1) Кыскарту. 2) Сөземтә чыгару, резюме ясау.

*м. VIII.* 1) Сокращение; краткость. 2) Резюмирование.

**Ихтисас I** اختصاص *м. VIII.* 1) Белгечлек. 2) Бер эшнең яхшы белгече булу.

*м. VIII.* 1) Профессия, специальность; специализация (в труде). 2) Хороший специалист, мастер своего дела.

**Ихтисас II** احتساس *м. VIII.* Хис итү, сизү, тою, күңел белән сизенү.

*м. VIII.* Чувствование, ощущение, восприятие.

**Ихтисасый** اختصاصی *с.* Берәр әйбергә хас булган; бер фән белгечлеге(нә бәйләнешле), специфик, махсус.

*прил.* Свойственный чему-либо; специфический, специальный.

**Ихтитаб** احتطاب *м. VIII.* Утын хәзерләү, утын җыю.

*м. VIII.* Заготовка дров.

**Ихтитам** اختتام *м. VIII.* 1) Тәмамлану, төгәлләнү. *Шигъръ вирдем* (шигырьгә бирдем) *ихтитам намеңне китманымлә бән.* (Г. Тук.) 2) Бетү.

*м. VIII.* 1) Заключение, заканчивание. 2) Окончание.

**Ихтифа** اختفا *м. VIII.* Яшеренү, кеше күзенә күренми качып тору, күздән югалу.

*м. VIII.* Исчезновение; скрывание; прятание; маскировка.

**Ихтифаль** احتفال *м. VIII.* 1) Мөһим бер вакыйга мөнәсәбәте белән җыелу. 2) Тантаналы хөрмәт күрсәтү; бәйрәм итү.

*м. VIII.* 1) Собрание, стечение (народа). 2) Торжество, празднество, церемониал.

**Ихтишам** احتشام *м. VIII.* Бик купшылык, бик зиннәтле, бик тантаналы күренеш.

*м. VIII.* Пышность, великолепие; торжественный вид.

**Ихтияр*** اختيار *м. VIII.* 1) Ирекле булу, теләгәнен итү. 2) Ирек. 3) Сайлап алу. *Ике юлның берен ихтияр идәчәк иде.* (З. Һад.)

*м. VIII.* 1) Самостоятельность, полномочие. 2) Воля, свобода. 3) Выбор; предпочтение.

**Ихтияри*** اختیاری *с.* Ирекле, үз ирегенә бәйләнешле.

*прил.* 1) Вольный. 2) Добровольный.

**Ихтиярән** اختیاراً *р.* Ирекле рәвештә, үзе теләп, үз ирәге белән.

*н.* Добровольно.

**Ихтият** احتياط *м. VIII.* 1) Саклык, сакланып эш итү. *Ихтият ягын тотарга кирәк — дип боларга да кәгазь ябыштырып куйды.* (Ф. Әмир.) 2) Кирәккә ярар дип калдырылган нәрсә.

*м. VIII.* 1) Осторожность, предосторожность, мера предосторожности. 2) Оставленный на всякий случай, запас.

**Ихтиятан** احتياطاً *р.* Сакланып, алай-болай булмагае дип саклык күрсәтеп.

*н.* На всякий случай, из предосторожности.

*Нәҗеслегә беленмәгәнлек сәбәпле шөбһәледер, ихтиятан укымаска тиеш.* (З. Һад.)

**Ихтиятый** احتياطى *с.* 1) Саклык белән эш итә торган. 2) Саклыкка калдырылган нәрсә(гә караган). — *прил.* 1) Осторожный. 2) Запасный, резервный.

**Ихтияҗ*** احتياج *м. VIII.* Мохтаҗлык, кирәклек, ихтыяҗ. *Ихтияҗын гарыз итеп килсә теләнче капкаңа, каты сүзләр берлә инсаниятен син таптама.* (Г. Тук.) — *м. VIII.* Потребность, необходимость, нужда (в чём-либо).

**Ихтияҗат** احتياجات *ис.* Ихтияҗ-ның *к.* — *сущ. мн.* от ихтияҗ.

**Ихтиҗаб** احتجاب *м. VIII.* 1) Пәрдәләнү, өретелү, каплану. 2) Яшерү, яшеренү. — *м. VIII.* 1) Закрываться покрывалом. 2) Укрывание, скрывание.

**Ихтиҗам** احتجام *м. VIII.* Тәннән кан алдыру. — *м. VIII.* Кровопускание.

**Ихфа** اخفاء *м. IV.* 1) Яшерү, яшертен эшләү, саклану, саклык күрсәтү. 2) *миф.* Кеше күзенә күренми йөрү. *Әбү-Гали-Сина, ихфага кереп, падишаһ сараенда тора иде.* (К. Нас.) — *м. IV.* 1) Скрывание, прятание, утаивание. 2) *миф.* Способность быть невидимым.

**Ихья** احيا *м. IV.* 1) Терелтү, тергезү, җанны кире кертү. 2) Аякка бастыру, торгызу, элекке хәленә кайтару. *Кем һава вә һәвәсенә табигъ булмас, ул мөрәүвәт вә инсаниятне ихья кыла.* (К. Нас.) 3) Берәр төрле тойгыны уяту, хәтердә яңарту. 4) Яңадан кору, яңарту. — *м. IV.* 1) Оживление, воскрешение, возрождение. 2) Восстановление, возвращение в прежнее состояние. 3) Воспоминание. 4) Обновление.

**Ихьяи әрыз** احياارض *из.* Җир яңарту (ташлаган чәчү җирен яңадан чәчәрлек хәлгә китереп яңарту). — *из.* Восстановление плодородия заброшенного земельного участка.

**Ишага** اشاعه *м. IV.* 1) Фаш итү. 2) Бер хәбәрне халык арасына тарату, җәю. — *м. IV.* 1) Разоблачение. 2) Разглашение, обнародование.

**Ишарә*** اشاره *м. IV.* 1) Ымлау, изәү. 2) Билге, галәмәт, тамга. 3) Турыдан-туры әйтмичә читләтеп әйтелгән сүз. *Карьянең адыны „н" хәрефе белән ишарә идәлем.* (М. Ак.). — *м. IV.* 1) Жестикуляция; махание. 2) Знак, сигнал, указание. 3) Намёк, иносказательное выражение.

**Ишбаг** اشباع *м. IV.* 1) Туйдыру. 2) *шигъ.* (Шигырьнең үлчәвен тотыру өчен сүзгә берәр артык) аваз өстәү. *Бәетнең ахыргы хәрефе ишбаг өчен мөстәгъмәлдер* (К. Нас.) — *м. IV.* 1) Насыщение; пропитывание. 2) *поэт.* Отделка слога, прибавление звука или тщательное произношение.

**Ишгаль I** اشغال *м. IV.* 1) Шөгыльләнү; берәр төрле эш, уй белән мәшгуль итү. 2) Биләү. *Хатын-кызлар аның бөтен димагасын ишгаль иткәннәр иде.* (Ф. Әмир.) — *м. IV.* 1) Занять (кого-либо чем-либо). 2) Оккупация, занятие.

**Ишгаль II** اشعال *м. IV.* 1) Яктырту. 2) Ялкынландыру, яндыру. — *м. IV.* Освещение. 2) Зажигание, воспламенение.

**Ишгар** اشعار *м. IV.* Белдерү, язма рәвештә белдерү, язу белән хәбәр итү. — *м. IV.* Сообщение, уведомление (письменное).

**Ишкял** اشكال *м. IV.* Кыенлык, тоткарлык, мөшкиллек. — *м. IV.* Трудность, затруднение.

**Ишраб** اشراب *м. IV.* Эчерү, эчертү. — *м. IV.* Напоение, пропитывание.

**Ишрак** اشراق *м. IV.* 1) Яктыру, яктырту, нурлану, нурландыру. 2) Нур. *Аягыңның аклыгы башмагыңның кызыллыгына ишрак биреп тора.* (К. Нас.) 3) Кояш чыгу. — *м. IV.* 1) Освещение, облучение. 2) Сияние, блеск; луч. 3) Восход солнца.

**Ишракь** اشراك *м. IV.* Мәҗүсилек, күп аллаларга ышану. — *м. IV.* Язычество, многобожие.

**Иштибаһ** اشتباه *м. VIII.* 1) Шикләнү, шик тоту, шөбһәләнү. 2) Аера алмаслык дәрәҗәдә бер-беренә охшау. — *м. VIII.* 1) Сомнение, подозрение. 2) Неразличимое сходство.

**Иштигаль I** اشتعال *м. VIII.* Ялкынлану, кабынып китү. — *м. VIII.* Горение, воспламенение.

**Иштигаль II** اشتغال *м. VIII.* Шөгыльләнү, бер эш белән шөгыльләнү. *...үземдәге куәтне канәгатьләндерерлек һичбер эш вә иштигаль таба алмый идем.* (Г. Ибр.) — *м. VIII.* Занятие (чем-либо).

**Иштидад** اشتداد *м. VIII.* Көчәю, көчәеп китү. — *м. VIII.* Усиление, укрепление.

**Иштикак** اشتقاق *м. VIII.* 1) Ярып алу. 2) *грам.* Тамыр яки нигез фигыльдән башка фигыль төркемчәләре ясау, сүз ясау. *Бер фигыль камилән иштикак кылынса, йөзгә кадәр фигыль хасил булыр.* (К. Нас.) — *м. VIII.* 1) Отделение, разделение. 2) *грам.* Словообразование; этимология.

**Иштикя** اشتكا *м. VIII.* Зарлану, шикаять итү, жалоба. *Халкымыздан иштикя киттеңезме тәңрия.* (Г. Тук.) — *м. VIII.* Жалоба.

**Иштималь** اشتمال *м. VIII.* 1) Төрү. 2) Эченә алу, эченә алган булу, эчендә булу. — *м. VIII.* 1) Завёртывание (во что-либо). 2) Охват, содержание в себе.

**Иштимам** اشتمام *м. VIII.* Иснәү; бер әйбернең исен иснәп белү. — *м. VIII.* Ощущение запаха, нюхание.

**Иштиракь** اشتراك *м. VIII.* 1) Уртак булу, катнашу; бергәләп эшләү, уртак эшләү. *Бохара вә башка җирләрдән иштиракь итүчеләр бар.* (Ш. Кам.) 2) Уртаклык. — *м. VIII.* 1) Участие; совместная работа; общее дело. 2) Общность, совместность.

**Иштираэ** اشتراٴ *м. VIII.* Сатып алу. — *м. VIII.* Покупка.

**Иштиякъ** اشتياق *м. VIII.* Күрәсе килү, сагыну, юксыну. — *м. VIII.* Желание увидеть; стремление; тоска по любимой.

**Иштиһа** اشتها *м. VIII.* 1) Теләк. 2) Ашау теләге булу, ашыйсы килү. — *м. VIII.* 1) Желание. 2) Аппетит.

**Иштиһад** اشتهاد *м. VIII.* Танык, шаһит китерү. — *м. VIII.* Приведение (кого-либо) в свидетели.

**Иштиһар** اشتهار *м. VIII.* Данлыклы булу, атаклы булу, дан тоту, шөһрәтле булу. — *м. VIII.* Известность, знаменитость, слава, популярность.

**Иэтиляф** ائتيلاف *м. VIII.* 1) Ияләшү, күнегү, үз итү, дуслашу. 2) Союз, коалиция. *Алланың хәбле дидекем иэтиляф.* (Г. Тук.) — *м. VIII.* 1) Привычка, дружба. 2) Согласие, союз, коалиция.

**Иҗабе кабул** ايجاب‌قبول *гыйб.* 1) Өйләнешүчеләрнең алу-барулары турында ризалыкларын белдерүләре. 2) Никях булганчы егет белән кызны алдан ярәштереп кую. *...вәгъдә бүләген китерерсең, бер-ике көннән үк иҗабе кабул итәрбез.* (Г. Кам.) — *фр.* 1) Согласие молодых на брак. 2) Сговор, помолвка.

**Иҗаби** ايجابى *с.* Уңай, уңайлы, уңышлы. *Революция хәрәкәтенең үсешендә иҗаби роль уйнаган әсәрләр булдылар.* (М. Җәл.) — *прил.* 1) Положительный, утвердительный (об ответе). 2) Позитивный.

**Иҗабәт** اجابت *м. IV.* 1) Кабул итү. 2) Колак салу, риза булу. 3) Яхшы, уңай җавап бирү. — *м. IV.* 1) Принятие. 2) Согласие. 3) Утверждение; положительный ответ.

**Иҗад*** ايجاد *м. IV.* Иҗат, барлыкка китерү, бар итү, уйлап табу, яңа нәрсә уйлап чыгару. — *м. IV.* Создание, открытие, изобретение, творчество.

**Иҗади*** ايجادى *с.* Иҗади, барлыкка китерә торган, уйлап табу(га бәйләнгән). — *прил.* Творческий.

**Иҗаз** ايجاز *м. IV.* 1) Кыска сөйләү. 2) Кыскарту. — *м. IV.* 1) Краткость, лаконичность. 2) Сокращение.

**Ижазәт** اجازت *м. IV*. Рөхсәт, рөхсәт бирү, берәр эш итәргә ирекле итү. *Дидем: „Әй күңелем, ижазәт бир миңа"*. (Мөхм.) — *м. IV*. Разрешение, позволение.

**Ижазәтнамә** اجازتنامه *гф. ис*. 1) Рөхсәт язуы. 2) Аттестат, диплом. — *ар.-п. сущ*. 1) Письменное разрешение. 2) Диплом, аттестат.

**Ижарә** اجاره *м. IV*. Вакытлы файдалану өчен хак түләп алу, вакытлы файдалану. *Рус өендә ике бүлмә ижарәя алмыш иде*. (М. Ак.) — *м. IV*. Наём, аренда; временное использование.

**Ижбар** اجبار *м. IV*. Җәберләү, мәҗбүр итү, көчләп ризаландыру, көчләп эшләтү. *Чит якларга чыгып йөрергә ижбар итәрлек эшләр булмаганга*... (Г. Ибр.) — *м. IV*. Принуждение, обязывание.

**Ижлял** اجلال *м. IV*. Олылау, хөрмәтләү. — *м. IV*. Почитание, почтение, уважение, почёт.

**Ижляс** اجلاس *м. IV*. Утырту. — *м. IV*. Усаживание, посадка.

**Ижлаэ** اجلاء *м. IV*. 1) Сөрү, берәр җиргә сөреп җибәрү. 2) Китү. — *м. IV*. 1) Изгнание. 2) Уход, удаление.

**Ижмаг** اجماع *м. IV*. 1) Җыю, туплау. 2) Бер сүзгә (бер карарга) килү. — *м. IV*. 1) Сбор, скопление. 2) Решение, соглашение.

**Ижмал** اجمال *м. IV*. Кыскартып, җыеп кына сөйләү, конспектлау. *Ул хикәянең ижмале шулдыр*. (К. Нас.) — *м. IV*. Краткое изложение, краткий обзор; конспектирование.

**Ижмали** اجمالى *с*. Кыскача, кыска рәвештә, кыскартылган; җыйнак. — *прил*. Суммарный, общий, обобщающий, совокупный; сжатый.

**Ижмалән** اجمالاً *р*. Кыскартып, кыскача итеп, кыска итеп, җыеп кына. — *н*. В общих чертах, вкратце, сжато.

**Ижраэ** اجراء *м. IV*. 1) Үтәү, эшкә ашыру; җиренә җиткерү. *Буның энҗе тешләре арасыннан чыккан һәрбер сүзе һичбер тәкәллефсез ижраэ кылынып, җиренә җиткерелеп торгандыр*. (М. Гаф.) 2) Агызу. — *м IV*. 1) Совершение, выполнение. 2) Пролитие, проливание.

**Ижтиза** اجتزا *м. VIII*. 1) Өлеш алу, өлеш аеру. 2) Канәгатьләнү. *Боныңлә ижтиза иттем кифаять*. (Г. Тук.) — *м. VIII*. 1) Получение доли; выделение части из целого. 2) Удовлетворение.

**Ижтимаг** اجتماع *м. VIII*. 1) Җыелу, туплану, бер урынга килеп туплану. — *м. VIII*. 1) Собрание, сходка, скопление; ми-

2) Кушылу. *Ижтимаг итмәс зина берлән гыйна.* (Г. Тук.) — тинг. 2) Встреча; соединение.

**Ижтимаг зыйддәен** اجتماع ضدين *гыйб.* Ике каршылыкның бергә җыелуы. *Ижтимаг зыйддәен мохаль дигән булалар.* (Ф. Әмир.) — *фр.* Соединение двух противоположностей.

**Ижтимаг нәкыйзәен** — *кара:* ижтимаг зыйддәен. — *см.* Ижтимаг зыйддәен.

**Ижтимагый*** اجتماعى *с.* Җәмәгать (кә), җәмәгатьчелек(кә), җәмгыять (кә бәйләнешле). — *прил.* Социальный, общественный.

**Ижтинаб** اجتناب *м. VIII.* Саклану, үзен сак тоту, сак булу, тыелу. *Димәк улыр ижтинаб әз ихтилаф...* (Г. Тук.) — *м. VIII.* Осторожность; избегание, воздержание.

**Ижтисар** اجتسار *м. VIII.* Батырлану, гайрәтләнү, курыкмау. — *м. VIII.* Храбрость.

**Ижтиһад*** اجتهاد *м. VIII.* Тырышу, эшкә күңел биреп эшләү, тырышлык. *Тир белән тапсын ашарын, итсен әлбәт ижтиһад.* (Г. Тук.) — *м. VIII.* Старание, усердие, прилежание.

**Ижһар** اجهار *м. IV.* Кычкырып уку, кычкырып сөйләү. — *м. IV.* Громкий разговор, громкое чтение.

**Иһам** ايهام *м. IV.* Шөбһәләндерү, икеләндерү, шикләндерү. — *м. IV.* Двусмысленность, аллегория, введение в заблуждение, внушение ложного представления.

**Иһанәт** اهانة *м. IV.* 1) Санга санамау, кимсетү, хурлау. *Ихсан кылган кешене иһанәт кылма.* (К. Нас.) 2) Исе китмәү. — *м. IV.* 1) Пренебрежение, оскорбление. 2) Равнодушие, хладнокровие.

**Иһда** اهدا *м. IV.* Бүләк итеп бирү, бүләк җибәрү. *Сәламнәребезне иһда идәмез.* (З. Биг.) — *м. IV.* Дарение.

**Иһдам** اهدام *м. IV.* Җимерү, вату, юк итү. *Милләте иһдам идән, игъдам идән шунлар имеш.* (Г. Тук.) — *м. IV.* Разрушение; слом, снос.

**Иһдар** اهدار *м. IV.* 1) Ваемсызлык. 2) (Берәр нәрсәгә) әһәмият бирмәү. — *м. IV.* 1) Беззаботность (в чём-либо). 2) Пренебрежение (чем-либо).

**Иһляк** اهلاك *м. IV.* Һәлак итү, юк итү, харап итү. — *м. IV.* Гибель, уничтожение.

**Иһмаль** اهمال *м. IV.* Салкын карау; санга алмау, җиңелгә санау, игътибарсызлык күрсәтү, әһәмият бирмәү. *Вә тәхсыйли дә тәгълими иттегез иһмаль.* (Г. Тук.) — *м. IV.* 1) Пренебрежение, небрежное отношение, невнимание. 2) Небрежность, упущение.

**Иһтида** اهتدا *м. VIII.* Туры юлга керү, турылыкка ирешү. — *м. VIII.* Нахождение верного пути.

**Иһтизаз** اهتزاز *м. VIII.* 1) Тетрәү, калтырау. 2) Тибрәнү, селкенү, дулкынлану. — *м. VIII.* 1) Колебание, вибрация. 2) Дрожание, волнение.

**Иһтимам** اهتمام *м. VIII.* 1) Кайгырту, карау. *Ашамак һәм эчмәктә аслан иһтимам юктыр.* (К. Нас.) 2) Бик тырышып (күңел биреп) эшләү, кызыксыну. *...Карт бик зур иһтимам илә сүз башлады.*. (Г. Ибр.) — *м. VIII.* 1) Забота, озабоченность. 2) Старание; заинтересованность; вдохновение, энергичность.

# Й

**Йосыф** يوسف *ис.* 1) Күркәмлек, матурлык иясе. 2) *ял. ис.* Йосыф. — *сущ.* 1) Красивый, привлекательный. 2) *и. с.* Иосиф.

**Йәздан (язьдан)** يزدان *ис.* Барлыкка китерүче, алла. *Ушал көн кем, сине йәздан яратты.* (Хөрәз.) — *сущ.* Бог, господь.

**Йөбүсәт** يبوست *ис.* Корылык, дымсызлык, кипкәнлек. — *сущ.* Засуха, бездождье.

**Йөмна** يمنى *ис.* 1) Уң кул. 2) Уң як. — *сущ.* 1) Правая рука. 2) Правая сторона.

**Йөмум** يموم *ис. к.* 1) Диңгезләр. 2) Елгалар, дәрьялар. — *сущ. мн.* 1) Моря. 2) Большие реки.

**Йөсер** يسر *ис.* 1) Җиңеллек, ансатлык. 2) Байлык, мул тормыш, рәхәтлек. — *сущ.* 1) Лёгкость, простота. 2) Благосостояние, достаток, богатство.

**Йөсра** يسرا *ис.* 1) Җиңеллек. 2) Сул кул. — *сущ.* 1) Лёгкость. 2) Левая рука.

# К

**Кясәлис** کاسه‌لیس *ф. ис.* Тәлинкә ялаучы, ялагай. — *п. сущ.* Блюдолиз, подхалим.

**Кятиб** کاتب *сф.* 1) Язучы, язу белән шөгыльләнүче. 2) Секретарь. *Мәҗлестә төлке кятиб, бүре рәис.* (М. Гаф.) — *пр. д.* 1) Пишущий. 2) Писец. 3) Писатель, журналист. 4) Секретарь.

**Кятибин** کاتبین *ис.* Кятиб-нең *к.* — *сущ. мн.* от кятиб.

**Кятим** کاتم *сф.* Серен кешегә сөйләмәүче, сер саклаучы, яшерүче. — *пр. д.* Скрывающий, утаивающий.

**Кяф** کاف *ис.* ك хәрефенең исеме. — *сущ.* „Кяф“ — название буквы „к“.

**Кяфи** کافی *сф.* Җитәрлек, тиешле, кирәкле кадәр. *Бу дәлил Фәтхулла хәзрәткә кяфи тоелды.* (Ф. Әмир.)
*пр. д.* Достаточный, удовлетворительный.

**Кяфил** کافل *сф. кара:* кәфил.
*см.* Кәфил.

**Кяфир** کافر *сф.* 1) Танымаучы, белмәүче. 2) Күргән яхшылыкны онытучы, яхшылыкны белмәүче, аш кадерен, аш хакын белмәүче. 3) *дини* Алланы бер дип танымаучы, мөселман булмаган кеше. 4) Алласыз. *Газизәгә күзе төшмәсен тагын, кяфир.* (Ш. Кам.)
*пр. д.* 1) Отвергающий, непризнающий. 2) Непризнательный, неблагодарный. 3) *рел.* Неверующий, нечестивый, неверный. 4) Безбожник, гяур.

**Кяфиранә** کافرانه *гф. р.* Кафирләрчә, кяфир кебек.
*ар.-п. н.* Безбожно, как безбожник.

**Кяфирстан** کافرستان 1) Кяфирләр (мөселман булмаган кешеләр) яши торган ил. 2) Кяфирстан (а) Азиядә элек Һиндстан, Афганстан, Урта Азия белән чиктәш булган бер мәмләкәт; б) Көнчыгыш Африканың көньяк өлешендә Зәнзибардан Өмет Борынына кадәр булган җир).
1) Страна, где живут неверные (немусульмане). 2) Кяфирстан (а) название государства, находившегося в прошлом на границе России с Афганистаном и Индией; б) название страны Кафров в Юговосточной Африке)

**Кяфур** کافور *ис.* 1) Камфара. *Кяфурдин аграк беләкләрең, әлләрең* (кулларын) *хәрирдән йомшак имде.* (К. Гал.) 2) *күч.* Ак төс; хуш ис.
*сущ.* 1) *бот.* Камфарное дерево. 2) Камфара. 3) *перен.* Белый цвет; благовоние.

**Кяффә** کافه *ис.* Бөтен, бары, һәммә, барлыгы.
*сущ.* 1) Совокупность. 2) Всё.

**Кяффәтән** کافة *р.* Тулысынча, бөтенләй, бөтенесе белән.
*н.* В совокупности, полностью, целиком.

**Кяш** کاش *ф. ым. кара:* кяшки.
*см.* Кяшки.

**Кяшанә** کاشانه *ф. ис.* 1) Оя, кош оясы. 2) Өй, тору урыны.
*п. сущ.* 1) Гнездо. 2) Дом, обитель.

**Кяшиф** کاشف *сф.* Ачучы, мәйданга чыгаручы, элек булмаган яңа бер нәрсәне уйлап табучы.
*пр. д.* Открывающий, обнаруживающий, изобретающий.

**Кяшки** کاشکی *ф. ым.* Эх, әгәр дә! (бик нык теләп тә булмавына пошынуны белдерә торган ымлык сүзе). *Кяшки белеме булсачы!*
*п. межд.* О, если бы! хотя бы! (употребляется для выражения крайнего сожаления).

**Кяһил** کاهل *сф.* Ялкау, иренчәк, мыштырдык, хөштер. *Кәсеп вә кяр кыйл, та кяһил улмаясән.* (Г. Фәез.)
*пр. д.* Неповоротливый, ленивый, медлительный.

**Кяһин** کاهن *сф.* Киләчәктән хәбәр бирүче, багучы, фалчы, күрәзәче.
*пр. д.* Предсказатель, гадальщик, провидец.

**Кә** ك *тер. кара*: кәл. — *см.* Кәл.

**Кәбаб*** كباب *ис.* Куырдак, куырма. *Гыйшык уты белән йөрәге кәбаб улып...* (К. Нас.) — *сущ.* Кебаб (рубленое мясо, изжаренное на огне).

**Кәбаир** كبائر *ис.* Кәбир-нен *к.* „**Гөнаһе кәбаир**" — олы гөнаһлар. — *сущ. мн. от* кәбир. **Гөнаһе кәбаир** — грехи великие.

**Кәбир, кәбирә** كبير، كبيره *с.* 1) Олы, зур, дәү, өлкән, бөек. 2) Мөһим. — *прил.* 1) Большой, огромный; великий. 2) Важный, серьёзный.

**Кәбисә*** كبيسه *ис.* Феврале 29 көннән килә торган ел. — *сущ.* Високосный (год).

**Кәбәд** كبد *ис.* 1) Бавыр. 2) Үзәк, йөрәк. — *сущ.* 1) Печень. 2) Середина; сердце.

**Кәбәш** كبش *ис.* Тәкә, куй тәкәсе. — *сущ.* Баран.

**Кәбүтәр** كبوتر *ф. ис.* Күгәрчен. — *п. сущ.* Голубь.

**Кәвакиб** كواكب *ис. к.* Йолдызлар. — *сущ. мн.* Звёзды.

**Кәвакиб сәйярә** كواكب سياره *ст.* Планеталар. — *сс.* Планеты.

**Кәвен** كون *ис.* 1) Булу, барлыкка килү. 2) Барлык галәм, космос. — *сущ.* 1) Бытие, существование, состояние. 2) Мировое пространство, вселенная, космос.

**Кәгыб** كعب *ис.* Тубык, тубык сөяге. — *сущ.* Лодыжка.

**Кәгъбә** كعبه *ис.* 1) Мәккә шәһәрендә борынгы бер гыйбадәтханә булып, мөселманнар гыйбадәт кылганда йөзләрен шуңа таба юнәлтәләр. 2) *күч.* Тоткан юл, идея, алга куелган максат. *Үз кәгъбәсенә ирешү юлында әллә ничаклы җирдән урап йөреп һәляк булган талантлы шагыйрь Бабич.* (Г. Ибр.) 3) *күч.* Сөйгән кыз. — *сущ.* 1) Кааба (мусульманский храм в г. Мекке). 2) *перен.* Цель, идея. 3) *перен.* Любимая девушка, возлюбленная.

**Кәдбану** كدبانو *ф. ис.* Хуҗа хатын, бикә, ханым. *Йә кәдбанў, нә сәбәптән хәтерең тар, җәмалең саригъ улмыш, нә госсаң вар.* (К. Гал.) — *п. сущ.* Хозяйка, дама, госпожа, барыня.

**Кәдәр** كدر *ис.* Кайгы, хәсрәт, көенеч, сагыш. *Кәдәрдән хали булмаен үткән көнгә тәәссеф кыйлынур.* (К. Нас.) — *сущ.* Беспокойство, горе, печаль.

**Кәдү** كدو *ф. ис.* Кабак (яшелчә). — *п. сущ.* Тыква, кабачок.

**Кәдүрәт** كدورت *ис.* Кайгылы булу, көенү, борчылу. — *сущ.* Горе, неприятность.

**Кәеф*** كيف *ис.* 1) Күңел торышы, күңел хушлыгы дәрәҗәсе. 2) Хозур, күңеллелек. 3) Саулык, сәламәтлек.

*сущ.* 1) Хорошее расположение духа, настроение, веселье; удовольствие, наслаждение, довольство. 2) Здоровье

**Кәеф-сафа** كيف‌صفا *ст.* Хозурлану, типтерү. *Байларның кәеф-сафада йөрүләре һаман да күз алдымда торалар.* (М. Гаф.)

*сс.* Пир, гулянье.

**Кәза, кәзалик** كذا، كذالك *алм.* Шулай, шулай ук, тагы, тагы да, яңадан, кабат, шуның кебек. *Кәсебкяр булмакыгызга сәбәп кәзалик үзегездер.* (М. Ак.)

*мест.* Так, так же, таким образом, вот такой

**Кәззаб** كذاب *ис.* Бик ялганчы, бик алдакчы.

*сущ.* 1) Весьма лживый 2) Лжец, обманщик.

**Кәзым** كظم *м. I.* Ачу йоту, ачу килгәндә үзен кулга алу, үзенә хуҗа булу.

*м. I.* Сдерживание, обуздывание гнева; проявление сдержанности.

**Кәйд** كيد *ис.* Хәйлә, мәкер, алдау.

*сущ.* Обман, козни, махинация.

**Кәйф** كيف *ис. кара:* кәеф.

*см.* кәеф.

**Кәйфият** كيفيت *ис.* 1) Бер әйбернең үзенчәлекле хәле (рәвеше). *Камыл төрле кәйфиятьтә буладыр: түгәрәк, өч кырлы, дүрт кырлы камыл.* (К. Нас.) 2) Бер вакыйганың ничек булу сурәте (рәвеше). *Бу кәйфиятьтә Маһруй хәстәханәдә ике җомга микъдар сырхап ятты.* (З. Биг.)

*сущ.* 1) Качество, состояние, свойство (предмета). 2) Образ, форма (события).

**Кәйфә** كيف *алм.* Ничек? *Кәйфә халәкә?* — хәлең ничек?

*мест.* Как, каким образом?

**Кәл** كل *тер.* Кебек, шикелле. *Кәл матари* — янгыр кебек. *Безә күстәрдегез һиммәт йөреп ашларга кәл әнгам.* (Г. Тук.)

*союз.* Подобно; как; словно как.

**Кәлб** كلب *ис.* Эт.

*сущ.* Собака.

**Кәлим** كليم *с.* Аңа сүз сөйләнгән, үзенә сөйләгәнне тыңлап торучы.

*прил.* Слушающий, собеседник.

**Кәлимә** كليمه *ис.* Сүз.

*сущ.* Слово.

**Кәлисә** كليسه *ис.* Чиркәү. *Санки (гүя) гыйшкың бер кәлисә, бән аның накусиһм.* (Г. Тук.)

*сущ.* Церковь

**Кәллә** کله *ф. ис.* Баш. — *п. сущ* Голова.

**Кәлял** کلال *ис.* Ару, талу, талчыгу, хәлдән таю, алжу. — *сущ.* Усталость, утомление.

**Кәлям** کلام *ис.* Сүз, сөйләм. — *сущ.* Связные слова, фраза, речь, разговор.

**Кәлямулла** كلام الله *ст. дини* Алла сүзе, Коръән. *Ул хәзер алган „Сабах“-тан бер кәлямулла сатып...* (Г. Тук.) — *сс. рел.* Коран, „слово божье“.

**Кәма** کما *тер.* Ничек... шулай; ничек булган булса, шулай. — *союз.* Как, равно как...

**Кәмаль** کمال *ис.* 1) Житешкәнлек, тулылык, өлгергәнлек, булуы житкәнлек, пешкәнлек. *Кеше үзен-үзе таныса кәмаль гакылы шуннан беленер.* (К. Нас.) 2) Кимчелексез, тулы, бөтен. — *сущ.* 1) Полнота, законченность, совершенство. 2) Без недостатков; совершенный.

**Кәмаләт** کمالت *ис. кара:* кәмаль. *Кәмаләтең бөек синең Өммекәмаль.* (Ш. Баб.) — *сущ. см.* Кәмаль.

**Кәма янбәгый** كماينبغى *гыйб.* Ничек кирәк, шулай; тиешле рәвештә. *Җинаятьләре өчен кәма янбәгый җәзасын алмыш.* (З. Биг.) — *фр.* Как следует, как необходимо; так, чтобы; как надлежит.

**Кәма һүә** كماهو *гыйб.* 1) Нәкъ үзе, нәкъ шул, шуның шикелле үк, бөтенләй шул. 2) Ничек булган шулай. *Кәма һүә тәфсыйл вә бәян кылды.* (З. Биг.) 3) Бөтенләй тулысынча, баштанаяк, кирәгенчә. — *фр.* 1) Как раз, точно так, так же. 2) Как оно есть. 3) Полностью; совершенно.

**Кәминә** کمینه *ф. с.* 1) Ким, түбән дәрәҗәле; хур. 2) Яшерен. — *п. прил.* 1) Малый; ничтожный; позорный. 2) Скрытый.

**Кәммая** کمایه *ф. с.* 1) Суммасы аз. 2) Заты түбән, бәясез, кыйммәте юк, арзан. — *п. прил.* 1) Обладающий недостаточным капиталом; несостоятельный. 2) Недостойный, дешёвый, неблагородный.

**Кәмьяб** کمیاب *ф. с.* Сирәк очрый торган, аз була торган, аз табыла торган. — *п. прил.* Трудно находимый, редкостный, редкий, уникальный.

**Кәмәнд** کمند *ф. ис.* Бау, аркан. *Ул кичә Таһир Зөһрәнең сараена килеп, кәмәнд илән юкар чыкты; Зөһрә таң аткан вакытта Таһирны ефәк кәмәнд илә җиргә иңдерде.* (Ә. У. К.) — *п. сущ.* Аркан, лассо.

**Кәмәр*** کمر *ф. ис.* Билбау, эзәр. *п. сущ.* Пояс, кушак.

**Кәнар** کنار *ф. ис.* 1) Кырый, чит. 2) Яр чите, елга буе, диңгез кырые. *Сәламәтлек кирәк булса диңгезгә керמә, ул кәнарда торыр димешләр.* (Г. Фәез.) 3) Як. *п. сущ.* 1) Край. 2) Берег (реки, моря), край (дороги и т. п.). 3) Сторона.

**Кәнд** کند *ф. ис.* 1) Шәһәр, ныгытмалы шәһәр. 2) Ныгытма, крепость. *Әйтелде шәһре Болгар кәндләрендә.* (М. Кол.) *п. сущ.* 1) Город, поселение. 2) Крепость, цитадель.

**Кәнеж** کنج *ис. Кара*: гәнеж. *сущ. см.* Гәнеж.

**Кәнизәк*** کنیزه ک *ф. ис.* Кол хатын, җария. *п. сущ.* Рабыня, невольница.

**Кәрамәт** کرامت *ис.* 1) Хөрмәтлелек, затлылык. 2) Кадер, хөрмәт. 3) Изге кешеләр тарафыннан күрсәтелгән гадәттән тыш хәл, могҗиза. *Ишанның кәрамәте күп ашап тиз сеңдермәктер.* (З. Һад.) 4) Юмартлык. *сущ.* 1) Честь, достоинство, престиж. 2) Почесть, уважение. 3) Чудо. 4) Щедрость, великодушие, благородство.

**Кәраһиять** کراهیت *ис. кара:* кәраһәт. *сущ. см.* Кәраһәт.

**Кәраһәт** کراهت *ис.* Чиркәнү, җирәнү, көчләнеп эшләү. *сущ.* Отвращение, антипатия, ненависть.

**Кәраһәтән** کراهتاً *р.* Җирәнеп, чиркәнеп, мәкруһ күреп. *н.* С отвращением, с ненавистью.

**Кәрб** کرب *ис.* Борчылу, эч пошу; кайгы, хәсрәт. *сущ.* Горесть, скорбь, печаль, тоска, мука.

**Кәрван*** کروان *ф. ис.* Юлчылар төркеме, мал йөртүчеләр төркеме. *п. сущ.* Караван.

**Кәрван кыйран** کروانقیران *ф. ст.* Таң йолдызы, Чулпан йолдызы. *п. сс.* Утренняя звезда; Аврора.

**Кәрдигяр** کردگار *ф. ис.* Бар итүче, тәнре. *Яри бирсә ул яраткан кәрдигяр.* (Мөхм.) *п. сущ.* Творец, создатель.

**Кәрим** کریم *с.* 1) Юмарт, рәхимле, киң күңелле. 2) Хөрмәтле, кадерле, бөек, газиз. *прил.* 1) Щедрый, великодушный, благородный, милостивый, любезный. 2) Почтенный, великий; уважаемый; дорогой.

**Кәримәнә** کریمانه *р.* 1) Кадер (хөрмәт) иясенә лаек рәвештә. 2) Юмартлык белән. *н.* 1) Великодушно, благородно. 2) Щедро.

**Кәримә** كريمه *с.* 1) Кәрим-нең *мнс.* 2) Атаның кызы. *Кәримәгез Фәхрияне дә балам кебек сөя идем.* (З. Һад.) — *прил.* 1) *жен.* от кәрим. 2) Дочь.

**Кәриһ** كريه *с.* Чирканыч, җирәнеч, шыксыз, сөйкемсез, кыяфәтсез. *Синең миндә кәриһ күргән нәрсәң бар'* (К. Нас.) — *прил.* Противный, неприятный, отвратительный, ненавистный.

**Кәриһелмәнзарә** كريه‌المنظره *из.* Шыксыз кыяфәтле, ямьсез төсле, җирәнеч күренешле. — *из.* Человек с отвратительным видом; неприятный, противный.

**Кәриһеннәфәс** كريه النفس *из.* Сулышы, авызы исле. — *из.* Зловонное дыхание, дурной запах изо рта.

**Кәриһә** كريهه *с.* Кәриһ-нең *мнс.* — *прил. жен.* от кәриһ.

**Кәррар** كرار *с.* Атакалаучы, һөҗүм итүче. — *прил.* Атакующий, нападающий.

**Кәррат** كرات *ис. к.* Кат-кат, әллә ничә тапкыр, бик күп тапкыр. — *сущ. мн.* Многократно; много раз.

**Кәррат вә мәррат** كرات و مرات *гыйб.* Күп тапкырлар һәм күп мәртәбәләр, бик күп тапкыр, бик күп мәртәбә, әллә ничә кат. *Гарәп вә гаҗәм хәкимнәренең кәррат вә мәррат тәҗрибә кыйлынмыш дүрт сүзләре бардыр.* (К. Нас.) — *фр.* Многократно, очень часто.

**Кәррә** كر *ис.* 1) Тапкыр, кат. *Кем чакырып бер кәррә сыйласа, аңа җир биреп...* (З. Һад.) 2) (Бер) һөҗүм, контратака, һөҗүмгә каршы һөҗүм. — *сущ.* 1) Раз. 2) (Одно) нападение, контратака.

**Кәрәм** كرم *ис.* Юмартлык, сорамастан бирү; киң күңеллелек. *Я, ашка да, чәйгә дә кәрәм боерыгыз.* (З. Биг.) — *сущ.* Щедрость, великодушие, благородство.

**Кәрәмкяр** كرمكار *гф. с.* Киң күңелле, рәхимле, шәфкатьле, ярдәмле, юмарт, игелекле. — *ар.-п. прил.* Щедрый, великодушный, благородный, милостивый.

**Кәрәмкяри** كرمكارى *гф. ис.* Киң күңеллелек, шәфкатьлелек, рәхимлелек. — *ар.-п. сущ.* Великодушие, щедрость.

**Кәрәмкяранә** كرمكارانه *гф. р.* Киң күңелләләрчә, киң күңелләләрчә булып, киң күңеллелек күрсәтеп. — *ар.-п. н.* Великодушно, милостиво, щедро.

**Кәрәфс** كرفس *ис.* Сельдерей (яшелчә, тамыры ашка салына). *Кәрәфс мигъдәгә куәт бирер вә агызга хуш ис китерер.* (К. Нас.) — *сущ.* Сельдерей (огородное растение).

**Кәрһ** كره *ис.* 1) Җирәнү, чиркәнү, начар күрү. 2) Көчләнү, ирексезләнү. — *сущ.* 1) Отвращение. 2) Неохота, невольность.

**Кәрһән** کرها *р.* 1) Җирәнеп, чиркәнеп. 2) Көчләнеп, теләмичә, ихтыярсыз. — *н.* 1) С отвращением. 2) Неохотно; поневоле.

**Кәс** کس *ф. ис.* Кеше, адәм, шәхыс. *Һәр кәс үз эшендә калды.* (М. Ак.) — *п. сущ.* Человек, личность, особа.

**Кәсад** کساد *ис.* 1) Кадере киту, үтмәү, базарсыз булу, базары булмау, үтми торган булу. 2) Кытлык, азлык, сирәклек. — *сущ.* 1) Застой в торговле, отсутствие спроса на товар, падение цен. 2) Недород; нехватка, недостача.

**Кәсаләт** کسالت *ис.* 1) Ялкаулык. 2) Сүлпәнлек. — *сущ.* 1) Лень. 2) Утомление, вялость.

**Кәсафәт I** کثافت *ис.* 1) Тыгызлык, куелык, сыекчаның чагыштырмача дәрәҗәләре. 2) Юанлык, калынлык. 3) Дорфалык, тупаслык. 4) Акыл, зиһен тупаслыгы. — *сущ.* 1) Густота, плотность. 2) Толщина. 3) Грубость. 4) Несообразительность, тупость.

**Кәсафәт II** کسافت *ис.* 1) Болганчыклык, ачык булмау. 2) Начарлык, зарар, зыян. *Бер яманның кәсафәте яхшы кешегә сираят итәр.* (К. Нас.) — *сущ.* 1) Помрачение, затмение; непрозрачность. 3) Вред, плохая черта.

**Кәсби** کسبی *с.* 1) Казанылган, казанып барлыкка китерелгән. *Кәсби сыйфат* — тумыштан булмыйча, казанып булган сыйфат. *Гакыл ике кыйсемдер: гакыл табигый, гакыл тәҗриби, ягъни кәсбидер.* (К. Нас.) 2) Эшләп табыла торган. — *прил.* 1) Добытый, приобретённый. 2) Заработанный.

**Кәсби һава** کسب هوا *из.* 1) Һава алмаштыру, һава алу, һавага чыгып йөреп кайту. 2) Сәйранга чыгу. — *из.* 1) Проветривание; прогулка по свежему воздуху. 2) Туристический поход.

**Кәсеб*** کسب *ис.* 1) Казану, табу, булдыру; эшләп табу. 2) Шөгыльләнү, тереклек иту өчен бер эш белән шөгыльләнү. *Гакыл кәсби кәсеб белән артыр, тәкрар вә тәкрар тәҗрибә белән гакылга күплек вә кәмаләт хасил булыр.* (К. Нас.) — *сущ.* Добывание, снискание пропитания, приобретение. 2) Промысел, занятие.

**Кәсер** کسر *ис.* 1) Сындыру, ваклау, кисәкләү. 2) Сыну. 3) *мат.* Вакланма. *Әй Вәлиш, „мин мин" Вәлиш, ныграк чалыш* (шөгыльлән) *„кәсрең" белән, башкаларның айгырыннан көлмәгел качырың белән.* (Ш. Баб.) — *сущ.* 1) Ломанье, разбивание. 2) Разлом, надлом, перелом. 3) *мат.* Дробь.

**Кәсер гади** کسرعادی *ст.* Гади вакланма. — *сс.* Простая дробь.

**Кәсер әгъшари** كسراعشارى *ст.* Унарлы вакланма. — *сс.* Десятичная дробь.

**Кәсир** كثير *с.* Күп, мул, еш. — *прил.* Обильный, многочисленный, значительный.

**Кәсиф** كثيف *с.* 1) Куе, тыгыз; еш. 2) Калын, юан. 3) Аңгыра, дорфа, тупас, мәнсез. — *прил.* 1) Густой, плотный, частый. 2) Толстый, тучный. 3) Несообразительный, тупой.

**Кәслян** كسلان *ис.* Ялкау, иренчәк. — *сущ.* Лодырь, лентяй.

**Кәсрә** كسره *ис.* Ас (гарәп орфографиясендә тартык аваз хәрефенә кыска „и" авазын ялгап уку өчен кулланыла торган диакритик билге). — *сущ.* Диакритический значок, обозначающий звук „и", ставится под согласной буквой.

**Кәсрәт** كثرت *ис.* Күплек, муллык, артыклык, өстенлек. *Сиңа гашыйк булып кәсрәт.* (Г. Кан.) — *сущ.* Множество, многочисленность; изобилие.

**Кәсәл** كسل *ис.* 1) Ялкаулык, иренчәклек. 2) Сүлпәнлек. 3) Авыру, сырхау. — *сущ.* 1) Лень, леность, нерадение. 2) Вялость, недомогание. 3) Болезнь.

**Кәтем** كتم *м. I.* Яшерү, астыртын эшләү, сер итеп тоту, кешегә фаш итмәү. *Тогры сүзне нинди файда кәтемдә бар.* (Г. Тук.) — *м. I.* Скрывание, утаивание.

**Кәтеф** كتف *ис. анат.* Калак сөяге, кулбаш сөяге. — *сущ. анат.* Лопатка; плечевая кость.

**Кәттан** كتان *ис.* 1) Җитен. 2) Җитен сүсе. 3) Җитен тукымасы. — *сущ.* 1) Лён. 2) Льняное волокно. 3) Льняная ткань.

**Кәтхода** كتخدا *ф. ис.* 1) Йорт хуҗасы. 2) Авыл старостасы; кечерәк эшкә билгеләнгән начальник, старшина. — *п. сущ.* 1) Хозяин дома. 2) Староста; небольшой начальник.

**Кәтәбәһе** كتبه *фиг.* „Язучысы" (китапның азагында языла торган сүз). — *гл.* „Написавший" (слово, приписываемое в конце книги перед именем автора).

**Кәф I** كف *ис.* 1) Кул, уч. 2) Хайванның аяк табаны. — *сущ.* 1) Кисть, ладонь, рука. 2) Нижняя часть копыта животного.

**Кәф II** كف *м. I.* Тыю, туктату. — *м. I.* Удерживание, воспрещение.

**Кәфаләт** كفالت *ис.* 1) Ышандырып үз өстенә алучылык. 2) Гарантия бирү; — *сущ.* 1) Ручательство, поручительство. 2) Обе-

берәү өчен җаваплылыкны үз өстенә алу; йөгенә керү. — спечение, залог, гарантия.

**Кәфаләт биннәфес** كفالت بالنفس *гыйб.* Кешенең үзенә кәфил булу, берәүне йолып алу. — *фр.* Личное поручительство, личная гарантия.

**Кәфаләт мөтәсәлсәлә** كفالت متسلسله *гыйб.* Ике яки икедән артык кешенең бер-берсен йолып алуы. — *фр.* Круговая порука.

**Кәфаләтнамә** كفالتنامه *гф. ис.* Кафәләт турында язышкан кәгазь. — *ар.-п. сущ.* Гарантийное письмо; поручительская расписка.

**Кәфаләтән** كفالتاً *р.* Кәфаләт белән. — *н.* Ручаясь, поручаясь.

**Кәфаф** كفاف *ис.* Тереклек өчен кирәк булган кадәр ризык. *Мәгыйшәтендә кәфаф вә канәгатьне мөлязим кыл.* (К. Нас.) — *сущ.* Пропитание, достаток.

**Кәфгир** كفگير *ф. ис.* Тишекләнгән сай чүмеч, күбек чүмече, плау чүмече, кәпкер. — *п. сущ.* Шумовка.

**Кәфен*** كفن *ис.* Мәет күлмәге, кәфен. — *сущ.* Саван.

**Кәфеш** كفش *ф. ис.* Кәвеш, башмак. — *п. сущ.* Башмаки, туфли.

**Кәфил** كفيل *с.* 1) Берәүнең йөгенә керүче, берәү өчен җаваплылыкны үз өстенә алучы. 2) Ышаныч күрсәтүче, гарантия бирүче. 3) Тәэмин итүче. *Күрер идең зур асыл таш ятканын, мәңге баетырга кәфил шул тапканың.* (Г. Тук.) — *прил.* 1) Поручитель. 2) Порука. 3) Гарантирующий. 4) Обеспечивающий.

**Кәффарәт** كفارت *ис. дини* Гөнаһтан арыну өмете белән кылынган яки кылынырга тиешле эш. *Аларга фәтва китаплары буенча да әле кәффарәт ваҗип түгел, каза гына ваҗип.* (Ф. Әмир.) — *сущ. рел.* Искупление, очищение покаянием, искупление грехов; епитимья.

**Кәххаль** كحال *ис.* 1) Сөрмәче, күзләргә сөрмә сөртүче. 2) Күз докторы. — *сущ.* 1) Наводящий сурьму на веки. 2) Глазной доктор, окулист.

**Кәшаиш** كشايش *ф. ис.* Ачыклык, җиңеллек, уңайлык. — *п. сущ.* Ясность, лёгкость, удобство.

**Кәшакәш** كشاكش *ф. ис.* 1) Бәхәсләшү. 2) Көрәшү. 3) Дулкынлану, борчылу. — *п. сущ.* 1) Спор. 2) Борьба. 3) Волнение.

**Кәшеф** كشف *ис.* Ачу, ачык беленмәгән бер нәрсәне табып мәйданга чыгару. *Ак талның хасиятен ят йорттан килеп кәшеф кылдылар.* (К. Нас.) — *сущ.* Открытие, обнаружение.

**Кәшиш** كشيش *ф. ис.* 1) Христиан рухание. 2) Монах. — *п. сущ.* 1) Священник христианский. 2) Монах.

**Кәшишханә** كشيشخانه *ф. ис.* Монастырь. — *п. сущ.* Монастырь.

**Кәшфеләсрар** كشف الاسرار *из.* Серләрне ачу, серле мәгънәләрне табу. — *из.* Открытие секретов, раскрытие тайн, истолкование таинственного смысла (чего-нибудь).

**Кәшфи** كشفى *с.* Уйлап табылган, уйлап табыла торган; уйлап табу(га бәйләнешле). — *прил.* Изыскательный, исследовательский.

**Кәшфият** كشفيات *ис.* Уйлап табылган нәрсәләр, яңа барлыкка китерелгән гыйльми, фәнни һәм техник яңалыклар. *Электрик фаслында берничә кәшфияты вә ихтирагысы белән мәшһүр электротехник Сөләйман.* (Ф. Әмир.) — *сущ.* Научные изобретения, открытия.

**Кәшшаф** كشاف *ис.* 1) Берәр яңа нәрсә ачучы, элек беленмәгән нәрсәне эзләп, тикшереп табучы. *Мулла Кәшшаф тәрҗемансыз мәгънәләр кәшшаф түгел.* (Ш. Баб.) 2) Разведкачы. — *сущ.* 1) Раскрывающий открывающий, обнаруживающий. 2) Разведчик.

**Кәшшафелколүб** كشاف القلوب *из.* Күңелләрне ачучы, күңелдәге серләрне ачучы. — *из.* Раскрывающий сердечные тайны.

**Кәэс** كائس *ис.* 1) Кәсә, бокал. 2) Бер бокал эчемлек. 3) Чәчәкләрнең орлык кузагы. — *сущ.* 1) Чаша, кубок. 2) Бокал вина. 3) Коробочка (цветка).

**Кәэннәһү** كانّه *ст.* Гүя, нәкъ, шикелле. — *сс.* Как будто бы... будто бы...

**Кәүкәб** كوكب *ис.* Йолдыз. *Кәүкәбең хак сәнең, хәүф итмә мәнхүс әйләнмәс.* (Г. Тук.) — *сущ.* Звезда.

**Кәүнәен** كونين *ис.* Ике дөнья: материаль һәм рухани дөнья. — *сущ.* Два мира (мир материальный и мир духовный).

**Кәүсәр*** كوثر *ис.* 1) Баллы ширбәт. *Авызың зәмзәм, ирнең кәүсәр, тешең гәүһәр.* (Ш. Баб.) 2) *бот.* Чәчәктәге бал сыекчасы. 3) *дини* Җәннәттә бер күл исеме. *Күл дә тик бер күл генә, әлбәттә, ул кәүсәр түгел.* (Г. Тук.) — *сущ.* 1) Медовый напиток. 2) *бот.* Нектар. 3) *рел.* Аль-кяусар (название райского источника).

**Кәҗ** كج *ф. с.* 1) Кәкре, кәкрәйгән, — *п. прил.* 1) Кривой, искривлённый, согну-

бөгелгән, иелгән. 2) Ялгыш, хаксыз, гаделлексез, дөрес булмаган. — тый, изогнутый. 2) Ошибочный, неправый. 3) Криво, вкривь и вкось; ошибочно, неверно.

**Кәҗ мизаҗ** کج مزاج *ст.* Яман холык(лы); усал, ачулы, кинәле. *Кәҗ мизаҗдан истикамәт килмәс.* (Г. Фәез.) — *сс.* Злобный, дурного характера.

**Кәһанәт** کهانت *ис.* Күрәзәчелек, киләчәктән хәбәр бирү, алдан хәбәр итү. — *сущ.* Предсказывание, пророчество.

**Кәһел** کهل *ис.* Ир уртасы. — *сущ.* Взрослый, возмужалый, средних лет.

**Кәһкәшан** کهکشان *ф. ис.* Киек каз юлы. — *п. сущ.* Млечный путь.

**Кәһлә** کهله *ф. ис.* Бет. — *п. сущ.* Вошь.

**Кәһнә** کهنه *ф. с. кара*: көһнә. — *п. прил. см.* Көһнә.

**Кәһреба** کهربا *ф. ис.* Гәрәбә. — *п. сущ.* Янтарь.

**Кәһәф** کهف *ис.* Тау тишеге, мәгарә, тау куышлыгы, куышлык. — *сущ.* Пещера, грот.

**Кәһүләт** کهولت *ис.* Кеше гомеренең ир уртасы чоры, 30—50 яшь арасы. — *сущ.* Возмужалость, зрелый возраст.

**Көбра** کبرا *с. мнс.* Иң зур, иң бөек. *Вирелде әһле гаднә җир сәкарьдән нары көбрадан* (Гадн җәннәтендәге кешеләргә сәкар тамугындагы иң зур уттан урын бирелде). (Г. Тук.) — *прил. жен.* Самая большая, величайшая.

**Көдүрәт** کدورت *ис.* Көенечлек, кайгы, хәсрәт; каушап калу. *Бу сугыштан тәннәрендә җәрәхәт вә күңелләрендә көдүрәт булмасмы?* (Г. Фәез.) — *сущ.* Смущение; горе, неприятность.

**Көлбә** کلبه *ф. ис.* Алачык, бүлмә, хөҗрә, кечкенә өй. *Көлбәи әхзан* — кайгы-хәсрәт өе. — *п. сущ.* Хижина, келья.

**Көлл** کل *ис.* 1) Һәммә. 2) Бөтен, бөтенесе. 3) Һәр. *Көлле нәфсен заикател мәүт икәндер белмәдем* (Һәркем үлемне татый икәнен белмәдем). (Һ. Сал.) — *сущ.* 1) Целое, совокупность. 2) Весь, вся, все. 3) Всякий, каждый.

**Көлли** کلی *с.* 1) Барысына караган, барысына да бәйләнешле, тулы. 2) Универсаль. — *прил.* 1) Совершенный, полный; полнейший, абсолютный. 2) Универсальный.

**Көллия** کلیه *ис.* 1) Бөтенлек, тулылык. 2) Университет. — *сущ.* 1) Целостность, полнота. 2) Университет.

**Көллиян** كليا *р.* Тулысынча, бөтенләй, барын бетереп. — *н.* Вполне, всёцело, совсем, полностью.

**Көллиять** كليت *ис. кара*: көллия. — *см.* Көллия.

**Көлфәт** كلفت *ис.* 1) Көч кую, тырышу, бер эшкә тырышлык. 2) Авырлык, кыенлык; читенлек, мәшәкать. *Китап тәтаббәгъ* (бастыру) *итмәк көлфәтеннән качып...* (К. Нас.) 3) Урынсыз азаплану, шәплек, егетлек күрсәтү теләге белән азаплану; көчәнүле кыланыш. — *сущ.* 1) Напряжение, труд. 2) Затруднение, трудность; беспокойство. 3) Стеснение; деланность; неестественность.

**Көн фәякүн** كن فيكون *гыйб.* „Бул!" дию белән үк була. — *фр.* Скажешь: „Будь!" будет.

**Көнья** كنيه *ис.* Кушамат (әбү, әби, ибен, өм, бинт сүзләренең берсен кушып ясалган ялгызлык исеме кушаматлары). — *сущ.* Прозвище, кличка.

**Көнһ** كنه *ис.* 1) Бер әйбернең нигезе, төбе, асылы. *Әмма көнһенә ирешмәктән гакылларны тар иткән.* (С. Рәм.) 2) Иң югары торган күтәрелү ноктасы. — *сущ.* 1) Сущность, значительность, глубина. 2) Апогей, предел; вершина.

**Көрбәт** كربت *ис.* Көенеч, сагыш, үкенеч. *Вөҗүдем кайнады, ирешге көрбәт.* (Г. Тук.) — *сущ.* Тоска, печаль.

**Көррасә** كراسه *ис.* Кулъязма табак (сигез бит). *Мәгарринең җөмлә китабы 55 гадәд улып 1120 көррасәдер.* (Р. Фәх.) — *сущ.* Рукопись в один печатный лист; часть книги, состоящая из 8 страниц.

**Көррә** كره *ис.* 1) Йомры, шар. 2) Туп. *Әйләнәсең, тулганасың, түгәрәк син, көррә син.* (Г. Тук.) — *сущ.* 1) Шар. 2) Мяч.

**Көррәи әрыз** كرهٔ ارض *ф. из.* Җир шары; глобус. *Нә хәл бу? Капланган көррәи әрыз кан илә буылган төтенгә.* (Н. Дум.) — *п. из.* Земной шар; глобус.

**Көррәи мөсаттахә** كرهٔ مسطحه *ф. из.* Ярымшар (географик карта). — *п. из.* Полушарие.

**Көрси** كرسى *ис.* 1) Урындык, утыргыч. 2) Кафедра. 3) Тәхет. *Хакимлек көрсисенә менеп алып.* (М. Гаф.) — *сущ.* 1) Сиденье; стул, кресло. 2) Кафедра, 3) Трон.

**Көрәма** كرما *ис.* Кәрим-нең *к.* — *сущ. мн.* от кәрим.

**Көсар** كسار *ф. с.* 1) Чигүче (җәфа). 2) Эчүче. — *п. прил.* 1) Подверженный (страданиям). 2) Пьющий, употребляющий спиртные напитки.

**Көстах** كستاخ *ф. с.* Әрсез, әдәпсез, тотнаксыз, тартынмас. — *п. прил.* Невоспитанный, дерзкий, наглый.

**Көсәля** كسالا *ис.* Кәслян-ның *к.* *Такатем вөсгынча коллык итмәдем көсәля булып.* (Һ. Сал.) — *сущ. мн.* от кәслян.

**Көсуф** كسوف *ис.* Кояш тотылу. — *сущ.* Солнечное затмение.

**Көсуф көлли** كسوف كلى *ст.* Кояшның тулысынча тотылуы. — *сс.* Полное солнечное затмение.

**Көсуф җөзьи** كسوف جزئى *ст.* Өлешчә кояш тотылу. — *сс.* Частичное, неполное затмение (о солнце).

**Көтеб** كتب *ис.* Китап-ның *к.* — *сущ. мн.* от. китаб.

**Көтебханә** كتبخانه *гф. ис. кара:* китабханә. — *гр.-п. сущ. см.* Китабханә.

**Көтлә** كتله *ис.* 1) Өем, күч, төркем; кисәк, кантар. 2) Масса, халык. 3) Политик блок; төркемләнү. — *сущ.* 1) Куча, груда, ком; глыба. 2) Масса, народ. 3) Политический блок, группировка.

**Көфер** * كفر *ис.* 1) Карышу. 2) Аллага ышанмау; алланы бер дип танымау. 3) Алланы хурлау, динсезлек. — *сущ.* 1) Сопротивление. 2) Неверие в бога, в единобожие. 3) Богохульство; безбожие.

**Көфран** كفران *ис.* 1) Танымау, алланы хурлау. 2) Кадерен белмәү. — *сущ.* 1) Безбожие, неверие, богохульство. 2) Неблагодарность, непризнание.

**Көфране нигъмәт** كفران نعمة *из.* Нигъмәт (аш) кадерен белмәү, булган әйберне яратмау; бирәүнең яхшылыгының кадерен белмәү. — *из.* Неблагодарность, непризнание.

**Көфу** كفو *ф. ис.* Тиң, пар, тиңдәш. — *п. сущ.* Равный, подобный; похожий.

**Көффар** كفار *ис.* Кяфир-нең *к.* *Вә көффарә тәнәззелдән, тәзәллел яшьне түкмәктән.* (Г. Тук.) — *сущ. мн.* от кяфир.

**Көхел** كحل *ис.* 1) Сөрмә. 2) Кара күзлеләр. — *сущ.* 1) Сурьма (для подкрашивания ресниц). 2) Черноглазые.

**Көш** كش *ф. ис.* Үтерүче. — *п. сущ.* Убийца.

**Көшад** كشاد *ф. ис.* 1) Ачык. 2) Шатлык. — *п. сущ.* 1) Открытый. 2) Радость.

**Көһнә** كهنه *ф. с.* Сәләмә, иске, борынгы; искергән; модадан чыккан. *Жа-* — *п. прил.* Старый, ветхий, немодный.

*масы көһнә улана бәдгөман мәтлуб имәс* (Киеме сәләмә булганга гына кешегә начар уй тоту тиеш түгел). (Ак.)

**Күфи** كوفى *ис.* Гарәп хәрефләренең каллиграфик бер төре. — *сущ.* Куфический (почерк).

**Күһ** كوه *ф. ис.* Тау. **Күһсар** — таулык, таулы урын. *Нәгяһән тикте юлым бер күһсар.* (Ут. Им.) — *п. сущ.* Гора.

**Күшә** كوشه *ф. ис.* Почмак, аулак урын. *Журналыгызның бер күшәсендә дәреҗ улынмасыны өмид идәрем.* (Г. Тук.) — *п. сущ.* Угол; свободное место.

# Л

**Л** — ل. Татар әлифбасында уникенче, гарәп әлифбасында егерме өченче хәреф. Гарәп сүзләрендә фәкать алла сүзендә генә калын укылып, башкаларда һәрвакыт нечкә укыла һәм үзеннән соң килгән „а" авазын „ә" авазына якын рәвештә нечкәртә. Сан урынында кулланганда 30 ны белдерә. — 12-ая буква татарского алфавита обозначает 23-ю букву арабского алфавита. Цифровое значение — 30. За исключением слова *алла* всегда читается мягко.

**Лала** لالا *ф. ис.* Бала караучы, тәрбияләүче. — *п. сущ.* Няня, воспитатель(ница).

**Лалә** لاله *ф. ис.* Лалә чәчәге. — *п. сущ.* Тюльпан.

**Лаләгүн** لاله گون *ф. с.* Лалә төсле, лалә төсендә. *Кил, әй сакый, китергел лаләгүн мәй.* (Хорәз.) — *п. прил.* Румяный; красный, как тюльпан.

**Лаләзар** لاله زار *ф. ис.* Лалә чәчәге бакчасы, лалә утыртылган җир; чәчәклек. — *п. сущ.* Поле, усеянное тюльпанами; цветник.

**Лаләрох** لاله رخ *ф. ис.* Ал яңак, яңагы лалә кебек ал, алсу бит. — *п. сущ.* С алыми щеками, розовощёкий.

**Лаек** لايق *сф. кара:* ляикъ. — *см.* Ляикъ.

**Ли** لى (ل) *бәйл.* Сүз башына кушылып языла торган һәм „өчен", „күрә" мәгънәләрендә кулланыла торган бәйлек. *Лиәб* — ата өчен. — *Предлог* „для", употребляется также для выражения принадлежности.

**Либас** لباس *ис.* Кием. *Йөзләп җарияләр ки, мөзәйян либаслар белән утырмышлар.* (К. Нас.) — *сущ.* Одежда.

**Лива** لوا *ис.* Байрак, флаг, әләм. *Тотып милләт ливасын югла чыктык...* (Г. Тук.)

*сущ.* Знамя, флаг, стяг.

**Ливәҗһе иллаһ** لوجهه‌الله *ст. дини* Алла ризалыгы өчен. ... *ливәҗһе иллаһ азад бул, — диде.* (К. Нас.)

*сс. рел.* Перед лицом аллаха.

**Лиган** لعان *м. III.* Бер-беренә ләгънәт әйтешү.

*м. III.* Проклинание друг друга.

**Лизалик** لذالك *ст.* Шуның өчен, шуңа күрә.

*сс.* Поэтому, потому, для этого.

**Ликаэ** لقا *ис.* 1) Юлыгу, очрашу; кавышу. 2) Йөз, чырай.

*сущ.* 1) Встреча, свидание. 2) Лицо, выражение лица.

**Лиллаһ** لله *ст. дини* Алла өчен.

*сс. рел.* Ради бога, ради аллаха.

**Лима ля яҗуз** لما لا يجوز *гыйб.* Ник дөрес булмасын? ник мөмкин булмасын? *Ул: „Кыйраәт" китабында кылт итеп искә төшү җаиз булгач, шап итеп искә төшү лима ля яҗуз? — дигәндер шул.* (Г. Тук.)

*фр.* Почему нельзя? Почему не разрешается?

**Лиман** ليمان *ис.* 1) Диңгез култыгы. 2) Гавань, порт.

*сущ.* 1) Лиман, залив. 2) Гавань, порт.

**Лисан** لسان *ис.* 1) *лингв.* Тел. 2) *физ.* Тел. *Лисаның зикере тәсбих өчен, сәна өчен.* (Г. Тук.)

*сущ.* 1) *лингв.* Язык. 2) *физ.* Язык.

**Лисане халь** لسان‌حال *ст.* 1) Берәүнең яки әйбернең торышыннан аңлашылып торган нәрсә. 2) Басма орган.

*сс.* 1) Язык обстоятельств. 2) Печатный орган.

**Лисане хәнҗәр** لسان‌خنجر *ст.* Хәнҗәр телле, ачы теллелек, ачы тел. *Чәнчә дә ул күңеленә явыз лисане хәнҗәрен.* (Г. Тук.)

*сс. букв.* Язык как бритва, „кинжальный язык"; злоязычие.

**Лисанән** لسانا *р.* Телдән.

*н.* Словесно, устно; на словах.

**Лисас** لثاث *ис.* Лиссә-нең *к.*

*сущ. мн.* от лиссә.

**Лиссә** لثه *ис.* Теш урты, теш казнасы.

*сущ.* Десна.

**Лифафә** لفافه *ис.* 1) Төргәк. 2) Урый торган, төрә торган чүпрәк.

*сущ.* 1) Свиток, свёрток. 2) Обёртка.

**Лихаф** لحاف *ис.* Юрган.

*сущ.* Одеяло.

**Лихья** لحيه *ис.* Сакал. *Аһ, кем! Абаэмез һәп лихьялы сыйбъян имеш.* (Г. Тук.)

*сущ.* Борода.

**Лиякать** لياقت *ис.* 1) Лаек булучылык, кулыннан эш килүчелек, булдыклылык. 2) Ярарлык. — *сущ.* 1) Соответствие; достоинство. 2) Пригодность.

**Лиәб** لاب *ст.* 1) Ата өчен. 2) Ата ягыннан. *Ул кеше минем лиәб карендәшемдер.* (К. Нас.) — *сс.* 1) За (для) отца. 2) Со стороны отца.

**Лиәҗел** لاجل *ст.* Өчен, максат белән. — *сс.* За, для, ради.

**Лиәҗли тәхсыйл** لاجل التحصل *ст.* Уку максаты белән; уку өчен. — *сс.* С целью получения знаний, для учёбы.

**Лиөм** لام *ст.* 1) Ана өчен. 2) Ана ягыннан. — 1) Для матери. 2) Со стороны матери.

**Лиҗам** لجام *ис.* Йөгән, нукта. — *сущ* Узда, уздечка.

**Лиһазә** لهذا *ст.* Болай булганга, моның өчен. — *сс.* Поэтому, на этом основании.

**Локмә** لقمه *ис.* Бер кабым, бер йотым, кечкенә кисәк ашамлык. *Ул сәдакачыга бер локмә тәгам бирде.* (К. Нас.) — *сущ.* Кусочек, нечто малое по размерам, пища на один глоток, ломтик.

**Локта** لقطه *ис.* Табылдык мал, табылган нәрсә. — *сущ.* Находка, неожиданная прибыль.

**Лосук** لصوق *м. I.* Ябышу, тоташу. — *м. I.* Прилипание (к чему-либо).

**Лосус** لصوص *ис. к.* Караклар. — *сущ. мн.* Воры.

**Лосусыйя** لصوصيه *ис.* Караклык. — *сущ.* Воровство.

**Лотфән** لطفاً *р.* Ярдәм йөзеннән, хуш күреп. — *н.* Из милости, из вежливости, любезно.

**Лотыф** لطف *ис.* Гүзәллек; мәрхәмәт, киң күңеллелек. *Безгә лотыф итеп, баш кода булсаңыз иде.* (М. Ак.) — *сущ.* Милость, любезность, вежливость, доброта, приятность.

**Ля** لا *кис.* Юк, түгел. *Шаһзадәнең ля вә нәгам димәккә мәҗале калмады.* (К. Нас.) 2) Юклыкны, инкарьне белдерә торган ма-мә, сыз-сез кушымчалары мәгънәләрендә йөри. — Частица отрицания, соответствует русскому „нет“, „не“, „без“.

**Лябед, лябеддә** لابد،لابد *ст.* Котылгысыз, үтә кирәк, әлбәттә, чарасыз, ансыз мөмкин түгел. *Лябед, сиңа терелер өчен корбан кирәк.* (Г. Тук.) — *сс.* Обязательно, непременно, непреложно, должно, неизбежно.

**Лябис** لابس *сф.* Киюче, кигән. — *пр. д.* Одевающий, одевший.

**Ля бәәс** لابئس *ст.* Зарар юк, зарарсыз. *Ашаганда ләтыйфә кылмак ля бәәстер.* (К. Нас.) — *сс.* Не беда, не вредно.

**Ля галәттәгъйин** لاعلى التعين *ст.* 1) Билгеләмичә, төбәп түгел, ничек эләксә шулай. 2) Юри түгел. — *сс.* 1) Не целясь, как попало. 2) Ненамеренно.

**Ля гыйлаҗ** لاعلاج *ст.* 1) Чарасыз, чара юк. 2) Дару юк. — *сс.* 1) Поневоле. 2) Неизлечимый.

**Лягъ I** لاع *ис.* Куркак. — *сущ.* Трус; боязливый.

**Лягъ II** لاغ *ф. ис.* Анекдот, әдәпсез сүзләр белән ясалган мәзәк, көлке. — *п. сущ.* Анекдот, побасёнка; непристойная шутка.

**Лягыйб** لاعب *сф.* 1) Уйнаучы, уенчы. 2) Спортчы. — *пр. д.* 1) Игрок, спортсмен. 2) Играющий, забавляющийся.

**Лягыр** لاغر *ф. с.* Арык, чандыр. — *п. прил.* Тощий, худой, худощавый, худосочный.

**Лягыя** لاغيه *ис.* 1) Юк-бар сүз. 2) Әдәпсез сүз, оятсыз сүз. — *сущ.* 1) Болтовня, вздор, пустословие. 2) Неприличное слово.

**Лязим** لازم *сф.* 1) Тиеш, кирәк, мәҗбүри, зарур. *Бер кемсәнә уяулыкны үзенә лязим итсә, дошманнан тәләф булмактан әмин булыр...* (К. Нас.) 2) *грам.* Күчемсез (фигыль). — *пр. д.* 1) Нужный, необходимый, потребный. 2) *грам.* Непереходный (глагол).

**Лязимә** لازمه *ис.* 1) Тиешле нәрсә, әйбер. 2) Өскә йөкләнгән бурыч, хезмәт. — *сущ.* 1) Необходимая вещь, принадлежность. 2) Служба, долг.

**Ляикъ** لائق *сф.* Тиешле, яраклы, килешле, лаек. *Һәдиягә ляикъ нәрсә бар икән, дип хәзинәгә кереп йөргәндә...* (К. Нас.) — *пр. д.* Надлежащий, достойный, подходящий, приличный, заслуживающий внимания.

**Ляихә** لائحه *ис.* 1) Проект. 2) Берәр эш яки закон өчен төрле яктан карап, тикшереп хәзерләнгән тәкъдим. — *сущ.* 1) Проект. 2) Изученное, подготовленное предложение (в вышестоящие органы).

**Ля йогкаль** لايعقل *ст.* Акыл ирешмәс, акыл җитмәслек. — *сс.* Непонятный, уму непостижимый.

**Ля йөбали** لايبالى *ст.* 1) Пәрвайсыз, игътибарсыз, сансыз. 2) Салкын канлы. — *сс.* 1) Невнимательный, небрежный, беспечный, непочтительный. 2) Хладнокровный, бесстрастный.

**Ля йөгадде** لا يعد *ст.* Исәпсез, хисапсыз, исәпсез күп. *Ля йөгадде вә ля йөхса сәлам.* (З. Биг.) — *сс.* Бесчисленный, не поддающийся счёту, неисчислимый.

**Ля йөсьәлә** لايسئل *ст.* Аннан сорамаслар, ул җавапка тартылмас, җаваплы булмас. *Белеп булмый эшеннән „ля йөсьәлә" ич ул.* (Г. Тук.) — *сс.* С него не спросят, у него не спросят.

**Ля йөхса** لايحصى *ст.* Исәбенә (санына) чыга алмаслык, хисапсыз, бик күп. — *сс.* Неисчислимый, несметный, множество.

**Ля кайд** لاقيد *ст.* Гамьсез, ваемсыз, пошынмас. *Башларыннан кичкән вакыйгалардан әсәрләнмәслек дәрәҗәдә ля кайд вә мук йөрәк булдылармы?* (Җ. Вәл.) — *сс.* Беспечный, нерадивый, беззаботный; бесстрастный, апатичный.

**Лякин** * لكن *тер.* Ләкин, әмма. — *част.* Но, однако.

**Ля кәлям** لاكلام *ст.* Сүз юк, һич әйтерлек сүз юк. — *сс.* Нет слов (чтобы выразить что-либо).

**Ля лихөбби галийин** لالحب على *гыйб.* Галине (кемне дә, нәрсәне дә булса) яратудан түгел (бәлки башка бернәрсә өчен). *Самараны яратудан түгел, ягъни „ля лихөбби галийин".* (Г. Тук.) — *фр.* Выражение употребляется в смысле „не за красивые глаза" (*букв.* „не из любви к Али".

**Лям** لام *ис.* ل хәрефенең исеме, ләм. — *сущ.* Название буквы.

**Лямигъ** لامع *сф. кара:* лямих. — *см.* Лямих.

**Лямига** لامعه *сф.* Нур чәчүче хатын. — *пр. д.* Лучезарная (о женщине).

**Лямис** لامس *сф.* Тотучы, капшап сизүче, тоючы. — *пр. д.* Дотрагивающийся, касающийся чего-либо, осязающий.

**Лямисә** لامسه *ис.* Тотып (капшап) белү тойгысы. — *сущ.* Осязание, чувство осязания.

**Лямих** لامح *сф.* Ялтыраучы, нур чәчүче. — *пр. д.* Сверкающий, блестящий.

**Ля мәкян** لامكان *ст.* Урыны юк, урынсыз, урыны билгеле булмаган (алла яки шундый исеме бар, гәүдәсе юк нәрсә). *Мөнтәзыйрлар ля мәкяннар, бар мәляикләр сиңа.* (Г. Тук.) — *сс. рел.* Вездесущий (эпитет бога).

**Ля мәхалә** لامحاله *ст.* 1) Чарасыз, котылгысыз. 2) Һичшиксез. — *сс.* 1) Неизбежно, неминуемо. 2) Без сомнения, безусловно.

**Ля нөсәллим** لانسلم *ст.* Күнмибез, риза түгел, алай түгел, канәгатьләнмибез. *Әмма ля нөсәллим дию кариәмнең иркенә.* (Г. Тук.) — *сс.* Не признаём, не соглашаемся, не допускаем.

**Лясыйк** لاصق *сф.* Тоташучы, ябышучы. — *пр. д.* Прилипающий, плотно прилегающий.

**Лят** لات *ял. ис.* Гарәпләрнең борын заманда табынган потларыннан берсе. *Әгәр лят вә мәнат керсә хәрәмгә* (хәрәм: бередә мәчет мәгънәсендә). (Дәрд.) — *и. с.* Имя одного из доисламских идолов у арабов.

**Ля тәйәсү** لاتئيسو *ст.* Өметсезләнмәгез, өмет кисмәгез. *Ля тәйәсү әмерене тот.* (Г. Тук.) — *сс.* Не теряйте надежды.

**Ля тәкъръбуззина** لاتقربوالزنا *ст.* Зинага якын булмагыз. *Ул ук сәгать тәһдид үзә өн ишетте: ля тәкъръбуззина дию укыр имди.* (К. Гал.) — *сс.* Остерегайтесь совершить прелюбодеяние.

**Ля тәкътелү** لاتقتلو *фиг.* Үтермәгез. *Ля тәкътелү Йосыфе дияр имди.* (К. Гал.) — *гл.* Не убивайте.

**Ляф** لاف *ф. ис.* Буш сүз, мактану сүзе. *Ляф ора*—лаф ора, шапырына, мактана. *Яхшылык юк, булса анда „яхшы мин!“—дип ляф ору.* (Г. Тук.) — *п. сущ.* Хвастовство, бахвальство; пустословие.

**Ля фәта илла Гали кәррар** لافتی الاعلی کرار *гыйб.* Гали батырдан башка чын егет юк. *Ля фәта илла Гали кәррар имди.* (К. Гал.) — *фр. букв.* „Нет молодца сильнее Гали-батыра“.

**Ляфзән** لافزن *ф. ис.* Буш сүз сөйләүче, лыгырдаучы, бушбугаз. — *п. сущ.* Хвастун, фанфарон, болтун.

**Ляхикан** لاحقا *р.* Хәзер, бу көндә. *Сагикан* (электән) *вә ляхикан хикәя күбрәктер.* (К. Нас.) — *н.* Теперь.

**Ляхикъ** لاحق *сф.* Соңыннан кушылучы, ялганучы, хәзерге көнгә иярүче. *Адәм өч төрледер: бер төрлесе ляхикълардыр ки, алар аталарның фазиләтләренә мөлхикълардыр.* (К. Нас.) — *пр. д.* Примыкающий, последующий, позднейший, настигающий.

**Ляхишә** لاخيشه *ф. ис.* Токмач. — *п. сущ.* Лапша.

**Ля хәйре фиһөннә вә ля беддә минһөннә** لاخير فيهن ولابدمنهن *гыйб.* „Алардан һичбер яхшылык юк, ә алардан башка мөмкин түгел“ (хатыннар турында әйтелә торган реакцион гыйбарә). — *фр.* „Нет от них добра, но и без них нельзя“ (реакционное выражение, свидетельствующее о презрительном отношении к женщине в прошлом).

**Ля хәүлә** لاحول *ст. дини* 1) Көч (кодрәт) юк. 2) Бу сүз белән башланган бер дога исеме. *Һәр кеше куркып укый ля хәүләсен.* (Г. Тук.). — *сс. рел.* 1) *букв:* Нет силы, могущества. 2) Начальное слово молитвы „на всё воля божья“.

**Ля хәүфә галәйһим** لاخوف عليهم *гыйб.* 1) Алар куркуны белмиләр. 2) Аларга куркыныч юк. — *фр.* 1) Они не знают страха. 2) Им ничто не угрожает.

**Ляшә** لاشه *ф. ис.* Үләксә, үлек хайван гәүдәсе. — *п. сущ.* Труп животного, падаль.

**Ля шәй** لاشى *ст.* Берни түгел, юк дәрәҗәсендә, һич кыйммәте юк, юк кебек; әһәмиятсез. *Моның янда башка кеше имеш ля шәй.* (М. Гаф.) — *сс.* Ничто, ничего, ничтожество.

**Ля шәк** لاشك *ст.* Шиксез, шөбһәсез, әлбәттә. *Ля шәк бер нәрсә дә улмаз.* (З. Биг.) — *сс.* Без сомнения, несомненно.

**Ля шәркыйя, ля гарбия** لاشرقيه، لاغربيه *гыйб.* Көнчыгышта да юк, көнбатышта да юк. *Ул синең васфыңда „ля шәркыйя, ля гарбия“, ди.* (Г. Тук.) — *фр.* Нет ни на востоке, ни на западе.

**Ля ягъкыйл** لايعقل *ст.* Акылын җуйган, аңы беткән, уй йөртми (сөйләү телендә *ләякыл* дип сөйләнә). *Гашикълар икесе дә һушсыз вә ля ягъкыйл булдылар.* (К. Нас.) — *сс.* Быть неразумным, не иметь здравого суждения.

**Ля ягъни** لايعنى *ст.* Мәгънәсез, буш, файдасыз. — *сс.* Не значит, не значащий, бессмысленный.

**Ля язал** لايزال *ст.* Бетмәс, үлүе (бетүе) мөмкин түгел, дәвам итә. — *сс.* Продолжает, не прекращает, длится.

**Ля язлимун** لايظلمون *ст.* Золым итмиләр, җәфа (газап) чиктермиләр. *Кайда соң бу җаһилүн кемнәргә соң ля язлимун* (В. Җәлал). — *сс.* Не притесняют, не угнетают.

**Ля ямүт** لايموت *ст.* Үлмәячәк, вафат булмас. — *сс.* Не умрёт, бессмертный.

**Ля ятәгайер** لايتغير *ст.* Алмашынмый, үзгәрми, һәрвакыт бертөсле тора. — *сс.* Не изменяется, не переменится.

**Ля ятәҗәзза** لا يتجزا *ст.* Тагын да бүленми, тагын да ваклап булмый торган. *Ля ятәҗәзза кабиленнән хәрдәбин аркылы карап та көч белән күренә торган кечкенә хайваннар.* (К. Нас.) — *сс.* Не делится на части, неделимый (в значении „очень мелкий“).

**Ля әкалле** لااقل *ст.* Иң кимендә, ким дигәндә, һич булмаса. — *сс.* Не меньше, по меньшей мере, хотя бы.

**Ля әбали** لاابالى *ст.* Игътибар итмим, илтифат итмим, исем китми, кызыксынмыйм. — *сс.* Не интересуюсь, не забочусь, не обращаю внимания, не стесняюсь.

**Ля җәрәм** لاجرم *ст.* Шиксез, шөбһәсез, әлбәттә. — *сс.* Конечно, несомненно, бесспорно.

**Ляҗүрд** لاجورد *ф. ис.* 1) Ляпис-лазурь. *Әгъла ляҗүрд ташы бик нәфис күк буяуга истигъмал ителгән.* (К. Нас.) 2) Күк төс.
*п. сущ.* 1) Ляпис-лазурь. 2) Лазурный (цвет).

**Ләамәт** لئامت *ис.* 1) Саранлык, үзеннән дә кызгану дәрәҗәсендә саранлык. *Үз тәгамыгызны китереп аның янында ашагыз дип, дустының гаять ләамәтен белде, де.* (К. Нас.) 2) Түбәнлек.
*сущ.* 1) Скупость, жадность. 2) Низость (в моральном отношении).

**Ләб** لب *ф. ис.* 1) Ирен. *Ләб иту* — үбү. *Туянча ләб итәр идем кочып Сәхибҗамалымны.* (Г. Кан.) 2) Чит, кырый, яр. *Ләби дәрья* — елга яры.
*п. сущ.* 1) Губа. 2) Край, срез, берег.

**Ләбабә** لبابه *ис.* Акыл иясе, акыллылык.
*сущ.* Проницательность, разумность.

**Ләббан** لبان *ис.* Сөтче.
*сущ.* Молочник (продавец молока).

**Ләббәйкә*** لبيك *ст.* 1) *дини* Менә мин синең алдында (Мәккәдә хаҗ вакытында әйтелә торган сүз). 2) Әү, тыңлыйм, ни боерасыз? Боерыгыз, йомышыгызга хәзермен, баш өсте. 3) Кичерегез, ишетеп җитмәдем.
*св.* 1) *рел.* „Вот я перед тобой" (формула, произносимая во время исполнения церемоний хаджа). 2) Что-что? приказывайте; слушаюсь! 3) Простите, не расслышал.

**Ләбес** لبس *ис.* Аера алмаслык итеп катыштыру.
*сущ.* Затемнение, делание неясным, непонятным.

**Ләбиб** لبيب *с.* Акыллы, белемле, зирәк кеше. *Ләбибләр күплеге берлә, әдипләр күплеге берлә.* (Г. Чок.)
*прил.* Умный, проницательный, разумный.

**Ләбәй** لبى *кара*: ләббәйкә.
*см.* Ләббәйкә.

**Ләбән** لبن *ис.* Сөт; әчегән сөт.
*сущ.* Молоко; кислое молоко.

**Ләбәни** لبنى *с.* Сөт(кә бәйләнешле).
*прил.* Молочный.

**Ләбәният** لبنيات *ис.* Сөттән эшләнгән ашамлыклар.
*сущ.* Молочные продукты.

**Ләвазим, ләвазимат** لوازم، لوازمات *ис.* 1) Тиешле булган нәрсәләр, кирәкяраклар, кирәкле эшләр. ... *йөзекләр, алкалар, тараклар, сәгатьләр — һәрни ләвазимат белән мәмлү иде.* (К. Нас.) 2) Хезмәт, хезмәт урыны — дәрәҗәсе. *Бер кеше бер ләвазимнан төшсә гомер буе шул ләвазимга кермәкне фәраз кылып йөридер.* (К. Нас.)
*сущ. мн.* 1) Необходимые вещи, принадлежность, всё необходимое, снаряжение. 2) Должность, работа.

**Ләвен** لون *ис.* Төс (буяу). — *сущ.* Цвет.

**Ләгаллә** لعل *тер.* Шаять, бәлки. *Хаҗәт иясен ләгаллә белән ишегендә көттермәктән, юк, гаеп итмә, дип җибәрмәк морадына ирештерү кебекләр.* (К. Нас.) — *част.* Может быть, авось, вероятно.

**Ләгу** لغو *ис.* 1) Буш сүз, юк сүз. 2) Чынлыкта булмаган эш, юк эш. 3) Ялгышу, хаталык. 4) Гамәлдән чыгару, бетерү, бозу. — *сущ.* 1) Болтовня, вздор. 2) Недействительность. 3) Ошибка, заблуждение. 4) Отмена, ликвидация.

**Ләгу вә ләһәб** – уен-көлке. *Ләгу вә ләһәб күрсәтелә торган кяфир йортына баргалавы хәзрәткә җиткерелде.* (Г. Ибр.) — Веселье.

**Ләгънәт*** لعنت *ис.* 1) Куу, сөрү. 2) Каргыш. — *сущ.* 1) Изгнание. 2) Проклятие.

**Ләгыб** لعب *ис.* Уен-көлке, юаныч. *Булмасын һичберсе, тик булсын ләгыб, булсын ләһү.* (Ш. Баб.) — *сущ.* Игра, веселье, забава.

**Ләгыйн*** لعين *с.* Каргыш төшкән, юньсез, мәрхәмәттән мәхрүм ителгән. *Күрде батыр, шунда яткан ул ләгыйн.* (Г. Тук.) — *прил.* Проклятый, заклятый, лишённый милости.

**Ләгыль** لعل *ис.* *мин.* Ал, кызыл төстә кыйммәтле таш. *Йөземнәр көнгә каршы ялтырыйлар ләгыль вә якуттай.* (Г. Тук.) — *сущ. мин.* Шпинель, лал.

**Ләгын** لعن *ис. кара:* ләгънәт. — *см.* Ләгънәт.

**Ләда** لدى *бәйл.* Каршысында, алдында, янында. — *Предлог* у, при (выражает принадлежность).

**Ләден** لدن *с.* Ягымлы, мәрхәмәтле. *Йосыфның йөзен күреп ләден булды.* (К. Гал.) — *прил.* Нежный, добрый.

**Ләдәгъ** لدغ *ис.* Елан, чаян кебек нәрсә чагу. — *сущ.* Укус (змеи, скорпиона и т. п.)

**Ләел** ليل *ис.* Кич, төн. — *сущ.* Ночь, вечер.

**Ләзаиз** لذائذ *ис.* Ләзизә-нең *к.* — *сущ. мн.* от ләзизә.

**Ләззат** لذات *ис.* Ләззәт-нең *к.* — *сущ. мн.* от ләззәт.

**Ләззәт*** لذت *ис.* 1) Тәм, татлылык. *Һәр җимештә үзенә ләззәт бардыр.* (З. Һад.) 2) Рух рәхәтлеге. *Мәгъсуманә ләззәт, хозур тапкан чагым.* (Г. Тук.) — *сущ.* 1) Вкус, сладость. 2) Приятность, наслаждение, удовольствие.

**Ләзиз** لذيذ *с.* Тәмле, татлы, ләззәтле. *Бу җиһанның ләзиз нигъмәтләре күп-* — *прил.* Сладостный, восхитительный, тонкий,

*тер, вә ләкин һичберсе бу чәйдик-юктыр* (Чәй бәете). — изысканный; вкусный, аппетитный.

**Ләзизә** لذيذه *ис.* Ләззәтле әйбер, тәмле (татлы) әйбер. — *сущ.* Сладость, приятность.

**Ләим** لئم *с.* Саран, үзеннән-үзе кызганучы, түбән (кеше). *Өмит итмә мәгашыңны ләимнән.* (Г. Тук.) — *прил* 1. Скряга, скупец. 2. Жадный, алчный.

**Ләйин** لين *с.* Йомшак, мөлаем. — *прил.* Мягкий, нежный; гибкий, податливый.

**Ләйлаә** ليلا *ис.* Караңгы (төн). — *сущ.* Тёмная (ночь).

**Ләйле камра** ليل قمرا *гыйб.* Айлы якты кич. *Ки истикъбале милләт раушан улсын ләйле камрадан.* (Г. Тук.) — *фр.* Светлая, лунная ночь.

**Ләйлә** ليله *ис.* 1. Кичә, ялгыз бер кичә, төн. *„Әлф ләйлә вә ләйлә"* — мең дә бер кичә (гарәп экиятләре җыентыгының исеме). 2. *ял. ис.* Ләйлә. — 1) Ночь, вечернее время. 2) *и. с.* Лейла.

**Ләйлән** ليلاً *р.* Төнлә белән, кичтә, төн вакытында. *Ләйлән тәшрифегездән соң ашау-эчүдән киселеп, аһ чикмәктәдер, — диде.* (К. Нас.) — *н.* Вечером, ночью.

**Ләйсә** ليس *кис.* Түгел, булмас, юк. — Отрицательная частица, соответствует русской частице „не", „нет".

**Ләйтә** ليت *кис.* Әй булса иде! булса иде! *Ул хаҗәт иясен ләйтә вә ләгаллә белән ишегендә көттермәктән...* (К. Нас.) — *част.* О если бы! (выражение желания).

**Ләкаб** لقب *ис.* 1) Кушамат. *Яла ягып ләкаб кушты.* (К. Нас.) 2) Фамилия, псевдоним. *Үземнең ләкабемә топаштырдым.* (З. Һад.) — *сущ.* 1) Прозвище, звание, титул. 2) Фамилия, псевдоним.

**Ләканәт** لقانت *ис.* Зирәклек, зиһен йөгереклеге, тиз уйлаучанлык, тиз аңлау, тиз төшенү. — *сущ.* Сообразительность, понятливость.

**Ләкъләка** لقلقه *ис.* 1) Ямьсез тавыш, гөрелдәү, шакылдау тавышы. 2) Буш (мәгънәсез) сүзләр. *Гыйсмәтинең күп вакытта мәгънәдән күп ләкъләка.* (Ш. Баб.) 3) Гайбәт сату. 4) Ләкләк тавышы. — *сущ.* 1) Шум, трескотня. 2) Болтовня. 3) Сплетничанье. 4) Щёлканье аиста.

**Ләкъләкъ** لقلق *ис.* Ләкләк кошы. — *сущ.* Аист.

**Ләкәгъ** لكع *м. I.* 1) Түтүрүш, хур кеше. 2) Кешегә хурлап эндәшә торган сүз. — *м. I.* 1) Опозоренный, оскорблённый человек. 2) Оскорбительное слово.

**Ләмгъ** لمع *ис.* Ялтыравык, ялтыраш, балкыш. — *сущ.* Блеск, сверкание, лоск.

**Ләмес** لمس *м. I.* Тоту, тию, бәрелү. *Вә ләмси без гөнаһкярә әрәмдер.* (Г. Тук.) — *м. I.* Касание, ощущение, осязание.

**Ләмех** لمح *м. I.* 1) Күз төшерү, бер карап алу. 2) Бик кыска вакыт. — *м. I.* 1) Взгляд. 2) Мгновение.

**Ләмзә** لمزه *ис.* 1) Нечкә мәгънә. 2) Күз, каш белән ымлау, каш сикертү. — *сущ.* 1) Тонкий смысл. 2) Подмигивание.

**Ләм язәл** لم یزل *ст.* Бетми торган, югалмый торган, мәңге. *Пәнаһ әйләп үзигә ләм язәлне* (Сайяди). — *сс.* Непрекращающийся; вечный, бессмертный.

**Ләм ялид** لم یلد *ст.* Тумады. *Мин өмид иткән вәлидләр „Җим Вәлид“тән ләм ялид.* (Ш. Баб.) — *сс.* Не рождён, не родился.

**Ләм яльтәфит** لم یلتفت *ст.* Илтифат итмәде, исе китмәде, игътибар бирмәде (бу сүз түбәндә өченче зат үткән заман фигыль булса да, һәр өч заман һәм өч зат өчен дә кулланыла). *Минем хәлне белгән иптәшләр дә миңа күп даруның исемен әйтеп калдылар, әмма мин ләм яльтәфит.* (Г. Тук.) — *сс.* Не обратил внимания, не придал значения (чему-либо).

**Ләмәган** لمعان *ис.* Ялтырап, нур чәчеп тора торган нәрсә. — *сущ.* Блеск, сияние, сверкание (звезды).

**Ләмәгане сәраб** لمعان سراب *ст.* Мираж (эссе чүлләрдә горизонтның ары ягындагы әйберләрнең һавада ялтырап күренүе). — *сс.* Мираж, марево.

**Могаҗҗәлән** معجلاً *р.* Ашыгыч рәвештә. — *н.* Срочно, спешно.

**Могаһид** معاهد *сф.* Вәгъдәләшүче, бер-беренә бирәр эш турында сүз берләшкән, договор ясашкан як. — *пр. д.* Договаривающаяся сторона, союзник.

**Могаһәдә** معاهده *м. III.* Договор, вәгъдәләшү, сүз бирешү, ике якның бер эш турында килешүе. — *м. III.* Договор, соглашение; взаимное согласие.

**Могдим** مغدیم *сф.* 1) Юкка чыгаручы, юк итүче. 2) Ярлы. — *пр. д.* 1) Лишающий. 2) Бедный.

**Могзиб** معذب *сф.* Газаплаучы, газап итүче. — *пр. д.* Истязатель, мучитель.

**Могзыйб** مغضب *сф.* Ачуландыручы. — *пр. д.* Гневящий, сердящий.

**Могрэб** معرب *сф. грам.* Төрләнә торган сүз, төрләнгән сүз. *Исем могрэб диерләр, шундаен кәлимәдер ки, игъраб кабул итәр.* (К. Нас.) — *пр. с. грам.* Склоняемый, спрягаемый.

**Могни** مغنی *сф.* Баетучы, мохтаҗлыкны бетерүче. — *пр. д.* Обогащающий, выручающий из нищеты.

**Могтад** معتاد *сф.* Гадәт ителгән, гадәт булган, гадәтләнгән. *Юмартлык белән, ингам вә ихсан белән могтад вә мәшһүр бер адәм бар иде.* (К. Нас.) — *пр. с.* 1) Привычный. 2) Обычный; обыденный.

**Могтый** معطی *сф.* Бирүче, өләшүче. — *пр. д.* 1) Дающий, выдающий, раздающий. 2) Податель.

**Могтәбәр** معتبر *сф.* 1) Игътибарлы, хөрмәтле. 2) Күзгә алынырлык. *„Көтү башы" дип атап йөртә торган берничә сыер бар, карт, зур, мәһабәт, могтәбәр хайваннар.* (Г. Ибр.) — *пр. с.* 1) Почитаемый, уважаемый, почтенный. 2) Солидный.

**Могтәбәран** معتبران *гф. ис. к.* Ихтирам ителә торган кешеләр; халык арасында күзгә ташлана торган (кешеләр). *Риҗале могтәбәран улырсыз.* (З. Биг.) — *ар.-п. сущ. мн.* Почтенные, уважаемые (о людях).

**Могтәд** معتد *сф.* Саналган, санала торган. — *пр. с.* Считаемое, исчисляемое.

**Могтәдил** معتدل *сф.* 1) Уртача; артык та, ким дә түгел. *Могтәдил җылылы мичтә киптермәк мөмкин.* (К. Нас.) 2) Пропорциональ. — *пр. д.* 1) Умеренный, средний. 2) Пропорциональный.

**Могтәдиланә** معتدلانه *гф. р.* Уртачалык белән, бертигез рәвештә; уртача. — *ар.-п. н.* 1) Умеренно, в меру. 2) Умеренный.

**Могтәзил** معتزل *сф.* 1) Җәмәгатьтән аерылучы. 2) Хезмәтне ташлап чыгучы. — *пр. д.* 1) Изолированный. 2) Удалившийся от других, от службы и т. д.

**Могтәзилә** معتزله *ис.* Мөселманнар арасында күпчелектән аерылып чыккан бер мәзһәп. *Бу сүз могтәзиләләр тарафыннан ихтираг ителде.* (Ш. ж.) — *сущ.* Религиозная секта в исламе.

**Могтәзир** معتذر *сф.* Сәбәбен әйтеп, кимчелеген кичерүне сораучы, гафу үтенүче. — *пр. д.* Просящий прощения; извиняющийся.

**Могтәкыйд** معتقد *сф.* Ышанучы, иман итүче, инанучы. — *пр. д.* Твёрдо верящий во что-либо; убеждённый.

**Могтәлл** معتل *сф.* 1) Авыру, авыруы бар. 2) *грам.* Тамырында а, у, и хәрефләре булган гарәп фигыльләре. — *пр. с.* 1) Немощный; слабый, больной; хилый. 2) *грам.* „Неправильные" глаголы арабского языка, имеющие в своём составе „больные" буквы *алиф, ва у, я.*

**Могтәмәд** معتمد *сф.* 1) Ышанылган, таянылган, ышанычлы. 2) Вәкил. — *пр. с.* 1) Надёжный, верный. 2) Представитель.

**Могтәризъ** معترض *сф.* Каршы килүче (башкалар фикеренә), бәхәсләшүче. — *пр. д.* Возражающий, спорящий.

**Могтәризә** معترضه *ис. грам.* 1) Сүз арасына кергән кереш сүз, кереш җөмлә. 2) Кереш җөмләне эченә алган җәя. — *сущ. грам.* 1) Вводное слово, предложение. 2) Скобки (для вводного предложения).

**Могтәриф** معترف *сф.* Үзенең гаебен (кимчелеген) өстенә алучы, гаебен танучы. *Белә алмыйбыз дигән сүзләре белән мокыйр вә могтәриф булдылар.* (К. Нас.) — *пр. д.* Сознающийся, признающийся; исповедующийся.

**Могтәсиф** معتسف *сф.* Кыерсытучы, золым итүче. — *пр. д.* Притесняющий, творящий насилие.

**Могыйн** معين *сф.* Ярдәмче, ярдәм итүче. *Могыйн вә ярдәмчеләре булмаган гаҗизлар.* (К. Нас.) — *пр. д.* Помощник.

**Могҗиб** معجب *сф.* Гаҗәпләндерүче, хәйран калдыручы, таң калдыручы. — *пр. д.* 1) Удивляющий; изумительный. 2) Приводящий в восторг.

**Могҗиз** معجز *сф.* 1) Гаҗиз итүче, кешенең кулыннан, көченнән килмәслек, аптырауда калырлык итеп эшләнгән нәрсә, күренеш, хәль. 2) Матур сөйләүче. *Уйнагач иблис кулында моңлы саз, Һәр тарафка яңрагач могҗиз аваз.* (Ш. Баб.) — *пр. д.* 1) Удивительный, чудный. 2) Красноречивый.

**Могҗизә*** معجزه *ис.* Могҗиза (акыл җитми торган, табигать законнарына сыймый торган күренеш). — *сущ.* Чудо.

**Могҗәм** معجم *сф.* Нокталы гарәп хәрефе. — *пр. с.* Буква с точками.

**Мозагафь** مضاعف *сф.* Кабатланган, өстәлгән, катлаулы. — *пр. с.* Удвоенный; осложнённый, дополненный.

**Мозагафәтән** مضاعفةً *р.* Кабатланып, берничә кат артык, ике өлеш. *Изге җиргә кызганган мал, батыйль җиргә мозагафәтән китәдер.* (К. Нас.) — *н.* Удвоенно, усложнённо, вдвойне, в несколько раз.

**Мозад** مضاد *сф.* Каршы булган, бер нәрсәнең киресенә хәрәкәт һәм тәэсир итә торган. *Берәү зәһәрле үлән истигъмаль кылып, мәсмүм булса, мозаде мәсмүм булган даруны тизеннән истигъмаль кылмак кирәк.* (К. Нас.) — *пр. д.* Противодействующий, противный.

**Мозариг** مضارع *ис. грам.* Киләчәк заман. — *сущ. грам.* Будущее время.

**Мозаллəл** مظلل *сф.* Күләгәләнгән, күләгә астында булган. — *пр. с.* Затенённый, находящийся под тенью.

**Мозарәбә** مضاربه *м. III.* 1) Сугышу. 2) Конкуренция. — *м. III.* 1) Борьба, битва; драка. 2) Конкуренция.

**Мозаф** مضاف *сф.* 1) Кушылган, бәйләнгән, ...-га караган. 2) *грам.* Иярүче сүз, изафә. *Әмма мозаф ахырындагы рабыт хәрефен хәзеф кыйлмак җаиз түгелдер.* (К. Нас.) — *пр. с.* 1) Добавленный; присоединённый. 2) *грам.* Слово, определяемое родительным падежом, изафет.

**Мозафат** مضافات *ис.* 1) Мозаф-ның *к.* 2) Район, төбәк. *Гомәр Хәйям 430 сәнәи һиҗридә Астрабад мозафатидә Дәһек карьясендә тәвәллед идеп, 517 дә вафат итте.* (Ш. ж.) — *сущ.* 1) *мн.* от мозаф. 2) Район.

**Мозафен иләйһи** مضاف اليه *ст. грам.* Ияртүче сүз, иялек килешендәге сүз. *Мозафен иләйһинең игърабы, ягъни „нең" гяһән хәзеф кылынадыр.* (К. Нас.) — *сс. грам.* Определение в родительном падеже.

**Мозаффар** مظفر *сф.* 1) Җиңгән, өстен килгән. 2) Теләгенә ирешкән. — *пр. с.* 1) Победивший, победоносный. 2) Достигший своей цели.

**Мозаффарият** مظفريت *ис.* 1) Өстен килүчелек, өстенлек. 2) Теләккә ирешүчелек. — *сущ.* 1) Победоносность, превосходство. 2) Достижение цели.

**Мозаяка** مضايقه *м. III.* 1) Тыгызлык, тарлык, рәхәтсезлек. 2) Дөнья тарлыгы, авыр хәллелек, кытлык, мохтаҗлык. 3) Кысу, йөдәтү, бәйләнү. *Моны кайдан алдың дип мозаяка кылмаклары шөбһәсездер.* (К. Нас.) — *м. III.* 1) Стеснение, затруднение. 2) Нужда; потребность. 3) Приставание, надоедание.

**Мозлим** مظلم *сф.* 1) Караңгы. 2) Билгесез. 3) Кара. — *пр.д.* 1) Тёмный, мрачный. 2) Неясный. 3) Чёрный.

**Мозмәхил** مضمحل *сф.* Беткән, югалган, эзе дә калмыйча һәлак булган. *Гайре нәрсәләр күңелләремездән тәмам мозмәхил булып ...* (К. Нас.) *пр. д.* Исчезнувший; погибший; пропавший бесследно.

**Мозтар** مضطر *сф.* 1) Чарасыз, көчләнгән, мәҗбүр, ирексез ителгән. *Булып мозтар, гыйлемгә кылды бәйгать.* (Дәрд.) 2) (Берәр нәрсәгә) мохтаҗ булган. *пр. с.* 1) Принуждённый, вынужденный. 2) Нуждающийся (в чём-либо).

**Мозтариб** مضطرب *сф.* 1) Тарлыкка төшкән, аптырауда калган, тынычсызланган, тетрәнгән, борчылган, дулкынланган. *Шаһзадәләрнең мәмләкәт эшенә катышуларына мозтариб булып, аларны бер якка җибәрүне уйлап йөри иде.* (К. Нас.) 2) Тигезсез (мәс., юл). *пр. д.* 1) Возбуждённый, волнующийся, путаный, беспокойный. 2) Неровный (о дороге); мутный (о воде).

**Мозхик** مضحك *сф.* 1) Көлдерүче; кызыклы көлке сөйләүче. *Бер мозхик, төрле мәсхәрәлекләр сөйләп, халыкны көлдерде.* (К. Нас.) 2) Мәзәкче. *пр. д.* 1) Комический, смешной. 2) Шутник.

**Мозыйг** مضيع *сф.* Әрәм-шәрәм итүче; югалтучы, заигъ итүче. *пр. д.* Расточитель; теряющий.

**Мозыйль** مضل *сф.* Туры юлдан чыгаручы (яздыручы); аздыручы, адаштыручы. *пр. д.* Сбивающий с пути; вводящий в заблуждение, обманчивый.

**Мозыйр** مضر *сф.* Зарар бирүче, зарарлы, зыянлы; зарар итүче. *Алар галәмгә мозыйрдыр.* (К. Нас.) *пр. д.* Вредный, зловредный.

**Мозыйф** مضيف *сф.* Кунак итүче, кунакчыл, кунак сыйлаучы. *пр. д.* Гостеприимный, радушный.

**Мозыйх** مضيح *сф.* Ачыклык кертүче, ачыклаучы. *пр. д.* Делающий ясным, разъясняющий.

**Мозыйэ** مضئ *сф.* 1) Яктыртучы, яктылык бирүче, нурландыручы. 2) Якты, нурлы. *пр. д.* 1) Освещающий; дающий свет. 2) Светлый, яркий.

**Мокабил** مقابل *сф.* 1) Кара-каршы. 2) Бер нәрсәнең алмашы, бер әйбергә каршы бирелгән әйбер. *Баланы бүре авызыннан алып: „Саил авызына каптырган локмәнең мокабиле бу", — дип хатын кулына тапшырды.* (К. Нас.) *пр. д.* 1) Противоположный. 2) Заменяющий. 3) Эквивалент, замена, возмещение.

**Мокабәлә** مقابله *м. III.* 1) Ике әйберне бер-беренә каршы куеп чагыштыру. 2) Каршылау. 3) *астр.* Кара-каршы килү. 4) Каршы тору, каршы җавап кайтару. *м. III.* 1) Сопоставление, сличение. 2) Свидание, встреча. 3) *астр.* Противостояние. 4) Противоречие; сопротивление.

**Мокабәхә** مقابحه *м. III.* Бер-берен сүгү, сүгешү. — *м. III.* Ругань, взаимное нанесение оскорблений.

**Мокавәлә** مقاوله *м. III.* 1) Сөйләшү. 2) Килешү, сүз бирешү, карар итешү. *Ике арада булган мокавәлә нигезендә ул Румада калып Италия вә Испанияне идарә итәчәк.* (Х. Чис.) — *м. III.* 1) Беседа, разговор. 2) Соглашение; примирение.

**Мокайәсә** مقایسه *м. III.* Тиңләштерү, чагыштыру, ике нәрсәне бер-бере белән чагыштыру. — *м. III.* Сопоставление, сравнение.

**Моканнәд** مقند *сф.* Шикәрләнгән, шикәр салынган, шикәрле. — *пр. с.* Засахаренный.

**Мокариб** مقارب *сф.* 1) Якын. 2) Бер-беренә якынлашкан, якынлаша торган. — *пр. д.* 1) Близкий. 2) Сближающийся, приближающийся.

**Мокарин** مقارن *сф. кара:* мокариб. *„Кыр тычканы әйтте: күп нигъмәтне каты бәлагә мокарин күрдем".* (К. Нас.) — *пр. д. см.* Мокариб.

**Мокаррир** مقرر *м. III.* Телдән сөйләп аңлатучы, бәян итүче, докладчы. — *м. III.* 1) Докладчик. 2) Разъясняющий.

**Мокарәбә** مقاربه *м. III. кара:* мокарәнәт. — *м. III. см.* Мокарәнәт.

**Мокарәнәт** مقارنت *м. III.* 1) Бер-беренә якын килү, якынлашу. 2) Якынлык. *Мин аларга мокарәнәтем белән бозыклар җөмләсеннән булып киттем.* (К. Нас.) — *м. III.* 1) Сближение, соединение. 2) Близость.

**Мокассәм** مقسم *сф.* Өлешләргә (кисәкләргә) бүлгәләнгән. — *пр. с.* Разделенный на много частей.

**Мокасәмә** مقاسمه *м. III.* 1) Бүлешү. 2) Ант итешү. — *м. III.* 1) Раздел. 2) Взаимная клятва.

**Мокатага** مقاطعه *м. III.* Дуслыкны өзү; мөнәсәбәтне (бәйләнешне) өзү. — *м. III.* Прерывание дружбы; разрыв отношений, связи.

**Мокаттаг** مقطع *сф.* 1) Кисәк-кисәк ителгән, кисәкләнгән. 2) Кыскартылган. 3) Өзелгән. — *пр. с.* 1) Разрубленный на части. 2) Сокращённый. 3) Прерванный.

**Мокаттагат** مقطعات *ис. к.* 1) Өзек-өзек тезмә әсәрләр. 2) Кыскартмалар. — *сущ.* 1) Поэтические отрывки, мелкие стихотворения. 2) Условные сокращения.

**Мокаттар** مقطر *сф.* Тамчыланган, тамчы-тамчы ителгән, тамчылатылган, куылган (сыек нәрсәне буга әйләндереп). — *пр. с.* Дестиллированный, перегнанный.

**Мокатәлә** مقاتله *м. III.* Үтерешү; сугыш, кисеш. — *м. III.* Битва, резня, бой, сражение.

**Мокаувим** مقويم *сф.* 1) Торгызучы, турайтучы, рәтләүче, тәртипкә китерүче. 2) Бәясен билгеләүче. — *пр. д.* 1) Выпрямитель; выравнивающий, упорядочивающий. 2) Оценщик; таксатор.

**Мокаффа** مقفا *сф. шигъ.* Кафияләнгән, рифмаланган (шигырь юлларының ахыры аваздаш сүзләргә яки бер калыптагы сүзгә, иҗеккә бетә торган ителгән). — *пр. с. поэт.* Рифмованный.

**Мокаясә** مقايسه *м. III.* Тиңләштерү, чагыштыру, ике нәрсәне бер-берсе белән чагыштырып карау. — *м. III.* Сопоставление, сравнение.

**Мокнигъ** مقنع *сф.* Канәгатьләндерүче, кандыручы. — *пр. д.* Удовлетворяющий.

**Моктәбис** مقتبس *сф.* Башкаларга ияреп, күчереп язучы, икенче бер язучыдан файдаланып язучы. *Моктәбислектә Жуковский зур остазым минем...* (Г. Тук.) — *пр. д.* Заимствующий; подражающий.

**Моктәбәс** مقتبس *сф.* Күчереп алынган, сайлап алынган, икенче бер чыганактан файдаланып язылган. — *пр. с.* Заимствованный, перенятый.

**Моктәда** مقتدا *сф. кара:* моктәда биһ. — *см.* Моктәда биһ.

**Моктәда биһ** مقتدابه *ст.* Иярткүче; буйсындыручы. — *сс.* Руководитель; ведущий; подчиняющий.

**Моктәди** مقتدى *сф.* Иярүче. — *пр. д.* 1) Следующий за кем-либо. 2) Подражающий.

**Моктәдир** مقتدر *сф.* 1) Көчле, көче житүче. *Каләм тотмая вә язмая моктәдир улмаян исәгез...* (З. Биг.) 2) Сәләтле. 3) Бай. — *пр. д.* 1) Сильный. 2) Способный. 3) Богатый.

**Моктәдирә** مقتدره *сф.* Моктәдир-нең *мнс. Сүз әйтмәя моктәдирә улмаеп...* (З. Биг.) — *жен.* от моктәдир.

**Моктәза** مقتضا، مقتضى *сф.* Теләнгән, кирәксенелгән, теләккә туры килгән, лязим булган. *Мосафирләргә вә гарипләргә моктәза булган ригаягә тәхриз мәкамендә китерелер.* (К. Нас.) — *пр. с.* Необходимость, нужда, потребность.

**Моктәзаи заман** مقتضاءِ زمان *из.* Заман теләгәнчә. — *из.* По требованию обстоятельств, времени.

**Моктәзый** مقتضى *сф.* 1) Теләүче, кирәк табучы. 2) Кирәкле, кирәк. — *пр. д.* 1) Желающий. 2) Нужный, необходимый, потребный.

**Моктәзыят** مقتضيات *ис. к.* Кирәкле булган нәрсәләр, тиеш табылган нәрсәләр (эшләр).
*сущ. мн.* Потребности, всё нужное, необходимое.

**Моктәсыйд** مقتصيد *сф.* 1) Экономика белгече. *Моктәсыйд мәгъруф Туган-Барановский әфәнде ...* (Ш. ж.) 2) Саклап тотучы.
*пр. д.* 1) Экономист. 2) Экономный, бережливый.

**Мокыйм** مقم *сф.* Урнашкан, бер урында урнашып торучы, өендә торучы. *Сарай эчрә* (эчендә) *Йосыф мокыйм улды исә ...* (К. Гал.)
*пр. д.* Живущий, проживающий (на одном месте).

**Мокыйр** مقر *сф.* 1) Карар чыгаручы. 2) Икърар итүче, турысын (дөресен) сөйләп бирүче. *Белә алмыйбыз дигән сүзләр белән мокыйр вә могтәриф булдылар.* (К. Нас.)
*пр. д.* 1) Решающий; постановляющий. 2) Сознающийся, признающийся.

**Моназарә** مناظره *м. III.* Сүз көрәштерү, бәхәсләшү; дискуссия.
*м. III.* Диспут, спор, дискуссия.

**Моназир** مناظر *сф.* Бәхәсләшүче, бер мәсьәлә өстендә сүз көрәштерүче, бәхәсләшүгә, сүз көрәштерүгә оста кеше. *Моназир Җиһанша исеме белән мәшһүр булды.* (З. Һад.)
*пр. д.* Спо́рящий.

**Монаказә** مناقضه *м. III.* Капма-каршылык, килешмәүчелек.
*м. III.* Противоречие, несогласие.

**Монафикъ** منافق *сф.* Монафыйк, ике йөзле, эчкерле (кеше).
*пр. д.* 1) Лицемер. 2) Двуличный.

**Монафәга** منافعه *м. III.* Файда; файда күрү.
*м. III.* Польза, благо, выгода.

**Монкад** منقاد *сф.* Буйсынучы, сүз тыңлаучы, сүзгә ияручe. *Киңәшемә монкад булмак кирәксең ...* (К. Нас.)
*пр. с.* Повинующийся, идущий на поводу у кого-либо.

**Монкашир** منقشر *сф.* Кабыгы суелган, тиресе туналган.
*пр. с.* Очищенный, вышелушенный.

**Монсариф** منصرف *сф.* 1) Китүче, узып китүче. ...*хезмәтчесе: „Әй кеше, монсариф бул“, — диде.* (К. Нас.) 2) Чигенгән, кирегә әйләнгән, кире әйләнеп кайтучы. 3) *грам.* Төрләнә ала торган (сүз).
*пр. д.* 1) Уходящий, проходящий; направляющийся куда-либо. 2) Отходящий. 3) *грам.* Склоняющийся.

**Монсарих** منصرح *сф.* Ачык; икеләнү мөмкин булмаслык дәрәҗәдә ачылган, шиксез.
*пр. д.* Ясный, понятный.

**Монсыйф** منصف *сф.* Инсафлы, турылыклы, гадел кеше. *Хәсән агай яхшы вә монсыйф бер зат иде.* (Г. Габ.)
*пр. д.* Справедливый, правосудный.

**Монсыйфанә** منصفانه *гф. р.* Инсафлы рәвештә, турылык белән, гаделлек белән. *„Балыкчы кармагын сатса, ни белән балык тотар",— дип монсыйфанә җавап биргән.* (К. Нас.) — *ар.-п. н.* По справедливости, справедливо.

**Монтабих** منطبخ *сф.* Пешкән, пешерелгән. — *пр. д.* Сваренный, испечённый.

**Монтабыйк** منطبق *сф.* Бөтенләй туры килгән, тигез, муафыйк. *Фәхринең фәхре, түгел язмышы белән монтабыйк.* (Ш. Баб.) — *пр. д.* Соответствующий, сходный с чем-либо; прилегающий.

**Монтазам** منتظم *сф.* Тәртипкә салынган, тәртипле, рәтләнгән, рәтле. *Монтазам булсынмыни соң гаскәрең, алгач үрнәккә Бохара гаскәрен.* (Г. Тук.) — *пр. д.* Упорядоченный; урегулированный; благоустроенный.

**Монтарид** منطرد *сф.* Кире кагылган, куылган, кулланудан чыгарып ташланган. — *пр. д.* Прогнанный, изгнанный; выкинутый.

**Монтәсаб** منتصب *сф.* Кадап куйган, текә утыртылган, кадалган. — *пр. с.* 1) Поставленный прямо. 2) Воздвигнутый, водружённый.

**Монтәсыйф** منتصف *с.* 1) Урталай ярылган, ярты, урта. 2) Яртылашкан, яртысына җиткән. — *прил.* 1) Средний, расколотый пополам. 2) Достигший середины.

**Морагать** مراعة *м. III.* 1) Саклау, күзәтү. 2) Игътибар итү, әдәп саклау. — *м. III.* 1) Охранение, наблюдение. 2) Уважение, внимание, соблюдение приличия.

**Морад*** مراد *сф.* Морат, максат, теләк, теләнгән әйбер, аңлатылырга, белдерелергә уйланган нәрсә. — *пр. с.* 1) Цель; желание. 2) Предмет желания.

**Морадиф** مرادف *сф. грам.* Бер мәгънәдә килә торган, бер мәгънәле, синоним. ... *Якыйн* (анык) *тарафы өстен булса, гыйлемнең морадифе булыр* ... (К. Нас.) — *пр. д. грам.* Синоним.

**Мораи** مرائى *сф.* Яхшылыкны кешегә күрсәтү өчен генә эшләүче, күз буяучы, риялык итүче; яхшы булып күренергә тырышучы. *Кеше терек вакытында да мораи була, үлгәч тә мораи була, чөнки җеназасында кеше күп булганны ярата, — диде.* (К. Нас.) — *пр. д.* Лицемер, ханжа; очковтиратель.

**Моракабә** مراقبه *м. III.* 1) Уйга чуму. 2) Көтү, көтеп тору, күзәтү. *Карт мулла, тирән моракабәгә охшаш бер хәл-* — *м. III.* 1) Созерцание, размышление. 2) Наблюдение, надзор; контроль.

*дән соң, ... тыныч йөрәк белән кайтырга и нәлде.* (Г. Ибр.)

**Моракыйб** مراقب *с.* Күзәтүче, саклаучы; моракабәгә китүче. *Моракыйб сурәтендә утырыплар.* (Ут. Им.) — *прил.* Наблюдающий, хранящий; размышляющий.

**Морафәга** مرافعه *м. III.* 1) Низаг. 2) Дауны чишү өчен судка мөрәҗәгать итү. ... *казый бар иде, аңа морафәга кылдылар.* (К. Нас.) — *м. III.* 1) Тяжба, процесс. 2) Обращение в суд.

**Мораэ** مرائ *ис.* Күз буяу, риялык, яхшылыкны кешегә күрсәтү өчен генә эшләү. — *сущ.* Лицемерие, ханжество.

**Моргъ** مرغ *ф. ис. кара:* мөргъ. — *см.* Мөргъ.

**Мордар** مردار *ф. ис. кара:* мөрдар. — *см.* Мөрдар.

**Морзига** مرضعه *сф.* 1) Сөт анасы, ялланып бала имезүче хатын. *Әмма морзига тапмак җиремездә мөмкин түгел.* (К. Нас.) 2) Имчәк баласы булган хатын. — *пр. д.* 1) Кормящая мать; наёмная кормилица. 2) Женщина, имеющая грудного ребёнка.

**Морәссаг** مرصع *сф.* Кыйммәтле ташлар белән бизәлгән. *Капкасы җәүһәрләр вә зөмерред белән морәссаг...* (К. Нас.) — *пр. с.* Осыпанный (украшенный) драгоценными камнями.

**Мосаггар** مصغر *сф.* 1) Кечерәйтелгән. 2) *грам.* Кечерәйтү исеме. — *пр. с.* 1) Уменьшенный. 2) *грам.* Уменьшительное имя.

**Мосаддак** مصدق *сф.* Тикшерелгән, расланган, дөрескә чыккан. — *пр. с.* Проверенный, установленный, удостоверенный; подтверждённый.

**Мосаддар** مصدر *сф.* Баш итеп куелган, югары дәрәҗәле. *Мосаддар җай илә тәгъзыйм итәрләр.* (Ут. Им.) — *пр. с.* Поставленный во главе.

**Мосаддыйк** مصدق *сф.* Раслаучы, дөреслеген ныгытучы. — *пр. д.* Считающий правильным, подтверждающий; удостоверяющий.

**Мосалла** مصلى *сф. дини* 1) Намаз укыла торган урын. 2) Намазлык. *Вафат булса, җирдә мосалласы, ягъни намазлыгы егълар димешләр.* (К. Нас.) — *пр. с. рел.* 1) Место для молитвы. 2) Коврик для молитвы.

**Мосалли** مصلى *сф.* Намаз укучы кеше. — *пр. д.* Молящийся.

**Мосаләхә** مصالحه *сф.* Ике хөкүмәт арасында килешү, ярашу; дау, низагны бетерү; тынычлашу. — *пр. с.* Примирение, установление мира.

**Мосаннаг** مصنع *сф.* Гүзәл, оста эшләнгән, сәнгатьчә эшләнгән. — *пр. с.* Сделанный мастерски, искусно.

**Мосанниф** مصنف *сф.* Китап (әсәр) төзүче, үз башыннан уйлап язучы. — *пр. д.* Автор, сочинитель; композитор.

**Мосаннәфат** مصنفات *ис. к.* Төзелгән, язылган китаплар, әсәрләр. — *сущ. мн.* Литературные произведения.

**Мосаррах** مصرح *сф.* Ачык итеп, киңәйтеп белдерелгән, ачык аңлатылган. — *пр. с.* Объяснённый, разъяснённый.

**Мосафих** مصافح *сф.* Күрешүче, кул бирүче. *Күрешсә, мосафих кулын алмый торып, кулын алмас иде.* (К. Нас.) — *пр. д.* Приветствующий рукопожатием.

**Мосаффа** مصفى *сф.* 1) Сафланган, чистартылган, тазартылган. 2) Саф, таза, ару. — *пр. с.* 1) Очищенный, процеженный, профильтрованный. 2) Приятный, чистый.

**Мосаффаф** مصفف *сф.* Саф-саф итеп тезелгән, сафларга тезелгән. — *пр. с.* Установленный в ряд, приведенный в порядок.

**Мосафәхә** مصافحه *м. III.* Күрешү, кул кысышу. *Һәр каюлары илә мосафәхә кылышып, кайтып китте.* (З. Биг.) — *м. III.* Рукопожатие.

**Мосахиб** مصاحب *сф.* Утырышка, сөйләшүгә катнашучы; утырдаш, иптәш. *Бер көн мосахибләре белән утырганда ...* (К. Нас.) — *пр. д.* Друг, собеседник.

**Мосахәбә** مصاحبه *м. III.* Кара-каршы сөйләшеп утыру, утырышу. *Әгәр бер адәм белән мосахәбә кыйлсаң, аның гакылына кара ...* (К. Нас.) — *м. III.* Собеседование.

**Мосахәбәт** مصاحبت *кара:* мосахәбә. — *см.* Мосахәбә.

**Мосаххих** مصحح *сф.* 1) Төзәтүче, дөресләүче. 2) Корректор. — *пр. д.* 1) Исправляющий. 2) Корректор.

**Мосаххәх** مصحح *сф.* Төзәтелгән, дөресләндерелгән. — *пр. с.* Исправленный.

**Мосаувир** مصور *сф.* Сурәт ясаучы, сурәт төшерүче, рәссам, художник. *И, мосаувир, кемгә биргән пакь вә чын сүз кибрия!* (Г. Тук.) — *пр. д.* 1) Художник; рисующий. 2) Живописец.

**Мосаувәр** مصور *сф.* 1) Сурәтләнгән, сурәтле. 2) Рәсемнәр белән бизәлгән, рәсемле. 3) Уйлап күз алдына китерелгән. — *пр. с.* 1) Иллюстрированный. 2) Нарисованный, изображённый. 3) Воображаемый.

**Мосаһәрәт** مصاهرة *м. III.* Ир белән хатынның якыннары арасындагы кардәшлек (кодалык, кияү булу һ. б.). — *м. III.* Родство; свойство́.

**Captions**

**Мослих** مصلح *сф.* 1) Төзәтүче, яхшылатучы. *Канәфер кәзалик тагамны мослих нәрсәдер.* (К. Нас.) 2) Реформатор. — *пр. д.* 1) Исправляющий; улучшающий. 2) Реформатор.

**Мосталәх** مصطلح *сф.* 1) Терминлашкан; әдәбиләшкән (сүз һәм тәгъбир). *Ул эшләрнең исемнәре гарәп арасында мәшһүр мосталәхтыр.* (К. Нас.) 2) Термин, атама. — *пр. с.* 1) Термин; условное выражение. 2) Идиоматический, принятый в языке.

**Мостафа** مصطفى *сф.* 1) Сайланган, сайлап алынган. *Дәрдә сәрдар улмага бән мостафаем, ниләем?* (Г. Тук.) 2) Мөхәммәт пигамбәрнең кушаматы. 3) Кеше исеме. — *пр. с.* 1) Избранный, избранник. 2) Эпитет Мухаммеда. 3) *и. с.* Мустафа.

**Мосхәф** مصحف *сф.* 1) Аерым кәгазь битләреннән җыелган, кушылган. 2) Коръән. *Кулларында мосхәф шәриф тотмышлар.* (К. Нас.) — *пр. с.* 1) Свиток, книга. 2) Коран.

**Мосыйб** مصيب *сф.* Дөресен табучы, теләгенә ирешүче, турылыкта булучы. — *пр. д.* Правильный, точный, согласный с истиной.

**Мосыйбәт** مصيبت *ис.* **1.** Аңсыздан килгән кайгы, бәла, башка төшкән авырлык. **2.** Кайгылы, хәсрәтле. — *сущ.* **1.** Беда, несчастье, катастрофа. **2.** Горестный.

**Мосыйбәтзадә** مصيبتزاده *гф. с.* Кайгыга очраган, кайгыга дучар булган, кайгылы. — *ар.-п. прил.* Горестный, печальный.

**Мотабикъ** مطابق *сф.* Туры килгән, охшаган, уйгын. *Максудыма мотабикъ җавап алдым.* (З. Бин.) — *пр. д.* Соответствующий, подходящий; согласующийся; сходный.

**Мотабәкать** مطابقت *м. III.* Туры килү, охшашлылык. — *м. III.* Соответствие, согласованность, сообразность, подобие.

**Мотавәгать** مطاوعت *м. III.* Буйсыну, баш ию. — *м. III.* Повиновение, подчинение, покорность.

**Моталла** مطلا *сф.* 1) Алтын йөгертелгән, алтын белән ялтыратылган. 2) Ялтыратылган, шомартылган, ялтыравыклы. *Һәркайсының кулларында мөҗәүһәр вә моталла берәр хөллә...* (К. Нас.) — *пр. с.* 1) Позолоченный. 2) Полированный, блестящий.

**Моталəбə** مطالبه *м. III.* Тиешле хакын сорау, түлəүне талəп итү. *Хəзинə малын аннан моталəбə кылдылар.* (К. Нас.)

*м. III.* Просьба об уплате; требование уплаты (долга).

**Моталəга** مطالعه *м. III.* Уку, өйрəнү; эшне, берəр мəсьəлəне төрле яктан тикшереп хөкем чыгару. *Китапларны моталəгалерəк шəкертлəрə вирсə кирəк.* (М. Ак.)

*м. III.* Чтение, изучение; суждение; резюме.

**Мотантан** مطنطن *сф.* Тантаналы.

*пр. с.* Торжественный.

**Мотаувəл** مطول *сф.* Озынайтылган, озын. *Тəфсыйлен эстəүчелəр „Шəрхе муафыйк" вə „Шəрхе гакайд" кебек мотаувəл китаплардан карарлар.* (К. Нас.)

*пр. с.* Удлинённый, вытянутый, растянутый.

**Мотаябə** مطايبه *м. III.* Кара-каршы көлкеле-күнелле сүзлəр əйтешү, сүз арасына кызыклы сүзлəр кыстыру. *Берберенең йөзенə төкереп аерылырлар иде дип, хуш мотаябə кылмыштыр.* (К. Нас.)

*м. III.* Шутка, острота.

**Мотаһһəр** مطهر *сф.* 1) Тазартылган, чистартылган, пакьлəнгəн. 2) Изге.

*пр. с.* 1) Очищенный, чистый. 2) Священный.

**Мотлак*** مطلق *сф.* 1) Һичнəрсə белəн шарт ителмəгəн, абсолют, чиклəнмəгəн; һич шартсыз, ничек кенə булмасын. *Шөбһə юк, мотлак харамдыр йоклап яту.* (М. Гаф.) 2. Бəйсез.

*пр. с.* 1) Абсолютный, безусловный, непременный. 2) Неограниченный, независимый.

**Мотлакан*** مطلقا *р.* Шартсыз, шиксез, ничек булса да, һичнəрсəгə карамастан. *Əфəндем бал икмəксез мотлакан мигъдəне яндырыр диде.* (К. Нас.)

*н.* Абсолютно, безусловно, непременно.

**Мотмəин** مطمئن *сф.* Тынычланган, күңеле тынычлык тапкан, күңеле утырган. *Кальбең мотмəин булган...* (К. Нас.)

*пр. д.* Уверенный, спокойный, убеждённый.

**Мотмəиннə** مطمئنه *сф.* Мотмəин-нең мнс. *Кайт, и нəфсе мотмəиннəм.* (Г. Тук.)

*жен.* от мотмəин.

**Моттарид** مطرد *сф.* 1) Эзлекле, бербер артлы килгəн. 2) Тулысынча кабул ителердəй, тəртипле. 3) Төзек.

*пр. д.* 1) Непрерывный, последовательный. 2) Безусловный. 3) Исправный.

**Мотыйг** مطيع *сф.* Буйсынучы, баш июче, сүз тыңлаучы. *Юмартлык кылган кеше халыкны үзенə мотыйг кылды.* (К. Нас.)

*пр. д.* Покорный, послушный.

**Мотыйганә** مطیعانه *р.* Буйсынып. *Зиа сукырның кулында мотыйганә җылаган гармонга карап катып торды.* (Г. Ибр.) — *н.* Покорно, послушно.

**Мофрит** مفرط *сф. кара:* мофрита. — *см.* Мофрита.

**Мофрита** مفرطه *сф.* Уртачалык чигеннән узып киткән; чамадан тыш. — *пр. д.* Чрезмерная, непомерная, неумеренная.

**Мофтыйр** مفطر *сф. дини* Уразасын ачучы. — *пр. д. рел.* Прерывающий пост, завтракающий.

**Мохабир** مخابر *сф.* Хәбәрләшүче, бер-бере белән хәбәрләшеп, язышып торучы. — *пр. д.* Переписывающийся, имеющий письменные сношения.

**Мохабәрат** مخابرات *ис.* Мохабәрәнең *к.* — *сущ. мн.* от мохабәрә.

**Мохабәрә** مخابره *м. III.* Хәбәрләшү, хәбәр алышу. — *м. III.* Переписка; корреспонденция.

**Мохадәга** مخادعه *м. III.* Алдашу, хәйләләшү. — *м. III.* Обман (взаимный).

**Мохадәнәт** مخادنت *м. III.* Дуслык, ихласлык. *Рәкыйбләр арасында мохадәнәт улмаячагы табигыйдер.* (Ш. ж.) — *м. III.* Изъявление дружбы; дружба.

**Мохалиф** مخالف *сф.* 1) Охшашмаган. 2) Каршы килә торган, каршы. *Җил мохалиф булып, диңгез өстендә дулкыннар пәйда булды.* (К. Нас.) — *пр. д.* 1) Противоречащий; противоречивый. 2) Противник.

**Мохаләса** مخالصه *м. III.* 1) Үзара чын дуслык, татулык, яратышып тору. 2) Ихласлы, турылыклы булу. — *м. III.* 1) Искренняя дружба. 2) Преданность, верность.

**Мохаләта** مخالطه *м. III.* 1) Катнаштыру, аралаштыру, буташтыру. 2) Катышу, катнашу. — *м. III.* 1) Примешивание. 2) Общение, сношение.

**Мохаләфәт** مخالفت *м. III.* Каршылык, каршы булу, оппозиция; каршы хәрәкәт. *Мохаләфәт дошманлыкны муҗибдер.* (К. Нас.) — *м. III.* Противоречие, оппозиция, неповиновение, противодействие.

**Мохасамә** مخاصمه *м. III.* Дәгъвәләшү, тарткалашу-низаглашу. *Җинаять мохасамәне, мохасамә дошманлыкны лязим итә.* (К. Нас.) — *м. III.* Спор, тяжба, вражда, антагонизм.

**Мохасим** مخاصم *сф.* Дәгъвәләшүче, тарткалашучы, низаглашучы, судлашып йөрүче. — *пр. д.* Противник, соперник, ведущий тяжбу.

**Мохат** مخاط *сф. кара:* мөхат. — *см.* Мөхат.

**Мохатарә** مخاطره *м. III.* Куркыныч, куркынычлыкка төшү. *Кыз кешенең кәлмәсе тәгаҗҗебле вә мохатарәле бер эш...* (М. Ак.) — *м. III.* Опасность, риск.

**Мохатиб** مخاطب *сф.* 1) Эндәшүче, сөйләшүче, сүз белән мөрәҗәгать итүче. 2) Сүз алып сөйләүче, оратор. — *пр. д.* 1) Говорящий, обращающийся с речью. 2) Оратор.

**Мохаттат** مخطط *сф.* Сызылган, юл-юл итеп сызылган. — *пр. с.* Полосатый, рубчатый.

**Мохатәб** مخاطب *сф.* 1) Эндәшелгән зат; тыңлаучы. *Тәнакыш юк мисалдә, әй мохатәб.* (Г. Тук.) 2) *грам.* II нче зат. — *пр. с.* 1) Тот, к кому обращена речь. 2) *грам.* 2-е лицо.

**Мохатәбә** مخاطبه *м. III.* 1) Бер-беренә эндәшү. 2) Кара-каршы сөйләшү. — *м. III.* 1) Обращение. 2) Обмен речами; беседа.

**Мохбир** مخبر *сф.* 1) Хәбәрче, хәбәр бирүче, хәбәр китерүче. 2) Газета хәбәрчесе. — *пр. д.* 1) Вестник. 2) Корреспондент.

**Мохилл** مخل *сф.* Зарар китерүче, бозучы; тукынучы; комачаулаучы; тәртип бозучы, шау-шу күтәрүче. — *пр. д.* Расстраивающий, портящий, мешающий, нарушающий порядок, тишину.

**Мохилл намус** — намуска тукынучы, намусны хурлаучы. — Задевающий (чью-либо) честь.

**Мохлис** مخلص *сф.* Ихласлы; дуслыгы, могамәләсе чын күңелдән булган кеше. *Адәмнең кәсеб кылганының иң файдалысы мохлис дустыр.* (К. Нас.) — *пр. д.* Искренний, сердечный, честный, преданный.

**Мохриб** مخرب *сф.* 1) Зарар китерүче, бозучы, һәлак итүче. 2) Харап итүче, вәйран итүче, ватучы, җимерүче. — *пр. д.* 1) Вредитель, разрушитель, губитель, истребитель. 2) Разрушающий; разрушительный.

**Мохсинат** محصنات *ис.* Мохсинә-нең *к.* — *сущ. мн.* от мохсинә.

**Мохсинә** محصنه *ис.* 1) Ирле хатын; намуслы хатын. 2) Гыйффәтле (хатын). — *сущ.* 1) Замужняя. 2) Целомудренная.

**Мохтазир** محتضر *сф.* Үләргә хәзер торучы, хәзерләнеп торучы, үлемгә хәзерләнүче. *Икесе дә кинәт сырхау булып, бер түшәктә мохтазир булган хәлдә...* (К. Нас.) — *пр. д.* Находящийся при смерти.

**Мохтар** مختار *сф.* 1) Сайланган, сайландык. 2) Ирекле, ихтыярлы. 3) Ирекге үзендә булган кеше, бәйсез. — *пр. с.* 1) Полномочный, самостоятельный. 2) Выборный. 3) Избранный, свободно действующий.

**Мохтарият** مختاريت *ис.* 1) Иреклелек, ихтыярлылык. 2) Бәйсезлек, идарә үз ихтыярында булучылык. — *сущ.* 1) Свобода выбора, свобода воли. 2) Самостоятельность; самоуправление.

**Мохтаж*** محتاج *сф.* Хаҗәте булган кеше, фәкыйрь, моң, ярдәмчесез. — *пр. д.* Нуждающийся, ощущающий потребность (в чем-либо).

**Мохтыйр** مخطر *сф.* Хәтергә китерүче, хәтерләтүче, искә төшертүче. — *пр. д.* Напоминающий, заставляющий вспоминать.

**Мохтәзән** مختزن *сф.* 1) Хәзинәдә сакланган. 2) Җыелган. — *пр. с.* 1) Накопленный; припасённый. 2) Собранный, хранимый.

**Мохтәлитъ** مختلط *сф.* 1) Катыш, башка әйбер белән катышкан. 2) Катлаулы. — *пр. д.* 1) Смешанный; сводный, сборный. 2) Сложный.

**Мохтәлиф** مختلف *сф.* Төрле, һәртөрле, капма-каршы; чуалган. — *пр. д.* Различный, разный; запутанный.

**Мохтәлифә** مختلفه Мөхтәлиф-нең *мнс.* — *жен.* от мохтәлиф.

**Мохтәләф** مختلف *сф.* Каршы (фикер); килешә алмау. — *пр. с.* Противоположное (мнение); несогласие, разногласие.

**Мохтәригъ** مخترع *сф.* Уйлап табучы, уйлап чыгаручы. — *пр. д.* Изобретатель, сочинитель.

**Мохтәрәгат** مخترعات *ис.* Уйлап табылганнар, уйлап чыгарылганнар, уйлап чыгарган нәрсәләр. *Баруд чин халкы мохтәрәгатыннандыр.* (К. Нас.) — *сущ.* Изобретения.

**Мохтәрәгъ** مخترع *сф.* 1) Уйлап табылган, уйлап чыгарылган. 2) *күч.* Уйдырма. — *пр. с.* 1) Изобретённый, выдуманный, сочинённый. 2) *перен.* Выдумка.

**Мохтәс** مختص *сф.* Бер нәрсәгә караган, хасланган, билгеләнгән; үзенчәлекле, специфик. — *пр. с.* Свойственный, специальный, особенный, специфический.

**Мохтәсар** مختصر *сф.* 1) Кыска, кыскача. 2) Теләкне кыскалык белән аңлату. *Мохтәсар кылды* — кыскартты. — *пр. с.* 1) Краткий, небольшой, сокращённый; резюмированный. 2) Краткое, сокращённое изложение.

**Мохтәсарән** مختصراً *р.* Кыскалык белән, кыска итеп, кыскача, кыскартып. — *н.* Вкратце, кратко.

**Мохтәҗиб** محتجب *сф.* Каплanучы, өртелүче, капланган, өртелгән. — *пр. д.* Покрывшийся, закутавшийся.

**Мохәйял** مخيل *сф.* Хыял ителгән, юк-бар уйдан торган, хыялый. — *пр. с.* Воображаемый, фантастический.

**Мохәйяр** مخير *сф.* Сайлауда ирекле, ихтыярлы. *Ике эш арасында мохәйяр булса, җиңелрәкне ихтыяр кылыр иде.* (К. Нас.)

*пр. с.* Свободный в выборе.

**Мохәлләфат** مخلفات *ис.* 1) Үлгән кешенең калдырган нәрсәләре. 2) Малмөлкәт.

*сущ.* 1) Имущество, перешедшее по наследству. 2) Достояние; собственность.

**Мохәлләфә** مخلفه *ис.* Тол хатын.

*сущ.* Вдова.

**Мохәрриб** مخرب *сф. кара:* мохриб.

***пр. д. см.*** **Мохриб.**

**Мохәссас** مخصص *сф.* Атап билгеләнгән; үзенә генә караган.

*пр. с.* 1) Назначенный, определённый. 2) Присвоенный (кому-либо).

**Мохәффиф** مخفف *сф.* 1) Җиңеләйтүче, җиңел ясаучы. 2) Гадиләштерүче. 3) Түбән күрүче.

*пр. д.* 1) Облегчающий, смягчающий. 2) Упрощающий. 3) Принижающий (чьё-либо достоинство).

**Мохәффәф** مخفف *сф.* 1) Җиңеләйгән, җиңеләйтелгән. 2) Кыскартылган. *Камилә белән „урыс Пәкри“ (Әбүбәкердән мохәффәф) дигән бер егетне уйнаш кылуда төһмәт итеп...* (Г. Ибр.)

*пр. с.* 1) Облегчённый, смягчённый. 2) Сокращённый, упрощённый.

**Муазәнәт** موازنت *ис.* 1) Бәрабәрлек, тигезлек. 2) Бертигез үлчәүдә булу.

*сущ.* 1) Балансирование, уравновешивание. 2) Равновесие.

**Муалят** موالات *м. III.* 1) Дуслык, дусларча мөгамәлә. 2) Ярдәм. *Дошманың синең белән мөшавәрәт кылышса, сиңа дошманлыгын куеп муалят итмеш булыр.* (К. Нас.)

*м. III.* 1) Дружба, дружеское отношение. 2) Помощь.

**Муанәсәт** موانسه *м. III.* 1) Дуслашу; бер-бере белән иләшеп, дуслашып, аралашып яшәү. 2) Утырдашлык. *Ялкаулар белән муанәсәт кыйлмактан, вә алар белән мәслихәт кыйлышмактан саклан, димешләр.* (К. Нас.)

*м. III.* 1) Установление дружеских отношений; дружба. 2) Собеседование.

**Муасат** مواسات *ис.* Кешенең сагышын (гамен) тарату; ярдәмләшү, булышлык. *Сездән әлгәреләр туйга мөвахәт вә муасат өчен чакыралар иде.* (К. Нас.)

*сущ.* Помощь, поддержка.

**Муасигъ** مواسع *сф.* Сыйдыра торган. *Милләтә һәр фикри тәфкирә муасигъ „Фикер“ емез.* (Г. Тук.)

*пр. д.* Вмещающий, вместительный.

**Муафикъ*** موافق *сф.* 1) Муафыйк, туры килгән, тиң килгән, яраклы, ки-

*пр. д.* 1) Соответствующий, сообразный, под-

лешле, урынлы. *Маһруйның исеме җисеменә муафикъ.* (З. Биг.) 2) Хуплаучы. — ходящий; благоприятный. 2) Согласный, одобряющий.

**Муаффәкыять** موفقيت *ис.* Уңыш, уңайлык, булдыра алучылык. *Алар бу муаффәкыятьләргә ничек ирештеләр.* (М. Гаф.) — *сущ.* Успех, удача; достижение.

**Муаффәкъ** موفق *сф.* Булдыра алган, ирешкән, ирешә алган, эше барып чыккан, көче җиткән. *Кариәләремә гарыз итәргә муаффәкъ булдым.* (Г. Кам.) — *пр. с.* Благоприятствуемый, сопутствуемый удаче; способный, достигающий.

**Муафәкать** موافقت *м. III.* 1) Туры килүчелек, килешү-ярашулык. *Муафәкать өлфәтне муҗибтер.* (К. Нас.) 2) Яраклылык. — *м. III.* 1) Согласование; согласованность, соответствие, согласие. 2) Пригодность.

**Муаҗәһә** مواجهه *м. III.* 1) Кара-каршы килү, йөзгә-йөз килү, очрашу. 2) Бер җирдә булу. — *м. III.* 1) Встреча лицом к лицу. 2) Присутствие (где-либо).

**Муаһиб** مواهب *ис.* Мәүһибә-нең *к.* — *сущ. мн.* от мәүһибә.

**Муаһәбә** مواهبه *м. III.* Зур итеп, күп итеп бүләк бирү. — *м. III.* Большие дары, дорогие подарки.

**Мувәкъкать** موقت *сф.* Вакытлы, бер вакытка караган, вакыт белән чикләнгән. *Мувәкъкать бер хакыйрьлек галәмидер.* (Г. Тук.) — *пр. с.* Временный; ограниченный во времени.

**Мувәкъкатән** موقتاً *р.* Вакытлыча, вакытлы рәвештә. — *н.* Временно.

**Мувәкъкыйть** موقت *сф.* 1) Вакытларны билгеләүче. 2) Хронометрчы. — *пр. д.* 1) Определяющий время. 2) Хронометражист.

**Мувәҗҗә** موجه *с.* Игътибарга алырлык, кабул итәрлек. *Мувәҗҗә гозер* — игътибарга алырлык сәбәп. *Мувәҗҗә гозерләр китерерсең...* (Г. Фәез.) — *прил.* Уважительный, приемлимый.

**Музи** موذى *сф.* Җәбер итүче, җәфалаучы, рәнҗетүче, усал, иза чиктерүче. — *пр. д.* 1) Злой, несправедливый, мучающий. 2) Мучитель, истязатель.

**Музият** موذيات *ис.* Музи-нең *к.* *Пакь булмаган җир бет, борча кебек музиятның булуына сәбәптер.* (К. Нас.) — *сущ. мн.* от музи.

**Мукыйз** موقظ *сф.* Уятучы; аңлатучы, ачыклаучы. — *пр. д.* Пробуждающий, возбудитель; объясняющий.

**Мукыйзат** موقظات *ис.* 1) Дару исеме. 2) Уятучылар. *Рөхемдәге авырулар* — *сущ.* 1) Название лекар-

*өчен истигъмаль кылыныр, „мукыйзате рөхем“ диерләр.* (К. Нас.) — ства. 2) Возбуждающие (лекарства).

**Мулля җәлял** ملاجلال *ис.* Китап исеме. *„Мулля җәлял“дан бәхәсләр йөртеп...* (З. Һади.) — *сущ.* Название книги.

**Мум** موم *ф. ис.* Балавыз; шәм. — *п. сущ.* Воск, свеча.

**Мума иләйһи** مومى اليه *ст.* Күрсәтелгән, югарыда исеме телгә алынган; шул. *Мума иләйһи сахиби мосафирханә кызы.* (М. Ак.) — *сс.* Вышеупомянутый; этот.

**Мумия** موميا *ф. ис.* 1) Мумия (черемәслек хәлгә китерелеп киптерелгән мәет). 2) Сынган сөякне ялгау өчен кулланыла торган дару. — *п. сущ.* 1) Мумия (набальзамированные останки покойника). 2) Мумия (мазь, исцеляющая перелом костей.)

**Мунис** مونس *сф.* 1) Ияләшкән, өйрәнгән, җирләшкән; дус, якын. 2) Якын дус, әшнә. *Ачык йөзлелек мунислекне пәйда кыйлыр.* (К. Нас.) — *пр. д.* 1) Общительный. 2) Интимный друг; сотоварищ.

**Мурис** مورث *сф.* 1) Китерүче; бирүче, йөкләүче. 2) Мирас калдыручы. — *пр. д.* 1) Приносящий; дающий, обязывающий. 2) Завещатель; завещающий.

**Мурчә, мурҗә** مورچه، مورجه *ф. ис.* Кырмыска. *Әгәр кеше яхшылыкны елан вә мурчәгә кылса, заегъ китмәй.* (Мәҗмәгыл хикәять). — *п. сущ.* Муравей.

**Муса ләһ** موصى له *ст.* Үлүче тарафыннан аңа васыять әйтелгән кеше. — *сс.* Наследник.

**Муса биһ** موصى به *ст.* Васыять ителгән нәрсә. — *сс.* Завещанная вещь.

**Мусави** موسوى *с.* 1) Мусага караган, Муса динен тотучы. 2) Яһуди. 3) Шигаларның җиденче имамнары Мусадан килүче. — *прил.* 1) Еврей, последователь Моисеева закона. 2) Еврейский. 3) Происходящий от седьмого шиитского имама Мусы.

**Мусый** موصى *сф.* Васыять әйтүче кеше. — *пр. д.* Завещающий.

**Мусыйкый** موسيقى *с.* Музыка белеме(нә), музыка(га караган). — *прил.* Музыкальный.

**Муш** موش *ф. ис.* Тычкан, күсе. *Уйку эчендә шөтер* (тәвә) *улан ул муш кеби.* (Ут. Им.) — *п. сущ.* Мышь, крыса.

**Мужиб** موجب *сф.* Сәбәп итүче, барлыкка китерүче. *Мөхәләфәт дошманлыкны мужибтер.* (К. Нас.) — *пр. д.* Причина, повод; побудительный мотив.

**Мужид** موجد *сф.* 1) Ижат итүче, барлыкка китерүче, үзлегеннән табып чыгаручы. 2) Алла эпитеты. *Алар өч муҗидкә ышаналар иде.* (З. Һади.) — *пр. д.* 1) Порождающий, вызывающий к существованию. 2) Творец, создатель (эпитет аллаха).

**Мужәб** موجب *сф.* 1) Берәр эштән яки сүздән килеп чыккан хәл. 2) Соңыннан булган эш, нәтиҗә, йомгак. *Зарарымызның мужәбе улан шәйләре...* (К. Нас.) — *пр. с.* 1) Ставший неизбежным. 2) Результат, вывод.

**Мужәз** موجز *сф.* Кыска һәм аңлаешлы сүз, уй. *Аз сүзле булмак вә мужәз сөйләмәк кешенең гакылына дәлилдер.* (К. Нас.) — *пр. с.* Сокращённый; лаконичный.

**Мәаб** مآب *ис.* Сыеначак җир, кайта торган җир, киләә торган урын. — *сущ.* Место возврата; убежище.

**Мәадиб** مآدب *ис.* Мәэдәбә-нең *к.* — *сущ. мн.* от мәэдәбә.

**Мәаль** مآل *ис.* 1) Аңлашылган мәгънә, кыскача эчтәлек. 2) Киләчәк, күздә тотылган соңгы максат. *Ниһаятьсез сәгадәттер мәали.* (Г. Тук.) — *сущ.* 1) Смысл, суть. 2) Конец; исход, последствие. 3) Конечная цель.

**Мәаләи** مآلاً *р.* Мәгънәсе (эчтәлеге) ягыннан. — *н.* По смыслу, не буквально.

**Мәасир** مآثر *ис. к.* Билгеләр, галәмәтләр; әсәрләр, истәлекләр. — *сущ. мн.* Следы, знаки, метки; памятники (старины).

**Мәатим** مآتم *ис. к.* Үлек артыннан елашырга җыелган хатын-кызлар. — *сущ. мн.* Женщины, оплакивающие покойника; плакальщицы.

**Мәахиз** مآخذ *ис.* Мәэхәз-нең *к.* — *сущ. мн.* от мәэхәз.

**Мәбадә** مباد *ф. ым.* Саклана күр, була күрмәсен (булса, эш начар). *Мәбадә, ул хәрәмгә бирсәләр юл.* (Дәрд.) — *п. межд.* Как бы не...; не дай бог, да не будет.

**Мәбалигъ** مبالغ *ис.* Мәбләгъ-нең *к.* — *сущ. мн.* от мәбләгъ.

**Мәбани** مبانی *ис.* Мәбна-ның *к.* — *сущ. мн.* от мәбна.

**Мәбариз** مبارز *ис.* Мәбрәз-нең *к.* — *сущ. мн.* от мәбрәз.

**Мәбахис** مباحث *ис. к.* 1) Бәхас ителгән, тикшерелгән як, тикшереләчәк нәрсәләр. 2) Темалар. 3) Әсәрнең аерым бүлекләре. *Мәбахисдә тәдриҗгә ригая* — *сущ. мн.* 1) Предмет спора, обсуждения. 2) Сюжет, тема. 3) Раздел книги.

*итмәк мәсьәләсе дә бик мөһимдер.* (Ш. ж.)

**Мәбгуз** مبغوض *сф.* 1) Ачу ителгән, дошман ителгән кеше. 2) Сөелмәгән. — *пр. с.* 1) Ненавидимый, ненавистный. 2) Нелюбимый.

**Мәбгус** مبعوث *сф.* 1) Депутат. *Думага барачак мәбгусләремезнең... хәбәрдар улмаклыклары лязим.* (Г. Ибр.) 2) Үлгәннән соң терелгән (кубарылган). — *пр. с.* 1) Посланец, депутат. 2) Воскресший.

**Мәбгусан** مبعوثان *гф. ис.* Мәбгуснең *к.* — *ар.-п. сущ. мн.* от мәбгус.

**Мәбдәэ** مبدأ *ис.* Башлангыч, баш, әүвәл, әйбернең беренче башлап чыккан урыны. *Беренче олимпиада уеннарын юнанилар мәбдәэ тарих иттихаз итмешләр иде.* (Х. Чис.) — *сущ.* Исходный пункт; происхождение; начало.

**Мәбдәэлкыйраэт** مبدأ القرائت *ст.* „Башлангыч уку" (китап исеме). — *сс.* Название книги „Начальное чтение".

**Мәбзул** مبذول *сф.* 1) Күп, мул. *Модачылар булса да, гакыллы, һәм мәгърифәтле егетләр һәм мәбзул.* (Г. Габ.) 2) Күп бирелгән, күп тотылган. — *пр. с.* 1) Изобильный, данный в изобилии. 2) Предоставленный в изобилии, в большом количестве.

**Мәбзулиять** مبذولیت *ис.* Муллык, күплек. — *сущ.* Изобилие, обилие; множество.

**Мәбигъ** مبیع *сф.* Сатылган; сатылган әйбер. — *пр. с.* Проданный.

**Мәбләгъ** مبلغ *ис.* 1) Үлчәү; сан. 2) Сума, акча күләме. — *сущ.* 1) Мера; количество. 2) Сумма (наличных денег).

**Мәбна** مبنی *сф.* 1) Нигезләнгән, корылган. *Кәлямы хикмәт вә мәгънәя мәбна.* (Г. Тук.) 2) Корылма. — *пр. с.* 1) Основанный, построенный, сооружённый. 2) Строение, сооружение.

**Мәбни** مبنی *сф.* 1) *кара:* мәбна 1. *Мәзахе хикмәткә мәбни иде.* (К. Нас.) 2) *грам.* Үзгәрми (гөрләнми) торган сүз. *Исем мәбни игъраp кабул итмәс вә игъраплянмас.* (К. Нас.) — 1) *см.* Мәбна 1. 2) *грам.* Несклоняемое имя (существительное).

**Мәбрур** مبرور *с.* Яхшы, макталган, гүзәл. — *прил.* Добрый, хороший, похвальный.

**Мәбрәз** مبرز *ис.* Кара-каршы сугыш урыны. — *сущ.* Место боя, схватки, поединка.

**Мәбсут** مبسوط *сф.* 1) Түшәлгән, җәелгән. 2) Разый, канәгать; шатлык- — *пр. с.* 1) Распростёртый. 2) Довольный, весёлый.

лы, шат күңелле. 3) Озын, тәфсыйльле (сүз, хикәя). — 3) Пространный, обстоятельный (о рассказе и т. п).

**Мәбтәдигъ** مبتدع *сф.* Яңаны уйлап чыгаручы. — *пр. д.* Новатор, изобретатель.

**Мәбхәс** مبحث *ис.* 1) Бәхәс объекты. 2) Әсәрнең аерым бүлеге. 3) Гыйльми мәкалә. — *сущ.* Предмет спора. 2) Раздел книги. 3) Научная статья.

**Мәбхүсен ганһ** مبحوثعنه *ст.* Бәхәс ителгән нәрсә, сөйләнгән, әйтелеп үткән. — *сс.* Предмет обсуждения, обсуждённая тема.

**Мәбшүш** مبشوش *сф.* Ачык йөзле, көләч йөзле. — *пр. с.* Весёлый, радостный.

**Мәбәррә** مبره *ис.* 1) Ярдәм. 2) Яхшылык, мәрхәмәт. — *сущ.* 1) Помощь. 2) Доброта; милосердие.

**Мәбһүт** مبهوت *сф.* Хәйран калган, аптырап калган, таң калган. *Күреп вә ишетеп мәбһүт булдык.* (К. Нас.) — *пр. с.* Изумлённый, поражённый.

**Мәвагыйд** مواعيد *ис.* Мәүгуд-нең *к.* — *сущ. мн.* от мәүгуд.

**Мәвагыйд** مواعد *ис.* Мәүгыйд-нең *к.* — *сущ. мн.* от мәүгыйд.

**Мәвагыйз** مواعظ *ис.* Мәүгазә-нең *к.* — *сущ. мн.* от мәүгазә.

**Мәвадди** مواد *ис.* Маддә (матдә)-нең *к.* — *сущ. мн.* от маддә (матдә).

**Мәвазигъ** مواضع *ис.* Мәүзыйг-нең *к.* — *сущ. мн.* от мәүзыйг.

**Мәвазин** موازين *ис.* Мизан-ның *к.* — *сущ. мн.* от мизан.

**Мәваид** موائد *ис.* Маидә-нең *к.* — *сущ. мн.* от маидә.

**Мәвакыйг** مواقع *ис.* Мәүкыйг-нең *к.* — *сущ. мн.* от мәүкыйг.

**Мәвакыйф** مواقف *ис.* Мәүкыйф-нең *к.* — *сущ. мн.* от мәүкыйф.

**Мәвалид** مواليد *ис.* Мәүлүд-нең *к.* — *сущ. мн.* от мәүлүд.

**Мәвалиде сөләсә** مواليدثلثه *ст.* Хайваннар, үсемлекләр, минераллар турындагы фән. — *сс.* Наука о трёх разделах природы (животных, растениях и минералах).

**Мәвалиделмаэ** مواليدالماء *ст.* 1) Чишмә. 2) Водород. — *сс.* 1) Водный источник. 2) Водород.

**Мәвалиделхәмузә** مواليدالحموضه *ст.* Кислород. — *сс.* Кислород.

**Мәванигъ** موانع *ис.* Манигъ-ның *к.* — *сущ. мн.* от манигъ.

**Мәварис** مواريث *ис.* Мирас-ның *к.* — *сущ. мн.* от мирас.

**Мәвасикъ** مواثيق *ис.* Мисак-нын *к.* — *сущ. мн.* от мисак.

**Мәвасим** مواسم *ис.* Мәүсим-нең *к.* — *сущ. мн.* от мәүсим.

**Мәвасим әрбәга** — елнын дүрт вакыты, фасылы (яз, жәй, көз, кыш). — Четыре времени года.

**Мәват** موات *ис. к.* 1) Ташландык жир. 2) Тере булмаган (жансыз) әйберләр. — *сущ. мн.* 1) Пустопорожние, невозделанные земли. 2) Безжизненные, неодушевлённые предметы.

**Мәвати** مواتى *с.* Үлем(гә)'һәм жансыз нәрсәләр(гә караган). — *прил.* Безжизненный.

**Мәватыйн** مواطن *ис.* Мәүтин-нең *к.* — *сущ. мн.* от мәүтин.

**Мәвет** موت *ис.* Үлем, вафат булу. *Хәмзә байның мәвете бәгъдендә улан сәнәләр гаять агыр.* (З. Биг.) — *сущ.* Смерть, кончина.

**Мәвәддәт** مودت *ис.* Дуслык, ярату, сөю, мәхәббәт. *Димешләрдер ки, дуслык вә мәвәддәт угрыларыннан сакланыгыз.* (К. Нас.) — *сущ.* Дружба, любовь, привязанность.

**Мәвәккил** موكل *сф.* Тапшыручы, бер эшне эшләргә яки бер мәсьәләне чишәргә бирәүгә тапшыручы. — *пр. д.* Уполномачивающий; обязывающий.

**Мәвәккәл** موكل *сф.* Тапшырылган, бер эшне эшләү аңа тапшырылган кеше. — *пр. с.* Доверенный, уполномоченный, обязанный.

**Мәвәллид** مولد *сф.* Тудыручы. — *пр. д.* Порождающий, производящий.

**Мәвәлләд** مولد *сф.* Тудырылган, туган. — *пр. с.* Рождённый; порождённый; произведённый.

**Мәвәлләдат** مولدات *ис.* Туу юлы белән барлыкка килгәннәр (адәм һәм хайваннар). — *сущ.* Рождённые, порождённые (о людях и животных).

**Мәга (мәгал)** مع *бәйл.* Белән, бергә. — Предлог с.

**Мәгабид** معابد *ис.* Гыйбадәт урыннары. — *сущ.* Места поклонения; храмы.

**Мәгабир** معابر *ис. к.* 1) Кичүләр. 2) Күперләр. — *сущ. мн.* 1) Переезды; переправы. 2) Паромы. 3) Мосты.

**Мәгад** معاد *ис.* 1) Кире кайту урыны. 2) *күч.* Ахирәт. — *сущ.* 1) Место возвращения. 2) *перен.* Будущая, загробная жизнь.

**Мәгадин** معادن *ис.* Мәгъдән-нең *к.* — *сущ. мн.* от мәгъдән.

**Мэгаз** معاذ *ис.* Сыену урыны, саклана торган жир. — *сущ.* Убежище.

**Мэгаз алла** — алла сакласын. *Мэгаз алла, хак белүр, мэн һич күрмэдем...* (К. Гал.) — Сохрани господи! Не дай бог!

**Мэга залик** مع ذلك *ст.* Шуның белэн бергэ. *Вэ мэга залик тэкэбберлек хакында эйтелер.* (К. Нас.) — *сс.* Вместе с этим, в то же время.

**Мэгазэрэ** معاذره *м. III.* Гозер (сылтау) белэн гафу үтенү. — *м. III.* Принесение извинений; извинение.

**Мэгаиб** معائب *ис. к.* Гаеплэр, кимчелеклэр; хаталар. — *сущ. мн.* Пороки, недостатки; ошибки.

**Мэгаиш** معايش *ис.* Мэгыйшэт-нең *к.* — *сущ. мн.* от мэгыйшэт.

**Мэгалмэмнүниять** مع الممنونيت *ст.* Шатлык белэн, шатланып. *Мэгалмэмнүниять кабул итэ инде ул аны, диде.* (Ш. Кам.) — *сс.* С радостью, радостно.

**Мэгали** معالى *ис.* 1) Югары сыйфатлар. 2) Бөек идеялэр. *Суңы рифгать, тэрэккыйдер мэгали.* (Г. Тук.) — *сущ.* 1) Высокие качества. 2) Возвышенные идеи.

**Мэгальурра вэ билбанзай** مع الاوراوبالبانزاى *гыйб.* „Урра... һэм банзай!" белэн. *Бетер, сындыр, кырып ташла, мэгальурра вэ билбанзай.* (Г. Тук.) — *фр* С криком ура! и с криком банзай!..

**Мэга ма фиһ** مع مافيه *ст.* Шуның белэн бергэ. *Мэга ма фиһ Юнан хөкемдарлары Асия хөкемдарлары кеби мөстэбид дэгел иде.* (Х. Чис.) — *сс.* Вместе с этим (с тем что в нем)

**Мэга һаза** مع هذا *ст.* Шуның белэн бергэ. *Мэга һаза үзе казыйга варыр.* (Һ. Сал.) — *сс.* Вместе с тем, в то; же время.

**Мэган** معاً *кис.* Бергэ, бергэлэшеп, икесе бергэ. — *част.* Вместе с..., совместно с..., вдвоем.

**Мэгани I** معانى *ис.* Мэгънэ-нең *к.* — *сущ. мн.* от мэгънэ.

**Мэгани II** مغانى *ис. к.* 1) Өйлэр. 2) Кунак өйлэре. — *сущ. мн.* 1) Жилища. 2) Дома для гостей.

**Мэгариб** مغارب *ис.* Мэгъриб -нең *к.* — *сущ. мн.* от мэгъриб.

**Мэгариф*** معارف *ис.* 1) Мэгърифэт-нең *к.* 2) Мэгълүмат, аң-белем. *Газета укучылар гыйлем вэ мэгарифкэ дэлалэт кылалар.* (З. Һади). 3) Мэгариф, уку-укыту, аң-белем бирү. — *сущ.* 1) *мн.* от мэгърифэт. 2) Сведения; знания. 3) Просвещение.

**Мәгарә*** مغاره *ис.* 1) Тау тишеге, өн. 2) Җир казып ясалган урын. *Җир асты мәгарәдә урын табып, жу итеп тора болар...* (Ш. Баб.)

*сущ.* 1) Пещера, грот. 2) Берлога.

**Мәгасил** مغاسل *ис. к.* 1) Су коену урыннары. 2) Үлек юа торган урыннар.

*сущ. мн.* 1) Места для купанья, купальни. 2) Места омовения покойников.

**Мәгасый** معاصى *ис.* 1) Мәгъсыятьнең *к.* 2) *дини* Гөнаһлы итә торган, гөнаһландыра торган эшләр *...аны укыган намазы мәгасыйдан мәнгы кылыр, диде.* (К. Нас.)

*сущ.* 1) *мн.* от мәгъсыять. 2) *рел.* Греховные дела.

**Мәгаттәэссеф** مع التأسف *ст.* Кайгы белән; үкенечкә (кайгыга) каршы.

*сс.* К сожалению.

**Мәхсусиять** مخصوصیت *ис.* Үзенчәлек; аерымлылык. — *сущ.* Особенность; специфическое свойство, специфичность, специфика.

**Мәхсусә** مخصوصه *сф.* Мәхсус-ның *мнс.* — *жен.* от мәхсус.

**Мәхсүб** محسوب *сф.* Саналган; хисапланган. *Мәхсүб булган әхваленә бинаән.* (К. Нас.) — *пр. с.* Сочтённый, считанный, вычисленный.

**Мәхсүбән** محسوبا *р.* Хисапланып, хисапланган килеш. — *н.* В сочтённом виде.

**Мәхсүд** محسود *сф.* 1) Көнләшелгән, көнләшерлек нәрсә. 2) Көндәш. *Хасидләр мәхсүднең кәдеренә мәмнүн булырлар.* (К. Нас.) — *пр. с.* 1) Предмет зависти. 2) Тот, кому завидуют.

**Мәхсүр** محسور *сф.* 1) Кайгылы, хәсрәтле. 2) Алҗыган, арыган. — *пр. с* . 1) Опечаленный, горестный. 2) Усталый, утомлённый.

**Мәхсүс** محسوس *сф.* Тоелган, сизелгән, хис ителгән. *Дәресләрне һәрвакыт мәшһүр вә мәхсүс булган нәрсәләрдән башларга кирәк.* (Ш. ж.) — *пр. с.* Познаваемый чувством, ощутимый.

**Мәхсүсат** محسوسات *ис.* Мәхсүс-нең *к.* *Мәхсүсат булган нәрсәләр күз белән күренгән кебек...* (К. Нас.) — *сущ. мн.* от мәхсүс.

**Мәхтубә** مخطوبه *сф.* Яучыланган, ярәшелгән (кыз). — *пр. с.* Помолвленная, обрученная (девушка).

**Мәхтур** مخطور *сф.* Куркыныч астында калган, куркынычлы. — *пр. с.* Опасный, рискованный.

**Мәхтут** مخطوط *сф.* Сызылган; язылган. — *пр. с.* Начертанный; написанный.

**Мәхтүм** مختوم *сф.* 1) Мөһерләнгән, печать сугылган. 2) Тәмамланган. — *пр. с.* 1) Запечатанный, с печатью. 2) Законченный, завершённый.

**Мәхуф** مخوف *сф.* Куркыныч нәрсә, дәһшәтле, коточыргыч. — *пр. с.* Страшный, ужасный, внушающий ужас.

**Мәхфи** مخفى *сф.* Яшерен. *Күңелендәге мәхфи серне идарә кыл дип тәнбиһ кылды.* (К. Нас.) — *пр. с.* Скрытый, спрятанный; тайный.

**Мәхфил** محفل *ис.* Җыелыш урыны. — *сущ.* Место собрания.

**Мәхфуз** محفوظ *сф.* 1) Сакланган, сакланыла торган. 2) Ятланган, күңелгә алынган. — *пр. с.* 1) Хранимый; сохранённый, сбережённый. 2) Заученный наизусть.

**Мәхфәзә** محفظه *ис.* 1) Саклау өчен эченә әйбер салына торган савыт. 2) Конверт. 3) Сумка, букча. — *сущ.* 1) Сосуд для хранения чего-либо. 2) Конверт. 3) Сумка.

**Мәхшәр*** محشر *ис.* 1) Җыелу. 2) *дини* Динчеләр уенча кыямәт көнендә яңа- — *сущ.* 1) Собрание, сборище. 2) *рел.* Место, где

ҙан терелгән кешеләрнең җыелу урыны яки вакыты. *Хаклык берлән мәхшәргәчә бергә булыр өчен, син дә тиз бул, тиз бул, җиргә күмел.* (Г. Тук.) 3) Мәш килү, ыгы-зыгы. — (когда) по верованию мусульман соберутся люди в день страшного суда. 3) Суматоха.

**Мәхыз** محض *с.* 1) Саф, кушылмасыз. 2) Тик, өчен; фәкать. *Сабынчыларның бу мәхыз хыянәтедер.* (К. Нас.) — *прил.* 1) Чистый, беспримесный. 2) Ради, для; только.

**Мәхәббәт*** محبت،محبة *ис.* Сөю, сөешү, гыйшык. — *сущ.* Любовь; привязанность.

**Мәхәвиять** محويت *ис.* 1) Үз-үзен кимсетү; түбәнчелек күрсәтү. 2) Юкка чыгару, юк итү. *Үзенең кануннарына каршы килгәннәрне дә мәхәвиять илә тәһдид итмештер.* (Ш. ж.) — *сущ.* 1) Самоунижение. 2) Уничтожение, истребление.

**Мәхәл** محل *ис.* 1) Урын. *Мәхәл бармы борынгыдай хөзен, хәсрәт, әләмнәргә...* (Г. Тук.) 2) Өй, йорт. — *сущ.* 1) Место. 2) Помещение; дом, жилище.

**Мәхәллат** محلات *ис.* Мәхәллә-нең *к.* — *сущ. мн.* от мәхәллә.

**Мәхәлли** محلی *с.* 1) Бер мәхәлләгә караган. 2) Җирле. — *прил.* 1) Приходский. 2) Местный.

**Мәхәллә*** محله *ис.* 1) Шәһәр һәм авылның бер мәчеткә караган өлеше. 2) Квартал. — *сущ.* 1) Приход. 2) Квартал.

**Мәхү** محو *ис.* Югалу, юкка чыгу, бетү. *Бетте, мәхү улды зәмин, һәм дә замана калмады.* (Г. Тук.) — *сущ.* Исчезновение, уничтожение.

**Мәхҗәрелгаен** محجرالعین *гыйб.* Күз чокыры, күз алмасы урнашкан чокыр. — *фр.* Глазная орбита.

**Мәхҗүб** محجوب *сф.* 1) Пәрдәле, пәрәнҗәле, өртүле. *Мөлаем вә ачык йөзле, ләкин бик мәхҗүб күреләләр иде.* (Г. Габ.) 2) Тыйнак; оялчан кеше. — *пр. с.* 1) Покрытый покрывалом, паранджой. 2) Скромный, застенчивый.

**Мәхҗүбиять** محجوبیت *ис.* Оялу, оялчанлык. — *сущ.* Стыдливость, застенчивость.

**Мәхҗүз** محجوز *сф.* 1) Алып калынган. 2) Мәхрум ителгән, арест салынган. — *пр. с.* 1) Удержанный, задержанный. 2) Лишённый, запрещённый.

**Мәшагыйль I** مشاغل Мәшгалә I-нең *к.* — *мн.* от мәшгалә I.

**Мәшагыйль II** مشاعل Мәшгалә II-нең *к.* — *мн.* от мәшгалә II.

**Мәшаих** مشایخ *ис. к.* 1) Ишаннар, дин галимнәре. 2) Картлар. — *сущ. мн.* 1) Ишаны, учёные богословы. 2) Старики.

**Мәшаиюн** مشائيون *ис.* Мөселманнарда бер мәзһәп исеме. — *сущ.* Одна из сект ислама.

**Мәшам** مشام *ис.* Иснәү органы, борын. — *сущ.* Орган обоняния, нос.

**Мәшариб** مشارب *ис.* Мәшрәб-нең *к.* — *сущ. мн.* от мәшрәб.

**Мәшариф** مشارف *ис. к.* Биек урыннар, биеклекләр. — *сущ. мн.* Возвышенные места, возвышенности.

**Мәшаһир** مشاهير *ис.* Мәшһүр-нең *к.* — *сущ. мн.* от мәшһүр.

**Мәшгаль** مشغل *с.* Мавыктыручы, кызыклы. *Зыя өчен бу чобар адәм җыены мәшгаль бер тамаша иде.* (Г. Ибр.) — *прил.* Занимательный, интересный.

**Мәшгалә I** مشغله *м. м.* Йомыш, эш, хезмәт. — *м. м.* Занятие, работа, дело.

**Мәшгалә II** مشعله *ис.* Факел, фонарь, яктырткыч, кандил. — *сущ.* Факел, фонарь, светильник, люстра.

**Мәшгуль*** مشغول *сф.* Эш белән шөгыльләнүче, буш түгел. *Ул заманнар һәркем үз хәле белән мәшгуль иде.* (Г. Тук.) — *пр. с.* Занятый делом, работой.

**Мәшгулият** مشغوليت *ис.* 1) Эш белән мәшгуль булу. 2) Эшчәнлек. *Кәтмәсен буша бәнем җәһдем вә мәшгулиятем.* (Г. Тук.) — *сущ.* 1) Занятость. 2) Деятельность, деловитость, трудолюбие.

**Мәшек** مشك *ф. ис.* Бурдюк, күн капчык (су ташу өчен). *Купты, пычак белән тәмам мәшекләрен ярды.* — *п. сущ.* Мех, бурдюк для воды.

**Мәши** مشى *м. I.* Йөрү, хәрәкәт итү, җәяү йөрү. — *м. I.* Ходьба, движение.

**Мәшимә** مشمه *ис. анат.* Соңгылык (ана карынында баланы ураган нәрсә). — *сущ. анат.* Послед.

**Мәшият** مشيت *ис. кара*: мәшиәт. *Ил улусы гаделе берлә тапса мәшият.* (Мөхм.) — *сущ. см.* Мәшиәт

**Мәшиән** مشياً *р.* Җәяүләп. — *н.* Пешком.

**Мәшиәт** مشيئة *ис.* 1) Теләү, кирәк табу. 2) Ирек, ихтыяр. — *сущ.* 1) Желание. 2) Воля.

**Мәшкъ** مشق *ис.* Матур язу үрнәге. — *сущ.* Образцы чистописания, прописи.

**Мәшкый** مشقى *с.* Матур язуга караган. *Мәшкый каләм* — матур язу каләме. — *прил.* Каллиграфический.

**Мәшкүк** مشكوك *сф.* Шикле, шөбһәле. — *пр. с.* Подозрительный, сомнительный.

**Мәшкүр** مشكور *сф.* 1) Рәхмәткә лаек булган. 2) Аңа рәхмәт әйтелгән, макталган.

*пр. с.* 1) Достойный признательности, благодарности. 2) Получивший благодарность; похвальный.

**Мәшмүл** مشمول *сф.* Эченә алган, җыйган.

*пр. с.* Включивший; охвативший.

**Мәшмүм** مشموم *сф.* Хуш ис; хуш исле.

*пр. с.* Ароматный запах, аромат.

**Мәшрикъ*** مشرق *ис.* 1) Көнчыгыш. *Атыла мәшрикъ һәм дә мәгърибкә табан.* (Ш. Баб.) 2) Кояш чыгу урыны.

*сущ.* 1) Восток, восход. 2) Место восхода солнца.

**Мәшруб** مشروب *сф.* 1) Эчелгән, эчертелгән, сугарылган. 2) Эчемлек, ширбәт.

*пр. с.* 1) Напоённый, увлажнённый, орошённый. 2) Питьё, напиток.

**Мәшрубат** مشروبات *ис. к.* Эчемлекләр, исерткечләр. *Трактир ач, татарга сат та тор һәртөрле мәшрубат.* (Г. Тук.)

*сущ. мн.* Напитки, спиртные.

**Мәшруг** مشروع *сф.* 1) *дини* Шәригать кушкан һәм шәригать каршында дөрес булган эш. 2) Керешкән, эшкә башлаган.

*пр. с. рел.* 1) Законный, легальный, дозволенный шариатом. 2) Начатый, приступленный.

**Мәшрут** مشروط *сф.* [Шарт ителгән, билгеле бер-бер шартка бәйләнгән. *Мәгънәви дуска мәкамдә иттихад мәшрут имәс.* (Ак.)

*пр. с.* Обусловленный, сговорённый, требуемый по условию.

**Мәшрута** مشروطه *ис.* Конституцияле (конституция белән чикләнгән) монархия.

*сущ.* Конституционная (ограниченная конституцией) монархия.

**Мәшрутиять** مشروطيت *ис.* 1) Шартлылык. 2) Конституциялелек.

*сущ.* 1) Условность. 2) Конституционный режим, конституционализм.

**Мәшрух** مشروح *сф.* Бик ачык аңлатылган; тасвирланган.

*пр. с.* Объяснённый; изложенный, комментированный; описанный.

**Мәшрәб** مشرب *м. м.* Табигать, холык; гадәт. *Хилафе мәшрәб* (гадәткә каршы) *хәрәкәт иткән кемсәнәдән ифтирак лязимдер.* (К. Нас.)

*м. м.* Склонность, характер, вкус, обычай.

**Мәшрәбә** مشربه *ис.* Су эчә торган савыт; кружка. *Кызыл алтын мәшрәбәләр дота дорсын.* (К. Гал.)

*сущ.* Сосуд для воды; кружка.

**Мәшхун** مشحون *сф.* Туп-тулы. — *пр. с.* Наполненный, нагруженный.

**Мәшъүм** مشئوم *сф.* Шомлы, шомланырлык; бәхетсез, уңмаган эш, явызлыклы хәл. *Эт улый мәшъүм вә тырный үз битен. Бәдбәхет! чәйнәргә хәзер үз итен.* (Г. Тук.) — *пр. с.* Злополучный; злосчастный; несчастливый, неудачный; роковой.

**Мәшәкъкать*** مشقت *м. м.* Мәшәкать, уңайсызлык, азап, матавык, борчу. — *м. м.* Трудность, затруднение; страдание, мучение.

**Мәшүб** مشوب *ис.* Катышкан, катнашмалы, саф булмаган. — *сущ.* Смешанный, имеющий примесь.

**Мәшһәд** مشهد *ис.* Шәһид булган урын, үтерелгән урын яки шәһид булган кеше күмелгән урын. *Ул, шәһид ул, мәшһәдең һичкемгә мәгълүм улмасын.* (Г. Тук.) — *сущ.* Место мученической кончины; место погребения мусульманского святого.

**Мәшһүд** مشهود *сф.* Күрелгән; күз белән күрелгән; күргәзмә (әсбап); таныкландырылган. *Дәресләрне һәрвакыт мәшһүд вә мәхсүс булган нәрсәләрдән башларга кирәк.* (Ш. ж.) — *пр. с.* Наблюдаемый, наглядный; засвидетельствованный.

**Мәшһүр*** مشهور *сф.* Халыкка билгеле; шөһрәтле, атаклы, данлы. — *пр. с.* Известный, знаменитый, славный, прославленный.

**Мәшҗәр, мәшҗәрә** مشجر، مشجره *ис.* Агачлык; агач күп үскән урын. — *сущ.* Роща; место, где много деревьев.

**Мәәва** مأوا *ис.* Торак йорт; тору (сыену) урыны. — *сущ.* Жилой дом; убежище, приют, обитель.

**Мәәдәбә** مأدبه *ис.* 1) Туйга (кунакка) чакыру. 2) Кунак ашы, сый. — *сущ.* 1) Приглашение на пир, празднество. 2) Угощение.

**Мәәзәнә** مأذنه *ис.* 1) Азан әйтә торган урын. 2) Мәчет манарасы. — *сущ.* 1) Место, откуда призывают на молитву. 2) Минарет мечети.

**Мәәзүн** مأذون *сф.* Рөхсәт ителгән; рөхсәтле, берәр эшкә хокук бирелгән. *Һичбер рөхсәтсез хәлифә янына кермәгә мәәзүн булып, хәлифәгә якынлык тапты.* (К. Нас.) — *пр. с.* Позволенный; получивший разрешение, право на что-либо.

**Мәәзүният** مأذونيت *ис.* 1) Рөхсәтле булу. 2) Тулы хокук. — *сущ.* 1) Наличие разрешения. 2) Полномочие.

**Мәәкәлә** مأكله *ис.* Ашамлык. — *сущ.* Съедобное.

**Мәәкүл** مأكول *сф.* Ашала торган, ашарга ярый торган (нәрсә). — *пр. с.* Съедобный; съедаемый.

**Мәәкүлят** مأكولات *ис. к.* Ашамлыклар, азык-төлек. — *сущ. мн.* Съестные припасы, провизия, провиант.

**Мәәлүф** مألوف *сф.* 1) Ияләшкән, өйрәнгән, күнегелгән. *Торна гадәте мәәлүфәсе үзерә, бөҗәкләрне аулап тәгаеш итәр икән, бер лачынны күрде.* (К. Нас.) — *пр. с.* Привычный, привыкший.

**Мәәлүм** مألوم *сф.* 1) Көенгән; кайгы-хәсрәткә төшкән. 2) Чирле. — *пр. с.* 1) Прискорбный, опечаленный. 2) Болезненный, хворый.

**Мәәмәл** مأمل *ис.* Өмет ителгән урын. — *сущ.* Место ожидания (чего-либо).

**Мәәмән** مأمن *ис.* Куркынычсыз урын; сакланырлык урын. — *сущ.* Безопасное место; убежище; прибежище.

**Мәәмүл** مأمول *сф.* 1) Булуы мөмкин, ихтимал. 2) Булыр дип өмет ителгән; булуы күздә тотылган. *Кайда бер тау, кайда мәәмүл чишмәи абелхәят.* (Дәрд.) — *пр. с.* 1) Ожидаемый, возможный. 2) Предмет ожиданий, надежд.

**Мәәмүн** مأمون *сф.* Куркынычтан азат, сакланулы; куркынычсыз, имин. — *пр. с.* Защищённый, обеспеченный, гарантированный, застрахованный; безопасный.

**Мәәмүр** مأمور *ис.* 1) Берәр эшне үтәүче кеше. 2) Аңа кушылган, боерылган. 3) Чиновник. — *сущ.* 1) Выполняющий. 2) Получающий приказание, подчинённый. 3) Должностное лицо, чиновник.

**Мәәмүрият** مأموريت *ис.* 1) Вазифа. 2) Йомыш, хезмәт, дәүләт эше. 3) Командировка. — *сущ.* 1) Должность. 2) Поручение; миссия. 3) Командировка.

**Мәәмүрән** مأمورا *р.* Берәр эшне үтәргә боерылган кеше буларак. — *н.* Смиренно, послушно.

**Мәәнүс** مأنوس *сф. кара:* мәәлүф. — *пр. с. см.* Мәәлүф.

**Мәәсәрә** مأثره *ис.* Борынгылардан (бабалардан) калган онытылмаслык гүзәл эш (сүз, хәрәкәт). — *сущ.* Похвальный поступок, подвиг (предков).

**Мәәсүр I** مأثور *сф.* Борынгылардан язма яки телдән телгә күчерелеп киленгән. — *пр.* Записанный, известный по преданию.

**Мәәсүр II** مأسور *сф.* Тоткын, әсир ителгән. — *пр. с.* Пленник, взятый в плен.

**Мәәсүф** مأسوف *сф.* Көендерә торган, кайгыга төшерә торган. — *пр. с.* Достойный сожаления; опечаливающий.

**Мәәхуз** مأخوذ *сф.* 1) Алынган, кабул ителгән әйбер. 2) Күчерелгән сүз һәм мәгълүмат. *Бала багыр ите димәк моннан мәәхуздер.* (К. Нас.) — *пр. с.* 1) Принятый, воспринятый. 2) Переданный, заимствованный.

**Мәәхәз** مأخذ *ис.* Алынган җир, чыганак. *Күңелдә яткучы изге хәзинә вакытлыча китә үз мәәхәзенә.* (Г. Тук.) — *сущ.* Источник, исток.

**Мәәюс** مأيوس *сф.* Өметсез, өмет өзгән. *Мәәюс карый, аның күзләрендә туйганлык бар залим дөньядан.* (М. Укм.) — *пр. с.* Отчаявшийся; потерявший надежду.

**Мәәюсанә** مأيوسانه *гф. р.* Өмет өзеп. — *п. н.* Безнадёжно; отчаянно.

**Мәәюсиять** مأيوسيت *ис.* Өметсезлек. — *сущ.* Отчаяние, безнадёжность.

**Мәәҗүр** مأجور *сф.* 1) Түләнгән, эш хакын алган. 2) Саваплы (булган). *Гафу кылу ниятләре белән мәәҗүр булсалар да.* (К. Нас.) — *пр. с.* 1) Оплаченный; оплачиваемый. 2) Благодетельный.

**Мәәҗүҗ** مأجوج *ял. ис.* Мифик халык исеме. (Дини хорафат буенча дөнья бетәр алдыннан озын һәм кыска буйлы ике төрле халык чыгып, дөньяның астын өскә китереп, төрле әшәкелекләр эшләячәк, имеш. Шуның кыска буйлысы Мәәҗүҗ исемле булачак, имеш. Озын буйлысы Яәҗүҗ дип атала, имеш.) — *и. с.* Магог (один из двух мифических народов: Яәҗүҗ — высокорослый, Мәәҗүҗ — низкорослый народ. Согласно религиозному преданию перед „концом света“ они появятся и будут творить на земле злые дела).

**Мәядин** ميادين *ис.* Мәйдан-ның *к.* — *сущ. мн.* от мәйдан.

**Мәүгыйд** موعد *ис.* 1) Сүз куешкан вакыт. 2) Сүз бирү, вәгъдә бирү. — *сущ.* 1) Срок; назначенное время. 2) Обещание; зарок.

**Мәүгазә** موعظه *ис.* 1) Вәгазь. 2) Нәсыйхәт, үгет; ышандыру. — *сущ.* 1) Проповедь, проповедывание. 2) Увещание, убеждение.

**Мәүгуд** موعود *сф.* 1) Чакырылган. 2) Вәгъдә ителгән, сүз бирелгән. *Мин тәвәккъкыфсыз мәүгуд кисәне кулына тапшырдым.* (К. Нас.) — *пр. с.* 1) Приглашённый. 2) Обещанный, условленный.

**Мәүдугъ** مودوع *сф.* 1) Сакланылган; калдырылган. 2) Әманәт ителгән. — *пр. с.* 1) Сбережённый; оставленный. 2) Доверяемая на хранение (вещь).

**Мәүдүд** مودود *сф.* 1) Сөелгән. 2) Дусланган. — *пр. с.* 1) Любимый. 2) Подружившийся.

**Мәүзугъ** موضوع *сф.* **1.** Тема; проблема; сюжет. **2.** Куелган, урнаштырылган. *Сәгатьчегә сәгать кыйтгаларының ни өчен мәүзугъ икәнен белмәк важибтер...* (К. Нас.) — *пр. с.* **1.** Предмет; тема; проблема; сюжет. **2.** Помещённый, установленный.

**Мәүзугат** موضوعات *ис.* Мәүзугъның *к.* — *сущ. мн.* от мәүзугъ.

**Мәүзыйг** موضع *ис.* Урын, җир. — *сущ.* Место, положение.

**Мәүзыйгый** موضعی *с.* Бер урынга гына караган (гомуми түгел). — *прил.* Местный, относящийся к определённому месту.

**Мәүзүн** موزون *сф. шигъ.* 1) Үлчәнгән, үлчәүле; тигезләнгән. 2) Тезмә. *Такылдамак белән мәүзүн сүз сөйләмәк икесе башка-башка булырга кирәк.* (Г. Тук.) — *пр. с. поэт.* 1) Ритмичный, метрический. 2) Стихотворение; стихотворная речь.

**Мәүкаф** موقف *ис. кара:* мәүкыйф. — *сущ. см.* Мәүкыйф.

**Мәүкут** موقوت *сф.* Вакыты билгеләнгән. — *пр. с.* В определенное время.

**Мәүкуф** موقوف *сф.* 1) Тотылган, туктатылган. 2) Бәйләнгән. *Бер милләт вә кавемнең тәрәккыйсе укымак — һөнәр вә сәнгать белмәккә мәүкуфдыр.* (Г. Габ.) 3) Кулга алынган, тоткын ителгән. 4) Вәкыф ителгән (иясе тарафыннан изге хисапланган эшкә бирелгән мал). — *пр. с.* 1) Прекращённый, приостановленный, отложенный; отсроченный. 2) Зависящий (от чего-либо); связанный (с чем-либо). 3) Арестованный, заключённый. 4) Назначенный, завещанный на благотворительные дела.

**Мәүкуфиять** موقوفيت *ис.* 1) Туктатылу. 2) Тоткынлык; кулга алыну. 3) Вәкыф ителгәнлек. — *сущ.* 1) Прекращение, отсрочка. 2) Неволя, заключение. 3) Всякого рода имущество, обращенное в вакф.

**Мәүкыйг** موقع *ис.* 1) Урын. 2) Берәр эш (вакыйга) урыны... *Мәзкүр рисаләме мәүкыйгы тамашая вәзгы идәрлек дәрәҗәдә итеп язу хәтеремә билә килмәмеш иде.* (Г. Кам.) 3) Уңай момент. — *сущ.* 1) Место, местоположение. 2) Место действия. 3) Случай, удобный момент.

**Мәүкыйз** موقظ *сф.* Уятылган. — *пр. с.* Разбуженный.

**Мәүкыйт** موقت *ис.* Билгеләнгән вакыт, срок. — *сущ.* Срок, назначенное время.

**Мәүкыйф** موقف *ис.* Тукталыш, тукталу урыны, туктап тора торган урын. — *сущ.* Остановка, стоянка; пристанище.

*Ардым инде, кайда актык мәүкыйфем.* (Г. Тук.)

**Мәүла** مولا،مولى *ис.* 1) Ия, хуҗа; яхшылык итүче. 2) Дус. 3) Колын азат итүче. 4) Алланың эпитеты. *Нә шагыйрьдер у кем әшгар аңа мәүладан ихсандыр.* (Г. Тук.) — *сущ.* 1) Хозяин; господин, покровитель. 2) Друг. 3) Отпускающий раба на волю. 4) Эпитет аллаха.

**Мәүлана** مولانا *ис.* Иябез, хуҗабыз; остазыбыз (мөселман дин галимнәренә әйтелә торган булган). — *сущ.* Наш хозяин, господин; наш учитель (титул мусульманских учёных и богословов).

**Мәүлид** مولد *ис.* 1) Туган җир, ватан. 2) Туу. 3) Туган көн, туган көн бәйрәме, рождество. *Рус мәүлиде үтеп китте, көннәр суык. Колакларда, борыннарда өреләә куык...* (Г. Тук.) — *сущ.* 1) Место рождения. 2) Рождение. 3) Рождество; день рождения.

**Мәүләви** مولوى *с.* 1) Җәләлетдин Руми юлына ияргән. 2) Галим. *Улырсың мәүләви бу кыйль вә кальдән.* (Ут. Им.) — *прил.* 1) Относящийся к дервишскому ордену Жалялетдина Руми. 2) Ученый муж.

**Мәүлүд*** مولود *сф.* 1) Туган; яңа туган бала. 2) *кара*: мәүлид 3. — *пр. с.* 1) Рождённый; дитя, младенец; ребёнок. 2) *см.* мәүлид 3.

**Мәүрүс** موروث *сф.* Мирас булып калган; нәселдән нәселгә күчкән. — *пр. с.* Унаследованный, наследственный.

**Мәүсаль** موصل *ис.* Тоташкан, урнашкан урын; кавышу урыны. — *сущ.* Место встречи, свидания.

**Мәүсим** موسم *ис.* 1) Сезон, вакыт. 2) Елның дүрт вакытыннан берсе. — *сущ.* 1) Сезон, время. 2) Одно из времён года.

**Мәүсук** موثوق *сф.* 1) Таянырлык, ышанырлык. 2) Дөрес. *Кылышып вәгъдәи мәүсук.* (Г. Кан.) — *пр. с.* 1) Достойный доверия, заслуживающий доверия. 2) Достоверный.

**Мәүсул** موصول *сф.* 1) Тоташтырылган, кавышкан, кушылган. 2) Берләшкән. 3) Юлыккан. — *пр. с.* 1) Соединённый, связанный. 2) Объединённый. 3) Встретившийся.

**Мәүсуф** موصوف *сф.* Сыйфатланган, билгеле бер сыйфатка ия булган. *Һәр кеше сүзе белән мәгъруф булыр вә фигыле белән мәүсуф булыр.* (К. Нас.) — *пр. с.* Обладающий каким-либо качеством.

**Мәүсыйк** موثق *ис.* Договор, килешү. — *сущ.* Договор; соглашение.

**Мәүсүм** موسوم *сф.* 1) Исемләнгән. 2) Тамгаланган, тәненә тамга басылган. — *пр. с.* 1) Именуемый, называемый. 2) Обозначенный; меченый, клеймёный.

**Мәүта** موتا *ис.* Мәет-нең *к. Имди мәүтага зиярәт итмәкнең асыл сәбәбе...* (К. Нас.) — *сущ. мн.* от мәет.

**Мәүте мөфаҗат** موت مفاجات *ф. из.* Кинәт үлем. *Шул кич мәүте мөфаҗат белән вафат булды.* (К. Нас.) — *п. из.* Внезапная смерть.

**Мәүтыйн** موطن *ис.* 1) Ватан, туган җир. 2) Торган урын. — *сущ.* 1) Родина, место рождения. 2) Место жительства.

**Мәүҗ, мәүҗә** موج، موجه *ис.* Дулкын. *Мәүҗә-мәүҗә улмазди, болганмазди гыйшкың диңгезе.* (Г. Тук.) — *сущ.* Волна.

**Мәүҗүд** موجود *сф.* 1) Бар, булган. 2) Тормышта бар, реаль. *Һәр гыйлем мәүҗүд улдыгы кеби, һәр нәүгъ таләбә дә мәүҗүддер.* (З. Һад.) 3) Яшәеш, барлык. — *пр. с.* 1) Имеющийся; наличный. 2) Существующий, реальный. 2) Бытие.

**Мәүҗүдат** موجودات *ис.* Мәүҗүд-нең *к.* — *сущ. мн.* от мәүҗүд.

**Мәүҗүдиять** موجوديت *ис.* 1) Барлык, бар булу. 2) Булганлык. — *сущ.* 1) Существование. 2) Наличность.

**Мәүһиб, мәүһибә** موهب، موهبه *ис.* Бүләк. — *сущ.* Дар, подарок,

**Мәүһин** موهن *сф.* Ябыктыручы, арыгайтучы. — *пр. д.* Заставляющий худеть; ослабляющий.

**Мәүһумат** موهومات *ис.* 1) Мәүһүм-нең *к.* 2) Хорафат, юк-барга ышану. — *сущ.* 1) *мн.* от мәүһүм. 2) Предрассудок, суеверие.

**Мәүһүм** موهوم *сф.* Хыялда гына булган, төпсез уй. *Берничә мең мәзлумның каны кайбер дипломатларның каләме илә сызылмыш хат мәүһүмдән гыйбарәт түгелме.* (Ш. ж.) — *пр. с.* Воображаемый, иллюзорный, неправдоподобный.

**Мәҗаз** مجاز *ис.* Сүзнең күчерелмә мәгънәдә йөртелүе, метафора. *Бу бәеттә булган мәҗазлар гаять урынлары на төшмеш.* (К. Нас.) — *сущ.* Иносказательность, образное выражение; метафора.

**Мәҗазән** مجازاً *р.* Читләтеп (әйтү), күчерелмә мәгънәле рәвештә (әйтү). — *н.* Иносказательно; метафорически.

**Мәҗал** مجال *ис.* 1) Көч, җегәр. 2) Мөмкинлек. 3) Түземлек. *Гашыйк булдым, тәмам бетте мәҗалем.* (Г. Тук.) — *сущ.* 1) Сила, мощь. 2) Возможность. 3) Терпение.

**Мәҗалис** مجالس *ис.* Мәҗлис-нең *к. Мәҗалистә сүзләре күбрәк ушбу нәрсәләр хакында иҗра кылыныр.* (К. Нас.) — *сущ. мн.* от мәҗлис.

**Мәҗамигъ** مجامع *ис.* Мәҗмәгъ -нең *к.* — *сущ. мн.* от мәҗмәгъ.

**Мәҗанин** مجانين *ис.* Мәҗнүн -нең *к.* — *сущ. мн.* от мәҗнүн.

**Мәҗанән** مجاناً *р.* Түләүсез, буш, тиген. *Гаиләләрне мәҗанән дәва кылып мәхәббәтләрене җәлеп итмәктәләрдер.* (Ш. ж.) — *н.* Бесплатно, безвозмездно, даром.

**Мәҗари** مجارى *ис.* Мәҗра-ның *к.* — *сущ. мн.* от мәҗра.

**Мәҗбүл** مجبول *сф.* Тумыштан булган, табигый (сыйфат яки хәл). — *пр. с.* Врождённый, природный (качество или состояние).

**Мәҗбүр*** مجبور *сф.* 1) Ирексезләнгән, җәберләнгән. *Нигә соң син мескен, мәҗбүр мужикларны талавыңда белә алмыйсың хәд чикләрне.* (Г. Тук.) 2) Мәҗбүри. — *пр. с.* 1) Вынужденный, принуждённый. 2) Обязательный.

**Мәҗбүрият** مجبوريت *ис.* Мәҗбүрлек, чарасызлык, ирексезлек. — *сущ.* Вынужденность.

**Мәҗбүрән** مجبوراً *р.* Көчләнеп, мәҗбүр булып, ирексез рәвештә. *Мартны башлап, арт тарафка кышны ташлап мәҗбүрән...* (Ш. Баб.) — *н.* Поневоле, принудительно, вынужденно.

**Мәҗзүб** مجذوب *сф.* Тартылган (икенче бер нәрсәнең тарту куәте белән тартылган). *Зыяның йөзенә әллә нинди хыялый төс вә каядыр мәҗзүб булучылык төсе чыкты.* (Г. Ибр.) — *пр. с.* Увлечённый, вдохновлённый.

**Мәҗзүм** مجزوم *сф.* 1) Киселгән. 2) Кискен уйланылган, хөкем ителгән. 3) *грам.* Сәкен белән укыла торган (хәреф.) — *пр. с.* 1) Отрезанный, отсечённый. 2) Решённый, окончательно определённый. 3) *грам.* Буква, снабжённая знаком „сукун".

**Мәҗид** مجيد *с.* Данлы, мактаулы. — *прил.* Славный, прославленный.

**Мәҗлес***, **мәҗлис** مجلس *ис.* 1) Җыелыш, утырыш. 2) Аш мәҗлесе, кунакка җыелу. — *сущ.* 1) Собрание, заседание. 2) Пирушка; пир; угощение.

**Мәҗлүб** مجلوب *сф.* 1) Тартылган. 2) Җәлеп ителгән. *Сиңа бит мәҗлүб минем күңлем, күзем.* (М. Гаф.) — *пр. с.* 1) Привлечённый. 2) Приворожённый.

**Мәҗлүбият** مجلوبيت *ис.* Җәлеп ителгәнлек, тартылганлык. *Бу сөбатә мөнхәсыйр мәфтүн вә мәҗлүбиятем.* (Г. Тук.) — *сущ.* Привлекательность; притягательность.

**Мәҗмуга** مجموعه *ис.* 1) Җыентык, альманах, журнал; хрестоматия. 2) Коллекция. — *сущ.* 1) Сборник, альманах, журнал; хрестоматия. 2) Коллекция.

**Мәҗмуган** مجموعاً *р.* Бөтенесе бердән, җыелып, бары да. — *н.* Всецело, целиком, в общей сложности.

**Мәҗмугъ** مجموع *сф.* Җыелган, тупланган, беркетелгән; барлык. — *пр. с.* Собранный; совокупный, коллективный.

**Мәҗмәгъ** مجمع *ис.* Җыела торган урын. *Мәҗмәгыл әфкяре намын вирмеш идек „Фикрә“ без.* (Г. Тук.) — *сущ.* Собрание, место сбора.

**Мәҗнүн** مجنون *сф.* 1) Җенле, тиле, дивана, юләр. 2) Мәҗнүн — *ял. ис.* „Ләйлә вә Мәҗнүн“ дигән бер дастанның каһарманы. *Качан бер көнне Мәҗнүн дилфикяр ителде фәүте Ләйләдән хәбәрдар...* (Дәрд.) — *пр. с.* 1) Безумный, помешанный, сумасшедший. 2) *и. с.* Меджнун — герой поэмы „Лейла и Меджнун“.

**Мәҗнүнанә** مجنونانه *р.* Тиленәрчә, диваналарча, юләрләрчә. — *н.* Безумно, как безумный.

**Мәҗнүнияти** مجنونيت *ис.* Тилелек, юләрлек, җенлелек. *Бу хыялаттән кәлер, гәр кәлсә мәҗнүниятем.* (Г. Тук.) — *сущ.* Безумие, помешательство; сумасшествие.

**Мәҗра** مجرا،مجرى *ис.* Су юлы, су ага торган урын. — *сущ.* Русло; путь, течение (воды).

**Мәҗрух** مجروح *сф.* Яраланган, яралы, җәрәхәтле. *Шулай мәҗрух күңелләр.* (М. Гаф.) — *пр. с.* Раненый, раненный.

**Мәҗәллә** مجله *ис.* Журнал; җыентык; китап. — *сущ.* Журнал; сборник; книга.

**Мәҗүс** مجوس *ис.* Айга (яки кояшка, утка, потка) табынучы. — *сущ.* Язычник; огнепоклонник, маг.

**Мәҗүси*** مجوسى *с.* 1) Потка табыну(га бәйләнешле). 2) Потка табынучы. *Эзе дә калмаган диннең, басып киткән мәҗүсиләр.* (Г. Тук.) — *прил.* 1) Языческий. 2) Огнепоклонник.

**Мәҗүсият** مجوسيت *ис.* Айга (яки кояшка, утка, потка) табынучылык. — *сущ.* Огнепоклонство.

**Мәҗһүд** مجهود *сф.* Көч кую, тырышлык. — *пр. с.* Усилие, старание.

**Мәҗһүл** مجهول *сф.* Билгесез, беленмәгән, танылмаган, мәгълүм булмаган. *Тышыннан кызгану күрсәтсә дә ул, эчендә нәрсәләр ятканы мәҗһүл.* (Г. Тук.) — *пр. с.* Неизвестный, неведомый; анонимный.

**Мәҗһүл фигыль** مجهول فعل *ст.* Төшем юнәлешендәге фигыль. — *сс.* Глагол в страдательном залоге.

**Мәһаб** مهاب *ис.* Куркынычлы урын. — *сущ.* Опасное место.

**Мәһабәт*** مهابت *м. м.* 1) Зурлык, олылык. 2) Күрер күзгә шәплек. 3) Күнелгә курку салырдай тышкы күренеш. *Мәһабәтле, озын буйлы Мөхәммәдъярыбыз бардыр.* (Г. Тук.) — *м. м.* 1) Солидный, величественный. 2) Величавый, знаменитый. 3) Внушительный, внушающий страх.

**Мәһам** مهام *м. м.* Зур, әһәмиятле эш. — *м. м.* Миссия, важное дело.

**Мәһалик** مهالك *ис.* Мәһликә-нең *к.* — *сущ. мн.* мәһликә.

**Мәһанәт** مهانت *ис.* Хур булу. — *сущ.* Унижение.

**Мәһарәт** مهارت *ис.* Бер эштә осталык; сәләтлелек. — *сущ.* Ловкость, искусство; способность.

**Мәһбитъ** مهبط *ис.* Төшә (инә) торган урын. — *сущ.* Место сошествия, нисхождения.

**Мәһбут** مهبوت *сф.* Куркуга, аптырауга төшкән. — *пр. с.* Испуганный, устрашённый; растерявшийся.

**Мәһвар** مهوار *ф. ис.* Айлык хезмәт хакы. — *п. сущ.* Жалованье; месячный заработок.

**Мәһди** مهدى *ис.* 1) Туры юлда булган кеше. 2) Туры юлга төшерүче. 3) Мәһди (шига мәзһәбендәге 12 нче имамның исеме). — *сущ.* 1) Стоящий на верном пути. 2) Наставляющий на верный путь, мессия. 3) Махди (имя 12-го шиитского имама).

**Мәһед** مهد *ис.* Бишек. *Саллаер аһәстә-аһәстә бәни бу мәһде дәрт.* (Г. Тук.) — *сущ.* Колыбель.

**Мәһзуз** مهزوز *сф.* Калтыранган, калтырауга китергән. *Хак шаһиди һич рыя мәсрүр вә мәһзуз әйләмәз.* (Г. Тук.) — *пр. с.* Дрожащий; приведённый в дрожь.

**Мәһзул** مهزول *сф.* Арык, ябык. — *пр. с.* Тощий, худой; немощный.

**Мәһликә** مهلكه *ис.* 1) Куркынычлы урын, үлем китерә торган урын. 2) Куркынычлык, һәлакәт. — *сущ.* 1) Опасное, гибельное место. 2) Опасность, гибель.

**Мәһпарә** مه‌پاره *ф. с.* 1) Айга охшаган (охшашлы). 2) Матур, гүзәл, сылу. *Барып күрсәң сән ул мәһпарәләрне* (Сайяди). — *п. прил.* 1) Луноподобный. 2) Красавица.

**Мәһпәрәст** مهپرست *ф. с.* 1) Айга табынучы. 2) Гашыйк. — *п. прил.* 1) Поклоняющийся луне. 2) Влюблённый.

**Мәһтаб** مهتاب *ф. ис.* 1) Ай яктысы, ай яктылыгы, ай нуры. 2) Ай. — *п. сущ.* 1) Лунный свет. 2) Луна.

**Мәһтаби** مهتابی *ф. ис.* 1) Ак (төстәге) якут ташы. *Якут кызыл төследер, дәхи сары вә күк төсләре бар, дәхи мәһтаби диерләр ак төстәдер.* (К. Нас.) 2) Айныкы, ай төсе. 3) Тулган ай яктысы. — *п. сущ.* 1) Белый рубин. 2) Лунный. 3) Свет от полнолуния.

**Мәһәр*** مهر *ис.* Калым (никях вакытында ир тарафыннан кыз ягына бирелә торган мал — акча). *Ул мине кем сораса, шуңа бирергә тора, тик кыска койрык булмасын да мәһәрне мул бирсен генә.* (Г. Ибр.) — *сущ.* Калым (сумма денег, даваемая женихом невесте при бракосочетании).

**Мәһүб** مهوب *сф.* Куркытылган, курыккан. — *пр. с.* Напуганный, испуганный.

**Мәһүш** مهوش *ф. с.* Матур йөзле, гүзәл йөзле. — *п. прил.* Красиволикий; луноликий.

**Мәһҗүр** مهجور *сф.* 1) Ераклашкан, читтә калган. 2) Ташланган, онытылган. *Зиндан эчрә мәхбүс мәһҗүр улсын имде.* (К. Гал.) — *пр. с.* 1) Удалённый, отстранённый. 2) Заброшенный; забытый.

**Мөахәзә** مواخذه *м. III.* 1) Шелтәләү, җәза бирү. 2) Тикшереп фикер йөртү, тәнкыйтьләү. *Әй гакыл, синең сәбәпле мөахәзә кылырмын, диде.* (К. Нас.) — *м. III.* 1) Выговор, порицание; наказание. 2) Суждение; критика.

**Мөбагадә** مباعده *м. III.* Бер-береннән ераклашу. — *м. III.* Удаление, отдаление.

**Мөбагазә** مباعضه *м. III.* Ачуланышу, дошманлашу. — *м. III.* Ссора; вражда.

**Мөбади** مبادی *ис.* Мөбдәә-нең *к.* — *сущ. мн.* от мөбдәә.

**Мөбадалә** مبادله *м. III.* Алмашу, алмаштыру. — *м. III.* Обмен; мена, взаимный размен.

**Мөбадәләи әфкяр,** مبادلهافکار *гыйб.* Фикер алышу. — *фр.* Обмен мнениями.

**Мөбадәрәт** مبادرت *м. III.* 1) Эшне башлап җибәрү. 2) Ашыгып эшкә керешү, ашыгычлык. — *м. III.* 1) Приступление к делу. 2) Поспешность.

**Мөбаин** مباین *сф.* Башка төрле, бүтәнчә, каршы, аермалы. — *пр. с.* Несоответствующий, расходящийся.

**Мөбакәрә** مباکره *м. III.* 1) Иртәләү. 2) Эшне иртәнге вакытта башкару. *Ибне Кәмал таләбе гыйлемдә мөбакәрә мөстәхәб димештер.* (К. Нас.) — *м. III.* 1) Делать что-либо раньше обычного времени. 2) Заниматься чем-либо ранним утром.

**Мөбалят** مبالات *ис* Кайгырту, игътибар (әһәмият) бирү.

*сущ.* Забота; внимание; попечение.

**Мөбаләга** مبالغه *м. III.* Арттыру, тиешле чикне узу, күпертү (гипербола).

*м. III.* Преувеличение, гипербола.

**Мөбариз** مبارز *сф.* Бергә-бер чыгып сугышучы; пәһлеван, батыр.

*пр. д.* Единоборец, боец; витязь.

**Мөбарәзә** مبارزه *ис.* Бергә-бер чыгып сугышу. *Мөбарәзә мәйданына бу чыккан соң, батырлар була калды югалгандай.* (Ак.)

*сущ.* Единоборство, поединок.

**Мөбарәк** مبارك *с.* Кадерле; бәхетле, хөрмәтле; *Мөбарәк җисмена гәр рух өрелсә.* (Г. Тук.)

*прил.* Благословенный; счастливый; благополучный; уважаемый.

**Мөбассыйр** مبصر *сф.* 1) Күзәтүче, тикшерүче. 2) Мәктәпләрдә укучыларның өстеннән күзәтүче.

*пр. д.* 1) Наблюдатель; надсмотрщик; контролёр. 2) Школьный надзиратель.

**Мөбасәлә** مباسله *м. III.* 1) Оршышу; гауга чыгару. 2) Кыюлык, батырлык, егетлек.

*м. III.* 1) Перебранка, ругань. 2) Храбрость, бесстрашие, неустрашимость.

**Мөбах** مباح *ис. дини* Тыелмаган да, кушылмаган да эш, эшләсәң гөнаһ та, савап та булмый торган эш.

*сущ. рел.* Дозволенный, допустимый, доступный; не предосудительный.

**Мөбахис** مباحث *сф.* Бәхәс итүче, сүз көрәштерүче.

*пр. д.* Спорщик; оппонент.

**Мөбахәсә** مباحثه *ис.* Бәхәсләшү, сүз көрәштерү, аңлашу. *Мөбахәсә нәдән гыйбарәт идекене белмәсләр.* (М. Ак.)

*сущ.* Дебаты, дискуссия, прения; обсуждение.

**Мөбашир** مباشر *сф.* 1. 1) Башлаучы; башкаручы, үтәүче. 2) Турыдан-туры. 2. Түрә, чиновник, тәртип саклап торучы.

*пр. д.* 1. 1) Начинающий; выполняющий. 2) Прямой, непосредственный. 2. Чиновник, смотритель.

**Мөбашәрәт** مباشرت *ис.* Керешү, башлау, эш башлау; үтәү. *Хәятка багыйс булган сәбәпләргә тәшәббес вә мөбашәрәт үзрә.* (К. Нас.)

*сущ.* Начинание, проведение, осуществление.

**Мөбаяга** مبايعه *м. III.* Сату-алу.

*м. III.* Покупка, купля-продажа.

**Мөбаянәт** مباينت *м. III.* 1) Аерымлык. 2) Туры килмәү, охшамау, үзгәлек.

*м. III.* 1) Разделение. 2) Несоответствие, расхождение.

**Мөбаһат** مباهات *м. III.* 1) Мактанышу, мактану. 2) Горурлык, дан. *Сез*

*м. III.* 1) Хвастовство. 2) Гордость, слава.

*туйга мөкяфәт вә мөбаһат өчен чакырасыз, диде.* (К. Нас.)

**Мөбаһи** مباهى *сф.* 1) Мактанучы. 2) Мактанчык. — *пр. д.* 1) Похваляющийся. 2) Хвастун, бахвал.

**Мөбдигъ** مبدع *сф.* 1) Уйлап чыгаручы. 2) *дини* Яратучы, барлыкка китерүче. — *пр. д.* 1) Изобретатель. 2) *рел.* Создатель.

**Мөбин** مبين *ис.* Дөреслек белән ялганны аеручы. — *сущ.* Отделяющий (правду от лжи).

**Мөбрәм** مبرم *с.* 1) Котылгысыз. 2) Зарури; әһәмиятле. 3) Үзгәртә алмаслык. — *прил.* 1) Неизбежный. 2) Необходимый; важный. 3) Неизменный.

**Мөбтал** مبطل *сф.* Ялганга чыгарылган; бетерелгән, юкка чыгарылган. — *пр. с.* Аннулированный, уничтоженный; опровергнутый.

**Мөбтыйль** مبطل *сф.* 1) Ялганга (юкка) чыгаручы. 2) Бозучы, бетерүче. — *пр. д.* 1) Опровергающий. 2) Нарушающий, отменяющий.

**Мөбтәга** مبتغا *ис.* Теләнгән һәм таләп ителгән әйбер. — *сущ.* Желаемое, искомое.

**Мөбтәда** مبتدا *сф.* 1) Башлангыч, башта килгән, башта булган. *Чөнки һәрбер дәртә мәбдәэ мөбтәдаемниләем.* (Г. Тук.) 2) *грам.* Җөмләнең иясе. — *пр. с.* 1) Начало. 2) *грам.* Подлежащее (именного предложения).

**Мөбтәди** مبتدى *сф.* 1) Бер эшне башлап җибәрүче. 2) Гади, примитив. — *пр.* 1) Начальный, начинающий. 2) Простой, примитивный.

**Мөбтәдигъ** مبتدع *сф.* Уйлап табучы, яңа нәрсәләр уйлап чыгаручы, новатор. — *пр. д.* Новатор; изобретатель.

**Мөбтәзәл** مبتذل *сф.* 1) Искергән, чәйнәлгән. 2) Түбән күрелгән, хур күрелгән. — *пр. с.* 1) Устарелый, банальный, избитый. 2) Презренный, низкий.

**Мөбтәля** مبتلا *сф.* 1) Дучар булучы, бәхетсезлеккә эләккән. *Анда тормакка һәвәслек берлә ваклар мөбтәля.* (Г. Тук.) 2) Кайгыга төшкән. — *пр. д.* 1) Подвергшийся беде, испытавший бедствие. 2) Огорчённый, опечаленный.

**Мөбтәна** مبتنى *сф.* *кара:* мөбтәни. *Та әзәлдән дәрте шәүка мөбтәнаем ниләем.* (Г. Тук.) — *пр. с. см.* Мөбтәни.

**Мөбтәни** مبتنى *сф.* 1) Нигезләнгән. *Аслы юк вәһемләргә мөбтәни улыр.* (Ш. ж.) 2) Корылган, төзелгән. — *пр. д.* 1) Обоснованный, основанный. 2) Построенный.

**Мөбәгъгыйд** مبعد *сф.* Ераклаштыручы, читкә җибәрүче. — *пр. д.* Удаляющий, отдаляющий.

**Мөбәддәл** مبدل *сф.* Үзгәргән, алмаштырылган.

*пр. с.* Превращённый; изменённый, заменённый.

**Мөбәззир** مبذر *сф.* 1. Исрафчы, әрәмшәрәм итүче. *Бик мөхалифтер мөбәззирлек мөрәттиб шәэненә.* (Г. Тук.) 2. Орлыкландыру; чәчү.

*пр. д.* 1. Расточитель, мот. 2. Осеменение; посев.

**Мөбәййиз** مبيض *сф.* Акка күчереп язучы.

*пр. д.* Переписывающий начисто, на беловик.

**Мөбәййин** مبين *сф.* Бик ачык аңлатучы; белдерүче; бәян итүче. *Соңгы җөмлә алдагы җөмләне мөбәййиндер.* (К. Нас.)

*пр. д.* Разъясняющий, объясняющий; доказывающий; декларирующий.

**Мөбәййяз** مبيض *сф.* Акка күчереп язылган.

*пр. с.* Переписанный на беловик.

**Мөбәййян** مبين *сф.* Бик ачык аңлатылган, бәян ителгән. ... *Сүзеңез мөбәййяндер зәгъмеңездә.* (Ак.)

*пр. с.* Разъяснённый; ясный, доказанный.

**Мөбәллигъ** مبلغ *сф.* 1) Кушылган, тапшырылган эшне җиренә җиткереп эшләүче. 2) Хәбәр бирүче.

*пр. д.* 1) Исполняющий; выполняющий. 2) Доводящий до сведения, сообщающий.

**Мөбәрра** مبرا *сф.* Тазартылган, арындырылган, пакь. *Бәлагатькә зарар бирүче әхвальдан мөбәрра булмак ...* (К. Нас.)

*пр. с.* Очищенный, чистый.

**Мөбәррат** مبرات *ис. к.* 1) Яхшылыклар, изге эшләр. 2) Җәмгыяте хәйрияләр, ярдәм оешмалары.

*сущ. мн.* 1) Благотворительные дела. 2) Благотворительные учреждения.

**Мөбәррид** مبرد *сф.* Суытучы, салкынлык бирүче. *Ак шалфи үләненнән бер төрле шәрап ясалыр, мөбәррид шәраптыр, табигатькә салкынлык бирер.* (К. Нас.)

*пр. д.* Охлаждающий, замораживающий.

**Мөбәшшир** مبشر *сф.* 1) Сөендерүче, яхшы хәбәр китерүче, сөенеч китерүче. 2) Дин таратучы, миссионер.

*пр. д.* 1) Добрый вестник, приносящий радость. 2) Миссионер, проповедник.

**Мөбәшшәр** مبشر *сф.* Сөендерелгән, шатландырылган, сөенечле хәбәр алган.

*пр. с.* Получивший радостную весть.

**Мөбәһһиҗ** مبهج *сф.* Кәефне китерүче.

*пр. д.* Веселящий.

**Мөбһәм** مبهم *сф.* Аңлаешсыз, билгесез, ачык түгел. *Әнә булса да ул хәзер мөбһәм.* (Г. Хар.) — *пр. с.* Неясный, неопределённый.

**Мөбһәмат** مبهمات *ис.* Мөбһәмнең *к.* — *сущ. мн.* от мөбһәм.

**Мөваззыйх** موضح *сф.* Ачыклаучы, аңлатып бирүче. *Болардыр мөваззыйх җөмлә гакаид.* (Г. Тук.) — *пр. д.* Разъясняющий, объясняющий.

**Мөвазәбәт** مواظبت *м. III.* 1) Кайгырту, дикъкатьлелек. 2) Эшне һәрвакыт гайрәт һәм чыдамлык белән дәвам иттерү, тырышлык. — *м. III.* 1) Заботливость; внимание. 2) Прилежание, усидчивость, старание.

**Мөванәсәт** موانست *м. III.* 1) Үзара ияләшү, бер-береңә өйрәнеп китү. 2) Дуслашу. — *м. III.* 1) Взаимная привязанность. 2) Дружба, взаимное влечение.

**Мөвасаләт** مواصلت *м. III.* 1) Очрашу, кавышу. 2) Берләшү. — *м. III.* 1) Встреча, свидание. 2) Соединение, объединение.

**Мөвасәка** مواثقه *м. III.* Килешү, сүз куешу. — *м. III.* Соглашение, заключение союза.

**Мөвахат** مواخات *м. III.* Туганлашу. — *м. III.* Братание, побратимство.

**Мөвәххид** موحد *сф.* Алланың берлегенә ышанучы. — *пр. д.* Монотеист, верующий в единого бога.

**Мөгаббир** معبر *сф.* Төш юраучы. *Мөгаббирә тәэвилене сорар имде.* (К. Гал.) — *пр. д.* Толкователь снов.

**Мөгаддил** معدل *сф.* 1) Тигезләүче, гаделләүче. 2) Тигезләгеч. 3) Билге, балл. *Һәфтәлек имтихан номерлары да көндәлек дәресләрнең мөгаддиленә кушылып ... бирелә бара.* (Ш. ж.) — *пр. д.* 1) Уравнивающий, умеряющий. 2) Ватерпас, уровень. 3) Отметка, балл, оценка (знаний).

**Мөгадәлә** معادله *м. III.* 1) Ике әйбернең бер-береңә тигезлеге, бәрабәрлеге. 2) *мат.* Алгебраик тигезләмә. — *м. III.* 1) Равновесие, эквивалентность, равенство. 2) *мат.* Алгебраическое уравнение.

**Мөгаен*** معين *кара:* мөгайян. — *см.* Мөгайян.

**Мөгаззи** مغذى *сф.* 1) Азыкландыручы. 2) Туклыклы. *Мөгаззи тагамнар ашатырлар.* (Ш. ж.) — *пр. д.* 1) Питающий. 2) Питательный.

**Мөгаззиб** معذب *сф.* Газаплаучы, азап чиктерүче. — *пр. д.* Мучитель, истязатель.

**Мөгаззәб** معذب *сф.* Газапланган, азап чиккән, авырлык күргән. *Бу көлү-* — *пр. с.* Измученный; мучимый.

*дән шат түгелмен, тик мөгаззәб җан чыга.* (М. Гаф.)

**Мөгаззәз** معزز *сф.* 1) Кадер, хөрмәт ителгән. 2) Кыйммәтле. *Һәм мөгаззәз һәм мөкәррәм дотар имди.* (К. Гал.) — *пр. с.* 1) Почтенный, уважаемый. 2) Драгоценный.

**Мөгайин** معين *сф.* Билгеләүче. — *пр. д.* Определяющий.

**Мөгайябат I** معيبات *ис. к.* Гаепләр, кимчелекләр; гаеп саналган нәрсәләр. — *сущ. мн.* Проступки, недостатки, пороки; предосудительные дела.

**Мөгайябат II** مغيبات *ис.* Тышкы тойгылар белән ачылмаган серләр. — *сущ. мн.* Нечто скрытое, невидимое.

**Мөгайян** معين *сф.* 1) Билгеләнгән. 2) Ачык, анык. *Мөгайян белмим.* (З. Биг.) — *пр. с.* 1) Определённый, точный; назначенный. 2) Определенно, точно.

**Мөгалла** معلا (معلى) *сф.* Югары күтәрелгән. — *пр. с.* Возвышенный, высший.

**Мөгалли** معلى *сф.* Югары итүче, күтәрүче. — *пр. д.* Возвышающий, поднимающий.

**Мөгаллим** معلم *сф.* 1) Өйрәтүче. 2) Укытучы, дәрес бирүче. — *пр. д.* 1) Обучающий. 2) Учитель; преподаватель.

**Мөгаллиме сыйбъян** معلم صبيان *гыйб.* 1) Яшь балаларны укытучы. 2) Башлангыч мәктәп укытучысы. — *фр.* 1) Обучающий маленьких детей. 2) Учитель начальной школы.

**Мөгаллимә** معلمه *сф.* Мөгаллим-нең *мнс.* — *жен.* от мөгаллим.

**Мөгаләбә** مغالبه *м. III.* 1) Өстен булырга тырышу, ярышу. 2) Өстенлек. — *м. III.* 1) Состязание, оспаривание. 2) Превосходство.

**Мөгаләта** مغالطه *м. III.* 1) Анлы рәвештә ялгыштыру, хатага этәрү, буташтыру. 2) Ялгыш фикер йөртүдән туган хата, нәтиҗә. — *м. III.* 1) Введение в заблуждение. 2) Неправильное умозаключение; паралогизм.

**Мөгаләҗә** معالجه *м. III.* Дәвалау. *Табиблар бәгъзы авыруга алтын катыштырган дәва илә мөгаләҗә итәрләр.* (К. Нас.) — *м. III.* Лечение, пользование больного.

**Мөгаммә** معما ، معمى *сф.* Табышмак, шарада; мәгънәсе аңлашылмаган шигырь. *Имтихан кылып карасак, балалар аңланмаган коры .ләфызларны бикләмешләр, яки гамиз вә мөгаммә халендә улан мәгънәләрне зиһеннәрендә хасил итмешләр.* (Ш. ж.) — *пр. с.* Загадка, шарада; стихотворение, содержащее загадку.

**Мөгаммәр** معمر *сф.* Озын гомерле, карт. — *пр. с.* Пожилой, старый, долговечный.

**Мөгамәлә*** معامله *м. III.* 1) Халык белән эш күрү, башкаларга карата үз-үзен тоту. 2) Кеше белән аралашу. — *м. III.* 1) Обхождение, обращение. 2) Сношение, отношение.

**Мөгамәлят** معاملات *ис.* Мөгамәләнең *к.* — *сущ. мн.* от мөгамәлә.

**Мөганни** مغنى *сф.* Җырчы. — *пр. д.* Певец.

**Мөганния** مغنيه *сф.* Җырчы хатын. — *пр. д.* Певица.

**Мөганәка** معانقه *м. III.* Кочаклашу. *Хуш, нәфис тагамнар ашадым, гүзәл җарияләр белән мөганәка кылдым, сәламәтлектән ләззәтле нәрсә тапмадым.* (К. Нас.) — *м. III.* Обнимание, объятие.

**Мөгаррикъ** معرق *сф.* Тирләтүче, тир чыгара (тирләтә) торган. — *пр. д.* Потогонный.

**Мөгарриф** معرف *сф.* 1) Таныштыручы. 2) Белдерүче, хәбәр итүче. — *пр. д.* 1) Знакомящий, ознакомляющий. 2) Сообщающий.

**Мөгарра** معرا *сф.* 1) Ялангач, шәрә. 2) Бушаган, азат. *Шаһзадә аны кичке кием белән вә зиннәттән мөгаррә вакытта күрмеш иде.* (К. Нас.) — *пр. с.* 1) Оголённый, обнажённый, голый. 2) Свободный.

**Мөгаррәб** معرب *сф.* Гарәпләшкән, гарәп булып киткән. — *пр. д.* Арабизированный.

**Мөгаррәф** معرف *сф.* 1) *грам.* Билгеләнгән. 2) Аңлатылган, хәбәр ителгән. — *пр.* 1) *грам.* Определённый. 2) Сообщённый.

**Мөгассир** معسر *сф.* Авырлыкка дучар булган. — *пр. д.* Терпящий нужду; подвергшийся (чему-либо).

**Мөгатәбә** معاتبه *м. III.* Каты әйтү, шелтәләү; орышып әйтү. — *м. III.* Порицание, попрекание; брань.

**Мөгаффил** مغفل *сф.* Аңсыз, белемсез итүче, аңгыра итүче. *Мөгаллим исемле мөҗәһҺил вә мөгаффилләр.* (Г. Тук.) — *пр. д.* Делающий глупым, непонятливым.

**Мөгаффәл** مغفل *сф.* 1) Җүләр, тиле, тинтәк. 2) Аңсыз, белемсез. — *пр. с.* 1. 1) Глупый, дурак. 2) Простофиля; простак, невежда. 2. Невежественный.

**Мөгашшәр** معشر *сф.* 1) Унарлы. 2) Унарлаштырылган. 3) *мат.* Ункырлы геометрик фигура. — *пр. с.* 1) Десятичный, десятеричный. 2) Удесятеренный. 3) *мат.* Десятиугольник.

**Мөгаябә** معايبه *м. III.* Гайбәт сату. — *м. III.* Сплетни.

**Мөгаядә** معايده *м. III.* Бәйрәм белән котлашу. — *м. III.* Поздравление с праздником.

**Мөгажҗиб** معجب *сф. кара:* могҗиб. — *пр. д. см.* Могҗиб.

**Мөгажҗәл** معجل *сф.* Ашыктырылган, хәзер үк үтәлүе тиеш булган. — *пр. с.* Ускоренный, спешный.

**Мөгъләкъ** مغلق *ис.* 1) Аңлашылмаган; читен, кыен. 2) Бикләнгән. — *сущ.* 1) Неясный, тёмный, непонятный. 2) Запертый; закрытый.

**Мөгътәним** مغتنم *сф.* 1) Очрактан файдаланучы. 2) Ганимәт (трофей) итеп алучы. — *пр. д.* 1) Пользующийся случаем. 2) Берущий что-либо в качестве трофея.

**Мөдавим** مداوم *сф.* 1) Дәвам иттерүче, бер эшне ташламый эшләүче. 2) Дәвамлы. *Мөдавим кыл һаман кафате хәмсә* (дәвамлы ит һәрвакыт биш „к" ны, ягъни казы, кузы, кыз, каз, кымыз). (Г. Тук.) — *пр. д.* 1) Продолжающий, непрекращающий. 2) Постоянный, неизменный.

**Мөдавәмәт** مداومت *м. III.* 1) Дәвам. 2) Үзгәрмәүчәнлек. — *м. III.* 1) Продолжение. 2) Постоянство, неизменность.

**Мөдавәт** مداوت *ис.* Авыруны дарулау, карау. — *сущ.* Лечение, уход за больным.

**Мөдам** مدام *м. м.* Өзлексез, дәвамлы рәвештә. *Йосыф үзә гыйшкым мөдам арта дорыр.* (К. Гал.) — *м. м.* 1) Постоянно, всегда. 2) Постоянный, непрерывный.

**Мөдарә** مداره *ис. кара:* мөдарәт. — *сущ. см.* Мөдарәт.

**Мөдарәт** مدارت *ис.* 1) Яхшы (күркәм) мөгамәлә. *Кешенең гакыллылыгына һәрбер җенес халык белән мөдарәт вә хөсне мөгашәрәсе дәлилдер.* (К. Нас.) 2) Тыштан дуслык күрсәтү, ялган дуслык. — *сущ.* 1) Приветливость, обходительность, вежливое обращение, учтивость. 2) Показное изъявление дружбы, притворство.

**Мөдарәсә** مدارسه *м. III.* Дәрес бирешү, укытышу. — *м. III.* Взаимное обучение.

**Мөдафигъ** مدافع *сф.* (Дошманга каршы торып) үзен саклаучы, кире кагучы, кайтаручы. — *пр. д.* Защищающий дающий отпор; защищающийся, отталкивающий.

**Мөдафәга** مدافعه *м. III.* (Дошманга каршы торып) үзен саклау; каршылыкны кире кайтару, каршы торып сугышу, каршылык күрсәтү. *Бүре килә, үгез кыла мөдафәга.* (М. Гаф.) — *м. III.* Оборона, защита; самозащита; отпор, сопротивление.

**Мөдахәлә** مداخله *м. III.* Керешү, катышу, кушылу, арага керү. *Патриархлар һәрвакыт хөкемдарларның эшләренә мөдахәлә итмәк эстәдекләреннән.* (Х. Чис.) — *м. III.* Вмешательство.

**Мөдаһин** مداهن *сф.* 1) Ялагай, тәлинкә тотучы. 2) Икейөзле, мөнафикъ. — *пр. д.* 1. 1) Льстец. 2) Лицемер. 2. Льстивый; двуличный.

**Мөдаһәнә** مداهنه *м. III.* 1) Икейөзлелек, мөнафикълык. 2) Ялагайланып мактау, юмалау. *Бу мөдаһәнә сыйфаты — мөнафикълар сыйфатыдыр.* (К. Нас.) — *м. III.* 1) Лицемерие. 2) Лесть.

**Мөдбир** مدبر *сф.* Бәхетсезлеккә төшүче, бәхетсез. — *пр. д.* Подвергшийся несчастью, несчастный.

**Мөддәга** مدعا،مدعى *сф.* 1) Дәгъва ителгән нәрсә, дәгъвага сәбәп булган нәрсә. 2) Таләп, дәгъва. *Үз мөддәгасына дәлил эзләп тапкан кеше кыяфәте белән* ... (Ф. Әмир.) — *пр. с.* 1) Предмет спора, иска, претензии. 2) Требование, претензия.

**Мөддәга галәйһи** مدعاعليه *гыйб.* Үзеннән берәр нәрсә дәгъва ителгән, нәрсә дә булса соралган, гаепләнгән (кеше). — *фр.* Ответчик.

**Мөддәгый** مدعى *сф.* 1) Дәгъва итүче, хакын сораучы; таләп итүче, даулаучы. *Мөддәгыйлар дәгъва берлән аңа кәлур.* (К. Гал.) 2) „Мин беләмлек" дәгъвасындагы кеше. 3) Гаепләүче. — *пр. д.* 1) Претендующий, требующий; тяжущийся. 2) Всезнайка. 3) Обвинитель; претендент; истец.

**Мөддәт** مدت *ис.* Ара, вакыт, срок. *Ул алма мөддәте тулганда пешкән.* (Г. Тук.) — *сущ.* Период, промежуток времени, срок.

**Мөдир* I** مدير *сф.* Идарә итүче, идарә башында торучы, директор. — *пр. д.* Управляющий; заведующий; директор.

**Мөдир II** مدر *сф. мед.* Эчтәге сыек нәрсәләрне тышка чыгаручы. — *пр. д. мед.* Вызывающий усиленное выделение (чего-нибудь).

**Мөдиррат** مدرات *ис. мед.* Сидерткеч, сидертә торган. — *сущ. мед.* Мочегонные средства.

**Мөдирә** مديره *сф.* Мөдир I-нең *мнс.* — *жен.* от мөдир I.

**Мөдмин** مدمن *сф.* 1) Берәр нәрсәгә бирелгән. 2) Дәвам иттерүче. *Мөскирата бөтен-бөтенә мөдмин улды.* (З. Биг.) — *пр. д.* 1) Имеющий, пристрастие (к чему-либо). 2) Продолжающий.

**Мөдрик** مدرك *сф.* Белә алучы, аңлый алучы, төшенүче. — *пр. д.* Разумеющий, понимающий; сознательный.

**Мөдәббир** مدبر *сф.* 1) Эшнең алдын-артын карап, уйлап эшләүче, эшне оста алып баручы. 2) Башкаручы. — *пр. д.* 1) Деловой, деловитый. 2) Администратор.

**Мөдәббирана** مدبرانه *ф. р.* 1) Эшнең ахырын белеп, чарасын күреп. 2) Саклык белән. — *п. н.* 1) Дельно, по-деловому; деловито. 2) Осторожно.

**Мөдәкъкыйк** مدقيق *сф.* Нечкәләп тикшерүче, тикшереп караучы, җентекләүче. — *пр. д.* 1) Внимательно, подробно изучающий. 2) Проверяющий.

**Мөдәррис** مدرس *сф.* 1) Югары уку йортларында дәрес бирүче. 2) Мәдрәсәдә өлкән укытучы. *Сөрүретдин Мифтахетдин һәм мөдәррис һәм имам.* (Ш. Баб.) — *пр. д.* 1) Преподаватель, педагог вуза. 2) Старший учитель в медресе.

**Мөдәүвән** مدون *сф.* Җыентык, тәртипкә салынган (китап), „диван" төсенә кертелгән. *Һәр лисанның табигый вә мөдәүвән кагыйдәләри улыр.* (К. Нас.) — *пр. с.* Собранный в „диван" (сборник).

**Мөдәүвәр** مدور *сф.* Йомры, шар кебек түгәрәк. — *пр. с.* Круглый, округлый, сферический, шарообразный.

**Мөдһиш** مدهش *сф.* Куркыныч, куркытырлык. *Ул гаҗиб мөдһиш сарайның бер ягы ... мәйдан иде.* (Ш. Баб.) — *пр. д.* Ужасающий, ужасный, страшный.

**Мөждә** مژده *ф. ис.* Сөенеч, куаныч, шатлыклы хәбәр. *Бәшир кәлеп Маликкә мөждәләде ...* (К. Гал.) — *п. сущ.* Добрая весть, радостное известие.

**Мөждәрәс** مژدهرس, **Мөждәрәсан** مژدهرسان, **Мөждәфәрман** مژدهفرمان *ф. ис.* Сөенеч китерүче. — *п. сущ.* Приносящий радостную весть.

**Мөзакәрә** مذاكره *м. III.* Фикер алышу, фикер алышып, сөйләшеп утыру; җыелыш. *Бу эшлә,дә кылу кирәк мөзакәрә.* (М. Гаф.) — *м. III.* Обсуждение; совещание, прения, дебаты.

**Мөзах** مزاح *ис.* Мәзәк, көлке, юмор. — *сущ.* Шутка, смех; юмор.

**Мөзахәмә** مزاحمه *м. III.* Тарлык, ыгы-зыгылык, кысылышу. *Вак-төяк халыклар миңа мөзахәмә кылырлар дип куркамын, диде.* (К. Нас.) — *м. III.* Давка, теснота; вытеснение.

**Мөзаядә** مذايده *м. III.* Торги белән сату, арттырышу (бәяне). — *м. III.* Набавление цены на аукционе.

**Мөзаһир** مظاهر *сф.* 1) Ярдәм итүче. 2) Таяныч булучы, яклаучы. — *пр. д.* 1) Помогающий, поддерживающий. 2) Покровитель.

**Мөзаһәрәт** مظاهرت *м. III.* Яклау, ярдәм итү, таяныч булу. — *м. III.* Поддержка; покровительство; помощь, опора.

**Мөздәлифә** مزدلفه *ял. ис.* Мәккә янында бер урын исеме. *Мөздәлифәдә өч таш атканда.* (К. Нас.) — *и. с.* Название местности недалеко от Мекки.

**Мөзиррә** مضره *сф.* Зарарлы, зарар китерүче. *Балаларда дәрескә нәфрәт тәгълимнең череклегеннән тугмыш бер нәтиҗәи мөзиррәдер.* (Ш. ж.) — *пр. д.* Вредный, зловредный.

**Мөзниб** مذنب *сф.* 1) Гөнаһлы, бозыклык эшләүче, гөнаһ эшләүче. 2) Азгын, бозылган. — *пр. д.* 1) Грешник. 2) Распущенный, развращённый; испорченный.

**Мөзтариб** مضطرب *сф.* 1) Көенгән, чарасыз калып ачынган, борчылган. 2) Тынычсыз. *Авыр вә мөзтариб кыяфәт белән бераз сөкүт кылганнан соң Нәфисә сүз кузгатты.* (Г. Ибр.) — *пр. д.* 1) Горестный, печальный. 2) Неспокойный; беспокойный.

**Мөзәбзәб** مذبذب *сф.* 1) Икеләнеп, шөбһәләнеп торган, һичбер якка да карар бирә алмаган. 2) Аптырашта калган (кеше). — *пр. с.* 1) Колеблющийся, нерешительный. 2) Растерявшийся.

**Мөзәйял** مذيل *сф.* Арттырылган; китапка өстәлгән (бүлек). — *пр. с.* Добавленный, дополненный; снабжённый приложением (о книге).

**Мөзәййән** مزين *сф.* Зиннәтләнгән, бизәлгән, матурланган. *Мәрҗән вә әнваг җәваһир белән мөзәйян ...* (К. Нас.) — *пр. с.* Украшенный, разукрашенный.

**Мөзәккәр** مذكر *грам.* Ир женескә караган — мужской родка караган сүз. *Әммә телемездә мөзәккәр вә мөәннәслекне белдерүче махсус хәреф юктыр.* (К. Нас.) — 1) *грам.* Мужского рода. 2) Мужской род.

**Мөзәһһәб** مذهب *сф.* Алтынлаган, алтынлап бизәлгән, алтын йөгерткән. — *пр. с.* Позолоченный.

**Мөкавим** مقاوم *сф.* 1) Үзсүзле, нык торучы. 2) Каршы торучы. — *пр. д.* 1) Стойкий, настойчивый. 2) Сопротивляющийся, противящийся.

**Мөкавәмәт** مقاومت *м. III.* 1) Каршы тору; түзеп, чыдап тору, нык тору. *Әгәр аз гаскәр җибәрсәгез аларның гаскәрләренә мөкавәмәт итә алмас ...* — *м. III.* 1) Сопротивление; стойкость. 2) Враждебное отношение.

*диде.* (К. Нас.) 2) Дошманнарча мөнәсәбәт, үзара дошманлык.

**Мөкаддимат хисабия** مقدمات حسابيه *гыйб.* Хисапның кереш өлеше, башлангычы, башлангыч арифметика. *Хәят аз вакыт эчендә русча укып аңларга, беркадәр язарга өйрәнеп һәм беркадәр мөкаддимат хисабия белеп өлгерде.* (Ф. Әмир.)

*фр.* Начальная арифметика.

**Мөкаддәм** مقدم *сф.* 1) Элекке. 2) Алдынгы. 3) Алла баручы. 4) Элек, борын, әүвәл, алда. *Дустың бер дәрәҗәгә ирешсә, аңа мөкаддәмдә карый торган күзең белән карама.* (К. Нас.)

*пр. с.* 1) Прежний. 2) Передовой. 3) Выдвинутый на первое место, идущий впереди. 4) Сперва, вначале.

**Мөкаддәмә** مقدمه *ис.* Сүз башы, кереш сүз.

*сущ.* Предисловие, вступление, введение (в книге).

**Мөкаддәмән** مقدماً *р.* Алдан, элек.

*н.* Прежде; предварительно.

**Мөкаддәр** مقدر *сф.* **1.** Билгеләнгән, алдан билгеле булган; тәкъдир ителгән. *Ул мөкаддәр ризкын ашаучыдыр, разыйк түгелдер,- диде.* (К. Нас.) **2.** Язмыш.

*пр. с.* **1.** 1) Определённый, оценённый. 2) Предопределённый, предрешённый. **2.** Судьба.

**Мөкаддәрат** مقدرات *ис.* Мөкаддәр-нең *к.*

*сущ. мн.* от мөкаддәр.

**Мөкаддәс*** مقدس *сф.* 1) Изге; бөек, иң мөһим, хөрмәтле. *Әй мөкаддәс моңлы сазым, уйнадың син ник бик аз.* (Г. Тук.) 2) Бик диндар.

*пр. с.* 1) Священный, святой. 2) Очень набожный, религиозный.

**Мөкаддәсә** مقدسه *ис.* Мөкаддәс-нең *мнс.*

*сущ. жен.* от мөкаддәс.

**Мөкайиат** مقيئات *ис. к. мед.* Косыру өчен кулланыла торган дарулар.

*сущ. мн. мед.* Лекарства, вызывающие рвоту.

**Мөкайяд** مقيد *сф.* 1) Бәйләнгән, бәйләп куелган. 2) Теркәлгән, язып куелган. 3) Богауланган. 4) Чикләнгән.

*пр. с.* 1) Связанный, привязанный. 2) Зарегистрированный. 3) Скованный; прикованный. 4) Ограниченный.

**Мөкаллид** مقلد *сф.* Иярүче, берәүдән күреп, шуның кебек булырга маташучы. *Долой, кирәкми, сөйләмәсен, бетмәс монда чабаталы дәһриләр ... сукыр мөкаллидләр, дип кычкырырга тотындылар.* (Г. Ибр.)

*пр. д.* 1) Подражатель; последователь. 2) Подражающий.

**Мөкалләд** مقلد *сф.* Иярелгән нәрсә яки кеше. *пр. с.* Подражаемый.

**Мөкарриб** مقرب *сф.* Якынлаштыручы, якын иттерүче. *пр. д.* Приближающий (что-либо).

**Мөкаррәб** مقرب *сф.* Якынайтылган, якынлашкан, якын күрелгән; якын (кеше). *Көймә килгәнен күргәч тә, мөкаррәбләреннән бердүне җибәрде.* (К. Нас.) *пр. с.* Приближённый, близкий; интимный друг.

**Мөкаррәбат** مقربات *ис.* Мөкаррәбнең *к.* *сущ. мн.* от мөкаррәб.

**Мөкаррәр** مقرر *сф.* Карар бирелгән, карар кылынган; билгеләнгән. *Баш алып качмакым мөкаррәрдер,— дип хәтме кәлям кылды.* (К. Нас.) *пр. с.* 1) Определённый; установленный, фиксированный. 2) Утверждённый; решённый, назначенный.

**Мөкассим** مقسم *сф.* Кисәкләргә бүлүче, тураклаучы, ваклаучы. *пр. д.* Разделяющий, распределяющий, делящий на мелкие части.

**Мөкауви** مقوى *сф.* Куәт бирүче, ныгытучы. *Шәйфи үләненнән бер шәрап ясалыр — мөкауви шәраптыр.* (К. Нас.) *пр. д.* Укрепляющий, усиливающий; придающий силы.

**Мөкаувият** مقويات *ис.* Мөкауви-нең *к.* *Мөкаувият бәдәнгә куәт бирүче дарулардыр.* (К. Нас.) *сущ. мн.* от мөкауви.

**Мөкиббән** مكبا *р.* Чиксез (бирелү), артык (мавыгу), сукыр рәвештә (ияру). *Аурупа* (Европа)*ның һәммә эшенә мөкиббән китәргә ярамый.* (Ф. Әмир.) *н.* Слепо (преклоняться перед чем или кем-либо), сильно (увлекаться чем-либо).

**Мөктәсиб** مكتسب *сф.* Кәсеп итүче, эшләп акча табучы. *пр. д.* Зарабатывающий.

**Мөктәсәб** مكتسب *сф.* Кәсеп итеп табылган, эшләп табылган. *пр. с.* Добытый, приобретённый; заработанный.

**Мөкыйл** مقل *сф.* 1) Ярлы, фәкыйрь. 2) Саран. *пр. д.* 1) Бедный. 2) Скупой.

**Мөкябәрә** مكابره *м. III.* Эрелек, горурлык, мин-минлек, олылану, эреләнү, масаю, тәкәбберләнү. *Морадлары мөкябәрә булганнан соң хасидләр күз салмыйлар ар ягына.* (Ак.) *м. III.* Гордость; спесь, надменность, высокомерие.

**Мөкяләмә** مكالمه *м. III.* Сөйләшү, гәпләшү. ... *Студент илә буйлә мөкяләмәмез улды.* (Г. Габ.) *м. III.* Разговор, беседа.

**Мөкясиб** مكاسب *ис.* Мәксәб-нең *к.* *сущ. мн.* от мәксәб.

**Мөкятәбә** مكاتبه *м. III.* Корреспонденция; хат язышу. — *м. III.* Корреспонденция; переписка.

**Мөкяфил** مكافل *сф.* Берәүнең йөгенә керүче, үз җаваплылыгына алучы. — *пр. д.* 1) Поручитель. 2) Берущий на поруки.

**Мөкяфәт** مكافت *м. III.* 1) Хезмәт бәрабәренә бирелгән премия, бүләк. 2) Яхшылыкка каршы эшләнгән яхшылык. *Бик асыл затлар биреп һәм зур мөкяфәтләр биреп котылган.* (Х. Чис.) — *м. III.* 1) Вознаграждение; награда. 2) Воздаяние.

**Мөкяшиф** مكاشف *сф.* 1) Ачучы, яшеренне ачыкка чыгаручы. 2) Фаш итүче. — *пр. д.* 1) Открывающий, обнаруживающий. 2) Разоблачающий.

**Мөкяшәфә** مكاشفه *м. III.* 1) Ачылу. 2) Фаш ителү. — *м. III.* 1) Открытие, обнаружение. 2) Разоблачение.

**Мөкәггаб** مكعب *сф.* 1) Өч юнәлешедә тигез йөзле фигура. 2) Бер санның үз-үзенә өч мәртәбә кабатланышы. — *пр. с.* 1) Имеющий форму куба; кубический; 2) *мат.* Куб.

**Мөкәддир** مكدر *сф.* Көендерүче, кайгы салучы, хәсрәтләндерүче. — *пр. д.* Огорчающий, печалящий.

**Мөкәддәр** مكدر *сф.* Кайгылы, хәсрәтләнгән. *Күңелемнең мөкәддәр улмасына сәбәп.* (М. Ак.) — *пр. с.* Омрачённый, огорчённый, раздосадованный.

**Мөкәззиб** مكذب *сф.* 1) Ялгандыр, дөрес түгелдер дип әйтүче. 2) Ялганга чыгаручы, ялганны фаш итүче. — *пр. д.* 1) Опровергающий. 2) Обличающий во лжи.

**Мөкәйиф** مكيف *сф.* 1) Кәефләндерүче, кәефне китерүче. *Зәгъфран мөфәррих вә мөкәйиф нәрсәдер.* (К. Нас.) 2) Наркотик. — *пр. д.* 1) Опьяняющий; хмельной. 2) Наркотик.

**Мөкәйифат** مكيفات *ис.* Мөкәйифнең *к.* — *сущ. мн.* от мөкәйиф.

**Мөкәлләл** مكلل *сф.* Башына таҗ кигерелгән; таҗлы. — *пр. с.* Увенчанный, коронованный.

**Мөкәлләф** مكلف *сф.* 1) Өстенә йөкләнгән. 2) Җаваплы. 3) Үсеп җиткән. *Угылы Садыйкны мөкәлләф булыр-булмас Габдерахман каридан кыйраәт иттерә иде* (Г. Газиз). — *пр. с.* 1) Обязанный, вынужденный. 2) Ответственный. 3) Взрослый, зрелый.

**Мөкәммәл** مكمل *сф.* 1) Тәмамланган; тулыландырылган. 2) Камилләшкән, житешкән, тулы. *Зиһне бик мөкәммәлдер.* (М. Ак.) — 1) Завершённый, законченный. 2) Доведённый до совершенства, совершённый, превосходный.

**Мөкәррир** مكرر *сф.* 1) Өйрәтүче, кабатлатучы. 2) Репетитор. *Бу мәдрәсәдә* — *пр. д.* 1) Заставляющий повторять. 2) Репетитор.

*хәтем кылганнан соң берничә ел мөкәррир, хәлфә булып ятарга да уйлый.* (Г. Ибр.)

**Мөкәррәм** مكرم *сф.* 1) Хөрмәт ителгән, кадерле, хөрмәтле. *Һәм мөгаззәз һәм мөкәррәм дотар имди.* (К. Гал.) 2) Киң күңелле. — *пр. с.* 1) Уважаемый, почитаемый. 2) Великодушный.

**Мөкәррәмә** مكرمه *сф.* Мөкәррәм-нең *мнс.* — *пр. с. жен.* от мөкәррәм.

**Мөкәррәмән** مكرماً *р.* Хөрмәтләп, кадерләп, кадер күрсәтеп. — *н.* С почтением, с уважением, почтительно.

**Мөкәррәр** مكرر *сф.* Кат-кат, берничә кат (булган), кабат-кабат (эшләнгән). *Кәнде сүзен мәкәррәр сөйләр имди.* (К. Гал.) — *пр. с.* Повторенный; удвоенный; повторный.

**Мөкәррәрән** مكررا *р.* 1) Еш, әлләничә кат, күп мәртәбә. 2) Кат-кат итеп, яңадан, икенчеләп. — *н.* 1) Часто, многократно. 2) Повторно, снова, опять, вторично.

**Мөкәссәр** مكسر *сф.* Ваклаңган, сындырылган. — *пр. с.* Разбитый, сломанный.

**Мөкәүвән** مكون *сф.* Барлыкка китерелгән, бар булган, ясалган. — *пр. с.* Созданный, сотворённый; порождённый.

**Мөкәүвәнат** مكونات *ис.* Мөкәүвәннең *к.* — *сущ. мн.* от мөкәүвән.

**Мөкәүкәб** مكوكب *сф.* Йолдызланган, йолдыз белән бизәлгән. *Минем күңлем мөкәүкәбдер өмет, хәсрәт, тәәссерлә.* (Г. Тук.) — *пр. с.* Усеянный, украшенный звёздами.

**Мөлек** ملك *ис. кара:* милек. — *сущ. см.* Милек.

**Мөлзәм** ملزم *сф.* Бәхәсләшеп җиңелгән, җиңелеп туктаган, туктауга мәҗбүр ителгән. *Дәлил китергән соңында да мөлзәм булмаган моганидлар* ... (К. Нас.) — *пр. с.* Убеждённый, переспоренный; побеждённый в споре.

**Мөлкия** ملكيه *ис.* 1) Хөкүмәткә караган. 2) Хөкүмәтне идарә итүчеләр төркеме. 3) *грам.* Иялек. *Ушбу замирлар затның ахырына илхак кылынып мөлкият мәгънәсен ифадә кылыр.* (К. Нас.) — *сущ.* 1) Относящийся к управлению. 2) Правящие круги. 3) *грам.* Притяжательность (местоимения).

**Мөлля** ملا *ис.* 1) Мулла; дин галиме. 2) Белүче, галим. *Мөллялык, төрле фәннән ормак кирәк.* (Ак.) — *сущ.* 1) Мулла; теолог. 2) Знающий, учёный.

**Мөлтәбәс** ملتبس *сф.* 1) Катышып беткән, буталып беткән, аерып ала алмаслык. *Татар исемен ташлап „төрек“* — *пр. с.* 1) Смешанный, запутанный, сбивчивый. 2) Двусмысленный.

*дип атала башласак, без башка төрек кабиләләре илә мөлтәбәс буламыз.* (Г. Ибр.) 2) Ике төрле аңларлык.

**Мөлтәзәм** ملتزم *сф.* 1) Өстенә эш йөкләнгән. 2) Җаваплы (берәр эш өчен). — *пр. с.* 1) Обязанный. 2) Ответственный (за что-либо).

**Мөлтәка** ملتقا *ис.* 1) Очрашу урыны. 2) Ике елга яки диңгезнең бер-берсенә кушылган урыны. — *сущ.* 1) Место встречи. 2) Место слияния (рек, морей).

**Мөлтәмәс** ملتمس *сф.* Соралган, үтенелгән, өмет ителгән. — *пр. с.* Просимое; то, о чём просят.

**Мөлтәфит** ملتفت *сф.* Илтифат итүче, игътибар бирүче, әһәмият бирүче; кызыксынучы. — *пр. д.* Внимательный, заботливый; интересующийся.

**Мөлхак** ملحق *сф.* 1) Тоташтырылган, кушылган. 2) Кушымта, өстәмә. 3) Ияргән, буйсынган. *Хәзер хаклыйм „Бәянелхак"ларыңны, тәмамилә аңа мөлхакларыңны.* (Г. Тук.) — *пр. с.* 1) Присоединённый; прибавленный. 2) Дополнение, добавление. 3) Зависимый.

**Мөлхакат** ملحقات *ис.* Мөлхак-ның *к.* — *сущ. мн.* от мөлхак.

**Мөлхид** ملحد *сф.* Динсез, динне инкарь итүче, диннән язган. *Мәшһүр бер хатын бер әдәби җәмгыятьтә Хәйямның мөлхидлеген исбат өчен нотык сөйләдекен укымыш идек.* (Ш. ж.) — *пр. д.* Еретик; богоотступник, атеист; безбожник.

**Мөлябис** ملابس *сф.* 1) Берәү белән бик нык аралашкан, катнашкан кеше. 2) Бәйле, якын. *Нигъмәткә мөлябис булганың хәлдә, ул нигъмәтләрне сөйләш.* (К. Нас.) — *пр. д.* 1) Имеющий тесную связь с кем-либо. 2) Близкий, имеющий отношение (к чему-либо).

**Мөлябәсә** ملابسه *м. III.* 1) Буталып бетү, ике нәрсәнең бер-береннән аерылмаслык булып буталуы. 2) Аралашу, дуслашу. — *м. III.* 1) Осложнение; двусмысленность, неясность. 2) Дружба, близость.

**Мөлягабә** ملاعبه *м. III.* Уен-көлке, уйнашу, күңел ачу. — *м. III.* Игра, забава; шутка, веселье.

**Мөлягәнә** ملاعنه *м. III.* Бер-берсен каргашу, ләгънәтләшү. — *м. III.* Взаимное проклятие.

**Мөляем** ملايم *сф.* 1) Ягымлы, йомшак табигатьле. *Мөляем вә хуш лисан кемсәнә улып...* (З. Биг.) 2) Яраклы, әдәпле. — *пр. д.* 1) Мягкий, нежный; тихий, ласковый. 2) Подходящий, приличный.

**Мөляемәт** ملايمت *м. III.* Йомшак күңеллелек, ягымлылык. *Кешегә йөз мөляемәт күрсәтсәң, мең катылыкка хәзер бул.* (К. Нас.) — *м. III.* Мягкость, нежность; ласковость.

**Мөлязим** ملازم *сф.* 1) Берәүдән аерылмаучы; хезмәт күрсәтүче. 2) Тырышучы, күңел биреп эшләүче. ... *И угълан, дәрескә мөлязим бул...* (К. Нас.)

*пр. д.* 1) Постоянно находящийся при кем-либо; состоящий на службе. 2) Прилежный; усердный, неутомимый.

**Мөлязәмәт** ملازمت *м. III.* 1) Бер эш белән шөгыльләнеп бер дә аерылмау. 2) Тырышлык. *Бу эшкә ник мөлязәмәт кыласың.* (К. Нас.)

*м. III.* 1) Неотлучность, неотступность. 2) Прилежность, усердие.

**Мөлякат** ملاقت *м. III.* Очрашу, юлыгышу, кавышу. *Әлхат нисфылмөлякат—сагынып яздым сәлам хат.*

*м. III.* Встреча, свидание.

**Мөлякый** ملاقى *сф.* Юлыгучы, кавышучы, очрашкан. ... *бер гаҗәп эшләргә мөлякый булгайсың.* (К. Нас.)

*пр. д.* Встречающийся, встречный.

**Мөлясыйк** ملاصق *сф.* 1) Янәшә урнашкан. 2) Ябышкан, тоташкан, кушылган.

*пр. д.* 1) Примыкающий, смежный. 2) Соединённый, склеенный.

**Мөлятафә** ملاطفه *м. III.* 1) Йомшаклык белән мөгамәлә итү. 2) Көлкеле итеп сөйләү, көлке сүзләр сөйләшү. *Мәҗлесне озайтмаенча, мөлятафә кыйлып шаһзадәне үз мәкянендә күндерде.* (К. Нас.)

*м. III.* 1) Ласковое обхождение, приветливость; вежливость; любезность, учтивость. 2) Шутливость (в разговоре).

**Мөлятыйф** ملاطف *сф.* 1) Әдәпле, нәзакәтле. 2) Көлке сүзләр, анекдотлар сөйләүче.

*пр. д.* **1.** Вежливый, учтивый, любезный. **2.** Шутник, рассказывающий анекдоты.

**Мөляхәзә** ملاحظه *м. III.* 1) Игътибар белән уйлау, фикер йөртү. ... *абыстай хили фикерләрдән соңра яхшы гына мөляхәзә идеп...* (М. Ак.) 2) Дикъкатьләп карау; күреп алу.

*м. III.* 1) Соображение; наблюдение. 2) Внимательное рассмотрение; примечание, замечание.

**Мөляхәт** ملاحت *м. III.* Ягымлылык, матурлык, гүзәллек.

*м. III.* Красота, изящество, прелесть.

**Мөләббәс** ملبس *сф.* 1) Аралашкан, катышкан, аергысыз. 2) Киелгән, кидергән.

*пр. с.* 1) Смешанный, примешанный. 2) Одетый, облачённый.

**Мөләззәз** ملذذ *сф.* Ләззәтле ителгән, татлыландырылган.

*пр. с.* Услащённый.

**Мөләйин** ملين *сф.* Йомшаклык бирүче, йомшартучы. *Алабута мөләйин вә мөләттыйф дәвалар җөмләсеннәндер.* (К. Нас.)

*пр. д.* Смягчающий; ослабляющий.

**Мөләкъкаб** ملقب *сф.* Кушамат кушылган, кушаматы белән йөртелгән,

*пр. с.* 1) Прозываемый. 2) По прозвищу.

*Иншад иткүче — мөләкъкаб дәрдемәнд - Акменлагыз.* (Ак.)

**Мөләттыйф** ملطف *сф.* Йомшартучы, тынычландыручы. — *пр. д.* Смягчающий; умеряющий; успокоительный.

**Мөләүвән** ملون *сф.* Буялган, төрле төстәге. *Меңләп төрле төстә мөләүвән байраклар.* (К. Нас.) — *пр. с.* Раскрашенный; разноцветный.

**Мөләүвәс** ملوث *сф.* Пычрак, шакшы; пычранган, шакшыланган. *Гөнаһ белән мөләүвәс булмас борын...* (К. Нас.) — *пр. с.* Запятнанный; загрязнённый; замаранный, осквернённый.

**Мөлүк** ملوك *ис.* Мәлик-нең *к.* — *сущ. мн.* от мәлик.

**Мөлүкянә** ملوكانه *гф. р.* Патшаларча, шаһларча, ханнарча. — *ар.-п. н.* По-царски, по-ханскн, по-королевски.

**Мөлһәм** ملهم *сф.* Илһам ителгән, илһамланган. — *пр. с.* Вдохновенный, вдохновлённый.

**Мөманәгать** ممانعت *м. III.* 1) Каршы тору, аркылы төшү, каршы төшү. 2) Тыешу, бер-берен тыю. — *м. III.* 1) Сопротивление; возражение. 2) Препятствование; воспрещение.

**Мөмарәсә** ممارسه *м. III.* Тәҗрибәлелек (кабатлау һәм күп шөгыльләнү аркасында булган осталык). *Замана вакыйгаларының тәҗрибәсе белән сачын агартып мәләкә вә мөмарәсә белән... кадер күргән кемсәнә гакылның күплеге белән мөттасыйфтыр.* (К. Нас.) — *м. III.* Опытность, практика; мастерство.

**Мөмасил** مماثل *сф.* Охшаучы, охшаган. *Әмма Камәрҗан сурәттә тәмам Гөлрохка мөмасил иде.* (К. Нас.) — *пр. д.* Подобный, сходный.

**Мөмасәләт** مماثلت *м. III.* Охшашлык, бер төслелек. — *м. III.* Подобие, сходство.

**Мөмкин*** ممكن *сф.* Булуы тыелмаган, булырлык. — *пр. д.* 1) Не запрещённый. 2) Возможный, вероятный.

**Мөмкинат** ممكنات *ис. к.* Булуы мөмкин булган нәрсәләр, булырлык әйберләр, хәлләр. — *сущ. мн.* Возможности.

**Мөмсик** ممسك *сф.* Каты тотучы, саран, каты кеше. *Әй ингам вә ихсан итмәгән саран, мөмсик, әгәһ бул!* (К. Нас.) — *пр. д.* Скупой, скряга.

**Мөмтаз** ممتاز *сф.* Берәр як белән башкалардан аерылган, башкаларга караганда өстенрәк булган. *Бик шаян, шуклык белән мөмтаз малай.* (Г. Тук.) — *пр. с.* Превосходящий; выделяющийся чем-либо.

**Мөмтәд** ممتد *сф.* Сузылган, озак дәвам иткән. *Бума ютәл баштарак дәва ителмәсә, озакка чаклы мөмтәд булыр.* (К. Нас.) — *пр. с.* Тянущийся, продолжающийся.

**Мөмтәнигъ** ممتنع *сф.* 1) Тыелган. 2) Мөмкин булмаган, булмаслык. — *пр. д.* 1) Запрещённый. 2) Недоступный; невозможный.

**Мөмтәнигат** ممتنعات *ис.* Мөмтәнигъның *к.* *Мөмтәнигат белән анда әмер юктыр.* (К. Нас.) — *сущ. мн.* от мөмтәнигъ.

**Мөмәйиз** مميز *сф.* 1) Аеручы, аера белүче, яхшыны-яманны аеручы. *Ил мөмәйиз, аңлар ул тиз; син аны сизмәс димә.* (Дәрд.) 2) Акыллы. — *пр. д.* 1) Различающий; умеющий отличить хорошее от плохого. 2) Разумный.

**Мөмәйяз** مميز *сф.* 1) Аерылган. 2) *грам.* Аерылмыш. *Исме гадәтнең мөмәйязе... мөфрәд үзрә вакыйгъ буладыр.* (К. Нас.) 3) *мат.* Исемле сан. — *пр. с.* 1) Отличённый, различённый. 2) *грам.* Определённый. 3) *мат.* Именованное число.

**Мөмәссил** ممثل *сф.* Охшатучы, охшатып эшләүче, чагыштыручы. — *пр. д.* Сравнивающий, уподобляющий.

**Мөмәүвәл** مموّل *сф.* Маллы, капиталлы; бай. — *пр. с.* Владелец; капиталист; богач.

**Мөнабәзә** منابذه *м. III.* Инкарь итү, кире кагу. — *м. III.* Отвержение, отказ.

**Мөнавәбә** مناوبه *м. III.* Нәүбәтләшү, чиратлашу, нәүбәтләп эш итү. — *м. III.* 1) Чередование. 2) Периодичность.

**Мөнадат** منادات *ис. к.* Эндәшү, кычкыру, чакыру, игълан итү. — *сущ. мн.* Оклик; приглашение; вызов; призыв, объявление.

**Мөнади** منادی *сф.* Чакыручы, кычкыручы, яр салучы (көнчыгышта хөкүмәтнең карарын яки берәр вакыйганы шәһәр урамнарында кычкырып, белдереп йөрүче). *Шәһәр мәхәлләләренә мөнадиләр җибәреп, һичбер фәрд килми калмасын дип нида кылсыннар диде.* (К. Нас.) — *пр. д.* 1) Глашатай. 2) Возвещающий, извещающий.

**Мөнадәмәт** منادمت *м. III.* 1) Дуслык мөнәсәбәтләре. 2) Утырдашчылык итү, күңел ачып сөйләшеп утыру. — *м. III.* 1) Приятельские отношения. 2) Собеседование.

**Мөназигъ** منازع *сф.* 1) Низаглашучы, ызгышучы. 2) Каршы чыгучы. — *пр. д.* 1) Спорящий; ссорящийся. 2) Возражающий.

**Мөназәга** منازعه *м. III.* 1) Ызгышу, низагълашу. *Әһали белән задәкян ара-* — *м. III.* 1) Спор; ссора. 2) Диспут.

*сында· мөназәгаләр тәкрарланды.* (Х. Чис.) 2) Бәхәс.

**Мөназәгъ фиһ** منازع فيه *ст.* Бәхәсле әйбер. — *сс.* Предмет спора; спорная вещь.

**Мөнакашә** مناقشه *м. III.* 1) Ваклап, жентекләп тикшерү, 2) Сүз көрәштерү; тартышу, бәхәс. *Мисалга мөнакашә юк диләр, диде.* (Г. Ибр.) — *м. III.* 1) Подробное изучение, обсуждение. 2) Дебаты, прения; спор.

**Мөнакәхә** مناكحه *м. III.* Никахланышу, өйләнешү. — *м. III.* Бракосочетание, заключение брака.

**Мөнасиб** مناسب *сф.* 1) Яраклы, яраклылык. *Үзләренә мөнасиб тормыш биреп...* (Ф. Әмир.) 2) Бер-берсенә туры килешкән, муафыйк. 3) Әдәпле. — *пр. д.* 1) Подходящий, соответствующий; сообразный; сходный. 2) Соразмерный; пропорциональный. 3) Приличный.

**Мөнасәбәт*** مناسبت *м. III.* Бәйләнеш, якынлык, бер-берсенә туры килешү. *Шул мөнасәбәт белән һәрвакыт бикәнең кунак булмәсенә йөрер.* (З. Һад.) — *м. III.* Отношение; соответствие, сообразность.

**Мөнасәфә** مناصفه *м. III.* Урталай (икегә) бүлү. — *м. III.* Разделение пополам, надвое.

**Мөнафат** منافات *м. III.* Капма-каршылык, туры килмәү; бергә җыела алмау (ут белән су кебек). — *м. III.* Противоположность, расхождение, несоответствие, несовместимость.

**Мөнафи** منافى *сф.* Бер-берсе белән ошамый торган, бер-берсенә каршы. *Морадына мөнафины сөйми торган.* (Ак.) — *пр. д.* Противоречащий, несовместимый.

**Мөнафиһа** منافيها *ст.* Аңа каршы. *Касавәт кәлмәер кальбә: сәнең шигъреӊ мөнафиһа.* (Г. Тук.) — *сс.* Ей противоречащий; ей (ему) несоответствующий.

**Мөнафәрәт** منافرت *м. III.* Җирәнешү, кара-каршы нәфрәт әйтешү, бизешү. — *м. III.* Презрение, взаимное отвращение.

**Мөнафәт** منافت *ис. кара:* мөнафат. — *сущ. см.* Мөнафат.

**Мөнафәсә** منافسه *м. III.* Үз файдасын күздә тотып бер-бере белән тартышу, көнләшү. — *м. III.* Соперничество, конкуренция.

**Мөнаҗат*** مناجات *м. III.* 1) Аллага ялвару, мактау сүзләре әйтү. 2) Дини тезмә әсәр. — *м. III.* 1) Мольба к аллаху; славословие. 2) Религиозный гимн, псалом.

**Мөнбит** منبت *сф.* Уңдырышлы, мул уңыш бирүче. *Күп еладым, яшьләрем мөнбит урынга төшмәде.* (М. Гаф.) — *пр. д.* Плодородный.

**Мөнбәгый** منبعى *сф.* Ятышлы, яраклы, ярашкан. — *пр. д.* Подходящий, соответствующий.

**Мөнбәгыйс** منبعث *сф.* 1) Бер сәбәптән туган, бер эштән килеп чыккан. 2) Индерелгән, җибәрелгән. — *пр. д.* 1) Имеющий один источник происхождения. 2) Ниспосланный, посланный.

**Мөнбәсыйт** منبسط *сф.* 1) Куанган; шатланган, күңеле булган. *Гыйльме булмаган кешегә „Син беләсең, син галим" дисәң, мәхзуз вә мөнбәсыйт булыр.* (К. Нас.) 2) Ачылган, ачылып киткән; киңәйгән, җәелгән. — *пр. д.* 1) Радостный, удовлетворённый. 2) Расширенный; обширный; разостланный, простёртый.

**Мөнгазил** منعزل *сф.* 1) Аерылган, ялгызланган. 2) Урыныннан төшерелгән. — *пр. д.* 1) Удалившийся, уединившийся. 2) Уволенный.

**Мөнгадил** منعدل *сф.* Туры юлдан чыккан, юлдан язган. — *пр. д.* Отклонившийся от прямого пути.

**Мөнгадим** منعدم *сф.* 1) Булмаган; юк булган. 2) Юк ителгән. 3) Юкка чыккан. — *пр. д.* 1) Отсутствующий. 2) Уничтоженный. 3) Исчезнувший.

**Мөнгакис** منعكس *сф.* Кире әйләнгән; кире кайтарылган. *Бер-беренә мөнгакис булыр, бер-беренә каршы куелмыш ике көзгегә охшар.* (К. Нас.) — *пр. д.* Отражённый, опрокинутый.

**Мөнгакыйд** منعقد *сф.* 1) Бәйләнгән, төенләнгән. 2) Килешеп, вәгъдәләшеп кул куелган. — *пр. д.* 1) Связанный (узлом). 2) Заключённый (о договоре).

**Мөнгыйм** منعم *сф.* Ашатучы, аш бирүче, нигъмәт бирүче. *Мөнгыймнәрдән бирәү садаканы учы өстенә куеп бирер иде.* (К. Нас.) — *пр. д.* 1) Благодетель; кормилец. 2) Благодетельный.

**Мөндәрис** مندرس *сф.* 1) Искереп бетеп юкка чыккан, таушалган, тузган. 2) Бетерелгән, әсәре дә калмаган. — *пр. д.* 1) Стёртый, исчезнувший; изношенный; ветхий. 2) Уничтоженный, изглаженный.

**Мөндәриҗ** مندرج *сф.* 1) Арага кертелгән, теркәлгән. 2) Эчтәлек. — *пр. д.* 1) Включённый, помещённый. 2) Содержимое.

**Мөндәриҗә** مندرجه *ис.* Мөндәриҗнең *мнс.* — *жен.* от мөндәриҗ.

**Мөндәриҗат** مندرجات *ис.* Мөндәриҗнең *к.* — *сущ. мн.* от мөндәриҗ.

**Мөндәфигъ** مندفع *сф.* Беткән, кире кайтарылган, бетерелгән. — *пр. д.* 1) Удалённый; устранённый. 2) Отвергнутый; отверженный.

**Мөндәфин** مندفن *сф.* Күмелгән, туфрак астында калган. — *пр. д.* Зарытый; погребенный.

**Мөнзаләм** منظلم *сф.* Җәбергә (кыерсытуга, кысуга) дучар булган. — *пр. с.* Угнетённый, обиженный.

**Мөнзам** منضم *сф.* Беректерелгән, кушылган, өстәлгән. — *пр. с.* Присоединённый; приложенный; дополненный.

**Мөнзир** منذر *сф.* Үгетләүче; алда куркыныч барлыкны хәбәр итүче; сак булырга кушучы. — *пр. д.* 1) Увещевающий; предостерегающий. 2) Увещеватель.

**Мөнзәви** منزوی *сф.* Читләшкән, читтә калган; аралашмаган. *Сиутый Әхмәтмидхәт кабиленнән фәкыйрь вә мөнзәви гаиләдән түгел.* (Р. Фәх.) — *пр. д.* Уединившийся, скрывшийся.

**Мөнзәл** منزل *сф.* Индерелгән, түбән төшерелгән. — *пр. с.* Ниспосланный.

**Мөниб** منب *сф.* Туры юлга керүче (бозык эшләрне ташлап, дөреслеккә кайтучы). — *пр. д.* Раскаявшийся; становящийся на правильный путь.

**Мөнир** منیر *сф.* Яктылык бирүче; нурландыручы; яктыртучы. — *пр. д.* Освещающий, светящийся.

**Мөнкабизъ** منقبض *сф.* 1) Кысылган, җыерылган, тартылган, тарайган. 2) Эч кату авыруы белән авыручы. — *пр. д.* 1) Сжавшийся, съёжившийся, сократившийся в объёме. 2) Страдающий запором.

**Мөнкалиб** منقلب *сф.* 1) Алмашынган, үзгәргән. 2) Әйләндерелгән. *Җәмигъ хәсрәтләре шатлыкка мөнкалиб булып, шаһзадәне тәгъзим белән...* (К. Нас.) — *пр. с.* 1) Изменившийся, переменившийся. 2) Перевёрнутый; опрокинутый.

**Мөнкариз** منقرض *сф.* Сүнгән, юкка чыккан, беткән, нәселе калмаган, һәлак булган. *Исламда хәрам булган рәһбанијать капладьı: иҗтиһад мөнкариз диделәр.* (Г. Ибр.) — *пр. д.* Угасший; исчезнувший; вымерший (о династии, народе и т. п.)

**Мөнкасим** منقسم *сф.* Бүленгән, өлешләнгән, кисәкләнгән, аерылган. *Кәлимә өчкә мөнкасимдер.* (К. Нас.) — *пр. д.* Разделённый; поделённый на части.

**Мөнкатыйг** منقطع *сф.* 1) Киселгән, өзелгән. 2) Тукталган, беткән. *Ашаучыдән мөнкатыйг булып төшәгендә аһ чикмәктәдер, — диде.* (К. Нас.) 3) Ялгызак. — *пр. д.* 1) Отрезанный; 2) Прекратившийся; конченный. 3) Одинокий.

**Мөнкир** منکر *сф.* **1.** Инкарь итүче; ышанмаучы, кабул итмәүче, юкка чы- — *пр. д.* **1.** Отрицающий, непризнающий; неверя-

гаручы, танымаучы. *Мөһәндис барлыгын мөнкир „көфер" почмагына барсын.* (Г. Тук.) 2) *дини* Мөнкир (ислам дине буенча кабердә сорау алучы ике фәрештәдән берсенең исеме). — щий. 2) *рел.* Мункир (имя одного из ангелов, допрашивающих покойников о их жизни).

**Мөнкыйл** منقل *сф.* Бер кеше сүзен фәлән сөйләде дип икенче берәүгә сөйләүче яки язучы. — *пр. д.* Пересказывающий, переписывающий.

**Мөнкәр** منكر *сф.* 1) Инкарь ителгән; танылмаган; 2) *дини* Начар, гөнаһ исәпләнгән. — *пр. с.* 1) Отвергаемый, непризнанный. 2) *рел.* Греховный, недозволенный.

**Мөнкәрат** منكرات *ис.* Мөнкәр -нең *к.* *Тик заман аны мөнкәраттан мәңгы кылыр, — диде.* (К. Нас.) — *сущ. мн.* от мөнкәр.

**Мөнкәсир** منكسر *сф.* Сынган, ватылган; вакланган. — *пр. д.* Разбитый, разломанный; раздробленный, переломленный.

**Мөнкәсиф** منكسف *сф.* Тотылган (кояш, ай). — *пр. д.* Попавший в затмение (о луне, солнце).

**Мөнкәшиф** منكشف *сф.* Ачылган, күренгән, мәйданга чыккан; табылган. *Байлыкка ирешеп мохтаҗлыктан чыккач, начар әхлакың мөнкәшиф булды.* (К. Нас.) — *пр. д.* Обнаруженный, открытый, найденный.

**Мөнсаб** منصب *ис.* Койган, тоташкан, коя торган, агып төшкән (елга турында). — *сущ.* Изливающийся, вливающийся, впадающий, стекающий (о реке, воде и т. д.).

**Мөнсәни** منثنى *сф.* Кәкре, бөкре. — *пр. с.* Кривой, горбатый.

**Мөнсарих** منصرح *сф.* Ачык, ачыкланган, аңлашылган. — *пр. д.* Ясный, понятный.

**Мөнсәд** منسد *сф.* Киртәләнгән, капланган. — *пр. с.* Преграждённый, закупоренный.

**Мөнсәлиб** منسلب *сф.* 1) Таланган. 2) Тартып алынган. 3) Инкарь ителгән. — *пр. д.* 1) Ограбленный. 2) Отнятый. 3) Отвергнутый.

**Мөнсәлик** منسلك *сф.* Нинди дә булса бер дини караште булган. — *пр. д.* Принадлежащий к какой-либо секте, вероучению.

**Мөнсәлих** منسلخ *сф.* 1) Тиресе туналган, суелган. 2) Суырып, аерып алынган. — *пр. с.* 1) Облупленный, облезлый (о коже). 2) Отделённый (от чего-либо).

**Мөнтабәгъ** منطبع *сф.* 1) Сугылган, басылган. 2) Сурәтләнгән, гәүдәләнгән. *Гакыл бер көзгедер, гаибат анда мөнтабәгъ булыр.* (К. Нас.) — *пр. с.* 1) Напечатанный 2) Отображённый.

**Мөнтави** منطوى *сф.* Төрелгән, уралган. — *пр. д.* Свёрнутый, завёрнутый.

**Мөнтафи** منطفى *сф.* Сүндерелгән, янудан туктатылган. — *пр. д.* Потушенный, погашенный.

**Мөнтиҗ** منتج *сф.* Нәтиҗәле, нәтиҗә бирүче. *Шул сәбәпле кыяслары мөнтиҗ түгеллекне исбат итәргә кирәк.* (Г. Ибр.) — *пр. д.* Дающий результаты, порождающий; производящий.

**Мөнтәбиһ** منتبه *сф.* 1) Уятылган. 2) Уяу. — *пр. д.* 1) Пробудившийся. 2) Бодрствующий.

**Мөнтәзар** منتظر *сф.* Көтелгән, булуы көтелгән. — *пр. с.* Ожидаемый.

**Мөнтәзыйр** منتظر *сф.* Көтеп торучы, күзәтүче, өмет итүче. *Көнчыгыш халкын беләалмыйм инде нәрсә мөнтәзыйр...* (Г. Тук.) — *пр. д.* Ожидающий; наблюдающий; надеющийся.

**Мөнтәзыйрән** منتظرا *р.* Көтеп, көткән (күзәткән) хәлдә. *Шаһның әмерене мөнтәзыйрән хәйран булып тордылар.* (К. Нас.) — *н.* В ожидании, в надежде.

**Мөнтәкыйд** منتقد *сф.* Тәнкыйть итүче, тәнкыйтьче. *Күп сөйләдем, яхшы инде, мөнтәкыйдләр сүкмәсә.* (Г. Тук.) — *пр. д.* 1) Критикующий. 2) Критик.

**Мөнтәкыйль** منتقل *сф.* 1) Күчүче, урынын алыштыручы. 2) Берәүдән икенче берәүгә күчкән. — *пр. д.* 1) Перемещающийся; переезжающий; отправляющийся (куда-либо). 2) Переходящий, переведённый.

**Мөнтәкыйм** منتقم *сф.* Үч алучы. — *пр. д.* Мстящий.

**Мөнтәкыйш** منتقش *сф.* Бизәлгән, бизәкләндерелгән. — *пр. д.* Разукрашенный.

**Мөнтәсиб** منتسب *сф.* Бер яктан бер нәрсәгә якынланучы, бер нәрсәгә тоташучы, бәйләнешле булган. — *пр. д.* Относящийся, приписываемый; имеющий связь.

**Мөнтәсыйх** منتصح *сф.* Үгет-нәсыйхәтне тотучы, кабул итүче. — *пр. д.* Слушающий, внимающий наставлению.

**Мөнтәхәб** منتخب *сф.* 1) Сайланган, сайлап алылган. 2) Сайланма, сайлап җыелган. *... шактый күп мөнтәхәб җырларыбызны эченә алган.* (Г. Тук.) — *пр. с.* 1) Избранный, выбранный. 2) Собранный. 3) Сборник.

**Мөнтәхәбат** منتخبات *ис.* Мөнтәхәбнең *к.* — *сущ. мн.* от мөнтәхәб.

**Мөнтәфи** منتفى *сф.* Куылган, сөрелгән; юк ителгән, бетерелгән. — *пр. с.* Устранённый, удалённый, отверженный; изгнанный; ликвидированный.

**Мөнтәфигъ** منتفع *сф.* Файдаланучы, файда күрүче. *Авырулар пәйда булып, адәм сиххәтлек белән мөнтәфигъ була алмас.* (К. Нас.) — *пр. д.* Получающий пользу; извлекающий выгоду, пользующийся.

**Мөнтәфих** منتفخ *сф.* Куыкланган, һава өреп тутырылган. — *пр. д.* Вздутый; наполненный воздухом.

**Мөнтәшир** منتشر *сф.* 1) Басылган, басып таратылган (китап). 2) Җәелгән. ... *мөләүвән байраклар сахраның ике ягына мөнтәшир булмышлар.* (К. Нас.) — *пр. д.* 1) Изданный, опубликованный. 2) Распространённый; обнародованный.

**Мөнтәҗ** منتج *сф.* **1.** Барлыкка кителгән. **2.** Продукт. — *пр. с.* **1.** Произведённый. **2.** Продукт.

**Мөнтәһа** منتها،منتهى *ис.* Ахыргы чик, соңгы оч. *Хәятының мөнтәһасы ушбу көндәдер.* (К. Нас.) — *сущ.* Конец; предел.

**Мөнтәһиз** منتهز *сф.* Вакытны бушка үткәрмәүче, форсаттан файдаланучы. — *пр. д.* Использующий удобный случай, момент.

**Мөнфикъ** منفق *сф.* 1) Берәүнең тәрбиясенә акча биреп торучы; акча биреп тәрбия итүче. 2) Хәер бирүче. — *пр. д.* 1) Прокармливающий; содержащий. 2) Раздающий милостыню.

**Мөнфәгыйль** منفعل *сф.* 1) Дулкынланучы, кичерүче. 2) Ачуланучы; хәтере калган, күңеле кырылган. *Бер вәзире бардыр, бәгъзе хосуста мөнфәгыйль булып газел кылынмыштыр.* (К. Нас.) — *пр. д.* 1) Волнующийся; переживающий. 2) Сердящийся.

**Мөнфәк** منفك *сф.* Аерылган, читләшкән. *Бәдиһидер ки: дин мөнфәк дәгелдер халкы дөньядан.* (Г. Тук) — *пр. с.* Отделённый; обособленный.

**Мөнфәрид** منفرد *сф.* Ялгыз, бер үзе, аерым, кушылмаган. *Кайберләре тәсауыф исеме белән мөнфәрид булдылар.* (К. Нас.) — *пр. д.* 1) Одинокий, одиночный. 2) Уединённый.

**Мөнфәридән** منفرداً *р.*Ялгызлыкта, ялгызлык хәлендә, үзе генә, ялгыз көенә. — *н.* Поодиночке, отдельно; по одному.

**Мөнфәриҗ** منفرج *сф.* Киң, ике арасы ачык, ерык. *Завияи мөнфәриҗә*— 90° тан артык почмак. — *пр. д.* Приоткрытый, треснувший, разверзшийся.

**Мөнфәсих** منفسخ *сф.* Юкка чыгарылган, көче бетерелгән, кулланудан чыккан. — *пр. д.* Уничтоженный; отменённый, аннулированный.

**Мөнфәсыйл** منفصل *сф.* 1) Бер-беренә кушылмаган, аерылган. 2) Аерым. *Замиры мөнфәсыйл дигәнемез замиры шәхыслардыр...* (К. Нас.) — *пр. д.* 1) Отделённый, разделённый. 2) Отдельный.

**Мөнфәһим** منفهم *сф.* Аңлашылган, төшенелгән. — *пр. д.* Понятый.

**Мөнхат** منحط *сф.* 1) Түбәнгә төшкән. 2) Иңгән. 3) Түбән. — *пр. с.* 1) Опустившийся вниз. 2) Ниспосланный. 3) Низкий.

**Мөнхәлл** منحل *сф.* 1) Таратылган. 2) Хәл ителгән, чишелгән. — *пр. с.* 1) Распущенный; расформированный. 2) Разрешённый.

**Мөнхәни** منحنی *сф.* Бөгелгән, кәкре. *Рәсем дәресенең икенче сәнәсендә мөнхәни сатыхлы җисемнәрнең дә рәсемнәрен сыздырырга ярый.* (Ш. ж.) — *пр. с.* Кривой, изогнутый.

**Мөнхәникъ** منخنق *сф.* Буылган, буылып үлгән. — *пр. д.* Задушенный, задохнувшийся.

**Мөнхәриф** منحرف *сф.* 1) Кирегә әйләнгән, читләшкән; авышкан. *Көчле булган гакыйлләр бардыр ки, ризык алардан мөнхәриф, ә зәгыйфел гакыл ахмаклар дәүләтне гүя диңгездән чумырып алалар.* (К. Нас.) 2) Туры юлдан чыккан. — *пр. д.* 1) Отклоняющийся; избегающий; уходящий в сторону. 2) Сходящий с правильного пути.

**Мөнхәсиф** منخسف *сф.* 1) Томаланган, караңгыланган, тотылган (ай). *Кыяматтер бу көн шәмсе хакыйкать мөнхәсиф улды.* (Г. Тук.) 2) Чоңгыл, упкын. — *пр. д.* 1) Затмившийся, находящийся в стадии затмения (о луне). 2) Бездна, пропасть.

**Мөнхәсыйр** منحصر *сф.* 1) Бөтен яктан чолгап алынган, камалган, чиге билгеле булган. 2) Кыскартылган, ялгыз бернәрсәгә генә хасланган. *Бу сәбатә мөнхәсыйр мәфтүн вә мәҗлүбиятем.* (Г. Тук.) — *пр. д.* 1) Ограниченный, окружённый, суженный. 2) Укороченный; определённый.

**Мөнхәсыйрән** منحصراً *р.* Чикләп, башкалардан аерып. — *н.* Ограниченно; исключительно.

**Мөнши** منشی *сф.* Күңелдән чыгарып язарга оста кеше; инша итүче. *Мин синең гаять мөнши вә бәлигъ икәнеңне белмим ләбаса.* (К. Нас.) — *пр. д.* Способный излагать свои мысли; сочинитель.

**Мөншәат** منشآت *ис. к.* Язылган нәрсәләр, иншалар, язу үрнәкләре.
*сущ. мн.* Сочинения, изложения; образцы письма.

**Мөншәгыйб** منشعب *сф.* Тармакланган, ботакланган, тармакларга аерылган; бүлекчәләнгән.
*пр. д.* Разветвляющийся, имеющий отрасли.

**Мөншәкъ** منشق *сф.* 1) Ярылган, аерылган. 2) Бүленгән, тармакланган.
*пр. с.* 1) Расколовшийся, расщепленный, треснувший. 2) Разделённый, разветвлённый.

**Мөншәрих** منشرح *сф.* Шат, шат күңелле, күңеле ачылган; ачык.
*пр. д.* Весёлый, радостный, довольный; приветливый.

**Мөнәббиһ** منبه *сф.* 1) Уятучы. *Бөтнек мигъдәнә вә йөрәкне мөнәббиһдер вә мөкаувидер.* (К. Нас.) 2) Кисәтүче.
*пр. д.* 1) Пробуждающий. 2) Предупреждающий.

**Мөнәззаф** منظف *сф.* Тазартылган, пакьләнгән, чистартылган, әрчелгән.
*пр. с.* Очищенный, прочищенный, вычищенный.

**Мөнәззәл** منزل *сф.* 1) Киметелгән, төшерелгән. 2) *дини* Индерелгән.
*пр. с.* 1) Пониженный. 2) *рел.* Ниспосланный.

**Мөнәззәһ** منزه *сф.* 1) Начар (бозык) сыйфатлардан арынган. 2) Начарлыклардан ерак торган.
*пр. с.* 1) Очищенный, чистый. 2) Далёкий от плохих поступков, дел.

**Мөнәкъка** منقى،منقا *сф.* 1. Чистарган, тазарынган. 2. Чиста, пакь.
*пр. с.* 1. Очищенный. 2) Чистый.

**Мөнәкъкас** منقص *сф.* Төшкән, азайган, кимегән. *Һәмишә хәтеремез мондин мөнәкъкас булып торыр.*
*пр. с.* Сокращённый, уменьшенный, сниженный.

**Мөнәкъкат** منقط *сф.* Нокталы, нокта куелган (хәрефләр турында).
*пр. с.* Усеянный точками; имеющий точки (о букве).

**Мөнәкъкаш** منقش *сф.* 1. Рәсемле, бизәкле. 2. Рәсемләндерелгән, бизәкләндерелгән, нәкышьләнгән.
*пр. с.* Расписанный, разукрашенный; гравированный.

**Мөнәкъкыйд** منقد *сф.* Тәнкыйть итүче, тәнкыйтьче.
*пр. д.* Критик.

Искәрмә. Мөнәкъкыйд һәм аның төбе булган тәнкыйть сүзләре гарәптә юк. Чөнки нәкыд тамырыннан 2 нче баб (тәфгыйль бабы) фигыль формасы ясалмый, моны фарсылар яки без үзебез ясаганбыз.

**Мөнәүвим** منوم *сф.* Йоклатучы. *Мондаен даруларны мөнәүвим тәсмия кылыныр.* (К. Нас.)
*пр. д.* Снотворный, погружающий в сон; наркотический.

**Мөнәүвир** منور *сф.* Нурландыручы, яктыртучы. *Улсын мөнәүвир фикереңез.* (Г. Тук.) — *пр. д.* Озаряющий, освещающий.

**Мөнәүвәр** منور *сф.* 1) Нурланган, яктыртылган. 2) Нурлы, якты. *Хәтеремне син мөнәүвәр кылгыл имде.* (К. Гал.) 3) Якты (Мәдинә шәһәренең эпитеты). — *пр. с.* 1) Озарённый; светящийся. 2) Светлый. 3) Светлый (эпитет г. Медины).

**Мөнәүвәрә** منوره Мөнәүвәр -нең *мнс.* — *жен.* от мөнәүвәр.

**Мөнәҗҗи** منجى *кара:* мөнҗи. — *см.* Мөнҗи

**Мөнәҗҗим** منجم *сф.* 1) Астроном, йолдызлар тикшерүче галим. 2) Йолдызлар хәленә карап киләчәктән хәбәр итүче, күрәзә. *Бөтенләй аптырап беткәч, чакырды хан багучыны, мөнәҗҗим, фалчыны һәм дә хәким исмен тагучыны.* (Г. Тук.) — *пр. д.* 1) Астроном. 2) Звездочёт; астролог.

**Мөнҗи** منجى *сф.* Коткаручы, котылдыручы. *Тапты нәҗат бер мөнҗидән.* (Г. Тук.) — *пр. д.* 1) Освобождающий; спасающий. 2) Спаситель.

**Мөнҗия** منجيه *сф.* Мөнҗи-нең *мнс.* — *пр. д. жен.* от мөнҗи.

**Мөнҗәзиб** منجذب *сф.* Тартылучы, тартып китерелә торган, якын китерелә торган. — *пр. д.* Притягиваемый.

**Мөнҗәмид** منجمد *сф.* Туң, каткан. *Бәхре мөнҗәмид* — боз диңгезе, каткан диңгез. — *пр. с.* Замёрзший; замороженный, обледеневший, застывший; затвердевший.

**Мөнҗәникъ** منجنق *сф.* Борынгы заман сугыш коралы, ныгытмаларны ватыру өчен таш аткыч. — *пр. д.* Осадная машина, баллиста.

**Мөнҗәр** منجر *сф.* Тартып алып барыла торган. — *пр. с.* Влекомый, увлекаемый, перетаскиваемый.

**Мөнһәдим** منهدم *сф.* Ватылган, җимерелгән; вәйран булган. — *пр. д.* Разрушенный; сломанный; обрушившийся.

**Мөнһәзим** منهزم *сф.* 1) Тар-мар ителгән, җиңелеп таралган. 2) Җиңелгән. — *пр. д.* 1) Разбитый, обращённый в бегство. 2) Побеждённый.

**Мөнһәзимән** منهزماً *р.* Җиңелгән, тар-мар ителгән хәлдә. — *н.* В разгромленном состоянии.

**Мөнһәзыйм** منهضم *сф.* Ашказанына сеңгән. — *пр. д.* Переваренный (о пище в желудке).

**Мөрабәхә** مرابحه *м. III.* 1) Күп файда белән сату, алып -сату. 3) Зур процент белән бурыч бирү яки алу. — *м. III.* 1) Перепродажа; продажа с большой выгодой. 2) Заём под большой процент.

**Мөрасәлә** مراسله *м. III.* Хат җибәрешү, хат язышу. — *м. III.* Переписка, корреспонденция.

**Мөрафикъ** مرافق *сф.* Юлдашлык итүче, юлдаш, озата баручы. — *пр. д.* 1) Сопровождающий (в пути). 2) Спутник.

**Мөрафәга** مرافعه *м. III.* Суд эше, каршылыкны чишү. *Мөрафәга өчен казый хозурына килделәр.* (Ш. ж.) — *м. III.* Судебный процесс; разбор дела.

**Мөрафәкать** مرافقت *м. III.* Юлдашлык итү, озата бару. — *м. III.* Сопровождение.

**Мөрахәлә** مراحله *м. III.* Әйберне бер җирдән икенче җиргә күчерешү. — *м. III.* Помошь в перемещении вещей с места на место.

**Мөраһикъ** مراهق *сф.* Яшүсмер. *Адәмнең яшьләре өчен: нарасидә, саби, мөраһикъ, егет, ир, ир уртасы, карт ләфызларыннан башка махсус юктыр.* (К. Нас.) — *пр. д.* Юноша; подросток.

**Мөргъ** مرغ *ф. ис.* Кош. *Мөрганә* — кош йомыркасы. — *п. сущ.* Птица. *Мөрганә* — Птичье яйцо.

**Мөргъ Сөләйман** — һөдһөд (кош). — Удод.

**Мөргъ сәхәр** — таң кошы (сандугач). — Птица, поющая на заре (соловей).

**Мөрд** مرد *ф. с.* Үлгән, вафат булган. — *п. прил.* Дохлый; умерший.

**Мөрдар*** مردار *ф. с.* 1) Үләксә. 2) *күч.* Пычрак, шакшы, кабахәт, әшәке. *Ул бик мөрдар кеше.* (З. Биг.) — *п. прил.* 1) Мертвечина, падаль; труп. 2) *перен.* Нечистый, поганый, осквернённый.

**Мөрид*** مريد *сф.* 1) Берәүгә иярүче, шәкерт. 2) *дини* Ишанга кул биргән кеше, ишан шәкерте, иярчен. — *пр. д.* 1) Последователь, ученик. 2) *рел.* Мурид (последователь духовного руководителя — муршида).

**Мөррә** مر *сф.* 1) Ачы. 2) Авыр, әрнетә торган. — *прил.* 1) Горький. 3) Тяжёлый, печальный, горестный.

**Мөрсәл** مرسل *сф.* 1) Җибәрелгән, күндерелгән кеше. 2) Илче. 3) Пигамбәр. *Йосыф мөрсәл нәби дип сүзләр имди.* (К. Гал.) — *пр. с.* 1) Посланный, отправленный. 2) Посланец. 3) Пророк.

**Мөрсәлат** مرسلات *ис. к.* Җибәрелгән әйберләр (хатлар, посылкалар). — *сущ. мн.* Отправленные (посылки, письма).

**Мөрсәлин** مرسلين *ис.* Мөрсәл-нең *к.* — *сущ. мн.* от мөрсәл.

**Мөртаза** مرتضى *сф.* 1) Канәгатьләндерелгән, күңелгә муафыйк ителгән. 2) Сайланган, артык күрелгән (Галинең эпитеты). — *пр. с.* 1) Удовлетворённый. 2) Избранный (эпитет Али).

**Мөртәгыйш** مرتعش *сф.* Тетрәүче, калтыраучы. — *пр. д.* Дрожащий, трясущийся, содрогающийся.

**Мөртәд*** مرتد *сф.* Мөртәт, динен ташлаган, диннән язган, башка дингә күчкән. — *пр. д.* Вероотступник; ренегат; перерожденец, отщепенец.

**Мөртәкиб** مرتكب *сф.* Начар эшкә бирелүче, гөнаһ кылучы. *...аз-аз гөнаһы кәбаирләргә мөртәкиб уладыр.* (З. Биг.) — *пр. д.* Совершающий (грех, преступление и т. п.).

**Мөртәсәм** مرتسم *сф.* Рәсемләнгән, сурәте төшерелгән; сызылган. *Бөтенләй мөртәсәм фикере миендә: ялангач кыз, бәлеш, тәнкә, тиен дә.* (Г. Тук.) — *пр. с.* Изображённый, нарисованный; начерченный.

**Мөртәфигъ** مرتفع *сф.* 1) Күтәренке, югары. 2) Гамәлдән чыгарылган. — *пр. д.* 1) Возвышенный, высокий. 2) Устранённый, снятый, ликвидированный.

**Мөртәхил** مرتحل *сф.* Күчүче, урынын алмаштыручы. — *пр. д.* Переезжающий меняющий своё место.

**Мөртәши** مرتشى *сф.* Ришвәтче, ришвәт алучы. — *пр. д.* Взяточник.

**Мөртәҗәл** مرتجل *сф.* Уйлап тормастан сөйләнгән (сүз). — *пр. с.* Сказанный экспромтом.

**Мөртәһин** مرتهن *сф.* Рәһен (залог) итеп бирәр нәрсә алучы. — *пр. д.* Берущий что-либо под залог.

**Мөршид** مرشد *сф.* 1) *дини* Туры юл күрсәтүче; хаклыкка, турылыкка өндәүче. *Мөритләре Җиһанша хәзрәтне мөршиде кямил дип белделәр* (З. Һади). 2) Юл күрсәтүче. — *пр. д.* 1) *рел.* Наставник, проповедник. 2) Проводник.

**Мөршидә** مرشده *ис.* Мөршид-нең *мнс.* — *жен.* от мөршид.

**Мөрәбба** مربى *сф.* 1) Тәрбияләнгән. 2) Варенье. — *пр. с.* 1) Воспитанный. 2) Варенье.

**Мөрәбби** مربى *сф.* Тәрбияче. — *пр. д.* Воспитатель.

**Мөрәббия** مربيه *сф.* Мөрәбби-нең *мнс.* — *жен.* от мөрәбби.

**Мөрәббәгъ** مربع *сф.* Квадрат, дүрт почмаклы, дүрт кырлы. — *пр. с.* Квадратный; четырёхугольный; четырёхгранный.

**Мөрәккәб** مركب *сф.* 1) Кушылган, бергә җыелган, берничә нәрсәдән оешкан. 2) Катлаулы; кушма. *Исме гадәд никадәр мөрәккәб булса да, әүвәле олуг гадәдләр ба тәртиб кечедән кече вәзгы кылыныр.* (К. Нас.) — *пр. с.* 1) Составленный, состоящий (из чего-либо). 2) Составной, сложный.

**Мөрәккәбат** مركبات *ис.* Мөрәккәбнең *к.* — *сущ. мн.* от мөрәккәб.

**Мөрәкъкам** مرقم *сф.* Номерланган, номер сугылган. — *пр. с.* Занумерованный.

**Мөрәттиб** مرتب *сф.* 1) Тәртипкә куючы, рәткә салучы, тезүче. 2) Хәреф җыючы. *Машинистлар, мөрәттибләр дә бар шунда.* (Г. Тук.) — *пр. д.* 1) Приводящий в порядок, аккуратный. 2) Наборщик.

**Мөрәттәб** مرتب *сф.* Тәртипкә китерелгән, рәткә салынган, төзелгән. — *пр. с.* Приведённый в порядок, расположенный по порядку; упорядоченный.

**Мөрәххәс** مرخص *сф.* Рөхсәт ителгән. *Мәзахның мөрәххәс булмакы турында хәдис бар дип язадыр.* (К. Нас.) 2) Илче, вәкил. — *пр. с.* 1) Разрешённый. 2) Полномочный; уполномоченный.

**Мөрәүвиҗ** مروج *сф.* 1) Таратучы, үткәрүче, куәтләүче. 2) Үткәрүче (товарны). — *пр. д.* 1) Распространяющий; помогающий распространению. 2) Сбывающий (о товаре).

**Мөрәүвәт** مروت *ис.* 1) Егетлек, ирлек. 2) Кешелек, галиҗәнаплык. *Яралганмы бу яшьләр күңле әллә, мөрәүвәт маддәсе ягылыр-ягылмас.* (Г. Тук.) — *сущ.* 1) Доблесть, мужество. 2) Великодушие, благородство.

**Мөрәүвәтмәнд** مروتمند *гф. с.* Кешелекле, вөҗданлы, затлы. — *ар.-п. прил.* Великодушный, благородный.

**Мөрәҗәгать*** مراجعت *м. III.* 1) Берәүгә эндәшү, сүз кушу. 2) Кайту, борылу. *Гомәр Хәйям ватанына мөрәҗәгать әйләдектән соңра, гомерене мәй эчмәк вә мәгъшукалар лә сөхбәт итмәк вә шигырь сөйләмәк илә үткәрмештер.* (Ш. ж.) — *м. III.* 1) Обращение к кому-либо. 2) Возвращение.

**Мөрәҗҗәх** مرجح *сф.* Башкалардан артык күрелгән, өстен булган, алдарак тотылган. — *пр. с.* Предпочтительный, предпочтенный.

**Мөрүр** مرور *ис.* Үтү, узу; узып китү, үтеп китү. *Бир сөрүр мәсхүреңә, бер кәррә боннан ит мөрүр.* (Г. Тук.) — *сущ.* Прохождение.

**Мөсаб** مثاب *сф. дини* Әҗерен (хакын) алган кеше, савaплы булучы.
*пр. с. рел.* Вознаграждённый (богом) за добро.

**Мөсабәка** مسابقه *м. III.* Ярышу, узышу, конкурс. *Мөсабәка вакытында гакыл китәдер, — димешләр.* (К. Нас.)
*м. III.* Состязание, соревнование, конкурс.

**Мөсабәкать** مسابقت *м. III. кара:* мөсабәка.
*м. III. см.* Мөсабәка.

**Мөсабәрә** مصابره *м. III.* Сабыр итү, түзеп тору.
*м. III.* Терпение, терпеливость; выносливость.

**Мөсави** مساوى *сф.* Тигез, бәрабәр, бер дәрәҗәдә булган, бердәй. *Рас кәлгәндә, кәндесен Гали байга мөсави кеби тотар.* (М. Ак.)
*пр. д.* Равный, одинаковый.

**Мөсавәт** مساوت *м. м.* Тигезлек, бердәйлек. *Мөсавәт утыны яндыр...* (Г. Тук.)
*м. м.* Равенство, одинаковость.

**Мөсавәте хокук** مساوتحقوق *из.* Хокук тигезлеге.
*из.* Равноправие.

**Мөсагадә** مساعده *м. III.* 1) Мөмкинлек бирү; булышу, ярдәм итү. *Аның өчен әхвал һәм шәраит мөсагадә итәме?* (Ш. Кам.) 2) Үзара ярдәм итешү.
*м. III.* 1) Содействие, способствование, помощь; поддержка. 2) Взаимопомощь.

**Мөсагыйд** مساعد *сф.* Мөмкинлек бирүче, ирек бирүче; рөхсәт (ярдәм) итүче. *Вакыт вә әхваль мөсагыйд улмаеп.* (М. Ак.)
*пр. д.* 1) Содействующий, благоприятный; разрешающий, помогающий. 2) Помощник.

**Мөсадиф** مصادف *сф.* Очрашучы, туры килүче, юлыгучы.
*пр. д.* 1) Встречающийся. 2) Совпадающий.

**Мөсадәмә** مصادمه *м. III.* 1) Бәрелешү, кара-каршы килеп сугышу. 2) Каршылык. *Эшчеләр арасында мәшрутият вә хөррият хәрәкәтләре арту илә хөкүмәтнең дахили мөсадәмәләре вакыйг булып...* (Ш. ж.) 3) Бәрү, сугу.
*м. III.* 1) Столкновение, стычка, конфликт. 2) Противоречие. 3) Удар.

**Мөсадәкат** مصادقت *м. III.* Эчкерсез дуслык, чын дуслык.
*м. III.* Искренность, искренняя дружба.

**Мөсадәрә** مصادره *м. III.* 1) Кулга төшерү, көчләп алу. 2) Конфискацияләү, хөкүмәт кулына алу.
*м. III.* 1) Отобрание. 2) Конфискация.

**Мөсадәфә** مصادفه *м. III.* 1) Очрашу, туры килешү, юлыгышу. 2) Очрак, туры килү.
*м. III.* 1) Случайная встреча. 2) Случай, совпадение.

**Мөсайкал** مصيقل *сф.* Ялтыратылган, шомартылган, ялтырап торган. *Арслан-*
*пр. с.* Полированный, шлифованный.

*ның атарга корылмыш җәя кебек кәкре кашлары уртасында мөсайкал кылыч шикелле уртача һәм тигез борыны бар...* (К. Нас.)

**Мөсалиф** مسالف *сф.* Юлдаш. — *пр. д.* Спутник, идущий вместе.

**Мөсаләмә** مسالمه *м. III.* Татулык, гомуми тынычлык, барлык халыкның тыныч һәм сәламәт яшәве. *Ватандашларымыз мөсаләмәт хакында теләш итдекләре хәлдә.* (Ш. ж.) — *м. III.* Мир, умиротворение.

**Мөсаләфәт** مسالفه *м. III.* Юлдаш булу. — *м. III.* Сопутствие.

**Мөсамәрә** مسامره *м. III.* Кич белән сөйләшеп утыру. *Ашап-эчеп тәмам булганнан соң да мөсамәрә кылып озак утырдылар.* (К. Нас.) — *м. III.* Ночная беседа.

**Мөсамәхә** مسامحه *м. III.* 1) Игътибарсызлык; йомшаклык күрсәтү. 2) Әһәмият бирмәү, күрмәү; салкын карау. — *м. III.* 1) Небрежность, халатное отношение. 2) Пренебрежение, равнодушие.

**Мөсарәгать** مسارعت *м. III.* Ашыгу, ашыгычлык. — *м. III.* Поспешность, спешка.

**Мөсафир*** مسافر *сф.* 1) Юлаучы, юлчы. 2) Узгынчы. — *пр. д.* 1) Путник. 2) Прохожий; проезжающий.

**Мөсафирханә** مسافرخانه *ис.* Гостиница, кунак йорты. — *сущ.* Гостиница, заезжий (постоялый) двор.

**Мөсафәрәт** مسافرت *м. III.* Юл йөрү, юлчылык, мөсафирлек. — *м. III.* Путешествие, странствование.

**Мөсаһәлә** مساهله *м. III.* Йомшаклык күрсәтү, игътибар итмәү, әһәмият бирмәү, җиңелгә санау. *Син өшегәнсең диде һәм начар бер мөсаһәләсе өчен гафу үтенгән тавыш белән яңадан кушты.* (Г. Ибр.) — *м. III.* Снисходительность, мягкость; пренебрежение.

**Мөсбит** مثبت *сф.* Исбат итүче, дөреслеген дәлил белән күрсәтеп бирүче. — *пр. д.* 1) Утверждающий. 2) Подтверждающий, удостоверяющий, доказывающий.

**Мөсбәт** مثبت *сф.* 1) Исбат ителгән, дөреслеге дәлил белән күрсәтелгән. *Сүземезнең хаклыгы мөсбәт улыр.* (З. Биг.) 2) Уңай. — *пр. с.* 1) Подтверждённый, доказанный, удостоверенный. 2) Положительный.

**Мөсгыйр** مسعر *сф.* Бәяләүче, бәя куючы, бәя билгеләүче. *Мөсгыйр вә* — *пр. д.* 1) Определяющий стоимость чего-либо. 2) Оценщик.

*нәрсәгә нәрех тәкъдир итүче улдыр.* (К. Нас.)

**Мөселман*** مسلمان *гф. ис.* Ислам динендәге кеше. — *ар.-п. сущ.* Мусульманин, магометанин.

**Мөсин** مسن *ис.* Карт, картайган, күп яшәгән. — *сущ.* Пожилой, старый; преклонных лет.

**Мөскир** مسكر *сф.* Исертүче, исертә торган, исерткеч. — *пр. д.* Пьянящий, опьяняющий.

**Мөскират** مسكرات *ис.* Мөскир- нең *к.* *Аз-аз мөскират улан шәйләргә боермая башлады.* (З. Биһ.) — *сущ. мн.* от мөскир.

**Мөскит** مسكت *сф.* Туктарга мәҗбүр итүче, сүздән туктатучы. *Әяс бин Мөгавия мөскит вә гаҗиб җаваплары илә мәгъруфдыр.* (Ш. ж.) — *пр. д.* 1) Заставляющий умолкнуть. 2) Не допускающий возражений.

**Мөскыйль** مثقل *сф.* Авырлык бирүче, авырлык китерүче. — *пр. д.* Отягощающий, обременяющий (чем-либо).

**Мөслим** مسلم *ис.* Ислам динендә булган кеше, мөселман. — *сущ.* Мусульманин.

**Мөслимә** مسلمه *ис.* Мөслим-нең *мнс.* — *жен.* от мөслим.

**Мөслимин** مسلمين *ис.* Мөслим- нең *к.* *Гомумән мөслимини һәр заман мәэмүре вөҗдан ит.* (Г. Тук.) — *сущ. мн.* от мөслим.

**Мөсмир** مثمر *сф.* 1) Җимеш бирүче. 2) Нәтиҗәле, җимешле. 3) Файдалы. — *пр. д.* 1) Плодородный, плодотворный. 2) Продуктивный. 3) Выгодный, доходный, полезный.

**Мөснәд** مسند *сф.* 1) Терәк. 2) *грам.* Хәбәр. — *пр. с.* 1) То, на что опираются. 2) *грам.* Сказуемое.

**Мөснәд иләйһи** مسنداليه *гыйб. грам.* Ия. *Бер кәлимәсе мөснәд вә икенчесе мөснәд иләйһи аталыр.* (К. Нас.) — *фр. грам.* Подлежащее.

**Мөсриф** مسرف *сф.* Әрәм-шәрәм итүче, исраф итүче. — *пр. д.* Расточительный.

**Мөстәбан** مستبان *сф.* 1) Ачык күренгән, күренеп тора торган. 2) Ачык аңланган. — *пр. с.* 1) Различимый, видимый. 2) Выясненный, ясный.

**Мөстәбид** مستبد *сф.* 1) Үзе теләгәнчә эш йөртүче. 2) Изүче, деспот. *Хәнәфиел Бакиригә ни дияргә белмәдем, чөнки анда мәгънәсезлек, мөстәбидлек күрмәдем.* (Ш. Баб.) — *пр. д.* 1) Действующий самоуправно, по своему произволу. 2) Тиран, деспот.

**Мөстәбиданә** مستبدانه *ф. р.* Изүчеләрчә, деспотларча.
*п. н.* Самовластно, деспотически.

**Мөстәви** مستوی *сф.* Тигез, бердәй, бер тигезлектәге, яссы.
*пр. д.* Ровный, плоский.

**Мәстәган** مستعان *сф.* Ярдәм соралган, ярдәм көтелгән зат.
*пр. с.* Привлекаемый на помощь.

**Мөстәгар** مستعار *сф.* 1) Кушамат, ялган исем. 2) Вакытлыча алынган, кире кайтарып бирергә тиешле нәрсә; әҗәт, бурыч. *Бер көн килер, ия чыгар, бу хәлең мөстәгар әле.* (Г. Тук.)
*пр. с.* 1) Псевдоним; прозвище. 2) Взятый на время, заимствованный. 3) Заём.

**Мөстәгъмир** مستعمر *сф.* Колонизатор; көчеп утырып җир үзләштерүче.
*пр. д.* Колонизатор, колонист.

**Мөстәгъмәл** مستعمل *сф.* Тотылган, йөртелгән, кулланылган; тотыла торган, кулланыла торган. *Русчада мөстәгъмәл сүзләр...* (К. Нас.)
*пр. с.* Бывший в употреблении; употребляемый; общеупотребительный.

**Мөстәгъмәрат** مستعمرات *ис.* Мөстәгъмәрә -нең *к.* *Юнан мөстәгъмәратыннан алдыклары җәһәтилә.* (Х. Чис.)
*сущ. мн.* от мөстәгъмәрә.

**Мөстәгъмәрә** مستعمره *ис.* 1) Колония. 2) Корылыш, төзелеш салынган җир. *Юнаннар Италия, Анатули сахилләренә китеп мөстәгъмәрәләр тәэсис итмешләр.* (Х. Чис.)
*сущ.* 1) Колония. 2) Местность с постройками, сооружениями.

**Мөстәгъни** مستغنی *сф.* Моңсыз, хаҗәтсез, кешегә хаҗәте төшмәүче, ялынычы юк. *Кеше даимән гайренең малыннан мөстәгъни булмак тиеш.* (К. Нас.)
*пр. д.* Не нуждающийся, не ищущий помощи.

**Мөстәгъръкъ** مستغرق *сф.* Баткан, чумган, күмелгән. *Кирәкми, балаларым һәм җәмәгатем төрле нигъмәткә мөстәгъръкъ.* (К. Нас.)
*пр. с.* Утонувший, погрузившийся (в воду и т. п.)

**Мөстәгъҗәл** مستعجل *сф.* Ашыктырылган, ашыгыч.
*пр. с.* Спешный, неотложный.

**Мәстәгъҗәлән** مستعجلاً *р.* Ашыгыч рәвештә.
*н.* Поспешно, наспех.

**Мөстәгыйд** مستعد *сф.* 1) Сәләтле, кулыннан килерлек, булдыклы. *Артык тырышлыгы, мөстәгыйдлеге аркасында остазының дәлаләте белән Камалов аңа ярдәм бирәчәк булды.* (Г. Ибр.) 2) Әзер булып торучы.
*пр. д.* 1) Способный, деятельный. 2) Подготовившийся, готовый.

**Мөстәгыйн** مستعین *сф.* Ярдәм теләүче, булышлык сораучы.
*пр. д.* Ищущий помощи, поддержки.

**Мөстәгыйнән** مستعينا *р.* Ярдәм (булышлык) сораган хәлдә. — *н.* Прося о помощи.

**Мөстәдам** مستدام *сф.* Дәвамлы, мәңгелек. — *пр. с.* Длительный, долгий, вечный.

**Мәстәдга** مستدعا، مستدعى *сф.* Соралган, таләп ителгән нәрсә. — *пр. с.* Предмет просьбы.

**Мөстәдгый** مستدعى *сф.* Сораучы, таләп итүче. — *пр. д.* Просящий, умоляющий; требующий.

**Мөстәдгыят** مستدعيات *ис.* Мөстәдганың *к.* — *сущ. мн.* от мөстәдга.

**Мәстәдиль** مستدل *сф.* Дәлил китерүче, дәлилләүче, исбатлаучы. — *пр. д.* Доказывающий, утверждающий.

**Мөстәдир** مستدير *сф.* Түгәрәк, түгәрәкләнгән. *Бер хавызе мөстәдир, буе, аркылысы унбиш зираг иде.* (К. Нас.) — *пр. д.* Круглый, сферический, шарообразный.

**Мөстәдләл** مستدلل *сф.* Дәлил белән ныгытылган, дәлилләнгән. — *пр. с.* Доказанный; обоснованный.

**Мөстәзраф** مستظرف *сф.* Якында үткән заман (вакыт). — *пр. с.* Недавно прошедшее время.

**Мөстәзыйллә** مستظله *сф.* Күләгәләнгән, күләгә астына кергән. — *пр. д.* Осеняемый; находящийся в тени.

**Мөстәкар** مستقر *ис.* Урынлашкан, җирләшкән урын, даими тору урыны. — *сущ.* Постоянное местопребывание; местожительство.

**Мөстәкриһ** مستكره *сф.* Җирәнүче, начар күрүче. — *пр. д.* Питающий отвращение; избегающий.

**Мөстәкрәһ** مستكره *сф.* Җирәнеч, начар күрелгән; күңел яратмаган. *Аю җиләгенең исе хуш, әмма тагмы мөстәкрәһ була.* (К. Нас.) — *пр. с.* Неприятный, противный, отвратительный.

**Мөстәкфи** مستكفى *сф.* Җитәрлек кадәр генә таләп итүче, канәгатьләнүче. — *пр. д.* Находящий достаточным, удовлетворяющийся.

**Мөстәкъбил** مستقبل *сф.* Каршы алучы; каршылаучы. — *пр. д.* Принимающий; встречающий (гостей).

**Мөстәкъбәл** مستقبل *сф.* 1) Киләчәк, алдагы, алда булачак. *Ул кадәресе мөстәкъбәлдә күреләчәк.* (К. Нас.) 2) *грам.* Киләчәк заман. — *пр. с.* 1) Будущий. 2) *грам.* Будущее время.

**Мөстәкъриз** مستقرض *сф.* Бурычка сораучы; әҗәткә алучы. — *пр. д.* Просящий взаймы, берущий заём.

**Мөстәкърәз** مستقرض *сф.* Бурычка бирелгән, әҗәт ителгән. — *пр. с.* Отданный взаймы.

**Мөстәкыйль*** مستقل *сф.* Бәйсез, башкага иярмәүче, буйсынмаучы, үзлегеннән эш итүче. — *пр. д.* Самостоятельный, независимый.

**Мөстәкыйлән** مستقلاً *р.* Бәйсез рәвештә, башкага иярмичә. — *н.* Независимо, самостоятельно.

**Мөстәкыйм** مستقيم *сф.* 1) Туры, төз. 2) Дөрес, чын. *Һәвәскә ияргән кеше тарикый мөстәкыймнән чыгар.* (К. Нас.) 3) Бер җирдә торучы. — *пр. д.* 1) Прямой, ровный, непосредственный. 2) Истинный; верный. 3) Имеющий постоянное местожительство.

**Мөстәкыйр** مستقر *сф.* Урнашкан, җирләшкән, хәрәкәтсез бер урында торучы. — *пр. д.* Утвердившийся, укрепившийся, упроченный, твёрдый.

**Мөстәлзим** مستلزم *сф.* 1. Сәбәпче, китереп чыгаручы, тудыручы. *Низаг вә тарткалашу дошманлыкны мөстәлзимдер.* (К. Нас.) 2. Сәбәп. — *пр. д.* 1. Обуславливающий; влекущий за собой (какое-либо последствие). 2. Причина.

**Мөстәмигъ** مستمع *сф.* Тыңлаучы, колак салучы. — *пр. д.* Слушающий, слушатель.

**Мөстәмигыйн** مستمعين *ис.* Мөстәмигънең *к.* *Хикәяләр китереп мөстәмигыйннәрнең күңелен хуш кылырлар.* (К. Нас.) — *сущ. мн.* от мөстәмигъ.

**Мөстәмир** مستمر *сф.* Озак вакытлар дәвам итүче, дәвамлы. — *пр. д.* Беспрерывный, постоянный; продолжительный.

**Мөстәмләкят** مستملكات *ис.* Мөстәмләкә-нең *к.* — *сущ. мн.* от мөстәмләкә.

**Мөстәмләкә** مستملكه *ис.* Колония. — *сущ.* Колония.

**Мөстәнбәтъ** مستنبط *сф.* Аңлашылган; бер сүз яки бер мәгънә чыгарылган. *Бу мәгълүмат рус, алман вә маҗар голәмасенең тәдкыйкаты нәтиҗәсеннән мө тәнбәтътыр.* (Ш. ж.) — *пр. с.* Извлечённый как вывод; постигнутый, понятый.

**Мөстәнид** مستند *сф.* Таянычлы, таянучы. — *пр. д.* Основывающийся, опирающийся (на что-либо).

**Мөстәнкәр** مستنكر *сф.* Инкарь ителгән, танылмаган. — *пр. с.* Отрицаемый, непризнаваемый.

**Мөстәнәд** مستند *сф.* 1. Таянган, нигезләнгән. *Сонуф мөмтазәнең куәт вә кабилияткә мөстәнәд имтиязлары балаларына күчеп.* (Җ. Вәл.) 2. Нигез. — *пр. с.* 1. Основанный, обоснованный. 2. Основание, базис.

**Мөстәрих** مستریح *сф.* Ял итүче, рәхәт табучы; тынычь — *пр. д.* Отдыхающий, находящийся в покое; спокойный.

**Мөстәриханә** مستریحانه *р.* Рәхәтләнеп, тынычлап. *Мән урада* (анда) *мөстәриханә яшәр вә калан гомеремне мәгъшук илә мәйгә сарыф идәр идем.* (Ш. ж.) — *н.* Спокойно, без волнений, тихо.

**Мөстәсна** مستثنا،مستثنی *сф.* 1) Башкалардан аерып алынган. 2) Аерым, чыгарма. *Ул бәлки нәселенең мөстәснасы булыр дип, уйлап йөриләр иде.* (Г. Ибр.) — *пр. с.* 1) Исключительный; из ряда вон выходящий. 2) Исключение.

**Мөстәтаб** مستطاب *сф.* 1) Яхшы күрелгән, кадерле, күңелгә ятышлы. 2) Әйбәт, шәп. — *пр. с.* 1) Досточтимый, высокочтимый. 2) Хороший, прекрасный; превосходный.

**Мөстәтыйл** مستطیل *сф.* 1) Озынча. 2) *Мат.* Туры почмаклык. — *пр. д.* 1) Продолговатый, удлинённый. 2) *Мат.* Прямоугольник.

**Мөстәтәр** مستتر *сф.* 1) Өртелгән, төрелгән, сакланган. 2) Яшерелгән. *...мөстәтәр булган мәелне аңлатып, ризалык бирде.* (К. Нас.) — *пр. с.* 1) Закутанный, покрытый. 2) Закрытый, скрытый.

**Мөстәфад** مستفاد *сф.* 1) Башка чыганаклардан алынган (җыентык). 2) Файдаланган. — *пр. с.* 1) Извлечённый, вынесенный (из содержания какой-либо бумаги). 2) Выведенный; использованный (из чего-либо).

**Мөстәфид** مستفید *сф.* Файдаланучы, файда күрүче. *Изахатләреңне укып бик мәмнүн вә-мөстәфид улдым.* (Ш. ж.) — *пр. д.* Получающий пользу, извлекающий выгоду.

**Мөстәфһем** مستفهم *сф.* Аңлашылган. — *пр. с.* Понятый.

**Мөстәхас** مستحاث *сф.* Каткан, ташка әйләнгән (нәрсәләр). — *пр. с.* Окаменелый.

**Мөстәхбәр** مستخبر *сф.* Хәбәр алынган, ишетелгән, хәбәр ителгән. — *пр. с.* Услышанный; сообщённый.

**Мөстәхдәм** مستخدم *сф.* 1) Хезмәткә алынган. 2) Хезмәткәр. — *пр. с.* 1) Принятый на службу. 2) Служащий.

**Мөстәхикъ** مستحق *сф.* 1) Хаклы, лаеклы; хакы бар. *Вә сез әнгам дәгелсез буйлә хаксыз, хокука мөстәхикъ, бәлки әхаксез.* (Г. Тук.) 2) Мохтаҗ. — *пр. д.* 1) Заслуживающий; достойный. 2) Нуждающийся.

**Мөстәхил** مستحیل *сф.* Мөмкин булмаслык, мөмкин булмаган. — *пр. д.* Невозможный, невероятный.

**Мөстәхкәм** مستحکم *сф.* Ныгытылган; крепость хәленә китерелгән; нык.

*пр. с.* Укреплённый, утверждённый; крепкий.

**Мөстә̇хрәҗ** مستخرج *сф.* Чыгарылган, чыгарып алынган.

*пр. с.* Извлечённый, полученный.

**Мөстәхсән** مستحسن *сф.* Һәркем яраткан, күркәм күрелгән, мактаулы. *Бәдәнне пак йөртмәкне гакыл мөстәхсән күрде.* (К. Нас.)

*пр. с.* Одобренный; заслуживающий похвалы; похвальный.

**Мөстәхәб** مستحب *сф.* Гүзәл, яхшы күрелә торган эш (дин күзлегеннән: эшләсә яхшы, эшләмәсә зарары-гөнаһсы булмаган эш).

*пр. с.* Любимый, излюбленный, нравящийся, одобряемый.

**Мөстәхҗәр** مستحجر *сф.* Ташка әйләнгән, ташка әверелгән.

*пр. с.* Окаменелый.

**Мөстәшар** مستشار *ис.* Киңәшче, киңәш белән ярдәм итүче.

*сущ.* Советник, консультант.

**Мөстәэкил** مستا کل *сф.* Фәкыйрьләр хакын ашаучы.

*пр. д. букв.* Поедающий долю бедняков.

**Мөстәэмин** مستأمن *сф.* 1) Ышанучы, ышанып тапшырылучы. 2) Әманлык-иминлек сораучы.

*пр. д.* 1) Доверяющий. 2) Ищущий спасения. 3) Просящий о пощаде.

**Мөстәэмән** مستأمن *сф.* 1) Имин булган, берәү тарафыннан яклана торган. 2) Ышанычлы дип санала торган.

*пр. с.* 1) Живущий под покровительством, под защитой. 2) Считаемый надёжным, верным; доверяемый.

**Мөстәэнис** مستأنس *сф.* Ияләшкән, кыргыйлыгы беткән, өйрәнгән.

*пр. д.* Привыкший к людям, прирученный.

**Мөстәэҗир** مستأجر *сф.* Арендага алучы.

*пр. д.* Арендатор, съёмщик, наниматель.

**Мөстәэһил** مستأهل *сф.* Лаек булу, яраклы булу.

*пр. д.* Заслуживающий, достойный.

**Мөстәүли** مستولی *сф.* Буйсындырып хуҗа булучы, яулап алучы.

*пр. д.* Покоряющий, овладевающий; завоёвывающий.

**Мөстәүҗиб** مستوجب *сф.* Лаек, кулай. *Берәүнең изгелеген инкарь кылса, зарарны мөстәүҗиб булыр.* (К. Нас.)

*пр. д.* Заслуживающий (чего-либо); достойный; подлежащий (чему-либо).

**Мөстәҗаб** مستجاب *сф.* Теләгәне кабул булган, кабул ителгән, соравы канәгатьләндерелгән. *Бу эш шуйлә гаҗәп булды, догасы мөстәҗаб булды.* (Г. Кан.)

*пр. с.* Удовлетворённый; получивший положительный ответ на свою просьбу, мольбу.

**Мөстәҗиб** مستجب *сф.* Сорауга (сорагангаʒ җавап бирүче, теләкне кабул итүче, үтәүче. *Әмереңә сәмган вә таган мөстәҗибмен мин гариб.* (С. Рәм.)

*пр. д.* Удовлетворяющий просьбу, отвечающий на вопросы; исполняющий (просьбу).

**Мөстәһзи** مستهزى *сф.* Көлүче, мыскыллаучы, мәзәкләүче.

*пр. д.* 1. Насмехающийся, насмешливый. 2. Насмешник.

**Мөстәһзиянә** مستهزيانه *р.* Көлеп, мыскыллап, мыскыл итеп.

*н.* Насмешливо; иронически.

**Мөстәһлик** مستهلك *сф.* Һәлак итүче.

*пр. д.* Истребляющий; уничтожающий, губительный; гибельный.

**Мөстәһтик** مستهتك *сф.* Әдәпсез, оятсыз.

*пр. д.* Бессовестный, бесстыжий.

**Мәстәһҗән** مستهجن *сф.* Начар, әдәпсез, кабахәт саналган эшләр, сүзләр.

*пр. с.* Предосудительный; позорный; неприличный; дурные поступки, слова.

**Мөсәббиб** مسبب *сф.* Сәбәпче, сәбәп булган нәрсә. *Маһруйның хәмеленнән мөсәббибе улан Галиевә магада кем хәбәрдар.* (З. Биг.)

*пр. д.* Обуславливающий, причиняющий, вызывающий (что-либо).

**Мөсәббәб** مسبب *сф.* Сәбәпләнгән, сәбәп белән бар ителгән, сәбәп белән булган. *Хикмәт мөсәббәбнең сәбәпкә иртибатындадыр.* (К. Нас.)

*пр. с.* Обусловленный, причинённый, имеющий своей причиной (что-либо).

**Мөсәййәб I** مثيب *ис.* Иреннән аерылган хатын.

*сущ.* Разведённая женщина.

**Мөсәййәб II** مسيب *сф.* Дикъкатьсез, җилбәзәк.

*пр. с.* Невнимательный, небрежный; ветреный.

**Мөсәккин** مسكن *сф.* Тынычландыручы, йомшартучы. *Андый да ула ны мөсәккин һәм тәсмия кылыныр.* (К. Нас.)

*пр. д.* Успокаивающий, смягчающий.

**Мөсәллитъ** مسلط *сф.* Ирекле итүче, власть бирүче, ирек куючы (берәүне икенче берәү өстеннән үзе теләгәнне эшләргә).

*пр. д.* Дающий волю, предоставляющий власть (над кем-либо).

**Мөсәлләм** مسلم *сф.* 1) Күндерелгән; канәгатьләндерелгән, инкарь ителми торган. 2) Риза, канәгать. *Нигъмәтулла әфәнде Шубинның сүзләренә мөсәлләм улды.* (З. Биг.) 3) Тапшырылган.

*пр. с.* 1) Принятый, неотвергнутый. 2) Согласный, довольный. 3) Врученный.

**Мөсәлләс** مثلث *сф.* 1) *мат.* Өчпочмак. 2) Өч почмаклы, өч кырлы, өчтән торган. 3) Әче бал, брага.

*пр. с.* 1) *мат.* Треугольник. 2) Утроенный, тройной, тройственный. 3) Треугольный. 4) Брага.

**Мөсәлләс каимеззавия** مثلث‌قائم‌الزاويه *гыйб.* Туры почмаклы өчпочмак. — *фр.* Прямоугольный треугольник.

**Мөсәлләс мөтәсавиеззавия** مثلث‌متساوى‌الزاويه *гыйб.* Өч кыры да тигез өчпочмак. — *фр.* Равнобедренный треугольник.

**Мөсәлләс мөнфәрижеззавия** مثلث‌منفرج‌الزاويه *гыйб.* Киң почмаклы өчпочмак. — *фр.* Тупоугольный треугольник.

**Мөсәлләсат** مثلثات *ис.* Тригонометрия. — *сущ.* Тригонометрия.

**Мөсәлләсат көрәвия** مثلثات كرويه *гыйб.* Сферик өчпочмаклар тригонометриясе. — *фр.* Сферическая тригонометрия.

**Мөсәлләтъ** مسلط *сф.* Жиңеп үз кулы астына алган, (берәүнең өстеннән) үзе теләгәнне эшләргә ирекле булган. *Мөсәлләтъ улдылар бонлар, белмим нә мәгънәдән.* (Г. Тук). — *пр. с.* Господствующий, овладевший, владеющий; самовластный.

**Мөсәлләх** مسلح *сф.* Кораллы, кораллandырылган. — *пр. с.* Вооружившийся, вооружённый.

**Мөсәлсәл** مسلسل *сф.* Чылбыр кебек бер-беренә бәйләнгән, тезелгән, тоташ. — *пр. с.* Образующий цепь; последовательный, преемственный, беспрерывный.

**Мөсәмма** مسمى، مسما *сф.* Аталган, исем бирелгән, исемләнгән. *Дус кемдер дип сорагач, мөсәммасе юк бер исемдер дип җавап бирмештер.* (К. Нас.) — *пр. с.* Названный, именуемый.

**Мөсәммән** مثمن *сф.* 1. 1) *мат.* Сигез кырлы; сигез почмаклы. 2) *шигъ.* Сигез стопадан торган. 2. Акчалы, акча һәм башка кыйммәтләр иясе. — *пр. с.* 1. 1) *мат.* Восьмигранный; восьмиугольный. 2) *поэт.* Состоящий из восьми стоп. 2. Имеющий деньги или другие ценности.

**Мөсәннә** مثنى *сф.* 1) Икеле, икешәрле, ике катлы. 2) *грам.* Ике ноктalы хәреф. 3) *грам.* Икелек саны. — *пр. с.* 1) Двойной, двукратный, удвоенный. 2) *грам.* Буква с двумя точками. 3) *грам.* Двойственное число.

**Мөсәттар** مسطر *сф.* Язылган; юл-юл итеп сызылган, сызыклы (кәгазь). — *пр. с.* Написанный; разлинованный.

**Мөсәттах** مسطح *сф.* 1) Тигез, яссы. 2) Йөз, өслек. — *пр. с.* 1) Ровный, плоский. 2) Площадь, поверхность.

**Мөсәххәр I** مسحر *сф.* Сихерләнгән. *Һәр кешене мөсәххәр итә торган күзләреннән...* (М. Гаф.) — *пр. с.* Заколдованный, завороженный.

**Мөсәххәр II** مسخر *сф.* Буйсындырылган, яулап алынган; мәҗбүр иттерелгән. — *пр. с.* Покорённый, завоеванный; принуждённый (что-либо делать).

**Мөсәүвид** مسود *сф.* Китапның караламасын язучы. — *пр. д.* Пишущий начерно.

**Мөсәүвәд** مسود *сф.* Каралама, акка күчерелмәгән (язу). *Ун җилддән гыйбарәт лөгать китабы мөсәүвәд хәлендә дөньядан югалмыштыр.* (Ш. ж.) — *пр. с.* Черновик.

**Мөсәҗҗәгъ** مسجع *сф. шигъ.* Рифмалаштырылган, рифмалы. *Мөсәҗҗәгь нәсер* – рифмалы чәчмә. — *пр. с. поэт.* Рифмованный.

**Мөсһил** مسهل *сф.* Эч җибәрүче, эчне йомшартучы. *Тәрәтне сыеклый торган дару мөсһил дип аталадыр.* (К. Нас.) — *пр. д.* Слабительное.

**Мөсһилат** مسهلات *ис.* Мөсһилнең *к.* — *сущ. мн.* от мөсһил.

**Мөтабәгать** متابعت *м. III.* Иярү, артыннан бару, артыннан китү; буйсыну. *Мөтабәгать өлфәтне муҗибтер.* (К. Нас.) — *м. III.* Следование (за кем-либо), приверженность; подчинение; послушание.

**Мөтавәлә** مطاوله *м. III.* Озайту, срокны сузу; кичектерү. — *м. III.* Оттягивание, откладывание; замедление, задержка.

**Мөтайиб** مطيب *сф.* Хушбуйланган, хуш исләр белән исләнгән. — *пр. д.* Надушенный (духами).

**Мөтарик** متارك *сф.* Калдырып китүче, ташлаучы. — *пр. д.* Оставляющий, покидающий.

**Мөтарәкә** متاركه *м. III.* 1) Калдыру, туктату. 2) Вакытлы килешү (сугышучы якларның). — *м. III.* 1) Оставление, прекращение. 2) Перемирие.

**Мөтаһир** مطاهر *сф.* Тазартучы, пакьләүче, чистартучы, арулаучы. — *пр. д.* Очищающий, чистящий.

**Мөтаһһәр** مطهر *сф.* Пакьләнгән, тазартылган, чистартылган, аруланган. — *пр. с.* Очищенный, чистый.

**Мөтга** متعه *ис.* 1) Вакытлыча никах, вакытлыча иргә чыгып тору (шигаларда). 2) Ләззәт бирә торган нәрсә. — *сущ.* 1) Временный брак (у шиитов). 2) Предмет наслаждения.

**Мөтим** متمم *сф.* Бетерүче, тәмам итүче, төгәлләүче. — *пр. д.* Заканчивающий, завершающий.

**Мөтлиф** متلف *сф.* 1) Юк итүче, һәлак итүче. 1). Бетерүче, исраф итүче, әрәм-шәрәм итүче. — *пр. д.* 1) Губитель, истребитель. 2) Расточитель, мот.

**Мөтталигъ** مطلع *сф.* Ирешкән, белгән, аңлап җиткергән. *Бу фәннәрнең голямасы белән мөзакәрә кылышып, тәфсыйлатына мөтталигъ булмак лязимдер.* (К. Нас.) — *пр. д.* Осведомлённый, знающий.

**Мөттасил** متصل *сф.* 1. Тоташ, кушылган. *Нитәк ки адәмнең әгъзасы берберенә мөттасилдыр.* (К. Нас.) 2. Өзлексез, туктаусыз. — *пр. д.* 1. Соединённый; смежный, непрерывный. 2. Постоянно.

**Мөттәкый** متقی *сф.* Динче, тәкъва. *Ул мөттәкый кеше булырга кирәк.* (З. Биг.) — *пр. д.* Богобоязненный, благочестивый, набожный.

**Мөттәкыйн** متقین *сф.* Шиксез, ачык белүче, бер әйбернең ничек булуын тулысынча анык белүче. — *пр. д.* Без сомнения, достоверно, в совершенстве знающий что-либо.

**Мөттәкыя** متقیه *сф.* Мөттәкый-ның *мнс. Бик суфия вә мөттәкыя, шуның белән бергә авылда бердәнбер язу танучы хатын иде.* (Г. Ибр.) — *жен.* от мөттәкый.

**Мөттәсигъ** متسع *сф.* Киңәйгән, таралган. — *пр. д.* Распространённый, расширенный, обширный.

**Мөттәсим** متسم *сф.* Башкалардан бер билге белән аерылган, аеру билгесе булган. — *пр. д.* Отличённый; имеющий опознавательный знак.

**Мөттәсыйф** متصف *сф.* Сыйфатланган, берәр сыйфатка ия булган. *Гыйлем белән мөттәсыйф адәмнең хәбәре инкарь кылынмас.* (К. Нас.) — *пр. д.* Охарактеризованный; одарённый (каким-либо качеством).

**Мөттәсыйфә** متصفه *ис.* Мөттәсыйф-ның *мнс. Анам саранлык белән мөттәсыйфә булганлыктан...* (К. Нас.) — *жен.* от мөттәсыйф.

**Мөттәхид** متحد *сф.* 1) Берләшкән. 2) Бер фикердә булган. — *пр. д.* 1) Соединённый, объединённый. 2) Согласный, единодушный.

**Мөттәхидән** متحداً *р.* Берләшеп, бергәләшеп, берлектә, бердәм. — *н.* Единодушно, согласно, совместно, сообща.

**Мөттәхәз** متخذ *сф.* Алынган, кабул ителгән, кулга кергән. — *пр. с.* Взятый, принятый, полученный.

**Мөттәфикан** متفقا *р.* Бергәләп, бергә кушылып, бергә көч куеп. — *н.* Совместно, заодно, сообща, соединёнными усилиями.

**Мөттәфикъ** متفق *сф.* 1) Килешүче, берләшкән, фикердә берләшкән. 2) Союздаш. *Мөттәфикъ безнең мәче тик күзләрен йөртеп кала.* (Г. Тук.) — *пр. д.* 1) Совпадающий; согласный; сходный, одинаковый. 2) Союзный.

**Мөттәһим** متهم *сф.* 1) Гаепле дип санаучы, гаеплелектә шикләнүче. 2) Гаепләүче. — *пр. д.* 1) Подозревающий; обвиняющий. 2) Обвинитель, истец.

**Мөттәһәм** متهم *сф.* 1) Яла ягылган. 2) Гаепле дип саналган, шикләнелгән. *Мөдәррис әфәнде мөттәһәмнең үзен чакыртты.* (Г. Ибр.) — *пр. с.* 1) Оклеветанный. 2) Обвиняемый, подозреваемый.

**Мөтәбагыйд** متباعد *сф.* Ераклашучы, бер-береннән ерак торган, аерым торган. — *пр. д.* 1) Удалившийся, отдалившийся. 2) Отдалённый, дальний.

**Мөтәбагыйз** متباغض *сф.* Кара-каршы ачуланышучы, дошманлашучы. — *пр. д.* Ругающийся; чувствующий взаимную неприязнь.

**Мөтәбадил** متبادل 1) Алмашучы, чиратлашучы. 2) Үзара, һәр ике яктан. — *пр. д.* 1) Переменный, поочерёдный. 2) Взаимный, обоюдный.

**Мөтәба́дир** متبادر *сф.* **1.** Ашыгучы, кабаланучы. **2.** Искә төшкән, хәтергә килгән. **3.** Кинәт килеп чыккан, аңсыздан барлыкка килгән. — *пр. д.* **1.** Торопящийся, спешащий. **2.** Вспомнившийся. **3.** Неожиданно появляющийся, возникающий.

**Мөтәбайин** متباين *сф.* 1) Аерылып торучы. 2) Капма-каршы, бер-беренә кире, каршылыклы. — *пр. д.* 1) Различающийся. 2) Противоречащий; контрастирующий; расходящийся.

**Мөтәбаки** متباکی *сф.* Үзен елаган итеп күрсәтүче, алдап елаучы. — *пр. д.* Притворно плачущий.

**Мөтәбакый** متباقی *сф.* 1) Артып калган, артык-портык, калдык 2) Мәңгелек булган, бетми торган. — *пр. д.* 1) Остающийся, оставшийся, остальной. 2) Вечный, бесконечный.

**Мөтәбасбыйс** متبصبص *сф.* Ялагайланучы, тәлинкә тотучы, юмакай. — *пр. д.* Подхалим, льстец.

**Мөтәбасбыйсанә** متبصبصانه *гф. р.* Койрык болгап, ялагайланып, тәлинкә тотып. — *ар.-п. н.* Льстиво, угодливо.

**Мөтәбассир** متبصر *сф.* 1) Алдан, ерактан күрүче, үтә күрүчән, зирәк, — *пр. д.* 1) Дальновидный, осмотрительный, про-

яхшы уйлаучы. 2) Эшнең алдын-артын карап (уйлап) эшләүче; зирәк кеше. — являющий рассудительность, благоразумие. 2) Прозорливый.

**Мөтәбассиранә** متبصرانه *гф. р.* Алдан күреп, үтә күреп. — *ар.-п. н.* Прозорливо, дальновидно, осмотрительно.

**Мөтәбашир** متباشر *сф.* Сөенеч (шатлыклы хәбәрләр) белән уртаклашучы. — *пр. д.* Обменивающийся радостными вестями.

**Мөтәбәддил** متبدل *сф.* 1) Икенче төрле хәлгә кергән, үзгәргән. 2) Алмаштырылган. — *пр. д.* 1) Изменившийся, переменившийся. 2) Заменённый.

**Мөтәбәйян** متبين *сф.* 1) Аңлашылган; ачык беленгән, бик билгеле булган. 2) Расланган, исбат ителгән. — *пр. с.* 1) Объяснившийся, обнаружившийся. 2) Доказанный.

**Мөтәбәссим** متبسم *сф.* Елмаючы, көлемсерәүче. — *пр. д.* Улыбающийся.

**Мөтәбәссиманә** متبسمانه *гф. р.* Елмайган кебек, елмаеп, көлемсерәп. — *ар.-п. н.* Улыбаясь, с улыбкой.

**Мөтәбәххир** متبحر *сф.* Дингез кебек тирән белемле, зур галим. — *пр. д.* Глубоко эрудированный; большой учёный.

**Мөтәбәххирин** متبحرين *сф.* Мөтәбәххир-нең *к.* — *пр. д. мн.* от мөтәбәххир.

**Мөтәвагыйд** متواعد *сф.* Бер-беренә сүз (вәгъдә) бирешкән. — *пр. д.* Обещающий, уславливающийся, сговаривающийся.

**Мөтәвази** متوازى *сф.* Янәшә, параллель. — *пр. д.* Параллельный.

**Мөтәвазиган** متواضعاً *р.* Түбәнчелек белән, түбәнчелек күрсәтеп. — *н.* Покорно, смирно, смиренно.

**Мөтәвазигъ** متواضع *сф.* Үз-үзен түбән тотучы, түбәнчелекле; эреләнмәүче. — *пр.* д. Смиренный, покорный, незаносчивый.

**Мөтәвазиессатух** متوازى السطوح *гыйб. мат.* Параллелепипед. *Рәсем дәресенең беренче елларына мөкәггаб, мөтәвазиессатух кебек шәкелләр ясау файдалы.* (Ш. ж.) — *фр. мат.* Параллелепипед.

**Мөтәвазиеләзлагъ** متوازى الاضلاع *гыйб. мат.* Параллелограмм. — *фр. мат.* Параллелограмм.

**Мөтәвазиян** متوازياً *р.* Янәшә рәвештә. — *н.* Параллельно.

**Мөтәвакыйф** متواقف *сф.* Бәйләнгән; бер әйбернең барлыгы икенче бер әйбергә бәйләнгән булуы. *Әсбабы мәдәниянең вөҗүдә кәлмәсе меңнәрчә кем-* — *пр. д.* Обуславливающий; зависимый; обусловленный.

*сәләрнең мәсагый итмәләренә вә йәк дигәрләренә могавәнәт әйләмәләренә мөтәвакыйфдыр.* (Ш. ж.)

**Мөтәвали** متوالى *сф.* Тоташ, өзлексез, бер-бер артлы килгән. — *пр. д.* Непрерывный, последовательный, преемственный.

**Мөтәвалиян** متواليا *р.* Бер тоташтан. — *н.* Непрерывно, последовательно.

**Мөтәварид** متوارد *сф.* Туры килүче, туры килгән. — *пр. д.* Совпадающий.

**Мөтәварис** متوارث *сф.* Мирас булып калган, буыннан буынга мирас булып килгән. — *пр. д.* Перешедший по наследству, унаследованный.

**Мөтәватир** متواتر *сф.* **1.** 1) Халык телендә күп сөйләнгән, халык арасына күп таралган. 2) Телдә әледән-әле кабатлана торган. **2.** Шигырь үлчәвенең исеме. — *пр. д.* **1.** 1) Передаваемый из уст в уста. 2) Периодически повторяемый. **2.** Название стихотворного размера.

**Мөтәваттыйн** متوطن *сф.* Ватан иткән, җирләшкән, шул җиргә күнеккән. — *пр. д.* Поселившийся, натурализовавшийся.

**Мөтәвәккил** متوكل *сф.* Тәвәккәл итүче; өмет итүче. — *пр. д.* Уповающий, полагающийся, надеющийся (на что-либо).

**Мөтәвәккилән** متوكلاً *р.* Тәвәккәлләп, таянып. — *н.* Уповая, полагаясь.

**Мөтәвәккыйф** متوقف *сф.* 1) Туктаган, тәрәлгән. 2) Бәйләнгән, бәйле булган. — *пр. д.* 1) Остановившийся, стоящий. 2) Зависящий, находящийся в зависимости.

**Мөтәвәлли*** متولى *сф.* 1) Вәкыф эшләре белән шөгыльләнүче. 2) Мәчет, мәдрәсә эшләрен башкаручы кеше. — *пр. д.* 1) Попечитель над пожертвованным „богоугодному делу" имуществом. 2) Ведающий делами мечети, медресе и т. п.

**Мөтәвәллид** متولد *сф.* Туган, барлыкка килгән; хасил булган, дөньяга килгән. *Канның табигате эсседер, аслы һаваи табигыйдән мөтәвәллид булыр.* (К. Нас.) — *пр. д.* Родившийся, зародившийся, происшедший; произведённый, появившийся на свет.

**Мөтәвәллидун** متولدون *ис.* Мөтәвәллид-нең *к.* — *сущ. мн.* от мөтәвәллид.

**Мөтәвәрригъ** متورع *сф.* Диндар, тәкъва, дин кушканча гына торучы. — *пр. д.* Набожный, благочестивый.

**Мөтәвәссил** متوسل *сф.* 1) Берәр сәбәптән файдаланучы. 2) Якынлык эзләүче, сарылучы. — *пр. д.* 1) Прибегающий к какому-либо средству. 2) Ищущий сближения; снискивающий благоволение.

**Мөтәвәррим** متورم *сф.* Шешенүче, шешенгән; шешкән, кабарган. — *пр. д.* Распухший, опухший.

**Мөтәвәссыйт** متوسط *сф.* 1) Уртача, ике якка да тигез булган. 2) Ике арага керүче; урталыкта, ике арада булучы. *Мәрҗән агач кебек тармакланып үсәр, хәнҗәр белән нәбат арасында мөтәвәссыйттыр.* (К. Нас.) 3) Артыкка да, кимгә дә китмәүче. — *пр. д.* 1) Средний, срединный. 2) Вступающийся, заступающийся, заступник. 3) Не переходящий за пределы минимума и максимума.

**Мөтәвәссыйтелкамә** متوسطالقامه *гыйб.* Урта буйлы. — *фр.* Среднего роста.

**Мөтәвәссыйтессин** متوسطالسن *гыйб.* Урта яшьтәге. — *фр.* Средних лет.

**Мөтәвәссыйф** متوصف *сф.* Сыйфатланган. — *пр. д.* Описанный, определённый.

**Мөтәвәффа** متوفى،متوفا *сф.* Үлгән, вафат булган. — *пр. с.* Умерший, мёртвый, покойный.

**Мөтәвәффи** متوفى *сф.* Үтерүче, үзүзен үтерүче. — *пр. д.* Покончивший жизнь самоубийством.

**Мөтәвәххиш** متوحش *сф.* Кыргыйланган, ерткычланган. — *пр. д.* Одичавший, озверевший.

**Мөтәвәҗҗиһ** متوجه *сф.* 1) Йөз тотучы, юнәлүче, шуна таба караучы. *Мөнля мәгъшукасилә бәрабәр кәнде йөгрек атында „Нун"га мөтәвәҗҗиһ улды.* (М. Ак.) 2) Илтифат итүче. — *пр. д.* 1) Направляющийся, отправляющийся. 2) Обращающий внимание, внимательный (к кому-либо).

**Мөтәвәҗҗиһән** متوجهاً *р.* Йөз тотып, юнәлеп. — *н.* Обратившись, обращаясь; направляясь.

**Мөтәвәһһим** متوهم *сф.* Хыяллапучы, төпсез (нигезсез) уйлар белән шөгыльләнүче. — *пр. д.* Мечтающий; предполагающий, воображающий.

**Мөтәгаббид** متعبد *сф.* Артык баш июче, коллык итүче; суфиланучы; динче. — *пр. д.* Преклоняющийся; набожный, религиозный.

**Мөтәгавин** متعاون *сф.* Хезмәттәшлек итүче; бер-беренә ярдәм итүче. — *пр. д.* Сотрудничающий; совместно работающий (над чем-либо); помогающий.

**Мөтәгадди** متعدى *сф.* 1) Кешегә хаксызлык эшләүче. 2) Чиктән чыгучы. — *пр. д.* 1) Обижающий, нападающий (на кого-либо). 2) Не знающий меры.

**Мөтәгадди фигыль** متعدى فعل *из. грам.* Үтемле фигыль, күчемле фигыль. — *из. грам.* Переходный глагол.

**Мөтәгаддид** متعدد *сф.* Берничә санлы, күп санлы. — *пр. с.* Многочисленный.

**Мөтәгадил** متعادل *сф.* Тигезләнгән, тигез, гадел. — *пр. д.* Равный, уравновешанный; справедливый.

**Мөтәгаззил** متعزل *сф.* Эшеннән алынган, урыныннан чыгарылган. — *пр. д.* Уволенный с работы, отстранённый от должности.

**Мөтәгаззир** متعذر *сф.* Авыр, читен, кыен эш; мөмкин булмаган. *Эт лафзында сәкен белән башлау мөтәгаззир дигән кабилдән бары сәкен белән башламастан гына әлиф языладыр.* (К. Нас.) — *пр. д.* Трудный, затруднительный; невозможный.

**Мөтәгаззыйм** متعظم *сф.* Масаючы, тәкәббер, кукрайган. — *пр. д.* Надменный, гордый.

**Мөтәгайир** متغير *сф.* Бер-берсенә ошамаган, төрле-төрле булган. — *пр. д.* Разнородный.

**Мөтәгайян** متعين *сф.* 1) Билгеләнгән; тәгаен ителгән. 2) Ачыкланган. — *пр. с.* 1) Назначенный, определённый. 2) Выясненный.

**Мөтәгайяр** متغير *сф.* Үзгәргән, башкаланган; алмашынган. *Уйландыгы вакытта һава мөтәгайяр улып бөтен бөтенә...* (З. Биг.) — *пр. с.* Меняющийся, изменчивый, переменчивый.

**Мөтәгакыйб** متعاقب *сф.* Чиратлашып аллы-артлы килүче, бер-бер артлы килүче. *Янә нәүбәтле яфрак аталыр, гарәпчә вә акы мөтәгакыйб аталыр, нәүбәт белән үсәр.* (К. Нас.) — *пр. д.* Непосредственно следующий; чередующийся.

**Мөтәгакыйбән** متعاقبا *р.* Артыннан килеп, соңыннан килеп, соңында ук. — *н.* Непосредственно; следующий за чем (кем)-либо.

**Мөтәгакыйд** متعاقد *сф.* Вәгъдәләшүче, вәгъдәләшүченең берсе. — *пр. д.* Договаривающийся, заключающий договор.

**Мөтәгал** متعال *сф. дини* Югары, бөек, кадерле. — *пр.* д. *рел.* Всевышний.

**Мөтәгали** متعالى *сф. кара:* мөтәгал. *Мәүлә мөтәгали сабыр вә тәхәммел вирсен.* (З. Биг.) — *пр. д. см.* Мөтәгал.

**Мөтәгалли** متغلب *сф.* 1) Җиңүче. 2) Җиңеп алучы. 3) Үзләштерүче; көч- — *пр. д.* 1) Одолевающий (кого-либо); побеждаю-

ләп алучы. *Хәкканиятле бер адәмнең хыялына кәлмәмеш вәһемләрне мөтәгаллибләр күзләре илә кашлары арасындагы бер эш хисаб идәрләр.* (Ш. ж.) щий. 2) Овладевающий. 3) Насильно овладевающий.

**Мөтәгалликат** متعلقات *ис.* 1) Мөтагалликъ-нын *к.* 2) Якыннар, кардәшләр. *Кайчан кызның мөтәгалликаты булучы хатыннар кызны зиннәт белән китереп...* (К. Нас.) 3) *грам.* Җөмләнең иярчен кисәкләре. — *сущ.* 1) *мн.* от мөтәгалликъ. 2) Родственники. 3) *грам.* Второстепенные члены предложения.

**Мөтәғалликъ** متعلق *сф.* 1) Бәйле, мөнасәбәтле. 2) Караган, бәйләнгән. *Хикәямез якындагы кичмеш заманга мөтәгалликъдер.* (М. Ак.) — *пр. д.* 1) Зависящий (от чего-либо). 2) Касающийся (чего-либо); относящийся (к чему-либо).

**Мөтәгаллим** متعلم *сф.* Өйрәнүче, укучы, шәкерт. — *пр. д.* Учащийся, обучающийся.

**Мөтәга́ммид** متعمد *сф.* Берәр эшне алдан уйлап эшләүче; тырыш. — *пр. д.* Поступающий обдуманно; серьёзный; старательный.

**Мөтәгаммидән** متعمدا *р.* Алдан уйлап, тырышып. — *н.* Обдуманно, серьёзно; старательно.

**Мөтәганни** متغنی *сф.* 1. Көйләп укучы, 2. Җырчы. — *пр.* д. 1. Читающий нараспев. 2. Певец.

**Мөтәгаризъ** متعارض *сф.* 1) Капмакаршы эш итүче; каршы төшүче. 2) Оппозицияче. 3) Бәрелешүче. — *пр. д.* 1) Противодействующий; возражающий. 2) Оппозиционер. 3) Сталкивающийся.

**Мөтәгариф** متعارف *сф.* 1) Танышучы, бер-берсен танучы. 2) Танылган, мәшһүр. — *пр. д.* 1) Знакомящийся. 2) Общепризнанный; общеизвестный.

**Мөтәгарризъ** متعرض *сф.* Һөҗүм итүче, берәүнең хокукына кул сузучы. — *пр. д.* Нападающий, наступающий, посягающий (на чьи-либо права).

**Мөтәгассир** متعسر *сф.* Авыр, кыен, читен, мәшәкатьле. — *пр. д.* Трудный, затруднительный.

**Мөтәгассыйб** متعصب *сф.* 1) Фанатик, берәр эшкә бик нык бирелгән кеше. *Ул шәһәрдә иң мөтәгассыйб кадимчеләрдән санала.* (Г. Ибр.) 2) Патриот. 3) Кире. — *пр. д.* 1) Фанатик, слепо преданный чему-либо. 2) Патриот. 3) Упрямый.

**Мөтәгассыйбанә** متعصبانه *гф. р.* Фанатик рәвештә, сукырларча бирелеп. — *ар.-п. н.* Фанатично, слепо.

**Мөтәгафил** متغافل *сф.* 1) Санга санамаучы. 2) Игътибар (дикъкать) итмәүгә салышучы. — *пр. д.* 1) Пренебрегающий (чем-либо). 2) Прикидывающийся небрежным, невнимательным.

**Мөтәгаффин** متعفن *сф.* 1) Черегән. 2) Исләнгән, начар ис чыгаручы, сасыган. — *пр. д.* 1) Гниющий, загнивающий. 2) Дурно пахнущий, вонючий.

**Мөтәгаффиф** متعفف *сф.* 1) Саф күңелле. 2) Азмаган, инсафлы, начар эшләрдән ерак торучы. 3) Тыйнаклык күрсәтүче. — *пр. д.* 1) Добродетельный. 2) Неизбалованный; неразвращённый. 1) Проявляющий скромность.

**Мөтәгаффифә** متعففه *сф.* Мөтәгаффиф-нең *мнс. Бер кыйсеме шундый хатындыр ки, йомшак вә мөтәгаффифә булучыдыр.* (К. Нас.) — *жен.* от мөтәгаффиф.

**Мөтәгаҗҗиб** متعجب *сф.* Гаҗәпләнүче, хәйран калучы, исе китеп аптырап калучы, таң калучы. — *пр. д.* Удивляющийся, изумляющийся.

**Мөтәгаҗҗибанә** متعجبانه *гф. р.* Исе китеп, таң калып, хәйран калып, гаҗәпләнеп. — *ар.-п. н.* Удивлённо, с изумлением, в удивлении.

**Мөтәгаһид** متعاهد *сф.* Сүз беркетүче, договор төзүче. — *пр. д.* Заключающий договор; договаривающийся.

**Мөтәгаһһид** متعهد *сф.* Йөкләмә алучы, үз өстенә алучы. — *пр. д.* Обязавшийся.

**Мөтәдави** متداوی *сф.* 1) Үз-үзен дәвалаучы. 2) Даруланучы, дәваланучы. — *пр. д.* 1) Самоизлечивающийся. 2) Лечащийся.

**Мөтәдавил** متدول *сф.* Кулдан кулга күчә торган, һәркем тарафыннан истигъмал ителә торган. *Ибне Синаның төрки, гарәби вә фарсый лисаннарында сөйләнмеш шигырьләре вә касыйдәләре мөтәдавилдер.* (Ш. ж.) — *пр. д.* Употребительный, находящийся в обращении; ходячий.

**Мөтәдарик** متدارك *сф.* 1) Арттан килеп җитүче, җитешүче, ирешүче. 2) Шигырьдә „мөтәфагыйлен" үлчәве. — *пр. д.* 1) Достигающий, настигающий. 2) *поэт.* Название стихотворного размера.

**Мөтәдафигъ** متدافع *сф.* Үзенә каршы чыгучыларны кире кайтаручы. — *пр. д.* Отражающий нападение, отвергающий.

**Мөтәдәйин** متدين *сф.* Динле кеше, диндар. *Гавәмнан ике мөтәдәйин адәм сөйләшеп утырганда...* (К. Нас). — *пр. д.* Религиозный, набожный, благочестивый.

**Мөтәдәнни** متدني *сф.* 1) Түбәнәйгән, артта калган. 2) Кирегә хәрәкәт (регресслашкан). 3) Әкренләп якынлашкан. — *пр. д.* 1) Отсталый. 2) Регрессивный. 3) Постепенно приближающийся.

**Мөтәдәффин** متدفن *сф.* Җиргә күмелүче, җиргә күмелгән. — *пр. д.* Зарывающийся в землю.

**Мөтәзагыйф** متضاعف *сф.* Ике өлеш арткан, ике тапкырга күбәйгән. — *пр. д.* Двойной, удвоенный; умноженный.

**Мөтәзад** متضاد *сф.* 1) Капма-каршы, бер-береңең киресе булган. 2) *грам.* Антоним. — *пр. с.* 1) Противоположный (по качеству, свойству), контрастирующий. 2) *грам.* Антоним.

**Мөтәзаид** متزائد *сф.* Арткан, ишәйгән, күбәйгән. — *пр. д.* Увеличивающийся, умножающийся; возрастающий.

**Мөтәзаллил** متظلل *сф.* Күләгәле булган, күләгәләнгән. — *пр. д.* Затенённый.

**Мөтәзаллим** متظلم *сф.* Үзенә карата булган хаксызлык, гаделсезлектән зарланучы. — *пр. д.* Жалующийся на притеснение.

**Мөтәзаммин** متضمن *сф.* Эченә алган. *Хәкарәтне мөтәзаммин бер кач җөмләләр язмыш иде.* (Ш. ж.) — *пр. д.* Заключающий в себе; содержащий; значащий.

**Мөтәзарригъ** متضرع *сф.* Түбәнчелек белән сораучы, үтенүче, ялваручы, ялынучы. — *пр. д.* Униженно просящий, умоляющий.

**Мөтәзаррир** متضرر *сф.* Зарар (зыян) күргән, зарарланучы. — *пр.* д. Понесший потери (убытки); потерпевший.

**Мөтәзахим** متزاحم *сф.* Этешеп, төртешеп тупланган. — *пр. д.* Толпившийся, столпившийся.

**Мөтәзәйин** متزين *сф.* Зиннәтләнгән, бизәлгән. — *пр. д.* Разукрашенный.

**Мөтәзәккир** متذكر *сф.* Искә төшерүче, хәтергә китерүче, искә төшереп телгә алучы. — *пр. д.* Напоминающий, припоминающий; упоминающий.

**Мөтәзәлзил** متزلزل *сф.* Тетрәүче, селкенүче, кузгалучы. — *пр. д.* Трясущийся, содрогающийся; дрожащий; вибрирующий.

**Мөтәзәллил** متذلل *сф.* 1) Буйсынган. 2) Түбән, хур булган, хурлыкка төшкән. — *пр. д.* 1) Покорный, смирный. 2) Унижающийся; униженный, опозоренный.

**Мөтәзәүвиҗ** متزوج *сф.* Өйләнгән, хатын алган. — *пр. д.* Состоящий в браке, женатый.

**Мөтәзәүвиҗә** متزوجه *сф.* Никяхланган, иргә чыккан, ирле (хатын). — *пр. д.* Замужняя, состоящая в браке.

**Мөтәзәһһир** متزهر *сф.* Чәчәкләнгән, чәчәк аткан. — *пр. д.* Цветущий, расцветающий.

**Мөтәкабил** متقابل *сф.* Каршылашкан, бер-беренә кара-каршы булган. *Кара-каршы яфрак димез, га әпчә вәракы мөтәкабил аталыр.* (К. Нас.) — *пр. д.* Противоположный, противолежащий.

**Мөтәкабилән** متقابلاً *р.* Һәр ике яктан, кара-каршы, үзара, бер-беренә. — *н.* Взаимно, обоюдно; друг против друга.

**Мөтәкагыйд** متقاعد *сф.* 1) Пенсиядә торучы. 2) Пенсионер. — *пр. д.* 1) Состоящий на пенсии. 2) Пенсионер.

**Мөтәкаддим** متقدم *сф.* **1.** 1) Алдан баручы. 2) Элекке, борынгы, моңа кадәр булган, алда килгән. 3) Алга баручы, үсеп баручы. **2.** *күч.* Начальник, түрә. — *пр. д.* **1.** 1) Идущий впереди. 2) Прежний, предшествующий; античный, давний. 3) Идущий вперёд; растущий. **2.** *перен.* Начальник.

**Мөтәкаддимин** متقدمين *ис.* Мөтәкаддим-нең *к. Бәдех ташы Бәдәхшанда зәлзәләдән соң зоһур итмештер, шуның өчен көтебе мөтәкаддиминдә юктыр.* (К. Нас.) — *сущ. мн.* от мөтәкаддим.

**Мөтәкариб** متقارب *сф.* Якынлашкан, якын килгән. — *пр. д.* Сближающийся.

**Мөтәкарриб** متقرب *сф.* Якынайган, якынаерга тырышкан кеше. — *пр. д.* Приближающийся; старающийся приблизиться.

**Мөтәкатыйг** متقاطع *сф.* Бер-берен кисеп үткән, кисешкән. — *пр. д.* Пересекающий.

**Мөтәкауви** متقوى *сф.* Куәтләнгән, көчәйгән, көчәйтелгән. — *пр. д.* Усиливающийся, укрепляющийся, ободряющийся.

**Мөтәкаувис** متقوس *сф.* Җәя кебек бөгелгән, бөкрәйгән. — *пр. д.* Согнутый дугой; согнувшийся, сгорбившийся.

**Мөтәкябир** متكابر *сф.* Үз-үзен һавалы (эре) тотучы, үзен зур күрүче. — *пр. д.* Гордящийся, высокомерный.

**Мөтәкясил** متكاسل *сф.* Иренчәк, ялкау, үшән. — *пр. д.* Ленивый, нерадивый, беспечный.

**Мөтәкясир** متكاثر *сф.* **1.** Күбәйгән, ешайган, арткан. **2.** Шигырь үлчәвенең исеме. — *пр. д.* **1.** Умножившийся, увеличившийся. **2.** *поэт.* Название стихотворного размера.

**Мөтәкясиф** متكاثف *сф.* 1) Тыгыз, тыгызланган, берекән. 2) Куеланган, куерган. — *пр. д.* 1) Тесный, компактный. 2) Сгущённый.

**Мөтәкәббир** متكبر *сф.* Үз-үзен зур күрүче, эреләнүче, масаючы, тәкәббер. *Зур куәтле мөтәкәббир тау артыннан тулган ай күтәрелә башлады.* (Г. Ибр.) — *пр. д.* Гордый, высокомерный, тщеславный.

**Мөтәкәббиранә** متكبرانه *гф. р.* Эрелек белән, эреләнеп, үз-үзен зур күреп, масаеп. *Бинаның ерак күккә мөтәкәббиранә күтәрелгәне күренә башлый.* (Г. Ибр.) — *ар.-п. н.* Гордо; высокомерно.

**Мөтәкәззиб** متكذب *сф.* Белә торып ялган сөйләүче. — *пр. д.* Намеренно лгущий.

**Мөтәкәллим** متكلم *сф.* 1) Сөйләүче, сөйләшүче, 2) *грам.* 1-зат фигыле. — *пр. д.* 1) Говорящий, беседующий. 2) *грам.* Первое лицо глагола.

**Мөтәкәллимин** متكلمين *ис.* Мөтәкәллим-нең *к.* (1 нче мәгънәсендә). *Ул мөтәкәллиминнән хөкяма фикерен алда тота.* (Г. Ибр.) — *сущ. мн.* от мөтәкәллим (в 1-ом значении).

**Мөтәкәллиф** متكلف *сф.* Кирәксезгә үз өстенә авыр йөк алучы. — *пр. д.* Взявший на себя труд, трудную задачу.

**Мөтәкәлләф** متكلف *сф.* Кыйммәт тора торган, зур чыгым сорый торган. *Шәһәрнең баштанаяк мода вә бизәк эченә чумган мөтәкәлләф хәяты...* (Г. Ибр.) — *пр. с.* Дорогостоящий, требующий больших расходов.

**Мөтәкәррир** متكرر *сф.* Кабатлана торган, кабат-кабат була торган. — *пр. д.* Повторяющийся.

**Мөтәкәссир** متكسر *сф.* Сынган, ватылган. — *пр. д.* Сломавшийся, разбившийся.

**Мөтәкәффил** متكفل *сф.* Берәр хәлнең үтәлешен тәэмин итәр өчен вәгъдә бирүче. — *пр. д.* Принявший на себя ответственность; поручившийся за выполнение какого-либо дела.

**Мөтәкәүвин** متكون *сф.* Барлыкка килүче, барлыкка килә торган, хасил була торган. *Энҗе, ягъни җәүһәрнең урыны вә мөтәкәүвин була торган җире диңгез и өбендәдер.* (К. Нас.) — *пр. д.* Образующийся; возникающий.

**Мөтәлязиман** متلازمان *с.* Берсе икенчесенә кирәкле булган ике әйбер, бер-береннән аерылмый торган. *Зыя белән музыка икесе мөтәлязиман булып, арадагы галякадә галякаи ләзүм булырга кирәк дип көлә иде.* (Г. Ибр.) — *прил.* Неразлучный, взаимонеобходимый.

**Мөтәлякый** متلاقى *сф.* Очраша торган, юлыга торган; аймыл булмый торган. — *пр. д.* Встречающийся.

**Мөтәлясыйк** متلاصق *сф.* Килеп кушылган, тоташкан. — *пр. д.* Присоединённый.

**Мөтәляхикъ** متلاحق *сф.* Бер-бер артлы килә торган. — *пр. д.* Следующий друг за другом.

**Мөтәләббис** متلبس *сф.* Киенгән, кием кигән. — *пр. д.* Одетый, облаченный; одевшийся, облачившийся.

**Мөтәләззиз** متلذذ *сф.* Ләззәтләнүче, тәмен татыган, тәм табучы. — *пр. д.* Наслаждающийся, вкусивший наслаждения.

**Мөтәләйин** متلين *сф.* Йомшак, йомшатылган. — *пр. д.* Смягчённый.

**Мөтәләкъкый** متلقى *сф.* 1) Очраша торган, очрашкан. 2) Каршылый торган, юлыгып кабул итә торган. — *пр. д.* 1) Встречающийся (с кем-либо). 2) Встречающий, принимающий.

**Мөтәләкъкыйб** متلقب *сф.* Кушаматлы, кушаматы булган. — *пр. д.* Прозываемый, прозванный; носящий прозвище.

**Мөтәләттыйф** متلطف *сф.* Ягымлы, ачык йөзле; мәрхәмәтле, нечкә күнелле. — *пр. д.* Ласковый, нежный; милосердный.

**Мөтәләүвин** متلون *сф.* 1) Төрле буяулы, төрле төсле. *Әнваг төс белән мөтәләүвин күркәм вә гүзәл тавис иде.* (К. Нас.) 2) Төрле фикергә күчеп йөри торган (кеше). — *пр. д.* 1) Разноцветный, пёстрый; раскрашенный. 2) Переменчивый, непостоянный (о людях).

**Мөтәләүвис** متلوث *сф.* Пычранган, керләнгән, буялган, әшәкеләнгән. — *пр. д.* Запачканный, замаранный, загрязнённый.

**Мөтәләһһиб** متلهب *сф.* Кабынучы, ялкынланучы, кабынган, ялкынланган. — *пр. д.* Пылающий, воспламенённый; загорающийся.

**Мөтәләһһиф** متلهف *сф.* Кайгылы, хәсрәтле, үкенечле; ачынучы. — *пр. д.* Скорбный, сокрушающийся; раскаивающийся.

**Мөтәмади** متمادى *сф.* Дәвам итә торган, озакка сузыла торган; даими, тоташ, өзлексез. — *пр. д.* Продолжительный, длительный, долгий; постоянный, беспрерывный.

**Мөтәмадиян** متماديا *р.* Туктаусыз, бертоташтан, өзлексез. — *н.* Постоянно, беспрерывно.

**Мөтәмаил** متمائل *сф.* Бер якка ауган, авыш. — *пр. д.* Склоняющийся, наклоняющийся.

**Мөтәмалик** متمالك *сф.* 1) Үз-үзен тота ала торган, үз-үзенә хуҗа булучы. 2) Хуҗа, ия, биләүче. — *пр. д.* 1) Сдерживающий себя, владеющий собой. 2) Владеющий; владетель, собственник.

**Мөтәмариз** متمارض *сф.* 1) Юри авыруга сабышучы, башын авыруга салган кеше. 2) Симулянт. — *пр. д.* 1) Притворяющийся больным, симулирующий болезнь. 3) Симулянт.

**Мөтәмасил** متماثل *сф.* Бер-беренә охшаган. — *пр. д.* Подобный, одинаковый, сходный.

**Мөтәммим** متمم *сф.* Тәмам итүче, бетерүче. — *пр. д.* Доканчивающий, дополняющий; заключительный.

**Мөтәммәм** متمم *сф.* Тәмам ителгән, беткән. — *пр. с.* Законченный, доконченный.

**Мөтәмәддин** متمدن *сф.* Мәдәниләшкән, культуралы булган, элга киткән. *Пакьлек сәбәпле адәм хайваннан вә мөтәмәддин вәхшидән аерыла.* (К. Нас.) — *пр. д.* Цивилизованный, культурный.

**Мөтәмәйиз** متميز *сф.* Башкалардан аерылып торучы, аерым урын тотучы. — *пр. д.* Отличающийся.

**Мөтәмәккин** متمكن *сф.* 1) Көчле, куәтле. 2) Бер урында торучы, урын тотучы. — *пр. д.* 1) Могущественный, властный. 2) Обитающий, живущий.

**Мөтәмәнна** متمنى، متمنا *сф.* 1) Теләнелгән, эстәлгән. 2) Теләнелгән нәрсә. — *пр. д.* 1) Желанное. 2) Предмет желаний.

**Мөтәмәнни** متمنى *сф.* Теләүче, өметләнүче. — *пр. д.* Желающий, надеющийся.

**Мөтәмәррид** متمرد *сф.* 1) Белә торып каршылык итүче, үзсүзле, кире беткән. *Шундый мөтәмәррид адәмне күрерсең ки, колакларына үгет-нәсихәтне төеп тутырсаң да алмаслар.* (К. Нас.) 2) Сүз тыңламаучы. — *пр. д.* 1) Сопротивляющийся, непокорный, упрямый, упорный, дерзкий. 2) Ослушник.

**Мөтәмәссик** متمسك *сф.* Нык тотынып ябышучы, тирбәлмәүче. — *пр. д.* Крепко придерживающийся (чего-либо), опирающийся (на что-либо), цепляющийся.

**Мөтәмәссил** متمثل *сф.* 1) Эштә (кыланышта) берәүгә охшарга тырышучы; охшап иярүче. 2) Мәкаль китерүче. — *пр. д.* 1) Подражающий, подделывающийся. 2) Приводящий пословицу.

**Мөтәмәттигъ** متمتع *сф.* Файдаланучы, файда алучы; рәхәтләнүче. — *пр. д.* Пользующийся, получающий пользу; наслаждающийся.

**Мөтәмәүвил** متمول *сф.* Бай кеше, маллы, хәлле, мал иясе. *Аның заманында Әдернә әһалисеннән бер мөтәмәүвил кемсәнә вафат итеп хатыны вә сеңелесе калды.* (К. Нас.) — *пр. д.* Богатый, состоятельный, зажиточный.

**Мөтәмәүвиж** متموج *сф.* Дулкынланучы, дулкынланган. — *пр. д.* Волнующийся, взволнованный.

**Мөтәнавиб** متناوب *сф.* Бер-бер артлы нәүбәтләшә торган, алмашлап дәвам итә торган. — *пр. д.* Чередующийся, попеременный, последовательный.

**Мөтәнавибән** متناوباً *р.* Бѐр-бер артлы, нәүбәтләшеп, алмаш-тилмәш, эзлекле рәвештә. — *н.* Поочерёдно, попеременно, посменно, последовательно.

**Мөтәназигъ** متنازع *сф.* Бәхәсче, бәхәсләшүче. — *пр. д.* Спорящий, спорщик.

**Мөтәназир** متناظر *сф.* Бер-беренә каршы караган, кара-каршы. — *пр. д.* Стоящий друг против друга; противолежащий; противостоящий.

**Мөтәназәгъ** متنازع *сф.* Бәхәсле. — *пр. д.* Оспариваемый, спорный.

**Мөтәназәгын фиһ** متنازع فيه *ст.* Бәхәсле әйбер, бәхәс ителгән нәрсә. — *сс.* Спорный предмет, оспариваемая вещь.

**Мөтәнакыйз** متناقض *сф.* Каршылыклы, берсе-берсенә каршы, каршылык итүче. — *пр. д.* Противоречивый, противоречащий, контрастный.

**Мөтәнакыйс** متناقص *сф.* Азаючы, җиткелексезләнүче. — *пр. д.* Уменьшающийся, делающийся недостаточным.

**Мөтәнасиб** متناسب *сф.* Тигез, бер чамадагы, туры килгән. — *пр. д.* Соразмерный, пропорциональный, симметричный.

**Мөтәнассыйр** متنصر *сф.* Христиан диненә чыккан кеше, христианлыкны кабул итүче, керәшен. — *пр. д.* Перешедший в христианскую веру; принявший христианство.

**Мөтәнафир** متنافر *сф.* Бер-беренә җирәнеп караучы, нәфрәт итешүче, яратышмаучы. — *пр. д.* Питающий отвращение.

**Мөтәнаһи** متناهى *сф.* Чикле, соңы, ахыры бар. *Гайре мөтәнаһи* — чиксез, очсыз-кырыйсыз. — *пр. д.* Конечный, ограниченный, определённый.

**Мөтәнәгъгыйм** متنعم *сф.* Иркен яшәүче, нигъмәтләнүче; тукланучы, ризыкланучы. *Халык сусаган вакытта галимнәр вә талибел гыйлемнәр мөтәнәгъгыйм булырлар...* (К. Нас.) — *пр. д.* Пользующийся земными благами, наслаждающийся жизнью; имеющий пропитание.

**Мөтәнәбби** متنبی *сф.* 1. Ялган пигамбәр, пигамбәрлек дәгъвасындагы кеше. *Пигамбәрнең вафаты соңында да, хәяты заманында да мөтәнәбби күп булды.* (К. Нас.) 2. Мәшһүр гарәп шагыйренең исеме. — *пр. д.* 1. Выдающий себя за пророка, лжепророк. 2. Имя собственное известного арабского поэта средних веков.

**Мөтәнәббиһ** متنبه *сф.* 1) Берәр эштән (сүздән) гыйбрәт алучы, акылын башына җыючы. *Хәлифә дәхи моннан мөтәнәббиһ булып халыкны үз хәлләренә куйды.* (К. Нас.) 2) Уянучы. 3) Уяу. — *пр. д.* 1) Извлекающий урок. 2) Внимательный, бдительный, осмотрительный. 3) Пробуждающийся. 4) Бодрствующий.

**Мөтәнәддим** متندم *сф.* Үкенүче. — *пр. д.* Раскаивающийся, кающийся.

**Мөтәнәззил** متنزل *сф.* 1) Түбән төшүче. 2) *дини* Иңдерелүче, иңдерелгән. 3) Түбәнчелек итүче. — *пр. д.* 1) Нисходящий. 2) *рел.* Ниспосланный. 3) Снисходящий.

**Мөтәнәккир** متنكر *сф.* 1) Яшеренеп, төсен үзгәртеп, үзен танытмый йөрүче. 2) Кем булуын белдермәүче, кем икәнен яшерүче. — *пр. д.* 1) Замаскированный, скрытный. 2) Инкогнито.

**Мөтәнәссыйх** متنصح *сф.* Үгетләнүче, нәсыйхәтләнүче, вәгазьләнүче. *Үзенең нәсыйхәтләре белән мөтәнәссыйх булмаган насыйхлар хакында „инә халыкны киенде, ә, ә үзе һаман ялангач“,— ди п әйтәләр.* (К. Нас.). — *пр. д.* Выслушивающий поучения, выговоры.

**Мөтәнәффир** متنفر *сф.* 1) Җирәнеп караучы. 2) Күренмәскә тырышучы. — *пр. д.* 1) Питающий отвращение. 2) Избегающий.

**Мөтәнәффис** متنفس *сф.* Сулу алучы; тын алучы; ял итүче. — *пр. д.* Вздыхающий; дышащий; делающий передышку.

**Мөтәнәүвига** متنوعه *сф. мнс.* 1) Төрле, төрле-төрле. 2) Газета, журналларның „төрле хәбәрләр“, „аннан-моннан“ дигән бүлеге. — *пр. д. жен.* 1) Различная, разнородная, разнообразная. 2) Отдел „отовсюду“ в газетах и журналах.

**Мөтәнәүвигъ** متنوع *сф.* Төрле-төрле, һәр төрле, бертөрле булмаган. *Ибне Синаның асаре күб вә гаять мөтәнәүвигъдыр.* (Ш. ж.) — *пр. д.* Разный, разнообразный, неодинаковый.

**Мөтәнәүвир** متنور *сф.* Нурландыручы, яктыртучы. — *пр. д.* Освещающий, озаряющий.

**Мөтәнәүвәр** متنور *сф.* Нурландырылган, яктыртылган. — *пр. с.* Освещённый, озарённый.

**Мөтәрадиф** مترادف *сф.* Мәгънәдәш сүз (синоним). — *пр. д.* Синоним.

**Мөтәракиб** متراكب *сф.* Берсе өстенә берсе куелган, өелгән, атландырылган. — *пр. д.* Положенный друг на друга, нагромождённый.

**Мөтәраким** متراكم *сф.* 1) Тупланган, җыелган, өелгән. 2) Куерган, тыгызланган, кысылган. — *пр. д.* 1) Скопившийся, накопившийся, сгрудившийся. 2) Сжатый, сгущённый.

**Мөтәрәбби** متربى *сф.* Тәрбия күргән, тәрбияләнгән. — *пр. д.* Получивший воспитание, воспитанный.

**Мөтәрәддид** متردد *сф.* Кыюсыз, икеләнүче, шикләнүче. *Вәҗһе тәсмиянең шөбһәле булуына карап татар сүзеннән качарга аны үзебезгә иснаддә мөтәрәддид булырга урын юк.* (Г. Ибр.) — *пр. д.* Нерешительный, колеблющийся; сомневающийся.

**Мөтәрәккиб** متركب *сф.* Берләштерүче; кушучы, катнаштыручы. — *пр. д.* Соединяющий, смешивающий.

**Мөтәрәкъкаб** مترقب *сф.* Көтелгән, күз текәлгән. — *пр. с.* Ожидаемый.

**Мөтәрәкъкый** مترقى *сф.* Алга киткән, тәрәкъкый иткән; зур уңышлар казанучы, алга баруны яклаучы (прогрессив). — *пр. д.* Прогрессивный, преуспевающий, идущий вперёд.

**Мөтәрәкъкыйб** مترقب *сф.* Зарыгып түземсезлек белән көтүче; күзәтеп көтеп торучы. *Болай тавыш белән уйганмагач, кызның уйганмакыны мөтәрәкъкыйб булып торды.* (К. Нас.) — *пр. д.* С нетерпением ожидающий, наблюдающий.

**Мәтәрәнним** مترنم *сф.* 1) Уйнаучы (музыка турында). 2) Җырлаучы, әкрен генә көйләүче. — *пр. д.* 1) Играющий (о музыке). 2) Напевающий; насвистывающий (песню).

**Мөтәрәссил** مترسل *сф.* 1) Корреспондент. 2) Язышучы (кара-каршы). — *пр. д.* 1) Корреспондент. 2) Ведущий переписку.

**Мөтәрәссыйд** مترصد *сф.* 1) Җентекләп күзәтүче. 2) Көтеп торучы. — *пр. д.* 1) Внимательно наблюдающий, подстерегающий, выжидающий. 2) Ожидающий.

**Мөтәрәттиб** مترتب *сф.* Тәртипләнгән, төзелгән, тәртипкә салынган. — *пр. д.* Приведённый в порядок, упорядоченный.

**Мөтәрәффигъ** مترفع *сф.* 1) Югарылык казанган, күтәрелгән. 2) Кәпрәйгән, масайган, һавалы. — *пр. д.* 1) Достигший высокого положения. 2) Высокомерный; заносчивый. 3) Пренебрежительно относящийся (к чему-либо).

**Мөтәрәххим** مترحم *сф.* Кайгысын уртаклашучы, аяучы, ачынучы, кызганучы. — *пр. д.* Сочувствующий, сожалеющий; жалеющий.

**Мөтәрәшшид** مترشد *сф.* Туры юлга кергән. — *пр. д.* Вставший на истинный, правильный путь.

**Мөтәрәшших** مترشح *сф.* Саркып үткән; тирләгән. — *пр. д.* Фильтрующийся, выпаренный.

**Мөтәрәҗҗи** مترجی *сф.* 1) Өмет итүче. 2) Үтенүче, теләүче, ялваручы. 3) Юллаучы, юллап йөрүче. — *пр. д.* 1) Надеющийся. 2) Желающий; просящий. 3) Проситель, ходатай.

**Мөтәрҗим** مترجم *сф.* Тәрҗемәче, толмач. — *пр. д.* Переводчик.

**Мөтәрҗәм** مترجم *сф.* Тәрҗемә ителгән. — *пр. с.* Переведённый.

**Мөтәсави** متساوی *сф.* Бер-беренә тигез, охшаган, бердәй, бертигез. *Мөтәсави завияләр* — бер-беренә тигез почмаклар (геометриядә). — *пр.* д. Равный, равняющийся.

**Мөтәсавиелкыйммә** متساوی القیمه *гыйб.* Бер үк дәрәҗәдәге, бер үк кыйммәттәге, тигез бәяле. — *фр.* В равной степени; равноценный.

**Мөтәсавиелхокук** متساوی الحقوق *гыйб.* Тигез хокук. — *фр.* Равноправие.

**Мөтәсавиеләгъза** متساوی الاعضا *гыйб.* Бердәй, тигез санда катнашуга нигезләнгән. — *фр.* Паритетный, составленный на паритетных началах.

**Мөтәсавиессакыйн** متساوی الساقین *гыйб. мат.* Тигезьянлы. — *фр. мат.* Равнобедренный.

**Мөтәсавиән** متساویاً *р.* Тигезләп, бертигез. — *н.* Поровну.

**Мөтәсадим** متصادم *сф.* Бер-беренә бәрелешә торган, бәрелешүче. — *пр. д.* Сталкивающиеся.

**Мөтәсадиф** متصادف *сф.* Туры килүче, очрап калучы. — *пр. д.* (Случайно) встречающийся; совпадающий.

**Мөтәсарриф** متصرف *сф.* 1) Тулы ия, хуҗа. 2) Малны үзе теләгәнчә тота, эш- — *пр. н.* 1) Полновластно распоряжающийся (чем-

не идарә итә алучы. 3) Аерым өлкәне, районны идарә итүче. *Озак мөтдәт ул шәһәрдә мөтәсарриф булып торучы...* (К. Нас.) — либо). 2) Действующий, поступающий по своему усмотрению. 3) Правитель, начальник округа, района.

**Мөтәсаувир** متصور *сф.* 1) Сурәтләүче, бер сурәтне күз алдына китерүче. 2) Рәсем ясаучы. — *пр. д.* 1) Воображающий, предполагающий. 2) Рисующий.

**Мөтәсаувиф** متصوف *сф.* 1) Суфилык итүче, эчке серләр белән шөгыльләнүче. 2) Суфи. — *пр. д.* 1) Погрузившийся в суфийскую мистику. 2) Суфий.

**Мөтәсаувәр** متصور *сф.* Уйда сурәтләнгән, күз алдына китерелгән, уйда гәүдәләнгән. *Бу җәзирәдә бәни адәмнең бер секунд тора алуы мөмкин вә мөтәсаувәр түгелдер.* (К. Нас.) — *пр. с.* Воображаемый, предположенный.

**Мөтәсәййиб** متثيب *сф.* Иреннән аерылган хатын, тол хатын. — *пр. д.* Разведённая жена, вдова.

**Мөтәсәлли** متسلی *сф.* Кайгысы таратылган, юанган. — *пр. д.* Утешающийся, находящий утешение.

**Мөтәсәллитъ** متسلط *сф.* Үз белдеге белән эш итүче; изүче, гаделсезлек һәм кыерсыту белән җинүче; хөкем сөрүче. — *пр. д.* Самовластный, деспотический, тиранический; господствующий.

**Мөтәсәлсил** متسلسل *сф.* Бер-беренә элмәкләнеп тезелмәле, бер-бер артлы тезелгән. — *пр. д.* 1) Беспрерывный, непрерывный. 2) Сцеплённый.

**Мөтәсәлсилән** متسلسلاً *р.* Бер-бер артлы тезелеп, өзлексез. — *н.* Беспрерывно, непрерывно.

**Мөтәсәттәр** متستر *сф.* Өретелгән, яшеренгән; сакланган. — *пр. д.* Скрывающийся, скрытый, сокровенный.

**Мөтәтаббиб** متطبيب *сф.* 1) Үзен врачлар рәтенә куючы шарлатан, ялган врач. 2) Врачлык эше белән шөгыльләнүче. — *пр. д.* 1) Выдающий себя за врача, шарлатан. 2) Занимающийся медицинской практикой.

**Мөтәтабиган** متتابعاً *р.* Бер-бер артлы, аллы-артлы булып, бер-беренә ияреп. — *н.* Последовательно, беспрерывно.

**Мөтәтабигъ** متتابع *сф.* Бер-бер артлы булган, бер-берсенә ияргән. — *пр. д.* Последовательный, преемственный; беспрерывный, непрерывный.

**Мөтәтабикъ** متطابق *сф.* Берсе нәкъ икенчесе кебек, бер-беренә бөтен яктан охшаган. — *пр. д.* Схожий, соответствующий, подобный.

**Мөтәфавит** متفاوت *сф.* Төрле, бер-береннән аермалы. *Мәктәптә укытыла торган бәхәсләрнең агырлыгы мөтәфавит.* (Ш. ж.) — *пр. д.* Различающийся, различный.

**Мөтәфахир** متفاخر *сф.* Мактанучы, башкалардан уздырырга тырышып мактанучы. — *пр. д.* Кичащийся, кичливый, заносчивый; хвастливый.

**Мөтәфәккир** متفكر *сф.* 1) Уйга чумган, уйлаучы, уйчан; уйлауга, фикер йөртүгә ия. 2) Фикер иясе. — *пр. д.* 1) Размышляющий, раздумывающий; задумчивый. 2) Мыслитель.

**Мөтәфәлсиф** متفلسف *сф.* 1) Философ булып маташучы. 2) Ялган философ, үзен философ итеп күрсәтүче. *Мөтәфәлсиф камыт аяк бер кыз янына барып* (Г. Газиз). — *пр. д.* Выдающий себя за философа. 2) Лжефилософ.

**Мөтәфәннин** متفنن *сф.* 1) Төрле фәннәрне белүче, күп фән белүче галим. 2) Энциклопедист. *Хәлифәләрнең кайбере мөтәфәнниннәрнең әсәре белән тулган көтебханәләрне утка ягудан кире тормадылар.* (Г. Ибр.) — *пр. д.* 1) Сведущий в различных областях науки, эрудированный человек. 2) Энциклопедист.

**Мөтәфәрригъ** متفرع *сф.* Бер төптән таралган, тармакланган, тармакланып аерылган. — *пр. д.* 1) Разветвлённый. 2) Производный.

**Мөтәфәррид** متفرد *сф.* 1) Кешеләрдән аерылып аулакта торучы, ялгыз калучы. 2) Үзенә генә караган, башкалардан аерым булган. *Ибне Сина Мәшаиюн мәсләгендә улмыш исә дә кәнденең мөтәфәррид улан фикерләре дә күбдер.* (Ш. ж.) — *пр. д.* 1) Уединяющийся. 2) Единственный в своем роде, уникальный, бесподобный.

**Мөтәфәррика** متفرقه *ис.* 1) Атлы гвардия. 2) Патша (король) сакчылары. — *сущ.* 1) Конная гвардия. 2) Копьеносцы или стрелки (из лука), сопровождающие короля.

**Мөтәфәррикан** متفرقاً *р.* Таралып, аерылып. — *н.* Врассыпную.

**Мөтәфәррикат** متفرقات *ис.* 1) Мөтәфәррикъ-ның *к.* 2) Төрле якка сибелгән нәрсәләр. — *сущ.* 1) *мн.* от мөтәфәррикъ. 2) Различные или разбросанные вещи.

**Мөтәфәррикъ** متفرق *сф.* 1) Аерылган, бүленгән; төрле. 2) Чәчелгән, таралган. — *пр. д.* 1) Разделённый; различный, разный. 2) Рассеянный, разбросанный.

**Мөтәфәрриж** متفرج *сф.* 1) Урамга чыгып йөрүче, кәефләнеп йөрүче. 2) Карап йөрүче. 3) Тамашачы. — *пр. д.* 1) Прогуливающийся, гуляющий. 2) Осматривающий; любующийся. 3) Зритель.

**Мөтәфәххир** متفخر *сф.* Мактанучы, масаючы. — *пр. д.* Кичащийся, хвастливый; горделивый.

**Мөтәфәүвикъ** متفوق *сф.* Өстен чыгучы, башкалардан өстен булган. — *пр. д.* Превосходный, превосходящий, одерживающий верх.

**Мөтәхаб** متحاب *сф.* Бер-бере белән дус булышучы; сөешүче. — *пр. д.* Дружащий; взаимно любящий.

**Мөтәхаззигъ** متخضع *сф.* Түбәнчелекле; тыйнак, кече күңелле. — *пр. д.* Смирный, скромный, сдержанный.

**Мөтәхалим** متحالم *сф.* Үзен йомшак һәм шәфкатьле итеп күрсәтүче. — *пр. д.* Представляющийся кротким, смирным.

**Мөтәхалиф** متخالف *сф.* 1) Төрле, үзенә башка, һәртөрле. 2) Капма-каршы, бер-беренә каршы булган, каршылыклы. — *пр. д.* 1) Различный, разнообразный. 2) Противоположный; противоречивый.

**Мөтәхамикъ** متحامق *сф.* Үзен ахмак (аңгыра) итеп күрсәтүче. — *пр. д.* Прикидывающийся дурачком.

**Мөтәхариб** متحارب *сф.* Сугышучы, сугыш хәлендә булучы. — *пр. д.* Воюющий, находящийся в состоянии войны.

**Мөтәхаригъ** متخارع *сф.* Үзен алданган итеп күрсәтүче. — *пр. д.* Притворяющийся обманутым, введённым в заблуждение.

**Мөтәхасид** متحاسد *сф.* Көнләшүче, комсыз. — *пр. д.* Завидущий.

**Мөтәхасим** متخاصم *сф.* Дошманлык итүче, дау куптаручы, кара-каршы дошманлашучы. — *пр. д.* Ведущий тяжбу, скандалящий; враждующий.

**Мөтәхассил** متحصل *сф.* Барлыкка килгән, бер эш нәтиҗәсендә булган, килеп чыккан. — *пр. д.* Образованный, созданный.

**Мөтәхассыйс** متخصص *сф.* Белгеч, специалист. — *пр. д.* Специалист.

**Мөтәхатый** متخاطی *сф.* Ялгышучы, хата эшләүче. — *пр. д.* Ошибающийся, заблуждающийся.

**Мөтәхаши** متحاشی *сф.* Куркак, өркүчән; юаш, сакланучы, оялчан. — *пр. д.* Трусливый, робкий, боязливый; смирный, застенчивый.

**Мөтәхашшигъ** متخشع *сф.* Түбәнчелек итүче, үзен ким күрүче; баш июче. — *пр. д.* Проявляющий покорность, благоговеющий (перед кем-либо); покорный.

**Мөтәхәддис** متحدث *сф.* 1) Килеп чыккан, мәйданга чыккан, юктан барлыкка килгән. 2) Сөйләшүче, әңгәмә алып баручы. — *пр. д.* 1) Появляющийся, создающийся. 2) Случающийся. 3) Разговаривающий, беседующий.

**Мөтәхәззин** متحزن *сф.* Кайгылы, хафалы, хәсрәтле. — *пр. д.* Скорбный, грустный, тягостный.

**Мөтәхәййиз** متحيز *сф.* 1) Сүзе үтемле, авторитетлы. 2) Берәр савыт эчендә булган. — *пр. д.* 1) Влиятельный, авторитетный. 2) Находящийся в каком-либо сосуде.

**Мөтәхәййил** متخيل *сф.* Хыяллы, төрле уйлар белән шөгыльләнүче. — *пр. д.* Фантазёр, мечтатель.

**Мөтәхәййир** متحير *сф.* Гаҗәпләнүче; хәйран калучы, аптырап калучы. *Нә димәя белмәеб мөтәхәйир улды.* (М. Ак.) — *пр. д.* Удивлённый, изумлённый; растерянный.

**Мөтәхәкъкыйк** متحقق *сф.* 1) Ышанычлы, шиксез, дөреслеге ачылган, беленгән. 2) Яхшылыгы исбат ителгән. *Язмакта шартлар бардыр ки, ул шартлар мөтәхәкъкыйк булмаганда файда өмит ителмәс.* (К. Нас.) — *пр. д.* 1) Достоверный, истинный. 2) Одобренный; подтвержденный.

**Мөтәхәлли** متحلى *сф.* Бизәнгән, купшыланган, зиннәтләнгән. — *пр. д.* Украшенный, наряженный.

**Мөтәхәлликъ** متخلق *сф.* Берәр холык белән сыйфатланучы. — *пр. д.* Отличающийся каким-либо нравом, характером.

**Мөтәхәллил** متحلل *сф.* 1) Эри торган, тарала торган; таркала торган. 2) Бушый торган. — *пр. д.* 1) Растворяющийся, разлагающийся. 2) Освобождающийся (от чего-либо).

**Мөтәхәллисъ** متخلص *сф.* Сакланган, котылган. — *пр. д.* 1) Сохранённый, избавленный. 2) Освобождающийся, избегающий (чего-либо).

**Мөтәхәллиф** متخلف *сф.* 1) Үз вәгъдәсен үзе бозучы. 2) Киреләнүче. — *пр. д.* 1) Нарушающий (обещание). 2) Упрямящийся.

**Мөтәхәммил** متحمل *сф.* Кыенлыклар күтәрүче, авырлыклар кичерүче; чыдап торучы. — *пр. д.* Переносящий, претерпевающий.

**Мөтәхәррик** متحرك *сф.* 1) Хәрәкәткә килүче, хәрәкәт итә торган. 2) *грам.* — *пр. д.* 1) Движущийся, подвижный. 2) *грам.*

Аслы, өсле, өтерле хәреф. *„К“ хәрефе бер хәрефе гыйлләттән соң вакыйг булып мөтәхәррик булса „г“ га мөнкалиб була.* (К. Нас.)

Огласованная буква.

**Мөтәхәррикъ I** متحرق *сф.* Янган.

*пр. д.* Сгоревший.

**Мөтәхәррикъ II** متخرق *сф.* Ертылган.

*пр. д.* Разорвавшийся, прорвавшийся.

**Мөтәхәссис** متحسس *сф.* 1) Сизүче, хис итүче. 2) Мәхәббәт белән сугарылучы. *Анда үзенең хиссияты берлә һичбер мөтәхәссис була алмаячагын уйлады.* (Г. Тук.)

*пр. д.* 1) Чувствующий, ощущающий. 2) Проникающийся чувством (любви, симпатии к кому-либо).

**Мөтәхәссир** متحسر *сф.* Хәсрәт чигүче, хәсрәтле, кайгыручы, кайгылы. *Хәятының кыйммәте ни дәрәҗәдә булса, үлемең өчен шул мәртәбәдә фөрьяд күтәрер, шул кадәр мөтәхәссир булырлар.* (Г. Ибр.)

*пр. д.* Тоскующий, горюющий.

**Мөтәхәссыйн** متحصن *сф.* **1.** Крепостька кереп бикләнгән, сыенган. **2.** Гыйффәтле.

*пр. д.* **1.** Засевший в крепости. **2.** Целомудренный.

**Мөтәхәссәс** متحسس *сф.* Сизелгән, тоелган, хис ителгән.

*пр. с.* Чувственный, ощутимый.

**Мөтәхәффизъ** متحفظ *сф.* Сакланучы, үзен саклаучы.

*пр. д.* Остерегающийся; берегущий самого себя.

**Мөтәхәшши** متخشى *сф.* Куркытылган, куркып чигенгән, куркучан.

*пр. д.* Устрашённый, испуганный, боязливый.

**Мөтәхәшшид** متحشد *сф.* Җыелучы; берләшүче.

*пр. д.* Собирающийся; объединяющийся.

**Мөтәхәүвил** متحول *сф.* 1) Үзгәртелгән, бер хәлдән икенче хәлгә күчерелгән. 2) Үзгәрүче, алмашынучы.

*пр. д.* 1) Превращённый, преобразованный. 2) Изменчивый; переменный.

**Мөтәхәҗҗәр** متحجر *сф.* Ташка әйләнгән, таш хәленә кергән.

*пр. с.* Окаменевший.

**Мөтәшабиһ** متشابه *сф.* 1) Охшаш, берсе икенчесе төсле. 2) Кинаяле, читләтеп әйтелгән.

*пр. д.* 1) Аналогичный, подобный. 2) Аллегорический.

**Мөтәшабиһат** متشابهات 1) Мөтәшабиһ-ның *к.* 2) Үзләрендәге ачык мәгънәне белдерү өчен булмыйча, башка бер теләккә мисал итеп (мәкаль кебек) кулланылган сүзләр.

*сущ.* 1) *мн.* от мөтәшабиһ. 2) Аллегорические выражения.

**Мөтәшагыйрь** متشاعر *сф.* Ялган шагыйрь, үзен үзе шагыйрь санаучы; шагыйрь булып маташучы.

*пр. д.* Считающий себя поэтом, лжепоэт.

**Мөтәшакил** متشاكل *сф.* 1) Охшаш, формалары бер төсле. 2) Шигырь үлчәве исеме. — *пр. д.* 1) Подобный, однотипный. 2) *поэт.* Название стихотворного размера.

**Мөтәшарик** متشارك *сф.* Катнашучы, уртаклашучы. — *пр. д.* 1) Участвующий. 2) Участник.

**Мөтәшәббис** متشبث *сф.* Бер эшкә бирелеп тотынучы, башлап керешүче. — *пр. д.* Предпринимающий; проявляющий инициативу.

**Мөтәшәббиһ** متشبه *сф.* Охшаш, охшаган. — *пр. д.* Подобный, похожий, сходный.

**Мөтәшәггыйб** متشعب *сф.* Ботакланган, аерылган, япьләнгән. — *пр. д.* Разветвлённый, ветвистый.

**Мөтәшәггыйр** متشعر *сф.* 1) Чәчле; йонлы. 2) Кытыршы. — *пр. д.* 1) Волосатый; шерстистый. 2) Шершавый.

**Мөтәшәйех** متشيخ *сф.* 1) Шәехлык итеп маташучы, ишанлык сатучы. 2) Картайган. — *пр. д.* 1) Представляющийся ишаном, шейхом. 2) Постаревший, старик.

**Мөтәшәкки** متشكى *сф.* Шикаять итүче, зарланучы, жалоба бирүче. — *пр. д.* Жалующийся.

**Мөтәшәккик** متشكك *сф.* Шикләнүче, икеләнеп уйлаучы. — *пр. д.* Сомневающийся, колеблющийся.

**Мөтәшәккил** متشكل *сф.* Бер сурәткә керүче; төзелгән, ясалган, оешкан. *Сезнең алдыгызда бер мөтәшәккил җәмәгать.* (Г. Ибр.) — *пр. д.* Сформировавшийся, образовавшийся, организовавшийся, принявший форму.

**Мөтәшәккир** متشكر *сф.* Рәхмәт әйтүче, яхшылыкның кадерен белүче. — *пр. д.* Благодарный, признательный.

**Мөтәшәккирән** متشكراً *р.* Рәхмәт әйтеп. — *н.* Благодарно, с признательностью.

**Мөтәшәррик** متشرك *сф.* Уртаклык итүче, ширкәттә катнашучы, компаньон. — *пр. д.* Компаньон.

**Мөтәшәрриф** متشرف *сф.* Кадерләнә торган, олылана торган, ихтирам ителүче. — *пр. д.* Почитаемый, уважаемый.

**Мөтәшәүвикъ** متشوق *сф.* Теләге (омтылышы, һәвәсе) көчле булган. — *пр. д.* Жаждущий, сильно желающий.

**Мөтәшәҗҗигъ** متشجع *сф.* 1) Гайрәтләнүче, батырланучы. 2) Батырчылык итүче, кыюланучы. — *пр. д.* 1) Храбрящийся. 2) Осмеливающийся, бодрящийся.

**Мөтәякъкыйз** متيقظ *сф.* Уяу кеше. *Мөтәякъкыйз бер җирдән ике мәртәбә алданмас.* (К. Нас.) — *пр. д.* Бодрствующий бдительный.

**Мөтәякъкыйн** متيقين *сф.* 1) Ачык беленгән. 2) Нык, шиксез беленгән; ышанычлы. — *пр. д.* 1) Выясненный. 2) Достоверный.

**Мөтәяссир** متيسر *сф.* Җиңел, җиңеләйтелгән. — *пр. д.* Облегчённый, лёгкий.

**Мөтәәддәб** متأدب *сф.* Әдәпле, әдәпләләнгән, тәрбияләнгән. — *пр. с.* Благовоспитанный, корректный.

**Мөтәәззи** متأذى *сф.* 1) Хәсрәтләнгән. 2) Изелгән, җәфаланган. — *пр. д.* 1) Огорчённый, опечаленный. 2) Измученный, истерзанный.

**Мөтәәйим** متأيم *сф.* Тол калган, хатынсыз калган кеше. — *пр. д.* Овдовевший.

**Мөтәәккилүн** متأكلون *сф. к.* Ашаучылар, ашарга бирелүчеләр. — *пр. д. мн.* Кушающие, едящие.

**Мөтәәллим** متألم *сф.* Кайгыручы, ачынучы; көенүче. *Җәмигъ халык наданлыктан качар, син надан дисәң рәнҗер, мөтәәллим булыр.* (К. Нас.) — *пр. д.* 1) Испытывающий боль. 2) Страдающий, мучающийся.

**Мөтәәммил** متأمل *сф.* Уйлап торучы, тирән уйга чумучы. — *пр. д.* Размышляющий, погружённый в размышления.

**Мөтәәнни** متأنى *сф.* 1) Ашыкмаучы, әкрен (кеше). 2) Уйлап эшләүче. — *пр. д.* 1) Медлящий. 2) Поступающий обдуманно, осмотрительно.

**Мөтәәнниянә** متأنيانه *р.* Ашыкмыйча. — *н.* Медленно, не торопясь.

**Мөтәәссир** متأثر *сф.* 1) Кайгы-хәсрәткә төшкән. 2) Йогынты алган, тәэсирләнгән. *Хәят белән ахыргы көрәшүендә Михаил үзе аңламый торган бер тойгыдан мөтәәссир булган иде.* (Ф. Әмир.) — *пр. д.* Опечаленный, огорчённый. 2) Получивший впечатление.

**Мөтәәссиф** متأسف *сф.* Кайгылы, үкенүче. — *пр. д.* Сожалеющий.

**Мөтәәххир** متأخر *сф.* Соңга калучы, кичегүче, артка калучы. — *пр. д.* Задерживающийся; опаздывающий; отстающий.

**Мөтәәххирин** متأخرين 1) Мөтәәххирнең *к.* 2) Соңгы замандагылар. — 1) *мн.* от мөтәәххир. 2) Преемники.

**Мөтәәһһил** متأهل *сф.* Өйләнгән, хатын алган, гаиләле. *Әмма мөтәәһһил адәмгә лаектыр ки...* (К. Нас.) — *пр. д.* Семейный, женатый.

**Мөтәҗавиб** متجاوب *сф.* 1) Кычкырып чакыручы. 2) Кара-каршы җаваплашучы. — *пр. д.* 1) Перекликающийся. 2) Взаимно отвечающий.

**Мөтәҗавиз** متجاوز *сф.* Чиктән узган, чамадан үткән. *Билхасса әбият мәзкүрә эчрәсендә 260 мөтәҗавиз бәет бардыр ки...* (Ш. ж.) — *пр. д.* Преступающий пределы; нарушающий границы; превышающий.

**Мөтәҗалис** متجالس *сф.* Башкалар белән бергә утыручы, мәҗлестәш. — *пр. д.* Сидящий совместно с другими.

**Мөтәҗанис** متجانس *сф.* Бер җенестән, бер төрдән булган, бер үк төсле, төрдәш, җенестәш. — *пр. д.* Уподобляющийся, однородный; однотипный.

**Мөтәҗаниб** متجانب *сф.* Тайпылучы, сакланып читтә калучы, читләшүче. — *пр. д.* Отстраняющийся, уклоняющийся, отклоняющийся.

**Мөтәҗасир** متجاسر *сф.* Батырлык итүче; батыр, кыю, йөрәкле. — *пр. д.* Смелый, храбрый, дерзкий.

**Мөтәҗасиранә** متجاسرانه *р.* Батырларча, батырлык белән. — *н.* Смело, храбро, дерзко.

**Мөтәҗаһил** متجاهل *сф.* Белмәмешкә салынучы, юри надан булып маташучы. — *пр. д.* Притворяющийся незнающим, невеждой.

**Мөтәҗаһиланә** متجاهلانه *р.* Белмәгәнсыман, белмәмешкә салынып, белмәгән булып. — *н.* Притворившись незнающим.

**Мөтәҗәббир** متجبر *сф.* 1) Изүче, кысучы, җәберләүче. 2) Һавалы, тәкәббер, масаючы. — *пр. д.* 1) Притеснитель, угнетатель, тиран. 2) Надменный, заносчивый.

**Мөтәҗәббиранә** متجبرانه *р.* Көчләп, җәберләп, изеп — *н.* Притесняя, угнетая.

**Мөтәҗәддид** متجدد *сф.* Яңарган, яңартылган; торгызылган. — *пр. д.* Возобновившийся, восстановленный; обновлённый.

**Мөтәҗәззи** متجزی *сф.* Өлешләнә торган, кисәкләргә бүленә торган, парчалана торган. — *пр. д.* Расчленяющийся, дробящийся.

**Мөтәҗәммигъ** متجمع *сф.* 1) Җыела торган, бергә туплана торган. 2) Группага берләшә торган. — *пр. д.* 1) Собирающийся, накопляющийся. 2) Объединяющийся в группу.

**Мөтәҗәммил** متجمل *сф.* Күркәмләнә торган, бизәнә торган, купшылана торган. — *пр. д.* Украшающийся; нарядный.

**Мөтәҗәнниб** متجنب *сф.* Сакланучы, сакланып читтә торучы. — *пр. д.* Уклоняющийся, отклоняющийся, посторонившийся.

**Мөтәҗәннин** متجنن *сф.* Җенләнгән, юләрләнгән, акылдан шашкан, тилергән. — *пр. д.* Сумасшедший, потерявший рассудок.

**Мөтәҗәссид** متجسد *сф.* Гәүдәләнгән, конкрет формага кергән. — *пр. д.* Воплощённый, воплотившийся, выразившийся в конкретной форме.

**Мөтәҗәссим** متجسم *сф.* Гәүдәләнгән, гәүдәләнеп күренгән. — *пр. д.* Воплотившийся, воплощённый.

**Мөтәҗәссис** متجسس *сф.* 1) Яшерен тикшереп йөрүче. 2) Кызыксынучы. 3) Разведкачы; шымчы. — *пр. д.* 1) Разведывающий; шпионящий. 2) Разведчик; шпион.

**Мөтәҗәүвигь** متجوع *сф.* Берәр максат белән ач торучы, үзе теләп ач торучы. — *пр. д.* Объявивший голодовку.

**Мөтәҗәүвиф** متجوف *сф.* 1) Эче буш. 2) „Күзле бүкән" (шәкерт телендә мөтәҗәүвиф һәм әҗвәф надан, белемсез мәгънәсендә). — *пр. д.* 1) Пустой. 2) „Дубина", „пень" — в смысле ничего не соображающий.

**Мөтәҗәһһиз** متجهز *сф.* Җиһазландырылган, әзер ителгән. — *пр. д.* Снаряжённый, приготовленный.

**Мөтәһалик** متهالك *сф.* Һәлакәтле эшкә керешүче, үз-үзен һәлакәт астына куючы. — *пр. д.* Идущий на опасные дела, бросающийся в пропасть.

**Мөтәһәддид** متهدد *сф.* Куркытучы, өркетүче; куркыта (өркетә) торган. — *пр. д.* Угрожающий, устрашающий.

**Мөтәһәззиз** متهزز *сф.* Тирбәнүче, тетрәүче; калтыраучы. — *пр. д.* Трясущийся; колеблющийся; дрожащий.

**Мөтәһәййиэ** متهى *сф.* Әзер, хәзерләнгән. — *пр. д.* Готовый, приготовленный.

**Мөтәһәййиҗ** متهيج *сф.* Дулкынланучы, дулкынланган. — *пр. д.* Волнующийся, возбужденный.

**Мөтәһәүвир** متهور *сф.* Дуамал, башсыз; кыю. — *пр. д.* Опрометчивый, безрассудный; отважный.

**Мөтәһәүвиранә** متهورانه *гф. р.* Тыйнаксыз, дуамал рәвештә. — *ар.-п. н.* Необузданно, опрометчиво.

**Мөфад** مفاد *ис.* Сүздән аңлашылган мәгънә, эчтәлек. *Шаригъның сөкүтеннән җәваз мөфад...* (Ак.) — *сущ.* Смысл, значение.

**Мөфарикъ** مفارق *сф.* Аерылучы, аерымланучы. — *пр. д.* Отделяющийся, различающийся; расстающийся.

**Мөфарәкать** مفارقت *м. III.* Аерылышу, бер-берсеннән ераклашу, бер-берсен ташлау. *Балаларыннан, зәүҗәннән вә* — *м. III.* Расставание, разлука; покидание.

*әнкәсеннән мөфарәкать идәчәктер.* (З. Биг.)

**Мөфассал** مفصل *сф.* Тулы, җентекле.
*пр. с.* Подробный, детальный.

**Мөфахәрә** مفاخره *м. III.* Тәкәбберлек, кукраю, масаю. *Замана халкын күрәмез ки, фәкать мөфахәрә вә мөкябәрә өчен генә гыйлем үгрәнерләр.* (К. Нас.)
*м. III.* Заносчивость, высокомерие, горделивость.

**Мөфзый** مفضى *сф.* Илтүче, тоташтыручы. *Фитнәгә мөфзый гаугага, бозыклыкка илтә.* (Ф. Әмир.)
*пр. д.* Ведущий, приводящий (к чему-либо).

**Мөфид** مفيد *сф.* 1) Файда китерүче. 2) Әһәмиятле. *Гаҗаип мөфид бер дәвадыр.* (К. Нас.)
*пр. д.* 1) Полезный, выгодный. 2) Значительный.

**Мөфлис** مفلس *сф.* 1) Бөлгән, бөлүче. 2) Банкрот. *Араларында бер мөфлис фәкыйрь бар иде.* (К. Нас.)
*пр. д.* 1) Разорившийся. 2) Банкрот.

**Мөфриз** مفرز *сф.* Аеручы.
*пр. д.* Отделяющий.

**Мөфризә** مفرزه *ис.* 1) Мөфриз-нең *мнс.* 2) Аеру билгесе, өтер.
*сущ.* 1) *жен.* от мөфриз. 2) Знак препинания, запятая.

**Мөфрәд** مفرد *сф.* 1) Ялгыз. 2) *грам.* Берлек сан.
*пр. д.* 1) Единственный, один. 2) *грам.* Единственное число.

**Мөфрәд мөтәкәллим** I-затның берлек саны (сөйләүче).
Един. число 1-го лица.

**Мөфрәд мөхатаб** II-затның берлек саны (тыңлаучы).
Един. число 2-го лица.

**Мөфрәд гаиб** III-затның берлек саны.
Един. число 3-го лица.

**Мөфрәдат** مفردات *ис. к.* 1) Кушылмаган, ялгыз булган әйберләр. 2) *грам.* Җөмләдәге аерым сүзләр. 3) Һәрбере бер дәвага яраган дару үләннәре. 4) Дару үләннәре турында язылган китап исеме („Мөфрәдат тыйб"). *Мөфрәдат тыйбда пападия чәчәге ике төрлесе зекер кылыныр.* (К. Нас.)
*сущ. мн.* 1) Простые, несмешанные вещества. 3) *грам.* Отдельные слова в предложении. 3) Целебные травы. 4) Название книги о целебных травах („Мөфрәдат тыйб").

**Мөфрә̊з** مفرز *сф.* Аерылган; аерым, бүленгән, гомумнән аерылган бер өлеш.
*пр. д.* Отдельный, выделенный, особый.

**Мөфсид** مفسد *сф.* 1) Аздыручы, бозучы. 2) Явызлык эшләүче; коткы салучы. 3) Провокатор.
*пр. д.* 1) Развратитель. 2) Злоумышленник, подстрекатель. 3) Провокатор.

**Мөфти*** مفتى *ис.* Мөфти, руханилар башлыгы, берәр мәсьәлә буенча диннең карашы ничек булуын белдерүче, фәтва бирүче. — *сущ.* Муфтий; главный судья по религиозному закону шариата, выносящий решения, называемые фетва.

**Мөфтәзәх** مفتضح *сф.* Хур ителгән, яман аты чыккан, рисвай ителгән. — *пр. д.* Опозоренный, осрамлённый, обесчещенный.

**Мөфтәзәхә** مفتضحه Мөфтәзәх-нең *мнс.* — *жен.* от мөфтәзәх.

**Мөфтәри** مفترى *сф.* Яла ягучы. — *пр. д.* Клеветник.

**Мөфтәрис** مفترس *сф.* 1) Ботарлаучы, өзгәләүче. 2) Ерткыч (хайван). — *пр. д.* 1) Терзающий. 2) Хищный (зверь).

**Мөфтәхир** مفتخر *сф.* Мактанучы. — *пр. д.* Хвастун.

**Мөфтәхиранә** مفتخرانه *гф. р.* Мактанган рәвештә, мактанып. — *ар.-п. н.* Хвастливо.

**Мөфхиш** مفحش *сф.* Әшәке сүз сөйләүче. — *пр. д.* Говорящий непристойности.

**Мөфәккир** مفكر *сф.* 1) Фикерләүче, уйчан, уйлаучы. 2) Төшенүче; төшендерүче. — *пр. д.* 1) Размышляющий; задумывающийся, задумчивый. 2) Разъясняющий.

**Мөфәррих** مفرح *сф.* Сөендерүче, шатландыручы. *Зәгъфран мөфәррих вә мөкәйиф нәрсәдер.* (К. Нас.) — *пр. д.* Веселящий, радующий, оживляющий.

**Мөфәссир** مفسر *сф.* Бер нәрсәне аңлатып (ачыклап) бирүче. *Ул вакыт католиклар инҗилнең „рәсми мөфәссире" папа диләр иде.* (Ш. ж.) — *пр. д.* Комментатор, толкователь.

**Мөфәссирин, мөфәссирун** مفسرين، مفسرون *ис.* Мөфәссир-нең *к.* — *сущ. мн.* от мөфәссир.

**Мөфәссәр** مفسر *сф.* Аңлатып (ачыклап) бирелгән. — *пр. с.* Истолкованный, объяснённый; комментированный.

**Мөфәттин** مفتن *сф.* Фетнәче; фетнә белән шөгыльләнүче. *Галиев мәккяр вә мөфәттин адәмдер.* (З. Биг.) — *пр. д.* 1) Бунтарь, смутьян, мятежник. 2) Сеющий смуту.

**Мөфәттиш** مفتش *сф.* 1) Тикшерүче. 2) Инспектор; ревизор, контролёр. — *пр. д.* 1) Проверяющий. 2) Инспектор; ревизор; контролёр.

**Мөфәххир** مفخر *сф.* Мактатучы, мактауга сәбәп булучы. — *пр. д.* Дающий повод к тому, чтобы хвалили.

**Мөфәүвәзъ** مفوض *сф.* Тапшырылган, бирелгән. — *пр. с.* Вверенный, порученный.

**Мөхавәрә** محاوره *м. III.* 1) Әңгәмә, кара-каршы сөйләшү; гәпләшү. 2) Киңәшмә. — *м. III.* 1) Беседа, разговор. 2) Совещание.

**Мөхадәсә** محادثه *м. III.* Сөйләшү, әңгәмә, бер-беренә хикәяләр сөйләшү. — *м. III.* Беседа, собеседование, разговор.

**Мөхазарат** محاضرات Мөхазарә-нең *к.* *Һөнәр вә сәнаигъ адәм гамьнән калмыш икәненә ничә мөхазарат китаплары дәлил белән тулыдыр.* (К. Нас.) — *мн.* от мөхазарә.

**Мөхазарә** محاضره *м. III.* 1) Бәхәс итәргә өйрәтә торган фән. 2) Әдәби темаларга сөйләшү. — *м. III.* 1) Наука о дискуссии. 2) Собеседование на литературные темы.

**Мөхази** محاذى *сф.* 1) Кара-каршы. 2) Янәшә, параллель. — *пр. д.* 1) Противолежащий. 2) Параллельный.

**Мөхакәмә** محاكمه *м. III.* Судта тикшерү, хөкем чыгару. — *м. III.* Судебное разбирательство, процесс; вынесение приговора.

**Мөхаль** محال *сф.* Булмый торган, мөмкин булмаган. *Гомердән бер дәкыйкане юкка үткәрсәң, аны кире кайтармак мөхальдер.* (М. Ак.) — *пр.* Невозможный, невероятный; абсурдный.

**Мөхалят** محالات *ис.* Мөхаль-нең *к.* — *сущ. мн.* от мөхаль.

**Мөхаләка** مخالقه *м. III.* Тирә-юньдәге кешеләр белән яхшы мөгамәләдә булып, тату тору. — *м. III.* Быть в хороших, добрососедских отношениях.

**Мөхаләфә** محالفه *м. III.* 1) Кара-каршы ант итешү. 2) Берләшмә (союз) төзү. 3) Союз, килешү. — *м. III.* 1) Взаимная клятва. 2) Заключение союза. 3) Союз; соглашение.

**Мөхариб** محارب *сф.* 1) Сугышучы, орышучы. 2) Сугышучы як. — *пр. д.* 1) Сражающийся, воюющий. 2) Воюющая сторона.

**Мөхарәбә** محاربه *м. III.* Сугыш, дошман белән сугышу. *Мөхарәбә илә забыт итә алмадылар.* (Х. Чис.) — *м. III.* Война, сражение, битва.

**Мөхасарә** محاصره *м. III.* Урап алу, камап алу, гаскәр тарафыннан чолганып алыну. *Юнанилар ун сәнә мөхасарә идеп торганлыклары хәлдә ...* (Х. Чис). — *м. III.* Осада, блокада.

**Мөхасиб** محاسب *сф.* Бухгалтер, хисапчы. — *пр. д.* Бухгалтер, счетовод.

**Мөхасин** محاسن *сф.* Яхшы мөгамәлә итүче. — *пр. д.* Хорошо обходящийся (с кем-либо).

**Мөхасир** محاصر *сф.* Камаучы, гаскәр белән чолгап алучы. — *пр. д.* Осаждающий, блокирующий.

**Мөхасәбә** محاسبه *м. III.* Хисап алышу, ике кеше арасында хисаплашу, санашу. *Минем белән мөхасәбә кылмаячак карт ушбу тары бөртеге кадәр мәсърафын санаган гүзәл егеттән артыграктыр,— диде.* (К. Нас.) — *м. III.* Отчёт, проверка; счёты, расчёты.

**Мөхат** محاط *сф.* Киртәләнгән, койма белән уралган, чолганып алынган. *Зөбанилар, кылыч, туплар, казак, мылтык палачларлә, мөхатыз һәр җәһәттән: саг вә сулдан, зир вә балядан.* (Г. Тук.) — *пр. с.* Окружённый, огражденный.

**Мөхафиз** محافظ *сф.* Саклаучы, сакчы. *Күз кабаклары күз эченә ят нәрсә кермәсен өчен мөхафиздыр.* (К. Нас.) — *пр. д.* Охраняющий, предохраняющий.

**Мөхафәзә** محافظه *м. III.* Саклау, яклау. *Ялган төшләрдән мөхафәзә әйләсен.* (З. Һади). — *м. III.* 1) Соблюдение, сохранение. 2) Охрана, защита.

**Мөхдис** محدث *сф.* Уйлап чыгаручы, иҗат итүче. — *пр. д.* Изобретатель, создатель.

**Мөхдәс** محدث *сф.* 1) Яңа барлыкка килгән, яңа ясалган. 2) Якында гына баеган. — *пр. с.* 1) Новый, новейший. 2) Недавно разбогатевший.

**Мөхиб** محب *сф.* 1) Сөюче, яратучы. 2) Якын дус, яратылган кеше ... *Хаммат хаҗи мәкамы белән корьән укучыларның мөхибе иде.* (Г. Газиз). — *пр. д.* 1) Любящий. 2) Близкий друг, любимый человек.

**Мөхиббанә** محبانه *гф. р.* Яратып, сөеп, дусларча. *Минем кебек үк хатыннар, кызлар ирләренең, егетләренең кулына мөхиббанә яталар да, гөлоердәшеп бакчага киләләр.* (Г. Ибр.) — *ар.-п. н.* По-дружески, любовно.

**Мөхиббелватан** محب الوطن *гыйб.* Илен сөюче, патриот. — *фр.* Любящий родину, патриот.

**Мөхиббеннәфес** محب النفس *гыйб.* Үзен сөюче. — *фр.* Себялюбивый, самолюбивый.

**Мөхиббәтән** محبةً *р.* Дусларча, сөеп, яратып. *Бер-береңең йөзенә елмаеп, мөхиббәтән кулларын тотышсалар* ... (К. Нас.) — *н.* По-дружески, любовно.

**Мөхи** محی *сф.* Терелтүче, җанландыручы. — *пр. д.* Оживляющий, животворный.

**Мөхикъ** محق *сф.* Хаклы, гадел, дөреслек, хаклык ягында булучы. — *пр. д.* Правый; справедливый тот, кто прав.

**Мөхилл** مخل *сф.* Бозучы, зарар итүче, кимчелек китерүче, тукынучы. *Минем һөҗүем аның шәхсенә мөхилл түгелдер.* (К. Нас.) — *пр. д.* 1) Портящий. 2) Нарушающий (что-либо), причиняющий, ущемляющий.

**Мөхитъ*** محيط *сф.* 1) Әйләнә-тирә, тирә-юнь. 2) Урап алган, чорнап алган, эченә алган. *Һава җәмигъ җисемнәрне мөхитътыр.* (К. Нас.) 3) Океан. — *пр. д.* 1) Среда, окружение. 2) Окружающий. 3) Океан.

**Мөхкәм, мәхкәм** محكم *сф.* 1) Таза, чыдамлы, нык. *Канәгать бер мөхкәм, күләгәле ләтыйф агачдыр ки, төбенә утырган кайгы эссесендә пешмәс.* (К. Нас.) 2) Төгәл, анык. — *пр. с.* 1) Прочный, крепкий, хорошо сделанный. 2) Точный, верный.

**Мөхлисанә** مخلصانه *гф. р.* Чын (саф) күңел белән, чын дуслык белән; чын дусларча. — *ар.-п. н.* Искренно, чистосердечно.

**Мөхсин** محسن *сф.* Яхшылык итүче, кешегә материаль ярдәм итүче, юмартлык итүче. — *пр. д.* **1.** Благодетельный. **2.** Благодетель; благотворитель.

**Мөхталь** محتال *сф.* 1) Хәйләкәр. *Гакыйлләр белсеннәр ки, ризыкта мөхтальнең хәйләсе юктыр.* (К. Нас.) 2) Алдакчы; аферист. — *пр. с.* 1) Ухитряющийся; хитрый, ловкий. 2) Обманщик; мошенник, жулик; аферист.

**Мөхтәви** محتوى *сф.* Эченә алган, җыйган, сыйдырган. *Бу җирләр Төркстан аталып, төркичә мөтәкәллим хили шәһәр вә касабәләрне мөхтәвидер.* (Ш. ж.) — *пр. д.* Содержащий, включающий в себя.

**Мөхтәзыйр** محتضر *сф.* Үлү дәрәҗәсендәге авыру. — *пр. д.* Находящийся в агонии, умирающий.

**Мөхтәкыйр** محتقر *сф.* Хурлаучы, нәфрәт белән караучы. — *пр. д.* Презирающий, пренебрегающий.

**Мөхтәлитъ** مختلط *сф.* Катыш, кушылган; төрле нәрсәләрдән кушылып ясалган. — *пр. д.* Смешанный, присоединенный.

**Мөхтәлиф** مختلف *сф.* 1) Төрле-төрле. 2) Каршылыклы, бәхәсле. *Өч җенесчә мөхтәлиф затлар нәдән берләшмешләр.* (М. Ак.) — *пр. д.* 1) Различный; разнообразный. 2) Спорный, несогласный.

**Мәхтәләфен фиһ** مختلف فيه *ст.* Бәхәсле, бертавыштан кабул ителмәгән. — *сс.* Спорный, единогласно не одобренный.

**Мөхтәмәл** محتمل *сф.* Булыр дип уйланган, булуы мөмкин саналган. *Бу* — — *пр. с.* Возможный, вполне вероятный.

*вөҗүде мөхтәмәл дә булмаган эшләрдән бередер.* (Г. Ибр.)

**Мөхтәриз** محترز *сф.* Саклаучы. — *пр. д.* Остерегающийся, берегущийся.

**Мөхтәрикъ** محترق *сф.* Кабынып китүче; янып торучы, ялкынлы. *Мөхтәрикъ улдым да яндым нары һиҗраның-лә бән.* (Г. Тук.) — *пр. д.* Воспламеняющийся; горящий, горючий.

**Мөхтәрәм*** محترم *сф.* Хөрмәтле, хөрмәт ителә торган. — *пр. с.* Уважаемый, почитаемый, почтенный.

**Мөхтәсиб** محتسب *сф.* 1) Хисап алучы, хисап алып торырга куелган кеше. 2) *дини* Муллалардан өстен дин галиме. — *пр. д.* 1) Контролёр; инспектор. 2) *рел.* Учёный богослов.

**Мөхтәшәм** محتشم *сф* Зиннәтләнгән, зиннәтле, бик шәп, менә дигән. *Мин бинәва, сез мөхтәшәмсез.* (Хорәз.) — *пр. с.* Великолепный, пышный, роскошный.

**Мөхәддид** محدد *сф.* Чикләүче, чиген билгеләүче. — *пр. д.* Ограничивающий.

**Мөхәддират** مخدرات *сф. к.* Авыртуны бетерә торган наркотик дарулар. *Тукран үләне тиле бәрән үләне кебек мөхәддират җөмләсеннәндер.* (К. Нас.) — *пр. д. мн.* Анестезирующие средства, наркотики.

**Мөхәддәд** محدد *сф.* Чикләнгән, чиге билгеләнгән. — *пр. с.* Ограниченный, определе ённый.

**Мөхәййир** محير *сф.* 1) Шаккатыручы, хәйран калдыручы. 2) Аптыратучы. — *пр. д.* 1) Изумляющий, смущающий. 2) Затрудняющий.

**Мөхәййял** مخيل *сф.* Хыялдагы, уйдырма, хыялый. — *пр. с.* Воображаемый, фантастический.

**Мөхәкъкак** محقق *сф.* 1) Ачык, чын, шөбһәсез. 2) Дөресләнгән, хаклыгы ачылган. *Аның сезгә ирешмәке мөхәкъкакдыр.* (К. Нас.) — *пр. с.* 1) Безусловный, очевидный; верный. 2) Проверенный, доказанный.

**Мөхәкъкар** محقر *сф.* Хур күрелгән, кимсетелгән. — *пр. с.* Презираемый, унижаемый.

**Мөхәкъкыйк** محقق *сф.* Тикшерүче, бер нәрсәнең төбен, дөреслеген, чынын тикшерүче. — *пр. д.* Проверяющий; изучающий; ищущий истину.

**Мөхәллил** محلل *сф.* Эретүче, таркатучы. *Су бәдәнгә ротубәт бирер, һәзымны сәһел кылыр вә тәгамны мөхәллилдер.* (К. Нас.) — *пр. д.* Растворяющий.

**Мөхәлләкъ** مخلق *сф.* Үзенә холык (гадәт) итеп алган. — *пр. с.* Перенявший нравы, манеры; усвоенные привычки.

**Мөхәммин** مخمن *сф.* **1.** Фараз итүче, чамалап сөйләүче. **2.** Бәя билгеләүче, такса куючы. — *пр. д.* **1.** Предполагающий, говорящий неопределенно. **2.** Калькулятор, таксатор, оценщик.

**Мөхәммәди** محمدى *с.* 1) Мөхәммәт(кә караган). 2) Мөхәммәткә ияргән, Мөхәммәт дине тотучы. — *прил.* 1) Мусульманский. 2) Мусульманин: последователь Мухаммеда.

**Мөхәммәс** مخمس *сф.* 1) Биш почмаклы, биш кырлы. 2) Биш тапкыр кабатлана торган. 3) Бишле (шигырь). — *пр. с.* 1) Пятиугольный; пятиугольник. 2) Пятикратный. 3) *поэт.* Пятистишие.

**Мөхәнникъ** مخنق *сф.* Буучы, буган. — *пр. д.* Удушающий, душащий.

**Мөхәррик** محرك *сф.* **1.** Хәрәкәтләндерүче. **2.** Уятучы, кузгатучы. **3.** Уятучы сәбәп. **4.** Мотор. — *пр. д.* **1.** Приводящий в движение. **2.** Побуждающий. **3.** Побудительная причина. **4.** Двигатель, мотор.

**Мөхәррикъ** محرق *сф.* Яндыручы, утка ягучы. — *пр. д.* Сжигающий, выжигающий.

**Мөхәррир** محرر *сф.* 1) Язучы; журналист. 2) Автор. 3) Редактор. *Сатучылык итә бездә мөхәррир, әдип исме аңа тагылыр-тагылмас.* (Г. Тук.) — *пр. д.* 1) Писатель; журналист. 2) Автор. 3) Редактор.

**Мөхәррирә** محرره *сф.* Мөхәррир-нең *мнс.* — *жен.* от мөхәррир.

**Мөхәррәм** محرم *сф.* 1) Харам ителгән, тыелган. 2) Һижри елының беренче ае исеме. — *пр. с.* 1) Запрещённый, недозволенный. 2. Название первого месяца Хиджры.

**Мөхәррәмат** محرمات *ис.* Мөхәррәмнең *к.* (1 нче мәгънәдә генә.) — *сущ. мн.* от мөхәррәм (только в 1-м значении).

**Мөхәррәрат** محررات *ис. к.* Язылган нәрсәләр; язылган хатлар. — *сущ. мн.* Писания, письма, бумаги, корреспонденция.

**Мөхәррәф** محرف *сф.* Бозылган, үзгәртелгән (сүзләр, хәрефләр турында). — *пр. с.* Изменённый, подменённый; искажённый, извращённый (о тексте).

**Мөхәссәнат** محسنات *ис. к.* Күркәмлекләр, күркәм (гүзәл) эшләр; яхшы сыйфатлар. *Мәгънәләре мөхәссәнат илә мөмтаз улмаклары кеби, ләфызлары да һәм бер чук мөхәссәнат ула белер.* (Ш. ж.) — *мн. ч.* Похвальные качества, хорошие свойства, достоинства.

**Мөхәүвәл** محول *сф.* 1) Күчерелгән. 2) Үзгәртелгән. 3) Йөкләтелгән, тапшырылган. *Мин: „Кызыгызның рәиенә мөхәүвәлдер",— дидем.* (К. Нас.)

*пр. с.* 1) Перенесённый. 2) Изменённый. 3) Возложенный; порученный.

**Мөшабиһ** مشابه *сф.* Охшаган, тиң. *Йөрәк яфрак димез, йөрәккә мөшабиһ яфрактыр.* (К. Нас.)

*пр. д.* Похожий, схожий, подобный.

**Мөшабәһә** مشابهه *кара:* мөшабәһәт.

*см.* Мөшабәһәт.

**Мөшабәһәт** مشابهت *м. III.* Охшашлык, охшаганлык, бертөслелек. *Араларында улган мөшабәһәт бонларның аналы-кызлы улуларыны белдерә иде.* (Г. Габ.)

*м. III.* Сходство, подобие.

**Мөшавир** مشاور *сф.* 1) Киңәшче, киңәш итешүче. 2) Киңәш(кә бәйләнгән).

*пр. д.* 1) Советчик, советник. 2) Совещательный.

**Мөшавәрәт, мөшавәрә** مشاوره، مشاورة *м. III.* Киңәшләшү, бер эшнең ничек эшләнүе турында сөйләшү, бер мәсьәлә турында фикер алышу, конференция, консилиум. *Надан белән мөшавәрәт вә киңәш кылсаң, сиңа зарарга киңәш бирер.* (К. Нас.)

*м. III.* Совещание, конференция, консультация; консилиум.

**Мөшагъ** مشاع *сф.* Фаш булган, беленгән, таралган.

*пр. с.* Разоблачённый, обнародованный, раскрытый.

**Мөшагарә** مشاعره *м. III.* Кара-каршы шигырь әйтешү.

*м. III.* Состязание поэтов, поэтический турнир.

**Мөшар** مشار *сф.* Ымланган, ишарә ителгән, күрсәтелгән.

*пр. с.* Указанный (знаком, кивком).

**Мөшарик** مشارك *сф.* 1) Берәүгә дус булган. 2) Шәрик булган, компаниягә кушылучы. *Мәгыйшәт кайгысында әһле дөнья белән мөшарик булып ...* (К. Нас).

*пр. д.* 1) Находящийся в товарищеских отношениях. 2) Соучастник, компаньон.

**Мөшар иләйһи** مشار اليه *ст.* 1) Югарыда күрсәтелгән. *Әһалине нәфрәт иттермәк өчен мөшар иләйһине „кан түгүче, адәм үтерүче" дия сөйләмешләрдер.* (Ш. ж.) 2) Ым белән күрсәтелгән, ишарә ителгән.

*сс.* 1) Вышеуказанный, указанный. 2) Тот, на кого показали кивком, знаком.

**Мөшарәкәт** مشاركت *м. III.* 1) Катнашу, катнашып эшләү. *Уенга мөшарәкәт итәләр.* (К. Нас.) 2) Уртаклык, компания.

*м. III.* 1) Участие, соучастие. 2) Товарищество; компания; сообщество.

**Мөшарэта** مشارطه *м. III.* Шарт итешү, шарт куешып вәгъдәләшү. — *м. III.* Соглашение, условие, договор.

**Мөшатәмә** مشاتمه *м. III.* Сүгешү, тиргәшү, орышышу. *Мөгатәбә дигәнемез мөшатәмәгә әйләнеп дошманлык керүдер.* (К. Нас.) — *м. III.* Взаимное оскорбление, перебранка.

**Мөшафәһә** مشافهه *м. III.* Әңгәмә, кара-каршы сөйләшү. — *м. III.* Устная речь, беседа, разговор.

**Мөшаһид** مشاهد *сф.* 1) Күз белән күреп торучы. 2) Шаһид, таный. — *пр. д.* 1) Наблюдатель, 2) Очевидец, свидетель.

**Мөшаһәд** مشاهد *сф.* Күз белән күрелгән, таныкланган. — *пр. с.* Наблюдаемый, видимый; свидетельствуемый.

**Мөшаһәдә** مشاهده *м. III.* 1) Күз күреп тору, күрү. *Яңгыр теләп чыгылса да, кабул әсәре мөшаһәдә кылынмады.* (К. Нас.) 2) Шаһид булу, таный булу. — *м. III.* 1) Наблюдение, рассмотрение. 2) Присутствие в качестве очевидца.

**Мөшгыйрь** مشعر *сф.* Хәбәр бирүче; сиздерүче, белдерүче, аңлатучы. *Дөньяга мәел кылмакта зәмне мөшгыйрь булган шигырьләр ...* (К. Нас.) — *пр. д.* Уведомляющий, сообщающий, разъясняющий.

**Мөшир** مشير *сф.* 1) Ымлаучы, ишарә итүче, күрсәтүче. 2) Киңәшче. — *пр. д.* 1) Киваюший (на что-либо), указывающий. 2) Советник.

**Мөшкил*** مشكل *сф.* 1) Читен, кыен, авыр. *Белү мөшкил, кирәк кемне сөяргә!* (Г. Тук.) 2) Читенлек, проблема. — *пр. д.* 1) Трудный, неясный, запутанный. 2) Трудность, проблема.

**Мөшкилят** مشكلات *ис.* Мөшкиләнең *к.* — *мн.* от мөшкилә.

**Мөшкилә** مشكله *ис.* Читенлек, кыенлык; мәсьәлә, проблема. — *сущ.* Трудность; задача, проблема.

**Мөшрик** مشرك *сф.* Мәҗүси, күп аллага ышанучы; ислам динендә булмаучы. *Иске мәхәлләне Мәккә мөшрикләренә охшатып җавап бирде.* (З. Һади). — *пр. д.* Язычник, многобожец; немусульманин.

**Мөшрикә** مشركه *сф.* Мөшрик-нең *мнс.* — *жен.* от мөшрик.

**Мөшрикин** مشركين Мөшрик-нең *к.* — *мн.* от мөшрик.

**Мөштак** مشتاق *сф.* 1) Омтылучы, күрергә теләүче. 2) Сагынучы, җан атып торучы. *Башка бер җирдә авырган кеше үз җире һавасына мөштактыр.* (К. Нас.) — *пр. с.* 1) Сильно желающий, жаждущий, вожделеющий. 2) Скучающий.

**Мөштәгыйл** مشتغل *сф.* Берәр эш белән шөгыльләнүче, эшле кеше, маташучы. — *пр. д.* Занимающийся, занятый.

**Мөштәкат** مشتقات *ис. к. грам.* Бер тамырдан ясалган сүзләр. *Җәмигъ мөштәкаты мөстәгъмәл булучы бер фигыльдән йөзгә кадәр фигыль хасил булыр.* (К. Нас.) — *сущ. мн. грам.* Дериваты, производные слова,

**Мөштәки** مشتکی *сф.* Зарланучы, жалоба бирүче, шикаять итүче. — *пр. д.* Жалобщик.

**Мөштәкъ** مشتق *сф.* Чыгарып алынган, икенче бер нәрсәдән ясалган. — *пр. с.* Производный.

**Мөштәкя** مشتکا *сф.* Зарланылган әйбер, шикаять объекты. — *пр. с.* Предмет, суть жалобы.

**Мөштәмил** مشتمل *сф.* Үз эченә алган, үзенә җыйган, үз эченә сыйдырган. *Сез дәхи мөһлик мәразлар, үзегезне ташлагыз. Барчагызны мөштәмилдер: кайтты истибдад кире.* (Г. Тук.) — *пр. д.* Содержащий, заключающий в себе, включающий.

**Мөштәмәл** مشتمل *сф.* Эченә кергән, эчендә булган, эченә алынган, эченә сыйдырылган. *„Бөстан“ хикмәт вә әдәбләрне мөштәмәл уларак нәзым иле язылмыш бер әсәрдер.* (Ш. ж.) — *пр. с.* Содержимое, содержание, *букв.* содержимый внутри.

**Мөштәмәлят** مشتملات Мөштәмәлнең *к.* — *мн.* от мөштәмәл.

**Мөштәра** مشتری *сф.* Сатып алынган. — *пр. с.* 1. Купленный 2. Покупка, закупка.

**Мөштәри** مشتری *сф.* 1) Сатып алучы, яздырып алучы. *Мөштәриләр булмагач, игълан булса да ярый.* (Г. Тук.) 2) Юпитер (планета). — *пр. д.* 1) Покупатель, покупщик. 2) Юпитер (планета).

**Мөштәрәк** مشترك *сф.* Уртак. — *пр. с.* Общий, совместный.

**Мөштәрәкән** مشترکا *р.* Уртаклашып, кушылып. — *н.* Сообща.

**Мөштәфа** مشتفی *сф.* Шифа тапкан, сәламәтләнгән, авырудан терелгән. — *пр. с.* Выздоровевший, поправившийся после болезни.

**Мөштәһа** مشتها *сф.* Күңел теләгән, күңел тарткан, күңел төшкән. — *пр. с.* Желаемое, предмет желания.

**Мөштәһи** مشتهی *сф.* Күңеле теләүче, күңеле төшүче; аппетиты кузгалучы. — *пр. д.* Желающий, вожделеющий; имеющий аппетит.

**Мөштәһир** مشتهر *сф.* Атказанган, данлы, билгеле. — *пр. д.* Известный, славный; популярный; с хорошей репутацией.

**Мөштәһият** مشتهيات *ис.* Мөштәһинең *к.* *Нәфсебезгә ләззәтләрәк нәрсә малдыр, башка бер мөштәһият түгелдер, дисәләр, наданлыктыр.* (К. Нас.) — *мн.* от мөштәһи.

**Мөшфикъ** مشفق *сф.* Шәфкать итүче, шәфкатьле, аяучы. *Боларның барчасы табибе хазикъ вә насыйхе мөшфикъ кебектер.* (К. Нас.) — *пр. д.* Добрый, сострадательный, мягкосердечный, нежный, мягкий.

**Мөшфиканә** مشفقانه *гф. р.* Шәфкать итүчедәй, шәфкать белән. — *ар.-п. н.* Мягко, нежно, участливо.

**Мөшәббәһ** مشبه *сф.* Охшатылган, шуның төсле дип әйтелгән. — *пр. с.* Уподобляемый, сравниваемый.

**Мөшәддәд** مشدد *сф.* 1) Нығытылган, көчәйтелгән; 2) *грам.* Сүздә бер авазның янәшә ике килүе. *Камәрия хәрефләре әлифлямдан соң мөшәддәд язылмас.* (К. Нас.) — *пр. с.* 1) Укреплённый, усиленный. 2) *грам.* Удвоенный (о согласном).

**Мөшәррәф** مشرف *сф.* Кадерләләнгән; кадерле, хөрмәтле. — *пр. с.* Почтенный, уважаемый.

**Мөшәүвәш** مشوش *сф.* Дулкынланган, борчылган, тәшвишләнгән. *Хәүфе рәҗа белән мөшәүвәш булып җәмаленә дикъкать ителмеш иде.* (К. Нас.) — *пр. с.* Расстроенный, взволнованный, обеспокоенный.

**Мөшәҗҗәр** مشجر *сф.* Ботаклы, агач кебек ботакланган. — *пр. с.* Имеющий разветвления, ветвистый.

**Мөэмин*** مؤمن *сф.* Ышанучы, инанучы; ислам динендәге кеше. — *пр. д.* Верующий; правоверный, мусульманин.

**Мөэмәнен биһ** مؤمن به *ст.* Иман китерә торган нәрсәләр, ышану тиешле нәрсәләр. — *сс.* Объект поклонения, веры.

**Мөэнә** مؤنه *сф.* Берәүне ашатып-эчертеп тору. *Аннан соң Хатәмнең мөэнәсен әмир тарафыннан каралмага әмер бирде.* (К. Нас.) — *пр. с.* Кормление, содержание.

**Мөэнәт** مؤنت *кара:* мөэнә. — *см.* Мөэнә.

**Мөэтәмән** مؤتمن *сф.* 1) Ышанычлы, таянычлы. 2) Ышанган. 3) Куркынычсыз. — *пр. с.* 1) Достойный доверия. 2) Доверенный; верный. 3) Безопасный.

**Мөэтәмәр** مؤتمر *сф.* Конференция, җыелыш, съезд, киңәшмә. — *пр. с.* Конференция; собрание; конгресс, съезд; совещание.

**Мөәҗир** مؤجر *сф.* 1) Арендага бирүче. 2) Яллаучы, хак түләүче. — *пр. д.* 1) Сдающий в аренду, сдающий в наём. 2) Нанимающий.

**Мөяссәр** میسر *сф.* 1) Җиңеләйтелгән, җиңел, җайлы. 2) Җиңел үтәлешле. *Аңар тәрәкъкый күкләренә күтәрелеп карау мөяссәр булмас.* (Г. Тук.) — *пр. с.* 1) Облегчённый, приспособленный; удобный. 2) Легко осуществимый.

**Мөәббәд** مؤبد *сф.* Мәңгелек, гомерлек, чиксез озак заманга сузыла торган. — *пр. с.* Вечный, пожизненный.

**Мөәдди** مؤدی *сф.* 1) Сәбәпче. 2) Алып баручы. *Фисык вә фәсадка, бозыклыкка мөәдди булган нәрсәгә дәлаләт кылмак тәүфикъсызлыктыр...* (К. Нас.) 3) Үтәүче. — *пр. д.* 1) Причиняющий; вызывающий (что-либо). 2) Ведущий. 3) Осуществляющий.

**Мөәддиб** مؤدب *сф.* Әдәп өйрәтүче, тәрбия бирүче. *Син минем мөгаллим вә мөәддибем булдың диде.* (К. Нас.) — *пр. д.* Воспитатель.

**Мөәддәб** مؤدب *сф.* Тәрбияләнгән; әдәпле, тәрбияле. — *пр. с.* Благовоспитанный, образованный; корректный.

**Мөәззин*** مؤذن *сф.* Азанчы, азан әйтүче, мөәзин. — *пр. д.* 1) Призывающий на молитву. 2) Муэдзин.

**Мөәззи** مؤذی *сф. кара:* музи. — *пр. д. см.* Музи.

**Мөәззият** مؤذیات *ис. кара:* музият. — *мн. см.* Музият.

**Мөәййид** مؤید *сф.* Куәт бирүче, ныгытучы, куәтләүче, беркетүче. — *пр. д.* Придающий силы, поддерживающий, усиливающий, укрепляющий.

**Мөәйяд** مؤید *сф.* 1) Куәтләнгән, ныгытылган. 2) Таза; чыдамлы. — *пр. с.* 1) Поддержанный, усиленный. 2) Здоровый; терпеливый.

**Мөәккид** مؤکد *сф.* Куәт бирүче, ныгытучы, кабатлаучы, беркетүче, раслаучы. — *пр. д.* Усиливающий, уверяющий, подтверждающий.

**Мөәкил** مؤکل *сф.* Вәкил итүче. — *пр. д.* Поручающий, доверяющий.

**Мөәккәд** مؤکد *сф.* Ныгытыла (беркетелә, куәтләнә, раслана) торган. — *пр. с.* Подтверждаемый, подкрепляемый; заверяемый.

**Мөәккәл** مؤکل *сф.* Вәкаләт бирелгән, берәр урынга куелган. *Ул ашлык амбарларына мин мөәккәлмен,— диде.* (К. Нас.) — *пр. с.* Облечённый полномочиями, определённый на какую-либо должность.

**Мөэллим** مؤلم *сф.* 1) Авырттыручы, көенеч бирүче, ачындыручы, кайгы салучы. 2) Рәнҗетүче, җәберләүче. — *пр. д.* 1) Причиняющий боль; огорчающий. 2) Мучающий.

**Мөәллиф** مؤلف *сф.* Китап язучы, китап төзүче. *Ул ... тарих әсәренең мөәллифе иде* (Г. Газиз). — *пр. д.* Автор; составитель.

**Мөәлләф** مؤلف *сф.* Язылган, төзелгән; китап. — *пр. с.* Сочинение, произведение; книга.

**Мөәлләфат** مؤلفات *ис.* Мөәлләфнең *к.* — *сущ. мн.* от мөәлләф.

**Мөәммил** مؤمل *сф.* Өмет итүче. — *пр. д.* Надеющийся, ожидающий.

**Мөәннәс** مؤنس *ис. грам.* Хатын җенес. *Әмма телемездә мөәннәслекне белдерүче махсус хәреф юктыр.* (К. Нас.) — *сущ. грам.* Женский род.

**Мөәррих** مؤرخ *сф.* Тарих язучы, тарихчы. *Искәндәр, үзенең фөтухаты, җир шәһәрләр алу белән, мөәррихләр карашында кәбир дип йөртелсә дә куәтле хөкүмәт төзи алмады.* (Х. Чис.) — *пр. д.* Историк.

**Мөәррихин** مؤرخين *ис.* Мөәррихнең *к.* — *сущ. мн.* от мөәррих.

**Мөәррәх** مؤرخ *сф.* Датасы куелган, тарихы күрсәтелгән, елы, ае, көне язылган. — *пр. с.* Датированный.

**Мөәссир** مؤثر *сф.* 1) Тәэсир итүче, тойгыландыручы, йогынты ясаучы. 2) Күңелдә эз калдыручы, йөрәккә үтүче. *Шигырьләрегез гаять мөәссир вә гүзәл.* (М. Гаф.) — *пр. д.* 1) Эффективный, влияющий. 2) Трогательный.

**Мөәссират** مؤثرات *ис.* Мөәссирнең *к.* *Адәмнең бәдәненә мөәссират хариҗәдән саклар өчен...* (К. Нас.) — *сущ. мн.* от мөәссир.

**Мөәссис** مؤسس *сф.* Коручы, төзүче, башлап нигез салучы. — *пр. д.* Основатель, учредитель, основоположник.

**Мөәссиф** مؤسف *сф.* Көендерүче, кайгы салучы. — *пр. д.* Огорчающий.

**Мөәссәр** مؤثر *сф.* Йогынтыланган, тойгыландырылган, йөрәгенә үткән. — *пр. с.* Подверженный влиянию.

**Мөәссәс** مؤسس *сф.* Корылган, төзелгән, нигезләнгән. — *пр. с.* Построенный, основанный, учреждённый.

**Мөәссәсат** موسّسات *ис.* 1) Мөәссәс-нең *к.* 2) Биналар. — *сущ.* 1) *мн.* от мөәссәс. 2) Здания.

**Мөәссәсә** موسّسه *ис.* Оешма, учреждение. — *сущ.* Организация, учреждение, заведение.

**Мөәххәр** موخّر *сф.* 1) Соңга калдырылган, артка калдырылган, кичектерелгән. 2) Акрынайтылган. — *пр. с.* 1) Отложенный, поставленный позади. 2) Замедленный.

**Мөәххәрән** موخّراً *р.* Соңыннан, азактан, соңлатып. — *н.* Позже, потом; впоследствии.

**Мөәүвил** موّول *сф.* Төп мәгънәсе булган сүзгә икенче төрле мәгънә биреп аңлатучы. — *пр. д.* Объясняющий аллегорически.

**Мөәүвәл** موّول *сф.* Башка мәгънәгә әйләндерелгән; күчмә мәгънәдә кулланылган, икенче төрле аңлатылган. — *пр. с.* Объяснённый аллегорически, иносказательно.

**Мөәҗҗәл** موّجل *сф.* Күттерелгән, күтәргә калдырылган, соңга калдырылган, кичектерелгән. — *пр. с.* Отсроченный, отложенный.

**Мөҗаб** مجاب *сф.* 1) Соравы, үтенече кабул ителгән. 2) Соравына җавап алынган. — *пр. с.* 1) Удовлетворённый. 2) Получивший ответ на вопрос.

**Мөҗавабә** مجاوبه *м. III.* Ызгышу, сүз көрәштерү, бәхәсләшү, әрепләшү. — *м. III.* Ссора, перебранка, спор.

**Мөҗавир** مجاور *сф.* 1) Янәшә кеше, күрше. 2) Каберлекләр сакчысы — дәрвиш. — *пр. д.* 1) Соседний, смежный, граничащий. 2) Кладбищенский сторож — дервиш.

**Мөҗавәрәт** مجاورت *м. III.* 1) Күршелек. 2) Дәрвишлек. — *м. III.* 1) Соседство, смежность. 2) Дервишество.

**Мөҗадәлә** مجادله *м. III.* Бәхәсләшү, сүз көрәштерү. *Мөҗадәлә берлә күп адәмнәрне җиңгән.* (З. Һад.) — *м. III.* Спор; распря.

**Мөҗаз** مجاز *сф.* 1) Яраклы, рөхсәт ителгән. 2) Дипломлы (шәһадәтнамәле) кеше. — *пр. с.* 1) Позволенный, разрешённый. 2) Имеющий диплом.

**Мөҗазат** مجازات *м. III.* 1) Җәзалау; җәза. *Интикам вә мөҗазатка көч җитә торып гафу белән мөгамәлә кылмак барча изге холыкларның күркәмидер.* (К. Нас.) 2) Бүләк, яхшылык өчен бирелгән әйбер. — *м. III.* 1) Наказание. 2) Награда.

**Мөҗазәбә** مجاذبه *м. III.* Бер-берсен тартышу. — *м. III.* Перетягивание (друг-друга).

**Мөҗаләсә** مجالسه *кара:* мөҗаләсәт. — *см.* Мөҗаләсәт.

**Мөҗаләсәт** مجالست *м. III.* Утырдаш булу, бергәләп сөйләшеп утыру. *Ибне Габдулла фәкыйрьләр вә мискиннәр белән мөҗаләсәт кылыр иде.* (К. Нас.) — *м. III.* Беседа, заседание.

**Мөҗанис** مجانس *сф.* Бер төрдән, бер төсле, бер җенесле. — *пр. д.* 1) Однородный. 2) Подобный, сходный.

**Мөҗанәбәт** مجانبت *м. III.* Бер якка китү, бер якта тору, саклану, ераклашу, читтә тору, читтә калу. *Һәртөрле фәналыктан мөҗанәбәт итмәк* ﺯ *зрә якь дигәреңезә могавәнәт итегез.* (Ш. ж.) — *м. III.* Устранение, воздержание; уклонение.

**Мөҗанәсәт** مجانست *м. III.* Бер төрлелек, бер төслелек, бер җенеслелек. — *м. III.* Однородность, сходство, подобие.

**Мөҗаһид** مجاهد *сф.* 1) Тырышучы. *Аның өчен мөҗаһидмез алгы сафдан.* (Ак.) 2) Дин өчен көрәшүче. — *пр. д.* 1) Прилагающий усилия; старающийся. 2) Борец за веру.

**Мөҗаһәдә** مجاهده *м. III.* 1) Тырышу, көч кую. *Мәхәббәт әһелләре күп мөҗаһәдә белән нәфесләрене зәхмәт чиктерерләр.* (К. Нас). 2) Дин өчен сугышу. — *м. III.* 1) Старание, усилие. 2) Борьба за веру.

**Мөҗбир** مجبر *сф.* Мәҗбүр итүче, көчләүче; йөкләүче. — *пр. д.* Принуждающий, заставляющий, обязывающий.

**Мөҗбәр** مجبر *сф.* Җәберләнгән, җәбер ителгән, мәҗбүр булган. — *пр. с.* Вынужденный, принуждённый, обязанный.

**Мөҗиб** مجيب *сф.* Сораганга җавап бирүче. *Бән бу бабда мөҗиб сурәте илә түгел, саил сыйфаты илә мәйданга чыгам.* (Ш. ж.) — *пр. д.* Отвечающий.

**Мөҗмәл** مجمل *сф.* 1) Гомуми. 2) Кыска. 3) Аз сүз белән белдерелгән; сводка. — *пр. с.* 1) Суммарный. 2) Краткий. 3) Краткое изложение; сводка.

**Мөҗмәлән** مجملاً *р.* Кыскача, җыеп кына. *Мин сезгә берничәсен мөҗмәлән сөйләп бирим.* (Ш. ж.) — *н.* Сокращённо, вкратце; суммарно.

**Мөҗрим** مجرم *сф.* 1) Җинаятьчел, җинаятькә бәйләнешле булган. 2) Җинаятьче. *Вәзир Зияд бер мөҗримнең башын кисмәккә әмер итте. Ул мөҗрим: минем атам синең күршең иде, синдә хакым бар, диде.* (К. Нас.) — *пр. д.* 1) Преступный. 2) Преступник.

**Мөҗтәмәгъ** مجتمع *сф.* 1) Җыелган, тупланган урын. *Аларда мөҗтәмәгъ һиммәт, фөтувәт.* (Г. Тук.) 2) Җыелыш. 3) Җыелган, тупланган, берләшкән. — *пр. с.* 1) Место собрания, свидания. 2) Собрание. 3) Собранный, сконцентрированный, объединённый.

**Мөҗтәниб** مجتنب *сф.* 1) Бер якка китүче. 2) Сакланучы, тыелучы. — *пр. д.* 1) Уклоняющийся. 2) Воздерживающийся.

**Мөҗтәһид** مجتهد *сф.* 1) Тырышучы, тырышлык күрсәтүче. 2) Дин китаплары буенча яңа хөкемнәр чыгаручы. — *пр. д.* 1) Прилежный, старательный, усердный. 2) Достигший высшей ступени знаний (в богословских науках).

**Мөҗә** مجه *ф. ис.* Керфек. — *пр. сущ.* Ресница.

**Мөҗәгян** (**мөчәгян**) (مچگان)مجگان *ф. ис. к.* Керфекләр. — *п. сущ. мн.* Ресницы.

**Мөҗәддид** مجدد *сф.* 1) Яңартучы, яңа хәлгә әйләндерүче. 2) Яңалык кертүче, новатор. — *пр. д.* 1) Возобновляющий; обновляющий. 2) Новатор.

**Мөҗәддәд** مجدد *сф.* Яңартылган, яңага әйләнгән. *Фикеремез улсын мөҗәддәд, кыл хәзер, искермәсен.* (Г. Тук.) — *пр. д.* Возобновлённый, обновлённый; восстановленный, новый.

**Мөҗәллид** مجلد *сф.* Китап төпләүче. — *пр. д.* Переплётчик.

**Мөҗәлля** مجلا *сф.* Шома, ялтыравыклы (көзге өсте кебек). *Мөҗәлля көзге кебек маңлай өстендә ялтыраган кара сачы...* (К. Нас.) — *пр. д.* 1) Глянцевый, блестящий. 2) Полированный, глазированный.

**Мөҗәлләд** مجلد *сф.* 1) Томланган, төпләнгән, тышланган. 2) Том (китап). — *пр. с.* 1) Переплетённый. 2) Том.

**Мөҗәрриб** مجرب *сф.* Тәҗрибә итүче, сынаучы. — *пр. д.* 1) Испытывающий, подвергающий испытанию. 2) Испытатель.

**Мөҗәррәб** مجرب *сф.* Сыналган, тәҗрибә ителгән. *Җәридә файдасы чукча мөҗәррәбдер бу галәмгә.* (Г. Тук.) — *пр. с.* 1) Испытанный, опытный. 2) Подвергнутый испытанию.

**Мөҗәррәд** مجرد *сф.* 1) Ялангач, шәрә. 2) Катлаусыз, кушымтасыз, саф. 3) Хатынсыз. 4) Ялгызак, ялгыз. *Мөтдәте хәятымда үземә мөҗәррәдлекне касд кылмыш идем.* (К. Нас.) 5) *грам.* Сүзнең тамыр формасы. — *пр. с.* 1) Нагой, обнажённый. 2) Чистый, несмешанный. 3) Холостой. 4) Одиночный, единственный. 5) *грам.* Корень слова.

**Мөҗәррәдат** مجردات *ис.* Мөҗәррәднең *к.* *Дәресләрдә мөҗәррәдат вә көллияткә гаид булган бәхәсләргә нигез хәзерләргә кирәк.* (Ш. ж.) — *мн.* от мөҗәррәд.

**Мөҗәссәм** مجسم *сф.* 1) Гәүдәләнгән, гәүдәсе булган. *Мөҗәссәм бер сафа сез...* (Г. Тук.) 2) Зур, мәһабәт. 3) Артык зурайтылган. 4) *мат.* Геометрик җисем. — *пр. с.* 1) Воплощённый. 2) Телесный. 3) Большой. 4) Преувеличенный. 5) *мат.* Геометрическое тело.

**Мөҗәһһил** مجهل *сф.* Надан калдыручы, наданландыручы, белемсез калдыручы. *Мөгаллим исемле мөҗәһһил вә мөгаффилләр.* (Г. Тук.) — *пр. д.* Насаждающий, невежество, держащий в невежестве.

**Мөҗәүвәф** مجوف *сф.* Эче буш, куыш. — *пр. с.* Пустой, полый.

**Мөҗәүһәр** مجوهر *сф.* Зиннәтләнгән, җәүһәрләнгән, алмаслы. *Бүлмәнең уртасында мөҗәүһәр тәхет өстендә бер мәхбүбә.* (К. Нас.) — *пр. с.* Украшенный драгоценными камнями.

**Мөҗәүһәрат** مجوهرات *ис.* 1) Мөҗәүһәр- нең *к.* 2) Асыл ташлар, кыйммәтле әйберләр. — *сущ.* 1) *мн.* от мөҗәүһәр. 2) Драгоценные камни, драгоценности.

**Мөҗәһһиз** مجهز *сф.* Җиһазлаучы. — *пр. д.* Оборудующий, снаряжающий.

**Мөҗәһһәз** مجهز *сф.* Җиһазланган, җиһазландырылган, бөтен кирәге булдырылган, әзерләнгән. *Аләте хәрбия белән мөҗәһһәз гаскәр тулы иде.* (К. Нас.) — *пр. с.* Снаряжённый, оборудованный; подготовленный, готовый.

**Мөһадәнәт** مهادنت *м. III.* Килешү, дуслашу. — *м. III.* Перемирие, установление дружеских отношений.

**Мөһаҗат** مهاجات *ис. к.* Бер-береннән көлү, мәсхәрә итешү. — *сущ. мн.* Насмешка; сатира.

**Мөһаҗим** مهاجم *сф.* Һөҗүм итүче. *Хикмәт, кимия, һәйәт, тарих кеби голуме җәдидәе белмәдекләреннән мөһаҗимләрә каршы агыз ачмаслар.* (Р. Фәх.) — *пр. д.* Нападающий, наступающий, атакующий.

**Мөһаҗир** مهاجر *сф.* Күчүче, башка җиргә күчүче, чит илгә күчеп баручы. — *пр. д.* 1) Переселяющийся, эмигрирующий. 2) Переселенец, эмигрант.

**Мөһаҗирин** مهاجرين *ис.* 1) Мөһаҗир-нең *к.* 2) Мөхәммәт белән Мәккәдән Мәдинәгә күчүчеләр. — *сущ.* 1) *мн.* от мөһаҗир. 2) Переселившиеся вместе с Мухаммедом из г. Мекки в г. Медину.

**Мөһаҗәмә** مهاجمه *м. III.* Һөҗүм итешү. *Салибиюн вә миссионерлар мөһаҗәмәләрне хәтергә төшереп һәми-* — *м. III.* Нападение, налёт.

*шә дошманлык дәвам итүгә хезмәт кылалар.* (Ш. ж.)

**Мөһаҗәрәт** مهاجرت *м. III.* Икенче бер җиргә күчеп бару, үз илен ташлап читкә күчеп китү. — *м. III.* Переселение, эмиграция.

**Мөһиб** مهيب *сф.* Куркынычлы, хәтәр. — *пр. д.* Ужасный, страшный.

**Мөһим*** مهم *сф.* Әһәмиятле, мөһим, бик кирәкле, ашыгыч кирәкле. — *пр. д.* Важный, значительный, серьёзный.

**Мөһиммат** مهمات *ис. к.* 1) Әһәмиятле эшләр. 2) Җайланмалар, кирәкле әйберләр. — *сущ. мн.* 1) Важные дела. 2) Приспособления, принадлежности, снаряжение, материалы.

**Мөһиммә** مهمه *ис.* Бурыч ителгән эш, әһәмиятле, кирәкле, мөһим эш. — *сущ.* Задание, задача, миссия, важное дело.

**Мөһлик** مهلك *сф.* Һәлакәт (үлем) китерүче, һәлак итүче, үлемгә (һәлакәткә) сәбәп булучы, хәтәр. *Сез дәхи мөһлик мәразлар үзегезне ташлагыз.* (Г. Тук.) — *пр. д.* Губительный, гибельный, смертельный, опасный.

**Мөһликә** مهلكه *кара*: мөһлик. — *см.* Мөһлик.

**Мөһләт** مهلت *ис.* Кичектереп тору, кичектерергә рөхсәт бирү, срокны кичектерү. *Следователь хозурына барсаң, һич тә мөһләт вирмәенчә, хәбесханәя юлламасы бәдиһидер.* (З. Биг.) — *сущ.* Отсрочка, льгота.

**Мөһмәл** مهمل *сф.* 1) Ташланган, буш. 2) Мәгънәсез (сүз). 3) Каралмаган, күзәтелмәгән. 4) *грам.* Ноктасыз хәреф. — *пр. с.* 1) Брошенный, пустой. 2) Бессмысленное слово. 3) Оставленный без надзора. 4) *грам.* Арабская буква без точки.

**Мөһмәлят** مهملات *ис. к.* 1) Буш, мәгънәсез сүзләр. 2) Ташландык, кирәксез, файдасыз нәрсәләр. *Яшь гомерләр мөһмәлят чәйнәп була монда һәляк.* (Г. Тук.) — *сущ. мн.* 1) Абсурдные, лишённые смысла слова. 2) Ненужные, бесполезные вещи.

**Мөһер*** مهر *ф. ис.* Печать, штамп. — *п. сущ.* Печать, штамп.

**Мөһердар** مهردار *ф. ис.* Идарәнең печатен саклап, кәгазьгә печать басып торучы. — *п. сущ.* Хранитель печати.

**Мөһер муми** مهرموى *ф. ис.* Сургыч. — *п. сущ.* Сургуч.

**Мөһтәди** مهتدى *сф. дини* Туры юлга төшүче; ислам динен кабул итүче. — *пр. д. рел.* Обратившийся на правый путь, принявший ислам.

**Мөһәззиб** مهذب *сф.* 1) Төзәтүче, юлга салучы. 2) Тәрбияче. — *пр. д.* 1) Исправляющий. 2) Воспитатель.

**Мөһәззәб** مهذب *сф.* 1) Төзек, төзелгән, юлга төшкән. 2) Тәрбияләнгән, культуралы. — *пр. с.* 1) Исправленный. 2) Воспитанный, культурный.

**Мөһәййиэ** مهيئ *сф.* Хәзерләүче. — *пр. д.* Готовящий, приготовляющий.

**Мөһәйяэ** مهيأ *сф.* Әзер, кирәк нәрсәләре хәзерләнгән, әзерләнгән. *Әсбабе сәфәр мөһәйяэдер, диде.* (К. Кас.) — *пр. с.* Готовый, приготовленный.

**Мөһәндис** مهندس *сф.* Инженер; җир үлчәүче; геометрияне белеп, аның белән эш итүче. *Мөһәндис барлыгын мөнкир Печән базарына барсын.* (Г. Тук.) — *пр. д.* Инженер; землемер.

**Мөһәндисә** مهندسه Мөһәндис-нең *мнс.* — *жен.* от мөһәндис.

**Мөһәлләл** مهلل *сф.* Яңа туган ай төсле ителгән; ай сурәтенә кертелгән. — *пр. с.* Имеющий форму полумесяца, серповидный.

**Мөһүр** مهور *ис.* Мәһәр-нең *к.* — *мн.* от мәһәр.

**Мүдигъ** مودع *сф.* Әманәт итеп бирүче, әманәт тапшыручы. *Мүдигъ, ягъни әманәт иясе, сүземдә тогры булсам, зәнҗирне миңа якын кыл, дип зәнҗиргә кулын сузды.* (К. Нас.) — *пр. д.* 1. Сдающий, отдающий в залог, доверяющий. 2. Вкладчик.

**Мүдәгъ** مودع *сф.* Әманәт саклаган кеше, әманәт саклаучы. *Мүдәгъ таякны, тотып тор дип, мүдигъ кулына бирде.* (К. Нас.) — *пр. с.* Берущий что-либо на хранение.

# Н

**Н** — ن. Татар әлифбасында 14 нче, гарәп әлифбасының егерме бишенче хәрефе булып, сан урынында кулланылганда 50 гә йөри. — 14-я буква татарского, 25-я буква арабского алфавита, цифровое значение — 50.

**На** نا *ф.* Юклыкны белдерүче *-ма, -мә, -сыз, -сез* һәм *түгел* урынында йөри торган префикс. — *п.* Частица отрицания, соответствует русской частице *не*, приставкам *без-, бес-* и предлогу *без.*

**На ашна** نا آشنا *ф. с.* Таныш түгел, дус түгел, әшнә түгел. — *п. прил.* Незнакомый, неблизкий.

**Наб** ناب *ф. с.* Ачык, үтә күренмәле; саф. — *п. прил.* Чистый, беспримесный, несмешанный.

**Набит** نابت *сф.* Җирдә үсүче, җирдә үсә торган, шытып чыгучы. — *пр. д.* Растущий, прорастающий.

**Набина** نابينا *ф. с.* Сукыр, тума сукыр. — *п. прил.* Слепой, незрячий.

**Набиз** نابض *сф.* Пульс (тамыр) типкән кебек ритмлы хәрәкәтләнүче. — *пр. д.* Пульсирующий.

**Набизә** نابضه *ис.* Пульс, тибә торган тамыр. — *сущ.* Пульс.

**Набуд** نابود *ф. с.* Юк ителгән, югалган, булмаган. *Хасид бәласыны табып яман хаљь үзә набуд булды.* (К. Нас.) — *п. прил.* Уничтоженный, исчезнувший, несуществующий.

**Навәк** ناوك *ф. ис.* Ук. *Орыр нәркисләр навәкне җанга.* (Хорәз.) — *п. сущ.* Стрела.

**Нагыйм** ناعم *сф.* 1) Сөяксез, йомшак. 2) Вак. — *пр. д.* 1) Мягкий, нежный. 2) Мелкий.

**На гыйлаж** ناعلاج *гф.* Чарасыз. *Атам вафатыннан соң на гыйлаҗ сәфәр мәшәкатьләрен илтизам иттем.* (К. Нас.) — *ар. -п. прил.* Неизбежный, вынужденный.

**Нагяһ** ناگاه *ф. р.* 1) Вакытсыз, көтелмәгәндә. 2) Аңсыздан. — *п. н.* 1) Внезапно, неожиданно. 2) Нечаянно.

**Нагяһан** ناگهان *ф. р.* Көтелмәгәндә, аңсыздан, кинәттән. *Нагяһан бер сахрая ирештеләр.* (Г. Тук.) — *п. н.* Внезапно, неожиданно.

**Надан*** نادان *ф. с.* 1) Укый-яза белмәүче. 2) Белемсез. — *п. прил.* 1) Неуч. 2) Невежда.

**Нади** نادى *сф.* 1) Чакыручы, кычкырып чакыручы. 2) Мөәзин. — *пр. д.* 1) Глашатай; зовущий. 2) Муэдзин.

**Надидә** ناديده *ф. с.* 1) Күрелмәгән, охшашы булмаган, сирәк очрый торган. Һәр җирдә табылмый торган. 2) Күрмәгән. — *п. прил.* 1) Бесподобный, невиданный. 2) Невидевший.

**Надим** نادم *сф.* Үкенүче, үкенгән. *Борынгы уйкуларны дөшенүбән улалым надим.* (Г. Тук.) — *пр. д.* Раскаивающийся; сожалеющий о чем-либо.

**Надир** نادر *сф.* Сирәк очрый торган, сирәк. *Безнең күңелләр үзең яраткан надир мәгъбүдләр – матур җаннар каршысында сәҗдә итәргә тели.* (Г. Ибр.) — *пр. д.* Редкостный, редкий.

**Надират** نادرات Надир-нын *к.* — *мн.* от надир.

**Надирелвөҗүд** نادرالوجود *гыйб.* Сирәк табыла (сирәк очрый) торган нәрсә, бердәнбер. *Җирне ислах кылу өчен, кош тизәге бездә надирелвөҗүд нәрсә булганлыктан ....* (К. Нас.) — *фр.* Редкость, редко встречающаяся вещь.

**Надирә** نادره 1) Надир-ның *мнс.* *Тукта бу ике надирәи җиһанны уяулыкта бер-беренә күрсәтәек...* (К. Нас.) 2) Анекдот, көтелмәгән хәл. — 1) *жен.* от надир. 2) Анекдот, необыкновенный случай.

**Надирәдан** نادره‌دان *гф. ис.* Кызыклы хикәяләр белүче. — *ар.- п. сущ.* Знаток анекдотов, смешных историй.

**Наз** ناز *ф. ис.* 1) Иркәлек, үзен сөйдерү өчен эшләнгән кыланыш. 2) Боргалану-сыргалану. *Наз итәр кемнәргә гөл, каршында былбыл булмаса.* (Г. Тук.) — *п. сущ.* 1) Нега, ласка. 2) Каприз.

**Назек** نازك *кара:* назик. — *см.* Назик.

**Назеки, назики** نازكی *ф. ис.* 1) Нечкәлек. 2) Гүзәллек. 3) Нәфислек. — *п. сущ.* 1) Тонкость. 2) Нежность, мягкость, деликатность. 3) Изящество, грациозность.

**Назик** نازك *ф. с.* 1) Нәзек, нечкә. 2) Гүзәл. 3) Нәфис. *Тупас кабыкларын салгач, иң гади ләззәтләргә, иң назик тойгыларга юл ачылмасмыни.* (Ф. Әмир.) — *п. прил.* 1) Тонкий. 2) Нежный, мягкий, деликатный. 3) Изящный.

**Назил** نازل *сф.* 1) Югарыдан түбәнгә төшүче. 2) Күктән төшүче, инүче. — *пр. д.* 1) Сходящий, спускающийся. 2) Нисходящий.

**Назмән** نظماً *р.* Тезмә рәвештә. *Назмән вә нәсрән язмакым вәгъдә идәрем.* (Г. Тук.) — *н.* Рифмованно, стихом.

**Назнин** نازنين *ф. с.* Иркә, назлы, сөекле, нәфис. *„Шундаен гүзәл вә назнин", дип, ул кызның мәдхен бәян кылгач...* (К. Нас.) — *п. прил.* Нежный, деликатный, изящный.

**Назурә** ناظوره *ис.* Телескоп; бинокль. *Газета вә мәҗмуга битләрен тәзәйен иткән каләмнәр укучыларга бер назурә хезмәтен кылалар.* (Ш. ж.) — *сущ.* Телескоп, бинокль.

**Назыйм** ناظم *сф.* 1) Тәртипкә (рәткә) салучы. 2) Тезмә әсәр язучы, шагыйрь. *Шулай ук һичбер назыйм... тукмак эзләмәс.* (Г. Тук.) — *пр. д.* 1) Организующий, приводящий в порядок. 2) Организатор; устроитель. 3) Стихотворец.

**Назыйр** ناظر *сф.* 1) Караучы, күрүче. 2) Идарә башында торучы, мөдир. 3) Министр. — *пр. д.* 1) Смотрящий, наблюдающий. 2) Заведующий. 3) Руководитель учреждения. 4) Министр.

**Назыйрә** ناظرة *сф.* 1) Назыйр-ның *мнс.* 2) Электә булган шигырьгә ошатып язылган шигырь. — *пр. д.* 1) *жен.* от назыйр. 2) Подражание в стихосложении.

**Наиб** نائب *сф.* Урынбасар. *Алты чын әгъза, дүрт наибдән гыйбарәт химая комитетының ашыгыч җыелышы булды.* (Г. Ибр.) — *пр. д.* 1) Замещающий. 2) Наместник, заместитель.

**Наил** نائل *сф.* Ирешә торган, ирешә алган; ирешүче. ... *Һичбер төрле игътибарга наил булмады.* (Ф. Әмир.) — *пр. д.* Достигающий, постигающий, добивающийся.

**Наим** نائم *сф.* Йоклаучы, йоклап ятучы. — *пр. д.* Спящий.

**Наимә** نائمه Наим-нең *мнс.* — *жен.* от Наим.

**Наинсаф** ناانصاف *гф. р.* Инсафсыз. *Һәй, бәдбәхет наинсаф, мин сине кыйммәт бәһа биреп сатып алдым.* (К. Нас.) — *ар.-п. н.* Несправедливый.

**Наихә** نائحه *сф.* Үлек артыннан елап баручы хатын, профессиональ елаучы, ялланып елаучы. *Бер галим сазәндә бер галимә наихәне никяхлады.* (К. Нас.) — *пр. д.* Профессиональная плакальщица.

**Най** نای *кара:* нәй. — *см.* Нәй.

**Накабил** ناقابل *ф. ст.* Көчсез, көче җитмәүче, булдыра алмаучы. — *п. сс.* Бессильный, слабый, неспособный.

**Накихә** ناكحه *ис.* Никяхлы хатын. — *сущ.* Женщина, вступившая в законный брак.

**Накус** ناقوس *ис.* Кыңгырау, чаң. *Санки гыйшкың бер кәлисә, бән аның накусием.* (Г. Тук.) — *сущ.* Звонок, колокол.

**Накыйль** ناقل *сф.* 1) Бер җирдән икенче җиргә күчүче. 2) Бер хәбәрне икенче кешегә сөйләүче. — *пр. д.* 1) Переезжающий с места на место. 2) Передающий, пересказывающий.

**Накыйлян** ناقلان *гф. ис.* Накыйль-нең *к.* *Накыйлян дөрренисар шундак риваять вә мондаг хикаять кылырларкем...* (Э. У. К.) — *ар.-п. сущ. мн.* от накыйль.

**Накыйс** ناقص *сф.* 1) Ким, кыска, тулы түгел, тәмам түгел. 2) *мат.* Алу билгесе, минус. — *пр. д.* 1) Недостающий, неимеющийся, недостаточный, дефективный, несовершенный, неполный. 2) *мат.* Знак вычитания, минус.

**Накыйсә, накыйсәт** ناقصه، ناقصة Накыйс -ның *мнс. Фәтхулла хәзрәт: „Хатыннар алар накыйсателгакыл вә дин" — дип, үзләрен орыша иде.* (Ф. Әмир). — *жен.* от накыйс.

**Накярә** ناكاره *ф. с.* 1) Файдасыз, бер эшкә яраксыз. 2) Эшлексез, ялкау. — *п. прил.* 1) Непригодный. 2) Ленивый, бездельничающий.

**Накәс, нәкәс** ناكس *ф. с.* Кешелексез, түбән, әшәке; тупас; саран. *Бу мәсәлдер: нәкәс аслыннан качар.* (Мөхм.) — *п. прил.* Негодяй, низкий, подлый, грубый; жадный.

**Накәси** ناكسى *ф. ис.* Түбәнлек, кешелексезлек. — *п. сущ.* Низость, подлость.

**Налаекъ** نالايق *гф. с.* Лаек түгел, яраклы түгел, лаек булмаган. — *ар. -п. прил.* Недостойный, неподобающий.

**Налан** نالان *ф. с.* Елаучы, үксүче, ыңгырашучы. — *п. прил.* Стонущий, испускающий стоны.

**Налиш** نالش *ф. с.* Ыңгырашу, елау, үксү, үксеп елау. *Нәдер, шагыйрь, кәчәр һәр анлари налишлә әзманың.* (Г. Тук.) — *п. прил.* Вопль, стон, рыдание.

**Налә** ناله *кара:* налиш. — *см.* Налиш.

**Нам** نام *ф. ис.* 1) Исем, ат. *Язылыр, ихтимал, алтынлә намың.* (Г. Тук.) 2) Дан, шөһрәт. — *п. сущ.* 1) Имя, название. 2) Слава, известность, репутация.

**Намаз*** نماز *ф. ис.* Намаз, көндәлек гыйбадәт. — *п. сущ.* Молитва.

**Намдар** نامدار *ф. с.* Атаклы, шөһрәтле, мәшһүр. — *п. прил.* Известный, прославленный, знаменитый.

**Намзәд** نامزد *ф. ис.* 1) Ярәшкән, өйләнешергә вәгъдәләшкән. 2) Кандидат. *... намзәдләр биш вә алты нәфәрдән гыйбарәт иде.* (Ш. ж.) — *п. сущ.* 1) Обрученный (жених, невеста). 2) Кандидат.

**Намиһербан** نامهربان *ф. с.* Миһербансыз, шәфкатьсез, сөйкемсез, мәхәббәтсез. — *п. прил.* Нелюбезный, немилостивый; неприятный.

**Намуафикъ** ناموافق *гф. с.* Яраксыз, муафыйк түгел. — *ар.-п. прил.* Несоответствующий, несогласный.

**Намус*** ناموس *ис.* 1) Йөз суы, абруй, вөждан. 2) Канун, кагыйдә. *Тор! рәхәтлән: кәп-кәкрене туры дисәң, истибдадның намусына тукынмасаң.* (Г. Тук.) 3) Сафлык, пакьлек, гыйффәтлелек. — *сущ.* 1) Честь, достоинство, репутация. 2) Закон, основоположение. 3) Чистота, целомудрие, 4) Позор, бесчестье.

4) Хурлык, рисвайлык. *Харис мине талак итсә, холыксызлыгыннан итәр, ул җәһәттән миңа намус булмас.* (К. Нас.)

**Намускяр** ناموسكار *гф. с.* Намуслы (кеше). — *ар.-п. прил.* Честный (человек).

**Намә** نامه *ф. ис.* Хат, язылган нәрсә; китап. — *п. сущ.* Письмо, грамота; книга.

**Намәгъдүд** نامعدود *гф. с.* Саналмый торган, санга алынмый торган, чиксез күп. — *ар.-п. прил.* Бесчисленный, неисчислимый, несметный.

**Намәгъкуль** نامعقول *гф. с.* Акылга сыймый торган, акылга муафыйк булмаган. — *ар.-п. прил.* Непостижимый, невероятный, абсурдный, бессмысленный.

**Намәгълүм** نامعلوم *гф. с.* Билгесез, беленмәгән, билгеле булмаган, мәгълүм түгел. *„Жан тынычланды" димә булганга малда артыгың, артык ул, алганга намәгълүм гарипләр актыгын.* (Г. Тук.) — *ар.-п. прил.* Безызвестный, неизвестный.

**Намәгъруф** نامعروف *гф. с.* Беленмәгән, танылмаган. — *ар.-п. прил.* Неизвестный, неузнанный.

**Намәкъбүл** نامقبول *гф. с.* Кабул ителми торган, кабул ителмәгән. — *ар.-п. прил.* Неприемлемый, непринятый.

**Намәрд** نامرد *ф. с.* 1) Кешелексез. 2) Яхшылыкны белмәгән. 3) Куркак. 4) Бәдбәхет, түбән кеше. — *п. прил.* 1) Низкий. 2) Неблагодарный. 3) Трус. 4) Негодяй, подлец.

**Намәсмуг** نامسموع *гф. с.* Ишетелмәгән. — *ар.-п. прил.* Неслыханный.

**Намәхдүд** نامحدود *гф. с.* Чикләнмәгән, чиге булмаган. — *ар.-п. прил.* Неограниченный.

**Намәхрәм*** نامحرم *гф. с.* Ерак кардәш һәм бөтенләй кардәш булмаган кеше (шәригать буенча өйләнешергә ярый торганнар). *Монда чыккач, Хәят та иркенләп утыра ала башлады, чөнки намәхрәмнәр күренмиләр иде.* (Ф. Әмир.) — *ар.-п. прил.* 1) Дальний родственник, посторонний. 2) *букв.* „Не запрещённый" (религией для женитьбы).

**Намәшруг** نامشروع *гф. с.* Шәригатьтә булмаган, шәригатьчә булмаган, шәригатькә сыймаган. — *ар.-п. прил.* Незаконный, противозаконный (не по шариату).

**Намөвәҗҗә** ناموجه *гф. с.* Буш, нигезсез, кабул итмәслек, игътибарга алмаслык. *Дусларыңны һәляк базына ташларсың да вафа дәгъва кылып, на-* — *ар.-п. прил.* Неосновательный, безосновательный, неприемлемый.

*мөвәҗҗә гозерләр күрсәтергә башларсың.* (Г. Фәез.)

**Намөляим** ناملايم *гф. с.* Ягымсыз, дорфа. — *ар.-п. прил.* Неприятный, грубый.

**Намөмкин** ناممكن *гф. с.* Мөмкин булмаган, мөмкин түгел. — *ар.-п. прил.* Невозможный, невероятный.

**Намөнасиб** نامناسب *гф. с.* Ятышсыз, килешми торган. — *ар.-п. прил.* Неподходящий.

**Намөтәнаһи** نامتناهى *гф. с.* Чиге булмаган, чиксез. — *ар.-п. прил.* Беспредельный, бесконечный.

**Нан** نان *ф. ис.* 1) Икмәк. 2) Берәүдән күргән хөрмәт, сый. *Миңа һәр көн бирә ул аш вә нани.* (Г. Тук.) — *п. сущ.* 1) Хлеб. 2) Угощение.

**Нанкүр** نانكور *ф. с.* Хөрмәт (сый) кадерен белмәүче, яхшылыкның кадерен белмәүче. — *п. прил.* Неблагодарный.

**Напайдар** ناپايدار *ф. с.* Тотрыксыз, ныклыксыз, эзлексез. — *п. прил.* Неустойчивый, непрочный, непоследовательный.

**Напаки** ناپاكى *ф. ис.* Чиста булмау, пычраклык, арусызлык. — *п. сущ.* Нечистоплотность.

**Напакь** ناپاك *ф. с.* 1) Чиста булмаган; таза (пакь) булмаган, шакшы, пычрак, арусыз. 2) Күрем күрүче хатын. — *п. прил.* 1) Нечистый, грязный. 2) Менструирующая (женщина).

**Напәрва** ناپروا *ф. с.* Пәрвайсыз, куркусыз, саксыз; тартынусыз. — *п. прил.* 1) Беспечный, безбоязненный; неосторожный. 2) Безбоязненно.

**Напәсәнд** ناپسند *ф. с.* 1) Урынсыз, кабул ителерлек булмаган. 2) Килешсез, яраксыз. *Әгәр йөз напәсәнд эш кылса дәрвиш...* (Дәрд.) — *п. прил.* 1) Неуместный, неподобающий. 2) Неодобрительный. 3) Недоброкачественный.

**Нар I** نار *ис.* 1) Ут, ялкын. 2) Тәмугъ. — *сущ.* 1) Огонь, пламя. 2) Ад.

**Нар II** نار *ф. ис.* Анар жимеше. — *п. сущ.* Гранат.

**Нар III** نار *ис.* Тәвәнең бер төре. — *сущ.* Название породы верблюдов.

**Наразый** ناراضى *гф. с.* Разый булмаган, риза булмаучы, канәгатьләнмәүче. — *ар.-п. прил.* Недовольный, неудовлетворённый.

**Нараси*** ناراسى *ф. кара:* нарасидә. — *п. см.* Нарасидә.

**Нарасидә** ناراسيده *ф. ис.* 1) Житешмәгән, өлгермәгән. 2) Нарасый, сабый бала. — *п. сущ.* 1) Незрелый, неспелый. 2) Ребёнок.

**Нараст** ناراست *ф. с.* 1) Гадел түгел, дөрес түгел, туры түгел, дөрес булмаган. 2) Гаделсезлек белән, урынсыз. — *п. прил.* 1. Несправедливый, неправильный, неверный. 2. Несправедливо, неправильно, неверно.

**Наргилә** نارگله *ф. ис.* Хурхур, кальян (төтенен су аркылы үткәрә торган тәмәке тарту коралы). — *п. сущ.* Наргиле (особая трубка для курения табака, дым в ней пропускается через воду).

**Нариять** ناريت *ис.* Утка караганлык. *Алтын сары төсле мәгъдәндер, сарылыгы нариятьтәндер.* (К. Нас.) — *сущ.* Огненный, огневой, относящийся к огню.

**Нароу** نارو *ф. с.* Йөрми торган (акча); үтми торган, үтемсез (товар); эшкә яраксыз, эштән, гамәлдән чыккан. *Врангель армиясе калдыгы бу көндә һичбер мәмләкәттә үзенә тору урны таба алмыйча нароу сәргәрдан булып качкын хәлендә йөри.* (Ф. Әмир.) 2) Алдау, алдаучылык, кәкре каенга терәү, тишек чуманга утырту. — *п. прил.* 1) Неходячий (монета), неходкий (товар). 2) Обман, надувательство.

**Нары гыйшык** نارعشق *ст.* Гыйшык уты, мәхәббәт ялкыны. — *сс.* Огонь любви.

**Нарәва** ناروا *ф. с.* Рөхсәт ителмәгән; яраклы түгел, туры килмәгән, кабул ителерлек булмаган. — *п. прил.* Недозволенный, неподобающий, неприемлемый.

**Нас** ناس *ис.* Инсан -ның *к. Гаваме настан ике адәм мөкяләмә кылышып утырганда...* (К. Нас.) — *сущ. мн.* от инсан.

**Насаваб** ناصواب *гф. с.* Ялгыш, дөрес булмаган, туры булмаган, хаксыз, хата. — *ар.-п. прил.* 1. Несправедливый, неправильный, ошибочный. 2. Несправедливо, неправильно, ошибочно.

**Насаз** ناساز *ф. с.* 1) Ятышсыз, мөнәсәбәтсез. 2) Килешсез, әдәпсез. — *п. прил.* 1) Нестройный, несогласный. 2) Непристойный, неприличный.

**Насаф** ناصاف *гф. с.* Саф түгел, катыш. — *ар.-п. прил.* Нечистый, смешанный.

**Наси** ناسى *сф.* Онытучы. — *пр. д.* Забывающий.

**Насир** ناثر *сф.* Чәчмә стильдә язучы. *Фәхрелислам ярты назыйм, ярты хәзин, ярты имам, ярты нашир, ярты насир, бәхте киткән яртыдан.* (Ш. Баб.) — *пр. д.* Прозаик.

**Насих** ناسخ *сф.* 1) Юкка чыгаручы, юк итүче. *Кайсы мәнсух, кайсы на-* — *пр. д.* 1) Уничтожающий, отменяющий. 2) Пе-

*сих? ансын инде син аер.* (Ш. Баб.) 2) Күчереп язучы. — реписчик.

**Насут** ناسوت *ис.* Кешелек, кешелек табигате. — *сущ.* Человечность, человеческая природа.

**Насыйб** ناصب *сф.* 1) Бер җиргә утыртып куючы, кадаучы. 2) Хезмәт урынына билгеләүче. — *пр. д.* 1) Водружающий, ставящий. 2) Назначающий (на службу).

**Насыйр** ناصر *сф.* 1) Ярдәм бирүче. 2) Ярдәмче, яклаучы. — *пр. д.* 1) Помогающий. 2) Помощник, защитник.

**Насыйх** ناصح *сф.* Нәсихәт итүче, вәгазьләүче, үгетләүче, яхшылыкка өндәүче. *Үзендә юк сыйфатын кешегә нәсыйхәт иткән насыйхлар хакында әйтелер.* (К. Нас.) — *пр. д.* 1) Наставляющий, увещевающий. 2) Наставник; советчик.

**Насыйханә** ناصحانه *гф. р.* Үгетләүчедәй, яхшы киңәш бирүчедәй, үгетләүче булып. — *ар.-п. н.* Подобно советчику, наставнику.

**Насыя, насыять** ناصيه، ناصية *ис.* 1) Маңгай; йөз, бит. 2) Тышкы күренеш. — *сущ.* 1) Лоб, чело; лицо. 2) Внешний вид, наружность.

**Натыйк** ناطق *сф.* Сөйләүче, фикер йөртүче, акыл иясе. *Адәмнең нәфсе әммарәсе адәмгә зиядә дошман икәнен натыйктыр.* (К. Нас.) — *пр. д.* Говорящий, рассуждающий; разумный.

**Натыйка** ناطقه *ис.* Сөйләү куәте, ягымлы һәм ышандырырлык итеп сөйләү. — *сущ.* Дар речи, красноречие.

**Натәван** ناتوان *ф. с.* Көчсез, куәтсез, тәкатьсез. — *п. прил.* Немощный, слабый.

**Натәмам** ناتمام *гф. с.* Бетмәгән, тәмам булмаган. — *ар.-п. прил.* Неоконченный, неполный.

**Нафи** نافى *сф.* 1) Бер урыннан икенче урынга сөрүче, сөргенгә җибәрүче. 2) Юкка чыгаручы, танымаучы, каршы килүче. — *пр. д.* 1) Высылающий, изгоняющий. 2) Отрицающий, отвергающий, противоречащий.

**Нафигъ** نافع *сф.* Файдалы, файда китерүче. *Дару өчен чәчәк ата башлаганчы җыялар, һәзым вә иштиһаи тәгам өчен нафигъдыр.* (К. Нас.) — *пр. д.* Полезный.

**Нафига** نافعه Нафигъ-ның *мнс.* — *жен.* от нафигъ.

**Нафиз** نافذ *сф.* 1) Сүзе үтә торган. *Ушбуның өчен сүзләре нафиз вә кадерләре бәләнд улан әсхабе кирам бигать бирделәр.* (Ш. ж.) 2) Эчкә керә — *пр. д.* 1) Влиятельный. 2) Проникающий через что-либо, проходящий.

(сеңә) торган, тишеп үтә торган, үтемле.

**Нафилә** نافله *сф.* 1) Буш, кирәксез, тиешсез, файдасыз. *Тырышма нафилә җиргә, вакыт гаҗзеңне икърарга.* (Г. Тук). 2) *дини* Фарыз һәм вәҗип булмаган эш, гыйбадәт. 3) Бирелгән әйбер, бүләк. — *пр. д.* 1) Ненужный, бесполезный. 2) *рел.* Дополнительное действие (сверх обязательств). 3) Дар, подарок.

**Нафия** نافيه *сф.* Юкка чыгаручы. *Җөмләи нафия* — юклык җөмлә. *Җөмләи нафиядә нәфи хәрефе „түгел“ кәлимәсе мөстәгъмәлдер.* (К. Нас.) — *пр. д.* Отрицательная; отрицающая.

**Нафә** نافه *ф. ис.* 1) Кабарганың мускус бизе. 2) Кендек. *Нәфис ак ефәктән тукылмыш кебек мөлаем кәрсакта ак фил тешеннән ясалган гөл мае савыты кебек нафәсе бар.* (К. Нас.) — *п. сущ.* 1) Мускусная железа кабарги. 2) Пуп.

**Нахак*** ناحق *гф. ст.* 1) Хаксыз, хаклык белән булмаган. 2) Ялган, яла, урынсыз. *Шагыйрь булып йөрүләрем... бөтенләй үк нахак имеш.* (Г. Тук.) — *ар.-п. сс.* 1) Несправедливый, незаконный. 2) Клевета, ложь, фальшь.

**Нахаһ** ناخواه *ф. ст.* Теләмичә, ирексездән. — *п. сс.* Невольно, нежелая.

**Нахия** ناحيه *ис.* Административ бүлек; өлкә, провинция, төбәк; район. — *сущ.* Административная единица; область, провинция; район.

**Нахуш** ناخوش *ф. ст.* 1) Яхшы булмаган, хуш булмаган, начар, яман. 2) Кәефсез, күңелсез. *Бер көн утырып үз катымда нахуш.* (Мөхм.) — *п. сс.* 1) Нехороший; плохой; вредный. 2) Невесёлое, плохое настроение.

**Нахушнуд** ناخوشنود *ф. с.* Күңелсез, шат түгел, ризасыз. — *п. прил.* Невесёлый, недовольный.

**Нахын** ناخن *ф. ис.* Тырнак. — *п. сущ.* Ноготь, коготь.

**Нахәлял** ناحلال *гф. ст.* Тыелган, дөрес булмаган. *Имам улып, хәйләи шәргый вә нахәлял кәсепләр кылып...* (З. Биг.) — *ар.-п. сс.* Запрещённый.

**Начар** ناچار *ф. с.* 1) Чарасыз, ирексез, чарасы булмаган. *Начар аһ-вах итеп, Мисырга якынлаштык.* (К. Нас.) 2) Начар. — *п. прил.* 1) Вынужденный, находящийся в безвыходном положении, беспомощный. 2) Поневоле. 3) Плохой; плохо.

**Начиз** ناچيز *ф. с.* 1) Берни дә тормый торган. 2) Әһәмиятсез, игътибарсыз. 3) Юк ителгән, харап ителгән. — *п. прил.* 1) Негодный. 2) Пустячный, ничтожный. 3) Уничтоженный.

*Аксак тимер Болгарны..., начиз вә набуд әйләде.* (Х. Мөсл.)

**Начизанә** ناچيزانه *ф. р.* Гаҗизанә, баш иеп, түбәнчелек белән. — *п. н.* Покорно, смиренно.

**Нашад** ناشاد *ф. с.* Шат түгел, кәефсез. — *п. прил.* Грустный, невесёлый, скучный.

**Нашаян** ناشايان *ф. с.* Ягымсыз, яраксыз, лаек түгел. — *п. прил.* Неудобный, нестоящий.

**Наши** ناشى *сф.* ...-дән барлыкка килгән; ...-дән барлыкка киләрәк. *Нәфисәнең артык көлүдән наши эченә катулар чыкты.* (Ф. Әмир.) — *пр. д.* Происходящий, рождающийся.

**Нашинас** ناشناس *ф. с.* 1) Белмәүче; мәгълүматсыз, белексез. 2) Билгесез. — *п. прил.* 1) Неведающий, несведущий. 2) Неизвестный.

**Нашир*** ناشر *сф.* Таратучы, матбугат бастырып таратучы. *Дөньяда булган кеби язганнарыңның нашире, монда да кортлар синең үлгән тәнеңнең „нашир"е* (Г. Тук.) — *пр. д.* 1) Распространяющий, публикующий. 2) Издатель.

**Наширин** ناشرين *ф. с.* Тәмсез, татлы түгел. — *п. прил.* Несладкий, невкусный.

**Нашәкиб** ناشكيب *ф. с.* Сабырсыз, чыдамсыз. — *п. прил.* 1. Нетерпеливый. 2. Нетерпеливо.

**Наяб** ناياب *ф. с.* Сирәк очрый торган, сирәк була торган, бердәнбер. — *п. прил.* Ненаходимый; редкий, уникальный.

**Наәһел** نااهل *гф. Әст.* һел түгел, теге яки бу эшнең чын иясе (кешесе) түгел. — *ар.-п. сс.* Не специалист какого-либо дела.

**Наөмид** نااميد *ф. ст.* Өметсез, өмете киселгән, нәүмиз. *Харисны билә наөмид кайтарып җибәрдем, ни йөзем белән кире чакырыйм.* (К. Нас.) — *п. сс.* Безнадёжный, обескураженный; пришедший в отчаяние.

**Наҗи** ناجى *сф.* Котылган, котылучы. — *пр. д.* Спасающийся, избегающий.

**Наҗия** ناجيه *сф.* Наҗи-нең *мнс.* — *жен.* от нажи.

**Нигам** نعم *ис.* Нигъмәт-нең *к.* — *сущ. мн.* от нигъмәт.

**Нигъмәт*** نعمت *ис.* Муллык; мул тормыш өчен кирәкле әйберләр, байлык; ашамлык-эчемлек. *Җир йөзе җәннәт иде, дәүләт вә нигъмәт бар иде.* (Г. Тук.) — *сущ.* Благоденствие, довольство, благополучие.

**Нигяр** نگار *ф. ис.* 1) Рәсем, сурәт. 2) *күч.* Пот, санәм. — *п. сущ.* 1) Картина, изображение. 2) *перен.* Кумир, идол.

**Нигярханә** نگارخانه *ф. ис.* Рәсемнәр (таштан ясалган сурәтләр) белән бизәлгән йорт, галерея. — *п. сущ.* Картинная, скульптурная галерея.

**Нигяһ** نگاه *ф. ис.* Карау, караш. — *п. сущ.* Взгляд, взор.

**Нида** ندا *ис.* 1) Өндәү, чакыру, тавыш. 2) Хөкүмәт карарларын халыкка кычкырып йөреп белдерү. 3) *грам.* Эндәш билгесе. 4) Зар-ыңгырашу тавышы. *Кара тупрак тулы мазлум нидасы.* (Дәрд.) — *сущ.* 1) Клич, призыв. 2) Воззвание, обращение. 3) *грам.* Восклицательный знак. 4) Стон, стенание, жалоба.

**Низ** نيز *ф.* Шулай ук. *Сәлям вирсә, сәлямын алмагыз низ.* (Ут. Им.) — *п.* Так же, тоже.

**Низаг*** نزاع *м. III.* Ызгыш, талаш, гауга. — *м. III.* Спор, распря, конфликт.

**Низам** نظام *м. III.* Тәртип, кагыйдә, канун, режим, устав. *Инкяр кылсаң, низам гыйндендә хәлас булуың шөбһәсездер.* (З. Биг.) — *м. III.* Порядок, строй; система, режим, регламент, устав.

**Низамат** نظامات Низам-ның *к.* — *мн.* от низам.

**Низамнамә** نظامنامه *гф. ст.* Бер мәсьәләгә карата язылган закон, кагыйдәләр җыентыгы. — *ар.-п. сс.* Устав, регламент, кодекс законов.

**Низамән** نظاماً *р.* Тәртипле рәвештә, закон буенча. *Шәрган вә низамән мәмнуг улган нәрсә.* (Ш. ж.) — *н.* Регулярно, законно.

**Ник (никү)** نيك،نيكو *ф. с.* Яхшы, хуш, гүзәл, матур. *Җиһанда ник, багның гөле ирдем* (Сайяди). — *п. прил.* Хороший, добрый.

**Никаб** نقاب *м. III.* Пәрдә, пәрәнҗә, йөз пәрдәсе, битлек. *Ач никабыңны йөзеңнән, парласын руе зәмин.* (Г. Тук.) — *м. III.* Покрывало, паранджа, вуаль.

**Никбин** نيكبين *ф. с.* Бәхетле, рәхәт яшәүче. *Толстой һәм Әхмәтмидхәт һәр икесе... никбин иделәр.* (Р. Фәх.) — *п. прил.* Счастливый, благоденствующий.

**Ник зат** نيك ذات *ф. с.* Намуслы, турылыклы, вөҗданлы (кеше). *Әйде кызы: и атам сән ник зат.* (Мөхм.) — *п. прил.* Благородный.

**Ник нам** نيكنام *ф. с.* Яхшылык белән даны чыккан, яхшылыгы танылган (кеше). *Булса бир сән мәңа, и ник нам.* (Мөхм.) — *п. прил.* Славный, прославленный.

**Ник нә арам** نيكنه‌آرام *ф. ст.* Яхшы характер, әйбәт холык. *Гыйшык ара* — *п. сс.* Хорошего характера, доброго нрава.